# АМИРХАН ЕНИКИ

СОЧИНЕНИЯ
в пяти томах

2

*Повести*

Казань
Татарское книжное издательство
2001

# ӘМИРХАН ЕНИКИ

ӘСӘРЛӘР
биш томда

2

*Повестьлар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2001

ББК 84 (2 Рос = Тат)-44
Е56

**Редколлегия:**

*З. Р. Вәлиева, Р. М. Миңнуллин, Ф. Г. Галимуллин, Д. С. Шакиров, Х. Г. Әюпов, Т. А. Миңнуллин, М. Х. Вәлиев, Н. С. Фәттах, Н. Т. Ильясова.*

**Еники Әмирхан**

Е56 Әсәрләр, биш томда, 2 том: Повестьлар.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.— 447 б.

Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники биштомлыгының бу китабына «Уяну» («Рәхмәт, иптәшләр!»), «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә» повестьлары кертелде.

ISBN 5-298-01009-1 © Татарстан китап нәшрияты, 2001

# УЯНУ

(Рәхмәт, иптәшләр!)

# I

Яз килә, сугыштан соңгы бишенче яз килә.

Әгәр кеше һәртөрле мәшәкатьләрдән бер генә минутка тукталып уйланса, исе китәр иде: чыннан да, бу бишенче язмыни? Дәһшәтле сугыш беткәнгә шулай ук биш ел узып киттемени? Һай, гомер, гомер!

Ләкин тукталу юк, бер генә минутка да артка борылып, шаккатып тору юк. Һаман алга карап ашыгу, һаман ашкыну... Вакыйгалар бер-берсен кысрыклый, эшләр берсе өстенә берсе өстәлә, һәр яңа көн белән ни дә булса туа, ни дә булса арта бара. Бөтен ил, бөтен халык өчен генә түгел, һәрбер шәһәр, һәрбер авыл, һәрбер кеше өчен бу шулай. Бу, билгеле, Яуширмә авылы, Ямашев исемендәге колхоз кешеләре, шул исәптән аларның терлекчелек фермасы мөдире Нургали Миңгалиев өчен дә шулай иде.

Яз исә болай да кызу аккан тормышка аеруча бер дәрт, аеруча бер ашкыну кертеп җибәрә. Гүя кояш кешеләрне үзе белән ярышка чакыра. «Өлгерегез минем арттан!» — ди ул һәм үзенең хуҗалыгы — табигатьтә һәр көн искитәрлек эшләр актарып ташлый. Аның кодрәте белән кырларда карлар ашыгып эри, түбә җирләр көннән-көн ачыла бара, тау битләреннән беренче гөрләвекләр шаулап чокырларга төшәләр, елгалар бүртә, бозлар күтәрелә, юллар өзелә, җылы яклардан төрле кошлар бер-бер артлы килеп җитәләр, урманнар зәңгәрләнә, бөтен җанлы-җансыз табигатьтә уяну башлана, һәм менә көнгә караган тау битендә, иң беренче яшеллек булып, күзне иркәләгән беренче үлән дә калкып чыга...

Әйе, яз килә, кояш ашыктыра, көннәр һаман санаулыга кала бара, һәм Ямашев колхозының кешеләре дә язгы чәчүгә өлгерер өчен кояштан да битәр ашыгыбрак, дәррәүрәк эшләргә тырышалар иде. Колхозның тимерчелегендә, амбарларында, ат абзарларында, бригадаларның хуҗалык лапасларында иртәдән кичкә кадәр халык кайнаша, бертуктаусыз эш кайный.

Нәкъ шундый ук хәлне Нургали фермасында да күзәтергә мөмкин иде. Яз биредә аеруча бер тынгысыз хәрәкәт тудыра, ыгы-зыгы көчәя, эш арта. Терлек — җан иясе. Аның табигатендәге күп нәрсәләрнең уянуы һәм үзгәрүе турыдан-туры яз белән бәйләнгән. Язын ул үрчи, язын ул бала тәрбияли башлый, язын ул арыклана. Билгеле, мондый тере җаннар белән эш иткән кешеләрнең мәшәкать борчылулары да яз көне бермә-бер арта.

Бүген мартның егерме икенче числосы. Нургали иртә караңгыдан фермада аяк өстендә. Күпме эш, күпме сүз, күпме борчылу! Ферма зур, терлек ишле, көн дә диярлек берәр сыер бозауламыйча калмый, көн дә өч-дүрт сарык бәрәнли... Көн дә күпме салам ташырга, күпме азык эшкәртергә, күпме су китерергә, күпме тирес чыгарырга кирәк. Бүген таңда бозауларга торган сыерларны сакларга, бозаулаганнарның хәлен белеп торырга, сарыклар һәм дуңгызлар арасында андый-мондый чир чыгуга каршы алдан тиешле чараларны күрергә, бигрәк тә яшь үрчемнәрне күз алмасыдай сакларга кирәк. Дөрес, бу эшләрнең барысы өчен дә куелган кешеләр бар, һәркем үз урынында, үз эшен белә, бер үк кагыйдә, бер үк тәртип буенча эш агып кына тора. Ләкин терлекләрнең саны эресе-вагы белән мең ярым баштан артып киткән шундый зур ферма җитәкче кеше күзеннән башка бер генә көн, бер генә сәгать тора аламы соң?.. Әлбәттә, юк. Бигрәк тә җитәкче дигәнебез Нургали кебек үзен аямый торган тынгысыз бер кеше булса, ул бер генә минут та тыныч утырып тора алмаса, һәм шуңа карамастан көн дә ерып чыга алмаслык авырлыклар бер-бер артлы туып торса — биредә инде ферма мөдиренә бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы, утлы табада биегәндәй, абзарлар арасында бәргәләнеп йөрмичә, кырык урынга өлгермичә туры килми.

Ә авырлыклар бар алар. Менә хәзер Нургалинең тәкатен корыткан нәрсә — азык кытлыгы. Һәр язын кабатлана бу каһәр суккан кытлык. Дөрес, соңгы дүрт ел эчендә Нургали бик күп авырлыкларны җиңеп чыкты, шул исәптән ферманың азык хәлен дә шактый җиңеләйтте, һәрхәлдә, саламнан һәм силостан өзелмәс булды. Әмма шулай да азык мәсьәләсе Нургали теләгәнчә (дөресрәге, терлекләр теләгәнчә) үк ителүдән ерак иде әле. Әлбәттә, бу хәлнең бер Нургалидән генә тормаган сәбәпләре бар: малларның саны елдан-ел арта, колхозның җире күп булса да, болынлыгы аз, терлекләр өчен үлән һәм тамыразык чәчү эшенә соңгы ике елда гына керештеләр. Ләкин абзарлардан үткән чакта сыерларың

синең арттан мөгрәп, сарыкларың иреннәрен кыймылдатып, кулыңа үрелеп калсалар, ул сәбәпләрдән ни юаныч!.. Нургали аларга тәмле печән, көрпә, чөгендер бирәсе урында, юкның сәбәпләрен аңлатып, акыл сатып тора алмый. Әле дә хайван дигәнең, бичара, чыдам: бирсәң — ашый, бирмәсәң — якаңа ябышмый. Юк, теш белән тартып чишә алмаслык бер чи төен булды бу азык мәсьәләсе... Үч иткәндәй, иң кирәк азыклар кыш ахырында, терлекләр ишелеп үрчегән чакта гына бетеп китә бит. Бу рәхимсез кышны бер ай ярымга гына кыскартып булса иде, ичмасам!

Бүген дә Нургали, иртә караңгыдан шул азык кайгысында йөреп, менә хәзер генә ферма өенә кайтып керде. Ферма өендә берәү дә юк иде; хисапчы Ләбибә иртәнге сөтне май заводына илтә киткәндер, ә савыт-сабалар юучы Зәйтүнә каядыр чыккан булса кирәк. Ләкин өй эче ялт итеп тора. Кызлар идәнне, стена буендагы эскәмияләрне, бүлмә уртасында ике тимер аяк өстендә торган тимер кыршаулы таза имән май язгычын һәм ишек төбенә якынрак идәнгә беркетелгән, кеше биеклек зур, зәңгәр төстәге «Урал» сепараторын юып, чистартып куйганнар. Шүрлекләрдә кибәргә тезгән эреле-ваклы савыт-сабалар, сепараторның сүтеп алынмалы вак-төяк алюмин өлешләре елтырашып торалар. Килеп керүгә бөтен өй эченнән һәм җиһазлардан таза, чиста дым исе аңкый... Стенадагы яңа сәгатьнең келт-келт йөргәне ишетелеп тора: ул вакытның инде беренче ярты булуын күрсәтә.

Нургали, юыла-юыла саргаеп беткән өстәл артына утырып, тунын чишәргә, бүреген салып, «Спорт» папиросын кабызырга өлгермәде, аның кайтуын гына күзәтеп торган шикелле, артыннан ук сыер савучы Кәримә килеп керде. Кыз ак итәкле зәңгәр алъяпкыч өстеннән кара тышлы кыска сырма кигән, башына ак яулык өстеннән арзанлы соры шәл бәйләгән, аякларында җыйнак кына күн итекләр. Ишектән кергәч тә ул стена буендагы тар эскәмиягә утырды, ләкин Нургалигә бер сүз дә дәшмәде. Хәер, ул дәшмәсә дә, Нургали аның ни өчен килүен бик яхшы белеп тора: һаман шул азык инде, азык!..

Дөрес, Кәримә юкка гына кеше борчып йөрүче кыз түгел ул. Әгәр килгән икән инде һәм ничек итеп сүз башларга белмичә утыра икән — димәк, хәле авырдан булырга тиеш. Шулай да Нургали үзе дә сүз башларга ашыкмады. Ул, тирә-ягын төтен белән тутырып һәм күзләрен кыса төшеп, Кәримәгә шактый озак карап торды. Бу җиткән кыз аның иң алдынгы, иң эшлекле сыер

савучысы иде. Башта ул бозаулар карады. Сыер савучылардан бер яшь кыз укырга китеп баргач, Нургали Кәримәне шуның урынына күчерде. Ә ул кыздан калган сыерлар арасында «Алма» кушаматлы холмогор нәселеннән бер сыер бар иде. Ләкин нәселе шәп булса да, картрак булганга күрәме, бу сыер теге кыз кулында көненә җидесигез литрдан артык сөт бирми иде. Кәримә менә шул сыерның көнлек сөтен беренче айда ук унике литрга җиткерде. Аннан тора-бара ундүрт-унбиш, ниһаять, егерме литрга чаклы күтәрде. Дөресе, ул үзенә беркетелгән башка вак сыерларның да сөт бирешен азмы-күпме арттыра алды, ләкин мөмкинлеге булган сыердан инде ул сөтне ала белгәнлеген ферма кешеләренә ачык күрсәтте.

Кайчандыр авылда малларны корчаңгыдан дәвалап йөргән, соңыннан кыска сроклы курслар бетереп, ферманың ветсанитары булып киткән Галләм абзый чын соклану белән аңа:

— Һай, кызым, кулларың синең сыер имие тотар өчен генә яралган икән,— диде.

Әмма хикмәт бер яхшы кулларда гына түгел иде. Кәримәнең сыерларга мөгамәләсе йомшак, җылы, каравы акыл белән, тәрбиясе дөрес иде. Ә хайван дигәнең кешенең мөгамәләсен бик яхшы тоя белә ул!..

«Алма» белән булган хәлдән соң, Кәримәнең исеме бик тиз колхозчылар теленә керде. Мактап сөйләүчеләр күп булган кебек, көнләшүдән аның уңышларын юкка чыгарырга тырышып сөйләнүчеләр дә булмады түгел, булды. Хәтта аңа үзе белән бергә эшләүче кайбер сыер савучыларның кырын карашларын һәм усал сүзләрен дә күтәрергә туры килде. Инде кыз кешенең намусын аеруча рәнҗетә торган гайбәтне — янәсе, ферма өчен түгел, ә Нургали абыйсына ярар өчен тырыша, дигән әшәке сүзне ишеткәч, ул гарьлегеннән ачы күз яшьләре белән елады, ләкин моны берәү дә белмәде. Һәм ул үз эшен эшли бирде.

Сыер карау, сыер саву эше Кәримәне башта ук тирән борчылу-газапка дучар итте. Сыерның сөте «тел очында» булуы һәм яхшы азык җитмәү аркасында сыерларыннан алырга мөмкин булган сөтне алып бетерә алмавы аның өчен һич сер түгел иде. Шуңа күрә дә безнең Кәримәбез күп вакыт, бигрәк тә яз айлары җиткәч, ниндидер бер эчке сызлавыгы бар кеше шикелле, һаман кашларын җыерып, чыраен сытып, сүзсез йөри иде. Әйе, азык кытлыгын сыер савучыдан да авыр кичерүче буламы соң?!

Менә шул аз сүзле сабыр кызга Нургали шактый озак карап торды. Кинәт аның йөрәге кызны кызганудан авыртып кысылды. Әйе, кызның азык җитмәү аркасында авыр хәлдә калуын түгел, ә аның үзен шулай сыкранып кызганды ул... Бу җиткән кыз егерме алтынчы яше белән бара инде, ә һаман да әле үзенә иш табып кияүгә чыга алганы юк. Рәхимсез сугышның кешеләр башына китергән, телдән сөйләнмәгән, ләкин кичерүе гаять авыр булган олы фаҗигасе иде бу... Күпме өмет, күпме ялкын аның йөрәгендә кабынып сүнмәгәндер. Ә нинди яхшы хатын, нинди иркә ана булмас иде бу тыйнак кыз!.. Карар күзгә сөйкемле ул, буе-сыны килешле, йөзе чиста, дөрес, нәкъ чигә сөяге өстендә битен нәрсәгәдер эләктереп ертудан калган җөй эзе бар, ләкин ул зарарсыз, аз гына беленеп тора... Аның каравы, кызның озын керфекле кара күзләре бик матур иде: сирәк күтәрелеп карый торган бу оялчан күзләрнең төбендә кешенең йөрәгенә кагылып китә торган ниндидер бер моңсу сагыш белән бергә бик яшерен кыюсыз дәрт чаткысы чагыла...

Әнә шундый сөйкемле һәм үзенә карата әнә шундый җылы тойгы кузгатучы бер кыз иде ул Кәримә.

Ниһаять, Нургали тартып беткән папиросын көл савыты урынына куелган чынаяк тәлинкәсенә басып сүндерде дә, сүзне башлар өчен, акрын гына дәште:

— «Алма»ның кәефе ничек соң?

— Ярыйсы кебек...

— Ни өчен «кебек» кенә?

— Саламны ашамый, иске баздагы силосны бирергә ярамый үзенә...

Бераз тынып тордылар, аннан Нургали:

— Әйе,— дип авыр көрсенеп куйды.

— Нургали абый, нигә яңа базны ачтырмыйсың, бүген таңда бозауларга торган сыерга сөрсегән силос биреп булмый бит.

— Беләм, акыллым, ләкин бер «Алма» өчен генә яңа баз ачтырып булмый шул... Барысы да шуннан ташый башларлар, ә ул безнең соңгы базыбыз. Сөрсегән булса да искесен бетерергә кирәк.

— Көрпә булса, һич югы, җылы су белән генә бутап бирер идем дә бит... үземдә дә бетте шул,— диде Кәримә, гаепле кеше сыман алдына гына карап.

Нургали белә, бу кыз сыерларының күңелен күрер өчен һәр көн диярлек бер-ике генә телем булса да куенына икмәк кыстырып килә иде... Кинәт аңа үзенең фермасы өчен гаять кыен, оят булып китте. Әйе, әйтәсе дә юк, аяныч хәл!.. Һәм ул ничек тә кызны юатырга теләде.

— Көрпә булачак, Кәримә акыллым!

Кыз тиз үк Нургалигә күтәрелеп карады.

— Кайчан соң, Нургали абый?

— Кайчанмы? Түбән тегермәнгә бүген ике тонна бөртек озаттык, иртәгә булмаса да, берсекөнгә кайтып җитәрләр.

Кәримә, күкрәге өстенә салынган шәл очын кулы белән бөтәрләп, бераз дәшми торды.

— «Алма» бүген төннән дә калмыйча бозаулар инде, Ходаем,— диде ул, үзалдына гына әйткәндәй.— Бераз хәл кертәсе иде үзенә.

— Синең «Алма»ңа көрпәне мин бүген үк табам.

Һәм Нургали кисәк кенә урыныннан торды. Кыз исә рәхмәт тулы күзләрен Нургалидән алмыйча һәм кузгалырга кыймыйча утыра бирде. Ләкин Нургали, нидер исенә төшкәндәй, кашларын җыерып кире урынына утырды.

— Син хәзер генә минем янга Зәйтүнәне табып җибәр әле. Ул сиңа китереп бирер.

— Үзем генә барыйм, Нургали абый,— диде кыз, кая һәм кемгә барасын белмәстән.

— Зәйтүнә генә барыр, акыллым. Син «Алма»ң янында бул! Инде болай да...

Кәримә, башка сүз кайтарып тормыйча, җәһәт кенә урыныннан кузгалып, чыгып китте. Ул чыгып киткәч тә, Нургали хатыны Миңсылуга, Зәйтүнә артыннан бер чиләк көрпә биреп җибәрергә кушып, записка язды. Миңсылу, әлбәттә, сукраначак инде, шуңа күрә үзе кайтып килмәкче булган иде, ләкин бүген алда торган зур бер эш исенә төште дә ул тукталып калды.

Ферма өендә эшләүче Зәйтүнә каядыр якын гына булган, күрәсең, шунда ук килеп тә керде. Бу ак чәчле, ак кашлы, ак керфекле тулы, түгәрәк кыз бик җиңел сөякле булырга охшый иде. Йөргәндә генә түгел, тик торганда да аның алъяпкыч күкрәкчәсенә сыймас түшләре һәм симез гәүдәсе тибрәнеп тора кебек, ә борылганда-ниткәндә, йомры иңбашлары уйнаклап, аркасындагы тәңкә чулпылары чылтырап-чылтырап китә иде.

Ул керүгә ак оек өстеннән кигән резин галошларын ишек төбендә салды да ашыгып Нургали каршысына атлады.

— Мин кирәк булдыммы, Нургали абый? — диде ул, ягымлы нечкә тавыш белән.

— Кирәк булдың шул, Зәйтүнәкәй... Менә бу язу белән Миңсылу апаңа бар әле. Кәримә сыерына көрпә китерерсең.

— Хәзер үкме?

— Хәзер үк. Капчык алырга онытма.

— Ярый, ярый, Нургали абый, җаным, онытмам. Бер аягым анда, бер аягым монда булыр.

Һәм йөрүдән, туктаусыз хәрәкәттән үзенә бер ләззәт табучы уңган кыз Зәйтүнә чөйдән сырмасын эләктереп алды да чыгып та китте.

Нургалине кашларын җыерып кире урынына утырырга мәҗбүр иткән эш исә — авыл советының бүген сәгать икедә булачак сессиясе иде. Чыннан да, Нургали Яуширмә авыл советының менә хәзер, колхоз язгы чәчүгә әзерлек белән әвәрә килгән бер чакта, терлекчелеккә багышлап махсус сессия чакыруын һич аңлый алмый иде. Сүз юк, терлекчелек бик зур эш, бик мөһим мәсьәлә, ләкин аны кузгатыр вакыт менә хәзерме соң? Авыл советы председателе Закир Сөләйманов аңа:

— Нургали абый, ферманың турында доклад ясарга әзерлән, якын көннәрдә авыл советы сессиясендә сине тыңлыйбыз,— дигәч, аны-моны уйлап тормастан, берсүзсез риза булган иде. Нинди сессия ул, нигә вакытлы-вакытсыз ферма турында сүз кузгатасыз, башка куяр мәсьәләгез юкмыни, дип сорашып та тормады. Рәхим ит! Нургали ферма турында отчет бирергә һәрвакыт әзер. Теләсә кайда, теләсә кем алдында... Эше чиста, намусы пакь аның, беркемнән дә куркып торасы юк...

Ләкин тора-бара ул булачак сессия турында борчылып уйлана башлады. Авыл советының бу чарасы аңа ничектер кирәкле һәм вакытлы бер эш булып тоелмый иде. «Чыннан да, ни өчен әле Сөләйманов язгы чәчүгә кызу әзерлек барган көннәрдә терлекчелек мәсьәләсен күтәреп чыга, сессияләр чакырып, докладлар куя? — дип баш ватты ул.— Район каршында бик шәп булып күренәсе киләме аның? Алай бик макталасың килә икән, әнә мая тупла — синең эш бит ул. Инде бик уңган булып, колхозга да булышыйм, дисең икән — әнә чәчүлек хәле белән кызыксын, ашламалар туплауны ашыктыр, атларны ялга кую турында кайгырт, чәчү коралларына ремонт ничек бара — шуны күзәт... Ә син, кешеләр хәзер ике аякны бер кунычка тыгарга йөргән чакта, фермага тотынасың. Әйтерсең аның өчен башка вакыт табылмас иде... Юк, тикмәгә түгелдер бу, астыртын берәр ният белән булмагае иде бу...»

Табигый, Нургалинең болай уйлавы бөтенләй үк нигезсез түгел иде. Сугыш елларында гына үсеп, күтәрелеп киткән яшь авыл советы председателе Закир Сөләймановны яратып бетерми иде ул. Шуның өстенә ни өчендер аңардан һаман шикләнеп тә йөри иде; гүя бу яшь егет бер килеп аңа һәм аның кебек иске ра-

ботникларга: «Агайлар, җитте сезгә аяк астында буталырга, яшьләргә юл бирегез!» — дип әйтер төсле иде. Һәрхәлдә, тора-бара башына берәр бәхетсезлек төшсә, сәбәпчесе шул егет булыр, дигән уй Нургалинең күңел төбендә яшәп килә иде.

Бу яратып бетермәүнең һәм шулай шикләнеп карауның сәбәбе нидә соң?

Билгеле, Нургалинең мондый сорауны үзалдына куйганы да юк, куйса да, ихтимал, дөрес җавабын тапмас иде. Сәбәп, әлбәттә, аларның яшь ягыннан аермалары зур булуда гына түгел иде. Бөтен үткән тормышлары һәм характерлары белән алар башка кешеләр иде. Чыннан да, Нургали Миңгалиев кем дә, Закир Сөләйманов кем?

Нургалинең бөтен гомере туган колхозында үтте, туган колхозының тарихы белән бергә үрелеп үсте, шунда ул кеше булды, дәрәҗә иясе булды. Әле егерме яшьлек егет чагында ул үз авылларын колхозлаштыру эшенә бик актив катнашып йөрде һәм колхоз оешкан көннән башлап диярлек аның җитәкче кешеләреннән берсе булып килде. Сугышка кадәр ул йә кырчылык бригадиры, йә төзү эшләре бригадиры, йә завхоз, йә председатель урынбасары булып эшләде. Колхозның идарә составына беркайчан да сайланмыйча калган чагы булмады. Сугыштан соң исә аны, фронттан кайтуы белән, колхозчылар ферма башына куйдылар... Кыскасы, Ямашев исемендәге колхозда аның катнашы булмаган, аның кул көче кермәгән бер генә эш тә юк иде. Шуңа күрә дә Нургали үзен, бик хаклы рәвештә, туган колхозына бөтен тормышын, йөрәген-дәртен «мә!» дип ике куллап биргән бер кеше итеп саный иде.

Шуның өстенә ул характеры белән гаять тынгысыз, үзен һич айый белми торган, эш дигәндә беткәнче яна торган бер кеше иде. Колхозчылар аның бу характерын бик яхшы беләләр һәм берәр терәлеп торган эш чыкса, тизрәк Нургалине шул эшкә димлиләр иде. «Нургалигә кулай эш бу, Нургали генә кузгатып җибәрсә җибәрер аны...» — ди торганнар иде алар. Һәм Нургали, киерелеп тарта торган ат шикелле, андый эшне кузгатып алып китә иде. Сугыштан кайтып ферма мөдире булгач та ул, үзе әйтмешли, фашистларны кыйнап-кыйнап та чыгып бетмәгән ярсу белән колхоз терлекчелеген аякка бастыру эшенә кереште. Йокы дип тормады, аш дип тормады, көн-төн фермадан кайтмыйча ятты, әмма колхоз фермасын җан көйдергеч кызганыч хәлдән чыгарып, кеше күзенә күрсәтерлек рәткә кертте. Әйе, Нургалинең, әгәр

теләсә, үткән эшләре белән масаерга да, горурланырга да хакы бар.

Закир Сөләймановның исә, билгеле, мондый бай үткәне юк. Колхозлашу елларында ул әле ертык түбәле эшләпә киеп, бозау көтеп йөрүче бер малай гына иде. Малайның да борча кебек чәчрәп торганы түгел, ә бик басынкы, юашы гына иде. Дөрес, Мәстүрә исемле бер тол җиңгинең җыен кыз балалары арасында бер ир бала булганга күрә, ул бик яшьли колхоз эшенә йөри башлады. Язгы чәчү өстендә ара-тирә тырмага чыккалый иде, печән чапканда хатын-кызлар тирәсендә чүмәлә тарттырып йөри иде, ашлык суккан чакларда ындырда салам тарттыра иде. Бер үк вакытта кызганырга да, мактарга да һәвәс булган йомшак күңелле апайлар бу дәшми-тынмый үзалдына тыныч кына эшләп йөргән ак чырайлы арык малайга карап: «Менә нинди акыллы бит ул безнең Закир, Мәстүрәнең бәхете инде, гомере генә була күрсен!» — ди торганнар иде.

Менә шул бала, кеше күзенә артык чалынмыйча гына, кай арададыр үсеп җитеп, утыз сигезенче елны үз авылларының җидееллык мәктәбен бетерде һәм, укытучыларының киңәше белән булса кирәк, Казанга элемтә техникумына укырга китәргә җыена башлады. Ләкин ятимнең борыны бер ашка тисә, бер канга тия дигәндәй, шул ук елның җәендә ул элеваторга ашлык илтә барышлый, машинадан егылып төшеп, билен имгәтте... Бик озак авырды ул, кыш буе диярлек Казанның бер клиникасында дәваланып ятты, ятып чыкканнан соң да, елдан артык биленә корсет бәйләп, таякка таянып кына йөрде...

Үзенең, үзеннән дә битәр бичара әнисенең бу бәхетсезлекне никадәр авыр кичерүләрен әйтеп торасы да юк. Шулай да егет тора-бара сәламәтләнде, буе-сыны әүвәлгечә туры булып калды. Ләкин билдән югарырак ике умыртка сөяге, кул белән капшасаң, сизелерлек булып кына бүлтәеп чыгып тора иде. Нәтиҗәдә, ул авыр йөк күтәрү эшенә һәм солдат хезмәтенә ярамас булып калды.

Бөек Ватан сугышы башланды. Авылның барлык таза ирләре, шул исәптән колхозның барлык җитәкче кешеләре илне якларга киттеләр. Закир исә инвалид булып авылда калды.

Сугышның беренче көненнән үк аны төрле җиргә тарткалап, төрле эшкә куша башладылар. Башта аны кем китеп барса, шуның урынына куеп алҗыттылар. Кыска гына вакыт эчендә ул хисапчы да, завхоз да, хәтта бригадир да булып алды. Аннан көннәрдән бер көнне аны,

һич уйламаганда, районга чакыртып алдылар да райкомол аппаратына эшкә куйдылар. Штат буенча учет мөдире генә булып исәпләнсә дә, аңа бушап калган райкомол аппаратында кем генә булып эшләргә туры килмәде... Күбрәк исә ул төрле хуҗалык кампанияләре үткәрер өчен көзге яңгырларда, кышкы суыкларда, язгы пычракларда, күбесенчә җәяүләп, авыллар гизеп йөрде... Шул чакта ул партиягә дә керде. Инде Ямашев исемендәге колхозның күптәнге председателе Шәйхи абзый да армиягә китеп баргач, аны тирән өзеклеккә төшә башлаган туган колхозына председатель итеп җибәрделәр.

Колхозда ел ярым эшләгәннән соң, кырык дүртенче елның башында, аны яңадан районга чакырып алдылар. Дөрес эшләү идеме бу, юкмы, әмма егетнең үз теләге белән артык хисаплашып тормыйча, аны бу юлы инде район партия комитетында пропагандист итеп эшләргә калдырдылар.

Сугыш бетеп, халык кайта башлаганда, ул шунда эшли иде. Кырык бишенче елның көзендә аны Казанга партия мәктәбенә укырга җибәрделәр... Сөләймановның күңелендә бер канәгатьләнеп бетмәгән теләк — үз авылында эшлисе килү теләге һаман сакланып йөри иде. Укуын бетереп кайткач, ул үзенең шул теләген район җитәкчеләренә белгертте. Район җитәкчеләре алдында исә сугыштан соң үткәреләчәк беренче сайлаулар вакытында җирле власть органнарын ныгытып калу кебек бик мөһим бер эш тора иде. Егеттән үз авылында эшлисе килүне ишеткәч, аңа Яуширмәгә кайтып, авыл советы председателе булырга тәкъдим иттеләр. Сөләйманов, халык каршы булмаса, мин риза, дип, авылына кайтып китте. Кырык җиденче елның кышында Яуширмә халкы аны үзләренең авыл советларына депутат итеп сайладылар. Шулай итеп, Закир Сөләйманов райондагы иң зур авыл советының председателе булды.

Менә аның кыскача гына эшчәнлек биографиясе шул. Күрәсез, бик гади, бер дә әллә ни юк, асылда, күптән түгел генә тормыш юлына аяк басып, шактый кыю, таза адымнар белән үзенең киләчәгенә таба атлап киткән бер яшь кеше ул... Халык та әле күбрәк аны, исем-фамилиясе белән атамыйча, «яшь председатель» дип кенә йөртә.

Йә, Нургали Миңгалиев шушы «бала каз»ны үзе белән тиң күрә аламы? Нургали бит, үзегез күрдегез, Ямашев колхозының ветеран эшлеклесе, егерме ел буенча шул колхозны, үзе әйтмешли, «төпкә җигелеп» тарткан кеше... Шуның өстенә ул Ватан сугышында илне кулы-

на корал тотып яклаган, ил өчен канын биргән һәм күкрәген орден-медальләр белән бизәп кайткан патриот солдат та... Ә Закир Сөләйманов? Кем ул, нишләгән ул? Нинди хезмәтләре белән мактана ала ул?

Нургали мондый сорауларны еш кына үзалдына куя һәм бик табигый куя, чөнки Сөләйманов аның күз алдында үсте, күтәрелде, бүгенге дәрәҗәгә иреште. Сугышка хәтле Закир ни яхшы, ни яман ягы белән телгә кермәгән йомыкый гына бер яшүсмер иде.

Инде сугыш вакытында күтәрелеп киткән икән, бу да бик аңлаешлы. Бар да сугышка китеп беткәч, кемгә дә булса күтәрелергә кирәк бит. Ул түгел, балалы хатыннар да монда дәрәҗә иясе булып беткәннәр. Әнә өч балалы Сәрвәр апаны да, алар кайтуга, районга алып, райсобес башына куйганнар. Әгәр Закир, алар урынына калып, сугыш беткәнче үз колхозында җиң сызганып эшләгән булса — бер хәер иде. Югыйсә анда ярты ел, монда бер ел эшләп, йә колхозда, йә районда, йә укуда йөреп гомер уздырган ич!

Юк, Нургали аны үзе белән һич тиң күрми, тиң күрмәү генә түгел, ул Сөләймановка сугыш вакытының уңайлы шартлары нәтиҗәсендә артык көч куймыйча, ансат кына күтәрелеп киткән бер кеше итеп карый. Билгеле, Нургали бу рәвешчә күтәрелүне гадел, хаклы күтәрелү дип танымый иде.

Табигый инде, үзе белән яшь егет арасында шундый тирән ызан үткәргәч, ул аны кеше итеп тә яратып бетерми иде. Ничектер ул аның басынкылыгын астыртынлык дип, бәйсез, тыныч булуын тәкәбберлек дип, оста сүз сөйләвен эшләргә яратмау дип күрергә гадәтләнгән иде. Гомумән, ул Сөләймановны үзенә капма-каршы характердагы яшерен, коры бер кеше итеп исәпли иде.

Шуның өстенә әле, җитмәсә, Нургалигә яшь председательнең, кемнең кем булуына карамыйча, туры әйтергә яратуын да берничә тапкыр үз җилкәсендә татып карарга туры килде. Бер шулай партия җыелышында Сөләйманов аны «үзе өстендә эшләмәүдә» гаепләп чыкты. Каты әйтте ул аңа шул чакта.

Икенче тапкыр идарә утырышында Сөләйманов ферма кешеләре арасында ярышның йомшак җәелдерелүен, ферма мөдиренең шундый мөһим эшкә «бармак аша гына каравын» тәнкыйть итеп чыкты. Бу юлы инде Нургали дәшми кала алмады. Яшь председательнең авызын каплау нияте белән ул, бик кызып, фермада социалистик ярыш барлыгын исбат итәргә тырышты.

Ләкин шактый уңышсыз... Сөләйманов шунда ук торып, бер дә кызганмыйча гына, аның социалистик ярыш дигәне күбрәк кәгазьдә генә булган бернәрсә икәнен, кешеләрнең көндәлек эшләрендә чагылмавын, бигрәк тә ярышның нәтиҗәләре һәрвакыт билгесез булып калуын әйтеп бирде. Һәм карарга да аның әйткәннәре язылып калды.

Шушы хәлләрдән соң инде Нургали Закир Сөләймановтан һәрвакыт шикләнеп йөри торган булды. Егет тәнкыйть белән бик мавыга, төпченергә ярата, кешенең дәрәҗәсе белән дә, яше белән дә хисаплашып тормый, һәм Нургали, яратмавын бер дә яшерергә тырышмыйча, үзен аның белән бик салкын тота башлады.

...Менә бүген авыл советы сессиясе, Нургали ферма өендә ялгызы, борын төбендәге күперенке кара мыегын имән һәм баш бармак битләре белән акрын гына сыпыра-сыпыра, сессиядә сөйләнәчәк доклады турында уйланып утыра. Мыек дигәннән, Нургали йөз сылулыгының бу яңа бизәген фронттан алып кайткан иде. Сугышка кадәр аның мыек үстереп караганы юк иде. Инде фронтта, күрсәткән батырлыклары белән бергә дәрәҗәсе дә үсә барып, старшина званиесен алгач, ул, башка гайрәтле старшиналардан калышмас өчен, кара мыек үстереп җибәрде, һәм кара мыек аның кыю, кайнар характерын тагы да көчәйтә төшкән бик кирәкле бернәрсә булып чыкты. Чыннан да, тулы кызыл иреннәр өстендә күпереп торган кара мыек аның туры борынлы, озынча карасу йөзенә бик килешә иде... Калын кара кашлар, бер ачылып, бер йомыла төшеп тынгысыз карый торган көрәнсу күзләр, маңгае өстенә алкаланып төшкән, аз гына чал йөгергән чем-кара чәч, әйтәсе дә юк, Нургалинең нинди чибәр ир һәм нинди ялкынлы йөрәк кешесе булуын бик ачык күрсәтеп торалар иде.

...Әйе, Нургали, мыегын ике бармак бите белән акрын гына сыпырып, сөйләячәк доклады турында уйлана. Ул моңарчы да озак уйланып йөргән иде. Ничек итеп сөйләргә? Бу турыда баш ваткан чакта, ихтыярсыздан, Сөләйманов аның исенә һаман төшә торды. Гүя ул докладын авыл советы депутатлары өчен түгел, аның председателе өчен генә әзерли иде. Ләкин аның бер дә Сөләймановка ошарга тырышып сөйлисе килми, шул ук вакытта, үзенә исәп бирмәстән, Сөләймановның бәйләнүеннән дә бераз шүрли иде. Башта ул колхоз терлекчелегенең тарихыннан тотынып, бүгенге хәлен тулы яктыртып һәм киләчәген сурәтләп бирмәкче булды. Ләкин уйлана торгач, бу ниятеннән кайтты. Аның,

Сөләйманов көткәнчә, сессиягә аеруча әһәмият биреп, бик зурдан кубасы килми иде. Нәрсә бирәчәк аңа ул сессия? Асылда бит бу Сөләймановның бер эш күрсәтергә маташып йөрүе генә... Шулай да Нургали, болай уйлауның ярап бетмәгәнлеген сизенеп һәм үз вөҗданы алдында акланырга тырышып, башкача да уйлап карады. Кемнәр алдында ул үзенең докладын сөйләячәк? Үз колхозчылары алдында ич! Ә алар колхоз фермасының үткәнен дә, хәзергесен дә, шулай ук киләчәген дә Нургалинең үзеннән бер дә ким белмиләр. Үткәне үткән инде аның, хәзергесе күз алдында, ә киләчәге турында һәркемгә билгеле булган терлекчелекне үстерүнең өчьеллык планы бар. Шулай булгач, артык җәелергә хаҗәт юк, киресенчә, аз сүз белән генә чикләнү яхшы булыр. Моның белән ул халык алдында үзенең, Сөләймановка караганда, сүздән битәр практик эш кешесе булуын оста гына итеп күрсәтер. Һәм Нургали сөйләячәк докладын бары ферманың бүгенге хәле белән генә чикләргә булды.

Көн төшлеккә җиткән иде инде, сессиягә барыр вакыт та якынлашты. Нургали тагын бер папирос кабызып, өстәлдән кәгазьләрен җыештырып алды да урыныннан кузгалды. Чыгып китәр алдыннан гына Сөләймановның бер үтенече аның исенә төште: яшь председатель аңа, ферма кешеләренең эштән буш булганнарын үзең белән ияртеп, сессиягә алып кил, дип әйткән иде. Шул турыда Нургали бик аз гына уйланып торды, аннан үз-үзенә:

— Халык җыеп йөрергә мин аңа йомышчы малай түгел! — диде дә, кулын селтәп, ишеккә юнәлде.

Ул тышка чыкканда, мартның аяз көнендә аеруча бер хөрлек сизеп йөзгән язгы кояш бөтен кырлар, бөтен авыл өстен дәртләнеп якты нурга коендыра иде. Нургали бер генә минутка тукталды. Ферма артындагы көнгә караган тау бите, пыяла вагы сибелгәндәй, күз явын алып бертуктаусыз җем-җем уйнаклап тора, тик тауның нәкъ маңгаенда анда-санда сарык тиресе чаклы гына кардан ачылган соры җир таплары күренә иде. Күзне кытыклаган нур чагылышы түгел, әнә шул җир таплары Нургалинең күңелен җилсетеп куйды. Тиздән, тиздән ул таплар зураер, тау бите тоташ ачылыр, беренче үлән төртеп чыгар. Ничек зарыгып көтә бит ул аны... Сарыклары аның, ичмасам, рәхәтләнеп бер җир иснәрләр иде!

Аннан ул ихата уртасындагы салам түбәле, озын, тәбәнәк сыерлар абзарына карады. Абзар кыегының нәкъ сырты өстеннән генә пар сыман яктылык көйри, ә кыек

читендәге саламнардан тамчылар, ычкынып киткән берсе чаткы шикелле кабынып, җиргә тамалар. Абзар алдында ферма кешеләре кайнаша. Аларга да бүген эссе булып киткән, күрәсең, әнә берсе тунын салып ишек башына ташлаган, әнә тагын сәнәк тоткан бер агай бүреген күтәреп-күтәреп башын җилләтә... Абзардан барлык сыерларны утарга* чыгарганнар. Олы сыерлар кояш җылысыннан рәхәтлеккә оеп, күзләрен йомып, башларын иеп, ялкау гына күшиләр. Бары таналар һәм яшь үгезләр генә бер урында тик кенә тора белмичә, карт сыерларның эчләрен пошырып, буталып йөриләр... Әнә авызында әле сөте дә кипмәгән бер үгез актыгы муенын сузып, бәбәген югары күтәреп, иреннәрен җыерып һава иснәгән була.

— Яз җитте, абзыкаем, яз! — диде Нургали үзалдына гына һәм кешеләр йөреп таптаудан тәмам эреп изрәгән сукмак буйлап таза адымнар белән ферманың киртә капкасына таба китте.

Капкадан чыгуга ул күлмәк-алъяпкычлары өстеннән кыска сырмалар кигән, кайсы шәл бәйләгән, кайсы яулык өстеннән бүрек кигән бер төркем хатын-кызның урам уртасыннан авыл советына таба китеп баруларын күрде. Болар, һичшиксез, сессиягә баручы ферма хатын-кызлары иде. Алар арасында кулларын артка куеп, бөкресен чыгара төшеп баручы бер озын буйлы, киң җилкәле ир кеше дә Нургали күзенә чалынды; бу Сөләймановның баҗасы фуражер Фәттах абзый иде. Аны күреп алгач, Нургалинең нигәдер йөзе караңгыланып, эче пошып китте. Бу күп сүзле, һаман ферма кешеләре арасында чуалучы өлкән яшьтәге абзыйны ул ни өчендер яратып бетерми иде. Председатель баҗасы аңа ничектер председательнең фермадагы яшерен күз-колагы шикелле булып күренә иде. Эчке бер канәгатьсезләнү белән ул үзалдына гына:

—...Ияргән икән, карт алаша! — дип куйды.— Хатыннар чабуына ябышып, колагын салындырып бармаса, юл тапмас иде шул!

Аның, билгеле, үз кешеләренә дә бераз кәефе кырылды: күңел өчен генә булса да кереп: «Әйдә, Нургали абый, киттек!» — дип әйтсәләр, ни була инде, дип уйлап алды ул.

---

*Терлекләрне һавада тотар өчен ферма ихатасында киртә белән уратып алынган урын утар дип атала.— *Ә.Е.*

# II

Ферма мөдире Нургали Миңгалиевнең доклады һәм өлкән ат караучы, депутат Вагыйз Гайнетдиновның терлекчелек комиссиясе исеменнән ясаган өстәмә докладын беткәч, сессиядә председательлек итүче Закир Сөләйманов аягүрә басып, ике кулы белән кызыл комач япкан өстәлгә җиңелчә таянып, җыелыш өстеннән сынаулы караш йөртеп чыкты. Бу утыз-утыз икеләр тирәсендәге яшь кеше үзенең бик төз юка гәүдәсе, дулкынланып артка яткан аксыл чәчле, елтырап торган киң маңгайлы, йомшак кылган шикелле сызылып киткән нечкә кашлы чиста йөзе белән башкалардан бик нык аерылып тора иде. Ул яхшы тәрбия күреп үскән интеллигент егетне хәтерләтә. Зур соры күзләре дә аның, үз дәрәҗәсен яхшы белгәндәй, бик тыныч, салкын, горур карыйлар. Хәтта аның өстенә берничә кат юылудан төсе уңган, ләкин әйбәтләп үтүкләгән, җиз төймәләре ялтырап торган гади солдат гимнастеркасын киң каеш белән кысып буып киюеннән үк бары бер пөхтәлек кенә түгел, ә ачык, эзлекле характерга ия булуы да сизелеп тора.

— Йә, иптәшләр, нигә тынып калдыгыз? — диде Сөләйманов, тыныч кына.— Мәсьәлә шулай бик ачык, сөйләп торасы юкмыни бер дә?

Әйе, Нургали исәбенчә, колхозның терлекчелек хәле һәркемгә ачык, халыкның болай тын утыруы бик табигый, гомумән, сүз күп булмаска тиеш.

Шулай да председательнең соравына каршы озын эскәмиянең башында стенага терәлеп кенә утырган ак тунлы, ак сакаллы, кечкенә буйлы Шакирҗан карт урыннан торды. Ул, рөхсәт-мазар сорап тормыйча, йомшак, акрын тавыш белән туры Нургалинең үзенә дәште:

— Карале, Нургали улым, сарыкларыгыз изүләрен чишә башлаганнар бит. Моны синең караучыларың күрәләрдер инде күрүен, тик куллары җитмиме шунда... Тал кайрысы ашатырга иде үзләренә, сарыкларга, мин әйтәм... Югыйсә йоннарын койрыкларына хәтле коеп бетермәгәйләре...

Шулай диде дә карт тынды, аз гына уйланып торды, аннан артына борылып, халыкка карап алды да кире урынына утырды. Шул арада аның ак сакаллы мөлаем йөзе кызарып өлгерде, күрәсең, ул зур җыелышта беренче башлап сүз әйтүеннән уңайсызланып китте. Сөләйманов, шуны сизгәндәй, картның бу кыска гына «чыгышын» куәтләп җибәрде:

— Дөрес әйттең, Шакирҗан бабай, шулай кимчелек-

ләрне күрсәтергә кирәк, алар аз түгел бит әле бездә... Йә, тагын кемгә сүз бирик, Шакирҗан бабай кебек кыю булыгыз, кыстатып тормагыз, иптәшләр!

Нургалигә Шакирҗан картның ике бөртек сүзе һәм, бигрәк тә шуны Сөләймановның эләктереп алуы бик сәер тоелды.

Сарыкларның йоннарын муеннарыннан коя башлаулары һәр язын була торган хәл, бер дә сессия кадәр сессиядә чыгып әйтерлек яңа нәрсә түгел... Инде аңа бик эчең поша икән, Нургалинең үзенә генә әйтеп булмыймыни? Безнең картлар бит яшьләргә урамда очраганда да файдалы киңәшләрен биреп китәргә яраталар. Юк, Нургали аңламады һәм ошатмады картның бу калкып куюын... Җитмәсә, Сөләйманов шуңа кинәнә, әйтерсең Шакирҗан карттан да акыллырак сүз әйтүче табылмас!

Әйе, табылыр дигән төсле, председатель җыелышны кыстый:

— Ягез, йә, иптәшләр, активрак булыгыз! Кемгә сүз бирдек?

Менә урыныннан өченче кырчылык бригадасының бригадиры, сыңар куллы Гашыйк абзый торды.

— Бирегә узыгыз, бирегә, Гашыйк абзый,— диде Сөләйманов, бу сөйләүчене аеруча хуплап каршы алгандай.— Сүз бригадир иптәш Җәләевкә бирелә.

Иптәш Җәләев, ягъни Гашыйк абзый, председатель өстәле янына ук килеп, сәламәт кулы белән тун төймәләрен чишеп җибәрде һәм, гадәтенчә, кара күзләре белән җыелыш өстенә туры, җитди карап, тавышын күтәрә төшеп сөйләргә кереште:

— Ел саен яз җиттеме, бездә азык кытлыгы башлана. Бу ни хәл бу, агайлар? Көздән барысы да бар, барысы да җитәр кебек... печәне дә, силосы да, бәрәңге-чөгендере дә, кибәге-көрпәсе дә, ә саламны әйтеп торасы да юк... Шул чакта малларны картына, яшенә, көренә, арыгына аерып, рацион төзеп ашата башлаган булабыз. Әйбәт, тыныч; тук сыерлар араннарында мышнап яталар. Нургали абзаң кулын артка куеп йөри бирә, Шәйхи абзаңның өстәл тартмасында ашъяулык кадәр баланс ята — анда бары да исәпләнгән, бары да җитәрлек. Менә бервакытны зәһәр кыш үтә, март керә, абзар ишек төпләренә сары сулар җыела башлый, маллар, кояшка чыгып, боек кына башларын иеп торалар, шул чакта баксаң — печәне дә беткән, көрпәсе дә беткән, бәрәңгесе дә бетеп килә, силосның да соңгы базын ачканнар... Инде көн саен бригадирларга кырдан кар баскан салам кибәннәрен ташырга наряд тоттыра башлыйлар. Давай салам да, давай салам!

Пожарга су ташыган шикелле салам ташыйбыз... Хәзер инде нәрсә ашатырга, күпме ашатырга — аны тикшереп тору юк. Тик бәрәкәтле салам гына җитсен! Йә, бу нигә ярый, иптәшләр? Маллар шундый котырып үрчегән бервакытта, аларны иң яхшы азыклар белән туйганчы сыйлый торган бер чакта кормасыз калу,— йә, бу безнең мәнсез булуыбызны, алдан күрә исәпләп, чамалап тота белмәвебезне күрсәтмиме соң?! Юк, җәмәгать, дөресен әйтим, без үзебезнең терлекчелек турында чынлап торып кайгыртмыйбыз әле, без малларыбызны фән кушканча карый да, ашата да белмибез әле!

Алгы рәттә тезләренә терсәкләрен салып иелеп утырган өлкән яшьләрдәге бер абзый, башын күтәрмичә генә:

— Йә, фән тагын... Көнең бер саламга калгач, фән турында ничек сөйләп торырга кирәк, кордаш?! — диде.

Амбар каравылчысы Хәйретдин картның салмак кына әйткән бу өметсез сүзләре Гашыйк абзыйны кабындырып җибәргәндәй итте.

— Анысы безнең үзебездән тора, кем, Хәйретдин абзый,— диде ул, дәшүчегә таба борылып һәм тавышын тагын да күтәрә төшеп.— Хикмәт бер саламга торып калмауда шул. Әгәр мин хәзер сезнең алда азык турында сөйлим икән, Вагыйз шикелле, бүген кайдан нәрсә табып булу турында түгел, ә киләсе елның, әйтик, язында азык белән бүгенге хәлгә төшмик, дип сөйлим.

— Дөрес сөйлисең, Гашыйк абзый! — диде Сөләйманов, учы белән акрын гына өстәлгә сугып.— Шулай алга карый белергә кирәк.

Бу реплика урынлы әйтелсә дә, Гашыйк абзый бераз таркала төште. Аз гына тотлыгып торып, ул бүленгән сүзен ялгап алып китте:

— Әйе, менә шул... Сабанда сайрашмасаң, ындырда ыңгырашырсың, дибез без еш кына. Борынгы сүз — хак сүз, ләкин нигә без аны азык хәзерләүгә килгәндә онытып җибәрәбез? Нургали безгә биредә терлекләрнең баш саны быел күпмегә артачагын әйтеп бирде, ә менә аңа быел ничә тонна печән, ничә тонна силос, күпме тамыразык кирәк булачак — ул турыда ләм-мим.

— Алары безнең производство планында күрсәтелгән, Гашыйк абзый!

— Тукта, Нургали туган, планда барын син әйтмәсәң дә беләм мин... Син үзең ни өчен ул турыда әйтми китәсең, планда язганны булдыру турында нәрсә уйлыйсың син, завферма, вәт мәсьәлә кайда!

Гашыйк абзый, Нургалидән җавап көткәндәй, тукталып калды. Өстәлнең икенче башында йодрыгы белән

битен терәп утырган Нургали исә, гүя бригадирның әйткәннәре үзенә кагылмаган шикелле, бер сүз дәшмичә шул килеш утыра бирде. Гашыйк абзыйның шуңа ачуы килдеме, ул ашыкмыйча гына Нургалигә таба борылып һәм аңа текәлеп, хәтта усал карап:

— Син, Нургали,— диде,— азык кытлыгыннан чыгасың килсә, кырчылык бригадаларына салынып торма, үзең башлап артыннан йөр. Бетсен инде ул, алма пеш, авызыма төш, дип ятулар... Моннан соң азык безнең терлекчелекне буып торган питлә булмасын! Менә шул!

Гашыйк абзый кисәк кенә сүзен бетереп өстәл яныннан китте һәм эскәмиядә калдырган колаклы бүреген сыңар кулы белән башына батырып киде дә урынына утырды.

...Күп кешеләрнең чырайларында һәм күзләрендә сөйләүченең үткен сүзләре кабызган тынгысыз кызыксыну чагылды. Кешеләр сүзсез генә нидер көтеп, сынап Нургалигә текәлделәр. Шул тынлык эчендә урындыгын этәреп, председатель Сөләйманов урыныннан торды, һәм халык та берьюлы хәрәкәткә килде. Кешеләр бер-берсенә таба борылдылар, эскәмияләр шыгырдады, һәм кемнәрнеңдер үзалларынамы, бер-берсенәме «алай-й», «тәк, тәк»,«менә сиңа терә вәт!», «шул шул», «Гашыйк абзаң әйтер ул!», «талканы коры булыр аның» дип әйтүләре ишетелде.

Сөләйманов, бу шау-шуга бер дә ризасызлык белдермичә, юаш кына өстәл кагып, халыкны тәртипкә чакырды:

— Йә, йә, иптәшләр, тынычланыгыз!

Нургали, председательнең йөзенә карап, аның бригадир чыгышыннан никадәр канәгать булуын ачык күрде, һәм барысыннан да битәр шушы нәрсә аны ярсытып җибәрде. Әйе, әйтәсе дә юк, Нургалинең Гашыйк абзыйга бик нык хәтере калды, бригадирның, күпме генә дөрес сөйләмәсен, бу кадәр каты бәрелүен ул кичерә алмады: «Эх, Гашыйк абзый, Гашыйк абзый, оят түгелме сиңа минем турыда болай сөйләү? — диде ул, эченнән тирән әрнү белән.— Йә, минме соң башкаларга салынып, көтеп ятучы? Йә, белмисеңмени син ферманың миңа кадәр нинди хәлдә булуын... Моннан ике-өч ел элек кенә малларга абзар түбәләренең черегән саламын төшереп ашаткан чакларны оныттыңмыни?.. Кем соң бездә азык чөгендере чәчүне башлап кертте, кем илле тонна сыешлы тагын бер силос базы казытты?.. Беләсең бит син, Гашыйк абзый, боларны, Сөләйманов белмәсә дә, син бик яхшы белә-

сең... ләкин нигә ул турыда тел яшереп каласың?.. Эх, Гашыйк абзый, көтмәгән идем мин синнән мондый нахак сүзләр, мактау сорамыйм, әмма дөреслекне дауларга хакым бар!»

Бик кыска арада әнә шундый ярсып, әрнеп әйтелгән үпкә тулы сүзләр Нургалинең күңеленә килеп киттеләр. Ул ихтыярсыздан урындыгы өстендә бер-ике тапкыр шуышып куйды, маңгаена алкаланып төшкән кара чәчләрен уң кулы белән кат-кат тарап алды, аннан пиджак кесәсеннән алюмин портсигарын чыгарды, ләкин җыелышта тартырга ярамаганын исенә төшереп булса кирәк, аны кире кесәсенә салды. Аңа үзен ничек тотса да авыр иде һәм эчке дулкынлануын халыктан яшерә алмавы өчен үзенә ачуы килә иде.

Нургали шулай газапланып утырган арада, өстәл янына хәзерләүләр министрлыгы район уполномоченныеның агенты Нәфикъ Шәйдуллин чыгып баскан иде инде.

Шәйдуллин Яуширмә халкына күптән билгеле бер кеше иде. Кайчандыр район масштабында зур гына урын тотып (заманында аның «Заготзерно» управляющие, соңра «Маслопром» директоры булып торган чаклары бар иде), чүгә-чүгә ул менә авыл советы күләмендәге бер агент булып калды. Моның сәбәбе, бердән, еш кына һәм мул гына итеп «салгалау» булса, икенчедән, артык бюрократлашып китеп, үзен чамасыз тәкәббер, тупас итеп тоту иде. Беренче кимчелеген (үзенчә «авыруын») ташларга ул бер кат түгел, берничә кат сүз бирде һәм тора-бара «салгалавын» шактый киметте дә (чөнки «Маслопром» директорының мөмкинчелекләре хәзер аңарда юк иде инде), ләкин икенче кимчелегеннән ул арына алмады. Киресенчә, йөзгән күле кечерәеп, үзе һаман зурая барган чуртан шикелле, ул, агент булып алгач, тагы да һавалана төште, гүя ул шуның белән: «Шәйдуллин Шәйдуллин булып калачак!» — дип әйтергә тели иде... Нургали, аның өстәл янына чыгып басуын күргәч тә, чыраен сытарга мәҗбүр булды: юк, рәхим көтми иде ул аңардан...

Шәйдуллин, кара дубка суккан арты бөрмәле туны өстеннән иңбашы аша кигән кыр сумкасын ачып, шуннан сары тышлы бер калын дәфтәр тартып чыгарды... Нургалигә таныш иде бу дәфтәр: анда, ягъни ул дәфтәрдә, уполминзаг агентының үз кулы белән һәр фермага йон, ит, сөт, тире, йомырка буенча төшкән дәүләт заданиесе, шуның айлап, кварталлап үтәлеше, үткән елдан калган недоимкалар бик әйбәтләп, графалап язып куелган иде. Шәйдуллин аны «гамәл дәфтәре» дип кенә атап йөртә, һәм гамәлләре бик үк шәп булмаган ферма мөдирләре бу

сары тышлы дәфтәрне агент кулында күрергә бер дә яратмыйлар иде.

Шәйдуллин менә шул дәфтәрнең битләрен ачкалап нәрсәдер эзләде, ашыкмыйча гына әле бер битен, әле икенче битен укып карады (халык көтә бит, дип уйлап та бирми, ичмасам), аннан дәфтәрен япты да, башын күтәреп, бер тын җыелыш өстенә карап торды һәм шуннан соң гына сөйли башлады.

Ул, үз сүзенең үлчәвен яхшы белгәнгә күрә, һәр сүзенә басым ясап, ашыкмыйча гына сөйли, шома итеп кырган битенең иреннәре читендә чак сизелерлек зәһәрле елмаю уйный. Аның Нургалигә төбәп әйткән сүзләрендә ниндидер бер яшерен үртәп көлү сизелгән кебек, гүя ул Нургалинең сүзләрен чынга алмый, яки аларга Нургали үзе биргән әһәмиятне бирергә теләми... Мәсәлән, Нургали үзенең докладында быел терлекләрнең баш саны күпмегә артачагын күрсәткән кайбер саннар китергән иде. Шәйдуллин шул саннарны кызык кына итеп тышы матур, эче буш тартмаларга охшатты. «Иптәш Миңгалиев ул тартмаларның эчен ачып тормыйча, болай тыштан гына елтыратып күрсәтеп алды»,— диде ул. Аныңча, Нургали Миңгалиевнең ул «тартмаларны» ачып күрсәтерлек бернәрсәсе дә юк әле, чөнки Нургали фермасында терлекләрнең продукт биреше һаман бик түбән тора...

Нургали, ихтыярсыздан, бу кешене Сөләйманов юри чакыртып китергәндер, дип уйлап куйды.

Шәйдуллин һаман шулай зәһәр көлемсерәп сүзен дәвам иттерде:

— Сез, иптәш Миңгалиев, сарыкларның быел саны күпмегә артуын әйттегез, ә аларның йон биреше турында бер сүз дә әйтмәдегез. Буш тартма булмыймы соң бу, ә?.. Сез, шулай ук савым сыерларның елдан-ел арта баруын бик зурлап әйттегез. Што же, бик яхшы бу, моның өчен сезне молодец дияргә була. Ә менә сөт биреш ничек, нигә бу турыда авыз йомып каласыз, ә? (Шәйдуллин моны Нургалигә карап түгел, җыелышка карап сорый.) Тагын буш тартма: сан бар, качество юк. Шулай түгелме? Сез, может, сөт тапшыру буенча дәүләт заданиесен үтәп барабыз, тагын сезгә нәрсә кирәк, диярсез! Дөрес, үтисез, үз сыерларыгызның сөте белән үтисез, элекке кебек колхозчылардан кружкалап җыеп түгел...

Нургали, ниһаять, бу мыскылга чыдый алмады — урыныннан кычкырды:

— Ялган сөйләмәгез, иптәш Шәйдуллин, безнең кружкалап сөт җыйганыбыз юк!

— Чү, чү,— диде Шәйдуллин, тыныч кына, кулын Нургалигә таба сузып.— Сезнең хәтерегез бик кыска икән, иптәш Миңгалиев! Үткән елдан элекке елны заданиене ничек тутырдыгыз? Колхозчылардан җыя-җыя көчхәл белән генә түгелме соң, оныттыгызмыни?

— Ялган бу,— дип сикереп торды Нургали,— без халыктан сөт җыеп задание тутырганыбыз юк.

Шәйдуллин халыкка карап иңбашларын җыерган булды:

— Күзгә карап тана бит, ә!

Нургали ярсудан тулып ташса да, үзен кулга алырга тырышып, карлыккан тавыш белән:

— Танмыйм мин...— диде.— Сез әйткән елны колхозчылар үзләре, фермада эшләүчеләр, дуңгыз балалары өчен өсте алган сөт китергәләштергәннәр иде. Колхоз белән колхозчыларның интереслары бер, иптәш Шәйдуллин... Белеп сөйләргә кирәк!

Берничә урыннан Нургалине яклап әйткән сүзләр дә ишетелде:

— Хак сүз, хак сүз! Задание өчен сөт җыю булганы юк.

— Арттырып җибәрдегез, иптәш Шәйдуллин, арттырып... Чамалап кирәк.

— Соң, алама дигәч тә, ул хәтле ярамый ла. Безнең ферма, шөкер, андый хәлгә төшкәне юк әле.

Моңарчы җыелышны күтәренке рух һәм якты йөз белән алып барган Сөләйманов та ничектер караңгыланып китте. Ул халыкны үз ихтыярына куеп, аның шаулавына читтән колак салып торгандай, берникадәр вакыт нечкә кашларын җыерып, тын гына утырды, аннан тавышын үзгәртмичә, сабыр гына:

— Иптәшләр, тынычланыгыз! — диде.— Шәйдуллин сөйләп бетерсен, соңыннан үз фикерегезне әйтерсез... Иптәш Шәйдуллин, дәвам итегез!

Шәйдуллин исә бу вакытта иңбашы аша кигән сумкасының брезент каешын сул кулы белән тотып, җыелышның дулкынлануына бер дә исе китмичә, текә генә басып тора иде. Халык тынгач, ул әлеге сары тышлы калын дәфтәрен яңадан ачты һәм иреннәрен нык кысып, җыелышны бераз көттереп торганнан соң:

— Мин фактлар китерәм,— диде.

Фактлар дигәне аның саннар булып чыкты, һәм, дөресен әйтергә кирәк, Нургали өчен шактый күңелсез саннар иде алар... Ферманың бер савым сыерга төшкән уртача сөт савып алу планы бер генә елны да үтәлгәне юк икән... Кайбер аерым сыерларны исәпләмәгәндә, күп

сыерларның саудыру вакытлары кыска, сөтләре бик аз һәм сыек икән. Ферма үткән елларны сөт заданиесен тутыра алмыйча кала торган булган. Тик соңгы ике елда гына, савым сыерларның баш саны арту нәтиҗәсендә, ферма дәүләт заданиесен тутыра башлаган. Ләкин...

— Факт факт булып кала,— ди Шәйдуллин, сары тышлы дәфтәрен ябып.— Ямашев исемендәге колхозның сыерлары сөтне һаман да әле аз, начар бирәләр. Так што мактанырлык эшегез юк хәзергә... Заданиене тутыру гына түгел, арттырып тутырырга, өстәп бирергә кирәк сөтне дәүләткә, иптәш Миңгалиев!

— Нигә сез шул сөткә каныктыгыз? — диде Нургали, ничектер рәхим сорагандай ачынып.— Нигә безнең башка заданиеләрне үтәү турында әйтмисез? Мәсәлән, ит турында, ә?

— Дөрес, ит заданиесен сез вакытында үтәп барасыз...

— Үтәү генә түгел, былтыр бу ел өчен алдан, авансом биреп куйдык бит...

— Ашыкмагыз, иптәш Миңгалиев, ашыкмагыз! — диде Шәйдуллин, һаман шулай үзенең рәхимсез салкын тынычлыгы белән...— Ит заданиесен үтәү авыр эш түгел ул, абзарда мал бар чагында җитәкләп илтәсең дә бирәсең. Только, нинди мал илтәсез — вопрос шунда. Менә монда бар да язылган, иптәш Миңгалиев! — Ул дәфтәрен селкеп күрсәтә.— Сез тапшырган малларның көрлеге һәрвакыт уртадан түбән була. Шуңа күрә сез бер яшь үгез урынына ике яшь үгез, ике сарык урынына өч сарык илтеп бирәсез. Фактмы бу? Факт! Ә «от факта никуда не убежишь» ди безнең начальник иптәш Галиковский... Так вот, ит заданиесен арык малларны күп итеп тапшыру хисабына түгел, ә аларның көрлеге хисабына выполнять итәргә кирәк. Менә шул чакта мактанырга правагыз булыр, иптәш Миңгалиев!

Шулай диде дә Шәйдуллин, бик эре генә, халыкның баш өстеннән югары карап, үз урынына китте, ә Нургали, ни уйларга да, ни әйтергә дә өлгермичә, кызганыч бер гаҗизлек белән аның бөрмәле кара тунына һәм текә аркасына карап калды. Шәйдуллинның соңгы сүзләре аны гүя җиргә сырты белән салдылар,— шундый үзәккә үтәрлек усал, мәрхәмәтсез булдылар алар... Кызарды, бүртенде ул, әмма бөтен ачуын, хурлыгын эченә йотып, дәшми калырга мәҗбүр булды. Нишләмәк кирәк, әйе, нишләмәк кирәк, фактлар чыннан да бик усал нәрсәләр икән! Дөрес, Шәйдуллин аларны бик күпертеп, әшәке итеп әйтте, ул, мәсәлән, малларның баш саны арту белән

бергә, елдан-ел көрәя баруларына, продукт бирешләренең азлап булса да арта баруына бөтенләй күз йомып узды. Ләкин шулай да уполминзаг агентының сары тышлы дәфтәренә язып куйган мәгълүматлары дөрес һәм аларны берничек тә инкарь итеп булмый иде.

Шәйдуллинның чыгышы җыелыштагы халыкка да бик начар тәэсир итте булса кирәк, бүлмәдә авыр бер тынлык урнашты. Күп агайлар, тезләренә терсәкләрен салып, башларын түбән игәннәр, гүя алар фермалары өчен дә, Нургали өчен дә бик гарьләнәләр һәм Нургалигә, үзен дә, ферманы да шул күркәдән хурлаткан өчен, ачулары килеп, күтәрелеп карыйсылары килмичә утыралар иде.

Халыкның мондый салкынлыгын һәм читләшүен сизеп алу, әйтәсе дә юк, Нургали өчен бик шомлы, бик авыр булды. Ничек кенә булса да акланырга теләп, аның тирән ачыну белән: «Абзыйлар, үткәнне онытa күрмәгез!» — диясе килде, моннан өч-дүрт ел элек кенә, ул ферманы кабул итеп алган вакытларда, терлекләрнең нинди хәлдә булуларын аларның күз алларына китереп бастырасы килде. Ул чакларда сыерларның янбашларына чиләк эләрлек иде бит, сарыклар көянтә шикелле кәкрәеп торалар иде, дуңгыз була торып дуңгызларның кабыргалары беленә иде... Йә, бүгенгесе канәгатьләнерлек түгел дип, шул хәлләрне онытырга ярыймы соң?

Председатель Сөләйманов халыкның хәрәкәткә килүен бераз көтеп торганнан соң, ниһаять, бу авыр тынлыкны үзе башлап бозды:

— Иптәшләр, нигә болай тынып калдыгыз? — диде ул, күкрәге белән өстәлгә ята төшеп.— Әллә иптәш Шәйдуллин әйтәсене әйтеп бетердеме? Минемчә, калгандыр әле, бардыр әле әйтәсе сүз.

Сөләймановның бу өндәве Нургалигә, әле Шәйдуллин әйткәннәргә өстәп тагын бик күп ямьсез нәрсәләр сөйләргә ярый, дигән төсле булып тоелды, һәм кинәт аның йөрәгендә барысы өчен — бөтен ишеткән нахак сүзләр, бөтен күргән урынсыз җәберләр өчен яшь председательгә карата хәтәр ачу кузгалды. Ул, башта ук күңелендә шик һәм яратып бетермәү йөрткән кеше, «хаклымы бу?» дип, әлбәттә, уйлап тормады. Табигый иде бу хәл аның өчен, һәм ул бик ансат кына ачу тойгысының көчсез әсире булып калды.

Бер дә кузгалучы булмагач, Сөләйманов урыныннан торып кыстый башлады:

— Ягез, йә, иптәшләр, активрак булыгыз!

Аннан артта кемнеңдер кыймылдаганын күреп дәште:

— Мөслим абзый, син сөйлисеңме?

Мөслим абзый кешеләрнең аркасы артыннан башын калкытмыйча, тонык кына:

— Юк, сөйләмим әле...— диде.

— Нигә?

— Менә тагын, нигә дип, шулай, сөйлисем килми... Тыңлап утыруы кызыграк,— дип өстәп куйды ул. Күршесендәге берничә кеше көлешеп алдылар.

Шул арада тышкы ишектән, өстенә кара бәрән якалы кыска сырма бишмәт, башына якасы белән берочтан бәрән бүрек кигән тәбәнәк буйлы, юантык кына таза гәүдәле колхоз председателе Шәйхи абзый Галләмов килеп керде. Бар да аңа борылып карадылар. Сөләйманов шунда ук аны алгы рәткә килеп утырырга чакырды. Башкалар да: «Шәйхи абзый, узыгыз, уз, анда урын бар»,— диештеләр, ләкин Шәйхи абзый, кулы белән тынычланырга ишарә ясап, арткы эскәмияләрнең берсенә утырды.

Нindидер бер кичектермәс эше чыгып, сессиягә соңга калган председательне түземсезлек белән борчылып көткән кеше Нургали иде. Югыйсә сессиядә бер Сөләймановның гына «хуҗалык итүе» аның эчен бик пошырып тора иде; җитмәсә, үч иткәндәй, шушындый көнне партоешма секретаре Дускаевны да район үзәгенә, нindидер киңәшмәгә чакыртып алганнар. Аның урынбасары Гашыйк абзый биредә җыелышны бизәп утырса да, үзенең кем чанасына кырын ятып җырлавын күрсәтеп өлгерде инде. Кыскасы, Шәйхи абзый килеп кергәч, ферма мөдире бер иркен сулыш алды. Колхоз председателе үзенең кешеләрен аяк астына салып таптаучылардан түгел ул! Тик менә Шәйдуллинны гына ишетми калды, хәерсез!

Шәйхи абзый утырып, халык тынычлангач, Сөләймановның: «Йә, кемгә сүз бирик соң?» — диюенә каршы, өченче рәттән колхоз умартачысы Нуретдин абзый урыныннан күтәрелде. Ул, өстәл янына чыкмыйча, шул баскан җиреннән генә сөйләргә тотынды.

Чандыр озын гәүдәле, яңаклары эчкә баткан какча битле, зур уйчан күзле, авызының ике як читеннән салынып төшкән нечкә сары мыеклы Нуретдин абзый үзеннән элек чыгып сөйләүчеләрдән бик нык аерыла иде. Аның юаш, сабыр табигатьле бер кеше булуы тавышыннан ук инде сизелеп тора иде. Алдына гына карап, тавышын борын эченнәнрәк чыгарып, салмак кына сөйли ул, ашыкмый, пошынмый һәм кулларын болгау түгел, ичмасам, башын да кыймылдатмый иде. Шундый сүлпән бу-

луына карамастан, бу, гадәттә, теле сирәк ачыла торган өлкән абзыйны халык тыңларга ярата торган иде.

Менә хәзер дә ул әле беркем дә телгә алмаган өр-яңа нәрсә — терлекләрнең нәселләрен яхшырту мәсьәләсен кузгатты һәм, дөресен әйтергә кирәк, шактый катлаулы мәсьәләне гаҗәп бер гадилек белән, һәркем аңлардлык итеп әйтеп бирә алды:

— Борын безнең авылга урыс арасыннан сирәк-мирәк кенә сөтне күп бирә торган яхшы нәселле сыер килеп эләккәли иде. Андый сыер, чит авылдан төшкән уңган, чибәр килен шикелле, бик тиз халык теленә керә торган иде. Һәркем шуның бозавын алырга тырыша, нигә дисәң, үзегез беләсез, яхшы малның токымы да яхшы булып чыга. Тик Мәләкәстән кайткан бу асыл сөяк сыерның нәселе, ни хикмәттер, безнең Яуширмәдә мантый алмый, икенче, өченче буыннан ук акрынлап ваклана башлый, тора-бара бөтенләй югала иде. Үзебезнең ул чактагы каралыгыбыз аркасында, без моның сәбәбен белмәгәнбез, әйе, ә хәзер беләбез, фән безгә моның нидән болай булганын әйтә хәзер...

— Нидән соң ул, Нуретдин абзый? — диде кемдер, акрын гына.

— Нидәнме? Ул, кем, Сираҗи туган, нәселне дөрес саклый белмәүдән килә. Авылда торганы вак сыер, ә теге Мәләкәс килене берүзе — менә ул шул ваклар арасында акрынлап йотыла да бетә...

— Хикмәтле эш! — диде кемдер тагын.

Нуретдин абзый, сары төк каплаган ияген кулы белән учлап, аз гына тукталып торды, аннан каршы стенада эленеп торган һәм бер ферманың тездән яшел үлән эчендә йөрүче зур, кызыл-чуар сыерларын төшергән буяулы плакатка карап, сүзен дәвам иттерде.

— Боларны искә төшерүем минем шуның өчен: без үзебезнең ферма малларын карауда борынгыча сукыр булмыйк, дим. Колхоз малы ишле мал, ишле малны каравы ансат түгел, билгеле, әмма белеп, аңлап, әйтик, фән кушканча карасаң, бик тиз зур нәтиҗәләргә ирешеп булыр иде, дип уйлыйм мин үзем... Моның өчен иң элек малларны аера, таный белергә кирәк, әйе, дөрес карау шуннан башлана. Безнең фермада яхшы нәселле, мул сөтле сыерлар юк түгел, бар. Әнә «Алма»ны алыгыз, нинди яхшы мал бит, хайван! Былтыр күпме сөт бирде әле ул, Нургали туган?

— Ике мең өч йөз илле литр бирде, Нуретдин абзый.

— Шулайдыр шул, әле тәрбия җитеп бетмәгән көе никадәр биргән, ә тәрбиясе җитсә, тагын күпме арттыр-

мас иде ул! Аңардан туган «Кама» да, әле ике бозау анасы гына булса да, сөтне башкалардан күп бирә ләбаса. «Зорька» белән «Йолдыз» да шулар рәтенә керә торган сыерлар. Дөрес, хәзергә мондый хайваннар безнең фермада күп түгел түгелен, ләкин, җәмәгать, әгәр теләсәк, ферманың бөтен савым сыерларын шулар кебек итә алабыз. Ихлас, итә алабыз... Моның өчен яхшы нәселле яңа сыерлар сатып алу да кирәкми, моның өчен бары үзебезнең шул күп сөтле сыерларның бозауларын гына ферма өчен калдыра барырга кирәк. Барып чыга торган эш бу... Тик ул бозаулардан яхшы савым сыерлар үстерер өчен, аларны дөрес итеп тәрбияли дә белергә кирәк булачак. Бу хакта фән болай дип әйтә: сөтле сыер үстерәсең килсә, бозауга яшь чагында мөмкин хәтле күп итеп куе сөт эчерт, ди. Бер галимнең әйтүенә караганда, иң яхшы сыерның да бозавына сөт урынына солы апарасы эчерсәң, ул аз сөтле сыер булып җитешә, ди. Күрәсез, җәмәгать, бозаулардан сөтне җәлләмәүнең әһәмияте никадәр зур!

Моңа каршы Шакирҗан карт:

— Сыналган нәрсә ул, Нуретдин, фән белмичә әйтми аны,— диде.

— Белеп әйткәнгә күрә дә, Шакирҗан бабай, без аңа ышанабыз, тик ул кушканча эшләргә генә иренәбез. Соң, менә безнең ферманың хәзер нәселле бозауларны үзләренә аерым тәрбияләргә хәленнән киләме? Минемчә, бик килә, эш бары теләктән генә тора. Өч-дүрт елдан аларның һәркайсы өч сыер биргән сөтне бирүзе бирер иде. Менә шул. Хәзер сыерларның бозаулаган чаклары, Нургали туган бу әйткәннәрне исендә тотып, шундый бер эш оештырса, бик әйбәт булыр иде.

— Әйбәт булмаган кайда ул! — диде председатель Сөләйманов та.

Җыелыш халкы Нуретдин абзыйның тигез тавыш белән шулай салмак кына сөйләвен чын канәгатьләнү белән тыңлап утыра иде. Беренче кайнар чыгышлардан кызып киткән атмосфера хәзер сизелерлек дәрәҗәдә сүрелә төште, һәм нервлары кытыкланып уйный башлаган кешеләр дә шактый тынычландылар. Ләкин бу хәл җыелышның киеренке-кызыклы булуын бер дә киметмәде.

Нургали дә Нуретдин абзыйның йон уңаена сыйпагандай итеп кенә сөйләвеннән бераз тынычлангандай булды һәм аның гыйбрәтле сүзләрен бик игътибар белән тыңлап утырды. Хәер, ул башта ук Нуретдин абзыйдан, Гашыйк абзый төсле, зәһәрләнеп әйтүне, яки Шәйдуллиндай күркә төсле кукраеп, югарыдан түбәнгә карап

сөйләүне көтмәгән иде. Кешесе ул түгел, көнчеләрдән түгел, явызлык эсти белмәс, кулыннан килгән киңәшен бирер, акыллы сүзен әйтер. Йә, һәрбер сүзе ферма өчен файдага түгелме?

Нургали бу файдалы киңәшләр өчен Нуретдин абзыйга ихлас күңелдән рәхмәт әйтергә дә хәзер иде инде, һәрхәлдә, җыелыш башка эзгә төшәр, урынлы-урынсыз яманлаулар бетәр, Сөләйманов та «тәнкыйть» дигән булып котыртып маташуын ташлар, дип утыра иде ул. Ләкин Нуретдин абзый сүзенең ахырында гына Нургали һич көтмәгән, җыелышны гаять кызыксындырган һәм, әйтергә кирәк, аны яңадан кыздырып җибәргән бер мәсьәлә кузгатты.

Нуретдин абзый бу соңгы сүзен әйтер алдыннан туктальп, мыегының түбән салынган сул як очын уң кулы белән тоткан килеш шактый уйланып торды. Күренеп тора: абзыйның тагын нәрсәдер әйтәсе килә, ләкин әйтергәме, юкмы һәм ничек итеп әйтергә? — шул турыда ул баш вата...

Сөләйманов та, өлкән абзыйны ашыктырасы килмичә, шактый көтеп утырганнан соң, ниһаять, түзмәде:

— Йә, Нуретдин абзый, беттеме сүзең, әллә тагын берәр әйтәсе нәрсәң бармы? — дип, аны озак уйланудан чыгарырга мәҗбүр булды.

Нуретдин абзый, башын күтәреп, председательгә уйчан акыллы күзләре белән карады һәм икеләнеп кенә:

— Бетте дисәң дә ярый инде, Закир туган,— диде.— Тик шулай да күңелдә яткан бер уй бар иде барын...

— Булгач әйт, Нуретдин абзый, ятып калмасын ул!

— Урынлы булыр микән, дим.

— Ниткән сүз ул, үзебезнең авыл советы сессиясендә сөйләшәбез ич!

— Анысы шулай,— диде Нуретдин абзый һәм җиңел генә сулап куйды. Халык зур кызыксыну белән, «шылт» иткән тавыш чыгармыйча, аның нәрсә әйтәсен көтеп тора иде. Ул, шуны ачык сизеп булса кирәк, үзенең озын, алга бөгелүчән гәүдәсен турайта төште һәм, гадәтенчә, ашыкмый гына «күңелендә ятканын» сөйләргә кереште:

— Мин үзем фермабызның бүгенге хәлен кайберәүләр кебек, мисал өчен, иптәш Шәйдуллин кебек, алай бик аяныч итеп күрмим. Билгеле, яшереп торасы юк, авыр сугыш елларында ул бик өшәнде, кечерәеп калды, терлекләр арасында зыянлаулар күп булды, вакландылар, арыкландылар алар... Әмма терлек дигән нәрсә бик яшәүчән нәрсә ул, җан иясе һаман үрчүгә, ишәюгә омты-

ла бит ул... Тик бераз уңай шарты гына булсын аңа! Менә Нургали туган фермага килгәч абзар-кура тирәләрен рәтләп җибәрде, кыш чыгарлык азык хәзерли башлады, инде үзегез күрәсез, өч-дүрт ел эчендә малларыбызның баш саны сугышка хәтледән узып та китте. Әгәр шуннан без аларның нәселләрен акрынлап яхшыртсак, дөрес итеп карарга да өйрәнсәк, тагын өч-дүрт елдан фермабыз танымаслык булып китәр, барысын да — сөтен дә, итен дә, йонын да мул итеп бирер. Шулай булыр ул, боерган булса, мин үзем шуңа ышанып торам... Тик шуның безгә, әйтик, колхозчыларга, кайчанрак файдасы тия башлар икән, әйе... нәрсә бирер икән, дим, ул безгә...

— Ачыграк итеп әйт, Нуретдин абзый! — диде арткы рәттән кемдер, каты гына кычкырып.

— Ачыграк итепме? Анысын бит үзегез дә аңларга тиешсез, туганнар... Мисал өчен, без иген чәчеп үстерәбез һәм ел саен, шөкер, хезмәт көнебезгә икмәк бүлешеп алабыз. Әнә Сөембикә сеңелкәш үзенең яшелчә бакчасыннан алган кәбестәсеннән, кишереннән, помидорыннан һәр көз диярлек безгә өлеш чыгарып килә. Менә умарта асрыйбыз, үзегез беләсез, ел саен диярлек бал бүлешмичә калганыбыз юк. Күңелле эш бит ул— уртак хуҗалыкның шулай игелеген күрү, ныграк бәйли бит ул безне үзенә... Менә, мин әйтәм, безнең ферма белән дә шулай булсын иде, дим. Ул да безгә, колхозчыларга, хезмәт көннәребезгә итен, сөтен, йонын биреп барсын иде, дим.

— Каян алып? — диде бик текә генә утырган Шәйдуллин.

— Инештән алып түгел инде, иптәш Шәйдуллин, ә терлек, ала белсәң, бирә ул, бик бирә. Аның чыгар чишмәсе бик иркен, дәүләткә дә полный итеп биреп була, безне дә буш итмәскә була. Андый фермаларның барлыгын без ишетеп торабыз лабаса! Күптән түгел генә иптәш Дускаев та безгә Украинадагы бер колхозның исеме, хәтерем ялгышмаса, «Червонный партизан» шикелле, менә шуның терлекчелек фермасы турында нинди гыйбрәтле сүзләр сөйләгән иде. Май заводы, колбаса фабрикасы бар, ди, аның, йөз меңнәрчә доход ала, ди, колхозчыларыңа итен, сөтен мул итеп бирү генә түгел, акчалата да өләшә икән. Ә сез, иптәш Шәйдуллин, каян алып, дисез!.. Тырышкан табар, ташка кадак кагар, дигәннәр бабайлар. Эш безнең үзебездән тора, әйе, чынлап тотынганда, иң якын елларда фермабызның игелеген күрә башларбыз, насыйп булса... Тик хәзердән үк шуны, ягъни башта әйткәнемчә, хезмәт көненә ит, сөт биреп баруны ферма

алдына бурыч итеп куясы килә. Иртә булмас, дип исәплим. Әгәр хата дип табасыз икән, төзәтерсез... Минем әйтәсе сүзем бетте, Закир туган!

Нуретдин абзый, артына борылып, эскәмиясенә карап алды да иплэп кенә урынына утырды. Соңгы сүзләреннән ул үзе дә шактый тирән дулкынлану кичерде булса кирәк — маңгаена берничә бөртек эре тир тамчысы калкып чыкты, ә салынып төшкән сул як мыегы дерт-дерт селкенеп куйгалый иде. Ул, тынычланырга теләгәндәй, тамырлары бүртеп чыккан зур кызгылт кулы белән әле бер яңагын, әле икенче яңагын сыпырып-сыпырып ала һәм еш кына тамак кырып куя иде.

Бу чыгыш, һичшиксез, халыкта тирән эз калдырды. Башта һәркем, хәзер генә ишеткәннәренең бөтен әһәмиятен аңларга теләгәндәй, бик аз гына вакыт үзалдына тынып утырды. Аннан, умарта иле кузгалгандай, җыелыш акрын гына гүли башлады. Һәм бу гүләү, бик тиз көчәя барып, ахырында бөтен бүлмә эчен тутырды.

Әйтәсе дә юк, күпләр Нуретдин абзыйның соңгы сүзләрен күтәреп, хуплап каршы алдылар:

— Бик дөрес әйттең, Нуретдин абзый, рәхмәт үзеңә!

— Соң, шулай булмыйча, үзебезнең ферма ла!

— Күптән кузгатырга вакыт иде инде бу мәсьәләне, туганнар!

— Вакыт, вакыт...

— Эшли белгән җирдә әнә ашый да беләләр.

Бу куәтләү сүзләренә каршы берничә җирдән йә көлеп, йә бик акыллы булган булып әйткән сүзләр дә ишетелде:

— Барын-югын белмидер, бал телидер тамагым!

— Туктагыз әле, егетләр, акылыгыз бармы сезнең? Ярамый бит болай...

— Нәрсәсе ярамый?

— Соң, нәрсәсе дип, үзегезгә мәгълүм ич! Бераз исәп кирәк ләбаса. Заданиесен адәм төсле тутырып барсын әле...

— Заданиесен дә тутырсын, безгә дә арттырсын, вәт ул колхоз фермасы булыр!

— Бер ун елдан арттырыр, Ходай насыйп итсә!

— Сөте, йоны инде аның, шөкер, үзебездә дә була. Икмәген әйт син, икмәген... Икмәктә хикмәт!

— Шауламагыз әле, җәмәгать... Әнә Җаппар нәрсәдер әйтмәкче була, кешегә сөйләргә бирегез!

— Чистый!

Җаппар — былтыр гына бригадир булып эшли башлаган яшь егет, баядан бирле арткы рәттән кулын бол-

гап, нидер кычкыра иде. Аның кыска, киң борынлы түгәрәк бите кара янып кызарган, гадәттә, ярыктан күзәткәндәй, кысылып кына карый торган коңгырт-кара күзләре хәтәр булып түгәрәкләнгәннәр, әйтерсең, ярсып, авызлыгын тешләп чабарга җыенган яшь ат,— шундый бер түземсезлек һәм ашкыну белән нәрсәдер әйтмәкче була ул... Халык чак кына тынуга, ул кычкырып, ләкин артык кабаланудан тотлыгып сөйли башлады:

— ...Мин Нургали, юк, Нуретдин абзый әйткәннәргә полный кушылам. Дөрес әйтте ул, әйе, шулай булырга тиеш. Колхозчылар хезмәт көненә алырга тиеш сөтен дә, итен дә. Без күпме йорт эшеннән бушар идек, колхозда кул көче артыр иде... Галәви абзый монда, сөт, йон үзебездә дә була, ди. Бу — колхоздагы единоличник сүзе... Шуңа күрә аның хатыны, Сабира җиңги, бер елны да минимумын тутырмый, интересы юк, станциягә катык ташый... Вәт нәрсә! Үзебезнең йорт терлегенә ябышып ятмаска, колхоз терлекчелеген үстерергә кирәк. Ул безгә...

Ләкин Җаппар сүзен әйтеп бетерә алмады, яңа көч белән купкан шау-шу аның тавышын басып китте:

— Әлә-лә-лә-лә...

— Кинәт бордың, энем, аударып ташлама!

— Уставка каршы сөйли бит бу, Сөләйманов нәрсә карый?!

— Уставка каршы түгел, ә синең киребеткән кеше булуыңа каршы сөйли ул, Галәви!..

— Дөрес сөйли, дөрес!

— Дөрес булмыйча соң, әллә мәңге шулай, үземнеке дигән булып, бер сыер койрыгына тотынып торырбызмы?

— Торма, сине кем көчли...

— И тормам да... Колхозныкы җиткәндә, нигә мин ул сыерны башыма җәфа итеп тотыйм соң!

— Што сөйләп торырга монда, иптәшләр. Нуретдин абзый дөрес кузгатты мәсьәләне... Коммунизмга барабыз ла!

— Коммунизмга барабыз, дип, колхозчыларның терлекләрен бетерергә кушасыңмыни син, ә, товарищ Могыйн?

— Белмичә лыгырдый ул, әнә партия һәр йортта сыер булсын дип тора!

Председатель Сөләймановка кинәт болай кулдан ычкынып, башбаштакланып киткән җыелышны яңадан кулга алу, эзгә төшерү ансат булмады. Ул, әлбәттә, халыкның нидән бу кадәр шау кубуын ачык күреп тора,

шунлыктан артык ризасызлык белдермичә, чыраен сытмыйча, сабыр гына тәртипкә чакыра иде.

— Булды, иптәшләр, булды. Җитәр, тынычланыгыз! Кем, Галәви абзый, Галимулла, Хәмит, йә, туктагыз инде, сессиябез урам җыенына әйләнеп китте бит.

Председатель шулай дигәч, кешеләр дә бер-берсен тәртипкә чакырырга тотындылар:

— Йә, җитте, Җаппар туган, калганы соңыннан...

— Тс-с-с, шауламагыз!

— Әй, син, Могыйн, кулыңны ул хәтле болгама әле, әнә Сафый абзыйның бүреген бәреп төшердең бит.

— Ә сиңа нәрсә? — диде Могыйн, усал гына, ләкин үзе шунда ук тынып, җәһәт кенә урынына утырды. Кемдер Сафый абзыйның бүреген идәннән алып башына каплады. Җыелыш, ниһаять, тынды.

Бу шау-шу дәвамында Нургали тирән бер аптырауга төшеп, җыелышка һичбер катнашы булмаган кеше шикелле, тик кенә утырды. Әйе, кызыкка китте бу! Иптәш Сөләйманов сессиясендә ни сөйләсәң дә ярый торган булып китте. Берәүсе, задание тутырыр өчен халыктан кружкалап сөт җыясыз, дип сөйләгән иде, икенчесе, халыкка хезмәт көненә сөт бирергә кирәк, дип сөйли. Теләсәң ничек аңла!

Юк, Нургали Нуретдин абзыйдан мондый чыгыш көтмәгән иде. Кем-кем, әмма Нуретдин абзый инде колхоз терлекчелегенең хәлен Нургалинең үзеннән дә артыграк белә... Һәм белә торып, хезмәт көненә ит, сөт, йон, йомырка бирү мәсьәләсен менә бүген күтәр, имеш! Нургали бирмәс идемени, рәхәтләнеп бирер иде, көн саен литрлап сөтен, атна саен килолап маен, дистәләп йомыркасын өләшер иде, ләкин бит күлеңә күрә чумасың...

Нуретдин абзый нинди яхшы ният белән сөйләмәсен, әмма аның бу чыгышы, Гашыйклар, Шәйдуллиннар чыгышыннан соң, чөй өстенә тукмак булып төште. Һәм, чыннан да, аның артыннан чыгып сөйләүчеләр ул күтәргән мәсьәләгә тегеләй яки болай кагылмыйча узмый башладылар. Тик участок зоотехнигы, бик яхшы татарча белүче яшь чуаш кызы Настя Шубина гына, агайларның бәхәсенә катнашып тормыйча, бары «витаминлы печән» хәзерләргә димләп, моның өчен аны күләгәдә киптерергә кушып, гомумән, яхшы сыйфатлы печән алыр өчен үләнне чәчәген коймас борын чабу кирәк икәнлеген кат-кат әйтеп, матур гына бер чыгыш ясады. Җыелыш халкы аңардан бик канәгать булып калды. Башкаларның исә телендә һаман шул сыерларның сөтне аз

бирүләреннән, малларның арык булуларыннан зарлану да «кайчан фермабызның игелеген күрербез» дип сукрану булды. Дөрес, арадан, яхшатлану йөзеннәнме яки, чыннан да, Нургалинең хәлен аңлапмы: «Җәмәгать, барысын да Нургали өстенә генә аударырга ярамый», «Нургали теләсә эшли ала торган егет ул!», «Беләбез без аны, төпкә җигелеп тартучы ул!» — дип әйтүчеләр дә булгалады. Әмма Нургалигә аңардан җиңел түгел иде, чөнки ничек кенә йомакайлап әйтмәсеннәр, ул көткән төп нәрсәне әйтүче: «Менә бит Нургали ферманы нинди авыр хәлдән чыгарды, ник шуны күрмисез?» — диюче кеше булмады.

Хәзер ул бары колхоз председателе Шәйхи абзыйга гына ышанып утыра иде. Ул, колхозның баш җитәкчесе, ниһаять, бу хаксызлыкны төтен урынына таратыр, чын дөреслекне әйтеп бирер!

Сөләйманов, урыныннан торып:

— Йә, кемгә сүз? — дигән саен, Нургали, текәлеп, Шәйхи абзый ягына карый. Ләкин арткы рәттә уң тезен ике кулы белән кочаклап утырган Шәйхи абзый ни өчендер кузгалырга ашыкмый. Ул сөйләүчеләрне тыңлый, әйтергә кирәк, бик игътибар белән тыңлый, һәм Нургали, аңа караган саен, «иң ахырдан барысына берьюлы җавап бирергә җыена торгандыр» дип, үзен юаткан була. Ләкин аның чынлап гаҗәпләнүенә каршы, Шәйхи абзый иң ахырдан да һаман шулай урыныннан кузгалмыйча һәм дәшмичә кала бирде.

Ниһаять, сөйләүчеләр бетте. Сөләймановның кыставына каршы кешеләр төрле урыннан:

— Йә, җитәр инде, Закир туган!

— Әйтәсе сүз әйтелеп бетте шикелле...

— Бетте инде, бетте, бауның гына озыны яхшы ул!

— Үзең генә очлап куй инде, булмаса...— диештеләр.

Сөләйманов җыелыш өстенә беравык тын гына карап торды да, күршесе Вагыйзгә нидер әйтеп, урынына утырды. Вагыйз, торып:

— Хәзер авыл советы председателе иптәш Сөләймановка сүз бирәбез! — диде. Аннан Вагыйз утырды, Сөләйманов торды.

Бүлмәдә тирән тынлык урнашты (халык, шаулый белгән кебек, кирәк вакытта тынып та кала белә иде). Баюга авышкан март кояшы көньяк-көнбатышка караган тәрәзәләрдән бүлмә эченә бер тутырып карады. Аның мул, куе нурлары Сөләймановның аркасын һәм аңа каршы утырган халыкның бит-башларын ачык яктыртып, түрдәге бүрәнә стенага, алтын йөгерткәндәй, тоташ сары

булып төште. Председательне бик дикъкать белән тыңларга җыенган халыкның ак сакаллы, җирән сакаллы, нечкә кара мыеклы, бөтенләй мыексыз, түгәрәк-тулы, озынча-какча йөзләре кояшның сары яктылыгында, бакырдан койгандай, хәрәкәтсез-тыныч, киеренке-җитди булып күренә иде.

Халык, билгеле, үзенең председателен беренче тапкыр гына тыңламый иде, һәм, дөресен әйтергә кирәк, Сөләйманов үзен оста сөйләүче итеп танытып өлгергән иде инде. Ул, зур аудиторияләр күргән, җаваплы чыгышлар ясап өйрәнгән бер кеше сыман, үзен бик тыныч тотып, ашыкмыйча, кабатламыйча гына тирән эз калдырырлык төпле чыгышлар ясый иде. Нургали аны менә шушы сөйли белүе өчен дә яратып бетерми иде шикелле. Дөрес, ул үзе дә кәефе килгән чакларда бик ялкынлы, үтемле чыгышлар ясый торган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, Сөләймановның өстенлеген ул авыр кичерә һәм шул тойгыны басар өчен үзен эш кешесе, ә аны сүз кешесе дип уйларга ярата иде.

Чыннан да, сез Сөләймановны тыңлап кына карагыз! Ничек оста итеп үрә бит ул үзенең җәтмәсен, бер дә сикереп сукмый, ерактан сак кына уратып китерә. Колхоз фермасын мактап телгә алу белән сүзен башлап җибәрде бит, шайтан алгыры! Нургали аны колаклары белән генә түгел, гүя бөтен сизү әгъзалары белән тыңлый һәм аның һәрбер сүзен туры мәгънәсендә генә түгел, бәлки нәрсә уйлап, ни өчен әйтүен дә аңларга тырыша.

— Без,— ди Сөләйманов,— колхоз терлекчелегенең бүгенге хәлендә күпме генә кимчелекләр күрмик, ләкин аның моңарчы ирешкән зур уңышларын онытырга тиеш түгел без. Әгәр колхоз терлекчелеге булмаса, авыр сугыш елларында авылда бер генә аяклы мал да калмаган булыр иде. Шулай ук сугыштан соң безнең колхоз терлекчелек фермасына чынлап тотынмаган булса, без дүртбиш ел эчендә терлекчелекне аякка бастыра алмаган булыр идек. Уңышларны онытырга ярамый, иптәшләр, чөнки ул уңышлар колхозда терлекчелекнең үсә алуын, тырышканда бик нык үсә алуын әйтеп торалар.

Бу уңай белән Сөләйманов уполминзаг агенты Шәйдуллинга да тиешле өлешне чыгарып, кулына тоттырып узды. Бер дә аның «Мин кем?» дип кычкырып торган рәсми йөзеннән дә, кара дубка суккан бөрмәле тунынан да куркып тормады,— әйтәсе сүзен, оста кул белән имәнгә кадак сугып керткәндәй, туры һәм кыска гына итеп әйтеп бирде. Ул аның ферма терлекләрен «буш тартмаларга» охшатуын мәгънәсез чагыштыру дип атады,

аларның баш саннарын арттыру — ферма алдында иң беренче чиратта торган бурыч булуын һәм колхозчыларның моңа бик куануларын әйтте. Ул, гомумән, иптәш Шәйдуллинга бюрократизмның черек манарасыннан аумас борын җиргә төшәргә, колхоз фермаларына үз кеше булып якын торырга киңәш бирде: «Сезнең бурычыгыз әнә шул үзегез әйткән кимчелекләрне бетерү өчен колхоз фермасына булышлык күрсәтүдән, ферма работникларын ничек эшләргә өйрәтүдән дә гыйбарәт булырга тиеш»,— диде.

Шәйдуллин, билгеле, председательнең бу «нотациясен» тыныч кан белән генә тыңлап кала алмады. Ул һич кичекмәстән «отпор бирү өчен» җәһәт кенә урыныннан торды:

— Сез нәрсә, иптәш Сөләйманов, минем обязанностьларым турында миңа нотация укымакчы буласызмы, ә?

Сөләйманов бик гади генә итеп җавап бирде:

— Мин, иптәш Шәйдуллин, сезгә бернәрсә дә укырга җыенмыйм, сез авторитетлы бер органның вәкиле, халык сезне яхшы итеп күрергә тели, шуңа күрә колхозчылар исеменнән киңәш итеп кенә әйтәм, тыңласагыз, бәлкем, файдасы тияр, дим.

Яшь председательнең каты бәрелешкә керергә теләмичә, шулай тыныч, салкын гына җавап бирүе Шәйдуллинны бераз таркатып җибәрде булса кирәк — ул нәрсә әйтергә белмичәрәк калды. Аннан, нидер исенә төшкәндәй, артистларча кулын сузып:

— Постой, постой...— дия башлаган иде, ләкин төрле яктан берьюлы кычкырган тавышлар аңа авыз ачарга ирек бирмәделәр:

— Ни өчен «постой»? Нигә кешене туктатасыз?

— Ташлагыз әле шул, тәкәдәй, гел сөзешергә торуыгызны.

— Утырыгыз әле урыныгызга гына, председательне каплыйсыз!

— Чын, җыелышыбызның ямен җибәрмәгезче, иптәш Шәйдуллин!

Шәйдуллин сер сынатмас өчен ясалма тәкәбберлек белән иңбашларын җыерган булды һәм артына борылып карамыйча гына урынына утырды. Ә Сөләйманов бернәрсә дә булмаган шикелле сүзен дәвам иттерде,—хәтере яхшы булырга тиеш аның,— кәгазь-мазарга карап тормастан, һаман шулай тигез тавыш белән, фикер агышын бозмыйча һәм кабатламыйча күңеленнән сөйли бирде. Ләкин, ни хикмәттер, аның тыныч, сабыр гына сөйләгән сүзләре торган саен көчәя, кискенләшә, хәтта усаллана

барган кебек иде. Моны һәркемнән элек аеруча уяу тыңлап утырган Нургали сизә башлады. Әйе, җилнең исеше әкрен-әкрен җылы яктан салкын якка борыла!.. Ферманың азмы-күпме уңышларын телгә алып сүзен башлаган яшь председатель акрынлап, ләкин эзлекле һәм рәхимсез рәвештә, ферма мөдирен кысрыкларга тотынды. Ул иң элек ферма мөдиренең бүгенге җаваплы җыелышка бик өстен генә хәзерләнеп килүен зур бер гаеп итеп теркәп узды:

— Нургали абыйның моңарчы ирешелгән уңышлар турында әйтергә онытуын кичерергә дә була, ярты бәла ул, ә менә ферманың киләчәге турында бер сүз дә әйтмичә калуын ничек аңларга? — Сөләйманов җавап көткәндәй аз гына тынып торды, аннан мәсьәләнең җитди булуына басым ясарга теләгәндәй, тагын сорау рәвешендә кабатлады: — Юк, чыннан да, авыл советының терлекчелеккә багышлап чакырган сессиясендә депутатларны, биредә утырган колхоз активын үзеңнең киләчәк планнарың белән таныштырмау — нәрсә бу, ничек аңларга моны? Артык бер эшкә санадыгызмы сез аны, Нургали абый, әллә югыйсә әйтер сүзегез булмадымы? Әгәр, чыннан да, әйтер сүзегез булмаган булса,— минем моңа ышанасым килми, билгеле,— бу бик аяныч хәл бит! Бу сезнең бары бүгенге көн белән генә мавыгып йөрүегезне, киләчәк турында уйламавыгызны, плансыз эшләвегезне, кыскасы, бүген көн үтсә ярар, иртәгәсен ишәк кайгыртсын, дип яшәвегезне күрсәтмиме соң?

Нургали, мәсьәләнең тирәнгә китүен сизеп, дәшмичә калырга булдыра алмады, әлбәттә, ләкин артык әһәмият бирмәгәндәй күренергә тырышып, ваемсыз гына әйтеп ташлаган булды:

— Безнең өчьеллык планыбыз бар, иптәш Сөләйманов, һәрбер колхозчы белә аны, сезгә дә билгеле ул, нәрсәсен сөйләп торасың аның...

Сөләйманов, Нургалинең юри ансат кына котылырга чамалавын ачык күреп, юка иреннәренең чите белән генә елмаеп куйды.

— Менә бөтен мәсьәлә дә шунда шул! — диде ул.— Безнең өчьеллык планыбыз бар, партиянең шул планны үтәү өчен безгә сызып биргән юлы бар, ниһаять, илебезнең терлекчелек алдына куйган зур таләпләре бар. Моны, сез әйтмешли, һәрбер колхозчы белә, шулай булгач, ничек инде бөтенебезне дә кызыксындырган киләчәк турында бер сүз дә әйтмичә калырга мөмкин ди! Йә, ревизия комиссиясенең протоколын укыгандай, «бүгенгесе көндә фәлән бар, төгән бар, ул юк, бу юк» дип, ашык-

пошык кына санап чыгу кемгә кирәк, кемне канәгатьләндерә ул?

Чын-чыннан нервысы уйный башлаган Нургали түзмәде — шактый дорфа итеп Сөләймановның сүзен тагын бүлде:

— Минем, кайберәүләр шикелле, сүз сөйләү курслары бетереп кайтканым юк, бигайбә, нибары белән...

— Нибары бик чамалы шул, Нургали абзый,— диде Сөләйманов, бу ачулы сүзләрнең үзенә төбәлгән начар кинаясенә һич игътибар итеп тормастан.— Менә шуңа безнең эчебез поша, менә шуңа күрә дә халык биредә фермабызның хәле турында ачынып сөйләргә мәҗбүр булды. Нибары безне канәгатьләндерми, юк, һич канәгатьләндерми, Нургали абзый...

Нургали авызыннан ычкынган һәрбер сүзенең, каклыгып суккан таяк шикелле, кире үзенә кайтуыннан гаҗиз булып, бөтенләй сабырлыгын җуяр хәлгә килде. Аңа үзең кулга алу, тышкы тынычлыгын саклау торган саен авыр була башлады. Шуны сиздермәс өчен ул, таш сындай, тик кенә утырырга тырыша, ләкин, үзе дә сизмәстән, әледән-әле кузгалып куя, бер өстәлгә таяна, бер урындыгы артына авыша иде.

Ә Сөләйманов Нургалинең бу хәлен гүя юри күрмәмешкә салына, һаман шулай халык өстенә ачык соры күзләре белән тыныч карап, ашыкмыйча гына сөйләвендә дәвам итә. Әгәр ул ферма мөдиренә каныгуын ачык сиздереп, чырай сытып ачу белән сөйләсә, Нургалигә, бәлкем, җиңелрәк булыр иде. Бу — һәркемгә күренеп торган дошманлык, дип әйтер иде ул... Әйтер иде, әгәр һәркем ул тойганны тойса.

Ләкин яшь председательнең моңарчы сөйләгәннәре зарарсыз чәчәкләр генә булган икән, әче җимешләрен менә хәзер авыз иттерә башлады ул... Нәкъ Нургали көткәнчә, Сөләйманов сессиядә чыгып сөйләүчеләрнең күп сүзләрен дөрес дип тапты. Тик ул биредә күтәрелгән мәсьәләләрнең зурлыгына яки кечкенәлегенә карап, һәркайсының урынын билгеләде, һәркайсын яңа дәлилләр белән ныгытып, әһәмиятен тагы да үстерә, үткенлеген тагы да көчәйтә төште.

Беренче чиратка ул азык мәсьәләсен куйды. Терлекчелекнең төп нигезе — азык, диде, һәм шул нигезне булдырмыйча торып, ферманың үсүе, алга китүе мөмкин түгел, диде. Нургалинең уннан тугыз кайгысы азык турында булырга тиеш (тыңлап тор, егет!), Нургали, табигый болынлыкларның азлыгын исендә тотып, үлән чәчү һәм тамыразыклар үстерү мәйданын киңәйтүдә башлап

йөрүче кеше булырга тиеш. Гашыйк абзый әйтмешли, бу эш — колхозның кырчылык эше, дип, ул кул кушырып утырмаска тиеш. (Кул кушырып, ди, ә, оялмый да, Нургалигә ике кул түгел, дүрт кул булса да җитмәслеген белми, күрәсең!)

Аннан Сөләйманов, депутат Вагыйз фикерләрен куәтләп, ферманың бик борынгыча эшләп маташырга яратуын, яңалыклар кертергә бер дә һәвәс булмавын сөйләргә тотынды. Әйтергә теләгәне механизация турында икән. «Нургали фермасында» (ни өчендер, үзенчә мыскыл иткән булыпмы, бу юлы ул туп-туры шулай дип әйтте) хәзергә чаклы саламны бүрәнәгә беркетелгән ураклар өстендә турыйлар, суны ат имгәтеп буадан ташыйлар, тиресне абзарлардан әллә ничә кеше, көрәк сапларын кендекләренә терәп, этәреп чыгаралар... Терлек ишле, хуҗалык зур — колхоз хуҗалыгы ул (кара аны, Нургали моңарчы шуны белмичә йөргән икән ләбаса!), ә эшләү нәкъ аерым хуҗалыкның ялгыз сыер абзарындагы төсле... Бу уңай белән председатель бик мәгънәле бер чагыштыру да китерде: кырчылыкта хәзер бөртек җиргә төшкәннән алып колхоз амбарларына ашлык кергәнгә кадәр барлык төп эшләр машина белән эшләнә. Трактор, комбайн, автомашина — менә нәрсәләргә без ияләштек. Ә фермада бер мотор тавышы ишетелми (үзебездә электр көче була торып!), бер машина тәгәрмәче әйләнми,— без моңа да күнеккәнбез, шуларның юклыгын сизмичә йөри бирәбез... Гаҗәп, Нургали абыйның моңа ничек җаны түзә икән?

Ниһаять, Сөләйманов Нуретдин абзый чыгышына киң итеп тукталды. Әлбәттә, ул өлкән умартачының һәр әйткәнен бик зурлап һәм хуплап каршы алды. Бигрәк тә өлкән абзыйның китапчалап сөйләвенә яшь председательнең кәефе бик килгән икән. Менә, имеш, кулыннан китап төшермәгән, фән белән кызыксынган кешенең эше башка, ул, имеш, еракка карый белә, дөрес күрә белә... Без яшьләргә Нуретдин абзыйдан үрнәк алырга кирәк, имеш, ләкин што-то, имеш, Нургали абыйның китап белән дуслыгы сизелми, үзе дә укымый, эшләүчеләрен дә укырга кыстамый... Үз күлеңдә генә йөзә торган чак түгел, алдынгылар тәҗрибәсен өйрәнергә, фәнгә таянып эшләргә кирәк, янәсе... Ә Нуретдиннең эше ни дә, Нургалинең эше ни — аны уйлап карау юк. Нуретдин абзаң кыш буена кулын артка куеп мәктәп белән уку йортының сукмагын таптый торган кеше, кортлары аның колак төбендә ашарга сорап безелдәмиләр, балны үзләренә дә, Нуретдиннең үзенә дә җитәрлек итеп җыеп калдыр-

ганнар. Ә Нургали ике мең башка якын терлекләрнең мәшәкате белән ел әйләнәсе, утлы табада биегәндәй, бәргәләнә, кырын ятып китап уку түгел, аягүрә газетадан күз йөгертеп чыгарга да вакыт таба алмый... Әйе, сөйләве ансат ул, тик менә барысына да өлгереп кара.

Инде колхозчыларга хезмәт көненә ит, сөт, май бирү мәсьәләсенә килгәч, Сөләйманов бу эшне ике куллап якларга тотынды. Нуретдин абзый, дөрес әйттем микән, дип, бер дә шикләнеп тормасын. Ферма нәкъ шуның өчен төзелгән. Бу — уставка да, партия таләбенә дә тулысынча туры килә. Ләкин бу әле колхозчыларның үз терлекләре булмасын дигән сүз түгел, халык ялгыш аңлый күрмәсен, партия алай кушмый. Киресенчә, партия әйтә: «һәр колхозчының сыеры да, вак терлекләре дә, кошкорты да булсын»,— ди. Бар да бер чокырга җыела, барысы да халык байлыгы, ил байлыгы ул!.. Ә колхоз терлекчелеге исә продукцияне шулкадәр мул итеп бирергә тиеш ки, илнең чималга, халыкның азык-төлеккә, колхозчыларның үз ихтыяҗларына булган сорауларын тулысынча капларга тиеш. Әгәр колхозчылар, менә шушы муллыкка ирешер вакыт җиткән, үз ихтыяҗыбызга кирәкне дә үзебезнең уртак фермабыздан алсак иде, дип әйтәләр икән — бу бик урынлы һәм бик хаклы таләп. Нургали абый моны бик яхшы аңларга һәм халыкның бу таләбен иң якын киләчәктә үтәүне үзенең алдына сугышчан бурыч итеп куярга тиеш.

Әйе, ферма мөдиренең әле беркайчан да бу кадәр гарык булганчы күп итеп кимчелекләр, эшләнмәгән эшләр, аңлап бетмәгән нәрсәләр һәм ачу китергеч «тиеш»ләр ишеткәне юк иде. Йә, аның моңарчы тир түгеп эшләвеннән, көн-төн тырышуыннан, мин шундый зур эшләр башкардым, дип куанып йөрүеннән нәрсә генә калды инде? Шартлаган үгез куыгы — менә шул! Әйтәсе дә юк, бу үз-үзенә артык ышанган чибәр егет аны пешекләде, яман пешекләде, керләнеп беткән малайны эссе ләүкәдә аунатып, парлы себерке белән чапкан шикелле итте... Ләкин юк, Нургали үз хакын, үзенең яхшы исемен аяк астына салып таптатучылардан түгел. Егерме ел буенча туган колхозына бөтен җаны-тәне белән иткән хезмәтен болай ансат кына сызып ташларга ирек бирмәс ул, юк, бирмәс. Әле дөньяның чиге бер авыл советы белән генә бетми, әле партия оешмасы бар, әле аны яхшы белгән район җитәкчеләре бар. Биредә сүзнең башы гына булыр, ул, Нургали, кайда, ничек итеп үзен аклый һәм яклый белүен күрсәтер.

Ә Сөләйманов, гүя Нургалинең эчендә ниләр кайнага-

нын сизеп, юри аны котырткандай, соңгы сүзләрен болай дип бетерде:

— Мин ышанам, Нургали абый биредә әйтелгән киңәшләргә колак салыр, таза, эшчән тәнкыйтьне берсүзсез кабул итәр. Колхоз терлекчелегенең үсешен тоткарлап торган зур кимчелекләрне бетерү эшенә җиң сызганып керешер. Безнең бүгенге сессия аңардан шуны көтә!

Ул тукталды, ике кулы белән бил каешы астындагы гимнастеркасын төзәткәләде, аннан, җыелышка колак салгандай, беравык тын гына карап торды да акрын гына:

— Менә шул, иптәшләр, минем сүзем бетте,— диде.

Председательдән күзләрен алмыйча аны игътибар белән тыңлап утыручылар барысы да берьюлы, бер күкрәктән иркен итеп суладылар. Барысы да диярлек урыннарыннан кузгалыштылар, утырып оеган сөякләрен язар өчен аякларын сузып җибәрделәр, ә кайберәүләр авыз ачып иснәп, тәмле генә киерелеп тә алдылар.

Тәрәзәгә күз төшергән кемдер:

— Бәй-бәй, кояш та баеп бара лабаса! — диде.

Икенче берәү, аңа өстәп:

— Озак утырдык шул,— дип куйды.

Инде хәзер җыелышның тиз бетәсен белеп, күпләр кузгалырга җыена башладылар, җыелыш башыннан бирле тәмәке тарта алмыйча интеккән агайлар кесәләреннән янчыкларын, калай тартмаларын чыгардылар. Нургалинең соңгы сүзен тыңлыйсы гына калды. Соңгы сүз соңгы сүз инде ул. Сөйләсәң — хуп, сөйләмәсәң — гаеп итү юк. Ишеткәннәреңне чабуыңа төя дә, түкми-чәчми генә алып кит. Кайткач яхшысын яманыннан үзең аерырсың. Ә шулай да, бик озынга китмәсә, Нургалиебезне тыңлап карарга да ярый. Егетнең йөзенә караганда миегы бик чуалганга охшый. Эше зур булгач, сүзе дә зур булды шул. Хәер, утны-суны кичкән егет, тиз генә бирешә торганнардан түгел әле...

Нургали сизә — утырып арыган халык әнә шулай ялкау гына, теләр-теләмәс кенә аңардан соңгы сүзне көтә. Нургали бик нык уйлана: нишләргә, сүз алыргамы, юкмы, алса, ничек итеп сөйләргә? Ләкин мондый җитди бер моментта, халыкның игътибары сиңа карата аеруча көчәйгән бер чакта анык акыллы, салкын канлы булырга кирәк. Ә ул нервларының артык киеренке булуын сизә, ачуын тыеп, сабыр гына сөйли алмасын, беренче сүзеннән үк кызып китәсен, шулай итеп, үзен һәм эшен яклыйсы урында, бары Сөләймановка карата ачыктан-

ачык дошманлык күрсәтү генә булып чыгасын белеп тора. Ярамый бу. Аннан сессиядә утыручы халык белән дә хисаплашмыйча булмый. Хәзерге минутта халык аңа, Нургалигә карата бик үк уңай караштa түгел. Сөләймановның һәм башкаларның тәнкыйте аларның башын-күзен томалап өлгерде, саксыз сөйләп, аларны бөтенләй үзеңә каршы аякландырырга мөмкин.

Боларның барысын да ул, салкын акыл белән уйлап өлгерүдән бигрәк, эчке сизгерлек белән чамалап алды. Димәк, хәзер сүз алды исә, ихтыярсыздан ул сессия белән хисаплашырга, теләсә-теләмәсә дә, Сөләймановның тәнкыйтен кабул итәргә мәҗбүр булачак. Ләкин Нургали бу минутта һичбер нинди тәнкыйтьне, аның нигездә хаклы булуын сизсә дә, кабул итә алмый, чөнки кабул итү ул Сөләйманов алдында баш ию булыр иде. Юк, булмый, Нургали баш иючеләрдән түгел. Ул хәзер бары үзенең өстенлеген, көчен, горурлыгын сиздерергә тиеш. Әйе, аның бу җыелышны Сөләйманов өчен серле һәм шомлы итеп бетерәсе килә.

Халык шулай берара кузгалышып, акрын гына шаулашып тынгач, Сөләйманов урыныннан тормыйча гына:

— Алайса соңгы сүзне Нургали абыйга бирәбез,— диде.

Шунда ук берничә урыннан:

— Бирергә кирәк.

— Әйдә, сөйләп җиффәрсен, булмаса.

— Түлке, Нургали туган, сүзеңне кыска тот! — диделәр.

Нургали ашыкмыйча гына урыныннан торды. Аның гадәттә еш үзгәрүчән йөзе таштай хәрәкәтсез, күперенке кара мыек астындагы тулы иреннәре, бер дә ачылмаска теләгәндәй, нык кысылган иде. Ул, текә генә тураеп, кашлары бер-берсенә тартылган һәм аз гына йомыла төшкән күзләре белән беравык Сөләймановка туп-туры карап торды да, йомык иреннәре арасыннан көчләп чыгаргандай акрын гына:

— Мин... бер сүз дә әйтмим,— диде.

— Ничек әйтмисез?

— Шулай, соңгы сүздән баш тартам.

Сөләйманов та урыныннан торды. Ул, билгеле, шунда ук Нургалинең усал карашын да, ни өчен соңгы сүздән баш тартуын да аңлап алды. Ләкин бу хәлгә ничек тә игътибар итмәскә тырышып, акрын-сабыр гына итеп әйтте:

— Халык сездән көтә бит, Нургали абый...

Нургали җавап биреп тормады. Ул тирән тынлык

эчендә, аптырап калган халыкның сынаулы авыр карашын сер сынатмыйча күтәрергә тырышкандай, гәүдәсен туры тотып, кире урынына утырды. Сөләйманов иңбашын җыерып куйды, аның йөзеннән караңгы бер шәүлә шуып үткәндәй булды, шулай да ул югалып калмады, башлыча халыкны юатыр өчен булса кирәк, җитди генә итеп:

— Иптәшләр, Нургали абый безнең биредә әйткәннәр белән тулысынча килешкән булырга тиеш. Мин аның соңгы сүздән баш тартуын шулай аңлыйм,— диде.

Нургали селкенмәде, ул кәгазьдәй ак иде.

## III

Сессиядән соң Нургали туры өенә кайтып китте. Аның берәү белән дә очрашасы да, сөйләшәсе дә килми иде, дөнья эше белән дә һәртөрле кызыксынуы кинәт бетеп китте. Берни күзенә күренми, бернәрсә уйлыйсы килми, хәтта үзенең хәзерге хәлен дә аңлап карарга тырышмый иде ул... Гүя аның эченнән бөтен уй-хисләрен суырып алдылар да шулар урынына бернәрсә дә тутырмыйча буш баш, буш йөрәк белән кайтарып җибәрделәр.

Шундый хәлдә кайтып керде ул, тунын салып чөйгә элде, итекләрен салып бер читкә куйды, оекчан гына түргә узып, артлы урындыкка барып утырды. Ике кулы белән бераз тезләрен ышкып торды, аннан бер аягын сузып, икенче — авыру аягын чәнчеп, тезен кочаклап тотты да шул килеш утыра бирде... Хатыны Миңсылу учак алдында булаша иде. Ул аңа да шактый вакыт бер сүз дә дәшмичә утырды. Миңсылу үзе дә ни өчендер тын иде.

Шулай караңгылы-яктылы өй эчендә, учак утынын идәнгә төшеп уйнаган шәүләсенә карап, озак кына утырганнан соң, ниһаять, Нургали телгә килде.

— Аш ничек? — диде ул.

— Хәзер була,— диде Миңсылу.— Мин сине авыл советыннан фермага менәрсең дип уйлаган идем.

Нургали дәшмәде. Аның бу минутта авыл советын телгә алу түгел, үзенең иң кечкенә берәр хаҗәте турында да сүз әйтәсе килми иде. Шулай да ул Миңсылуның сорашмавына бераз гаҗәпләнә төште. Ихтыярсыз, бу хатын дигән нәрсәдән дә ваемсыз кеше юктыр, дип уйлап куйды.

Миңсылу: «Утны кабыз!» — диде. Нургали, урыныннан тормыйча, үрелеп кенә включательне борды — өй эче яктырып китте. Аннан Миңсылу өстәлгә киндер ашъя-

улык китереп җәйде, кашыклар куйды, икмәк, пычак китереп куйды. Ул бүген, кемгәдер хәтере калгандай караңгы чырай белән, каты басып ачулы йөри иде. Нургали бераз аңа сынап карап торды: нидән болай бу, Нургали үзе дәшми утырганга шулай ачулы йөриме? Алай дисәң, сәбәбен сорашырга тиеш иде, ул бит әле бернәрсә дә белми.

Әйтәсе дә юк, аның Миңсылуы да үзе кебек «характерлы» хатын иде. Бик сизгер, чая, телгә үткен, әйтсә —түшәмгә сикертерлек итеп әйтә, эшләсә — кулыннан ут чәчә. Ике кырыс бергә килсәләр дә, алар бер-берсен яратып торалар иде... Миңсылу чит авыл кызы, утыз алтынчы елны Яуширмәгә кунакка килгән җиреннән Нургалигә чыкты да куйды. Нургали аны бер күрү белән дөрләп кабынды: унҗиде яшьлек кызның тыгыз итеп үргән озын чәч толымнары, сызылып кына киткән нечкә кара кашлары, пешкән чия төсле коңгырт-кара, тере түгәрәк күзләре, бер үк вакытта көләргә дә, ачуланырга да әзер торган нечкә кызыл иреннәре, аз-аз гына күренеп куйгалаган вак кына ак тешләре, озын какча, ләкин тулы күкрәкле сыны егетнең һушын шундый алды ки, кызга авылына кайтып китәргә дә ирек бирмәде.

— Минеке бул, аннан кайтырсың! — диде ул, кат-кат, ялварып кына түгел, хәтта ачуланып та.

Мәсьәләне бу рәвешчә кискен кую кызны берничә көн генә булса да югалтып торасы килмәүдән битәр, бөтенләйгә югалтырмын, дип куркудан иде. Кыз буйсынды. Ихтимал, ул да күңеле төбеннән генә, бу кайнар егет суынып китмәсен, дип шикләнгәндер. Кыскасы, алар тимерне кызуында суктылар: әүвәл кушылдылар, аннан инде тиешле ризалыкларны алып, туй ясап җибәрделәр. Шундый баш әйләндергеч тизлек белән өйләнешсәләр дә, алар «характерлар туры килмәде» дигән аяныч хәлгә төшмәделәр. Дөрес, тормыш булгач, табак-савыт шалтырамыйча тормады, хәтта бик нык шалтыраган чаклары да булгалады (характерлары бу җәһәттән туры килә иде аларның), әмма шулай да алар бер-берсенә кирәк булуларын тирән тоеп, нык берегеп яшәделәр.

Хәзер инде алар олыгаеп баралар, элекке кебек күзгә-күз карашып кына да тормыйлар, шулай да тынгысыз, көнчелекле яратышуларының һич кимегәне юк иде. Миңсылу хәзер дә әле янып торган таза чибәр хатын, шуның өстенә искиткеч уңган, йорт-җир тирәсен «ялт» итеп тота. Һәм ел саен тау чаклы хезмәт көне эшләп ала. Тик аларның тормышында бер генә кимчелек, бер генә күңеллә-

рен шомландырган бәхетсезлек бар — ул да булса Миңсылуның бала китермәве... Менә ундүрт ел бергә торып, аларның әле бер генә балалары да булганы юк. Башта бу хәлгә артык игътибар итмәскә тырыштылар, ләкин торабара икесенең дә эчләре бик поша башлады.

Ел артыннан ел узып тора, ел саен алар Казанның яки Мәскәүнең зур профессорларына бару турында сөйләшәләр, ләкин әлеге дөнья мәшәкатеннән һич ычкына алмыйлар. Ә дөнья мәшәкате шундый нәрсә икән ул, аны куып узам, ди торгач, менә бүгенге кебек кайчак абынып та егыласың икән.

...Миңсылу өстәлгә агач табак белән токмач китереп куйды. Аннан кире барып, учак астына күмерләрне өештерде дә Нургали каршына килеп утырды. Ул, кашыгын кулына алып, иренең башлап ашка үрелгәнен көтә башлады, ә Нургали алдындагы ашны да күрмәгәндәй онытылып утыра бирде.

— Йә! — диде, ниһаять, Миңсылу.

Нургали иренеп кенә кашыгын алды. Иренә бик текәлеп карап торган Миңсылу кинәт ачуланып әйтә куйды:

— Йә, шулчаклы сөремеңне коеп утырма әле, әйтерсең дөнья җимерелгән.

— Дөнья җимерелмәс! — диде Нургали, хатынының ни өчен алай дип әйтүен аңламыйча, бары сүзгә сүз туры килгәнгә күрә генә.

— Син дә җимерелмәссең, Алла кушса,— диде Миңсылу, тавышын йомшарта төшеп.

Нургали гаҗәпләнеп хатынына карады: ни өчен ул алай дип әйтә?

Ә Миңсылу, Нургалинең гаҗәпләнүен тагы да көчәйтә төшеп, өстәде:

— Шул көзге әтәчнең сүзенә карап, ул хәтле көяргә ярыймы соң?

— Тукта, туктале, Миңсылу,— диде Нургали, ашка үрелгән җиреннән туктап.— Нәрсә сөйлисең син, кемне болай сүгәсең?

— Соң, кемне булсын, шул Мәстүрәнең йомыкый Закирын әйтәм инде... Кайчан аягына баскан да, кайчан кеше булган... ачуым килмәгәе, ә көн-төн эшләгән берәүнең башын ашамакчы була.

— Ничек башын ашамакчы була?

Нургалинең болай балаларча аңламаганга салынып утыруы Миңсылуны тагын ярсытып җибәрде.

— Нәрсә син, тилебәрән орлыгы ашаган кеше шикелле, томана булып утырасың? Кем әле үзеңне авыл советына чакырып адәм хуры итте, Закир түгелме соң?

— Авыл советында нәрсә булганын син кайдан беләсең?

— Ник белмим ди. Мин дә шушы авылда торам ла.

Нургали моңа каршы ни дияргә дә белмәде. Гаҗәп, гаҗәп бу хатын-кыз дигәнең, кай арада барысын да ишетеп, барысын да белеп өлгерә! Тәмам аптырауга төшеп, ул кыюсыз гына:

— Син, Миңсылу, бернәрсә дә аңламыйсың! — дигән булды.

— Минме? — диде Миңсылу, күзләрен зур ачып.— Мин аңламыйммы? Әйттең сүз! Минем хәтле аңласаң иде син, шул малай каршына барып та тормас идең.

— Мин аның каршына бармадым, мин авыл советына, депутатлар каршына бардым.

— Юкны сөйләмә,— диде Миңсылу, һаман кыза төшеп,— депутатлар чакырмады, ул чакырды сине.

— Ул — председатель.

— Булмагае... Ә син беләсеңме ни өчен ул моны эшләде, ни өчен халык җыеп, синең эшеңне сүтеп ташлады, ә?

Миңсылуның аяусыз кысрыклавыннан гаҗиз булган Нургали авыз эченнән генә әйтеп куйды:

— Шулай кирәк булгандыр инде...

— Кирәк булгандыр, кирәк булгандыр,— дип үртәде аны Миңсылу.— Юләр, шыр тиле син, үзең күлмәгеңнең белән беркатлы булгач та, башкаларны да шулай дип уйлыйсың. Ә башкалар, башкалар син түгел шул: эшне бик астыртын, оста йөртә беләләр... Йә, аңа, Закирга, мин әйтәм, синең эштә чокыну нигә кирәк булды әле?

Нургали дәшмәде, Миңсылу, көтеп торып, соравын яңадан кабатлады:

— Йә, әйт, нигә ул синең эшеңә тыгыла, нигә вакытлы-вакытсыз фермага тотына, ә?

— Каян белим мин.

— Белмисең шул. Алайса мин сиңа әйтеп бирим инде: баҗасы Фәттахны синең урынга куяр өчен бит ул шулай...

Нургали аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

— Булмас бу,— диде ул, кисәк кенә кычкырып һәм кашыгын читкә үк этәреп җибәрде.

Алар бер-берсенең күзләренә карашып тордылар: Миңсылу чын хакыйкатьне тәгаен белгән кешедәй бик батыр карый иде.

— Булмас түгел шул, бар,— диде ул, тавышын акрынайта төшеп.— Фәттахның Закирга, баҗай, мине юньле

бер эшкә дә куя белмәдегез, дип зарланганын үз колаклары белән ишеткән кешеләр бар.

Нургали әллә ышанмыйча, әллә тыңлыйсы килмичә, кызу гына башын чайкап торды, аннан кулын күкрәгенә куеп, сүзләрен өзеп-өзеп әйтте:

— Ферма мөдирен алыштыру — Сөләйманов эше түгел ул. Син шуны аңла. Колхозчыларның гомуми җыелышы гына аны эшли ала.

— Бигрәк тә беркатлы юләр син,— диде Миңсылу, чын-чынлап ачынып.— Колхозчыларны үз якларына аударыр өчен бит болар эшләнә. Ничек син шуны аңламыйсың? Башта, эшли алмый, кулыннан килми, булдыксыз, дип, яманатыңны чыгаралар, аннан инде алыштырырга кирәк, дип, халык алдына куялар. Шулай эшләнә бит ул...

Нургали һаман башын чайкап, авызының бер як кырые белән генә әче елмайган булды.

— Эх, нинди акыллы баш син, карчык! Әйтерсең мин кичә генә чит авылдан килгән бер кеше, әйтерсең минем кем булуымны да, ничек эшләвемне дә халык белми... Юк, Миңсылу, җанкисәгем, бер Сөләйманов белән Фәттах кына мине ияр өстеннән сөйрәп төшерә алмаслар... Аннан мин Закирның баҗасы өчен генә сессия кадәр сессияләр җыюына ышанмыйм да, андый этлеккә бармас ул!

— Ышанмасаң ышанмассың,— диде Миңсылу, иренең сүзләрен колагына да элмичә.— Ә мин ул йомыкыйның хәйләсен фаш итәчәкмен!

— Ничек итеп?

— Иртәгә үк авыл советына барып, үзен рисвай итәм. Минем Нургалигә баз казып маташма, барыбер баҗаңны ферма башына утырта алмассың, диярмен, әле син, диярмен, минем Нургалинең кулына су салырга да ярамыйсың, диярмен мин...

Нургали, күзләрен хәтәр елтыратып, кинәт өстәлгә тимердәй йодырыгы белән бер китереп сукты:

— Барып кына кара, мин сине чәчеңнән өрлеккә асып куярмын!

Миңсылу, сискәнеп һәм куркынып, Нургалинең каны атылып чыгардай булып бүртенгән йөзенә һәм мәче сыртыдай кабарып киткән кара мыегына карады: чынлапмы бу? Юк, Нургалие аның шаярмый иде, бик куркыныч иде ул бу минутта... Ә Миңсылу кайнар иренең дәртле һәм назлы йөрәген генә түгел, каты кулларын да бик яхшы белә иде. Хатын кинәт йомшарды:

— Соң, ир булып, үз-үзеңне яклый белмәгәч, мин нишлим инде,— диде ул, еламсырап.

— Минем хатын яклавына калганым юк әле, син шуны белеп тор! — диде Нургали, бик катгый рәвештә, аннан, бераз сүрелә төшеп, өстәде: — Ничәмә тапкырлар сиңа әйткәнем бар, тыгылма үзеңә кагылмаган эшкә, дип... Әле дә инде колхозда миңа кагылган берәр эш чыкса, «Нургалинең Миңсылуы ни әйтер бит әле»,— диләр.

— Начармыни ул? — диде Миңсылу, беркатлылык белән.

— Начар шул... Берәүнең дә бит хатыны ире өчен җиң сызганып талашып йөрми. Шуны аңларга кирәк.

— Алайса Дускаев белән барып сөйләшер идең. Үзегезнең секретарегыз ич, кемнең кем икәнен таный торган кеше, шәт, хәлеңә керер.

— Менә бер акыллы сүз әйттең, ичмасам,— диде Нургали һәм ни өчендер авыр гына сулап куйды.— Үзем дә ул турыда уйлыйм уйлавын, тик...

— Нәрсәсе тагын «тик»? — диде Миңсылу, яңадан кабынырга җыенып.— Бу ни булды сиңа, гаебең бар кебек, тәмам курку алган үзеңне!

Ләкин Нургали «калдыр, зинһар!» дигән төсле бары кулын гына селекте; аның, билгеле, Дускаевка карата булган шикләрен хатынына сөйләп торасы килмәде. Шуның белән алар арасында сүз дә бетте.

Ләкин бу сөйләшүдән соң, бигрәк тә йокларга яткач, Нургалинең йөрәгендә барысы да яңадан кузгалды. Сессиядән соң бер мәлгә туган бушлык бетте, басылып торган әлеге рәнҗү, хәтер калу, ачу килү кебек тойгылар барысы берьюлы, тау артыннан үрмәләгән көзге салкын болыттай, каяндыр төптән күтәрелә башладылар. Шуның өстенә Миңсылуның әйткәннәре, никадәр акылга сыймас булып тоелса да, аның йөрәгенә бер корт булып төште. Корт тынычлык бирми, корт акрын гына аның бәгырен ашый иде...

Киң агач караватта чалкан яткан килеш ул, тәрәзәдән иңгән төнге шәүлә белән чак сизелерлек булып кына күзгә шәйләнгән түшәмгә карап, керфек тә какмыйча бертуктаусыз уйланды, бүген күргәннәрен кат-кат хәтереннән кичереп, тегеләй дә, болай да аңлап карарга тырышты, ләкин күпме генә уйланмасын, аның тынгысыз уе, казыкка бәйләп куйган тай шикелле, һаман шул Сөләймановтан ычкынып китә алмады. Чыннан да, Миңсылу әйткәннәр дөрес булыр микән, чыннан да, бу кардан ак, сөттән пакь булып күренергә тырышкан чибәр егет бары баҗасы өчен генә шундый мәкер корып маташыр микән? Юк, булмас, булмас! Андый усал хәйләгә һәм намуссызлыкка барырга ул бик яшь әле, бигрәк тә

аңа, Нургалигә, каршы яшерен эш йөртергә аның йөрәге җитмәс, куркыр, куркырга тиеш ул. Ләкин... ни өчен Миңсылу алай дип әйтә, каян алып әйтә? Хатын-кыз андый нәрсәгә бик сизгер була бит ул! Бәлкем, аның әйткәннәре бөтенләй үк нигезсез түгелдер, белер-белмәс сөйләсә дә, бәлкем, дөреслеккә туры киләдер?

Закир Сөләйманов үткән көз генә (Октябрь бәйрәменә туры китереп) яшь укытучы Саимәгә өйләнде. Саимә шактый ишле гаиләдә үскән төп Яуширмә кызы иде. Моңарчы кул-аягы «туганлык җепләре» белән артык чорналмаган Закирның берьюлы каенага, каене-каенигәч, каениш, балдыз, баҗай кебек якыннары артып китте. Аларның «яшь председательгә» тигәнәк кебек сырышулары мөмкин бит... Әнә өлкән баҗасы Фәттах, чыннан да, колхозда үз урынын тапмыйча йөрүчеләрдән түгелме соң?

Фәттах Яуширмәнең бик борынгы колхозчысы, сугышка кадәр берничә ел тоташтан бригадир булып эшләгән кеше ул. 1942 елны мобилизация буенча Уралдагы бер хәрби заводка эшкә китеп барды. Аның семьясы — хатыны, җитеп килгән ике кызы һәм бер яшь малае һаман колхозда эшләп тордылар. Фәттах үзе сугыш беткәч тә әле берничә ел илгә кайтмады, кунакка кайткан чакларында, семьяны үз яныма, Уралга алдырам, дип тә сөйләнеп йөрде, ләкин кырык сигезенче елның ахырында көтмәгәндә генә ул, яшелгә буялган зур фанер чемоданын күтәреп, авылга кайтып төште. Абзыебыз бик өшәнеп, суырылып кайткан иде. Аның ашказаны авырта башлаган икән, докторлар аңа «ак аш» (сөт, катык, эремчек) белән генә торырга кушканнар... Билгеле инде, докторлардан андый киңәш ишеткән кеше тизрәк илгә, хатын янына, каймаклап тугыган катык ашарга, май аенда җыеп бәйләгән каен себеркесе белән мунча чабынырга ашыга ул...

Өендә бер ай чамасы ял иткәннән соң, Фәттах колхоздан эш сорады. «Хәл чамалы, эш бик авырдан булмасын»,— диде. Колхоз идарәсе аны фермага фуражер итеп куйды. Фуражер эше аның өчен авыр түгел иде: фермадан кешеләр киләләр, фуражны үзләре үлчиләр, үзләре төйиләр. Фәттах исә урталайга бөкләгән, яньчелеп беткән дәфтәренә, шәмәхә каләмне теленә тидереп теркәп кенә бара.

Ләкин тора-бара колхозның хәл-әхвәле белән ныграк танышкач һәм үзенә дә «ак аштан» рәт кергәч, аның фуражер кебек «вак» эш белән генә канәгать булып бетмәве сизелә башлады. Һәрхәлдә, Нургалигә шулай тоела

иде; гүя олы яшьтәге, тәҗрибәле, татарча гына түгел, русча да берникадәр укый-яза белгән кеше үзенә лаеклы эшнең чыгуын көтеп йөри иде. Димәк, аның эченнән генә ферма мөдирлеген өмет итеп йөрүе бик ихтимал бит? Соң, Нургали бит моның кайбер галәмәтләрен дә сизеп калгалаган иде, тик ул аларга моңарчы игътибар гына итеп җиткермәгән икән, хәерсез... Фәттахның, кулын артка куеп, ферма абзарлары тирәсендә караштыргалап йөрүе, сыер савучы, сарык караучы хатын-кызлар белән озак-озак кына сөйләшеп торуы, идарәдә яки ферма өендә сүз чыкканда терлекчелек турында акыл сатулары тиктомалга гына булмаган икән ул... Әйе, шик юк, Фәттах үзе Нургали урынын, бүген бирсәләр, ике куллап алыр иде.

Әмма Сөләйманов ничек соң, Сөләйманов? Шул баҗасын истә тотып кына, кайчан да булса аны ферма мөдире итәр өчен генә ул Нургалигә каныгырмы? Бары шул ният белән генә махсус сессия чакырып, ул Нургалинең эшен тәнкыйть итәрме? Әгәр шулай булса, әйтеп бетергесез зур кабахәтлек, оятсызлык бит бу! Бу бит иң-иң әшәке рәвештә халыкны алдау булып чыгачак! Ничек аның коммунистик намусы моны сыйдыра алыр? Ничек ул моннан соң кешенең күзенә туры карый алыр? Юк, булмас, булмас! Акыл сыйдырмый, күңел кабул итми моны... безнең кеше эше түгел бу.

Ләкин... шик, шик, һай, бу шик! Агач кортымыни — кимерә бит Нургалинең миен. Нургали хәтерли — фронтта вакытта, төнлә белән тын землянкада яткан чакта, агач кортының түшәм бүрәнәсен шулай эч пошырып акрын гына кытыр-кытыр кимерүе һәм агач вагының өстәлдә калган кәгазьләр өстенә кыштыр-кыштыр коелуы ишетелә торган иде. Нәкъ шуның төсле, шик аның уйларын кыра, ваклый... Миңсылуга аның җен ачулары килә — кайдан алып бу мәгънәсез, тузга язмаган сүзне әйтте ул: баҗасы Фәттах өчен, имеш!

Бик озак көрсенеп, азапланып ятты ул, өй бөркү булгангамы, йөрәге янганга күрәме, өстеннән калын юрганны да аягы белән ачып ташлады, һәм аның авыр уйлардан шешенгән башы ничектер бер арада тынгысыз, сискәнүле йокыга талды. Өзелмәгән уйлар саташулы төшкә әверелде, шул ук Сөләйманов, шул ук сессия, авыл советы бүлмәсендә утырган шул ук кешеләр аның күз алдында буталдылар, аларның сөйләшүләре, көлүләре, ерактан ишетелгән буа тавышыдай, колагында шаулап торды, тик төшкә әверелгән бу өн артык чуалчык иде, мәгънәсез иде.

Ахырында ул нәрсәдәндер сискәнеп уянды һәм башка йоклый алмасын белеп, төннең кайвакыты булуы белән хисаплашмыйча, урыныннан торды... Утны кабызгач, ул, авыр башын салындырып, урындыкта бераз утырып торды, яңадан йокы сыман әллә нинди бер онытылу баса башлаган кебек булды, шуннан кисәк кенә калкып, керфекләрендә асылынып торган йокыны гына түгел, ә бөтен тән хәлсезлеген, җан сүлпәнлеген селтәп ыргытырга теләгәндәй, ашыгып торды да, физзарядка ясаган шикелле, кулларын ике якка сузып җибәрде, терсәкләреннән бөгеп, таштай мускулларын калкытты, югары күтәрде, түбән төшерде һәм, ниһаять, тузган чәчле кара башын учлап, урынына утыртырга теләгәндәй, селкеп куйды. Берьюлы җиңеләеп калган кебек булды, ишек төбенә барып, асылмалы умывальниктан битен-күзен юды, чиккән башлы озын сөлге белән әйбәтләп сөртенде, аннан инде мич куышыннан җылы оекбашларын, чолгауларын алып киенә башлады... Туны белән бүреген дә киеп алгач, ул, кире утырып, тун кесәсе төбеннән сыпырып чыгарган тәмәкесен төрә-төрә, хатынына дәште:

— Миңсылу, Миңсылу, дим!

Агач караватта стена кырыйлап тәмле йоклап яткан Миңсылу бер дәшүдән генә уяна алмады. Кыш көне гел бер вакытта — сәгать биштә торып өйрәнгәнгә күрә ул хәзер каты йоклый иде. Шулай да ире:

— Миң-сылу! — дип, шактый каты кычкыргач, ул сискәнеп күзләрен ачты.

— Тфү, тфү, әстәгъфирулла, син кычкырдыңмы шулай?

— Кычкырмыйча, бөтенләй арт саныңны онытып йоклыйсың бит.

— Тиле,— диде Миңсылу, терсәкләренә күтәрелеп.— Йә, ни булды?

— Мин китәм.

— Китәсең, нишләп болай бик иртә?

— Эшләрем бар... Син мичеңне яккач, мин кайтуга, берәр таба аш пешереп тор әле.

Миңсылу, ялангач каратутлы кулларын күтәреп, чәчен рәтләде.

— Нәрсә, берәрсе белән кайтасыңмы әллә?

— Юк,— диде Нургали, тәмәкесен кабызып һәм бияләйләрен кулына алып,— үземнең сыйланасым килә. Шешәдә калганы бармы?

— Бар шикелле... Нәрсә әзерлим: беленме, кыстыбыймы?

— Анысын үзең кара инде,— диде ишек тоткасына тотынган Нургали.

...Ул тышка чыкканда, чак кына сызылып таң беленеп килә иде. Кош-корт уянган чак, абзар саен әтәч кычкыра, якындагысы тынуга, ерактан кычкырганы килеп ишетелә.

Ни өчендер әтәчләр кычкырган шушы вакытны «Галиябану таңы» дип атыйсы килә. Моңсу тынлык, бар да әле йоклый, тик мәхәббәттән сызланган яшь йөрәк кенә уяу... Бу һәр заманда, һәр халыкта шулайдыр кебек.

Соң гына калыккан тулы ай иренеп кенә җир түренә төшеп бара. Йолдызлар әле дәртле җемелдиләр, тик кара төндәге шикелле зәңгәрләнеп уйнаклап түгел, ә агарып тыныч кына җемелдиләр... Сулаган саен тәнне җиңеләйтә, адымнарны үзеннән-үзе тизләтә торган яңгыравыклы салкын, шифалы саф һава... Әмма март аеның шушы салкын һавасында каядыр якында гына йоклаган язның сулышы сизелә, гүя ай батып, йолдызлар сүнгәч тә, кышкы төн урынында язгы көн балкып туачак. Таң үзе дә хәзер күктән генә иңмичә, җирдән дә күтәрелә кебек, һәм караңгылык ике уртада эреп югала төсле... Әйе, бу вакытларда кыш белән язның янәшә — берсенең моңсу-хәлсез, икенчесенең йомшак-дәртле сулавын һәрбер җан иясе сизеп тора.

Нургали киң урам уртасыннан, көзгеләнеп каткан һәм тонык кына елтырап яткан чана юлы буйлап югары очка таба тәмәкесен көйрәтә-көйрәтә китте. Аның күн итекләре ара-тирә тайгалап куя, ә чана табаны батып узган җирләргә басканда, боз өлгеләре уалып кала иде. Урамда әле торып чыккан кеше күренми, берәм-сәрәм өйләрнең тәрәзәләрендә генә сары ут чагыла, морҗаларыннан ак төтен тын һавага ялкау гына күтәрелә, кайбер ишегалларыннан сыер мөгрәве, абзар капкасының шыгырдап ачылуы ишетелеп кала. Кышкы авыл яңа баш күтәрә, ә җәен бу вакытларда халык кырга китеп беткән була инде...

Менә Нургали Закир Сөләйманов өе турыннан үтә. Яңа такта түбәле, түбәсеннән нечкә генә антенна күтәрелгән, ике кечкенә тәрәзәсе белән урамга юаш кына карап торган бу җыйнак өйгә ул кырын караш ташлап, эченнән генә «яшь түрә яшь кәләш кочагында...» дип, ямьсез уйлап ала һәм, кемгәдер нәрсәдер исбат итәргә теләгәндәй, «без йоклап ятмыйбыз, без эшлибез, дүрт ел буена без шулай эшләдек, без эшләрбез әле» дия-дия уза.

Авыл очында, тегермән буасының ярына тезелешеп үскән һәм күксел бәскә төренгән мәһабәт тирәкләр бо-

такларын киң җәеп, бөтен яр буен караңгылап торалар. Ак бурадан салынган кечкенә тегермән кышкы айларда эшләми. Шунлыктан бу тирәләр хәзер тын, томанлы, тирәкләр караңгылыгында... Буадан бер йөз илле метр чамасы үрдә тигез тугайлыкка урнашкан ферма абзарлары да, җиргә чүккәндәй, томан белән өретелгән тәбәнәк, кар баскан калкулыклар булып кына күренәләр.

Нургали, буа күпереннән чыккач, ат юлыннан сукмакка төште дә биек тирәкләр астыннан яр буйлап фермага таба китте. Бу тирәкләр Нургали бала чакта да шулай биек, мәһабәт, карт иделәр. Соңгы егерме биш-утыз ел эчендә нинди искиткеч хәлләр булып үтмәде! Шул вакыт эчендә тирәкләрнең бары икесе корыды: берсен яшен сукты, икенчесенең — иң читтәгесенең — нәрсә өчендер бер зур баз казыганда күп кенә тамырларын кистеләр —шуннан корый башлады. Тамырны кисәргә ярамый икән, һәлакәт китерә икән ул... Шуңа күрә дә бит халыкта кешеләргә карата да «Тамырына балта чапма» дигән мәкаль яшәп килә. Әйе, әгәр кеше тирәк кебек озын гомерле булса, тагы да никадәр күбрәк белер иде, нинди бай тәҗрибә җыяр иде, яңадан-яңа тау кадәр эшләр башкарыр иде... Менә Нургали соңгы дүрт ел эчендә генә дә күпме эшләр эшләп өлгерде. Бирегез әле сез аңа тагын бер өч-дүрт ел гына вакыт, күрерсез шунда сез аның фермасын, Мәскәү күргәзмәсенә күчереп куярлык булыр... Әйе, әлбәттә, тик сез аның тамырына гына кизәнмәгез! Тирәкләр ышыгында туган бу уйлар Нургали өчен бер үк вакытта ләззәтле дә, әрнүле дә иде.

## IV

Ул фермага килеп җиткәндә, анда кызу эш бара иде инде. Эш биредә таң белән башлана, беренче савуны дүрт белән биш арасында ук үткәрәләр. Әнә сырма өстеннән ак халат кигән өч хатын киң авызлы, өсте ябык чиләкләрдә иртәнге сөтләрен ферма өенә китерәләр. Өй эченнән «гүү-гүү» итеп тонык кына шаулаган сепаратор тавышы һәм шуңа аралашып хатын-кызларның сөйләшкән, көлешкән тавышлары ишетелеп тора... Сыерлар абзарының урта ишеге киңенчә ачык, аннан тирес көрәп чыгаралар. Ике чанага ике үгез җигеп, ишек төбенә килеп туктаган ике яшүсмер юеш, парлы тиресне чаналарына төйиләр. Абзарның ары баш ишегеннән салам кочаклап эчкәре кергән хатыннар күренәләр... Бозаулар абзары, аңардан ары сарыклар белән дуңгызлар абзары тирәсендә дә чиләк күтәргән, көрәк тоткан шәүләләр

чуалалар. Ихата түрендәге ферма алачыгының морҗасыннан ишелеп-ишелеп куе төтен чыга; анда зур бакларда бозаулар, буаз сыерлар өчен су җылыталар, казаннарда дуңгызлар өчен бәрәңге пешерәләр, кайбер маллар өчен генә печән вагы парлыйлар... Алачыкның стенасы аша тыштан эчкә үткәрелгән улак янында юан корсаклы туры ак җиккән үрәчәсез чана белән бозланып каткан мичкә тора; кыска соры чикмән кигән су ташучы Әпкәли (Габделрәхим) бау таккан кара чиләк белән мичкәсен улакка бушата.

Нургали бу эш-хәрәкәтнең барысын берьюлы диярлек күреп алды. Көн дә шулай, көн дә ферма эше, бер дә туктый белмәгән сәгать шикелле, үз җае белән барып кына тора.

Әмма шулай да Нургали бүген ферманың киртә капкасыннан үзен яңа, ят бер кеше сыманрак тоеп килеп керде. Ничектер аның бу әллә кайчан күз ияләшеп беткән ферма каралтыларына һәм анда эшләп йөрүчеләргә башкачарак, беренче тапкыр күргән кебегрәк карыйсы килде... Һәм, билгеле, ул үзе өчен сәер булып тоелган бернәрсә дә күрмәде. Тик менә йөз метр ераклыкта гына яткан буадан мичкә белән су ташу... бер дә кызык түгел. Хәер, аның моңа күптәннән эче пошып йөри иде. «Чит кеше килеп күрсә, хурлык, билләһи, ярамый, ярамый. Су җәфасын быел җәйдән калдырмыйча хәл итәргә кирәк. Бу Әпкәлинең үзе дә, үрәчәсез чанасы да ферма ихатасында булмасын»,— дип узды ул.

Нургали, беркая да сугылмыйча, туры сыерлар абзарына китте. Нәкъ ихата уртасында ул кара толыпка чорналып тик кенә басып торган каравылчы Хисмәт абзыйга очрады. Тәмам каршысына килеп баскач кына, ул аңа дәеште:

— Нихәл, Хисмәт абзый?

Баганадай озын Хисмәт селкенеп куйды.

— Шөкер әле, Нургали туган! — диде ул, гаять көр, мәһабәт тавыш белән.

Беренче тапкыр бу тавышны ишеткән кеше чын-чыннан хәйранга кала торган иде: кайдан килгән бу абзыйга мондый сирәк очрый торган саф, көчле калын тавыш? Менә талант! Хәтта, былтырмы икән шулай, газетадан килгән бер егет аңа:

— Чистый Шаляпин икәнсең син, абый! — дип киткән иде.

Хисмәт абзый үзе, эченнән күпме уйланса да, ни өчен, нәрсәсе белән «Шаляпин» булуын һич аңлый алмады, башкалардан сорарга кыймады, ахырда, «Шаляпин» ул

«эшләпә» дигән сүздән алынгандыр, минем озын булуыма карап әйтелгәндер, дип юрап куйды.

Нургали, исәнләшкәннән соң:

— Йә, Хикмәт абзый, ул-бу юкмы? — дип сорады.

— Иминлек, Нургали туган, шылт иткән нәрсә юк,— диде Хисмәт абзый, аннан бераз көттереп: — Менә Кәримәнең «Алма»сы, шөкер Хода, исән-имин котылды,— дип өстәде.

— Шулаймыни? Күптәнме?

— Әле яңарак кына булса кирәк.

Нургали абзар ишегенә китте, Хисмәт абзый, сүс бау таккан берданкасын бер иңбашыннан икенчесенә күчереп, аның артыннан иярде.

— Кәримә үзе мондамы соң?

— Монда, Нургали туган, монда. Рәхмәт төшкере, кыз төн буе «Алма»сы янынннан китмәде.

— Галләм абзый да мондамы?

— Монда. Ярты төннән бирле ул да сагалап йөрде.

— Алай. Бүген дежур кем әле, Сөембикәме?

— Әйе, чалыш Хәйбулла килене Сөембикә дежур бүген. Инсафлы хатын, югалып йөрми, гелән терлекләр янында... Ул булганда җан тыныч, ичмасам.

— Ярый, ярый, Хисмәт абзый!

— Ярамаган кая, Нургали туган... Кешеләребез, шөкер, әйбәтләр, ферманыкы дип тормыйлар, әйе, үз терлекләреннән битәр карыйлар...

Һәр көнне шулай Хисмәт абзый үзенең көр тавышы белән салмак кына гөрелдәп, Нургалигә төнлә күргәнбелгәннәрен сөйләп, бераз ияреп йөри-йөри дә аннан берәр җирдә туктап кала иде.

...Абзар эче ярым караңгы, җылы тирес һәм сөт исе аңкый... Нургали озын коридор буйлап тирә-ягына карана-карана, шул ук вакытта араннардан көрәп чыгарылган тирес өемнәренә абынмаска тырышып, абзарның ары башына бара. Сыер савучыларның кайберләре араннарын чистартып бетергәннәр, сыерларына тураклап җылы су белән чылатылган салам өләшеп йөриләр. Ә кайберләре исә һаман араннарын чистартып маташалар.

Әле теге, әле бу аранда сыер савучыларның:

— Түчә!

— Кузгалсана!

— «Зорька», җанкисәгем, сабыр ит!

— Чистый убыр икәнсең!

— Аша, аша, малкаем! — дип дәшүләре һәм сыерларның авыр мышнаулары ишетелә.

Иртәнге өлешләрен алган сыерлар койрык очларын

уңга-сулга селеккәләп, юеш саламны ашыкмыйча озак кына күши-күши ашыйлар, ә алып өлгермәгәннәре аран чистартучы хуҗаларының артында «тизрәк бул инде» дигән төсле мөгрәп торалар.

Араннардан чыгарылган тиресне ике хатын көрәкләр белән абзар ишегенә таба этәрәләр. Нургали алар белән исәнләшеп узды. Хатыннар:

— Әйбәт әле!

— Шөкер әле! — дип калдылар.

Нургали бер аран янында тукталды һәм тирә-ягына каранып:

— Кем, Җиһан, кайда син? — дип дәште.

Өченче араннан түп-түгәрәк битле, төптәй таза бер кыз чыкты.

— Нәрсә, Нургали абый?

— Кара, сыерыңның ярты саламы идәндә бит. Нигә җыймыйсың?

Кыз, аранга кереп, сыерның янбашына учы белән каты итеп сукты.

— Чукынган да нәрсә инде, тузгытып ашый бит, ни эзли торгандыр, убыр!

— Син, Җиһан, хайванны алай ачуланма,— диде Нургали, олыларча акыл биреп.— Ул гаепле түгел. Тузгытып ашый икән — берьюлы бирмә, бүлеп-бүлеп бир.

— Тагын шул гына җитмәгән,— диде кыз, шактый дорфа итеп.

Нургали, аптырап, кызга текәлде: кара, кара, нигә әле бу үзе болай тузгый? Ә кыз җәһәт кенә иелде дә сыер аягы астыннан вак саламны кулы белән сыпырып җыя башлады.

— Иртә салам, кич салам,— диде ул, ачулы сукранып,— кемне гаепләргә дә белмәссең монда.

Кичәгенең зәхмәте бу, дигән уй кинәт Нургалинең йөрәген чәнчеп куйды. Шунда ук аның йөзенә ачу бәреп чыкты, бик яман итеп кызны сүгеп ташлыйсы килде, ләкин үзен ничек тә кулга алырга тырышып, ул карлыга төшкән тавыш белән:

— Син, сеңелкәш, дулама! — диде.— Юкны таптыра торган вакыт түгел, барын әйбәтләп ашата бел. Менә шул!

Кыз дәшмәде, эшен эшли бирде, ә Нургали башка әйтер сүз таба алмыйча бераз таптанып торды да кисәк кенә борылып китеп барды.

Абзарның аргы башында, уң яклап, такта белән бүлеп алган зур бер аран — бүлмә бар... Стеналары тыштан да, эчтән дә известь белән акка буялган бу бүлмә сыерлар бозаулый торган махсус урын — вакыты җиткән буаз

сыерны шунда күчереп тоталар. Әлбәттә, аның тулай абзар эчендә булуы ярап бетми бетүен, ләкин башкача чара юк, кул моңарчы зуррак, әһәмиятлерәк төзелешләрдән бушамады. Быел җәй Нургали аерым йорт салдырырга уйлап йөри, тик ни булып чыгар, ел саен бит «ашыгыч», «кичектермәс» объектлар туып кына торалар. Менә быелдан да калдырмыйча бозаулар абзарын зурайтырга, профилакторий салдырырга кирәк, дуңгызлар өчен үзләренә бөтенләй аерым, бер читтә урын булдырырга кирәк, югыйсә алар хәзергә кадәр сарыклар белән бер кыек астында яшәп килделәр... Болар — зурлары, ә ваклары аның күпме чыгып тора! Барын да исәплә, барын да күр, барына да материалын тап, барына да өлгер!

Нургали бүлмәгә килеп кергәндә, «Алма», чыннан да, Хисмәт абзый әйтмешли, исән-имин котылган иде инде. Ветсанитар Галләм абзый белән Кәримә «Алма»га тиешле ярдәмне күрсәтеп, бозауны кабул итеп алганнар.

Тууына күпме генә вакыт үткәндер, әмма нәкъ әнисе төсле аклы-каралы чуар бозау, ак тояклы нечкә аякларын дүрт якка аера төшеп, басып ук тора. Әнкәсе «Алма» акрын гына мөгрәп, кытыршы телен сузып бозавының яңакларын, колакларын, муенын, аркасын, янтыгын, ботларын, корсак астын ялый иде. Кәримә, Галләм абзый, дежур Сөембикә бер читтәрәк басып, сүзсез генә бу күренешкә сокланып карап торалар.

Нургали килеп кереп, бозауны аяк өстендә күргәч, аптырап китте.

— Тфү, тфү, күз тия күрмәсен,— диде ул, бозау янына узып.— Нәрсә, бу чибәр туганда ук аягүрә тудымы әллә?

Сыер, бозавына якынлашкан Нургалигә «тимә!» дигән төсле, сәер бер тавыш белән кыска гына «мө-ө» дип куйды.

— Аягүрә тумады тууын, әмма үзең күрәсең, Нургали, бозавыбыз, шөкер, яман түгел,— диде Галләм абзый, артык мактарга теләмичә, ләкин шул ук вакытта мактыйсы килүен яшерә дә алмыйча.

Дежур Сөембикә, Галләм абзыйның тыйнакланып маташуы белән килешеп бетмәде, ахрысы, шунда ук ашыгып өстәде:

— Бозау, Нургали абый, сокланып туймаслык инде кара син аңа, хәзер үк бит колакларын селкетеп тора!

Әйе, сүз юк, бозау карап торырга бик чибәр иде. Башка яңа туган бозаулар белән чагыштырганда, ул гәүдәгә шактый зур, таза, йомры иде. Кечкенә башын кыска муены өстендә, үзенә күрә түгел, текә генә тоткан була,

өсте елкылдап, тамак төбе матур гына сырланып тора. Сөембикә әйткәнчә, хәзер үк инде дәртләнеп, башын селеккәләп, колакларын уйнаткалап ала.

Нургали аның янына чүгәләп, сыйпап сөймәкче булган иде дә, әнисе борчыла башлагач, торып, арткарак чигенде.

— Менә, Кәримә акыллым, көн-төн карауларың бушка китмәде бит,— диде ул, бозауга булган соклануын һәм нечкәрүен янында басып торган кызга күчереп.— Нинди асыл бозаулы булдың!

Ә Кәримәнең тирләгән ак йөзендә, дымланган кара күзләрендә шундый тирән сөенеч иде ки, сүз әйтерлек тәкате калмаган иде аның, авызын ачты исә, елап җибәрер төсле иде ул... Үзен ничек тә кулга алырга, сөенеч яшьләре булып түгелергә торган бу шатлыгын аз гына булса да тыярга тырышып, ул аскы иренен тешләп тиз генә «Алма»ның икенче ягына күчте.

— Үзе, җитмәсә, бикәч икән,— диде Нургали, Галләм абзыйга борылып.

— Әйе, гомере генә булсын, әнкәсе кебек затлы мал булыр бу...

— Әйбәт кенә бер исем табарга кирәк булыр инде үзенә.

— Исем?.. Әйе, матур исем кирәк бу төтен күзгә...

Сыерның икенче ягына чыгып яшеренгән Кәримә моны ишеткәч, ашыгып, гүя башка бирәү ярамаган берәр исем биреп ташламасын дигән төсле, әйтеп куйды:

— Минем әзерләп куйган исемем бар инде.

— Шулаймыни?! Ничек соң?

— «Хөрмә», «Хөрмә» булыр аның исеме,— диде Кәримә, үз баласына дәшкәндәй, шундый назлы итеп.

— «Хөрмә»?

— Әйе, «Хөрмә»!

— «Алма»ның баласы «Хөрмә»! Ярый бу, ярый...— диде Галләм абзый.

Сөембикә дә аран эчен яңгыратып көлеп җибәрде.

— Һай, Кәримә бәгырем, каян күңеленә килгән! Кушып җырларга була хәзер: берсе алма, берсе хөрмә, берсе кура җиләге...

Бар да ашыкмыйча гына көлешеп алдылар.

— Фермабыз акрынлап бакчага әйләнә, ахрысы,— диде Нургали.— Тәзкирәдә «Роза» бар, Зәкиядә «Ал чәчәк» бар, Нурислам картта — нәсел үгезе «Балан».

— Булсын, булсын, Нургали абзый,— диде Сөембикә, аны бүлдереп,— бакча кебек мул җимешле булсын фермабыз.

— Ни әйттең иде!

Кәримә кире бу якка чыкты да әнисенең имиенә үрелә башлаган «Хөрмә»не, маңгаеннан сыйпап, йомшак кына тамак астыннан тотып алды.

— Йә, йә, нанькам, йә, йә, матурым, менә хәзер сауганын эчәрсең, күп итеп эчәрсең! — дия иде ул, ярым кызгану, ярым иркәләү белән.

Ә «Алма» һаман әлегәчә акрын гына мөгрәп, бозавы белән бергә Кәримәнең кулларын да ялап-ялап ала иде. Ул үзенең караучысын бик ярата булса кирәк, бозавын гына өзелеп назлау түгел, Кәримәгә дә бөтен күрсәткән яхшылыклары өчен гүя рәхмәт укый, бу минутта кичергәннәрен аңа да аңлатырга тели кебек иде.

...«Алма»ның шулай мөгрәвеннән әсәрләнгән Сөембикә:

— Теле генә юк малкаемның, әллә ни әйтер иде,— дип куйды.

— Үзенчә әйтә инде ул, Сөембикә,— диде Галләм абзый, бернәрсәгә дә исе китмәгән кеше сыман сакалын сыпырып.— Аптырама, йөрәгендәге аңлата белә ул.

Бу минутта Нургалинең дә күңеле нечкәреп китте, ничектер, күзләре дымланып, тамак төбе кымырҗып куйды. Сәер кеше ул, үз кулы белән аның тавык та суйганы юк. Элек-электән ул хайваннарны кызганып, аларга гел йомшак мөгамәләдә булып килде. Кайчан шулай үзенең кызу характеры аркасында берәр малга кул күтәреп сукса да, соңыннан ул бу эше өчен үкенеп йөри һәм рәнҗетелгән малның ничек тә күңелен табарга тырыша торган иде. Кеше белән хайван мөнәсәбәтенә карата аның хәтта билгеле бер карашы да бар: аныңча, хайваннар кешеләрне беренче күрүдән үк «таный» беләләр, «яхшы кешегә» үзләре үк киләләр һәм аңа бик тиз ияләшәләр; «усал кешегә» кырын торалар, аңардан читләшәләр, һәм беркайчан да андый кеше белән хайван арасында яхшы мөнәсәбәт урнаша алмый... Нургалинең мондый хәлне практикада сынаганы бар, шуңа ышана ул һәм фермада эшләүчеләрнең терлекләргә мөнәсәбәтләрен үзенчә тикшереп тора. Ул хәтта терлекләр белән дуслаша алмаган берничә яшь кызны икенче берәүләр белән алыштырырга да мәҗбүр булган иде.

Кыскасы, ул, асылда йөрәк кешесе булганга күрә, хайваннарның кичерешләренә бервакытта да салкын канлы булып кала алмый иде. Дөрес, ул моны ачык итеп күрсәтүдән ничек тә тыелырга тырыша, чөнки ферма кешеләре алдында үзен артык нечкә күңелле итеп танытасы килми иде.

Менә хәзер дә ул, үзенең дулкынлануын басарга тырышып, күперенке кара мыегын бармак битләре белән сыпырып торды, торды да, тавышының гадәттәгечә табигый нык булуына ышанганнан соң, бернәрсә дә булмагандай Галләм абзыйга дәште:

— Бозауны үлчәмәгәнсездер әле, Галләм абзый?

— Юк әле, менә әнкәсе тынып калсын дидек, хәзер илтәбез.

— Ярый алайса, мин бозаулар янында булырмын,— диде Нургали һәм «Хөрмә»не әнисеннән аерып алып китүне күрмәс өчен алдан үзе китеп барды. Билгеле, сыер, бичара, бозавыннан аерылуны бик авыр кичерә, бик борчыла, һаман эзли, сорый, йөрәккә төшәрлек итеп кычкыра, йә бертуктаусыз мөгрәп тора. Ләкин бозауны әнисеннән аеру зарур, элек әле туган минуты белән алып китәләр иде, хәзер исә туган әнисенә яларга бирәләр... Әнисеннән ялатуны хәзер тәҗрибә ияләре дә, фән кешеләре дә бозау өчен файдалы дип табалар.

Әмма, ничек кенә булмасын, фермага килүе белән иң яхшы нәселле сыерның шулай исән-сау бозаулап торуы Нургалинең кәефен бер мәлгә яхшы якка таба шактый нык үзгәртеп җибәрде. Ул үзендә гаять зур дәрт уянуын тойды. Таулар актарасы килә иде аның, бүген эшләп туймас шикелле иде ул... Хыялында әллә нинди планнар туып өлгерде... Ферманы районда гына түгел, бөтен республикада беренче итеп куя алуына, каяндыр килеп, үзендә бик нык ышаныч туды.

Бу дәртләнүнең һәм хыяллануның төбендә һаман әлеге исбат итәсе килү теләге ята иде: Сөләймановка, юк, бер Сөләймановка гына түгел, ә аны тәнкыйть итүчеләрнең барысына да үзенең ничек эшли алуын күрсәтәсе килә... Аныңча, тәнкыйть итүчеләр аның эшен бер дә яхшы итеп күрергә теләмиләр, чөнки ул яхшы эшләгәч, аларга тәнкыйть итәргә урын калмый, ә Сөләйманов кебек эшләр кемнең дә булса кимчелеген күрмичә, гаебен тапмыйча тора алмыйлар...

Шундый гаҗәеп бер логика белән Нургали эшкә тотынмакчы була, аңарда дәрт, энергия, ачу һәм ярсу —барысы бергә кайный. Ул эченнән тәнкыйтьчеләр белән бертуктаусыз бәхәс алып бара, ләкин — гаҗәп бер хәл! — нәрсә генә эшләргә җыенмасын, аның эше, үзе дә сизмәстән нәкъ тәнкыйтьчеләр кушканча булып чыга иде.

Кечкенә «Хөрмә»не үлчәп, яңа туган бозаулар өендә калдыргач, Нургали, Галләм абзый белән Сөембикәне ияртеп, кире сыерлар абзарына кайтты. Бер генә минутка Кәримә янында тукталдылар. Кәримә «Алма»ның

ботларын, койрыгын, җиленен җылы су белән юган, астын алыштырып, яңа салам түшәгән, хәзер зур ак чиләккә беренче угыз сөтен савып утыра иде. Алар килеп кергәч, «Алма» зур башын әле берсенә, әле икенчесенә сузып кат-кат һаваны иснәде һәм, башта акрын гына мөгрәп торды да аннан йөрәк өзгеч итеп бер кычкырып куйды: гүя ул «баламны кая куйдыгыз?» дип сорый иде. Аның хәлсез-тонык караган һәм кан йөгергән зур күзләрендә үпкә катыш тирән әрнү чагыла иде. Кәримә торып, чүчү, «Алмакаем», дия-дия аркасыннан сыйпарга тотынды, «Алма» исә, башын аңа таба борып, җиңеннән ялап алды.

— «Алма» түти борчыламы?

— Борчыла шул.

— Менә хәзер үзенә туйганчы бер яхшы печән ашатасы иде,— диде Галләм абзый, кыюсыз гына.

— Шулай дисеңме?

— Шулай димичә соң, печән булса, малкайга хәл кереп китәр иде.

— Печән юк бит.

— Юк шул,— диде Галләм абзый, авыр көрсенеп. Нургали кызу гына китеп барды. Галләм абзый аның артыннан иярде. Абзар коридорыннан тиресне көрәп чыгарганнар, ул буеннан-буена чистарып, бушап калган. Араннарда сыерлар дәррәү генә салам ашыйлар. Нургали бүген һәр сыерга сынап, тикшереп карамыйча үтә алмый, хәер, ветсанитарны ияртеп бөтен терлекләрне шулай күздән кичереп чыгу аның өчен, ферма мөдире булган көннән алып, һәр тумыш көн кабатлана торган бер эш, ләкин шулай да бүген ул башкачарак, чит кеше булыбрак, беренче тапкыр күргән шикеллерәк итеп карап уза. Һәм, дөресен әйтергә кирәк, күзе белән күргәнне намусыннан яшереп маташмый: әйе, сыерлар арык. Күбесенең эчләре суырылып, иңбашлары таяк башыдай калкып, кабыргалары сырланып тора. Җиленнәре бөрмәле буш янчык шикелле җыерылып, кечерәеп калган, әйтерсең аларның бер дә сөт белән тулганнары юк... Дөрес, хәзер кыш ахыры, азыкның бик кысан чагы, терлекләрнең иң өшәнгән бер вакыты, шунлыктан аларның бу кыяфәтләренә, бәлкем, артык ис тә китәргә ярамый торгандыр. Әмма шулай да... Нургали, кем алдындадыр акланырга теләгәндәй, кинәт кызып китә:

— Кичәге җыелышны әйтәм әле, Нуретдин абзый әйтә, сыерның сөте тел очында, ди. Кем аны белми, балага сөйлә син аны... Шул шул. Иң элек фермагызны азык белән әйбәтләп туйдырыгыз, аннан сөт таптырырсыз. Әйе!

Галләм абзый, Нургалинең сүзләренә кушыласы килмәгән бер чырай белән ияген күтәреп, сакал астын кашый. Нургали, шуны сизгәндәй:

— Юк инде, быел дурак булмам,— ди, уң кулын каты йодрыклап,— терлекләргә кирәген сугышып алырмын, печәнен дә, бәрәңгесен дә, көрпәсен дә... Җитәр!

— Азыкны яздан ук хәстәрли башларга кирәк аны, Нургали, шунда да әле ул таманга килә.

— Дөрес әйтәсең, Галләм абзый, конешно, шулай кирәк. Идарә алдына мәсьәләне каты куячакмын... Үзең беләсең, без болынга бай түгелбез. Безгә күп итеп үлән чәчәргә, күп итеп тамыразык чәчәргә кирәк...

Галләм абзый тагын үз сүзен кыстырып куя:

— Аннан бар кадәресен вакытында әрәм-шәрәм итмичә җыеп та алырга кирәк.

— Конешно, конешно. Боларның барысы турында да, Галләм абзый, минем бик шәп төзеп куйган планым бар,— ди Нургали, бүген генә күңеленә килгән кайбер уйларын чынга юрап.— Язгы чәчүгә генә төшик, бераз баш-күз алгач та, идарә алдына мин ул планымны җәеп салачакмын... Сөләйманов шикелле мин кирле-мырлы эшләргә яратмыйм.

Галләм абзый дипломатларча дәшми кала, ә Нургали һаман шулай араннардагы сыерларга бик дикъкать белән карый-карый алга китә. Ни әйтәсең, сыерлар ваклар, күбесе ваклар, хәтта култык астына кыстырып алып китәрдәйләре дә бар. Нинди нәселдән дип тә булмый аларны, борыннан килгән вак нәсел дә, колхоз вакытында алынган кайбер эре нәселләр дә сугыш вакытында буталып беткәннәр. «Ярамый болай,— ди Нургали, эченнән генә көрсенеп,— нәселне тазартырга, сафландырырга кирәк, әнә шул Кәримәнең «Алма»сыннан, Хәлимәнең «Зорька»сыннан, Тәзкирәнең «Роза»сыннан туган бозауларны аерып тәрбияләргә туры килер. Югыйсә нәрсә бу? Кешегә күрсәтергә оят, прәме!» Ләкин бу уйларын, кичә генә турыдан-туры кеше авызыннан ишеткәннәрен Галләм абзый белән уртаклашырга, билгеле, аның батырчылыгы җитми. Ләкин бертуктаусыз җанын борчып торган ниндидер ярсулы ачыну аның йөрәгендә килгәннән бирле тыгызлана, һаман күп итеп сөйлисе, бушанасы килеп тора... Юк сәбәптән дә, бәлкем, ул бүген бушаныр иде, әмма хәзергә җай чыкмый әле.

Сыерларның чисталыгын да яхшыдан дип булмый, күбесенең алгы тез башлары, арткы янтыклары буялып каткан, аркаларына юл-юл булып тузан утырган, ә кайберләренең сыртларына укра да оялый башлаган. Галләм

абзый белән Нургали бик кечкенә кара сыерның аркасын сыйпап-сыйпап карадылар. Тире астында каты төер сыткы бик ачык кулга беленеп тора. Галләм абзый шул сыткының берсен ике бармагы белән каты кысып сытты һәм аның эченнән корт чыкты. Бу укра иде.

— Хәерсез! — диде Галләм абзый, кортны алып ташлап.— Яз җиттеме, арык хайванның теңкәсенә тия башлый инде.

— Чүпләргә кирәк үзләрен.

— Кирәк шул. Һәммәсе дә сыерларын карап чыксыннар, аннан миңа әйтерләр.

Нургали сыер савучыларның абзарда булганнарын үз янына чакырып алып, аларга хәзер үк сыерларын тикшерергә һәм сыткылары барын Галләм абзыйга күрсәтергә кушты. Кайберләрен орышып та алды.

— Бу ни бу, Мәфтуха, сыерыңның өстенә карарлык түгел. Безобразие. Кем, Җамал, синең дә әнә «Зирәг»ең янбашына хәтле буялып беткән. Нигә күрмисез, ә? Нигә чистартмыйсыз, кем эше дип беләсез, ә? Әллә булмаса мин йә менә Галләм абзый килеп чистартканны көтәсезме?

Хәтерләре калган кызлар сузынкы тавыш белән көйләп, шаулашып алдылар:

— Чистартырбыз ла инде, Нургали абый!

— Хайван лабаса ул, хәзер чистартасың, хәзер пычрана.

— Бигрәк тә инде, ак җәймәгә яткырыйкмыни соң үзләрен?

Нургали тавышын тагы да күтәрә төште:

— Нәрсә, сүз көрәштереп торыр идегезме әллә? Оят кайда, ә, Мәфтуха, сиңа әйтәм?! Ак җәймә, имеш! Ак җәймә — әнә чиста салам. Иренмичә, ешрак алыштыр. Күрәм: вазифаларыгызны оныта башлагансыз. Юк, ярамый болай, ярамый! Хезмәт дисциплинасын бозарга мин юл куймам, эленке-салынкы йөрүчеләр белән минем сүзем кыска булыр, белеп торыгыз аны! Менә шул, чибәрләрем! Бүген үк, сыерларыгызны кояшка чыгаргач, себерке, кыргавычлар белән коралланасыз да һәммәсен дә ялт иттереп куясыз. Ялап алган кебек булсын, ишеттегезме?

Кызларның кайберләре генә:

— Ишеттек! — диделәр, һәм шелтәгә эләккәннәре авыз-борыннарын турсайтып, эләкмәгәннәре авызларын каплап көлә-көлә, сүзсез генә урыннарына таралдылар.

Нургали, аларның артларыннан карап, үзалдына гына:

— Дисциплина, дисциплина йомшара башлаган, мин

сиңа әйтим! — дип куйды. Кем сүзе иде бу, кичә кем ферма эшчеләренә бу гаепне ташлаган иде — ул кадәресе аның күңеленә килмәде.

Аннан алар әчкелтем исләр аңкып торган дуңгызлар абзарына керделәр. Ишектән кергәч тә нәкъ каршыдагы иркен аран эчен тутырып галәмәт олы дуңгыз ята. Бу —«Бояр» исемле токым үрчетә алудан узган карт ата дуңгыз.

Нургали гадәтенчә аңа ачык чырай белән кычкырып дәште:

— Исәнмесез, исән-сау гына ятасыңмы, «Бояр» дус!

Әмма карт «Бояр», ашап туйганнан соң, шундый онытылып, тәмам рәхәткә чумып йоклый ки, әйтерсең ул бу фани дөньяда да түгел. Күпме генә дәшмә, ул колагына да элми, ак керфекләрен дә, ичмасам, селкетми, искиткеч игътибарсызлык һәм гамьсезлек үзендә... Шуның өчен дә Нургали аны бик ярата, аның зурлыгына сокланып бетә алмый. Ә «Бояр» зур, бик зур, аның чит-читләре җыерылып торган ике янәшә тишекле түгәрәк борыны өлеш тәлинкәсе кадәр бар, колаклары, юләр әйтмешли, әрекмән яфрагы хәтле булыр, шуңа күрә дә ул бөтен аран эчен берүзе тутырып, ишелеп ята.

Дөрес, ул, үрчем өчен ярамый башлагач, махсус тәрбиягә, симертергә куелган дуңгыз, Нургалинең исәбе — аны бераз ашатып, дәүләткә ит заданиесе өчен тапшыру иде. Ләкин «Бояр» ашаткан саен зурая, тазара бара, ә Нургалинең аның саен кызыксынуы көчәя: дуңгыз дигәнең күпмегә хәтле арта ала икән? Менә өченче ай инде ул аны ашата. Хәзер ферма кешеләре «Бояр» өстенә карап: «Бу әкәмәт унбиш пот булыр!» — диләр.

Кичә сессиядә уполминзаг агенты Шәйдуллин, дәүләткә арык мал тапшырасың, дип, Нургалинең җан ачуын чыгарган иде... «Бояр»ны күрсәтәсе иде аңа, «Бояр»ны, менә күр, дәүләт өчен махсус симертәбез, диясе иде үзенә... белеп сөйләргә өйрәнер иде.

Әмма, үзара гына әйткәндә, бер нәрсә Нургалинең йөрәген тырнап тора: «Бояр» хәзергә берүзе генә, ишләре юк аның, илтеп биргәч, кешегә күрсәтергә дә калмый. Дөрес, фермада бу «кәпәч борыннар» аз түгел, карты-яше йөз баштан артып китә, тик... хәзергә кул кыска, барысына да «Бояр»га биргәнне биреп булмый.

Шулай да «Бояр» Нургали күңелендә күп кенә уйлар кузгатты. Ит бирү ягыннан дуңгыздан уздырган хайван юк. Шуның өстенә бик тиз үсә, тиз үрчи, бер тапканда икешәр дистә, хәтта аннан да артыграк бала китерә. Ләкин бөтен бәла шунда — дуңгыз артык четерекле хай-

ван. Бик нечкә табигатьле ул, азыкны бик талымлап кына ашый («дуңгыз барын да ашый» дип әйтү дөрес түгел икән ул), чирләргә бик ярата, кояшка да, яңгырга да чыдамсыз, кайчан шулай барысы берьюлы авырып, ферма кешеләренең тәмам котларын алалар.

Нургали исәбенчә, дуңгызлар белән эшнең канәгатьләнерлек булмавы бу хайванны яхшылап белмәүдән килеп чыга. Ничә әйтсәң дә, борыннан асрап өйрәнгән хайван түгел, аны тәрбияләүнең бөтен серләренә төшенеп җителмәгән әле. Мәсәлән, дуңгыз балаларының аз канлы булуларын ничек бетерергә, ана дуңгызның балаларын имезергә имчәкләре җитмәсә, нишләргә? — менә практика үзе алга китереп куйган шушы сорауларга җавап эзләп, Нургали үзе дә һәм аның кешеләре дә күптән инде баш ваталар. Һәрхәлдә, Нургалинең дуңгызлар асрау эшенә җиң сызганып тотынырга нияте бар. «Бөтен көтүләре белән «Бояр» кебек булсыннар,— дип йөри ул.— Һәрберсе бер йөк ит булсын, Украинадагы кебек... Айһай, андагы дуңгызлар, башлап күргәндә куркып китәсең, әкәмәт!»

«Бояр» өстенә карап шулай уйланып торган чакта, сарык караучы Һәдия килеп Нургалине һәм Галләм абзыйны дуңгызлар күршесендәге сарыклар абзарына чакырды.

— Минем бер сарыгыма әллә ни булган, шуны карагыз әле,— диде ул.

Кыз артыннан иярделәр һәм зур абзарны икегә бүлгән юка стенаның такта ишегеннән икенче якка чыктылар. Бу якта иркен-иркен итеп киртәләгән араннарда төркем-төркем сарыклар торалар. Хәзер араннар буш: сарыкларны тышка, абзар алдындагы утарга чыгарганнар.

Һәдия юлдашларын бер буш аранда стена буена сыенып кына, башын хәлсез салындырып ятып торган сарык янына алып килде. Галләм абзый чүгәләп сарыкны сак кына капшый, тоткалый башлады, ләкин сарык, гадәтенчә, куркып сискәнмәде дә, сикереп торырга да омтылмады. Шик юк, сарык авырый иде. Галләм абзый аны күтәреп торгызды, ләкин сарык арткы аягының берсен җиргә тидерә алмый, бары өч аягына гына басып тора иде.

— Сугып сындырганнармы моның аягын?

— Юк, кем суксын ди.

— Алайса үгез сөзгәндер.

— ?

Капшана торгач, Галләм абзый сарыкның корсак артыннан тагын бер ярасын тапты.

— Бу ни бу, мәхлукның эче тишек ләбаса. Менә!

Ул канга буялган кулын күрсәтте, Нургали аптырап башын чайкады.

— Сөздергәннәр шул, харап иткәннәр хайванны... Кайвакытта, ничек булды бу? — диде ул кызга, кашларын җыерып.

Кыз еларга торган тавыш белән:

— Берәү дә сөзгәне юк,— диде,— билләһи менә, валлаһи...

Нургали, сабырлыгын җуя башлап, аның сүзен бүлде:

— Йә, йә, ант итә башлама, күрмәсәң, күрмәдем диген, тик дөресен генә әйт!

Һәдия кинәт каушап калды булса кирәк, дәшмичә авызын сузып, җиргә текәлеп тик тора бирде: күренә, елап җибәрергә дә күп калмаган... Нургали аңа сөзеп карап торды.

— Йә, ник дәшмисең?

Кыз шактый көттереп, ниһаять, «ни булса ул» дигәндәй, бер тыннан әйтеп куйды:

— Сарык яшь үгезләр янына кереп калган, бүген шуннан чыкты.

— Күптән шулай дип әйтү кирәк иде,— диде Галләм абзый, чүгәләгән җиреннән торып.— Бәрәне бармы?

— Бар!

Нургали кыздан сабыр гына, ачуын ничек тә сиздермәскә тырышып, сорашырга тотынды:

— Кичтән сарыкларыңны барлап калдырмаган идеңмени?

— Нишләп барламыйм ди. Карап яптым, барысы да шунда иделәр.

— Ничек соң ул яшь үгезләр янына барып эләккән?

— Миннән соң, караңгы төшкәч инде, Хатирә шушы ишектән бозаулар ягына чыгып йөрде. Шул чакта бу сарык кереп калган, күрәсең...

— Алайса Хатирә гаепле?

Кыз дәшмәде, башын иде. Нәкъ шул чакта абзар ишеге төбендә башына күн түбәле колакчын бүрек, өстенә кыек кесәле кыска бушлат кигән авыл советы председателе Сөләйманов күренде. Нургали аны күрү белән, Һәдиягә башка бер сүз дә әйтмичә, туры ишеккә таба китте. Сөләймановның ачык тавыш белән:

— Исәнме, Нургали абый! — диюенә каршы ул:

— Ярый әле,— диде дә яныннан кырын узып тышка чыкты. Сөләйманов, аз гына читкә тайпылып, аңа юл биреп калды.

...Бик вакытсыз чакта Нургалинең күзенә килеп

күренде бу Сөләйманов. Шундый иртә, яшь кәләш кочагыннан торып йөрергә ни пычагым калгандыр аңа... Үзенчә, бәлкем, кичәгедән соң Нургалинең кәефен белергә чамалыйдыр. Бик телисең икән, Нургали кәефенең нинди икәнен күрсәтә белер!

Әнә шулай, ихтыярыннан тыш, йөрәгендә тыгызлана башлаган сукыр ачуга бирелеп, ул беркая да сугылмыйча туры ферма өенә китте. Кычкырып, автомат очередедай озын итеп сүгенәсе килә иде аның... Җитмәсә, Һәдиягә дә бер усал сүз дә әйтә алмыйча калды. Әмма ул аны бүген үк фермадан куачак. Корыч дисциплина булачак аның фермасында. Һәртөрле җебегәнлекне, салкынлыкны, җавапсызлыкны кызган тимер белән көйдерәчәк! Сөләйманов кебекләргә «әнә Нургалинең эше ничек» дип төртеп күрсәтергә урын калдырмаячак.

Нургали ферма өенә кереп, башыннан йомшак йомран бүреген салып өстәлгә ташларга өлгермәде, артыннан ук Сөләйманов та килеп керде.

— Һай, кызу атлыйсыз икән, Нургали абый,— диде ул, елмаеп.— Артыгыздан җитәр хәл юк.

Нургали, аны күргәч, шактый аптырап калды һәм уңайсызланып китте — көтмәгән иде ул председательнең артыннан ук ияреп килүен. Ләкин шунда ук үзен кулга алып, керпедәй салкын рәсми кыяфәткә төренде.

— Әйдә, узыгыз! — диде ул аңа.

Сөләйманов, өстәл янына килеп, буялмаган ак табуреткага утырды. Нургали өстәлдә яткан бер газетаның читен ертып алды. Аның нәрсә эшләргә җыенуын күреп, Сөләйманов кесәсеннән ак портсигар чыгарып сузды:

— Алыгыз, Нургали абый!

— Яратмыйм шул папирос дигән нәрсәне,— диде Нургали, тун кесәсенең төбен тырнап.— Минем өчен чуаш тәмәкесеннән дә шәбе юк.

— Кайсы көнне әле үзегез мине папирос белән сыйлаган идегез? — диде Сөләйманов, сак кына.

Нургали җавап тапканчы тәмәке төрү белән мавыккан булды һәм зур итеп төргән тәмәкесен ялап авызына капкач кына әйтеп куйды:

— Ничектер бер алган идем дә, кешегә өләшеп бетердем шунда...

Алар тәмәкеләрен кабыздылар һәм, Сөләйманов ачык соры күзләре белән туры Нургалигә карап, ә Нургали кашларын җыера биреп тәрәзәдән тышка карап, бер тын суырганчы сүзсез генә утырдылар. Аннан председатель Нургалинең кырын торуын (һәм папирос турында ни

өчендер алдашып маташуын) ачык күрсә дә, аны-моны уйламыйча, сүз башлар өчен:

— Тимерчеләр янында булган идем әле,— диде,— бүген соңгы тырмага актык тешне сугып куячаклар. Бу Садыйк абзыйны әйтәм, чистый алтын кул, язгы чәчүгә бөтен эш коралларын өлгертеп куйды бит!

— Садыйк абзаң шул ул!

— Әйтәсе дә юк, тырыш кеше һәм яхшы оста... Һәр эштә дә Садыйк абзый кебек кешеләр булса, бөтен нәрсә ал да гөл булыр иде.

«Монысы ни өчен?» — дип уйлап алды Нургали, ә Сөләйманов сүзен дәвам итеп:

— Кәримәнең «Алма»сы бозаулаган икән,— диде.

— Бозаулады шул.

— Шуны ишетеп килдем әле үзем дә... Ничек, әйбәтме соң?

— Нәрсә?

— Бозауны әйтәм... Әнисе холмогор, әтисе теге «Балан», ай-һай, таза үгез... алардан туган бозау да чибәрдер инде?

— Ярыйсы.

— Күпме тартты соң? Үлчәдегезме?

— Кырык килограмм.

— Кырык! Бу инде, Нургали абый, ярыйсы гына түгел, бу, минемчә, бик яхшы инде. Мондый бозауның безнең фермада туганы юк иде шикелле?..

Нургали тәмәкесенең очына җыелган бармак буыны кадәр көлне кагып төшерде.

— Ник тумасын, туды.

— Кайчан, кайсы сыердан.

— Былтыр Хәлимәнең коба сыерыннан.

— Теге «Зорька»данмы? Аның бозавы утыз алты килограмм булды бит!

Нургали иреннәрен кысты, аннан, бераз дәшми торгач, теләр-теләмәс кенә әйтте:

— Утыз алты түгел, утыз сигез иде.

— Шул шул. Ә кырык килограмм бездә рекорд әле ул!

Нургалинең мыегы чуалганнан-чуала бара. Яшь председательнең аңа, ферма мөдиренә караганда да белдеклерәк булып (кара син, сыер исемнәрен дә белә ул, кайчан нинди бозау туганын да хәтерли ул), җитмәсә, төзәтмәләр биреп утыруы аның ачуын кабарткannan-кабарта иде. Ә Сөләйманов, аны-моны абайламыйча (әллә юри абайламаган булыпмы), беркатлылык белән ихлас күңелдән һаман сөйләнә бирә:

— Әйе, Нургали абый, бер Кәримә сыерыннан гына түгел, барлык сыерлардан да шундый бозаулар аласы иде. Бу бит теләгәндә булдырып була торган эш. Тик моның өчен кичә, сессиядә, Нуретдин абзый әйткәнчә...

Нургали сабырсызланып аның сүзен бүлде:

— Ишеттем мин анда кемнең нәрсә сөйләгәнен!

— Әлбәттә. Менә шул ишеткәннәрдән чыгып инде, Нургали абый, терлекләрнең нәселләрен яхшыртуны планлы рәвештә алып барырга кирәк булыр.

Нургали тартып бетермәгән тәмәкесен сүндермичә мич авызына ыргытты.

— Миңа берәүнең дә өйрәтүе кирәкми. Нәрсә эшләргә кирәклекне мин үзем дә бик яхшы беләм.

Сөләйманов бу көтелмәгән сүзләрдән бер мәлгә аптырап калды, дәшмичә Нургалинең кызыл таплар уйнаган караңгы йөзенә һәм ак иреннәре өстендә тырпайган кара мыегына җитди генә карап торды, аннан тыныч, сабыр гына әйтеп куйды:

— Өйрәтү түгел бит бу, Нургали абый...

— Ә нәрсә соң?

— Бумы, бу — бергәләп кайгырту.

Нургали үзен никадәр тыярга, кулдан ычкындырмаска тырышса да, Сөләймановның бу тынычлыгы, үз иткәндәй, ике сүзнең берендә «Нургали абый» дип дәшүе аны, ниһаять, ярсытып җибәрде. Ул, урындыгын артка этәрә биреп һәм нәрсәгә тукталырга белмәгән күзләрен Сөләймановтан яшереп, кызу-кызу әйтеп ташлады:

— Кайгырту, имеш! Шулай булмыймы соң! Беләм мин синең нәрсә кайгыртып йөрүеңне, ничу монда күзгә төтен җибәреп утырырга... Юк, Закир туган, авыл советы председателе булсаң да, мин сиңа турысын әйтим...

Һәм Нургали бер секундка кинәт тукталып калды: хатыны Миңсылуның кичә йөрәгенә салган һәм кадалган шырпыдай бертуктаусыз бәгырен сызландырып торган вәсвәсәсе аның теленә килде, ләкин ычкындырып җибәрүдән үзе дә куркып китте. Табуреткасында текә генә утырган Сөләйманов аңа туп-туры карап, үзгәрүен бер дә сиздермичә, акрын гына:

— Йә, әйтеп бетер! — диде.

Моңарчы күзләрен нәрсәгә туктатырга белмәгән Нургали кисәк кенә, яшендәй ачу чәчрәтеп, Сөләймановка карап алды һәм, үзендәге һәртөрле икеләнүне селтәп ыргытырга теләгәндәй, сул кулы белән һаваны югарыдан түбәнгә таба ярып төшерде.

— Әйтәм! — диде ул, зәңгәрле тавыш белән яман кычкырып.— Әйе, ферма турында кайгырту түгел бу, бажаң

Фәттах кайгысы бу, аны минем урынга куярга йөрисең син... Менә нәрсә өчен бу уйдырмалар барысы да...

Сөләйманов урыныннан торды.

— Нургали абый, только кычкырма!

— Кычкырмыйм мин, әйтәм генә...

Алар беравык бер-берсенә туп-туры текәлеп карап тордылар. Нургалинең кашлары тартылып кушылганнар, күз төпләренә тир дымы һәм маңгае аркылысына калын тамыр калкып чыккан иде. Ул Сөләймановка никадәр батыр карарга тырышмасын, әмма күзләренең төбендә ниндидер бер тынгысызлык — борчылумы, гаепме — кая яшеренергә белмәгәндәй йөренеп тора иде. Ә Сөләймановның агарып киткән йөзендә һәм зур булып ачылган соры күзләрендә шундый бер гаҗәпләнү ки, ул хәтта ишеткәннәрен уенга алып, көлеп җибәрергә хәзер торган шикелле күренә иде. Ләкин ул көлмәде, киресенчә, карлыга төшкән тавыш белән бик җитди итеп сорады:

— Нургали абый, моны син әйтәсеңме?

— Нәрсә, әллә дөрес түгелме?

Сөләйманов, тәмам гаҗәп-хәйранга калып, башын чайкап торды.

— Их, Нургали абый, Нургали абый, көтмәгән идем мин синнән мондый сүзләр, уйламаган идем мин сине болай дип. Нихәтле тирән ялгышасың икән син... Әгәр синең бар теләгең мине хурлау гына булса, бу кечкенә мәсьәлә, бу кадәресен кичерергә дә була. Әгәр инде син авыл советының эшен уйдырма дип атыйсың икән, бу инде зур, бик зур... мәсьәлә. Бу турыда сөйләшмичә булмас.

— Өркетмә син мине, Сөләйманов! — диде Нургали, йодрыгы белән өстәлгә яман сугып.— Минем авыл советына тел тидергәнем юк.

— Алайса син нәрсәне уйдырма дисең?

— Минме? Нәрсәнеме?

— Әйе, син!

— Мин... синең терлекчелек мәсьәләсен вакытлы-вакытсыз, язгы чәчү борын төбендә торган чагында сессиягә куюыңны уйдырма, дим, күз буяу, дим.

— Ни өчен уйдырма, ни өчен күз буяу?

— Ни өчен икәнен мин сиңа әйттем инде.

— Фәттах абыйны синең урынга куяр өченме?

Нургалинең кабатлап расларга көче җитмәде, ләкин артык ярсудан һәм сүз таба алмау гаҗизлегеннән ул, авыр сулап, аскы иренен чәйни башлады. Сөләйманов күрә — сүз көрәштереп торуның мәгънәсе юк, иң яхшысы — хәзер үк чыгып киту.

— Нургали абый,— диде ул, мөмкин кадәр тыныч, гади булырга тырышып,— сезнең нервларыгыз кузгалган, сезгә тынычланырга кирәк. Соңыннан без... бер җай табып аңлашырбыз.

Һәм башындагы күн түбәле бүреген ике кулы белән баса төште дә ашыкмыйча гына ишеккә таба китте.

## V

Сөләйманов чыгып китүгә, Нургали, аякларының хәле бетеп аугандай, урындыгына утырды һәм көче киткән кулларын өстәлгә сузып салды. Шул хәлдә берникадәр вакыт һичнәрсә уйламыйча тик кенә утырды ул, әйтерсең бер яман шеше тишелде дә кинәт хәлсезләнеп һәм җиңеләеп калды. Ләкин әле ярсуы бөтенләй басылып беткәне юк иде, шунлыктан ул үзендә бернинди үкенү сизми, тик, ихтыярсыздан, «аңа авыр булдымы икән?» — дип ялкау гына уйлап куйгалый иде. Күпме вакыт утыргандыр ул бу сәер хәлдә, әмма ярсуы басыла барган саен аның бөтен эченә әллә нинди авыр, караңгы бушлык акрын гына тула бара иде. Әшәке иде бу боздай салкын бушлык, йөрәгенә сарылып, бөтен уй-хисләрен туңдыра кебек иде...

Башлыча менә шул бушлыктан котылырга теләгәндәй, ул кинәт урыныннан торды. Бүген алдында торган эшләрне хәтерләргә тырышты, үзенчә әүвәл нинди эшкә тотыну турында уйлаган булды, ләкин болар бар да үзен тынычландыру өчен көчәнеп маташу гына иде. Ниһаять, ул өенә иртәнге чәйгә кайтырга булды һәм ферма өеннән чыккач, кулларын артка куеп, авыр башын күкрәгенә салып, аяк астына гына карап, авылга таба атлады.

Үз эченә шулкадәр йотылган иде ул, хәтта кайтып җиткәнче урамда кем очраганын да шәйләмәде. Бик авыр иде аңа, Сөләйманов белән бәрелешкәнгә кадәр күпме генә авыр булмасын, ләкин хәзер йөз мәртәбә, мең мәртәбә авыррак иде. Нидән бу? Ни өчен, кичәдән бирле йөрәгендә тыгызланган ярсудан, ниһаять, бушангач, ул җиңеләеп каласы, тынычланасы урында, караңгы базга җимерелеп төшкәндәй, баш-аягы белән авыр газапка йотылды?

...Төрлечә ул үзенең Сөләймановка ташлануын аклап карады, бернинди үкенүгә юл куймас өчен бөтен хәтер калуларын, бөтен ишеткән-күргән «хаксызлыкларны» яңадан бер кат арттырып, күпертеп уйлап чыкты, не-

рвларының артык киеренке булуына да сылтамакчы булды, хәтта Сөләйманов үзе гаепле, үзе мине шушы хәлгә китереп җиткерде, дип, гаепне аның өстенә дә аударып карады. Ләкин юк, ничек кенә үзен юатырга тырышмасын, ничек кенә вөҗданы алдында акланып маташмасын, әмма намусы аңа: «Ах, начар эшләдең син, хата эшләдең»,— дия иде. Җитмәсә, аның күз алдыннан Сөләймановның: «Их, Нургали абый, Нургали абый!» — дип баш чайкап торуы һич китми, һәм бу хәл аны өшеп китәргә мәҗбүр итә иде.

Ниһаять, Нургалинең йөрәге төбеннән тирән үкенү акрын гына күтәрелә башлады. Өенә кайтып җитәрәк ул урам уртасында бер мәлгә тукталып калды, кашларына төшкән бүреген артка таба этәрде, маңгае аның шабыр тир иде. Үз эченә колак салгандай, бик аз гына тынып торды, аннан тирән газап тулы күзләре белән таркау гына тирә-ягына каранып алды һәм, авыр уйларын селтәп ыргытырга теләгәндәй, кисәк кенә башын бер-ике кат селкеп куйды. «Юк, булмый болай, ярамый болай, эш түгел бу!» — дия-дия, ул кызу гына атлап китте...

Үкенү тойгысы бик тиз арада аның бөтен җанын биләп алды, ләкин ул аны ничек тә басарга, ничек тә аңардан котылырга тели иде. Һәм кинәт туган бер тынгысыз борчылу белән ул, үзен кая куярга белмичә, арыбире чаба башлады.

Өенә ул кереп кенә чыкты. Миңсылуның кыстыбыена кагылмады да, аның сукрануына колак салмыйча, «хәзер кайтам» дип ашыгып, колхоз идарәсенә китеп барды. Аңа кеше кирәк иде, эш, сүз, бәхәс, хәрәкәт кирәк иде, бөтен авыр уйларын, әрнү-ярсуларын, эшләгән ахмаклыкларын оныту, ялкынны җил белән сыпырып ташлаган кебек (Нургали солдат кеше, ут капкан танкның соңгы тизлек белән чабып ялкыннан аерылырга тырышканын күргәне бар), шуларның барысыннан, барысыннан да котылу кирәк иде.

...Идарәдә, кызганычка каршы, колхоз председателе Шәйхи абзый юк иде. Бу арада ул җигүле аттан төшми. Бүген дә күрше райондагы «Якты күл» колхозына берничә дистә яңа капчык сатып алу нияте белән китеп барган... Хуҗа кешенең язгы чәчүгә төшәр алдыннан барысын исәпләп, алдан хәстәрләп йөрмичә чарасы юк, шулай да аның идарәдә булмавы Нургалинең күңелен шактый боектырып җибәрде. Бик күрәсе килгән иде аның Шәйхи абзасын... Ничек карар, ни дияр, нәрсә турында сүз башлар — шуларны уйлап килгән иде ул.

Идарәдә бары чәче-башы тузган хисапчы Муса, урта бармак чаклы итеп төргән утлы тәмәкесен өстәл читенә куеп, зур-зур кенәгәләр актарып утыра иде. Ул Нургалине ачык чырай белән каршы алды. Килеп керүенә:

— Ә, Нургали әкә, хуш килепсең, йөрең, йөрең! Йә, сессиядән киен тыныч кына йокладыңызмы, төшеңездә адәм башлы сыгыр-мыгыр, куй-мой, чучка-мучкалар күреп саташып калмадыңызмы? — дип, үзенчә яртылаш үзбәкчәләп, аны сүз белән күмеп ташлады. Муса ил гизеп өлгергән егет иде.

Нургалинең, билгеле, болай Мусага ияреп юләр сатарга һич теләге юк иде. Ул, җавап биреп тормастан, Шәйхи абзыйның кая китүен сорап белде дә, телефон трубкасын алып, «Заготскот»ка шалтырата башлады. Ә Муса ялгызы озак утырып сүз тансыклаган, күрәсең, Нургалинең кәефендә эше булмыйча, һаман теленә килгәнне сөйли бирде:

— Әй-яй, мин әйтәм, безнең Сөләйманов Шәйдуллинны нишләтте! Йомшак кына җәеп катыга яткырды бит, чистый! Нәкъ цирктагыча... Аннан, Нургали абый, үзебездә туып үскән «Кылыч»ны нишләтербез икән, җигәргә ярамый ул үгезне, яман да усал, суярга туры килерме икән инде?

— Ит ашыйсың килдемени?

— Печмәгән үгез итен ашамыйм мин,— диде Муса, эре генә.— Куй ите булса, баш өсте, отказ юк.

Бу Муса шундый әйле-шәйлерәк, телгә беткән бер егет булса, да бик шәп хисапчы иде, хәтта талантлы хисапчы дип әйтергә мөмкин иде. Искиткеч хәтер үзендә, саннар белән, кытай мәзәкчесе төрле шарлар чөеп уйнаган кебек, гаҗәп өлгер эш итә, беркайчан да бернинди хатасы булмый, шуның өстенә ташка баскандай сокландыргыч матур, пөхтә итеп яза да белә иде. Юкка гына Шәйхи абзый аңа ябышып ятмый иде.

Нургали «Заготскот»ка шалтыратып әллә ни белә алмады. Управляющий үзе юк иде, шуңа күрә комбикорм биреп, салам алу турында өзеп кенә бер сүз дә әйтә алмадылар. Шулай да саламның бик кирәк булуын әйттеләр. Нургали урман астындагы ике салам эскертен карап кайтырга булды. Әгәр тиз арада районга ташытырга туры килсә, юлның торышы ничек, эскертләр тирәсендә кар калын ятамы, яннарына чана белән кереп булырлыкмы — шуларны белеп кайтасы килде.

Ашыга-ашыга атлар дворына барып, ат иярләтеп алды. Анда да кешеләр аңа ничектер сынап, сүз көтеп карыйлар төсле, гүя аның белән ниләр булганын да, ниләр уй-

лап, ниләр кичергәнен дә белеп торалар иде. Ат иярләп бирүче, кыска сырма өстеннән киндер алъяпкыч бәйләгән Бәдри абзый да, атны авызлыклап, тезгенне Нургалигә тоттырган чакта гына сорап куйды:

— Урман астындагы эскертләрне кузгатырга булдыгызмыни, Нургали туган?

— Карап кайтам әле,— диде Нургали, туры җавап биреп торасы килми генә.

— Кичә авыл советында зур сүз булган, дип ишеттек, шуңа соравым.

— Сүз күп булыр ул, Бәдри абзый!

— Әй-е,— диде Бәдри абзый, сузып кына.— Сүздән сарай салып булмый, эш кирәк шул!

Нургали аның бу шактый кинаяле сүзен, ат белән булашып, ишетмәмешкә салынды. Яшь, кырыс туры ат аңардан һаман арты белән чигенеп маташа иде. Нургали аның ялыннан каты кысып тотты да, өзәңгегә сул аягын куеп, җәһәт кенә сикереп атланды. Ат башын текә күтәреп, сылу гәүдәсе белән сыгыла биреп, кырынлап китте, китте дә аннан, йөгәнен каты кулларда булуын сизгәч, кинәт алга ыргылып чапмакчы булды. Ләкин Нургали аңа чабарга ирек бирмәде, кызу юыртуга күчеп, чын кавалеристларча матур, җиңел генә тибрәнеп, җеп-шек карны чәчрәтә-чәчрәтә, җилкапкадан чыгып китте.

Тауны менеп җиткәч тә ул шулай атын кызу юыртып карады. Ләкин аз тапталган тар гына юл бик йомшарган, әледән-әле ат аягы батып китә һәм тояк чокырлары кар суы белән тулып кала иде. Көн бик җылы иде, тиз арада Нургали үзе дә, ат та тирләп өлгерделәр. Нургали тун төймәләрен чишеп җибәрде.

Җәелеп яткан ак ялан ат өстеннән иркен-ачык күренә иде. Җир, бүген булмаса, иртәгә, кыры-кыры белән ачылырга тора, кояш карны ашыгып, комсызланып ашый, кар өсте тоташ юка челтәр өлгеләр белән чуарлана; кырын басып торган бу күксел өлгеләр әледән-әле уалып төшә торалар. Кардан ачылып өлгергән җир, тирән-тирән итеп сулагандай, ак пар көйрәтә башлый, ә язгы уйнак җил җирнең бу дымлы сулышын авыллар өстенә алып китә, ислемай өләшкәндәй, кешеләргә һәм хайваннарга сирпеп йөри... Хуш исле чәчәктән дә исерткечрәк була бу беренче дым исе!

Нургали шул дым исен иснәп, кояшның йомшак җылысын тирләгән битендә, тезген тоткан кулында тоеп, тирә-ягына карана-карана бара. Аның туган җирләре бу, аның тир түгеп эшләгән кырлары бу... Бармы икән биредә ул белмәгән берәр ызан, берәр чокыр яки берәр кал-

кулык! Кайчан кешегә тынычланыр өчен бик аз нәрсә дә җитә. Менә хәзер дә нурлы офыкларга китеп эрегән иркен кырларны күргәч, җир-ананың кышкы озак йокыдан тирләп уянуын тойгач, йөрәк ярасы аның, йомшак канат белән сыпырып алгандай, авыртуыннан туктап, бер мәлгә тынычланып калды. Ул хәтта, бүгенге газапларын онытып, киләчәк турында хыялга бирелде. Кичәдән бирле инде аңарда үзенең фермасын кешеләргә бик яхшы итеп күрсәтер өченниләрдер эшлисе, ниндидер зур чаралар күрәсе килү теләге яши иде... Әйе, Ямашев колхозының көтүләре бик ишле булсын, терлекләре бик көр булсын, итен, сөтен, йонын гаять мул итеп бирсен, ферма каралтылары, менә биредән — тау өстеннән караганда, тәртип белән салынган зур бер фабрика төзелешләре кебек, мәһабәт-матур булып күренеп торсын, анда үрнәкле тәртип, көлеп торган чисталык булсын, кешеләрнең хезмәтен җиңеләйткән һәм хезмәтнең бәрәкәтен арттырган электр көче бөтен эш тармагына үтеп керсен, кешеләре аның барысы да гадел, намуслы, тырыш булсыннар.

Татлы уйларга йотылган Нургали ике зур салам эскерте янына килеп җиткәнен сизми дә калды. Юлдан чыкмыйча гына атын туктатып, ул эскертләргә карап тора башлады. Кышкы җилләр, тырыша торгач, эскертләр әйләнәсенә шактый калын итеп көрт салганнар. Хәзер инде бу тау булып яткан көрт көннән-көн шиңә, читләреннән эреп һаман чигенә бара, ләкин шулай да көрт белән эскерт арасындагы ышыклыкның тирәнлеген чамалап караганда, карның калынлыгы ат корсагыннан югары булырга тиеш иде. Чана белән туры эскерт төбенә үтәрлек түгел, моның өчен карны көрәк белән ташларга кирәк булачак. Тик ашыгырга, иртәгәдән калмыйча ике эскертнең берсен ташый башларга кирәк...

Кышын бу эскертләр янына аяк баскан кеше булмагандыр, ләкин килеп күргәч, кичә генә булып үткән төсле гаҗәп ачык булып, былтыр көз шушы урында ашлык сугып йөрүләр Нургалинең күз алдына килде. Ә баксаң, менә озын кыш та үтеп китте... Ничек кызу әйләнә гомернең бу зур көпчәге — ел дигәнең! Озакламый тагын бу тирәләр җанланыр, бер атна-ун көннән кешеләр килер, язгы чәчү башланыр, тракторлар шаулар... Шулай итеп язы, җәе, көзе тагын кабатланыр. Ә хәзергә әле бөтен әйләнәдә нурлы тынлык хөкем сөрә, шул тынлыкта ике зур эскерт янәшә оеп кына утыра, бернинди җан әсәре дә, тавыш та юк, тик эскертләрне уратып алган көрт

өстендә уч-уч соры куян тизәге дә, чигеп төшергәндәй вак кына ләтчә эзләре ярылып ята...

Нургали, эскертләрдән аз гына ары узып, ярты километр чамасы ераклыктан зәңгәрләнеп күренгән мәһабәт урманга бераз карап торды да атын авылга таба борды...

Ләкин ул кайтып, атын ат караучыларга тапшыргач та, үзен кая куярга белмичә, тагын ары барып, бире килеп йөри башлады. Бер котылгысыз теләк аулап алды аны хәзер: кем беләндер сөйләшергә, кемгәдер бөтен эчен бушатырга кирәк иде аңа... Әлбәттә, «кем» дигәне аның колхоз председателе Шәйхи абзый иде, менә шул кешегә ул йөрәген сосар иде, ләкин Шәйхи абзыйның әле кайтканы юк, хисапчы Мусаның әйтүенә караганда, ул бүген кайтса да, бик соң гына кайтып җитәргә тиеш икән. Председательнең кая, ни өчен киткәнен бик яхшы белсә дә, «шундый чакта әллә кайда югалып йөри» дип, ачуы да килеп куйды аның... Хәер, колхозда көндәлек эш үз җае белән бара: һәркем үз эшендә, һәм берәү дә, билгеле, Нургалинең аяк астында бу хәтле җир янадыр дип белми иде.

Нургали өенә дә берничә тапкыр кереп чыкты. Бер кереп чыгуында шулай, башына бүрек киеп, күлмәкчән генә ишегалдында нидер эшләп йөргән хатыны Миңсылу ачулы гаҗәпләнү белән аңа:

— Нишләп әле син бүген бертуктаусыз тудыйм-судыйм йөрисең? — диде.

Бик урынлы һәм тапкыр әйтелгән сүз булды бу,— Нургали хәтта җавап та кайтарып әйтә алмады. Әйе, бетерергә кирәк иде болай... «тудыйм-судыйм» йөрүне, һәм Нургали, озак уйлап тормастан, авыл читендәге зур ихата белән әйләндереп алган мәктәпкә таба китте. Ул, ниһаять, Идрис Дускаев белән сөйләшергә булды.

## VI

Дускаев төп Яуширмә кешесе түгел; ул күрше районнарның берсендә туып үскән егет. Ватан сугышы башлангач, педагогия институтының өченче курсыннан ирекле рәвештә армиягә киткән һәм сугыш беткәч, фронттан кайтып, бүленгән укуын тәмамлаган яшь укытучы иде. Яуширмәгә ул кырык сигезенче елның көзендә генә мәктәп директоры булып килде. Директорлык хезмәтеннән тыш, үзе тарихтан, ә хатыны — кечкенә буйлы, ак чырайлы, юаш кына табигатьле, ике яшь бала анасы

Әминә ханым — биологиядән укытып, Яуширмә халкы өчен яңа кешеләр булып яши башладылар.

Алар Нургалиләрдән ерак түгел бер улы һәм килене белән генә тора торган Гөлйөзем исемле карчыкның урам баш өенә квартирага кергәннәр иде. Нургали, башлыча хатыны Миңсылудан ишетеп, аларның үзара бик тату торуларын һәм гади-тыйнак кына көн итүләрен белә иде. Миңсылу бигрәк тә Дускаевның хатынын мактап бетерә алмый иде. Бик ачык йөзле, кече күңелле, имеш ул берәүнең дә йомышын кире какмый, имеш, җитмәсә, үзе бик акыллы да, укымышлы да, имеш... Миңсылуның хәтта: «Бу сабый чырайлы орчык хәтле генә хатын каян шулкадәр күп белә икән?» — дип, чын-чыннан гаҗәпләнеп сөйләнгән чаклары да булгалады. Ул инде, аңа үзенең бала таба алмау фаҗигасен сөйләп, аңардан ниндидер киңәшләр дә алып өлгергән иде.

Һәр көнне иртән алар икәүләп ашыкмыйча гына мәктәпкә китәләр, төштән соң әүвәл Әминә ханым ашыгып, ә берәр сәгать үткәч, хатыны артыннан Дускаев үзе өйгә кайталар иде. Еш кына алар кичләрен, дүрт яшьлек улларын алып, колхоз идарәсенә килә торганнар иде. Дускаев, суеп каплагандай үзенә охшаган, аягына кечкенә ак фетр белән галошлар кигән, пальто якасын торгызып шарф ураган туп шикелле малаен бер дә яныннан җибәрмичә, күбрәк председатель һәм бригадирлар янында, аларның әңгәмәләренә колак салып утыра торган иде. Ә Әминә ханым идарә белән янәшә уку бүлмәсендә яшь кызларны тирәсенә җыеп, сөйкемле көлемсерәп, аларга нидер акрын гына сөйләп утыра, һәм бер карауда аны шул яшь кызлардан аерып та булмый иде... Төннәрен исә аларның ике кечкенә тәрәзәләрендә бик озак ут яна. Гөлйөзем әбинең әйтүенә караганда, Дускаев, караватта яшь баласын имезеп яткан хатынының баш очына утырып, аңа шыпырт кына китап укый, имеш. (Карчыкның аларга, йокы кадерен белмәгәннәре өчен, бераз кәефе дә кырыла иде шикелле.)

...Ел башында авыл коммунистлары Дускаевны колхоз партия оешмасының секретаре итеп сайладылар. Аңарчы яшь укытучы үзен авыл халкына уңай яктан танытып өлгергән иде инде. Халык арасында аның турында «төпле егет», «дөнья күргән егет», «буш бугаз түгел», «сүзен җилгә очырмас», «үзебезнең кеше», «олы белән олы, кече белән кече була белә» кебек сүзләр дә йөри башлады. Ихтимал, аларның кайберләре арттырып та әйтелгәндер (яңа кеше турында беренче тәэсир кай-

чан шулайрак була бит), ләкин асылда алар дөрес булырга тиеш иде: халык белмичә әйтми ул.

Менә шул Дускаевка барып, ачыктан-ачык сөйләшү теләге Нургалинең күңеленә кичәдән бирле бер түгел, берничә кат килсә дә, ул шушы вакытка кадәр һаман тыелып йөрде. Моның беренче сәбәбе, әлбәттә, башлап колхоз председателе Шәйхи абзыйны күрәсе килүдә иде. Ә ни өчен иң элек Шәйхи абзыйны күрергә дә, аннан соң гына, кирәк булса, Дускаев белән сөйләшергә — моның да үз нәүбәтендә сәбәпләре, Нургали уйлаганча, шактый җитди сәбәпләре бар иде.

...Нургали өчен Шәйхи абзый туган атасы урынына калган кеше, ул аны үзен бердәнбер яхшы белүче, аңлаучы һәм яклаучы дип таный. Ә Дускаев исә, ничек кенә булмасын, аның өчен яңа кеше, асылда ул аны бик өстән генә белә. Дөрес, аның Дускаевка ышанмаска яки аңардан шикләнергә бернинди хакы юк, күңелендә аңа карата салкынлык, чит итү кебек нәрсә дә тоймый тоюын, ләкин шулай да ул аңа үз булып, ияләшеп китә калганы юк әле. Әйләнә дә һаман: «Ул мине белми, мин аны яхшылап белмим, без бер-беребезне аңлый алабызмыни соң?» — дип, үзалдына көрсенеп куя иде... Дускаевның яшьрәк булуы да аның эчен кыра, ничектер үзеңнән яшь кешегә зарыңны сөйләргә бару бераз гарьләндерә кебек... Аннан, соңгы вакытларда Дускаев белән Сөләйманов үзара шактый якынаеп киттеләр. Сөләймановның да хатыны укытучы бит, шуңа күрәдер инде бәйрәмнәрдә бер-берсенә кунакка да йөрешә башладылар. Менә бу хәл дә, дөресен әйтергә кирәк, Нургалинең шактый эчен пошыра иде. Ничек пошырмасын ди, кул кулны, ике кул битне юа бит ул, хәерсез!

Юк, Дускаевны күпме, генә төпле егет, гадел кеше, дип мактамасыннар, ул, Нургали, Шәйхи абзасы өйдә булса, мәктәпкә таба юл тотарга ашыкмаган булыр иде әле...

Шундый каршылыклы уйларга бирелеп, Нургали мәктәпнең рәшәткә белән әйләндереп алган ялан кадәр ихатасына килеп кергәндә, бүрәнәдән салган ике катлы зур бина өлкән тынлык эчендә утыра иде. Бу тынлык Нургалине уйларыннан айнытып җибәргәндәй итте. «Дәрес вакыты!» — диде ул һәм икеләнеп туктала калды. Башын иеп, вакытсыз килүе өчен ачынып торган чакта, каршыдан тәрәзә чиерткән тавыш ишетеп алды. Күтәрелеп караса, аскы тәрәзәләрнең берсендә Дускаев үзе кул изәп, аны чакырып тора иде.

Нургали мәктәпнең болдырына таба атлады. Дускаев аны коридорда, бүлмә ишеге төбендә каршы алды.

— Әйдүк, Нургали абзый, хуш киләсез!
— Саумы, Идрис туган?
— Бик яхшы әле, Нургали абый... Гафу ит, күрешә алмыйм.

Аның куллары кара балчыкка буялган иде. Нургали уңайсызланыбрак калды.

— Нишләп болай бик иртә туфракка буялдың? — диде ул.

— Язгы чәчүгә төштек,— диде Дускаев, шаяртып.— Әйдә, уз, Нургали абый...

Ул Нургалине үзеннән алда бүлмәгә уздырды.

— Менә Әминәнең кушуы буенча, ящикка чәчәкле кәбестә орлыгын чәчеп маташа идем әле...

— Алай икән,— диде Нургали, тәрәзә каршындагы тар өстәл өстендә торган ящикларга һәм сулы-тәлинкәләргә карап.— Кәбестәнең дә чәчәклесен генә үстермәкче буласызмыни?

— ...Һәм чәчәклесен дә... Моңарчы безнең бу тирәләрдә үскән нәрсә түгел, шулай да Әминә сынап карамакчы була... Мин, Нургали абый, синең безгә таба килүеңне тәрәзәдән күреп тордым, ләкин килеп җиткәч кенә нигәдер тукталып калдың?

— Дәрестәдерсең дип уйлаган идем,— диде Нургали, ничектер сүлпән генә.

Дускаев, билгеле, аның бу вакытта тикмәгә генә килмәвен сизенә иде, һәм ул аны үз бүлмәсенә чакырды:

— Әйдә, минем бүлмәгә кереп утыра тор, мин кулларымны гына юып алам.

— Синең вакытың бармы соң?

— Бар. Мин ике дәрестән буш.

— Ярый алайса.

Ләкин ул үзе генә түр бүлмәгә узмады. Дускаевның кул юганын көтеп торды. Бу бер-ике минут дәвамында ул бүлмә эченнән күз йөртеп чыкты. Хәер, аның биредә беренче тапкыр гына булуы түгел иде, әмма кергән саен үзендә ниндидер бер уңайсызлану тоя ул. Менә бу пыяла шкафлар эчендә тезелешеп торган китаплар, стеналарга эленгән географик карталар, зоологик, ботаник таблицалар, кайбер галимнәрнең портретлары, гомумән, бүлмәнең һавасыннан ук белем йортларына гына хас, кешене үстерә һәм яхшы итә торган, ниндидер, телдән әйтүе читен үзенә бер атмосфераның аңкып торуы аңарда үзен биредә ят кеше итеп тою хисен тудыра иде. Ихтыярсыздан аның күңелендә укымыйча калу өчен тирән үкенү уяна: «Эх, дуамаллык, эх, ахмаклык»,— ди ул, ачынып, һәм үзенең бала вакытта артык шуклыгы, ваемсыз-

лыгы аркасында биш классны бетерер-бетермәс укуны ташлавын исенә төшерә. Соңыннан үсә төшкәч тә укып китәргә бик мөмкин иде, сәләте бар иде, зирәклеге бар иде, ләкин хөрлекне артык сөюе, тизрәк зурлар арасына керәсе килүе һәм бик иртә тормыш ыгы-зыгысына бирелеп китүе аны харап итте. Инде олы кеше булып җиткәч, үзенең наданлыгын аклар өчен укыган кешеләрне «китап күшәүчеләр» дип, ә үзен «эш кешесе» дигән булып, юләр сатып йөрде. Ә менә хәзер аның кул астында эшләүче сыер савучы, дуңгыз караучы, бозау тәрбияләүче күп кенә яшь кызларның җидееллык белемнәре бар... Ферма йортында ул кызлар ара-тирә үзара шулай тере организм өчен нинди матдәләрнең кирәклеге, кайсы азыкта нинди витаминның күбрәк булуы, яки һаваның нидән үзгәрүе кебек «гыйлем» сүзләр сөйләшеп утырган чакта, Нургалигә мыек очын тешләп, колак салып кына утырырга туры килә. Әйе, Нургали хәзер терсәген тешләр иде дә, авызга җиткереп кара син аны!

Дускаев кулын юып сөрткәч, алар түр бүлмәгә керделәр, Нургали кызыл постау япкан озынча өстәл янына утырып, башта бүреген салды, аннан сул кулы белән маңгаен тотып, күзләрен каплап торды. Дускаев үзенең озынча өстәл башына аркылы терәп куйган язу өстәле артына барып утырды. Ул Нургалигә бераз җитди генә карап торганнан соң: «Нургали абый, мин сезне тыңлыйм!» —дип әйтмәкче булган иде дә, тыелып калды. Ләкин ни өчен алай дип әйтүдән тыелды ул? Хикмәт шунда, Дускаевның: «Мин сезне тыңлыйм»,— дигән сүзләрдән кайчандыр җаны бизгән иде. Шәһәрдә укыган чагында аңа культура эшләре белән идарә итә торган бер учреждениенең җаваплы эшчесе янына йомышы төшеп баргаларга туры килгән иде. Менә шул кыска буйлы, юантык кына, пенсне кигән кеше, бүлмәсенең ишегеннән барып керүгә, күтәрелеп тә карамыйча һәм утырырга урын да тәкъдим итмичә: «Мин сезне тыңлыйм!» — дип әйтә торган иде. Ул бу бик табигый, яхшы сүзләрне шундый коры итеп, җан өшеткеч бер рәсмилек белән әйтә белә иде ки, Дускаевның сөйлисе килү теләге берьюлы сүнеп китә иде. Шуннан соң Дускаев үзенә килгән кешеләргә башлап беркайчан да: «Мин сезне тыңлыйм!» — дип әйтмәс булды. Әгәр инде ихтыярсыздан ул сүзләр аның күңеленә килсәләр, хәзер үк әлеге пенснеле салкын чиновник күз алдына килеп баса...

...Ниһаять, Нургали маңгаеннан кулын алды һәм басынкы тавыш белән:

— Мин, Идрис туган, синең белән сөйләшергә дип килгән идем,— диде.

— Бик яхшы, Нургали абый, әйдә, сөйләшик! — диде Дускаев, җәһәт кенә.

— Кичә авыл советының сессиясе булды бит.

— Беләм, тик, кызганычка каршы, үзем була алмадым... Районга, директорлар киңәшмәсенә барырга туры килде.

— Әйе, булмадыгыз шул, булсагыз, бик хикмәтле сүзләр ишеткән булыр идегез,— диде Нургали, җиңелчә генә көрсенеп.

Дускаев сессиядә ниләр булганын һәм нинди «хикмәтле сүзләр» сөйләнгәнен белә иде инде, ләкин шул белгәнен сиздерергә теләмәде һәм белмәгән булып күренергә дә яхшысынмады. Бары:

— Сөйләгез, Нургали абый, сөйләгез! — дию белән генә чикләнде.

Нургали аз гына тынып торды.

— Мин бит... үзем турында гына.

— Кем турында сөйләшсәк тә бер-беребезне аңларбыз дип ышанам,— диде Дускаев һәм, урыныннан торып, ачык калган бүлмә ишеген ябып килде. Язу өстәле артына яңадан утырмыйча, ул урындык алып Нургалинең каршысына утырды.

Нургали күтәрелеп аңа карады. Ул Дускаевның сары йөгергән ябык тыныч йөзен, ике каш арасына аркылы тирән сызык төшкән аз гына калку киң маңгаен һәм үзенә төбәлгән кечкенә җитди күзләрен күрде. Аның бу кыяфәтеннән игътибар белән тыңларга җыенуы күренеп тора иде, әмма шуңа карамастан Нургалигә сүз башлап алып китү гаять авыр булды. Нәрсәдер менә әйтәсе килгәннәрен буып торган төсле, нидер аңа ачылмаска, сер сынатмаска кушкан шикелле иде. Ләкин аны бирегә бүген эшләгән ахмаклыгын тою, шуның өчен үкенү хисе куып китерде бит! Кай арада югалды соң болар барысы да? Дөрес эшләдеме ул бирегә килеп? Ләкин аның нәрсә әйтергә тиешлеген алдан ук сизгән шикелле бик җитди көтеп утырган Дускаев алдында хәзер чигенүе соң иде, ничек тә сүзне башларга кирәк иде. Ниһаять, Нургали кашларын нык җыерып, Дускаевка күтәрелеп карамыйча:

— Бүген фермада Сөләйманов белән безнең күчәр башлары әләгешеп алды әле,— диде һәм көчәнеп елмайган булды.

Дускаев дәшмәде, һәм Нургали «күчәр башларының ничек әләгүен» кыска гына итеп булса да сөйләп бирергә мәҗбүр булды.

— Нидән килеп чыкты соң ул? — дип сорады Дускаев.

— Нидәнме? Просто, үземне үзем белештермичә кызып киткәнмен.

— Кызып китүнең дә сәбәбе бардыр бит?

— Иптәш Дускаев, әгәр кичә сессиядә булган булсагыз, сорап тормас идегез,— диде Нургали, кыза төшеп, ләкин шунда ук үзен кулга алды һәм аз гына тынып торып, басынкы тавыш белән өстәде: — Яшермим, минем дә ялгышым булды, кеше гайбәтенә ышанып, Сөләймановка катырак сүзләр әйтеп ташладым. Шуңа эчем яна...

— Нургали абый, ачыграк әйтегез, нинди гайбәт ул?

— Имештер, Сөләйманов баҗасын ферма мөдире итәргә йөри, аның миңа бар каныгуы да шуның өчен генә, янәсе...

— Кызык! Кем чыгарган гайбәт соң ул?

— Сүз иясе белән йөрми,— диде Нургали, кинәт кызарып.

Дускаев аның хәленә керергә ашыкты:

— Хәер, анысы кечкенә мәсьәлә. Сез ул гайбәткә үзегез дә ышанмыйсыз, шулаймы?

— Шулай, ышанасым килми...

— Менә шунсы әһәмиятле. Сөләймановтан алай шикләнү, минемчә дә, бик урынсыз булыр иде. Андый эшкә бара торган егет түгел ул... Ләкин, Нургали абый, гафу итегез, әле генә әйткән бер сүзегезне мин шулай да аңлап җиткермим.

— Нинди сүз?

— Сез, Сөләймановның миңа каныгуы, дип әйттегез. Моны ничек аңларга?

Нургали туры җавап бирәсе урында сүзнеерактан башлады. Дускаевның Сөләйманов турында кистереп «андый егет түгел ул» дип әйтүе дә һәм соңгы соравы да аңа бер дә ошамады. Һаман шулай кашларын җыерган хәлдә, алдына гына карап сөйләргә тырышты ул:

— Сез, иптәш Дускаев, безнең колхозда бик яңа кеше шул. Безнең мондагы эшләрне дә, кешеләрне дә борыннан белмисез. Әйе. Мин менә колхоз төзелгән көннән башлап тәртә арасыннан чыкканым юк. Без колхоз төзеп йөргән чакларда менә бу мәктәп урынында тип-тигез чирәмлек иде, ә Сөләйманов шунда чыбык сөйрәп, бозау көтеп йөрүче кечкенә генә бер малай иде. Әйе. Болар бик борын булган хәлләр, диярсез, бәлкем... Алайса соңгы елларга күчик. Кырык бишенче елны фронттан кайтып төшүгә диярлек мине ферма башына куйдылар. Кайберәүләр кебек, дүрт ел сугышып кайткан кеше әле мин, дип, хатын кочагында ял итеп ятмадым. Бер атнадан

эшкә тотындым. Ә ферма үзе ни хәлдә иде ул чакта? Абзар-куралар тузып, җимерелеп беткән, курмы юк, сыерлар ачтан күтәртә, прәме өсләренә карап еларлык... Әйе. Сез ферманың хәзерге хәлен генә беләсез, мин, конешно, хәзергесе дә шәп, дип әйтмим, ләкин үткән белән чагыштырырлык түгел инде. Юк, иптәш Дускаев, ансат булмады, сугыш китергән бөлгенлектән чыгу ансат булмады, үзем генә беләм, Сөләйманов ул вакытларда Казанда укып ятты. Әйе...

Дускаев озак дәшмичә аны тыңлап утырды. Сөләймановны яклап сүз әйтергә ярамаганлыгын ул хәзер бик яхшы күреп тора, шуңа күрә Нургалинең сөйләп бетергәнен сабыр гына көтә иде.

Ә Нургали, нәкъ кирәген генә сөйли алмавына үзеннән-үзе канәгатьсез булып һәм ни өчендер Дускаевка да үпкәләгән сыман караңгыланып, тагын бераз үткәннәрне санап утырды да, аннан сүзне тизрәк бетерергә теләгәндәй, кинәт туп-туры сорап куйды:

— Йә, әйтегез инде, яхшымы-яманмы, ләкин минем шул фермага иткән хезмәтемне аның күрмәскә хакы булмы?

— Әлбәттә, юк! — диде Дускаев, тыныч кына.

— Шулай булгач, нигә ул миңа каныга?

Дускаев иңбашларын җыерып куйды.

— Гафу итегез, Нургали абый, мин аның сезгә ничек итеп каныгуын һаман әле аңламыйм.

— Аңламыйсыз? Аңламассыз шул... Әйе,— диде Нургали, яшен тизлеге белән Дускаевка зәһәрле караш ташлап. Ниндидер бер усал сүз ычкындырудан чак тыелып калды ул.

Дускаев бу карашны тотып алды булса кирәк, аның да саргылт йөзе караңгыланып киткән кебек булды, ләкин ул тынычлыгын җуймады.

— Юк, сез конкрет әйтеп бирегез, ничек итеп каныга ул?

— Ничек итепме? Ә аның кичә сессиядә сөйләгәннәре нәрсә соң? Ферма эшендә ник бер уңай як күрсен, кимчелек тә кимчелек, анысы эшләнмәгән, монысы эшләнмәгән, әйтерсең Нургали фермада бары корткычлык эшләп яткан. Йә, моны ничек дип аңларга, каныгу түгелмени бу?

— Нургали абый, кызмыйча гына сөйләшик, без олы кешеләр... Әгәр Сөләйманов, чыннан да, сезнең эшегездә бары кимчелек кенә күрә икән, сезнең моңарчы күрсәткән хезмәтләрегезне танымый икән, бу, әлбәттә, дөрес түгел, һәм менә мин, мәсәлән, аның белән бу туры-

да һич килешмәячәкмен. Ләкин ышаныгыз, Нургали абый, кулымны күкрәгемә куеп әйтәм, мин Сөләймановтан сезнең хакта андый начар сүз ишеткәнем юк. Ул инде миннән яшермәс иде.

— Нигә алай дисез, Сөләйманов дурак түгел...

— Сабыр, Нургали абый! Сез менә, каныгу, дисез. Мин бу сүзне болай аңлыйм: әгәр берәү берәүгә каныкса, ул аның яманатын сатып йөри, аның һәр эшен кыек күрә, җай чыккан саен аңа бәйләнә...

— Нигә, Сөләймановның да миңа бәйләнүе беренче тапкыр гына түгел бит!

— Һәрхәлдә, каныгу, дип әйтеп булмый. Бигрәк тә кичәге сессиягә килсәк, дөрес түгел бу... Сөләймановның анда нәрсә сөйләгәне миңа билгеле, ул, эш интересыннан чыгып, ферманың күп кенә кимчелекләрен күрсәтеп биргән. Без моны, каныгу, димибез, ә ачык, туры тәнкыйть, дибез.

— Тәнкыйть! — диде Нургали, башын чөеп һәм әче елмаеп.— Шәп сылтау, бик модный сүз, бу сүз белән барысын да каплап була хәзер... Тәнкыйть! Алдан ук белгән идем сезнең Сөләймановны ничек яклыйсыгызны...

Дускаевның кинәт йөзе үзгәреп китте, кашлары тартышып куйды, иреннәрен кысты... Һәм дәшмичә калды. Ә Нургали кинәт урыныннан кубып, яман кызып сөйләргә тотынды:

— Белегез, иптәш Дускаев, тәнкыйтьне аны Сөләйманов кына түгел, мин дә бик яратам. Аңлыйм, төшенәм, кирәк булуын бик яхшы белеп торам. Ләкин мин, гадел тәнкыйть булсын, дим. Минем эшемдә кимчелекләр күрәсез икән, әйтегез, рәхмәттән башка сүз юк, иллә мәгәр мине халык алдында рисвай итмәгез, моңарчы күрсәткән хезмәтемне юкка чыгарып ташламагыз! Әйе! Мин менә шушы куенымда (ул тун изүен чишеп җибәрде) өшегән бәрәннәрне җылытып йөргән кеше, мин келәтемнән бөртегемне фермага илтеп ашаткан кеше. Әйе. Миңа дөреслек кирәк, мин дөреслек сорыйм!

Нургали бизгәк тоткандай калтырана башлады. Дускаев тиз генә графиннан стаканга су салып, аңа сузды:

— Нургали абый, тынычланыгыз!

Нургали бер генә йотым эчеп куйды да кире урынына утырды. «Ни булды миңа, нигә мин үземне тота белмим?» дигән аптырау һәм әрнү тулы сорау аның күңелен тырнап узды. Бик авыр, бик оят булып китте аңа, һәм, хәлсез бер гаҗизлеккә төшкәндәй, ул башын салындырып, шактый тынып торды, аннан иренеп кенә өстәлдән бүреген алды.

— Контузия зәхмәте бу,— диде ул, акланырга теләгәндәй, акрын тавыш белән.— Мин сезгә, Идрис туган, кычкырышырга дип килмәгән идем. Йөрәгем янганга килдем, кичәдән бирле үземне кая куярга белмичә йөрим... Артыгын әйткән булсам, кичерегез!

— Мин сезне аңлыйм, Нургали абый! — диде Дускаев, җитди-сабыр гына.— Зур борчу төшкән сезнең күңелгә... Нишлисең, була ул. Тик сезгә тынычланырга кирәк. Вакыт шифалы нәрсә, күп тә үтмәс, бар да ачыкланыр, бар да үзенең эзенә төшәр.

— Шулай дисезме?

— Әлбәттә, шулай!

Нургали авыр сулап куйды.

— Ярый алайса, мин киттем...

Ул урыныннан торды, Дускаев та кузгалды.

— Нургали абый,— диде ул, мөмкин кадәр сак булырга тырышып,— сезгә ничектер, миңа калса, безнең арада сүз бетмәгән кебек әле. Яңадан бер очрашып сөйләшү зарар итмәс иде. Мәсьәлә шактый... катлаулы бит.

— Очрашырга, сөйләшергә мин... каршы түгел,— диде Нургали, түбән карап.— Әйе, катлаулы... Нәрсәне аңламыйм, хатам нидә минем, сез миңа шуны туп-туры әйтеп бирсәгез иде.

— Үзара сөйләшеп кенә кешеләр дөреслекне табалар, Нургали абый, тик... ничек кенә дип әйтим... моның өчен кешегә карата да, үзеңә карата да объектив була белергә кирәк.

— Нәрсә әле ул... объектив? Белә идем шикелле...

Нургали, кулы белән күзләрен каплап, уйга талгандай булды, ә Дускаев, аны-моны сизмичә, чыннан, да ул бу чит сүзнең мәгънәсен онытып җибәргән, ахрысы, дип үзенчә аңлатырга ашыкты:

— Объектив дигәнебез, Нургали абый...

Ләкин Нургали аның сүзен бүлде:

— Беләм! Аңлашыла!.. Рәхмәт яхшы киңәшегезгә!.. Ләкин, Дускаев, мин сезгә хәзер үк бер объектив... нәрсәне өзеп әйтим алайса.— Нургали сылу гәүдәсенә турайды, аның кара мыеклы ак йөзе җиңелчә кызарып, каракөрәнсу күзләре очкынланып киткән кебек булды: — Канызгучылар, сезнеңчә әйткәндә, тәнкыйть итүчеләр күбрәк булган саен, мин бишләтә-унлата тырышыбрак эшләячәкмен!

Дускаев саран-йомшак кына елмайды:

— Ышанам, ышанам, Нургали абый!

— Хушыгыз.

— Хуш, Нургали абый, хуш!

Ул кунагын алгы бүлмәнең ишегенә хәтле озата чыкты.

Нургалине озатып, ике сәгать дәрес укытканнан соң, Дускаев үзе дә өенә кайтырга чыкты. Март кояшы төшлектән авышса да, әле бик юмарт, бик иркә иде. Көн үтә якты, мамыктай йомшак, тик күләгәләр озыная төшеп, кояшка аркан торган кыек читләреннән зәңгәрсу «сөңгеләр» сузыла башлаган иде. Нигәдер көннең бу вакытында, бигрәк тә мәктәптән чыккан балалар бер ду кубып, шаулашып өйләренә таралганнан соң, авыл бер ара бик тын булып тора. Урамнарда кешеләр сирәк очрый, ишегалларында хатын-кыз тавышы, абзар тирәләрендә сыерларның ашарга сорап мөгрәүләре ишетелми, хәтта бер мәлгә чыпчыклар да тыналар, тик берәрсенең кыегы астыннан ата күгәрченнең кабарынып гөрләве генә ишетелә...

Дускаев урам уртасыннан, саргылт-көрән төскә кергән ат юлы буйлап ашыкмыйча гына бара, вакыт-вакыт астын су ашаган карга батып китә, туктап, кая таба атлыйм икән дигәндәй уйланып тора, ләкин атлау турында оныта булса кирәк, аяк астына караган килеш бер урында һаман тора бирә... Шул чакта аның йончыган тәне ниндидер бер хәлсез рәхәт талгынлык тоя, кояшның нурлары әйтерсең керфекләренә куна — күз кабаклары авырая, һәм күзләрен йомды исә, менә хәзер җирдән аерылып, җылы нур диңгезендә йөзеп китәр төсле була... Кыска гына бу онытылудан ул бик тиз айный, башын күтәрә, өстендә, битендә, күзләрендә уйнаган кояшны «китсәнә!» дип кугандай кулын селки дә тагын акрын гына атлап китә.

Әйе, Нургали белән сөйләшү аны тирән уйга төшерде. Уйлары аның күңелледән түгел иде, бу уйлар барысыннан да элек аның йөрәгендә үз-үзеннән ризасызлык хисе тудырды. Ул моңарчы Нургалине бөтенләй белмәгән икән, яки бары: ферма мөдире, уңган кеше, тырыш эшче дип, тышкы, формаль яктан гына белеп йөргән икән. Ә менә кеше һич көтмәгәндә үзенең бөтен эчке дөньясы белән ачылып куйды. Эчке дөнья тирән ул, катлаулы ул! Аның әнә Нургали үзе дә аңлап җитмәгән шактый караңгы яклары бар. Әгәр ул, Дускаев, көн саен диярлек бергә аралашып, очрашып, сөйләшеп йөргән партиядәше белән ныграк кызыксынса, аңа якынрак торса, сүзләренә ныграк колак салса, ферма мөдиренең бүгенге торгынлыкка килеп төшәсен алданрак күргән булыр иде. Димәк, Нургалинең хәзер авыр борчылуга дучар булуында, тирән

газап кичерүендә аның да өлешчә гаебе бар... Кеше, кеше, һәрдаим кеше торырга тиеш бит аның игътибар үзәгендә... Ничек ул белә торып шушы хакыйкатьне онытып җибәргән? Юк, ул үзен бу ваемсызлыгы өчен гафу итәчәк түгел!

Нургали аңа сүзенең ахырында: «Миңа дөреслек кирәк, мин бары дөреслек сорыйм»,— диде. Сүз юк, бик урынлы таләп; һичшиксез, Нургалигә дөреслекне төшендереп бирергә кирәк булачак. Ләкин дөреслек нидән гыйбарәт соң? Әйе, Нургали теләгән дөреслек белән чын дөреслек икесе бер нәрсәме ул?

Укытучы булганга күрәме яки үзенең характеры белән ачыклык һәм төгәллек ратканга күрәме, Дускаев һәр мәсьәләнең, нинди катлаулы булуына карамастан, эчке мәгънәсен табарга һәм аны бер-ике сүз белән кыска, тулы итеп билгеләргә ярата иде. Хәзер дә ул, бөтен акылын җигеп, ике коммунист арасындагы конфликтны аңларга, шуны ачык итеп билгеләргә тырыша иде. Чынлап та, бу конфликтның асылы нәрсәгә кайтып кала, төбендә аның нәрсә ята? Берсенең (ягъни Сөләймановның) ферма эшендә бары кимчелекләр генә күрергә, икенчесенең (ягъни Нургалинең) уңышларга күз йомарга ярамаганлыгын исбат итәргә; берсенең ферма мөдирен начар җитәкче итеп күрсәтергә, икенчесенең еллар буенча җаны-тәне белән бирелеп эшләвен якларга тырышуы, кыскасы, берсенең «нахак» сөйләве, икенчесенең «гаделлек» таләп итүеме бу?

Юк, алай булмаска тиеш, бу бары Нургалинең ике арадагы конфликтны үзенчә аңлатып бирүе генә әле... Асылда исә бу ике кешенең гаять мөһим мәсьәләгә ике төрле мөнәсәбәттә булуларын чагылдырган бер факт. Әйе, бу һичшиксез шулай.

— Исәнмесез, Идрис абый! — диде бер хатын-кыз тавышы.

Дускаев тавышка башын күтәрде. Ул, уйларыннан арынып җитмәгәнгә, ахры, дәшүчегә беравык, танымагандай, аптырабрак карады. Дәшүче инде үтеп китеп бара иде.

— Ә, Сөембикә, син икәнсең, исәнме? — диде, ниһаять, Дускаев.— Кая болай ашыгасың?

Сөембикә тукталды.

— Өйгә, Идрис абый, бүген өемдә булганым юк әле.

— Нишләп алай?

— Төнлә фермада дежур иттем. Дежурдан кайтышлый бәрәңге чүпләүчеләр янына тукталган идем, тәки шушы вакытка кадәр китә алмыйча тордым.

— Ашау-эчүне дә онытыпмы?

— Ашау мул анда,— диде Сөембикә, көлемсерәп.—

Кызларның кайсы май, кайсы сөт китергән... Өйдә алай тәмле итеп ашап та булмый.

— Алай, урынаш ясагансыз икән,— диде Дускаев, елмаеп.— Белмәдем, мин дә кызлар янына сыйланырга барган булыр идем.

— Килү кирәк иде, бер-ике центнер бәрәңге дә чүпләп киткән булыр идегез,— диде Сөембикә һәм, хәтере калмасын дигән төсле, карашын тизрәк читкә алды.

Дускаев, күзләрен кыса төшеп, бераз дәшмичә Сөембикәгә карап торды. Сугыш вакытында иреннән яшьли генә калган, хәзер дә әле утызлар тирәсеннән узмаган бу яшь тол хатын соңгы елларда колхозның бик күренекле эшчесе булып киткән иде. Ул күптән инде яшелчә бакчасының бригадиры булып эшли, иренең үлү хәбәре килгәч, партиягә кергән, хәзер исә бюро әгъзасы да булып тора иде. Хатын-кызлар белән бик аралашып, алар арасында күптән инде, беркем кушмастан, үзе теләп, үзе белгәнчә агитация эшләре алып бара иде. Дускаев аның бу хосусыятен белеп алгач, бик кызыксынып, ләкин бер дә рәсми сызыкка басмыйча гына, аңа үзенең киңәшләрен бирә башлады.

Менә хәзер Дускаевның кинәт Сөембикәдән Нургали турында сорашасы килде. Аныңча, ул кичәге һәм бүгенге хәлләр турында үзенең хатын-кызларыннан шактый хәбәр ишетеп өлгергән булырга тиеш иде. (Сөембикә үзе әйтмешли, хатын-кызның эшләгәндә дә теле тик тормый бит аның...) Ләкин турыдан-туры сорауны яхшысынмады.

— Фермада ниләр бар соң? — диде ул.

— Әллә ни юк,— диде Сөембикә һәм өстәп куйды: — Кәримәнең «Алма»сы бозаулады.

— Шулаймыни?! Әллә ни юк дисең, менә нинди күңелле вакыйга булган ич! Бозавы әйбәтме соң?

— Бик әйбәт, Идрис абый, шундый зур, шундый тере үзе... Кырык килограмм тартты.

— Ай-һай, кара син аны,— диде Дускаев, башын чайкап.— Кәримә бик куангандыр инде!

— Куанмаган кая ул! Түбәсе күккә тия язды кызыйның...

— Әнә ничек! Бик нечкә күңелле кыз шул безнең Кәримәбез, Нургали абыеңның да алайса кәефе шәптер инде?

Сөембикә бераз көттереп җавап бирде:

— Аңламый башладым әле мин аны,— диде ул, кечкенә кара күзләрен тагы да кыса төшеп.— Әллә нәрсә булган аңа.

— Ничек алай әллә нәрсә булган?

— Ничек кенә дип әйтергә дә белмим, Идрис абый... Бөтен кешегә хәтере калгандай, кара көеп йөри, бер сүз әйтергә ярамый үзенә, хәзер кабынып китәргә тора. Элек алай түгел иде кебек.

— Аның бик борчулы чагы бит, Сөембикә,— диде Дускаев, юри Нургалине акларга тырышкан булып.— Үзең беләсең, фермабыз авыр вакыт кичерә.

— Анысы шулай,— диде Сөембикә һәм авыр гына сулап куйды.— Ләкин бер ферма кайгысы гына түгел шикелле, Идрис абый, башка кайгысы барга охшый.

— Нинди кайгысы булыр икән тагын?

— Кичәге сессиядән соң җаны әрнеп йөрмиме икән, дим?

— Нигә, анда шулай Нургали абыйның җанын әрнетерлек нахак сүзләр әйттеләрмени?

— Юк, нишләп нахак сөйләсеннәр, бик дөресен әйттеләр. Ләкин, Идрис абый, дөреслек кайчак бик әче була бит ул!

— Әче булган саен шифалырак та була ул, Сөембикә! — диде Дускаев, бик гади генә итеп.

Сөембикә дәшмәде. Ул икегә аерып тараган чем-кара чәче өстеннән артка таба авышкан шәлен алга таба тартып куйды һәм читкә карап бераз уйланып торды. Күптән күңелендә туган нindидер бер уй борчый иде шикелле аны...

— Тик менә,— диде ул, ниһаять, шул уен әйтергә сүзләр эзләгән кебек, тотлыга төшеп,— шуны, ничек дим, сез әйткәнчә, дөреслекнең шифалы булуын димме, ул үзе аңласа иде.— Һәм ул кинәт кенә ашыгып әйтеп куйды: — Юк, Идрис абый, аңа төшендерергә кирәк, халыкның аңа каршы булмавын, аның файдасына сөйләүләрен төшендерергә кирәк. Югыйсә кеше бер ялгыш уйлый башласа, бөтенләй эздән язып, чуалып бетәр.

— Дөрес, Сөембикә, мин синең бу сүзләреңә кушылам. Әлбәттә, Нургали абыйга кайбер нәрсәләрне яхшылап төшендерергә кирәк булыр. Ләкин без моны бергәләп эшләргә тиешбез.

— Ничек итеп? Әллә тагын берәр утырыш җыярга уйлыйсызмы?

— Юк, уйламыйбыз! Анысы хәзергә кирәкми. Башкача да эшләп була. Менә әйт әле, халык арасында Нургалине фермадан алалар, аның урынына Сөләйманов баҗасын куялар икән, дигән сүз йөрмиме?

— Ничектер бүген колагыма кереп калган иде дә, мин әһәмият бирмәдем, Идрис абый!

— Бирү кирәк, Сөембикә! Дөрес, ул һич нигезе булмаган гайбәт кенә, ләкин әнә Нургали абыеңның мыегын чуалтыр өчен җитә калган. Син ул гайбәтне кемнән ишетсәң дә юкка чыгар!

— Кем ышана соң аңа!

— Төрле кеше бар, акыллым, ышанучылар да табылыр, ә бәлкем юри куертучылар да бардыр. Халык белеп торсын, Нургали үз урынында булачак!

— Ярый, Идрис абый, мин аны истә тотармын,— диде Сөембикә, башын кагып.

Дускаев аңа якынрак килә төште.

— Аннан беләсеңме нәрсә, Сөембикә! — диде ул, сер әйткәндәй, тавышын әкренәйтә төшеп.— Кичә сессиядә сөйләнгән сүзләр алар бер Нургали абыеңа гына түгел, ферманың барлык кешеләренә дә кагыла бит. Ферма кешеләренә менә шуны аңлатасы иде. Бер тынгысыз абыйларына гына салынып тормасыннар иде, дим. Син ничек уйлыйсың?

— Дөрес бу, бик дөрес, Идрис абый! — диде Сөембикә, кинәт ачылып.

— Ферма кешеләре үзләренең мөдирләрен яраталар ич!

— Әйе, яраталар!

— Менә шуны эштә күрсәтсеннәр дә!

Сөембикә куанычыннан көлеп үк җибәрде:

— Һай, беләм мин аны, кызларның: «Нургали абый!»— дип, янында бөтерелеп йөрүләрен бик ярата ул!

— Шулаймы? — диде Дускаев та, елмаеп.— Менә син ферма кызларын көйлә инде. Ешрак йөр ул тирәгә...

— Эшлим мин моны, Идрис абый, эшлим!

— Бик яхшы алайса! — Ул Сөембикәгә кулын сузды: —Ярый, мин синең юлыңны бүлдем, Сөембикә, хәзергә хуш! — Һәм Сөембикәнең атсыз бармагына көмеш йөзек кигән каратутлы кулын кысты да ашыкмыйча гына китеп барды.

Аерылып үз юлы белән киткәч тә Дускаев, «Нургали мәсьәләсе» турында борчылып уйланмыйча булдыра алмады. Мин-минлеге бик кимсетелгән, үзен, чыннан да, хаксызга рәнҗетелгән дип нык ышанган, шунлыктан һәркемгә ышанмыйча, шикләнеп карый башлаган кешегә чын дөреслекне аңлатып бирүнең бик читен эш булуын ул, әлбәттә, белә иде. Ләкин... Сөембикә белән сөйләшү аны бераз тынычландырды. Нургали өчен кайгырып торучылар бар чагында, кешегә авыр торгынлыктан чыгарга, шаять, ярдәм итә алыр ул.

# VII

Күрше районга капчыклар алырга киткән колхоз председателе Шәйхи абзый икенче көнне Яуширмәгә кайтып килә иде.

Көн җилле, ак читле кабарынкы болытлар язгыча бик биектән ашыгып агалар, кояш, бозлар арасында йөзгән каек шикелле, бер югала, бер ялтырап килеп чыга, ә каралган кырлар өстеннән, очсыз-кырыйсыз маллар көтүедәй, болытлар шәүләсе шуып үтә. Кичәбүген генә килгән кара каргалар юл буенда, җилгә кырын торып, сикерә-сикерә йөриләр яки түбәннән генә очып китәләр...

Моннан бер атна чамасы элек яки ике көн рәттән котырган буран бөтен дөньяны мамыктай йомшак кар белән ап-ак итеп сылап куйган иде. Буран артыннан ук кар ашыгып эри башлады, бөтен ерганаклардан кырлар өстен тонык гөрләтеп шарлавыклар йөгерде, уйсу җирләргә зур-зур чуар күлләр җыелды... Инде менә иңеиңе белән кырлар да ачылып килә.

Кечкенә кашёвка чанага урталайга бөкләп салган капчыклар өеме өстенә аякларын читкә салындырып утырган Шәйхи абзый атын атлатып кына бара. Иртәнге салкын белән кайтып җитәргә чамалап, «Якты күл»дән караңгылы-яктылы чыккан иде ул, ләкин Яуширмә җирләренә килеп җиткәндә, юл тәмам бозылып өлгерде. Юлның буеннан-буена вак кына гөрләвекләр узыша-узыша шаулап агалар, ара-тирә кар астыннан чыккан кара җир өстендә соңгы чаналарның киң табан эзләре ярылып ята, чокыр-чакырлар исә су белән тулган.

Шәйхи абзыйның йонлач бәкәлле, койрыгын төйнәп бәйләгән кечкенә аты, тайгак бозга сак кына басып, күбрәк юл кырыеннан, кар яткан төшләрне сайлабрак барырга тырыша. Аның инде азапланып килә-килә аркасы, эче генә түгел, бот буйлары, хәтта сыйраклары да тирләп чыккан иде.

...Авыл советы сессиясеннән соң икенче көнне иртән иртүк юлга чыгып киткәнгә күрә, Шәйхи абзый колхоздагы вакыйгалардан хәбәрсез иде. Әмма сессия үзе аңардан күп уйлар кузгатты, барганда да, менә хәзер кайтышлый да ул колхоз фермасы турында нык уйланды. Әлбәттә, ул ферманың хәлен бик яхшы белеп тора, андагы кимчелекләрне күптән күреп йөри иде. Ләкин куркыныч бер авыруга юлыгуын, ягъни белә торып та кимчелекләргә килешеп каравын, бүтәннәрдә бездән дә начар, безне әле яхшы исәптә йөртәләр, дип тынычланып

яшәвен ул менә хәзер генә аңлады. Ачынып, эченнән сүкте ул үзен: «Карт алаша! Өстерәгән буласың шунда, ә кая өстерисең, нәрсә өстерисең — шуны үзең күрмисең. Рәхмәт Сөләймановка, ияк астына бик вакытлы төртте әле!» Бәлкем, Шәйхи абзыйның үзен болай каты сүгүе урынсызрак та булгандыр, чөнки ул, председатель кеше, алга карамыйча, киләчәк турында уйламыйча зур һәм катлаулы хуҗалыкны алып баралмас иде, билгеле. Ләкин, ничек кенә булмасын, бер хакыйкать аның өчен хәзер бәхәссез: халык колхоз фермасыннан канәгать түгел, үзләре әйтмешли, «игелеген күрмиләр»... Һәм бик урынлы таләпләр куялар. Әйе, бик урынлы, үз хуҗалыклары лабаса, сакларга алган кеше байлыгы түгел! Димәк, моңарчы ирешелгән уңышлар белән мактанып, юанып йөрүдән туктарга вакыт. Эшкә бөтенләй башкача килеп карарга һәм өр-яңа теләктән чыгып тотынырга кирәк. Һич икеләнмичә: «Болай ярамый!» — дип әйтергә кыюлык җитәргә тиеш. Терлекләрнең продукт бирүләрен арттыруда, азык хәзерләүдә, абзар-кураларны төзүдә, фермага техника кертүдә көчне дә, акчаны да жәлләмәскә кирәк. Колхозның моңа хәле җитәрлек, эшли алырдай кешеләре бар.

Бу уңай белән Шәйхи абзый Нургали турында да күп уйланды. Бик белә иде ул үзенең ферма мөдирен, бөтен көчле һәм йомшак яклары белән белә иде... Шәйхи абзый, Нургалинең агасы Сәетгали белән яшьтәшләр булып, герман сугышына бергә киткәннәр иде. Солдат нужасын бергә татып, бергә йөргәннәр, Шәйхи абзыйның әйтүенә караганда, бик дус булганнар. Сәетгали 1919 елны Кызыл Армия сафында һәлак була, ә Шәйхи абзый, гражданнар сугышын бетереп, егерме беренче елны илгә кайта. Ул чакларда әле Нургали унике-унөч яшьлек кенә малай иде, ләкин төсе-бите, күз карашлары, хәтта кайбер кыланышлары белән ул мәрхүм агасына шундый охшый, Шәйхи абзый бер күрүдән аны бик үз, якын итеп китә. Бу якын итү тойгысы аның күңелендә соңгы елларга кадәр бер дә кимемичә сакланып килә.

Асылда, Нургалине ул күтәрде. Председатель булуыннан файдаланып, аны гел җитәкче урыннарга куеп килде. Кешеләр тел тидерә башлаган чакта да ул аны якларга тырышты, вак-төяк кимчелекләренә күз йомды, кыскасы, егетнең опекунына әйләнде. Дөрес, Нургали үзе дә моңарчы аның ышанычын аклап килде — егет бик уңган, тырыш булып чыкты, кая куйсаң да, кулыннан эш килгәнлеген күрсәтте, үзе янды, башкаларны яндыра белде, эленке-салынкы йөрүчеләргә тынычлык бирмәде.

Болары яхшы иде. Әмма шулай да Шәйхи абзыйның күңеле тыныч түгел иде; егет үзенең кырыслыгы, сүз күтәрмәве, масаерга да яратуы белән аны еш кына уңайсыз хәлгә куйгалый иде. Бигрәк тә анның ачыктан-ачык председатель канаты астына сыенуы, һәр җирдә, һәр очракта председательне үзенең яклаучысы итеп танытуы Шәйхи абзыйның соңгы вакытларда эчен бик пошыра башлады. Бу хәерлегә илтмәячәк. Мисал артыннан ерак барасы да түгел: менә булып үткән сессиядә Нургали үзен ничек алама тотты. Сөйләүчеләргә бәйләнеп утырды, халык белән хисаплашмыйча соңгы сүздән баш тартты, ә Сөләймановка булган дошманлыгын яшереп тә тормый хәзер... Кемгә таянып, кемгә ышанып ул болай кылана? Болай кыланып, ул кузгатылган мәсьәләнең җитдилеген аңлый аламы, ферма алдында торган зур эшләрне күрергә сәләте җитәме анның? Кичә генә макталып йөргән Нургалиебезгә бүген колхозчылар: «Пүчтәк кеше син!» —дип әйтмәсләрме? Яклап кара син аны шул чакта! Ах, җил баш, җил баш!

Шулай ачынып уйлана-уйлана авыл урамына килеп керүенә ул Сөләймановны очратты. Зур авыл урамында иң башлап аны очратуына гаҗәпләнә калды, ихтыярсыз, эченнән: «Гел күз алдында бу егет!» — дип уйлап алды. Кинәт ул Нургалинең ни өчен аңа шулхәтле каны катып йөрүен аңлаган кебек булды: көнләшү, яшь, яңа, өстен кеше булуыннан көнләшү!

— Саумы, Шәйхи абый! — дип ерактан ук дәште Сөләйманов.

— Исәнме, Закир туган!

Яшь председатель, Шәйхи абзый янына килеп, чана башына тотынды да янәшә атлап бара башлады.

— Юлың уңышлы чыккан икән, Шәйхи абзый!

— Үзем барып яхшы иттем әле,— диде Шәйхи абзый салмак кына һәм кул сырты белән яңагын ышкып алды.— «Якты күл» председателен күндерүе ансат булмады. Сатасын сатып беттек, артыгы юк, ди, ишетәсе дә килми. Ярый әле, ике пот балавыз алып барган идем, шуның белән көйләп булды тагын... Син каян кайтып киләсең?

— Сушилканы барып карадым.

— Мичен төзәтәләрме?

— Бүген бетерәләр.

Бераз сүзсез бардылар. Аннан Шәйхи абзый сорап куйды:

— Йә, сессиядән соң халык арасында нинди сүзләр йөри?

— Әллә ни ишеткәнем юк, Шәйхи абзый!

— Атла әйдә, атла! — диде Шәйхи абзый арыган атына йомшак кына.— Ферма тирәсенә барып чыкканың юкмы?

— Барган идем дә...— диде Сөләйманов, ләкин сүзен әйтеп бетермәде.

— Соң?

— Шул.— Сөләйманов юка иреннәренең чите белән генә елмайгандай итте.— Хәзергә ул тирәдә йөрмәү яхшырак икән дип кайттым.

— Нишләп алай?

Сөләйманов җавап бирергә ашыкмады. Аның әле ферма өендә булган вакыйганы (Нургалинең аны ничек әшәке итеп хурлавын) беркемгә дә сөйләгәне юк иде һәм сөйлисе дә килми иде. Ләкин Шәйхи абзыйдан яшереп калуны килештермәде.

— Ничек итеп кенә әйтергә, Шәйхи абзый? — диде ул, авыр гына көрсенеп, һәм ферма өендә булган вакыйганы кыскача гына сөйләп бирде. Зарлану булып чыкмасын дип, ул Нургалинең нахак әйткән сүзләрен, ямьсез җикеренеп кычкыруларын мөмкин кадәр йомшартып сөйләргә тырышты һәм сүзен ярым шаярту белән:

— Нургали абыйның начар төш күреп килгән вакытына туры килдем, ахрысы,— дип бетерде.

Шулай да Шәйхи абзый эшнең асылда ничек булганлыгын яхшы аңлады булса кирәк, агарган куе кашлары аның җыерылып, кечкенә күзләре усалланып кысыла төште. Ләкин ул бер сүз дә дәшмәде, тик дилбегәсен генә каты тартып куйды.

Сөләйманов, аз гына тынып барганнан соң, ферма мөдирен акларга теләгәндәй:

— Ферманың бик мәшәкатьле чагы, азык хәле авыр, менә шулар Нургали абзыйның нервысын бераз какшатып җибәргән булса кирәк,— диде.

Шәйхи абзый бу юлы да дәшмичә калды. Үзенең яраткан кешесен ул сүгәргә теләми идеме, әллә аңа гаять хәтере калган идеме — Сөләйманов аңлый алмады. Аңа хәтта бераз авыр да булып китте; ул үзе Нургалине күңеленнән кичерергә һәм аңа ачу тотмаска тырышса да, башкаларның ферма мөдирен гел генә кичереп, йомакайлап калулары белән килешүе аның өчен, билгеле, җиңел түгел иде.

Колхоз идарәсенә килеп җиткәч, алар аерылыштылар. Шәйхи абзый колхозның завхозы Сираҗины чакыртып алды да, аңа атын һәм йөген тапшырып, өенә кайтып китте.

Бераздан чәй эчеп килгәч һәм идарәдәге кешеләр белән исәнләшкәч, ул иң элек дежурныйны фермага Нургали артыннан җибәрде, аннан зур канцеляриянең сулъяклап такта белән бүлгән кечкенә ягына — «үзенең кабинетына» кереп, тунын, бүреген салып элде. Түр тәрәзә каршындагы кечкенә өстәле артына кереп утыргач та, ул хисапчы Мусаны дәшеп алды.

Шәйхи абзыйдан чакыру килгәч тә, Нургали тизрәк идарәгә барырга ашыкты. Аның кәефе берьюлы күтәрелеп киткән кебек булды. Ниһаять, Шәйхи абзасын күрә ул! Бу ике-өч көн эчендә иң якын кешесенең юк булып торуы күпме аның җанын борчыган иде. Менә хәзер, ичмасам, рәхәтләнеп бер сөйләшү булачак! Артык зарланырга исәбе юк аның, әмма Шәйхи абзый болай да эшнең серен тиз төшенер.

Нургали бер генә минутка өенә дә кереп чыкты. Мич алдында чуалган Миңсылу аны:

— Нигә болай бик иртә, минем чәем дә әзер түгел әле,— дип каршы алды.

— Мин әйтеп чыгарга гына кердем,— диде Нургали, кабаланып.— Без соңгарак Шәйхи абзый белән бергәләп кайтырбыз. Син шул вакытка табыныңны әйбәт кенә әзерләп тор, баздан кәбестә дә чыгарып куярга онытма.

— Кайчанрак кайтырсыз соң?

— Озакламабыз.

Өеннән ашыгып чыгып киткәч, Нургали кибеттән бер ярты аракы алып чыгу турында уйланды. Шәйхи абзасы белән аның ара-тирә, яки үзендә, яки аларда, аш алдыннан берәр йомры эчеп, сөйләшеп утырган чаклары булгалый иде. Шуңа күрә председательнең гаеп итү ихтималы юк иде. Шулай да Нургали аның белән бергә кайткан чакта аракы артыннан кибеткә керүне килештермәде, хәзер барышлый алып чыгуны уңайрак күрде һәм сельпо кибетенә борылды.

Кибеттә, бер почмакка җыелган биш-алты малайдан башка, зурлардан беркем дә юк иде. Малайларның берәрсе, иптәшләрен көтүе белән ияртеп, конфет яки каткан прәннек алырга кергәндер инде, хәзер барысы да куып чыгарганны көтеп, кибеткә кем кергәнне, кемнең нәрсә алганын, авызларын күтәреп, карап торалар.

Сырма өстеннән ак халат, башына колакчын бүрек кигән сатучы Габделхәй Нургалине бик куштанланып каршы алды:

— Әйдүк, Нургали абый, әйдүк! Нишләптер бик сирәк керә башладыгыз әле?

— Эш, парин! — диде Нургали һәм кибетнең шүрлекләре өстеннән күз йөртергә тотынды.

Габделхәйнең сары керфекле, куянныкыдай аксыл күзләре, Нургалинең ни өчен керүен тиз үк сизеп алырга теләп, аңа төбәлде, ә кызыл чыраена елмаю катыш каушау билгесе чыкты. Ни хикмәттер, Габделхәй дә, күп кенә кибетчеләр шикелле үк, колхозның җитәкче кешеләреннән ихтыярсыз шүрли иде.

— Бу чаршау һаман тора икән әле,— диде Нургали, түшәмгә камыт белән янәшә элеп куйган эре чәчкәле ефәк хатын-кыз халатына күрсәтеп.

— Тора шул,— диде сатучы, халатка карамаска тырышып.— Менә сез, Нургали абзый, Миңсылу апага алып җибәрер идегез.

— Аны кисә, Миңсылу апаң мине танымый башлар йә!

Габделхәй кеткелдәп куйды:

— Таныр, алтынга мансагыз да таныр! Сезнең кебек ирне танымаска, юләр...

Ләкин Нургалинең сатучы белән мәзәк сөйләшеп торырга вакыты юк иде, ул борылып малайлар төркеменә карап алды. Габделхәй шунда ук эшне сизде.

— Ягез әле, малайлар, үкчәгезне күтәрегез моннан,— дип кычкырды ул, кулы белән ишеккә таба селтәп.— Көшегез, көш, тизрәк булыгыз!

Малайлар дөбердәшеп ишеккә ташландылар. Алар чыгып киткәч, Нургали:

— Кая, бер акбашны бир әле! — диде.

Габделхәй җәһәт кенә ярты литр аракыны алып, халат чабуы белән сөрткәләп прилавкага куйды. Нургали аракыны эчке чалбар кесәсенә тыкты да егерме биш сумлык акча чыгарып бирде:

— Здачасына конфет үлчимме?

— Ярар, үлчә!

Сатучы, укмашып каткан тышсыз конфетны үлчәп, ящик кырыеннан кәгазь ертып алды да шуңа төреп Нургалигә сузды. Нургали конфетны тун кесәсенә тыгып чыгып китте.

Ул идарәгә барып кергәндә Шәйхи абзый бүлмәсендә берничә кеше утыра иде. Туры бүлмәгә узмыйча, башта ул хисапчы Муса янында тукталды. Ләкин телгә беткән Мусаның бу юлы эше бик тыгыз иде, ахрысы, Нургалигә күтәрелеп тә карамыйча, бары үзбәкчәләп:

— Хуш килепсең! — дип кенә куйды. Нургали аның тузган чәченнән тотып, борыны белән өстәлгә бер-ике кат иеп алды.

— Хуш килепсең! Яуширмәдән куарга кирәк сине, әнә кире Пәрганәгә кит!

— Нимә өчен, әкә җан?

— Үзбәк булганың өчен... Шулкадәр күңелеңә ошагач, ни пычагыма монда кайттың? Берәр үзбәк чибәренә өйләнер идең дә шунда «әкә җан» булып торыр идең!

— Һай-й! — диде Муса, күзләрен йомып.— Үзбәкстан —багостан ул, ә аның чибәрләрен күрсәң, һушыңнан язарсың! Кашлары карлыгач канатыдай, күзләре кара җимештәй, иреннәре ал чәчәктәй! Бер кашык су белән йотып җибәрерлек инде! — Аннан, айнырга теләгәндәй, ул башын селкеп куйды: — Ярар, Нургали абый, минем эш бик тыгыз...

— Нишлисең?

— Менә Шәйхи абзый терлекләргә кирәк азыкның еллык расходын яңадан бер кат исәпләп чыгарга кушты. Кайбер азыкның, мәсәлән, бәрәңгенең терлек башына нормасын арттырып бирде.

— Алай икән! — диде Нургали һәм, бүген күп нәрсәләр турында сүз буласын уйлап, председатель бүлмәсенә керде.

Шәйхи абзый, исәнләшкәч, аңа утырырга урын күрсәтте. Нургали бүреген салып, тун изүен чишеп өстәл янына утырды. Чалбар кесәсенең бик шикле булып кабарып торуына бүлмәдәгеләр игътибар итмәсеннәр дип булса кирәк, ул аягын сузып җибәрде һәм тун чабуларын җыя төште.

Бүлмәдә утыручыларның берсе өлкән ат караучы Бәдри абзый, икенчесе тимерче Садыйк абзый иде. Сүз язгы чәчүгә төшәр алдыннан атларны ялга кую турында бара... Нургали, Шәйхи абзыйның ниндирәк кәефтә булуын алдан сизәргә теләп, аңа бик төбәлеп кенә карап торды. Ләкин председательнең җил-суыктан бакыр төсенә кергән тирән сызыклы йөзе, гадәттәгечә, тыныч иде. Ул, өстәлгә терсәге белән таянып, кырган чал башын акрын гына сыпыргалап, агайларны дәшми генә тыңлап утыра.

Сүз инде ахырына җиткән булырга тиеш. Шәйхи абзый итләч калын кулын өстәлгә салып, кыскача гына йомгаклап куйды:

— Менә шул, агайлар! Атларга полный ял. Минем рөхсәттән башка беркая җигү юк, төшкән, какшаган дагаларны өч көндә алыштырып бетерерсез! Сөйләштекме?

— Әйе, Шәйхелислам, сөйләшкәнчә булыр,— диделәр агайлар.

— Инде алайса, барыгыз, чәй эчәргә кайтыгыз!

Агайлар торып, Нургалигә бер күз ташлап, бүрекләрен кия-кия чыгып киттеләр. Алар тышкы ишектән чыгуга, Шәйхи абзый такта стена аша Мусага да кычкырып дәште:

— Муса, бар, булмаса, син дә кайтып кил!

— Бетерим дигән идем, Шәйхи абзый!

— Килгәч бетерерсең.

Нургали дә урыныннан торды.

— Ә син кая кузгаласың? — диде Шәйхи абзый аңа.

— Нигә, безгә дә вакыттыр ич! — диде Нургали, җиңелчә гаҗәпләнеп.— Миңа гына кайтып сөйләшербез дигән идем. Миңсылуның чәе әзер.

Ләкин Шәйхи абзый урыныннан кузгалмады.

— Сиңа кайтсак, Миңсылу бар, миңа кайтсак — Хәбирә җиңгән...— диде ул, такыр башын сыпырып.— Юк, монда гына утырыйк әле.

Нургали, билгеле, Шәйхи абзыйның күздән-күзгә генә сөйләшергә теләвен аңлады һәм үзе дә, сүзне бетереп кайту яхшырак булыр, дип уйлап алды. Ләкин ул кире утырырга өлгермәде, Шәйхи абзый урыныннан торды.

— Әйдә әле, алгы якка чыгыйк! — диде ул, үз бүлмәсен кысан күргән шикелле.

Алгы якка чыккач, ул Нургалигә утырырга кушты. Нургали, тун аша чалбар кесәсен капшап, иpләп кенә утырды (теге хәерсезнең бөкесе бик алама, авызы түбән килеп саркый башлавы бар). Шәйхи абзый үзе утырмады, Нургали каршысына кыска аякларын аера биреп басты да, куе кашларын җыерып, кечкенә кыйпылчыктай үткен, салкын күзләре белән Нургалинең йөзенә туп-туры төбәлеп, беравык карап торды, аннан акрын гына дәште:

— Нишләп әле син, яхшыдан яман туган нәрсә, артың белән киртә җимереп йөрисең, ә?

Нургали аптырап китте, ләкин, Шәйхи абзыйның ачуланып соравына бер дә ышанасы килмичә, елмайган булды:

— Ничек алай киртә җимереп?

— Ә ферма өендә Сөләйманов өстенә яшь этәч төсле очып кунуың нәрсә ул? Геройлык күрсәтмәкче булдыңмыни? Мин кем, янәсе! Сөләйманов — бозау. Аның урынында булсам, күрсәтер идем мин сиңа геройлыкны!

— Тукта әле, Шәйхи абзый...

— Туктап торасы юк,— диде Шәйхи абзый, кинәт кычкырып.— Страм бу! Авыл советы председателен фермадан куарга кем сиңа права бирде, кем булдың син, ә?

Председательнең каплан шикелле бу кадәр кинәт ташлануыннан Нургали аптырау гына түгел, бөтенләй каушап төште. Каршы сүз әйтә алу сәләтен югалтып җибәрде ул.

— Кемне куркытмакчы, кемнең исен китәрмәкче буласың, ә? — диде Шәйхи абзый, шул арада кызганнан-кызып; ярсудан хәтта аның муен тамырлары калкып чыкты.— Сессия — сессия түгел сиңа, председатель — председатель түгел. Халык белән хисаплашу юк, кешеләр сүзенә колак салу юк. Бу ни эш бу! Халык сиңа әллә сарык көтүеме? Кара аны, болай дөньяга сыймас булсаң, арбадан очып төшкәнеңне сизми дә калырсың!

— Тукта әле, Шәйхи абзый, кем хисаплашмый, кем колак салмый? — диде, ниһаять, Нургали, тәмам гаҗизлеккә төшеп.

Шәйхи абзый аңа кисәк кенә бармак янап алды:

— Син минем күзгә төтен җибәрмә, мин бит сине үтәдән-үтә күреп торам. Кем, имеш! Йә, сессиядә кара янып, кем сөйләсә шуңа кадалып утыруың нәрсә иде ул — агайларга рәхмәт әйтү идеме әллә? Җил баш син! Күк күкрәгән өчен болытларга бармак янап маташасың, адәм көлкесе!

Нургали сизә: Шәйхи абзый артыгын әйтә, урынсыз каты әйтә, ләкин аның сүзләрендә рәхимсез дөреслек бар кебек, югыйсә шундый якын кеше бу кадәр ярсып аны орышмас иде. Шулай да Нургалинең үзен бик аклыйсы, бик аклыйсы килә, чөнки аның үзе тойган дөреслеге бар, ул аңгыра бер малай түгел ләбаса! Әмма — гаҗәп хәл! —ул бөтенләй таркалып калды, әйтерсең Шәйхи абзый аның үзен-үзе яклау ихтыярын берьюлы сындырып ташлады. Җитмәсә, салкын аракы шешәсен гел тоеп торуы аңа үзен күпме-азмы тыныч, батыр хис итәргә гаять комачаулый иде. Ахырда ул, үз сүзенең көченә, чынлыгына ышанып бетмәгәндәй, кыюсыз гына әйтеп куйды:

— Шәйхи абзый, аңла әле, мин берәүгә дә каршы түгел, мин бары дөреслек кенә булсын дим.

Ләкин Шәйхи абзый, аның нинди дөреслек теләвен алдан ук сизеп, тыңлыйсы килмичә кулын гына селекте.

— Дөреслекне безгә әйтеп бирделәр,— диде ул, кырт кисеп.— Фермабыз алама. Адәм рәтле доход китергәне юк, колхозчыларга бер кружка сөт, сыңар бияләйлек йон бирә алганыбыз юк. Менә сиңа дөреслек!

— Ну бит, Шәйхи абзый, ферманың хәзергедән күп начар вакытлары бар иде.

— Яуширмә халкы аны белә, ләкин сине дә, мине дә аркадан кагып мактарга ашыкмый, иртәрәк әле, ди, эш

көтә але ул бездән. Ә алда торган эшләр тау кадәр. Сөләйманов сиңа акыллы киңәш бирде: киләчәк турында уйларга кирәк!

Нургали аскы иренен агартканчы тешләде, ә Шәйхи абзый, кулларын артка куеп, түр тәрәзә янына китте һәм шуннан торып, артына борылмыйча, коры гына:

— Бар, кайт! — диде.— Икенче болай кеше көлдереп, тилереп йөрүеңне ишетәсе булмыйм. Киләсе атнада правление җыям, шуңа әзер булып тор. Ниләр эшләргә уйлыйсың — әнә сессиядә ишеткәннәреңнән чыгып, план төзеп китерерсең!

— Анысын инде кеше көлкесенә калмаган башка берәү эшләр,— диде Нургали, кара янып.

Шәйхи абзый кинәт аңа таба борылды.

— Юк, син эшләрсең, синнән сораячакбыз!

Аның тавышыннан тәрәзә зыңлап киткән кебек булды... Һәм Нургали кинәт урыныннан кубып ишеккә ташланды.

...Өенә җиткәнче ул йөгерә-йөгерә кайтты. Урамда очраган кешеләр аның артыннан: «Ни булган бу Нургалигә?» — дип, тукталып карап калалар иде. Ә Нургалинең кешеләрдә эше юк, сыртына каты чыбыркы төшкән яшь ат шикелле, ул ак-кара күрмичә чабуын белде.

Йортының ишегалдына кайтып кергәч, ул иң элек капкасын нык итеп ябып куйды. Аннан кеше-мазар юкмы дип, тирә-ягына ялт-йолт каранып алды да, чалбар кесәсеннән аракы шешәсен чыгарып койма буенда яткан зур ташка челпәрәмә бәреп ватты.

## VIII

Һәр көнне сәгать биштән, алтыдан да калмыйча торып фермасына йөгерә торган Нургалиебез бүген җылы түшәгеннән кузгалмады. Хатыны Миңсылу күптән сыерын савып керде, мичен ягып уздырды, чәен хәзерләде, ә ул кулларын баш астына салып, йомылмас күзләрен түшәмгә текәп ята бирде. Аяусыз бер сорау аның миенә чөй булып кадалган иде: нишләргә? Әйе, нишләргә? Гарьлек һәм ачу тойгысы аңа бары бернәрсәне тукый: фермадан китәргә, бүгеннән калмый китәргә. Бары китеп кенә ул үзенең кешелек дәрәҗәсен саклаячак, «дошманнарына» горур бәйсезлеген күрсәтә алачак.

Чыннан да, туган атасыдай күреп йөргән иң якын кешесеннән дә шундый рәхимсез сүгү ишеткәч, китүдән башка аңа ни кала? Су ташучы Әпкәли түгел бит ул, ә

ике мең башка якын терлекләр өчен җавап бирүче кеше. Кемнең аны сүгә-сүгә, хурлый-хурлый эшләтергә хакы бар?

Ләкин... күпме генә ул үзен шушы уенда ныгытырга тырышмасын, күңеле төбендә «дөрес эшлим» дигән ышаныч туа алмый иде. Иң элек фермадан аерылуын күз алдына китерү белән аңа үзе дә, иярләшкән кешеләре дә, карап үстергән терлекләре дә гаять кызганыч булып китә. Ихтыярсыздан күңеле нечкәреп, җылыйсылары килә башлый. Бик газаплы була аңа шул чакта...

Аннан, акылының сәламәт бер ноктасы белән дигәндәй, мәсьәләнең җитдилеген аңлау һәм кешеләр алдында гына түгел, үз намусы алдында да җаваплылык тоюю аны кат-кат уйланырга мәҗбүр итә иде. Әгәр бүгеннән ферманы ташласа, мәсьәлә тирәнгә китәчәк, каш ясыйм дип күз чыгаруың да бар. Карт председательнең шундый ярсып, шундый көч белән: « Юк, син эшләрсең, синнән сораячакбыз!» — дип әйткән сүзләре әле дә булса аның колагы төбендә яңгырап торалар кебек...

Ләкин... хурлык бит, хурлык! Бар да сине сүксеннәр, бар да сине гаепләсеннәр! Бар да хаклы, тик син берүзең гаепле! Ничек бу болай? Бу каһәр суккан төенне чишеп ташлар өчен генә булса да фермадан китәргә кирәкмиме?

...Уйлый Нургалиебез, миләре авырткачы уйлый, ләкин һич кенә бер карарга килә алмый. Таш белән бастырып куйгандай ята да ята.

Ә Миңсылуның гомердә булмаган бу хәлгә саруы кайный булса кирәк, идәнгә каты-каты басып йөри һәм әледән-әле урын өстенә күз кырые белән усал гына карап куйгалый... Кичә Нургалинең Шәйхи абзыйны алырга киткән җиреннән, утка тыгып алгандай, кара көеп кайтуы, кайткач телен йоткандай, бер сүз сөйләшмәве аны артык гаҗәпләндермәде дә, борчымады да. «Шәйхи абзасы таза гына өшкереп җибәргәндер, ярар, таманга килер, тешлерәк булыр»,— диде ул эченнән һәм, гадәтенчә, бәйләнеп сорашып та тормады. Үзенчә, ул аңа «зиһенен җыяр» өчен вакыт бирергә теләде, шуңа күрә бүген дә озаграк ятуына сүз әйтмәде. Ләкин ир кешенең, һаман булса «зиһенен җыя» алмыйча, күзләре белән түшәм бораулап ятуы, ниһаять, аның ачуын китерә башлады.

Ахырда түзмәде, кырыс кына әйтеп узды:

— Бүген май бәйрәме түгел, эш көне, торсаң да ярый.

Нургали дәшмәде, хәтта селкенмәде дә, гүя аңа түгел, стенага әйттеләр. Миңсылуга бу җитә калды, карчыгадай бер әйләнде дә карават янына ук килеп басты:

— Тор әйдә, тор, тор, зимагур шикелле, өйнең ямен җибәреп ятма!

Нургали тонык тавыш белән бары:

— Бәйләнмәле! — дип кенә куйды.

Ләкин Миңсылу бәйләнү генә түгел, бөтенләй кыздырып алып китте:

— Оят дигән нәрсә кайда, ә? Бөтен кеше эштә, Шәйхи абзый караңгылы-яктылы атын җигеп узды, бригадирлар иртәнге чәйгә әйләнеп кайттылар, ә син әзер чәйгә тормыйча түр башында аунап ятасың. Әдәм страмы! Берәрсе килеп керсә, ни әйтерсең? Фермада кырык эшең кырылып ята, кешеләрең зарыгып көтә торгандыр... Тагын Закир ишеләр теленә керәсең киләмени? Әле җитмәдемени, аз булдымыни?..

Нургали тирән ачыну белән нидер әйтмәкче булды:

— Миңсылу, аңла...

Бер кызып киткән Миңсылуны хәзер алай өзгәләнеп әйтү белән генә туктатып булмый иде инде.

— Аңлыйсы да юк, сөйләп торасы да юк,— диде ул, кулын гына селтәп.— Тор да эшеңә кит, син эш кешесе...

— Мин эшкә чыкмыйм!..

— Чыкмыйсы-ың? — диде Миңсылу, чын-чыннан ачулы гаҗәпләнү белән сузып.— Ю-юк, җанкисәгем, чыгарсың! Мин сиңа коммунист башың белән рисвай булырга ирек бирмәм. Тотам да хәзер үк өстеңнән Дускаевка барам.

Һәм ул, кисәк кенә борылып, ишеккә үк китте. Нургали юрганын тибеп ташлады да урыныннан сикереп торды. Искиткеч ачуы кабарды аның, тешләрен шыкырдатып, кулларын йодрыклады һәм... чөйдәге киемнәренә ташланды. Бер мәлгә агарып ук киткән Миңсылу өстәл янына килеп чәй ясарга тотынды. Бераздан гади, сабыр гына:

— Кил, берәрне эчеп кит,— диде.

Нургали дәшмәде, ашык-пошык кына киенде дә, битен-күзен дә юып тормыйча, чыгып йөгерде.

Юл буенча ул ярсып, авыз эченнән нидер сөйләнеп барды. Хатыныннан да тынычлык юк, менә кая китте эшләр. Юк, булмый болай! Барысына да нокта куярга вакыт! Бүген үк партбюрога гариза язып бирәчәк ул. Яки, яки! Яки кешене сүгүдән, аның эшен юкка чыгарудан, аңа аяк чалудан туктыйсыз... яки инде, бигайбә, саубуллашырга рөхсәт итәсез! Әйдә, башка берәү эшләп карасын (Сөләймановның баҗасымы, кемнең дә булса каенагасымы — барыбер), башка берәү, бәлкем, ферманы сөт

күленә әйләндерер. Ә ул эшләмәдә түгел, эшләде, кырылып бетеп барган ферманы аякка бастырып бирде. Хәзер кадерне белмәсәгез дә, бер килеп исегезгә төшәр әле.

Шундый ярсу катыш әрнүле уйлар белән Нургали ферма капкасыннан килеп керде... Һәм, биш-ун минут та үтмәгәндер, ферма эше, ургылып аккан елга кебек, аны үз эченә бөтереп алып кереп тә китте.

Ә гариза ул көнне язылмады, икенче, өченче көнне дә язылмады ул... һәм беркайчан да язылласы юк иде аның. Чөнки Нургали өчен утырып гариза язуга караганда, тауга үгез күтәреп менгезү җиңелрәк иде...

...Һәм менә бер атна инде Нургалиебез, бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы тун изүен чишеп, бүреген куе чәчләре өстеннән артка этәреп, беркемгә тынычлык бирмичә, киң ферма ихатасының язгы пычрагын су үтмәс таза итекләре белән таптап йөри. Вакыты нинди бит әле! Көн дә өч-дүрт сарык бәрәнли, берәр сыер бозауламыйча калмый, дуңгызлар дистәләп бала китерә башладылар. Яшь үрчемгә урын җитми башлады, сарык, дуңгыз абзарлары бик тыгызланып китте, терлекләр арасында берәр чирнең кинәт калкып чыгу куркынычы туды. Җитмәсә, бөтен дөнья эреп, суга әйләнеп бара, абзар эчләре пычрак, юеш, кешеләр чистартып өлгермиләр... Тынгысыз яз тудырган һәм берьюлы килеп тыгылган һәртөрле эшләр өстенә терлекләрне ашату, карау да көннән-көн арта, катлаулана бара. Азык кытлыгы, ашыгыч чаралар күрүгә карамастан, муенга ташланган бау кебек, ферманы һаман әле буып тора. Кыскасы, эш муеннан, мәшәкать баштан ашкан!

Һәм Нургалигә шул кирәк тә иде. Яңадан аңарда искиткеч дәрт уянды. Яңадан ул бөтен Яуширмә халкына үзенең кем, нинди эшче булуын исбат итәсе килү теләге белән яна башлады. Бигрәк тә аның колхоз терлекчелеге алдында торган бурычларны Сөләймановтан бер дә ким аңламавын күрсәтәсе килә иде. Ферма бай булырга тиеш — точка! Ничек итеп, нинди юллар белән моңа ирешергә — вакыт кына бирегез, ул, Нургали, анысын да табар, күрсәтер...

Тик бер генә нәрсә хәзер аның күңелен борчып тора иде: ферма кешеләре белән аның арасы ничек булыр? Бик табигый буларак, ул сессиядән соң ферма кешеләренең, барысы булмаса да, билгеле бер өлеше миңа аркалары белән борылыр, буйсынудан чыгар, ә кайберәүләр, бәлкем, каршы коткы да алып барырлар дип уйлады. Һәм шундый хәл сизелә калса, аны шул минутта ук рәхимсез рәвештә тамырыннан йолкып атар өчен ул үзен

алдан ук көйләп тә куйды. Һәркемгә сынау күзе белән карый торган булды, эш кушса, старшиналарча кыска, коры итеп кушарга тырышты, аз гына сүз кайтарып маташучы булса, хәзер кабынып китәргә торды.

Ә ферма кешеләре Нургалинең шул хәлен әллә күрмичә, әллә күрсәләр дә юри игътибар итмичә, нәкъ элекке шикелле, үз эшләрен эшләп йөри бирәләр иде. Олы яшьтәге апайлар үзләрен элеккечә бик сабыр тоталар, «хуҗалары» әйткәнне сүзсез генә тыңлыйлар, эшләрен ашыкмыйча, ләкин җиренә җиткереп эшлиләр. Яшьләр исә, берни булмагандай, шаулыйлар, көләләр. «Нургали абый!» дип аның тирәсендә бөтерелеп йөриләр һәм ул ни кушса, шуны элеп алып, эшләп ташларга әзер торалар.

Менә әле алар, нәкъ өмәдәге шикелле, дәррәү тотынып бер көндә абзар түбәләреннән карларны көрәп төшерделәр, ишек төпләренә җыелган суларны агызыр өчен канаулар ердылар, өем-өем яткан пычрак кар, бозларны үгез җиккән чаналарга төяп, яр астына илтеп аудардылар. Икенче көнне барлык эре терлекләрне ихатага чыгарып каты себерке, ишкән салам белән кыш буена утырган пычрак-тузаннарыннан чистарттылар, кайбер арык сыерларның сыртларына оялаган украларын бармаклары белән сытып чыгардылар. Аннан абзарларның эчләрен тазартып, ишек-тәрәзәләрен ачып җилләттеләр. Терлекләрнең асларына түшәр өчен саламны, үзләре барып, якындагы эскерттән бау яки аркалык белән күтәреп алып кайттылар. (Фуражер Фәттахның кешеләре саламны азык өчен дә чак ташып өлгертәләр иде.)

...Бу көннәрдә ферма ихатасында нишләптер Сөембикә дә ешрак күренә башлады. Хәер, аның үзенә күрә сылтавы бар иде: фермага каршы аръякта гына аның яшелчә җирләре ята, менә ул өч-дүрт чана белән килеп ферма тиресен шунда ташыта иде...

Ләкин, ни хикмәттер, Сөембикә, үз чаналары янында булудан бигрәк, сыер савучылар, сарык, дуңгыз караучылар тирәсендә күбрәк чуала. Әле бер төркем, әле икенче төркем хатын-кыз уртасына басып, нидер сөйли, шикле кешедәй, як-ягына каранып ала, әледән-әле кара чәчен шәле астына сыпырып куя. Хатыннар, көрәк-сәнәкләренә таянып, аны дәшми генә тыңлап торалар... Инде Нургали килгәнен күреп калсалар, шунда ук таралышалар. Сөембикә, туп-туры Нургалигә каршы килеп, ләкин тукталмыйча, хәйләкәр генә елмаеп узып китә.

«Нишләп йөри бу хатын, Сөләймановлар сүзен сөйләп,коткы таратып йөрмиме?» — дип борчылып уйланды Нургали.

Ниһаять, аның Сөембикәгә ачуы килә башлады һәм беркөнне аны туктатып, кырыс кына сорап куйды:

— Нинди ул бетмәгән сүзең бар минем апайлар белән, ә?

— Бар инде...— диде Сөембикә, елмаюын кулы белән яшерергә тырышып.

— Юк, ачык әйт, лекция укыйсыңмы син аларга, әллә гайбәт сатасыңмы?

Сөембикә Нургалинең күзләренә җитез генә карап алды, елмаюы аның шунда ук сүнде.

— Курыкма, синең гайбәтеңне сатмыйм! — диде ул, башын чөеп, һәм китеп тә барды.

«Ачуландырдым киленне... их, җил баш мин!» — дип ихтыярсыз ачынып калды Нургали. Кешеләр белән адәм рәтле сөйләшә белмәвенә аның үз-үзенә чынлап ачуы килде. Бигрәк тә Сөембикәгә карата мондый дорфа булмаска кирәк иде. Үзе ул бригадир хатын, шуның өстенә партбюро әгъзасы. Нургалигә беркайчан да зарары тигәне юк... Эшсез буталып йөрми бит, ә хатын-кыз арасында нинди сүз булмас, аңа, ир кешегә, ни өчен вакланып торырга кирәк иде... Һәм бу сөйләшүдән Нургали йөрәгендә тагын бер шырпы утырып калды.

Ләкин бу сөйләшүнең аңа зур гына файдасы да тиде: кешеләр белән сөйләшкәндә инде ул кара бөркәнчеген ача төшеп, яктырак йөз, йомшаграк тел белән сөйләшә башлады.

...Беркөнне Нургали бозау караучы Саҗидә апаны янына чакыртып алды. Озак көттерми, башына яулык өстеннән бүрек кигән, иске бишмәт өстеннән күкрәкчәсез алъяпкыч бәйләгән чандыр гәүдәле, озынча ак чырайлы Саҗидә апа тавышсыз гына килеп керде һәм бусагадан узмыйча тукталды. Нургали аны күрү белән, кулын сузып:

— Әйдә, Саҗидә җиңги, якынрак уз,— диде.

Саҗидә апа идәнне пычратмаска теләп аяк астына карап алды да, бер-ике генә атлап, стена буендагы эскәмиягә утырды. Нургали сүзне аның үз хәл-әхвәлен сорашудан башлады:

— Йә, Саҗидә җиңги, эшләрең ничек?

— Нинди эш турында сорыйсың, Нургали? — диде Саҗидә апа, тыныч кына.

— Хәлең ничек, саулык, тормыш дип соравым.

— Шөкер әле, зарланыр урын юк кебек хәзергә...

— Икмәгең бармы?

— Бар әле.

— Яңага барып җитәрлекме?

— Җитсә кирәк.

— Алай, ярый,— диде Нургали, бармаклары белән өстәлне шакып.— Җитмәсә, әйтерсең, рәтләрбез!

— Рәхмәт яхшы сүзеңә, Нургали, иншалла мохтаҗ булмабыз.— Саҗидә апа җиңел генә сулап куйды.— Әдәм баласы үзе дә җаен таба, тик менә бичара хайван гына кеше кулына карап тора...

— Әдәм баласы үзенә генә түгел, әнә шул кулына карап торган хайваннар өчен дә җаен табарга тиеш! — диде Нургали, нигәдер тавышын күтәрә төшеп.

Саҗидә апа дәшмәде, бары яшьләнебрәк торган зур соры күзләрен җиң очы белән сөртеп алды.

— Борчылма, Саҗидә җиңги,— диде Нургали, һаман дәртләнә барып,— быел, авыррак булса да, кышны чыгып киләбез, ә алдагы ел өчен азык хәзерләү хәстәренә язга аяк басу белән үк керешербез! Бүтән болай тилмереп утыру булмас!

Шуны әйтергә кирәк: Нургали азык мәсьәләсен күңеленнән катгый рәвештә чишеп куйган иде. Азык булырга тиеш кенә түгел, хәтта, уйлана торгач, аның хыялында тау-тау өелеп ята иде инде. Ничек итеп ул бу муллыкка ирешер — анысы икенче мәсьәлә, ләкин булачак, бу кадәресе — бәхәссез, чөнки азыксыз ферма мөдире булуны ул хәзер күз алдына китерә алмый иде...

— Сине чакыруым шуның өчен, Саҗидә җиңги,—диде Нургали, ниһаять, төп мәсьәләгә күчеп,— без бозауларны карап үстерүдә кайбер яңалыклар кертергә булдык. Әйе. Моннан соң сөтле сыерлардан туган бозауларны аерым тәрбияләүгә күчәбез.

Саҗидә апа, Нургалинең бу сүзләрен бик кызыксынып тыңласа да, тагын дәшмичә калды, чөнки ул моның кебек «фәлән итәбез», «төгән итәбез» дип гомуми рәвештә әйтелгән сүзләргә җавап бирә белми иде. Күп ишетте ул болай сөйләшүләрне, ләкин үзе, яше узганга күрәме, өйрәнә алмады. Нургали, Саҗидә җиңгәсенең шул хәлен сизгәндәй, аз гына тынып торды да туп-туры әйтеп бирде:

— Син күптәнге тәҗрибәле карауччы, менә нәселле бозауларның барысын да сиңа җыеп бирәбез. Яхшы тәрбиялә, сөтне жәлләмә, гарык булганчы эчсеннәр!

Мондый көтелмәгән боерыктан, бигрәк тә сөт мәсьәләсендә бу хәтле юмартлык күрсәтүдән Саҗидә апа аптырый калды, югарыдан берәр кәгазь килдеме икән әллә, дип тә уйлап алды. Беравык Нургалигә, чынлап әйтәме бу дигән төсле, сынап карап торды да кыюсыз гына сорау бирде:

— Кем шулай нәселле бозауларны аерым карарга, сөтне жәлләмәскә куша соң?

Нургали кырт кисеп кенә «менә мин кушам» димәкче булган иде дә, үзе дә сизмәстән, эре генә:

— Фән куша! — дип куйды.

Саҗидә апага фәннең мондый юмарт булуы, билгеле, ошады. Фән бик хикмәтле нәрсә инде ул, күп серләрне ачып бирә белә, тик менә Саҗидә апа тирәсеннән ул, фән дигәнебез, ерактарак йөри шул. Яуширмә якларына фән ияләренең бер дә килеп чыкканнары юк, ә килеп чыксалар — Саҗидә апаның да сорашыр нәрсәсе табылыр иде. Әйтик, менә бозауларның эче китә башласа нишләргә — шул турыда аның бик беләсе килә. Ветсанитар Галләм абзыйдан сорасаң, ул да кулларын гына җәя. Имештер, бер дарумы, нәрсәдер салып әчеткән сөт файда итә икән дә, тик аның шул даруы юк, ди.

Шулай да Саҗидә апа үзе сынап караган бернәрсәне Нургалигә әйтергә булды:

— Бозауларга катык та килешә икән.

— Катык?!

— Әйе шул. Ике бозавымның эче китә башлаган иде. Нишлим икән болар белән дип йөргәндә исемә төште: ниндидер прашук салып әчеткән сөт килешә дип ишеткәнем бар иде, туктале, мин әйтәм, катык ничегрәк булыр икән, дим. Катыкны да бит сөттән оетабыз. Шуннан бер чүлмәк катык китереп, бозауларыма тугып бирдем. Яратып чүмерделәр, мескеннәрем! Бер эчердем, ике эчердем, Ходаның хикмәте, рәтләнделәр, эч китүләре бетте.

Нургали, шактый гаҗәпләнеп, бераз вакыт Саҗидә апага сүзсез генә карап торды... Саҗидә апаның ак йөзендә һаман шул юаш тыйнаклык... бер дә әллә ни уйлап тапкан кеше кыяфәте юк инде үзендә.

— Һем, алай-й,— диде Нургали, урындыгы өстендә кыймылдап.— Ә может катыктан булмагандыр ул эчләре төзәлү, мин әйтәм?

— Катыктан икән шул... Мин Хәдичә белән Мәстүрәгә әйткән идем, алар да биреп караганнар, төзәтә, ди.

— Карале, Саҗидә җиңги, нишләп син аны миңа әйтмичә йөрисең?

— Нәрсәсен әйтәсең...— Саҗидә апа, алъяпкыч итәген күтәреп, авызын сөртеп алды.

Җиңгинең бу ваемсызлыгы Нургалине хәтта бераз кыздырып та җибәрде.

— Үзең беләсең, Саҗидә җиңги, бозаулар арасында эч китү еш була торган нәрсә, әгәр синең катыгың килешә икән, без бит аны тәпән-тәпән оета алабыз. Шулай түгелме?

— Анысын үзең кара инде, Нургали, мин белгәнем-

не әйттем... Ярар, китим әле, бозауларым көтә торгандыр.

Ул урыныннан торды, алъяпкычын рәтләп, түшен сыпыргалап куйды. Нургали аның эштән озак аерылып торырга яратмаганын белә иде, шуңа күрә артык кыстамады.

— Шулай, Сәҗидә җиңги, мин әйткәнчә эшләрбез инде. Бозауларны җыеп Галләм абзый сиңа бирер... Ә бу катыгың өчен рәхмәт!

Сәҗидә апа кыюсыз гына елмайды:

— Рәхмәт әйтерлек нәрсәме соң!

— Ә как же... Ферма турында кайгырту бит бу!..

— Шунда эшләгәч, кайгыртмыйча ни... Бар да кайгырта.

Шулай диде дә Сәҗидә апа, Нургалине шактый гаҗәпкә калдырып, чыгып китте. Нургалинең гаҗәпләнеп калуы табигый иде, чөнки әлеге кешеләрем миннән йөзләрен борырлар дип, йөрәген борчып торган шик менә хәзер урынсыз булып чыкты. Хәер, бер Сәҗидә апа белән генә эш бетми бит әле, башкалар, бигрәк тә яшьләр ничегрәк соң?

...Икенче көнне Нургалине ферма ихатасында бер төркем сыер савучы кызлар урап алдылар. Барысы берьюлы шаулашып, алар:

— Әйдәле, Нургали абый, әйдәле! — дип, култыгыннан эләктереп, аны ферманың арткы киртәсе буена алып киттеләр.

Нургалинең:

— Нишлисез, кая илтәсез, наяннар? — диюенә каршы җавап бирмичә, көлешә-көлешә, җилтерәтеп илтәләр генә.

Ни булган бу кызларга, әллә киртә буенда хәзинә тапканнармы — барысының да йөзләре яна, күзләре яна, ә зифа буйлы җиңел сөякле Кәримә алдан очып кына бара, кечкенә кара итекләре, әйтерсең җиргә дә тими.

Киртә буена килеп җиттеләр, кызарып пешкән кызларыбыз тирән итеп бер суладылар, аннан араларыннан иң чаясы Җиһан кулын алга сузып күрсәтте:

— Нургали абый, менә бу җир күпме булыр?

— Ничек күпме булыр?

— Ничә гектар булыр, дим?

Киртә буеннан башланып киткән һәм, тарая барып, елганың тауга якынлашкан киңлегендә кызыл ярга җитеп беткән бер тигез тугайлык иде бу. Тау белән елга арасында яткан тар гына бер мәйдан булганлыктан, ул елын-ел да буш кала, һәм җәен анда ферма бозаулары гына йөри торган иде.

— Ике гектардан да ким булмас,— диде Нургали, бераз чамалап торып.— Ә нигә кирәк булды әле ул сезгә?

— Беләсеңме, Нургали абый,— диде Җиһан, башка берәү әйтеп өлгермәсен дигәндәй, ашыгып.— Без бу җиргә кабак утыртмакчы булабыз.

— Кемнәр ул сез?

— Менә без инде, сыер савучылар...

— Аңлап җитмим,— диде Нургали, иңбашын җыерып.— Нәрсә, колхоздан үзегезгә өстәмә җир алмакчы буласызмы?

Җиһан кулын селтәп куйды, ә озын буйлы Тәзкирә, хәтере калгандай, сузып әйтте:

— Юк ла инде... нишләп үзебез өчен булсын, ферма өчен.

— Ферма өчен?

— Әйе шул.

— Ә кем сезгә ферма өчен кабак утыртырга кушты?

— Берәү дә кушмады, без үзебез...

— Нәрсә үзегез?

Ниһаять, Кәримә уртага кереп сүзгә кушылды:

— Туктагыз әле, кызлар, мин генә әйтеп бирим, әйбәтләп кенә...

Бар да тынып калдылар, ә Кәримә йомшак, ягымлы тавышы белән гадәттәгечә каушабрак (шунлыктан, ахрысы, кызлар аны, сүзен бүлмичә, тыңларга өйрәнгәннәр иде) сөйләргә кереште:

— Менә нәрсә... Нургали абый. Без, сыер савучылар, үзара сөйләшеп, шушы буш яткан җиргә кабак утыртырга булдык. Җәй көне безнең буш вакытыбыз була, без кабакны карап үстерә алыр идек, су да яныбызда гына... Ә сыерларыбызга менә дигән өстәмә азык булыр иде.

— Димәк, үзегез карый торган сыерлар өчен үстермәкче буласыз?

— Әйе шул, сыерларыбыз өчен.

— Ә нигә кабак, бүтән нәрсә түгел, әйтик, чөгендер, кәбестә?

— Бу бит мал йөргән, тиресләнгән җир. Сөембикә апа әйтә: монда, ди, менә мондый кочак җитмәс кабаклар үсәр, ди... Ул безгә орлыгын да бирергә булды.

— Алай икән,— диде Нургали, мыегын сыпыргалап.— Ниятегез яхшы, кызлар, тик шулай да уйларга кирәк.

— Йә, нәрсәсен уйлап торасы тагын! — диде Җиһан, сабырсызланып.

— Ашыкма, аппагым!

Кызлар дәррәү генә көлешеп алдылар,чөнки Җиһан-

ның зур түгәрәк бите, көйгән сөт өстедәй, гаять кара тутлы иде. Хәер, кызыйның моңа хәтере калмады, вакыты андый түгел, аннан Нургали абыйсының юри көлеп әйтмәгәнен күреп тора бит ул... Ә Нургали, кызларның көлүенә ничек тә игътибар итмәскә тырышып, сүзен әйтергә ашыкты:

— Мине менә нәрсә шикләндерә: кабакны утыртуын утыртырсыз, ә карап үстерергә чыдамыгыз җитәрме? Бу бит үзегез теләп алган өстәмә эш, тора-бара кул селтәмәссезме дим?

Кызлар бертавыштан, кайсы үпкәләгәндәй булып, кайсы ихлас күңелдән ышандырырга тырышып, шауларга тотындылар:

— И-и инде, Нургали абый, кемгә санныйсың син безне?

— Чын. Бала-чага түгел лә без.

— Аллам сакласын, ташлар булгач, тотынмыйм да мин аңар.

— Үзегез бездән сөт сорыйсыз, ә үзегез...

Нургали кулларын күтәреп, бал кортларын кугандай, селки башлады:

— Йә, бетте, бетте, кызлар, сез дигәнчә булыр. Рәхәтләнеп үстерегез!

— Менә рәхмәт, Нургали абый!

Әйе, аның өчен бар ышаныч хәзер ферма кешеләрендә... Куанычлы хәл, ул алардан күпме генә шикләнеп йөрмәсен, ә алар әнә ничек аңа үз итеп карыйлар, ферма турында нинди кайгыртучанлык күрсәтәләр. Нидән икән бу?

...Һәм көтелмәгән кечкенә бер вакыйга Нургалинең күзен ачты.

Сарык караучы Һәдия Нургалигә яңадан эшкә алуын сорап килде. Укучы хәтерлидер, сессия булып узган көннең иртәгесендә Нургали Һәдияне, бер сарыгын үгездән сөздергән өчен, фермадан куган иде. Кызый елап идарәгә, Шәйхи абзыйга да барган икән, ләкин председатель аны орышып, кире Нургалигә җибәргән булса кирәк. Кыз моны үзе әйтеп ташлады.

Нургали аңардан:

— Йә, шуннан Шәйхи абзый сине кире алырга куштымы? — дип сорагач, кыз башын иеп шактый дәшми торды. Ләкин ул хәзер алдаша алмый иде инде. Ахырда, чак ишетелерлек итеп кенә:

— Юк, алай дип әйтмәде,— диде кызый.

— Ә нәрсә дип әйтте соң?

— Нургали абыеңның үзеннән сора дип әйтте...

Һәм кызый елап та җибәрде.

Нургали кызны җәлләде, ләкин юри коры булырга тырышып:

— Ярый алайса, бар, эшлә, тик моннан соң авызыңны ачып йөрмә,— дип озатты.

Бу кичә булды, ә бүген төшке чәйдән әйләнеп килгәч, ул, сарык караучылар янында булырга теләп (Һәдиягә дә бер күз төшереп аласы килә иде), туры ихатаның түренә, абзарлар янына узды. Сарыклар абзарының ишеге төбенә килеп җиткәндә генә эчке якта берничә хатын-кызның нидер сөйләшеп торуларын ишетеп алды. Ихтыярсыздан тукталды һәм, иелә биреп, яртылаш ачык ишекнең тупса ярыгыннан эчкәре карады. Нәкъ ишек турысында гына берничә сарык караучы кызлар һәм Кәримә, Һәдияне урап алганнар да, нәрсәдер турында аның белән сүз көрәштерәләр. Нургали бераз колак салып тормыйча булдыра алмады.

— Син каян ишеттең аны? — дип, кызларның берсе Һәдиядән каты гына сорап куйды.

— Каян ишеттең, каян ишеттең? — диде Һәдия, үчекләп.— Анысы сиңа нигә кирәк, беләсең килсә әнә урамга чык та сораш, бөтен авыл сөйли...

— Бөтен авыл сөйләмәс! — диде, кырт кисеп әлеге сорау бирүче кыз.— Сөйләсә, менә синең кебек, Нургали абыйны күрәлмаучылар гына сөйләр.

Һәдия, зәһәрләнеп, башын селкеп куйды:

— Һе, алай икән!

Кичә генә елап килгән кызның бүген шундый чаяланып китүе Нургалине чынлап гаҗәпләндерде.

— Ишетәсегез килсә, алайса әйтим,— диде Һәдия, кызларны юри үртәргә теләгәндәй кукраеп.— Сираҗи абый Дускаевның үз авызыннан ишеткән: Нургалинең көннәре санаулы, тиздән җыелыш ясап, аны фермадан алып ташлыйбыз, дигән...

Кәримә, үзенә һич хас булмаган рәвештә, нечкә тавышы белән кычкырып ук җибәрде:

— Ялган, ышанмагыз, ялган бу... Сөембикә апа килеп безгә сөйләп китте: Нургали абыйны фермадан алу турында сүз дә буласы юк, гайбәт ул, сез ышанмагыз ул гайбәткә, диде. Дускаев абый үзе шулай дип әйтергә кушкан лабаса!

Сарык караучылардан бер базык, таза, ирләрнекедәй калын тавышлы яшь хатын шунда ук Кәримәгә кушылды:

— Шулай булмыйни, Нургали абый кебек ферма өчен янып-көеп йөрүче кешене табасы бар әле.

— Ә сессия? Сессиядә хур иттеләр бит үзен.

— Һәдия! — диде Кәримә, ачынып.— Ничек телең бара шулай дип әйтергә? Сессиядә бит Нургали абыйны начар кеше дип әйтүче булмады, нигә ялган сөйлисең? Сөембикә апа әйтә, сессиядә сөйләнгән сүзләр барыгызга да тия, бер Нургали абый гына түгел, барыгыз да тырышып эшләргә тиешсез, ди. Әнә ничек бит ул!

Калганнар да шаулашып нидер әйтә башлаганнар иде, ләкин әлеге таза хатынның калын тавышы тагын барысының сүзен берьюлы басты:

— Нигә шуңа сүз әрәм итеп торасыз, кызлар! Һәдияне беләбез бит инде... Нургали абыена рәхмәт әйтәсе урында, фермага килеп керергә өлгермәс борын, аның яманатын сатарга тотынды. Мин болай уйлыйм, кызлар! Һәдиянең колагына нык кына киртеп куйыйк: әгәр сарыкларын әйбәтләп карыйсы урында, ялган таратып, ара бутап йөри икән, Нургали абыйдан үзебез сорап, фермадан кудырабыз! Шулай түгелме?

— Шулай! Шулай!

— Җитәр, безгә комачаулыйсы булмасын! — диешteләр кызлар, бертавыштан.

Һәдия агарып ук китте... Берьюлы мескенәеп, ишетелер-ишетелмәс нидер әйтеп акланырга тотынды. Ләкин Нургали артык тыңлап тормады, акрын гына чигенеп, абзар буйлап китеп барды.

Гаҗәеп бер дулкынлану аны биләп алды... Ялгыз булырга, тынычланырга кирәк иде аңа, һәм ул, кешеләр күзенә артык күренмәскә тырышып, ферманың арткы капкасыннан кырга ук чыгып китте. Җәен терлекләр салган тар сукмак белән, аяк астына карап кына, сөзәк тау башына күтәрелде.

Сукмак буенда кардан ычкынган былтыргы әрем, тәмлекәй сабаклары баш күтәреп маташалар. Менә тау битләрендә җир ачылуга иң беренче булып калка торган бүтәкә үләне черегән үләннәр астыннан чыгып килә... Әйе, бар да терелә, үләннәр дә... кеше дә! Дөреслек кояш нуры кебек икән ул, кояш нуры кебек күз алларын яктыртып җибәрә икән. Аһ, валлаһи! Дускаев аның яклаучысы булып чыкты! Сөембикә, кечкенә кара күзләре белән аңа хәйләкәр елмаеп караган Сөембикә, ферма кызлары тирәсендә аның кайгысын кайгыртып йөргән икән! Ә кызлар, кызлар! Рәхмәт төшкерләре, үзләренең саф, кешелекле йөрәкләре белән аның өчен, ферма өчен, эш өчен янып-көяләр икән! Ә ул, тиле, күпме кара сөремен коеп, алардан шикләнеп йөрде. Рәхәт... һәм оят! Рәхәт һәм оят!

Тау башына менеп җиткәч, Нургали башын артка ташлый биреп, дымлана төшкән күзләре белән авылы өстенә

беравык карап торды... Юеш түбәләр, күзге уйнаткандай кояштан чагылып-чагылып куйган кечкенә тәрәзәләр, озын колгаларда сыерчык оялары, бәрәңге бакчалары буйлап көрт астыннан чыгып килгән кара читәннәр, берәрсенең мунчасы тузгыткан зәңгәр төтен — никадәр таныш һәм җанга якын бу күренеш! Анда ферма, анда миләш артына яшеренгән аның өе, анда һәр тумыш көн тапталган сукмаклар, анда көн саен кабатлана торган өмет-куанычлар, яки эч пошу-борчылулар, анда, ниһаять, бер үк суны эчеп, бер үк һаваны сулап яшәүче, бер-берсеннән башка тора алмас һәм бер-берсенә тынычлык бирмәс кешеләр. ...Юк, анда янмыйча, борчылмыйча яшәү мөмкин түгел. Әнә урам уртасыннан өч кеше ашыкмыйча гына фермага таба килә: берсе, кулларын артка куйганы, Шәйхи абзый икән, аның ике ягында Дускаев белән Сөләйманов.

Нургали аптырап калды: каршыларына төшәргәме, юкмы? Әллә, кире борылып, абзарларга таба китәргәме? Бу бит качу булачак. Ояты ни тора?! Читен хәл. Алар алдында ул үзен ничек тотарга тиеш? Бигрәк тә Сөләйманов алдында... яшь егетнең күзләренә күтәрелеп карарга көче җитәрме?..

Саташулы төштән соң исен җыя алмагандай, ул, тегеләр килеп җиткәнче, бер урында тик басып тора бирде.

*1951—1952*

# САЗ ЧӘЧӘГЕ

...Былтыр көз булып үткән район партия конференциясендә делегатлар райкомның икенче секретаре Шакир Мостафинны «тәгәрәттеләр». Комиссия, кызыл ящикны ачып, бюллетеньнәрне санап карагач, Мостафинга «за» бирүчеләр илле дүрт кеше, ә каршылар ике йөз уналты кеше булып чыкты. Дөрес, башта ук инде Мостафинның төшеп калу ихтималы зур иде, ләкин бу кадәр җимерелеп төшү күпләр өчен чын мәгънәсендә сюрприз булды.

Бары тик бер кеше бу хәлгә артык гаҗәпләнмәде, ул да булса Мостафин үзе... «Тәгәрәячәген» ул сизеп торды һәм көтеп алды. Чыннан да, конференция барышында коммунистлар аңа бик җитди гаепләр ташладылар: халыктан аерылдың, халык кайгысыннан бигрәк, үз кайгыңны күбрәк кайгыртасың, кыскасы, обывательгә әйләнеп барасың, диделәр. Мондый гаепләүләрнең нәтиҗәсе бер — коммунистларның ышанычын югалту булырга тиеш иде. Куркыныч хәл иде бу җитәкче кеше өчен, ләкин... тау ишелә башласа, аны ничек туктатасың? Хәер, Мостафин акланып торуны кирәк тә тапмады. Күңеленнән ул барлык гаепләүләр белән килеште, тик соңгы нәтиҗәне көтте. Ниһаять, менә ул булды.

Башта Мостафинның күңелендә хурлану һәм оялу кебек нәрсә кыймылдап куйды, ләкин ул бу тойгыны тизрәк басарга тырышты. Ниндидер бер җансыз җитдилек белән катып калган йөзе, аз гына сагыш белән өртелеп, ялкау караган күзләре аның ничек тә салкын-тыныч булырга тырышуын күрсәтәләр иде. Кешеләр аңа туры карарга уңайсызландылар, ул үзе беркем белән бер авыз сүз сөйләшмәде... Конференция ябылгач та туптуры өенә кайтып китте.

Күп кенә еллардан бирле партия эшендә эшләп йөргән кеше ничек итеп бу хәлгә килеп җитте соң? Моның тарихы шактый гыйбрәтле, һәм аны сөйләп бирү зарарлы булмас дип уйлыйм.

# I

Мостафин моннан өч ел элек Байгузиннарның бердәнбер кызларына өйләнде. Бу аның икенче өйләнүе иде. Беренче хатыны Мәрьям белән ул биш кенә ел торып калды. Чирмешәндә торган чакларында (Мостафин анда да райком секретаре иде) Мәрьям, әниләре авылыннан машинада кайтып килешли, авариягә очрап, өч яшьлек кызы белән бергә һәлак булды. Аяз көнне яшен суккандай, кинәт башына төшкән бу фаҗигане Мостафин гаять авыр кичерде, бер ел буена хәсрәттән айный алмыйча йөрде. Ахырда, өлкә комитетыннан үзенең икенче бер районга күчерүләрен сорады — яңа җиргә күчкәч, хәсрәтем онытылмасмы, юньгә кереп булмасмы, дип уйлады ул... Өлкә комитеты аның соравын тыңлады һәм шушы Камышлыга райкомның икенче секретаре итеп күчерде.

Аның белән бер үк вакытта райкомның беренче секретаре булып Андрей Петрович Андреев килде. Андреев партия эшендә яңа кеше, моңарчы аның район җирендә эшләгәне юк иде. Шәһәр ВУЗларында политэкономия укытып йөргән укымышлы, интеллигент бер кеше иде ул.

Андреевның беренче секретарь булып килүе Мостафинда әллә нинди сәер генә каршылыклы хис кузгатты. Иң элек ул үзен кимсетелгәндәй хис итте. Ни өчен беренче секретарьлыкны аңа тапшырмадылар? Партия эшендә тәҗрибәсе бар, район шартларын яхшы белә, теоретик яктан да хәзерлексез түгел — заманында ике еллык өлкә партия мәктәбен бетереп кайткан иде. Чирмешәндә соңгы вакытта беренче секретарь булып начар эшләмәде бит. Ә менә Камышлыда ни өчендер укымышлы Андреевны артыграк күрделәр. Янәсе, Камышлы Чирмешәннән ике тапкыр зуррак, икмәкне күп бирә торган, ләкин шактый артка калган район, үзенә күрә промышленносте да бар (авыл хуҗалыгы машиналарының ремонт мастерскойлары,спирт, кирпеч заводлары, депо, зур элеватор, паровой тегермән, ит комбинаты һ.б.), интеллигенция дә монда күбрәк, шуның өстенә һәртөрле районара оешмалар да Камышлыда тупланган, кыскасы, эш зуррак та, катлаулырак та... Мондый район белән җитәкчелек итәр өчен бер тәҗрибә генә җитеп бетми, теориядән дә көчле булырга кирәк. Өлкә комитетының мәсьәләгә шулай каравын Мостафин, әлбәттә, аңлады. Ләкин ышанып тапшырган булсалар, ул үзен бу урында аклый алмас идемени? Менә шушы аның көченә бик үк

ышанып җитмәүне тою Мостафинның хәтерен калдырды, шактый кәефен бозды.

...Шул ук вакытта, беренче секретарьлар өстенә төшә торган гаять зур җаваплылыктан азат булу, икенче дәрәҗәдә торып, икенче чиратта җавап бирү аның өчен уңайрак та булып күренде. Әллә арыганлыктан, әллә башыннан кичкән авыр фаҗига тәэсиреннән ул соңгы вакытларда, ничектер, басыла төште, артык ватылмыйча, тынычрак җан белән эшләүне тансыклый башлады. Шуңа күрә әлеге хәтер калу-кимсенүләргә кул селтәп, анымоны уйламыйча, тизрәк эшкә тотынды. Ләкин эченнән генә ул үзен Андреевтан бәйсез тотарга, үзенчәрәк яшәп, үзе белгәнчәрәк эшләргә булды. Әйдә, укымышлы иптәш беренче теоретик булып утырсын, ә без практик кына булып йөрик, шунда да сер сынатмабыз әле, диде ул үзенә.

...Андреев семьясы белән райком күршесендәге беренче секретарьлар өчен махсус салынган һәм секретарьдан секретарьга күчә торган бер катлы таш йортка урнашты. Ә Мостафинга райбашкарма карамагындагы ике катлы агач йорттан зур гына бер бүлмә бирделәр. Ул артыгын сорамады да, хәзергә аның өчен кайтып кунар урын булса, шул җиткән иде. Мәрьям үлгәннән соң кайда тору, ничек тору кебек мәсьәләләргә аның исе китмәс булды. Хәер, ялгыз кешенең, керсә бар, чыкса юк дигәндәй, шул бер бүлмәсе дә көннәр буе буш, ятим тора иде.

Мостафин эшкә тотынды. Иртә-кич кабинетыннан чыкмыйча, ул райкомның агымдагы эшләре белән шөгыльләнде, райондагы җитәкче иптәшләр белән танышты-сөйләште, аннан колхозларга чыгып китте. Район зур, колхозлар күп, кайчак, ераграк китсә, икешәрөчәр көн дә йөреп кайта иде. Йөрергә ярата иде ул. Кышкы юлдан артлы чанада зур толыпка төренеп барган чакта тәмле генә черем итеп ала, уянгач, райкомның карт кучеры Галәви агайдан бу якларның үткәне, җир-сулары, авыллары турында сорашып бара. Авылга җиткәч, колхоз идарәсенең зур мичле, кечкенә тәрәзәле җылы бүлмәсендә, стена буйлап тар эскәмиягә, күпне белгән акыл иясләредәй, сүзсез-тыныч кына тезелешкән агайлар белән анысын-монысын сөйләшеп утыра. Аннан председательне ияртеп колхозның хуҗалыгы белән озак кына танышып йөри, бригадирлар, ат караучылар, фермада эшләүче хатын-кызлар, тимерчеләр, шорниклар, амбарларда орлык чистартучылар белән озаклап сөйләшә, кичен исә берәр утырыш та үткәрә. Бик төнгә калмаса, икенче авылга китеп бара, вакыт инде соң

булса, берәр хәллерәк агайга куна керә. (Ул председательләргә кермәскә тырыша торган иде.) Бик ярата иде ул тәмле аш исе таралган өйдә оекчан гына сәкегә менеп, җиңги кайнар шулпа сосып китергәнне көтеп, хуҗа белән дөнья хәлләре турында ашыкмыйча гына сөйләшеп утыруны...

... Бу чыгып йөрүләрдән Мостафин көч җыеп, рухланып кайта торган иде. Соңгы вакытларда ул бер дә ялгызлыкны күтәрә алмый башлаган иде. Районзәкнең үзендә никадәр генә эш күп булмасын, тәүлекнең билгеле бер вакыты буш кала. Менә шул чакта ул үзен кая куярга белми иде. Баштарак яңа урын, яңа кешеләр аңа ялгызлыкны болай авыр кичерергә ирек бирмәде. Ләкин көн үткән саен, ялгызлык үзен ныграк сиздерә башлады. Күп вакытта ул ятим, моңсу бүлмәсенә кайтырга теләмичә, кабинетында гына кунып кала торган булды. Аның хәлендәге, аның яшендәге кеше өчен бу бер дә килешми дә, ярамый да иде. Бу ятимлектән, бу ялгызлыктан һичшиксез котылырга кирәк иде. Ниһаять, Мәрьямен югалтканнан соң беренче тапкыр аның күңеленә «әллә өйләнергәме?» дигән уй килде. Чирмешәндә чакта ул өйләнү турында уйлый да алмады, үзен гомергә тол булып яшәргә хөкем ителгән кешедәй хис иткән иде. Ә менә яңа җирдә өйләнәсе килү аңарда кинәт котылгысыз бер теләк булып уянды. Гүя Мәрьям үзе аңа: «Азап чикмә, дустым, тап үзеңә яхшы бер хатын», — дип әйтеп тора иде. Табигать законының көчеме, семья тормышын сагынумы — ләкин ни генә булмасын — өйләнәсе килү теләге аны көннән-көн ныграк йота барды.

Менә шундый хәлдә, йөрәге белән инде кемнедер берәүне эзләп йөргән чакта, ул район саклык кассасында эшләүче Наҗия исемле кызны очратты. Яз башы, юллар буйлап гөрләвекләр йөгерә башлаган вакыт иде бу... Очратты, игътибар итте, ә берничә көннән соң җаен туры китереп сүз катты... һәм кызны чынлап ошатты. Барысыннан элек Наҗия туташ шәһәрчә нәфис кыз иде. Аннан үзен бик сөйкемле итеп тота белә иде. Күренә, бер бәрәңгедә генә үсмәгән бу кыз, авыр кара эш аны аркылыга җәймәгән. Бөтен килеш-килбәтеннән, торышкыланышыннан, шулай ук шактый фасонча киенгән өсбашыннан аның җитеш тормышта, оста кулда пешеп җитешкән кыз булуы әллә каян күзгә бәрелеп тора иде. Кем чибәре соң бу туташ?

Мостафин, әлбәттә, моны бик тиз белде. Наҗия туташ Идият Байгузин дигән кешенең бердәнбер кызы икән.

Ә Идият Байгузинның үзен Мостафин шактый яхшы ук белә иде инде. Ул «Районара йомырка базасының» директоры, партия члены, Камышлыда күптәннән үз йорты белән торучы кеше. Район халкы аның турында, йомырка серләрен бик белә, теләсә чеби генә түгел, зуррак җанварларны да басып чыгара, дип сөйлиләр иде. Билгеле, эшли белмәгән кеше унбиш елдан бер ояда гына утыра алмас иде. Район шартларында сирәк була торган хәл бу... Шул ук сүзләргә караганда, Идият абзый ашау-эчү белән мавыкмый икән, район җитәкчеләренең күзенә артык керергә тырышмый, имеш, ләкин райком йөкләмәләрен гадел үтәп бара, диләр. Мостафин, килгәч, үзе дә аның белән бер-ике тапкыр сөйләшеп утырган иде. Әйтергә кирәк, зарарсыз гына тәэсир калдырды ул аңарда:ялагайлану күрсәтмәде, каушау сиздермәде, гади, тыныч кына тотты үзен. Сүзне чамалап кына сөйли, күбрәк тыңларга ярата, гомумән, уяу, сак кеше булырга тиеш. Хәер, Идият абзыйның кыяфәте дә шундыйрак иде: бите өреп тутырган куык сыманрак түп-түгәрәк тә шоп-шома, һәм ул биткә карап беркайчан да аның эчендә ни барын сизә алмассың...

«Районара йомырка базасы» директоры үзе әнә шундый, ни яхшы, ни яман дигәндәй, уртача бер исем-дәрәҗә белән йөрсә, хатыны инде аның, Майпәрвәз ханым, райүзәктә зур дан белән файдалана иде. Мостафинның аны күргәне юк иде әле, ләкин аның турында күп кенә сүзләр ишетеп өлгерде. Гаять үткен, акыллы хатын, ди ул, искиткеч уңган, ди, гомере буе район җирендә генә торса да, көн итүнең тәртип-низамнарын кайбер шәһәр кешеләреннән дә шәбрәк белә, ди. Аш-суга бик оста икән, ә өен шундый чиста итеп тота, имеш, керсәң — әйләнеп чыгасың килмәс, ди.

Ничек кенә булмасын, Наҗиянең әти-әниләре ни җитте кешеләр генә түгел иде. «Байгузиннар» дип яхшы исәптә йөргән төпле һәм ныклы бер оя иде алар. Шуңа күрә Наҗиянең нәфис һәм сөйкемле бер туташ булуы да гаҗәп түгел иде.

Мостафин, күпме-азмы уйлаганнан соң, Байгузиннарны үзе өчен лаеклы кешеләр дип тапты. Район җирендә артыгын эзләп торасы да юк. Эш хәзер Наҗиянең үзендә иде. Мостафин, мәсьәләгә җитди караучы кеше буларак, кызга төрле яктан килеп карарга тырышты. Ләкин кай яктан гына килеп карамасын, аның күз алдында гел менә үзенә тартып сихри бер тере сын басып тора: дәшсәң аңа, матур башын кырынайта төшеп, җитез генә күз сирпеп ала ул, сүз кайтарганда нечкә кашларын уйнатып

куя, ал чәчәктәй иреннәре елмая башлаганда энҗе тешләре елтырап китә — менә шул инде Нәҗия! Калган якларын исә Мостафин акылы белән генә чамалый: әлбәттә, кыз, шундый булдыклы ана кулында үскәч, әдәпле дә, тәрбияле дә, уңган да, зирәк тә булырга тиеш. Заманнан да артта торып калмагандыр, чөнки әтисе коммунист кеше.

Кыскасы, шәп, лаек кандидатура!

Тик бернәрсә генә Мостафинның эчен кыра, ул да булса — яшь аермасы. Әйе, кыз яшь, бик яшь әле, күп булса унсигездә генә булыр. Ә Мостафин утыз сигезне тутырды инде. Дөрес, ул үзе дә төшеп калганнардан түгел; буй —мәһабәт, чәчләр чем-кара, йөз чиста, тик борын тирәсендә генә бераз шадра билгеләре бар: ләкин белә, шул шадра билгеләре булганга күрә дә, ул хатын-кызлар күзенә һәрвакытта сөйкемле күренә торган иде. Һәрхәлдә, ул нык сакланган ир әле, моны үзе үк сизеп тора. Әйе. Аннан әгәр Нәҗия аның яшеннән курыкмаса, шуның белән инде ул үзенең кеше таный белгән акыллы кыз икәнен күрсәтәчәк.

Хәзер кызның кылын тартып карарга кирәк иде. Ләкин Мостафин өчен бу бик читен эш. Исеме дә, дәрәҗәсе дә аңа япь-яшь кыз артыннан озын-озак ухаживать итеп йөрергә мөмкинлек бирми, шуңа күрә тиз һәм кыю хәрәкәт итәргә кирәк иде. Бигрәк тә кызның күз карашларыннан ул кыю булырга яраганлыгын сизенгән иде инде.

Ике тапкыр сөйләшү мәсьәләне хәл итте. Аның да берсе шаярып кына булды дияргә ярый. Шулай, көннәрдән беркөнне Мостафин, Нәҗия өенә кайткан чакта юлын туры китереп, аңа ияреп китте. Исәнләште, кыз куанып җавап кайтарды, ничектер аның йөзе Мостафинны күрүгә ачылып киткәндәй булды. Һич тарсынусыз, уйнак кәеф белән, алар телләренә ни килсә, шуны сөйләшеп бардылар. Шулчак Мостафин әйтеп куйды:

— Сезнең ухажерларыгыз күптер инде, Нәҗия?

Кыз, гадәтенчә, кара, тере күзләрен сирпеп алды.

— Нигә алай дисез, Шакир абый?

— Нигә дип, сез Камышлының бер чибәре, ә егетләр монда күп булса кирәк.

— Көлмәгез, Шакир абый,— дигән булды кыз.— Минем бер ухажерым да юк.

— Сез әйтерсез инде!

— Чын, чын. Мин малай-салайлар белән чуалырга яратмыйм.

Мостафин аңа җитди генә карап алды.

— Егетләрнең шәпләре, өлгереп җиткәннәре дә бардыр әле,— диде ул, аз гына дәшми барганнан соң.

Кызның да йөзе бер мәлгә уйчанланган кебек булды. Аннан уңайсызланыбрак:

— Белмим, очратканым юк,— диде.— Бездә бар да әллә нииндиләр... Үзләрен тота белмиләр.

Шуның белән бу турыда сүз бетте, нииндидер бүтән темага сөйләшеп киттеләр.

Ләкин соңыннан Мостафин шул ярым шаярып сөйләшүне еш кына исенә төшергәләде. Кызның сүзләрендә үзенә күрә бер мәгънә бар кебек тоелды аңа. Чыннан да, «Малай-салайлар белән чуалмыйм» дип нәрсә әйтергә теләде ул? Ихтимал, йөргән кешесе булмавын аңлатырга тырышкандыр. Ә аның «очратканым юк» диюен ничек аңларга? Бу — егетләр юк дип әйтүе түгелдер инде, күңелемә ошаган кеше туры килгәне юк әле дип әйтүедер. Моның шулай булуы бик мөмкин, чөнки үз дәрәҗәсен яхшы белгән чибәр кызның тиз генә үзенә лаек кешене таба алуы ансат эш түгел ул!

Ниһаять, Мостафин ныклы карарга килде: кыз белән чынлап сөйләшеп карарга, әгәр аңласа, әгәр күңелендә аңа, Мостафинга, карата чын хис уянган булса, кулын сорарга.

Шул ният белән ул язгы кичләрнең берсендә Нәҗияне үзенең кабинетына чакыртып алды. Уңайсызрак иде райком бинасы эчендә үзеңә генә кагылган үтә шәхси мәсьәлә турында сүз алып бару, ләкин, нишләмәк кирәк, аның башка мөмкинлеге юк иде.

...Кызны ул бик җылы каршы алды, күптәннән якын кешеседәй, кулыннан тотып, диванга утыртты, үзе, тынычланыр өчен бүлмәне бер-ике әйләнгәч, урындык алып, аның каршысына утырды. Беренче сүздән үк ул сөйләнәчәк мәсьәләнең бары икесенә генә кагылуын һәм бик җитди буласын аңлатты. Кызга ничектер берьюлы эссе булып китте, бит алмалары аның кызарып яна башлады.

Мостафин ашыкмыйча, никадәр ихлас күңелдән сөйләвен сиздереп торган акрын, йомшак тавыш белән Нәҗиягә үзенең үткән тормышын кыскача гына сөйләп бирде. Яраткан хатынының фаҗигале рәвештә һәлак булуын да, аны озак вакыт оныта алмыйча газаплануын да яшермичә ачык әйтте. Бары бирегә килгәч кенә, яңа эштә, яңа кешеләр арасында бераз нормаль хәлгә кайткан кебек булдым, диде. Аннан... менә ул Нәҗияне очратты һәм... яралы йөрәгенә аның йомшак канат тигән

кебек булды. Бу коры сүз генә түгел. Үзен сынап йөри торгач, күңелендә туган хиснең чын булуына ул, ниһаять, ышанды. Әлбәттә, андый олы хисне телдән әйтү генә җитми, аны исбат итә белергә дә кирәк. Сүз менә шул турыда барырга тиеш. Әйе. Ул ялгыз кеше, аңа өйләнергә кирәк. Яше дә, эше дә, положениесе дә аңардан шуны сорый. Дөрес, семья кору бик җитди мәсьәлә, җиде тапкыр үлчәп, бер тапкыр кисүне таләп итә ул. Ләкин күп уйланганнан соң, яратуының чын булуына тәмам ышангач, ахырда менә бүген ныклы карарга килде: ул Нәҗиягә өйләнергә тели, акылы белән генә түгел, йөрәге белән тели, бәхетле булуларына ышанып тели.

Мостафин аз гына тынып торды, аннан:

— Менә шул, Нәҗия! — диде, кыска гына сулап.— Инде синнән ишетәсем килә. Ни уйлыйсың син? Йөрәгең ни әйтә? Ышанасыңмы миңа, ышанасыңмы бәхетле булуыңа?

Әйтәсе дә юк, Мостафинның сүзләре Нәҗиягә гаять көчле тәэсир итте. Бөтен тәнендә аның вак калтырау йөри, үзе уттай яна, ә йөрәге учтагы кошчыктай дерелдәп тора иде. Һәртөрле уйлый алу сәләтен югалткан иде ул. Томан эчендә йөзгән башын түбән салындырып, тел тибрәтергә куркып, ул дәшми утыра иде. Мостафин ахырда борчыла башлады.

— Йә, Нәҗия, ник дәшмисең? — диде ул, кызның калтыранган тезләренә йомшак кына орынып.

Бераз көткәннән соң, тагын кабатлады:

— Син бер генә сүз әйт: ризамы, түгелме?

Ниһаять, кыз, тагы да иелә төшеп акрын гына пышылдады:

— Әтиләр белән сөйләшегез.

— Ә син үзең?

Кыз дәшмәде. Мостафин көрсенеп куйды.

— Нәҗия, эш синең үзеңнән тора бит. Синең теләгеңне белмичә торып, мин ничек әтиләреңә барыйм?

Җавап юк. Мостафин аптырагач, кызның йөзен күрергә теләп, аңа якын ук иелде:

— Йә, Нәҗия, әйт бер генә сүз, ризамы?

Нәҗия кинәт Мостафинның алдына капланды.

...Байгузиннар Мостафин турында тулы хәбәрдар иделәр. Тиешле мәгълүматлар алар кулында бар иде инде. Һәм райком секретареның киләсен, ни өчен киләсен белеп, көтеп торалар иде.

## II

Майпәрвәз ханым еш кына:

— Ирне көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын! — дип әйтергә ярата торган иде. Бик ышана иде ул моның шулай булуына һәм, исбат итәсе килсә, үз тормышын мисал итеп китерә иде. Идият абзаң кем булган да, ул, Майпәрвәз, аны кем иткән? Чын булса (үзе сөйләгәч чындыр инде), Идият абзый нэп заманында волостьта милиционер булып йөргән, ди. Йорт-җире түгел, аның каккан казыгы да булмаган, ди. Ә Майпәрвәз үзе өяз шәһәрендә зур гына байның кызы булып, кече яшьтән әнисеннән калган, унөч-ундүрткә җиткәндә әтисе дә үлеп киткән. Шуннан аны зур базарлы авылда тире-яры белән кәсеп итеп торучы Шәяхмәт дигән абзасы (әнисенең агасы) үзенә «тәрбиягә» алган. Ләкин бу тиречe гаять саран, кансыз бер кеше булып, Майпәрвәзгә бер дә көн күрсәтмәгән. Шулай итеп, Майпәрвәз байлыкның да читен генә булса да күреп калган, азмы-күпме рәхәт тормышны да татыган, үксезлекнең ачы күз яшен дә эчкән, кеше ипиенең никадәр әче булуын да белгән.

Абзасының каты кулыннан ничек ычкынырга белмичә тыпырчынып яшәгән чагында, ул милиционер Идияткә тап булган. Күп уйлап тормыйча, тоткан да шуңа ябышып чыккан. Моның белән ул берьюлы ике куянны атарга теләгән: бердән, налог түләмәгән сатучыларның мал-мөлкәтләрен өйләреннән төяп китүче милиционерга чыгып, абзасын гел өркетеп тормакчы, икенчедән, заманның кая таба баруын сизеп, «власть кешесе» кулында сакланып калмакчы булган. Майпәрвәз туташ, билгеле, чалышайган үкчәле каткан итек киеп, үзенә исе китеп йөргән Идиятне яратмаган да, яратырга тырышып та карамаган. Аңа бары Идиятнең җилкәсе кирәк булган. Шул җилкәгә атланып алгач, Майпәрвәз тезгенне тота белгән инде. Бәхетеннән, Идиятебез тезгенне тиз сизә торган шактый йомшак башлы мәхлук булып чыккан.

Озак та үтми, Майпәрвәзнең абзаларын Себергә озатканнар. Авылда байлар беткән, аларның мал-мөлкәтләре колхозга күчкән, милиционерның да эше үзгәргән: хәзер инде аңа байлар йортыннан җиһаз төяп чыгу урынына, ярыкларга поскан дошманнар белән көрәшергә туры килә башлаган. Шул чакта Майпәрвәз аңа әйткән:

— Йә, җитәр, каешыңны сал, фуражкаңны ыргыт. Кеше булырга вакыт сиңа,— дигән.

— Моны ничек аңларга? — дип сораган Идият, күзләрен йомгалап.

— Монымы? Малайлыктан чыктың, балигъ булдың дип аңларга кирәк,— дигән Майпәрвәз, әче елмаеп.— Тормыш көтә башларга вакыт. Җалуньяң тәмәкедән артмый, ә мин сиңа наган сабы кимереп ятарга килмәдем.

Бу катгый сүзләрдән Идиятебез каушап ук төшкән.

— Нишлим соң мин? — дигән ул, тәмам аптырап.

— Әнә дәүләткә тире, йон, йомырка җыючы агент булып кер. Күрәсеңме, агентлар балда-майда йөзәләр!

— Мин ул эшне белмим бит.

— Син белмәсәң, мин беләм. Үзем өйрәтермен,— дигән Майпәрвәз, кырт кисеп.

Һәм Идиятен агент иткән, күкәйне танырга, тирене сортлый белергә өйрәткән.

Хәзер карагыз инде: Идият абзый утыз елдан бирле йомырка белгече исеме белән төпле, дәрәҗәле бер кеше булып яшәп килә. Кайчандыр милиционер булып йөрүенә хәзер үзе дә ышанмый. Чибәр генә йорты, әйбәт кенә көйләп җибәргән хуҗалыгы: сыеры, чучкасы, бакчасы, умарталары, кош-кортлары бар һәм... Майпәрвәз ханым чыннан да балда-майда йөзә.

Әйе, ул хаклы: ирне көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын! Ләкин «көлдерү» белән «бөлдерүнең» күп кенә нечкә серләре бар. Менә шул серләрне аның Наҗиягә ык кына төшендереп каласы килә иде. Кияү буласы кеше дә башка бит: милиционер түгел, ә райком секретаре! Биредә инде «көлдерер» өчен эт булып өрергә ярамый, ә кош булып сайрый белергә кирәк.

Наҗияне бирергә вәгъдәләшкән көннән алып, Майпәрвәз ханым ир дигән бәндәне ничек итеп сихерләүнең серләрен кызының колагына тукырга тотынды.

— Беренче кичтән үк ирне үзеңә ефәк җепләр белән бәйли белергә кирәк,— ди иде ул, пышылдап кына.— Әйе, әйе, кызым, юкка чыраеңны сытма! Тора башлагач, үзең үк аңларсың. Күпме генә анда: хатын-кызлар ирләр өчен тормыш иптәше, киңәшче, фәлән-фәсмәтән, дип сөйләмәсеннәр, иргә иң элек хатын кирәк. Хатын булып үзеңне яраттыра алсаң гына, Шакирыңны кулыңда тота алырсың.

Тәннәре кымырҗып киткән Наҗия елардай булып:— Җитәр, әни,— ди.

Майпәрвәз ханым ачынуыннан хәтта башын калтыратып ала:

— Тиле, синең бәхетең өчен сөйлим мин... Мин өйрәтмичә, кем өйрәтсен сине!

Һәм Наҗия, уттай янган битен ике кулы белән кыскан килеш, әнисенең бернинди оят киртәсенә сыймаган

киңәшләрен тыңларга мәҗбүр. Ходаем, ирне ефәк җепләр белән үзеңә бәйләү нинди хәйләкәр, читен эш икән ул! Син аңа назлы да бул, киреләнә дә бел, сыланып та торма, салкын да булма. Син аңа буйсын, әмма үз теләгәнеңне эшләтә дә бел. Аны тыңла, үз сүзеңне үткәр. Син аңа мәхәббәттә юмарт булсаң, ул синең күңелеңне табуда юмарт булыр. Киен, ясан, бизән, чибәр бул, чиста бул, пөхтә бул, шул чакта син ireңә гел тансык булып торырсың. Ара-тирә көнләштерә дә бел, бик үсенеп китмәсен ул, куркыбрак та торсын. Менә шунда инде син аны кечкенә кулларыңа йомарлап алырсың. Песи кебек мырлап кына йөрер ул синең тирәңдә, җаның ни теләсә, шуны табып китерер.

Нәҗияне иргә чыгу куркытмый иде. Иргә чыгарга кирәклеген, хәтта үзе табып чыгарга тиешлеген ул белә иде. Бөтен киләчәге аның иргә чыгуга бәйләнгән иде. Бәхетне аңа ир китерергә тиеш. Бу әнисе тарафыннан күптән әйтелеп килгән һәм үзе дә яхшы аңлап торган хакыйкать иде. Ләкин ир белән торуның бу кадәр мәкерле исәпләргә корылган нәрсә булуын ул моңарчы, әлбәттә, күңеленә дә китергәне юк иде. Кайда соң мәхәббәт? Ул бит иргә чыгу бары мәхәббәт аркасында гына була дип уйлый иде. Шакир мине ярата, мин аны яратам, шуңа күрә без өйләнешәбез, дип йөри иде. Ә менә әнисе әйтә, мәхәббәт тә искерә, туза торган нәрсә, ди, бигрәк тә ул ирләрдә тиз искерүчән була, ди, иргә ышанмаска, гел уяу булып торырга кирәк, ди. Бөтен хикмәт, имеш, үзеңне яраттыра белүдә...

Шулай да Нәҗия әнисенең ир белән торуны бу кадәр ямьсез, шәрә итеп сөйләвенә, ниһаять, түзмәде — калтыранып елап җибәрде. Күпме генә әнисенә ышанмасын, һәр сүзен тыңлап өйрәнгән булмасын, бу юлы саф кыз йөрәге аның хурланмыйча һәм чирканмыйча кала алмады. Майпәрвәз ханым, билгеле, кызының бу күз яшьләрен һәр кыз балада иргә чыгар алдыннан була торган бер күңел нечкәрүе генә дип аңлады. Үзенең дә күз читенә килгән бер бөртек яшен бармак очы белән селтәп ташлады да, кызын, аркасыннан сөеп, юаткан булды:

— Елама, кызым, елама. Син бик бәхетлесең, бик вакытлы чакта үзеңә нинди әйбәт кеше табылды.

Хәер, кызын юатыр өчен ул шулай дип әйтсә дә, күңеле аның бик үк тыныч түгел иде. Булачак кияүнең райком секретаре булуы аны, юк-юк та, борчылып уйланырга мәҗбүр итә иде: бер дә язганнан узмый торган артык тәкъва, артык коры кеше булып чыкмасмы? Аның бит бердәнбер кызын дәрәҗәле, исемле, әмма шуның белән

бергә тормыш көтүнең рәтен-җаен белгән кешегә бирәсе килә иде. Мостафинның дәрәҗәсе дә, исеме дә бар (шуңа күрә алар аны ычкындырмадылар), тик менә Нәҗияне бәхетле итәрлек җитеш, матур тормыш корып җибәрә алырмы? «Ихтимал, аңа, Майпәрвәз ханымга, кияүне «чын семья кешесе» итәр өчен күп көч салырга, зур осталык күрсәтергә туры килер. Ярый әле Мостафин хатын күргән ир, яше белән дә Нәҗиядән шактый өлкән кеше. Андый кеше яшь хатынга чат ябышучан була ул. Әгәр Нәҗия, акылы җитеп, үзен әнисе өйрәткәнчә тотса, райком секретаре да, кулга ияләшкән аю кебек, алар көенә бии башлар.

Мостафин, Байгузиннардан ризалыкны алгач та, Нәҗия белән язылышып тора башлауны ашыктырды. Шуның белән бергә ул эшенең күплеген, бередә яңа кеше булуын әйтеп, зурдан купмыйча, артык шау-шу чыгармыйча туйсыз гына өйләнүне сорады. Аны тыңларга мәҗбүр булдылар. Дөрес, Майпәрвәз ханымның исәбе бөтенләй башкача иде, бердәнбер кызын ул, әлбәттә, бик зурлап, шаулатып, туйлап бирергә хыялланып йөри иде. Әйдә, дус-дошманның эче бер янсын: Нәҗиясен ул кемгә бирә дә ничек итеп бирә! Ләкин... райком секретаре белән эш иткәч нишлисең — эченнән тынып калырга мәҗбүр булды.

Шулай да бу мыштым гына өйләнү Мостафин өчен туйлап өйләнүдән бер дә ким булып чыкмады. Язылышкан көннән башлап ул Байгузиннарның кадерле кияүләренә әверелде. Кадерле кияү! — бу инде, иптәш, кеше ихтыярыннан тыш объектив яши торган факт, ә философлар, факттан качып котылып булмый, диләр.

...Иң элек, язылышканнан соң, Нәҗия бер-ике атна әниләреннән китмичә торды: янәсе, Майпәрвәз ханым өчен бердәнбер йөрәк парәсен кинәт кенә ят кулларга биреп җибәрүе бик «авыр» иде. Мостафин, билгеле, ана күңелен кызганырга тиеш иде, һәм бик тарсынып булса да, ул «кәләш куенына» әбисенең түрендә керергә мәҗбүр булды. Шулай итеп, аңа ихтыярсыздан кияүләп ятарга, чын мәгънәсендә «ширбәтле ай» кичерергә туры килде. Әбисе белән бабасы аны өрмәгән урынга утыртмадылар, ике атна буена, гүя зур туйга хәзерләнгән сый-хөрмәтне берүзенә ашатып бетерергә теләгәндәй, гарык иткәнче сыйладылар... Ә Нәҗия үзе? Күпме ләззәтле минутлар бүләк итмәде ул аңа! Башта, болан баласыдай, эчке калтырану белән курка-курка гына кулга бирелгән нәфис, сылу Нәҗия тиз арада аңа шулкадәр ияләшеп китте, әйтерсең аның сулышына әверелде... Яшь, оялчан

мәхәббәтнең Мостафинга исерткеч тәэсире шундый булды ки, авыр югалтудан калган йөрәк ярасы да аның бик тиз төзәлде, моңарчы күз алдында торган Мәрьям үзе дә, томан эчендә эрегәндәй, эзсез югалды.

Әмма шулай да Мостафинның күңеле бик үк тыныч түгел иде. Шул сый-хөрмәт, шул ләззәт-бәхет эчендә ул һаман нидәндер уңайсызлана, үзен, ничектер, икегә бүленгән кеше сыман хис итә иде. Чыннан да, көндезен ул райком секретаре һәм, райком секретаре буларак, дөньясын онытып, башы белән эшкә чума. Ә кичләрен (утырышлар булган көнне хәтта төн урталарында да) Байгузиннарның бәйрәмчә җыештырылган өендә, нәкъ борынгы җеп мыеклы кияүләр төсле, яшь кәләш белән түрдә янәшә утырып сыйлана, аннан... махсус хәзерләнгән бүлмәгә кереп бикләнә. Әллә ничек ят, сәер, кыен иде бу... Вакыт-вакыт аның бабасына кызын бу кадәр искечә кыландырып бирүе өчен ачуы да килгәләп куйды.

Ә Майпәрвәз ханым астыртын гына һаман үзенчә эшли бирде. Көннәрдән беркөнне ул ил өстендә балаларга исем кушып, мәет юып йөрүче бер картны урамнан борып алып керде дә, кухня якта табуреткага гына утыртып, кызы белән киявенә никах укытып алды. Ярый, өйдә берәү дә юк чак иде, моны «этем дә» күрмәде... Майпәрвәз ханым сәдака биргәндә егерме биш сумлыкны йомарлаган кулын бабайның борынына ук китереп терәде.

— Кара аны, әгәр берәр җирдә авызыңнан ычкындырасы булсаң,— диде ул, ысылдап,— рәхим көтмә, Камышлыдан гына түгел, районнан кудырырмын үзеңне, белеп тор!

Бабай кат-кат тәүбәсен әйтте дә, яктыдан качкан яркаnattай, тиз үк гаип тә булды.

Бу хәлне Мостафин түгел, Идият абзый да, хәтта Наҗия дә белмәделәр.

Ниһаять, «ширбәтле ай» узды шикелле. Ике атна кияүләп йөргәннән соң, Мостафин Наҗиясен үзенә алып кайтты. Туйлап килен төшерү булмаса да, Наҗия артыннан әллә никадәр урын-җир нәрсәсе, өй җиһазы ияреп килде. Мостафин аптырый калды: ай-һай, бабайлар бердәнбер кызларын әзерләгәннәр икән! Җиз таз белән җиз комганнан кала бөтенесе бар: ак шарлы никель карават, яңа комод, көзгеле шифоньер, алты данә таза урындык, тимерле сандык, стенага эләргә кыйммәтле келәм, кызыл ефәк белән тышлап сырган зур юрган, бер йомшак одеял, ярты дюжина урын җәймәсе, өчәр кат батист

мендәр тышлары, берничә яхшы эскәтер, тюльдән челтәр тәрәзә пәрдәләре, дистәләп сөлге, бер табынлык салфетка, ак самовар, бик матур чәй сервизы, тутыкмас корычтан чәнечке-пычаклар, аш тәлинкәләре, төрле савыт-сабалар... Ә Нәҗиянең өс-баш әйберсе тагын күпме? Бары затлы материядән язгы-көзге, кышкы пальтолар, әллә ничә төрле аяк киеме, ефәктән дә йоннан дистәләп күлмәк, аннан калганнарын әйткән дә юк. Кыскасы, Мостафинга бер биш ел хатын өчен акча чыгармаска була!

Шуның өстенә әле кияүнең үзен дә буш итмәделәр: күп түгел, әмма шулай да кыз бүләге итеп аңа яхшы хром итек белән күк бостон костюм бирделәр. Мостафин тәмам хәйран калып:

— Бусы тагын ни өчен? — дигәч, юмарт «әби»күрсенгән булып:

— Гаеп итмәгез, Шакир, нишлисең, ата-бабадан калган йола! — диде.

Мостафин кулын гына селекте: йолага каршы ни әйтәсең, әйдә, үзләренчә кыландырган булсыннар инде! Хәер, йола дигәннәре алай бик начар нәрсә түгел икән ул. Әнә Нәҗия артыннан килгән әйбер-җиһаз аның буш яткан зур бүлмәсенә никадәр ямь кертеп җибәрде. Кайтып керсәң рәхәт, чыгып китсәң күңелле. Дөрес, элек ул әйберләргә игътибарсыз карый иде, чөнки, иң кирәк нәрсәләрдән һәм чамалы гына кием-салымнан башка аның мондый байлык күргәне юк иде. Мәрьяме дә аның болай йөк өеме придан белән килә алмады. Гади колхозчы кызының аңа килгәндә ике-өч күлмәге дә бер кышкы пальтосы гына бар иде. Бергә яшәгән биш ел гомернең өчесен ул укып үткәрде. Инде икәүләп эшләп, мамыклана башлагач кына... әнә ничек булып китте. Язмышлар!

...Шулай итеп, Мостафин яшь хатын белән тора башлады. Тормыш үзенең көндәлек эзенә төшкән кебек булды. Ләкин бу кияү сыйлаудан туя белмәгән «әбинең» йоласы искиткеч юмарт булып чыкты. Хәзер инде алар — «яшь» кияү, яңа киткән кыз — атна саен парлап күрешә барырга тиешләр иде. Мостафинның атнага бер килгән буш киче — шимбә кич — әнә шул мәҗбүриятне үтәүгә китә торган булды.

Әйе, кеше нәрсәгә генә ияләшми! Азап-михнәткә ияләшү кыен булса да, рәхәткә ияләшүе, һичшиксез, ансатрак ич... Мостафин өчен дә бу шулайрак булырга тиеш иде. Дөрес, беренче кушылып киткән чакларда ул Байгузиннарның үзләрен дә, тормышларын да шактый ятсынган иде, ләкин тора-бара, үзе дә сизмәстән, күнегә башлады. Чыннан да,

дип уйлады ул, нәрсәсе аларның яман, ни өчен аларны ят күрергә? Җитеш, әйбәт торулары өченме? Ләкин бит кешеләрне аның өчен генә ят күрү һич дөрес булмаячак. Күптәннән алар бергә төпләнеп торалар, ныгып өлгергәннәр, үзләре дә бер кызлары гына, шуның өстенә гаять уңган, булдыклы кешеләр, димәк, җитеш торуларына бер дә ис китәргә ярамый... Инде аны, кияү итеп, артык хөрмәтлиләр икән, моның өчен дә аларны гаепләп булмый. Бердәнбер кызларын биргән ата-аналар кияү өчен һәрвакытта шулай җан атып торучан булалар... Аның каравы, алар, исемле, дәрәҗәле кияү дип, аның чабуына ябышырга тормыйлар. Идият абзый хәтта Мостафинның үзләренә кияү булуын авыз ачып беркемгә әйткәне дә юк.

Мостафин өчен тагын шунысы яхшы иде: Байгузиннар халык белән артык аралашмыйлар, кунак-төшем белән мавыкмыйлар, һәрвакыт аларда аулак, тыныч була — шуңа күрә ул барган саен рәхәтләнеп, җәелеп утыра иде.

Гадәт буенча, баргач та иң элек мунча, мунчадан соң аш, чәй... «Әбинең» уңганлыгына шаккатарсың. Мунчасын бусагасыннан алып ләүкәсенә кадәр сап-сары итеп юган, алгы яктагы киң эскәмиягә ак киндерен җәйгән, идәненә тар юллыгын салган, мунча тәрәзәсенә ак пәрдәсен корган... Хәтта ләүкәгә куйган себеркесе дә аның гади себерке түгел, ә мәтрүшкә кыстырып бәйләнгән себерке —хуш исләр аңкып тора.

Мунчадан кайткач кияүне түргә, зур фикус гөле ышыгына утырталар, кулына чиккән башлы сөлге бирәләр. Шунда ук Майпәрвәз ханым графин белән бал китереп өстәлгә куя. Идият абзый, аз гына сабыр итеп, балны ашыкмыйча гына стаканга коя да Мостафинга суза:

— Яле, кияү, рәхим итегез!

Мунча кереп чыккан саен бу бал килмичә калмый. «Әби» әйтә: «Балдан да шифалы нәрсә юк, бигрәк тә мунча артыннан килешә, бөтен әгъзаларга хәл кертә»,— ди. Чынлап та шулай икән: үзе салкын, үзе борычлы ширбәттәй; эчкәндә юаш кына кебек сизелсә дә, торабара астыртын куәте бармак очларына кадәр килеп җитә.

Менә Майпәрвәз ханым таш миски белән аш күтәреп керә, аның артыннан Наҗия дә ияреп чыга. Ул тиз генә табын өстенә япкан киҗеле ашъяулыкны ача, әнисе мискиен өстәлгә куя. Наҗиягә кияве янына кереп утырырга кушалар, ләкин ул, әтисе каршына утырмас өченме, түргә кермичә, әнисе янына урнаша... Аның әле чәчләре дә кибеп өлгермәгән, ике бите уттай яна, күз төпләре сөрмәләнеп уелган, ә тыгыз, сылу гәүдәсеннән дымлы

хуш ис (әллә теге каен seberkesenең мәтрүшкә исе) аңкып тора. Мостафин ихтыярсыз эченнән генә көлеп, уйлап ала: «Каракның бүреге янамыни! Үзенчә әтисеннән ояла инде, ә менә әнисеннән бер дә тарсынмый, әйтерсең серләре береккән ике ахирәт!»

Ни хикмәттер, кайбер хатыннар, кызларын биргәч олыгаясы, тыйнакланасы урында, яшьрәк күренергә, көязрәк булырга тырышалар. Кара инде бу «әбигә!» Ак батист яулыгын кара кашлары өстеннән генә артка кайтарып бәйләгән, якасы ачык, кыска җиңле тар күлмәк киеп, җыерчыклы муенына вак мәрҗәннән кечкенә муенса таккан, симез беләгенә кара көмеш беләзек кигән. Шешенке битенә әллә кершән ягып, иннек салган инде, бит урталары алсуланып яна, ә кечкенә йомшак ияге, гел тирләүчән борыны, капчыклана төшкән күз төпләре агарып тора. Мостафин барында аның йөзеннән һич елмаю китми, елмаеп дәшә ул, елмаеп карый, елмаеп кына йөри. Иренә йомыш кушса да елмаеп кына куша, хәтта шелтәләсә дә (ә ул Идият абзыйны әледән-әле шелтәләп кенә тора) елмаеп шелтәли. Тик ул чакта аның елмаюы ыржаюга охшап китә.

Майпәрвәз ханым нечкә генә итеп киселгән ак токмачны тәлинкәгә соса, аш өстеннән куе өресен җыеп сала һәм Мостафинга суза.

— Рәхим итегез әле! — ди ул, назлы тавыш белән.— Ашымны яратырсызмы икән, токмачым куера төште.

Ни өчендер ул һәрвакыт ашының берәр кимчелеген табарга ярата, ә ашлары аның — шулпасы дисеңме, бәлеше дисеңме, пылавы дисеңме — ашап туймаслык була. Мостафин, әлбәттә, мактый-мактый ашый. Майпәрвәз ханым аның саен кыстый:

— Тагын азрак кына өстим!

— Менә бу кисәген генә салыйм әле!

— Йә, Шакир, кыстатмагыз инде, яратып ашау шул буламыни?!

Ул Мостафинга бер дә «кияү» дип дәшми, әнә шулай үз итәргә, тиң итәргә теләгәндәй, назлап кына исеме белән дәшә.

Әйе, «әби» — дөньяда бер! Төче теле, куштанлыгы, сыйхөрмәте белән әллә кемеңне дә сихерләр. Шул ук вакытта ул вак сүзле дә түгел, үз дәрәҗәсен белә, мескен ялагайлык күрсәтми, кыскасы, министр әбие булырлык хатын.

Мостафин аңа карап кайчак Мәрьям әнисен, үзенең беренче әбисен исенә төшерә иде. Мескен әби! Колхоздан җәяүләп килә торган иде, түр бүлмәгә узмыйча ишек төбендә, табуреткада озак кына хәл җыеп утыра иде. Ул

шундый кыюсыз, юаш иде. Мостафинга: «Исәнме, кияү!» — дип дәшүдән башка сүз ката алмый иде. Билгеле, ул киявен гаять зур кешегә саный иде, шунлыктан бер өстәл артына утырып ашарга да тарсына торган иде. Мәрьям шуның өчен аны еш кына орыша иде:

— Бу ни хәл бу, әни? Киявеңә ни гомер ияләшә алмыйсың! Кем дип беләсең син аны? Безнең кебек үк бер кеше ич ул да. Килешми, ярамый болай!

Мостафин үзе, әлбәттә, әбисе белән мөмкин кадәр гади, ачык йөзле булырга тырыша. Көчләп булса да түргә утырта, аш сосканда тәлинкәсен тотып тора, ихлас күңелдән кыстый, теле ачылмасмы дип хәл-әхвәлләрен җентекләп сораша. Ә яулыгының кырыйларын күзләренә үк тартып куйган кечкенә битле әби алдына гына карап утыра, аз-азлап кына ашын каба, җавап биргәндә әледән-әле учы белән авызын сөрткәләп ала. Җавабы да аның күбрәк «ярый», «шөкер», «әйе», «юк әле» кебек беркатлы гына сүзләр була.

Инде Мостафин газета алып укырга утырса, ул, күләгә төсле, сиздерми генә кухня якка чыгып китә һәм бары шунда гына кызы белән озаклап пышым-пышым сөйләшә.

Елның кай вакытында гына килмәсен, ике-өч көннән ул кайтып китәргә ашыга торган иде. Күпме кыстамасыннар, җавабы бер: озак торырга кушмадылар! Мәрьямнең шуңа бик ачуы килә, ләкин җибәрмичә хәле юк, чөнки авылдагы җиңгәсенең берсеннән-берсе кечкенә дүрт баласы бар. Карчыктан башка анда эш харап! Шул ике-өч көн эчендә дә бичара әби аларның әллә никадәр вак-төяк эшләрен эшләп китә иде. Мостафин аны һәрвакыт атта яки машинада озатып җибәрә иде.

Ә менә бу акшарлы битенә елмаю каткан «әби» Мостафинның оекбашына йомшак итеп ямау салучы түгел инде. Пылау белән сыйлар, җимеш суы белән сыйлар, ике сүзнең берендә «Шакир!» дип дәшер, әмма әрсезхәйләкәр карашыннан: «Менә без сиңа нинди кызыбызны бирдек, кадеребезне бел!» — дигән горур кисәтү сизелеп торыр.

Әйе, кешеләр үзләре дә, аларның тормыш хәлләре дә бер булмый икән. Бу хакыйкать белән килешмичә мөмкин түгел. Ләкин шулай да Мостафинның күңелендә кайчак беренче әбисен кызгану хисе кузгала, аның алдында үзен ни өчендер гаепле сизгәндәй була. Китеп, кош теле хәтле генә бер хат та язганы юк, ичмасам, үзенә!.. Һай, ераклашты ул Мәрьямнең туганнарыннан, бик ераклашты.

## III

Бу җәйне Мостафинның эшләре аеруча тыгызга килде. Алда колхозларны эреләндерү эше тора иде. Бу эшне урып-җыюга төшкәнче башкарып өлгерергә кирәк иде. Камышлыга күптән түгел генә, кыш ахырында гына килгәнгә күрә, ул райондагы һәрбер колхозның хуҗалык хәлен, үзенчәлеген өйрәнеп җитмәгән, кешеләре белән ныклап танышып бетмәгән иде әле. Бигрәк тә алтмышлап председательнең һәркайсын якыннан белеп җиткәне юк иде. Ә шуларның барысын да белмичә торып, колхозларны ничек дөрес кушарга мөмкин? Җитмәсә, бу өйләнеп, кияүләп йөрү дә аның күп кенә бүтән эшләрен шактый артка калдырды. Хәзер инде шул ычкынган вакытны кире кайтарырга, буылган су кебек җыелып торган эшләрне тизрәк ерып җибәрергә кирәк иде. Һәм ул башаягы белән эшкә чумды. Йә көн-төн райкомда утыра торган булды, йә, машинага утырып, колхоздан колхозга чапты.

Хәер, аның күңеле көр, кәефе яхшы иде. Кая гына бармасын, нинди генә авыр эшкә йотылмасын, ул, ничектер, аркасыннан җылыткан кояшны сизгәндәй, үзенең бәхетен тоеп йөри: хәзер аның балкып торган бүлмәсе, бүлмәсендә сагынып көтеп алган япь-яшь хатыны бар. Инде шул яшь хатын кулы белән курчак өедәй җыештырылган бүлмәгә, шул кочагын ачып каршысына йөгереп килгән Наҗиясе янына кайтып кергәч, аның ару-талулары да берьюлы онытыла, райкомнан ияреп кайткан һәртөрле мәшәкатьле уйлары да шунда ук тарала.

Итекләрен салуга, Наҗия аңа йомшак туфлиләрен китереп бирә. Кулын юганда сөлге тотып тора, үзе, җитез кошчыктай, бертуктаусыз сайрый:

— Бик ачыккансыңдыр инде, җаным. Үзем дә көтә-көтә арып беттем. Ашымны плитага бер куям, бер алам. Куерып китмәгән булса ярар иде... Ә мин сиңа шундый бернәрсә пешердем, менә телеңне йотарсың... әни өйрәтте.

Мостафин, сөенеп, Наҗиясен бер кулы белән күкрәгенә кыса, ә Наҗия аяк очларына күтәрелеп, тиз генә иренен суза.

— Карлыгачым син минем,— ди Мостафин, иренен тидереп, аннан кулларын угалый-угалый, өстәл артына кереп утыра.

Өстәл өсте күз явын алып тора: кечкенә графин, нечкә саплы рюмка, чәнечке-пычаклар, ак салфетка, эреле-ваклы тәлинкәләр — бар да нинди чиста, нинди тәртип белән куелган. Мондый пөхтәлек өчен Мостафин эченнән генә

әбисен мактап ала: «Өйрәтә белгәнсең кызыңны, молодец, әби!»

...Ашап-эчкәннән соң ул алып кайткан бер кочак газета-журналларын караштырмакчы була. Ләкин озак та үтми, Нәҗия «көйсезләнә» башлый. Нечкә беләкләре белән Мостафинның муенына сарылып, кечкенә, тыгыз түше белән аның иңбашына ышкынып, ул үпкә катыш назланырга тотына:

— Йә инде, җитәр инде, җаным, ял итик, арыгансыңдыр ич! Әллә мине бер дә сагынмадыңмы? Юк шул, сагынмагансың икән шул, кайтасың да газетка тотынасың, менә укый-укый күзләрең сукыраер әле!

Ул шундый ихлас күңелдән, ни әйткәнен һич уйлап-нитеп тормыйча, чын күз яше сизелгән тавыш белән сөйләнә, Мостафин каршы сүз әйтү түгел, үз хәлен аңлатып та тора алмый. Ә хәле аның... җилкә кашытырлык! Әнә күпме укылмаган журнал өелде; икешәр-өчәр бите генә укылып ташланган күпме китап җыелды. Хәтта газеталарны да элеккечә җентекләп карап бара алмый башлады. Күңелле эш түгел иде бу. Юк-юк та, аның моңа эче пошып куя иде. Ләкин... шушы минутта елардай булып сырпаланган, баладай үпкәләргә торган сөеклеңә нинди тел белән: «Укырга кирәк, укымаган кеше артта кала!» — дип акыл сатасың? Әнә ничек сагынып көткән бит ул аны!.. Һәм Мостафин сиздермичә эченнән генә көрсенеп урыныннан тора.

Шулай көйләнеп китә Мостафинның эчке тормышы... Җылы, җыйнак, тыныч, аулак бу тормыш. Карау-кайгырту, назлау-сөю белән тулы аның һәр көне. Ни кирәк тагын? Рәхәтләнә бир, маемлап кына китмә!

Нәҗия, билгеле, хезмәттә түгел хәзер. Бергә тора башлагач та, ул тизрәк эшеннән чыкты. Райком секретаре хатыны була торып саклык кассасының тәрәзәчеге төбендә утыру аны хурландырды. Дөрес, Шакирына ул ачыктан-ачык алай дип әйтмәде, сине генә карап торасым килә, диде. Мостафин, билгеле, каршы килмәде, ул семья тормышын сагынган иде, аңа чын мәгънәсендә хатын кирәк иде. Әгәр аның Мәрьяме бер генә көн дә эшләмичә тормаган икән, бу башка мәсьәлә: Мәрьям укытучы иде, хезмәтендә кирәк кеше иде, хезмәтен ярата иде. Ә Нәҗиянең саклык кассасында утыруы кемгә кирәк? Счет төймәсен сала белгән һәрбер уналты-унҗиде яшьлек кыз аны алыштыра ала ич. Аннан, дөресен генә әйткәндә, Нәҗиянең зур, җаваплы эштәге ирен караптәрбияләп торуы җәмгыять өчен файдалырак та булачак. Күп кенә җаваплы эшчеләрнең тормыш иптәшләре әнә

шулай ирләренә хатын, балаларына ана булып кына торалар. Гаеп эш түгел, законга да, моральгә дә сыя бу...

...Нәҗия, хезмәттән чыккач, үзен читлектән ычкынган кош кебек тоя башлады. Үзенә үзе хуҗа, теләсә ни эшли, вакытны кая куеп бетерерлек түгел. Һәр көн иртәнчәк ирен озатып, бүлмәсен бик әйбәтләп җыештыргач, ул зур сумкасын әләктереп базарга йөгерә. Башта базарны бер әйләнеп, бөтен нәрсәнең бәясен сорашып чыга, аннан сумкасын тутырып итен, маен, суганын, кишерен, кәбестәсен ала. Кайтышлый базар капкасы төбендә көнбагыш сатып утыручы хатыннардан ярты гына стакан көнбагыш та кесәсенә салдыра. Райком секретаре хатынына көнбагыш яруның килешмәгәнен белсә дә, һаман әле яшьтән үк килгән гадәтен җиңә алмый, ялтйолт каранып, көнбагышын яра-яра кайта.

Мостафин төшке чәйгә кайтып киткәннән соң, ул киенеп-ясанып Камышлы «центрына» йөрергә чыгып китә. Райүзәкнең бер генә урамына тезелешкән эреле-ваклы кибетләрен йөреп чыга. Кибетләргә нәрсә килгән яки нәрсә көтәләр — шуларны сораша. Сатучылардан аның: «Нәҗия иптәш (район мокытлары «ханым» дип әйтә белмиләр инде), сезгә габардин кирәк түгелме? Кирәксә, сезнең өчен генә табарбыз», дип әйтүләрен ишетәсе килә. Каршыларында Мостафин кадәр Мостафинның хатыны басып торгач, әйтергә тиешләр ләбаса! Юк, хәерсезләр, әйтмиләр, песнәк күргән ата мәчедәй, күзләрен чекерәйтеп тик карап торалар... Тукта менә, бер килеп әйттерә башлар әле ул алардан!

Кибетләрне йөреп чыккач, Нәҗия станциягә китә. Анда да бит берничә киоск һәм алама гына буфет бар. Ә буфетта кайчак шешәле лимонад була. Шәһәрдән кайткан лимонад! Нәҗия аны эчмичә һич тә түзә алмый инде.

Әгәр пассажир поезды килгән чак булса, ул тәмам дөньясын оныта. Бигрәк тә мягкий вагон алдында әрлебирле йөргән көяз, сылу ханымнардан күзен ала алмый. Аларның аяк йөзләренә кадәр салынып төшкән асыл ефәк халатлары, бер олтырактан гына торган әкәмәт туфлиләре аны көнләшеп һәм көрсенеп уйланырга мәҗбүр итә: «Нинди кешеләрнең хатыннары икән болар, ирләре күпме ала икән?..» Шәп ирләр күренсә, аларны да игътибарсыз калдырмый ул. Үзе үк аларның күзенә чалынырга тырыша: «Камышлыда да сез карамаслык чибәрләр юк түгел»,— дип әйтәсе килә аның...

Станциядән кайтышлый клуб алдына тукталып уза. Ни бар икән бүген? Хәер, ни барын белер өчен тукталып тору да кирәкми, ерактан ук күренеп тора. Әгәр читтән

килгән артистлар булса, типография баскан афиша эленгән булыр. Танцы буласы икән, фанера такта сөялеп торыр. Кино икән, шәмәхә кара белән картинаның исеме язылган иске газета коймага ябыштырылган булыр. Ә кай көнне исә боларның берсе дә булмый.

Тагын бер тапкыр әйләнмәгәндә, райүзәк «центрында» йөрү шуның белән тәмамлана. Әз булып кала бу, әлеге ярты стакан көнбагыш та ярылып бетми, ләкин, нишлисең, кырга чыгып китмәгәндә, бүтән барыр җир юк инде... Нәҗия кайтып аш пешерергә тотына. Бу аның көндәлек иң зур эше. Бик яратып, дәртләнеп тотына ул бу эшкә. Үзенчә баш вата: көн дә бер үк төрле аш булмасын, тәмле булсын, Шакиры мактарлык булсын. Әледән-әле әнисенә шалтыратып, сорашып кына тора: пилмән камырына ничә күкәй сытарга, пылауны ничә стакан суда кайнатырга, төче бәлеш камырына күпме сода салырга?.. Әнисе кебек аның мактаулы аш-су остасы буласы килә. Аларның әле мәҗлес җыйганнары юк, Шакиры ни өчендер теләми,ә үзләре ике җирдә — райисполком председателендә һәм прокурорда кунакта булдылар инде. Нәҗия хәзер аларның хатыннарыннан оялып йөри. Кунак ашы — кара-каршы булырга тиеш ләбаса! Юк, чакырмый булмас, ихтимал, бер аралашып киткәч, еш кына чакырырга туры килер. Менә шул чакта инде килгән кунаклар аның ашларын: «Ах, Нәҗия ханымның бәлеше!», «Ах, Нәҗия ханымның пылавы!» дип мактый-мактый ашасалар, ни бәхет!

Мостафин кайтып, ашап-эчеп, бераз ял итеп кичке эшкә киткәч, Нәҗия өчен шактый күңелсез бер вакыт башлана. Шакир тиз генә кайтасы түгел, табак-савыт юып, өй җыештырудан башка бүтән эш юк, кая куеп бетерергә бу вакытны? Китап алып утырса, укыганы башына керми, йокы баса; элекке иптәш кызларына барыр иде, алар хәзер аңа, ничектер, ятсынып карыйлар, үз итмиләр; киноaccess Шакирдан башка бару уңайсыз — нишләргә? Аптырагач киенә дә әниләренә китә. Әтисе күп вакыт өйдә булмый ( ул чакларда бер райком работниклары гына түгел, гомумән, җитәкче кешеләр, кирәк булса да, булмаса да, кичләрен эшләгән җирләренә барып утыралар иде), һәм алар, аналы-кызлы, чәй эчә-эчә, озак кына гәпләшеп утыралар. Майпәрвәз ханым бик җентекләп кияве турында сораша: кәефе ничек, бик арып кайтмыймы, аңа (Нәҗиягә) салкын түгелме, алай-болай каты сүз әйткәне юкмы? Ни сөйли, нәрсә тели, нәрсә вәгъдә итә, акча белән кысмыймы? Кемне мактый, кемне яманлый, райсоюз председателе Ибәтуллинны ни өчен эшеннән алганнар, аның

урынына кемне куймакчы булалар? Былтыр килгән яшь врач Асия больницаның шоферы Васяга чыккан, ди, ә Васяның кайсыдыр районда хатыны белән баласы бар, имеш. Шакир шуны беләме, ни әйтә?

Майпәрвәз ханымда моның кебек «яңалыклар» һәрвакытта булып тора, ләкин ни өчендер ул һаман шуларга киявенең мөнәсәбәтен белергә тырыша. Ә Нәҗия ни диеп җавап бирергә дә белми: Шакирыннан андый нәрсәләр ишеткәне юк аның, гомумән, ул райкомда ниләр булганын сөйләргә яратмый, тик ара-тирә эшенең күп булуыннан гына зарлана.

— Юри яшерә торгандыр,— ди Майпәрвәз ханым, тирләгән битен алдында яткан сөлге башы белән сөртеп.— Ирләр бер-берсенең гаебен йомарга яраталар, ышан син аларга, бар да бер чыбыктан куылган халык. Шулай, кызым, ирләргә бервакытта да ышанып бетәргә ярамый, аш төрләндерергә яраталар алар... Уяу, сизгер булырга кирәк...

Кызының уңайсызланып урындыгы өстендә кыймылдый башлавын күргәч, Майпәрвәз ханым сүзен тизрәк икенчегә бора:

— Әйе, сорарга оныта язганмын. Кышкы пальтоңның якасы кыршылган түгелме соң? Алыштыр. Соры каракүл килешер. Биш йөзгә табып була, ди. Шакирыңнан сора, куркып торма... Ирне аны, җанкисәгем, гел акча табу кайгысында тотарга кирәк... Син яшь, син чибәр,синең өс-башың да менә дигән булырга тиеш. Бел, үз-үзен карамаган хатын ир күзенә кухарка булып күренә башлый ул.

— Әни, туктале, анысы шулай да бит, тик Шакир райкомда эшләп, зарплатадан башка ничек итеп акча тапсын ди?

— И-и, кызым, бик яшь шул әле син, дөньяның серләрен белмисең... Кеше кая гына, кем генә булып эшләмәсен, теләсә, юлын таба. Тукта, менә Шакирны тагы да ныграк белә төшик — мал җанлы кешеме, түгелме — шуннан соң мин үзем сезгә юлларын күрсәтермен. Ышан, кызым, сезнең киләчәк бәхетегез турында мин төн йокламыйча уйланам.

— Ышанам, әни...— ди Нәҗия, акрын гына.

Майпәрвәз ханым, җиңел сулап, урыныннан тора:

— Ярар, күп утырдык, бар кайт инде булмаса, кызым. Йә Шакирың, кайтып, борчылып торыр.

Нәҗия кыска жакетын киеп, матур бизәкле зәңгәр ефәк косынкасын башына, чәч бөртекләрен юри җыймыйча калдырып, саксыз гына бәйләгән чакта, Майпәрвәз ханым аңа сокланып карап тора.

— Чибәр син, Нәҗия, бик чибәрсең! Алла бәхет кенә бирсен! — ди ул һәм кызын, аркасыннан сөеп, ишектән озатып кала.

Нәҗия, иңбашына канатлар чыккандай, өенә очып кайта. Әнисенең сүзләре аны әллә нишләтеп җибәрә. Капма-каршы хисләр утында яна ул: тирән шомлану йөрәген биләп ала, сукыр көнчелек акылын томалый, әгәр Шакирының энә очы кадәр генә хыянәтен сизеп калса, кечкенә усал ерткычтай, нинди ләззәт белән үч аласын уйлап хыяллана. Шул ук вакытта үзенең чибәрлеген, ташып барган дәртен тоеп, ничектер, зәһәрле горурлану белән куана. Шакирын үзенә генә табындырып, беткәнче аңа хуҗа булып торасына кинәнеп ышана. Шунда ук аның Шакирын күрәсе, кинәт ут булып кабынган дәртенең кодрәтен сынап карыйсы килә. Кайтып кергәч тә, ул райкомга шалтырата башлый. Беренче шалтыратуында иренең тыныч тавышын ишетә: «Озакламам», ди. Бераздан икенче тапкыр шалтыраткач, Шакир инде сабырсызланып һәм ялварыбрак сөйли:

— Аңла син, карлыгачым, эш ташлап китә алмыйм бит мин... Нигә ул хәтле борчыласың, бушагач, үзем дә бер минут та тормам — кайтып җитәрмен.

Ниһаять, өченче тапкыр шалтыратканнан соң, кабаланган тавыш:

— Бетте, өстемә кидем, биш минуттан яныңда булырмын,— ди.

Мостафин әнә шулай чибәрен зарыктырып, эшен бетерер-бетермәс ашыга-ашыга кайтып кергәндә, Нәҗия инде урын өстендә була. Ул стенага карап, тавыш-тынсыз гына ята. Мостафин чишенеп, итекләрен салып, карават читенә килеп утыра. Сакланып кына кулын аның аркасына сала, бераз көтеп, үзенә таба бормакчы була. Нәҗия кисәк кенә иңбашын селкетеп куя, янәсе — кит, тимә... Мостафин, аның колагына иелеп, юмалап кына:

— Карлыгачым, бик үпкәләдеңмени шулай? — ди.— Менә кайттым ич, сине сагынып кайттым... Йә, борыл инде.

Нәҗия тиз генә борылырга теләми, шулай да, аркасыннан сөя торгач, иңбашын селкетми башлый. Ахырда Мостафин аның башын акрын гына үзенә таба бора: карлыгачы озын керфекләрен йомган, нечкә иреннәрен кыскан — күрәсе, дәшәсе килми, имеш. Ә йөзе аның нинди алсу, борыны нинди нәфис, күз төпләре нинди чиста, маңгае нинди ак, ир хатыны да димәссең! Мостафин аның карлыгач канатыдай нечкә кашларын бармак бите белән йомшак кына сыпыра, аннан акрын гына борыны буй-

лап төшә, ирене тирәсеннән әйләнеп уза, ап-ак ияк астын кытыклый башлый. Үзе ялварып:

— Ач инде күзеңне,матурым, ач, азаплама мине,— ди.

Нәҗиянең иреннәрендә елмаю сыман нәрсә чагылып кала, ләкин күзләрен һаман әле ачмаска тырыша. Мостафин сизеп тора — ачуы кайткан инде, тик үзенчә сер сынатмаска тырышкан була... «Бала шул әле, бала!» — ди Мостафин эченнән генә һәм, иелеп, борын очыннан үбеп ала.

Менә, ниһаять, бала дигәнебез күзләрен ача. Беравык ул җитди, ачулы карамакчы була, ләкин, юк, көче җитми — башын чайкап куя... Кинәт аның күзләре кысыла төшә, карашы ничектер әчкә, еракка китә, томан белән өртелә һәм, шул томанлы ерактан артык чыдарга тәкате калмагандай, инәлеп, чакырып карый. Менә ул, сылу гәүдәсенә киерелеп, кулларын Мостафинның муенына суза, кибеп киткән иреннәре белән кайнар пышылдап:

— Йә! — ди.

Мостафинның бөтен тамырлары буйлап, әйтерсең ток йөгерә — ихтыярсыз тетрәнеп китә ул...

## IV

Игеннәр өлгерә. Офыктан офыкка кадәр җәелеп яткан арыш кырлары тоташ агарды инде, авыллар диңгездәге утрауларга охшап калдылар. Басу юллары күздән югалдылар; атлы юлчының арыш эченнән йөзеп килгән дугасы гына күренә... Кичләрен, караңгы төшкәч, бөтен офык буйлап наҗәгай өзлексез «камчысын уйната»...

Кайбер колхозларда арышның өлгергән җирләрен, сайлап, кулдан урырга да тотындылар. Авыл читләрендә күксел комбайннарның ак зонтлары күренә башлады. Бүген булмаса иртәгә алар да ерак сәфәргә кузгалырлар. Әйе, кызу эш көннәре килеп җитте.

Мостафин бу көннәрдә, машинадан төшмичә, колхоздан колхозга чаба. Менә бүген дә ул ерак колхозларның берсеннән кайтып килә. Йөрүне ул һәрвакытта ярата торган иде. Юл вак-төяк мәшәкатьләрдән аера, юл үзе кебек озын, борылмалы уйлар кузгата. Тик, ни сәбәптәндер, бу уйлар, юлның үзе кебек, алга юнәлмәгән, ә күбрәк артка, үткәнгә таба караган. Элек ул, юлга чыкса, тыныч җан белән алда торган зур эшләр, киләчәктә көткән максатлар турында уйлана торган иде. Ә хәзер андый зур уйлар өзек-өзек кенә килеп китәләр; бер дә баштан чыкмаганы исә — һаман үз көне, үз хәле турында...

Иң элек бер генә минутка да аның күңеленнән Нәҗиясе чыкмый. Нигә бер дә онытып тора алмый ул аны — үзе дә аптырый. Әлбәттә, ул аны утырып җиткән, тирән, басынкы ир мәхәббәте белән ярата, ләкин каян килә бу нәрсә икәнен тел белән дә әйтеп булмас әллә нинди билгесез борчылу?.. Менә Нәҗиясе аның көннәр буе ялгыз кала. Нишли ул, вакытын ничек үткәрә, нәрсә белән юана?.. Ихтыярсыз күңеленә әшәке шик килә башлый, ләкин шунда ук ул аны, үз-үзенә ачуы килеп, читкә ыргыта. Синең белән тора башлавына ике-өч ай да узмаган, беткәнче сиңа бирелеп, буйсынып торган хатыныңнан шикләнә дә башла, имеш! Йә, нигә ярый бу? Әмма... җан тыныч түгел. Нәҗиядә кайнар дәртнең болай иртә кузгалуы аны куркыта да, шомландыра да... Бик яшь бит әле ул, мавыгып, хискә бирелеп яши торган чагы, җаваплылык тойгысы да, бәлкем, ныгып җитмәгәндер, гомумән тормышның нечкә, катлаулы яклары турында уйлый белми торгандыр. Шундый хәлдә берәр мәкерле, мут кешегә очрап, үзе дә сизмәстән хурлыкка төшүе бар. Нинди коточкыч бәхетсезлек булыр иде бу...

Әйе. Нәҗия ялгыз яши алмый торган аккош шикелле ул, аның янында, бер адым читкә китмичә, карап, сагалап торучы ата кош булырга тиеш. Ләкин ул, Мостафин, үзенең оясында аккошын гына саклап торучы ата аккош була аламы? Әлбәттә, юк. Димәк, алар арасында тугрылык, яхшы исем, семья абруе бары бер-береңә ышану, бер-береңне аңлау, бер үк теләкләр белән яшәү аркасында гына сакланырга мөмкин. Әмма шулар — ышану, аңлау, уртак теләк — алар арасында бармы соң? Хәзергә әйтүе читен, ихтимал, тора-бара, бергәләп тозны күбрәк ашагач, барысы да булыр, бу билгесез борчылулар үзеннән-үзе бетәр... Бетсен иде, тизрәк бетсен иде, тату, тыныч тормыш тели бит ул, бик тели!

Юллар озын, юллардан да бигрәк уйлар озын. Юлларның барып җиткәч туктый торган җире була, ә уйларның җитеп туктар җире юк. Бигрәк тә үз эчендә генә йөргән уйларның очына чыгуы кыен — берсе бетми, икенчесе ялганып китә.

Кичәгенәк шулай Андреев белән озак кына сөйләшеп утырганнар иде. Әйе, башта шуны әйтергә кирәк, иптәш Андреев бик әдәпле һәм ипле кеше булып чыкты. Беренче секретарь икәнен урынлы-урынсыз сиздереп тормый, үз карашын кешеләргә тагарга ашыкмый. Ничә әйтсәң дә, интеллигент, укымышлылар арасында яшәгән, культура күргән кеше... Ә Мостафин белән аеруча сана-

ша, үзе үк: «Шакир Сабитович, сезнең тәҗрибә — минем өчен зур хәзинә ул»,— дип әйтеп тора.

Сүз башта, билгеле, чираттагы эшләр турында барды, аннан бер яңа эреләндерелгән колхозга кемне председатель итеп кую турында киңәшеп алдылар. Шунысы кызыклы, Андреев эчкән кешеләрне бер дә яратмый икән. «Эчкән кеше — төшеп калачак кеше»,— ди.

Сүз бетеп, Мостафин чыгып китәргә кузгалгач кына, ул өстәлендә ачык килеш яткан бер китапка башы белән күрсәтеп сорады:

— Сез бу әйберне укыдыгызмы әле?

— Нәрсә ул?

— «Урак өсте».

Мостафин җиңелчә генә кызарды.

— Юк әле, укырга өлгермәдем.

— Укыгыз. Әйбәт язылган. Шактый гыйбрәтле нәрсәләр бар безнең өчен дә...

— Вакыт, вакыт, Андрей Петрович! — диде Мостафин, көрсенеп.

— Вакыт холостяк кешегә генә җитми бит ул,— диде Андреев, йомшак елмаеп.— Сезнең хәзер свиданиегә йөрисегез юк ич!

Мостафин тагын кызара төште.

— Анысы шулай,— дигән булды ул, елмаерга тырышып,— ләкин, үзегез күрәсез, Андрей Петрович, свиданиегә йөрүдән бер дә ким чабарга туры килми бит.

— Күрәм, күрәм. Без, оя үрүче кошлар кебек, гел хәрәкәттә... Яшь ханымның кәефе ничек соң?

— Рәхмәт, хәзергә зарарсыз.

— Бик чибәр, сөйкемле кыз дип ишеттем, ләкин, кызганычка каршы, күрергә туры килгәне юк әле,— диде Андреев, Мостафинга туры гына карап.

Мостафин ни дип җавап бирергә белмичә шактый уңайсызланып калды, ә Андреев моны сизенде булса кирәк, тизрәк өстәде:

— Сәлам әйтегез үзенә!

— Яхшы,— диде Мостафин, ничектер, үзен үрә каткан солдат шикеллерәк хис итеп.

Әйе, бик начар тәэсир итте аңа секретарьның бу соңгы сүзләре... Гүя, Андреев, үзе дә сизмәстән, аның өчен гаять күңелсез бер хакыйкатьне фаш итте: чыннан да, ул Нәҗиясен аңардан яшерә бит. Әлбәттә, юри түгел, ә үзенә исәп бирмәстән, аның Нәҗияне Андреев күзенә күрсәтәсе килми иде. Нидән бу? Көнләшүдән дип булмый моны... Тизрәк ул райком шоферыннан көнләшер, әмма Андреевтан түгел... Эш нидә соң, ни өчен ул көн-

төн бергә эшләгән өлкән иптәшенә яңа өйләнешкән хатынын, әдәп йөзеннән генә булса да, күрсәтергә теләми? Чөнки ул курка, курка һәм уңайсызлана... Хакыйкать менә шул: Нәҗиянең артык чибәр, артык яшь булуы Андреевны гаҗәпләндерер, эченнән генә аны әллә ничек ямьсез уйлап куярга мәҗбүр итәр, дип курка иде ул... Секретарьның, Мостафин бу туташтан, кычкырып торган чибәрлектән башка, үзе өчен уртак нәрсә генә тапты икән, дип уйлау ихтималы борчый иде аны...

Хакыйкать тагын шул: өйләнгәннән соң Мостафин район җитәкчеләре белән якыннан аралашып, кунакка йөрешеп китүдән аеруча саклана иде. Моның сәбәбен ул, бәлкем, әйтеп тә бирә алмас, әмма нигәдер күңеле тартмый, нәрсәдер фаш ителер кебек, якынаю урынына салкынаю, бизү килеп чыгар кебек... Кайбер хәлләрдә кешеләрнең бер-берсеннән ераграк торулары хәерлерәк ич, шул чакта алар бер-берсе турында әйбәтрәк уйлаучан булалар.

Әйе, уйлан да уйлан, ә тынычлану юк. Ни җитми икән соң аңа? Барысы да бар лабаса — тазалык, тук тормыш, яраткан эш, сөйгән хатын — йә, тагын ни кирәк?.. Ә шулай да ялгыз ул, бик ялгыз... Кемнедер өзелеп юксына ул. Кемдер кирәк аңа, йөрәгенә тигәнәк шикелле сырышкан шушы чуалчык, файдасыз уйларын рәхимле кулы белән йомшак кына сыпырып алучы кемдер кирәк аңа... Кем соң ул?

Мәрьям. Менә кем кирәк, менә кемне юксына икән ул! Хәер... актыкка кадәр әйтеп бетерик: Мостафин Мәрьямен алай еш исенә төшерергә яратмый иде, юри тыела иде, чөнки аныңча: үлгәннәр тере калганнарның тормышында үзләрен берничек тә сиздермәскә тиешләр. Бигрәк тә менә аның, Мостафинның, тормышында бу шулай... Беркем алдында да үзен гаепле тоясы, үкенәсе килми иде аның... Ләкин була шундый минутлар, Мостафин үлек Мәрьямне түгел, ә тере Мәрьямне бөтен барлыгы белән сагынып юксына иде. Менә шулай таза «ГАЗ-67» машинасы ташлы ком сипкән юлдан кыштыр-кыштыр чапкан чакта, ул аны гүя янәшәсендә тоеп бара иде.

Якынрак елышып: «Шулай, дустым!» — дип дәшәсе килә аның. Әйе, барысыннан элек Мәрьям аңа дус иде шул, сердәшче, якын киңәшче иде. «Ир» дип табынып тормады ул аңа, хатын булып кына яраргa тырышмады. Тыныч, тыйнак, әмма тирән ярату белән яратты ул аны. Бик кадерле иде ярату хисе аның өчен, шуңа күрә тирән яшерә торган иде. Ә ул, ахмак, вакыт-вакыт аны салкын булуда гаепли иде. Хәзер менә мәхәббәтнең, примус өстендәге чәйнек төсле, кайнап торганы бар, ләкин...

көн саен пешүдән башка нәрсә ала ул бу «мәхәббәттән»? Юк, кайнар хатын түгел, кайнар дус тансык икән хәзер аңа... Үзе ул асылда йомшак характерлы кеше, тормышның кискен борылышларын авыр кичерә, үтә җитди мәсьәлә алдына килеп басканда тиз генә берәр карарга килә алмыйча аптырап калучан иде... Ә Мәрьяме аның, киресенчә, тигез-сабыр холыклы, анык акыллы хатын иде һәм ире аптырауга төшкән минутларда аңа нәкъ кирәген әйтеп бирә белә торган иде. Менә хәзер дә Мәрьяменең кулларыннан тотып ул: «Әйт, акыллым, ни эшлим мин, кая таба барам, дөрес юлдамы мин?» — дип сорамас идемени!..

Ләкин машина Камышлыга якынлаша, Мәрьяме, гүя, аның яныннан сиздермичә генә төшеп кала, һәм Мостафинның инде күз алдына «сылу карлыгачы» — өстенә очып кунарга торган Нәҗиясе килеп баса.

Әллә нинди каршылыклы, тынгысыз хис биләп ала аны... Шундый якын, шундый кадерле яшь чибәр хатыны янына ашкына кебек ул, әмма шул ук вакытта шундый ерак, шундый ят бер кеше янына күчләнеп барган шикелле. Беткәнче үзенеке генә булган яшь хатынның кайнар дәрте аны тарта кебек, әмма шул ук вакытта бу торган саен туемсызлана барган дәрт аны куркыта һәм чиркандыра шикелле... Аңа гына сыенып, аны гына назлап тора торган чәчәктәй нәфис Нәҗиясе белән ул кешеләр алдында горур һәм бәхетле булыр кебек, әмма шул ук вакытта берни белми, берни уйламый торган җилбәзәк хатын белән адәм көлкесенә калыр һәм тирән бәхетсезлеккә төшәр шикелле...

## V

Кара көз җитеп, сулар туңгач һәм беренче кар җиргә яткач, Байгузиннар унике каз,бер тана, бер иләмсез зур дуңгыз, өч хуҗа берләшеп, бер яшь ат суйдылар. Дуңгызы сатар өчен, ә калганнары — үзләренә кышлык өчен иде. Бу — һәр көзен кабатлана торган сугым булып, алар кыш буе итне буш диярлек ашап чыгалар. Дуңгызны шәһәргә җибәреп, кыйбат бәядән саттыралар. Зат әйбер алу, яхшы кием тектерү башлыча әнә шул дуңгыз акчасына була торган иде.

Сугым көннәрендә Нәҗия, үзләренә китеп, иртәдән кичкә кадәр әнисенә булыша иде. Кечкенә спай итекләрдән, кыска итәкле күлмәктән, өстенә килешле утырган сырмадан, башына ак шәл бәйләп ул армый-

талмый эшләп йөри: су китерә, утын кертә, кызлар белән бергә каз йолка, аннан икешәр-икешәр дүрт казны көянтә башына элеп елгага алып төшә, ә тышкы эшләрдән бушагач, өйдә әнисенә аш-су тирәсендә дә ярдәмләшә иде. Эш тансыклаганга, ахрысы, ул бу көннәрдә аеруча җанланып, канатланып китә. Бит урталары аның әнистәй пешеп чыга, күзләрендә очкын уйный, ә сылу гәүдәсе үзеннән-үзе уйнаклап тора. Шундый чакларында Мостафин аны күрсә, чын гаҗәпләнү белән эченнән: «Менә эш кешене нишләтә!» — дип уйлый һәм Наҗиянең үзенә дә: «Карлыгачым, тышта эшләү сиңа нинди килешә, ничек син тагы да матурланып китәсең!» — ди иде.

Мостафин да, билгеле, бу көннәрдә төшке чәйгә һәм кичке ашка әбиләренә кайтып йөрде. Сугым көннәрендәге аш-су гаҗәп бит ул! Ишектән килеп керүгә инде казанда акрын гына гөбер-гөбер кайнаган итнең өйгә таралган буы, мичтән чыккан шулпалы бәлеш исе борыннарны кытыклап җибәрә. Аппетит берьюлы котырып китә, ашау ләззәтен, «тәгам» алдыңа килмәс борын ук, авыз суларыңны йота-йота бөтен эчең белән тоеп торасың.

Мостафин кулын юып, әбисенең җылы түренә узып утыргач, Майпәрвәз ханым иң элек, гадәтенчә, графин белән бал китереп куя. Бал янына атның йомры картасы белән бавырын бирә. Аннан өреле шулпа килә, шулпа артыннан — каз бәлеше, бәлеш артыннан табак өеме ит килә. Майпәрвәз ханым киявенең тәлинкәсенә итнең иң шәп җиреннән зур түтәрәм янбаш сөяген сала — бусы кимерер өчен...

Мостафин кара гимнастеркасының җиңен кайтарып, бил каешын ычкындырып ашый-ашый, әбисенең уңганлыгын мактап бетерә алмый, бабасының исәп белән тора белүенә чын-чынлап гаҗәпләнә. Ә бабасы, Идият абзый, кулына счет алып, аңа аяклы мал симертеп суюның базардан ит сатып алуга караганда никадәр арзанга төшүен исәпләп күрсәтә. Тик ул дуңгызына май заводыннан эремчек суын бушлай ташып эчертүен һәм печәнне колхоздан буш бәягә китертүен генә секретарь киявенә әйтмичә кала.

Менә шундый кичләрнең берендә, бал эчеп, казылык ашап утырган чакта, Майпәрвәз ханым күптән уйлап йөргән ниятен киявенә, ниһаять, сак кына әйтергә булды.

— Сез, Шакир, һаман безне, тора беләсез, дип мактыйсыз,— диде ул, җаен китереп.— Алай бик ошагач, үзегез дә безнең кебек торып карар идегез.

— Кая инде ул безгә! — диде Мостафин, көлеп.

— Юк, сез көлмәгез әле,— диде Майпәрвәз ханым, кинәт җитдиләнеп.— Мин чынлап әйтәм. Теләгән кешеләр тора беләләр. Сезгә дә вакыттыр инде...

Майпәрвәз ханым ни өчендер сүзен әйтеп бетермичә тукталып калды, ә Мостафин аңа гаҗәпләнеп карады.

Шушы карашка җавап итеп булса кирәк «әби»:

— Син, Шакир, сүземне гаепкә алма,— диде йомшак тавыш белән.— Син безгә бик якын кеше бит, бердәнбер Наҗиябезнең ире булгач, үз балабыз кебексең... Шуның өчен дә менә мин сезнең тормышыгыз турында гел уйланам...

— Рәхмәт, әби, рәхмәт!

— ...Сезнең дә, кешеләр төсле, мул тормыш, киң ризык белән гомер итүегезне күрәсем килә.

— Монысы өчен дә рәхмәт, әби! — диде Мостафин, сүзнең җитдилеген аңламагандай һаман әле елмаеп.— Ләкин безнең ризык, картлар әйтмешли, шөкер хәзергә, киң әле. Күрәсез, алдыбызда никадәр сый...

Майпәрвәз ханым да, киявенең әче балдан булса кирәк шат кәефенә яраргa тырышып, үзенчә бик сөйкемле елмайды, ләкин сүзен уенга борырга теләмәде.

— Әйе, Аллага шөкер, ризыгыбыз киң, чөнки үз хәзинәбездән, базардан сатып алган түгел... Менә, мин әйтәм, сезнең дә өстәлегездә үз хәзинәгезнең җимешләре булсын иде дим.

— Нигә, барыбер түгелмени? Акча җимеше ни, бакча җимеше ни?

— Барыбер түгел шул. Бакча җимеше булганда акча кесәдә кала.

— Һай, әби, җанкисәгем,— диде Мостафин, башын чайкап,— нинди дөрес исәп йөртә беләсез сез!.. Соң, нишләргә кушасыз безгә? Әллә... сезнең кебек мал-туар асраргамы?

Майпәрвәз ханым, киявенең райком секретаре булуын бер генә минутка да исеннән чыгармаганга күрә, сорауга сорау белән җавап бирде:

— Нигә, гаепмени? Үз көнең өчен генә терлек асрауны закон тыймый лабаса!

— Юк, тыймый.

— Шулай булгач, нигә аңа исегез китә? Әллә сезгә, партийный кешеләргә, ярамыймы?

— Безгәме? Безгә ни...— диде Мостафин, ике каш арасын ышкып,— кирәк кадәр генә безгә дә ярый. Әйтик, сыер асрарга була... Ләкин кем карый соң аны бездә?

Наҗия, кинәт калкынып, ашыгып әйтте:

— Һи, булсын гына, үзем карыйм, рәхәтләнеп... Мин хайванны бик яратам.

Мостафин аңа, балага карагандай, көлеп һәм сөеп карады.

— Шулаймыни?! Син яратырсың да бит, хайван сине яратырмы икән соң?

— Әйттең сүз! — диде Нәҗия, матур башын горур гына чөеп.— Үзебезнең сыерны гел мин сава торган идем әле... Дөрес бит, әни?!

— Дөрес, кызым!

— Ярый алайса, сыерны савучы булды да ди. Ә кайда тотарбыз без аны? Чоландамы?

Мостафинның болай ярым шаяртып сөйләнүе Майпәрвәз ханымга бер дә ошамый иде, ләкин ул тыштан моны һич сиздермәде, хәтта җитди булырга теләгән чакларында да әлеге йөзенә каткан елмаюны югалтмаска тырышты. Шул ук вакытта ул, бу әңгәмәне ни өчен башлавын нык исендә тотып, сүзне уенга бормыйча, ничек тә төп мәсьәләгә илтеп җиткерергә тели иде.

— Әйе,— диде ул, мәгънәле генә итеп,— борын ат алырдан элек йөгәнен әзерләп куярга куша торганнар иде.

— Менә шул шул! — диде Мостафин, тизрәк килешеп.

Майпәрвәз ханым сүзен дәвам иттерде:

— ...Димәк, сезгә дә сыер алудан элек, аны кайда асрау турында уйларга кирәк икән...

— Бик дөрес!

— Алайса сүз дә шул турыда барырга тиеш. Бабайлар казык каккан җиргә мал ияләшер дигәннәр. Сезгә дә, Шакир, үз казыгыгызны кагар вакыт җиткәндер, шәт.

— Моны ничек аңларга? — диде Мостафин, әбисенә дикъкать белән карап.

Майпәрвәз ханым бер мизгел иреннәрен кысып торды да ашыкмыйча, тыныч кына, әмма бик җитди итеп әйтеп бирде:

— Сезнең үз йортыгыз булырга тиеш!

Мостафин гаҗәпләнүдән хәтта урындыгы артына ауды.

— Йо-орт! Ай-һай, әби җаным, салдыгыз сез хәбәрне! Йорт! Кем салып бирер икән соң аны безгә? Минем бит капиталым юк, әллә Нәҗиянең җыеп торган акчасы бармы?

Майпәрвәз ханым бер җиңел сулап куйды: Аллага шөкер, куркыныч үтте аның өчен, кияү йорт дигәнне ишеткәч, курыкмады, кәефе дә кырылмады, бары бик нык гаҗәпләнде генә...

— Нәҗиянең җыйган акчасы булса, сезнең кулда булыр иде,— диде ул, киявенә сөйкемле карап.— Ләкин

сез борчылмагыз, йорт салырга акчаны сезгә дәүләт тә биреп торыр.

Мостафин бабасына таба борылды:

— Бабай, ишеттегезме, әби нинди зур мәсьәлә күтәрде? Сез ничек уйлыйсыз бу турыда?

Моңарчы битараф бер чырай белән тыңлап кына утырган Идият абзый кузгалып куйды, сакалсыз ияген сыпырып алды, ләкин җавап бирергә ашыкмады. Майпәрвәз ханым күптән инде аны: «Мин сөйләгәндә тыгылма, үз чиратыңны көт»,— дип өйрәтеп куйган иде. Һәм ул зур сабырлык белән үз чиратын көтеп алды, хәзер инде ир кеше авторитеты белән хатынының әйткәннәрен ныгытырга тиеш иде.

— Әһем,— дип тамак кырып куйды Идият абзый.— Әйе, җитди мәсьәлә, уйлашырга кирәк... Минемчә, Майпәрвәз дөрес әйтә: үз өең булса — яхшы инде ул, тормыш ансаткарак килә, әйе... Үзегез беләсез, район җирендә күп кешеләр үз йортлары белән торалар. Әле менә соңгы елларда гына күп кенә җаваплы иптәшләр — мәсәлән, райфо мөдире Курмашев, милиция начальнигы Куликов, поселковый совет председателе Сәхәпов, «Маслобаза» директоры Мусин, «Заготзерно» управляющие Иванов, райком инструкторы Рәкыйпов — бар да, ссуда алып, йорт салдырдылар. Әнә райисполком председателе Сәйфуллин да былтыр чибәр генә йорт салдырып керде. Безнең монда ул эшкә кырын карамыйлар, куәтләп торалар.

— Анысы шулай,— диде Мостафин, икеләнебрәк.— Ләкин менә безнең өчен кирәкме ул йорт дигән нәрсә? Без — икәүдән-икәү генә, бүген монда, иртәгә — әллә кайда...

Майпәрвәз ханым мондый сүзне көткән иде, һәм аның җавабы да әзер иде.

— Һи, Шакир,— диде ул, кулын селтәп,— сез яшь кешеләр ич! Икәүдән өчәү, өчәүдән дүртәү булырсыз әле, боерган булса... Йорт бит ул — гомерлек нәрсә. Китсәгез — бәлкем, тагын бер кайтырсыз. Монда, ичмасам, нигезегез сакланыр. Кайтмыйсыз икән, сатып та була бит аны.

Моңа каршы Мостафин бер сүз дә әйтмәде — ул уйга калган иде. Бу сөйләшү ни белән бетәр икән дип, әле әнисенә, әле Шакирына, әле әтисенә сабырсызланып карап утырган Наҗия, кинәт кулларын чабып, кычкырып ук җибәрде:

— Их, үзебезнең йорт булса, мин аны курчак өе кебек итеп тотар идем!

Бар да аңа елмаеп карадылар.

Шул кичтән соң йорт мәсьәләсе Мостафинның башыннан чыкмас булды. Кат-кат уйланды ул бу турыда. Дөрес, башта ул бу мәсьәләгә әһәмият бирмәскә тырышты, булмас нәрсә турында нигә баш ватарга, дип кул да селтәмәкче булды... Ләкин ихтыярыннан тыш диярлек йорт салдыру уе һаман әйләнеп килә торды, килгән саен аны ныграк били барды. Эштә утырганда да, юл йөргәндә дә, хәтта бюро утырышы барган чакларда да ул, онытылып, шул уйга бирелеп китә иде.

Элек һич кенә бер күңеленә килмәгән мондый уй нигә бу кадәр аның акылын биләп алды соң? Моның сәбәпчесе, билгеле, Нәҗия иде. Сер түгел, яшь хатынның дәртен, энергиясен кая куярга белмәве Мостафинны соңгы вакытларда бик борчый иде. Үзе көн-төн эшләгәч, аңа эшсез яткан хатынын назлау да көйләү торган саен авырга килә башлады. Нәрсә белән генә моны мавыктырырга соң дип, ул еш кына баш вата иде. Укырга ихласы юк, иренең эше белән кызыксынмый, кул эше дә тотмый, ичмасам, бар белгәне — өстәл яны да йомшак урын өсте. Болай дәвам итсә бит, Алла сакласын, бөтенләй байбикәгә әйләнеп китәр...

Юк, ярамый болай, ничек тә аны бер тәртә арасына кертергә кирәк иде. Вакыт-вакыт Мостафинның, әллә яңадан эшкә кертергәме икән, дип уйлаган чаклары да булгалады. Ләкин ул турыда сүз кузгатырга көче җитмәде; бердән, Нәҗияне күндерә алуына ышанмады (Нәҗия үзе бит эшсезлектән зарланмый), икенчедән... ничектер, үзенең дә күңеле тартмый иде; һәр җирдә мут ирләр була, Нәҗия хискә тиз бирелүчән... юк, кирәкми!

Ә йорт дигәндә үзе үк әнә ничек очынып тора. Ихтимал, аның үзе теләп җигеләсе килгән тәртә — шул йорт-хуҗалыктыр; ихтимал, әнисе кебек йорт җанлы уңган хозяйка булыр. Һәрхәлдә, йортка бәйләнсә, аның эше дә, мәшәкате дә бермә-бер артыр иде, тормышка җитдирәк карый башлар иде, вакыты, игътибары күбрәк дөнья эшенә китәр иде.

Чыннан да, начар булмас иде бу: ак бүрәнәдән чибәр генә өй, яңа капка, яңа койма, ишегалды яшел чирәм, түрдә ак мунча. Шул җиткән. Артык зур, купшы түгел, әмма пөхтә-җыйнак — сөеп кенә торырлык. Менә шул якты дөньяга елмаеп караган өйдә аның Нәҗиясе! Сыерчык үзенең оясында! Сайра, талпын, оч! Әйе, ул тора белер иде. Майпәрвәз кызы бит, җитезлеге дә, уңганлыгы да бар. Берәр сыер да алып бирергә була, әйдә, тулы нагрузка белән эшләсен. Аннан тора-бара өй артын рәшәткәләп, бакча да утыртып җибәрергә булыр. Бусы

инде аның үзе өчен юаныч, шунда казынып, арыган башын ял иттерер иде.

...Бик мавыктыргыч иде бу хыял, әмма шулай да Мостафинны нидер тота, күңеле ул эшкә ничектер бик тартмый, шуңа күрә тәгаен бер карарга килү аның өчен кыен иде. Болай, формаль яктан, тыеп торырлык сәбәп тә юк, киресенчә, йорт салдыру һәркемгә, шул исәптән коммунистка да, рөхсәт ителә, дәүләт үзе аны куәтләп тора, акчасын бирә, материалын бирә. Ләкин... йорт хуҗасы булу аңа килешерме? Халык ни дияр? Райком секретаре, Байгузиннар кызына өйләнгәч, йорт та салдырып җибәрде, дип сөйләмәсләрме? Халыкның бертөрлесе аның хәлендәге кешенең гайбәтен сөйләргә ярата бит ул.

Ә бабайларга барган саен бөтен сүз шул йорт тирәсендә генә әйләнә торган иде. Мостафин аларга шикләрен әйтеп бетерми иде бетерүен, шулай да Майпәрвәз ханым сизенә иде булса кирәк... Еш кына ул башын чайкап:

— Шакир! Шакир! — ди иде.— Бу нинди кыюсызлык сездә? Йә, нәрсә тота сезне, нидән куркасыз?

— Бик мәшәкатьле эш бит,— ди Мостафин, башка ни әйтергә белмичә.— Күпме вакыт әрәм итәргә кирәк аңа...

Идият абзый авторитетлы рәвештә белдерә:

— Тәвәккәлләп тотынганда әллә кая китми, бер җәйдә өлгертеп була.

— Материалын табу да хәзер бик читендер инде...

— Эш аңардан тукталып тормас, табылыр, шаять.

Майпәрвәз ханым шунда ук иренең сүзләрен куәтләп өсти:

— Син, Шакир, бер дә борчылма, без барында сиңа әллә ни мәшәкатьләнергә туры килмәс. Тик син үзеңә участок сора да ссуда гына ал, калган ягын менә бабаң карар.

— Анысы шулай,— дип кенә куя Мостафин.

Ә бабайның күз тотып йөргән участогы да бар икән инде. Ударник урамында, Сабирларны узгач, МТМга җитмәс борын бер буш аралык бар, имеш, бик тыныч, аулак урын, ди. Ләкин Нәҗия шунда ук кызып әтисенә каршы төшә: тапкансың урын, үзе читтә, үзе МТМ күршесе, машина тавышыннан колагың тонып бетәр анда... Юк, кирәкми, кирәкми, гомергә барачак түгел андый җиргә. Булса, нәкъ центрда, йә Карл Маркс, йә Ленин урамында булсын... Әтисе йомшак кына: «Ул тирәләрдә буш урын табылмас шул, кызым»,— дигәч, Нәҗия кырт кисә:

— Шакир сорагач, табып бирерләр!

Аннан Идият абзый әйтә: күрше районндагы Бәдрәш

авылында алты почмаклы бер бура сатыла икән. Теге «Заготживсырье» агенты аксак Басарый күреп кайткан, эре бүрәнәдән, бик таза бура, ди. Менә шуны да белешеп карыйсы иде. Әзер бура арзанга да төшә, эше дә тизрәк була... Гомумән, тәвәккәлләгәндә мәсьәләне озакка сузарга ярамый, язга чыккач та салдыра башлау өчен, хәзердән үк хәстәренә керешергә кирәк.

Бу сөйләшүләр нәтиҗәсендә Мостафин үзе дә йорт салдыру мәсьәләсен хәл кылынып беткән шикелле тоя башлый иде. Җитмәсә, кич кайтып яткач, Нажия аның муенына сарылып гөрләргә тотына: үз өйләре булгач, алар нинди рәхәт торырлар, тыныч булыр, иркен булыр, матур булыр. Шундый тәрбияләп торыр ул үз өйләрен, кергән кешенең кире чыгасы килмәс...

Инде Мостафин йорт салдыруның үзе өчен уңайсыз, килешмәгән якларын әйтә башласа, Нажия, аның сүзен бүлеп, кызып та китә иде:

— Куркак син, куян йөрәк! Әнә Сәйфуллин абзый да коммунист, салды да керде. Килеп куган кеше юк әле үзен!

Хатын-кыз белән сүз көрәштерүе бик авыр бит ул. Аның һәрвакытта үз кырыгы кырык... Ахырда Мостафин сабырлыгын җуеп катырак әйтә башласа, Нажия аның култык астына башын төртеп, ачы күз яшьләре белән еларга да тотына: «Син мине яратмыйсың, имеш, син әти-әниләремне дә яратмыйсың, син беркемне дә яратмыйсың, син бары үзең турында гына уйлыйсың...»

Һай, бу яшь хатынның күз яше! Бер күрмәс өчен өй түгел, сарай вәгъдә итәрсең!

Нажиянең бер юмаланып, бер дулап бу кадәр бәйләнүенең төп серен Мостафин, әлбәттә, белми иде. Карлыгачымның хыялына матур оя кереп утырган, шуңа күрә өзми дә куймый,дип кенә уйлый иде ул. Асылда исә кеч-кенә «карлыгач» шактый олы карчыганың җырын җырлый иде; йорт салдыру мәсьәләсе кузгалгач та, Майпәрвәз ханым кызының колагына бик нык киртеп куйды:

— Нажия, сезнең йортыгыз булырга тиеш. Шакир өчен кирәкмәсә, синең өчен кирәк ул. Дөнья хәлен белеп булмый, үлем бар, җитем бар, Аллам сакласын, аерылышып китү бар. Ләкин ни генә булмасын, син йортлы-нигезле булып калырга тиешсең. Шуны бик нык исеңдә тот, Шакирыңны, ай-ваена куймыйча, күндер!

Шулай да Мостафин тиз генә күнәргә ашыкмады. Бабасы-әбисенең яхшы ният белән димләүләренә ышанасы килсә дә һәм аларның дәлилләрен бер яктан хаклы дип тапса да, ул соңгы сүзен әйтергә һаман җөрьәт итә

алмый иде. Ул, әлбәттә, алар хәле белән үз хәленең бер түгеллеген, аларга яраган эшнең үзенә бик үк ярап бетмәвен аңлый иде. Шуңа күрә аның чит, битараф, әмма ышанычлы бер кеше белән киңәш итеп карыйсы килә иде. Ләкин андый кеше кем булырга мөмкин? «Читләр», «битарафлар» күп, ә менә «ышанычлы» кешесе бөтенләй юк аның... Бирегә күчеп килгәч тә Байгузиннарга бәйләнеп китү аркасында ул, ничектер, берәү белән дә якынаерга да, дуслашырга да өлгерми калды. «Наҗия дөньясы» аны берьюлы шундый йотты, дус-ишләр булдыру теләге аңарда хәтта тумады да... Яңа җирдәге кешеләр белән эш буенча бары формаль мөнәсәбәт кенә урнашты. Бу формаль мөнәсәбәт буенча үзеннән түбәннәр бар, үзе белән бер баскычтарак торганнар бар (мәсәлән, РИК председателе, МВД начальнигы, район прокуроры), ниһаять, югарырак торган бердәнбер кеше — райкомның беренче секретаре иптәш Андреев бар. Формаль мөнәсәбәт, түбәннәр белән вакланма, ди, тиңнәргә сер сынатудан тыя, өстен белән сак булырга куша. Әйе, бик читен мондый хәлдә эчке шик-уйларыңны кемгә дә булса ачу.

Шулай да ул, райисполком председателе Сәйфуллин белән бер очрашканда, ничектер, уйламастан гына йорт турында сүз кузгатты. Сәйфуллин, йомышын йомышлап, чыгып китәргә дип урыныннан торган иде инде, шул чакта Мостафин аңа кисәк кенә дәште:

— Да, сездән шуны сорамакчы идем...— Һәм тукталып калды.

— Нәрсә турында? — диде Сәйфуллин.

— Болай, личный бер мәсьәлә турында гына,— диде Мостафин, мөмкин кадәр ваемсыз күренергә тырышып.— Бер куыш корып җибәрергә исәп бар иде дә, тик мәшәкате бик күптер дип куркыбрак торам. Сезнең ул эштә тәҗрибәгез бар, ничегрәк булыр икән?

Сәйфуллин, чыннан да тәҗрибәле кеше, сүзнең нәрсә турында барганын шунда ук аңлады һәм төпченеп сорашып та тормады.

— Давай, давай, бик әйбәт булыр,— диде ул, күн перчаткаларын кия-кия.— Үзебез булышырбыз. Ссуда алмадыңмы әле?

— Юк әле.

— Нигә сузасың?

Мостафин «ык-мык» итебрәк торды:

— Әллә ничегрәк шунда... стоит микән дим?

— Һи, юләр, шикләнеп торасың тагы! Менә мин бер дә стоит микән дип тормадым, салдырдым да кердем. Ә нигә кермәскә, кирәк булгач?.. Миндә менә ревматизм,

колхозлардан йөреп кайткан саен мунча яктырам да аякларны эт итеп чабам. Үземнеке булмаса, нишләр идем? Безнең өчен бит йорт — байлык түгел, ә торыр бер урын гына... Менә дәүләт, кулы җитеп, район җирләрендә дә коммуналь йортлар, мунчалар салдыра башлагач, кетәкләрне үзебез үк местный советларга бушлай бирербез... Шулай түгелме?

— Әлбәттә... шулай! — диде Мостафин, үзалдына әйткәндәй уйланып.

— Шулай булгач, нечево икеләнеп торырга! Наше — ваше, вәссәлам! Хуш!

— Хуш!

Сәйфуллин, галош белән кара чесанка кигән аякларына кыек-мыек басып, ашыгып чыгып киткәч, Мостафин, урыныннан торып, әрле-бирле йөрергә тотынды. Әйе, диде ул үз-үзенә, кешеләр мәсьәләгә ничек гади карыйлар, тормышча карыйлар... Күрәсең, шулай карарга кирәктер дә, фәлсәфәдән баш кына тала, ә мәгънә чыкмый, башка болай да эш күп.

Үзе кебек үк җаваплы эшченең һәм коммунистның шулай куәтләп һәм дәртләндереп чыгып китүе аңа үз вөҗданы алдында аклану өчен җитә калды. Хәтта ялгышкан тәкъдирдә дә әллә ни зур куркыныч юк, дип уйлады ул, чөнки андый гына ялгышны һәрвакытта төзәтеп булачак.

...Тагын нәкъ соңгы минутта, әллә каян гына килеп, мондый уй да аның башыннан чагылып узды: кем белә, бәлкем, партия эшендә гомер буе утырып та булмас. Китәргә, бүтән эшкә күчәргә туры килер. Ул чакта инде берәү дә аңа «йорт хуҗасы» дип бәйләнә алмас. Мондагы күп кенә совет, хуҗалык эшчеләре кебек үз өендә тыныч кына тора бирер.

Ниһаять, Мостафин бөтен шикләрен әнә шулай көчләнеп җиңеп булса да ниятләде.

Наҗия ул кичне әйтеп бетергесез бәхетле иде. Юк сылтауны бар итеп, тиз генә әниләренә барып сөенче дә алып кайтты. Майпәрвәз ханым, исе китмичә горур гына:

— Кияүнең риза буласын мин алдан ук белеп тордым, — диде.

## VI

Берничә айлар үткәч, Мостафинга шулай да райкомның беренче секретаре Андреев белән сөйләшергә туры килде. Сүзне Андреев үзе кузгатты. Халык арасына таралган Мостафинның йорт салдыру хәбәре, ниһаять, аңа

да килеп җиткән иде. Ул бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмәде, гаҗәпләнде һәм, мәсьәлә шактый җитди булганга күрә, Мостафин белән иптәшләрчә сөйләшеп карарга булды.

Кичләрнең берендә, бюро утырышыннан соң, Андреев Мостафинга калып торырга кушты. Түгәрәк галанка мичле бөркү кабинет халыктан бушап калгач, Андреев, урыныннан торып, тәрәзә форточкасын барып ачты. Тыштан март аеның салкын, ләкин яз дымы аңкыган һавасы кызу гына агып керә башлады. Андреев тәрәзәдән тайпылды да, кулларын артка куеп, ашыкмыйча гына ишекле-түрле йөрергә тотынды. Бу кечерәк буйлы, юка гәүдәле, ак чырайлы, зур пеләш башлы бер кеше иде. Өстендә аның кара костюм, ак яка, кара-күк галстук, ә аякларында җыйнак кына кара киез итекләр иде. Мостафин, йомшак аркалы киң диванда кырын ята биреп, аның сүз башлаганын көтә иде.

Андреев бүлмә буйлап сүзсез генә берничә әйләнде дә йөрүеннән туктамыйча:

— Сез, Шакир Сабирович, яшерен кеше икәнсез,— диде.— Уйламаган идем.

Андреев моны һич үпкә сиздермичә гади генә итеп әйтсә дә, Мостафин шунда ук сагаеп калды. Ул тураебрак утырды.

— Аңламыйм, Андрей Петрович, ни өчен алай дисез?

— ...Кешеләрдән ишеткәч, әллә ничек уңайсыз булып китте,— диде Андреев, аның соравына игътибар итмичә.— Көн-төн бергә эшлибез үзебез! Мин әйткән булыр идем.

Мостафин беренче секретарьның нәрсә турында болай зарлануын, ниһаять, аңлап алды, ләкин тагы да гаҗәпләнә төшеп сораган булды:

— Ачык кына әйтегез әле, Андрей Петрович, нәрсәне мин сездән яшергәнмен?

— Йорт салдыруыгызны...

— Ах, әнә нәрсә!..— Мостафин, башын артка чөеп, кыска гына көлеп алды.— Ышаныгыз, һич яшерү түгел бу... Просто ул эшкә артык әһәмият бирмәүдән генә әйтеп тормаганмындыр...

— Ләкин дөрестер бит!

— Дөрес, Андрей Петрович!

— Әһәмият бирмәслек эш түгел бу,— диде Андреев, аннан ни өчендер көрсенеп, өстәп куйды: — Что ж, уңыш телим!

— Рәхмәт, Андрей Петрович!

Андреев тагын сүзсез генә берничә әйләнде дә өстәл

башына барып туктады. Кашларын җыера төшеп, бераз уйланып торды.

— Шулай да... мин аңлап җиткермим, ни өчен сезгә йорт салдыру кирәк булды?

Мостафин сорау белән җавап бирде:

— Нигә, йорт салдыру гаеп эшмени?

— Нишләп гаеп эш булсын! Сүз ул турыда бармый... Мин әйтәм, менә сез, сез нинди исәптән чыгып йорт салдырырга булдыгыз?

Мостафин иңбашларын җыерып куйды:

— Кызык сорау!.. Торыр өчен кирәк булганга күрә салдырам — менә шул! Бик законлы эш ич!

— Әйе, законлы эш,— диде Андреев, ялангач маңгаен ышкып.— Формаль яктан сез хаклы. Шулай да...

— Нәрсә шулай да?

— ...Аңлап җиткермим. Мин үзем, мәсәлән, йорт салдырмас идем.

— Ни өчен?

— Ничек кенә дип әйтергә сезгә... Безнең положениедә йорт хуҗасы булу бер дә килешми, минемчә...

Мостафин көлүгә охшаган сәер бер тавыш чыгарып куйды:

— Һе-һе. Бик четерекле кеше икәнсез сез, Андрей Петрович. Ни өчен килешми? Безнең дә адәм рәтле шартларда яшәргә хакыбыз юкмыни?

— Ник булмасын, бар, бар!

— Шулай булгач?

Андреев дәшмәде, тагын бүлмә буйлап йөреп китте. Ул бу турыда сүз кузгатуына үкенә дә башлады. Мәсьәлә ачык: Мостафин ул уйлаганча уйламый, ул тойганны тоймый. Димәк, сүз әрәм итеп торуның кирәге дә юк. Алар һәр яктан бер дәрәҗәдәге кешеләр, үгетләп тә агитлап маташу бик урынсыз булыр иде, хәтта алай итеп кешенең хәтерен генә калдырырга мөмкин... Анысы шулай, ләкин сүз кузгалган икән инде, ул, һәрхәлдә, үз фикерен әйтеп бетерергә тиеш. Тыңлыймы, тыңламыймы — ул кадәресе аның эше.

Һәм Андреев аяк астына карап йөри-йөри яңадан сүз башлады:

— Мин ул эшнең, ягъни йорт салдыруның, ике төрле куркыныч ягын күрәм. Аңлагыз, сүз менә безнең турыда — партия работниклары турында бара... Так. Беренчедән, йорт ул — шәхси милек... Шәхси милекнең нәрсә икәнен үзегез дә яхшы беләсез. Тик шуны гына исегезгә төшерәсем килә: партия эшендәге кайбер иптәшләрнең политик сөртенүләре һәм мораль сафлыкларын

югалтулары күп кенә очракта әнә шул шәхси милек коллыгына төшүләреннән килеп чыга. Моның мисаллары сезгә билгеле булырга тиеш... Икенчедән, үз көнкүреше белән артык мавыгып киткән кеше халык ихтыяҗын күрми башлый. Ягъни, әлеге мәшһүр язучы төсле, үзен халыктан зәңгәр койма белән аерып куюы бар. Ә халыкның ихтыяҗы...

— Фәлсәфә болар бар да, Андрей Петрович,— диде Мостафин, аның сүзен бүлеп.— Борчылмагыз, сез әйткән куркынычлар булмас алар...

Андреевның йөзенә кинәт кызыллык йөгерде — Мостафинның тыңлап бетермичә каршы төшүе аның хәтерен калдырды булса кирәк.

— Нигә фәлсәфәдән куркасыз? — диде ул, коры гына.—Безгә ара-тирә фәлсәфәләшеп алырга да ярый, минемчә.

— Объект бик кечкенә, Андрей Петрович, зур фәлсәфә күтәрә алырлык түгел.

— Шулай дисезме?.. Алайса, гафу итегез, минем бүтән әйтер сүзем юк.

Андреев үз урынына барып утырды. Алар арасында бер мәлгә уңайсыз тынлык урнашты. Аларның икесенә дә авыр иде, чөнки алар арасында чын дуслык юк, шуңа күрә дусларча «йөрәктән йөрәккә» сөйләшү булмады, ә коры, формаль сөйләшүдән бер-берсенә бары хәтерләре генә калды.

Аз гына тынып утырганнан соң, Мостафин урыныннан торды; арадагы ямьсез киеренкелекне бераз йомшартырга теләп булса кирәк, гадәттәгечә:

— Кайтабызмы? — диде.

Андреев көттереп җавап бирде:

— Юк, мин калам әле.

Юл буенча Мостафинның Андреевка ачуы килеп кайтты. Гаҗәп кеше дигәнең! Башта, нинди карарга килергә белмичә шикләнеп йөргән чакларында, Андреевның әйткәннәре теге яки бу рәвештә Мостафин күңеленә килгәләгән иде. Фәлсәфә булып түгел, ә шактый конкрет формада: «Миңа, райком секретарена, йорт хуҗасы булу килешерме? Халык ни әйтер?» — дигән шик булып аның җанын борчыган иде. Хәзер исә ул, кайнарланып, Андреевка каршы эченнән бәхәс алып бара: кемгә саный ул мине, кемгә саный? Шәхси милек, имеш! Әйтерсең сүз ташпулат салдыру турында бара. Әнә прокурор Измайлов, авыру үпкәсенә кымыз кирәк булгач, кәҗә асрый. Тоже шәхси милек! Бичара кәҗә прокурорның мораль сафлыгын кимереп бетермәс микән?

Аннан халык ихтыяҗын оныту, имеш, халыктан зәңгәр койма белән аерылу, имеш! Гүя минем ихтыяҗым — ихтыяҗ түгел, гүя мин халык дип кетәктә торырга тиешмен! Нинди тузга язмаган «фәлсәфә»! Дөньяны китаптан укып таныган, тормыш күрмәгән кешенең генә болай уйлавы мөмкин бит. Хәер, гомергә шәһәрдә, үзенең английский йозак белән бикләнә торган квартирасыннан чыкмыйча яшәгән кеше тормышны каян белсен ди ул?

...Әйе, Мостафинның, дөресен генә әйткәндә, мондый кайнар бәхәс алып бармыйча хәле юк иде. Ссуда алынган, бура сатып алынган, халык арасына сүз чыккан, инде чигенеп булмаячак. Димәк, хәзер аңа үз намусы алдында да, кешеләр алдында ничектер акланырга кирәк иде.

Май бәйрәме үтеп киткәч тә, Мостафинның булачак ихатасына (участокны аңа ике зур урам арасындагы ташташ чирәм белән капланган кыска тыкрыктан бирделәр; урын бик әйбәт, үзе үзәктә диярлек, үзе аулак җирдә) колхоздан дүрт оста килде һәм, балталарын кояшта уйнатып, эшкә дә тотындылар. Хәерле сәгатьтә!

Баштарак осталар янына Мостафин үзе килеп-китеп йөрде. Ләкин килгән саен нинди дә булса мәшәкать чыга, анысын-монысын табарга кирәк була, шалтыратырга, сорарга, кушарга туры килә, кыскасы, бәләкәй генә төзелеш шактый вакыт һәм игътибарны ала иде. Бу өй мәшәкатенә тарыгып йөрүнең кайчан вак-төяк күңелсезлекләр китереп чыгарган чаклары да булды.

...Бервакытны шулай осталар белән нидер сөйләшеп торган Мостафин янына «Үрнәк» колхозының партоешма секретаре килеп туктады. Йодрыгын авызына китереп, бер тамак кырып алгач ул:

— Иптәш Мостафин, сез мине кабул итмәссез микән? —дип дәште.

Мостафин, аны-моны уйламыйча: «Ярар, кабул итәрмен»,— диде дә осталары белән һаман сөйләшә бирде. Килгән иптәш исә, кулларын артка куеп, аның янында сабыр гына басып тора башлады. Бераздан, артына борылып карагач кына, Мостафин көтеп торучыны «кабул итәр өчен» иң элек кабинетына кайтып утырырга тиеш булуын аңлап алды. Шактый уңайсызланып һәм, ни өчендер, үзенә генә түгел, басып торган иптәшкә дә ачуы килеп, аны райкомга ияртеп алып китте.

Шушының кебек, райком секретарен салынып яткан йорт тирәсеннән эзләп йөрүләр булгалый башлагач, Мостафин осталар янында күп чуалудан туктады. Һәм йортны салдыру эшен тулысынча бабасына тапшырды.

Аның каравы, Нәҗия көненә берничә тапкыр осталар янына очып килеп җитә иде. Чирәмдә аунап яткан бүрәнәләр өстендә ул, кыр кәҗәседәй, сикеренеп йөри иде. Башта осталар аңа сокланып бетә алмадылар; нинди чибәр ул, нинди сылу, аяклары нинди төз аның! Бигрәк тә осталарның берсе, күптән түгел армиядән кайткан кара егет, Нәҗиядән күзен ала алмый иде. Торып-торып авыр сулый ул, йөрәгенә капкан уттан котылырга теләгәндәй, бөдрә башын чайкап-чайкап куя, ә вакыт-вакыт уйга төшеп, бөтенләй онытылып китә. Өметсез сагыш һәм яшерен дәрт белән тулы күзләре аның гүя: «Дөньяда нинди бәхетле кешеләр бар! Шулар кебек тапсаң иде, алсаң иде шушындый бер кызны!» — дип әйтеп тора иде.

Иптәшләре егеттән көләләр, еш кына аңа: «Кара, егет, сиңа болай исерергә ярамый, кулыңда үткен балта барын онытма, аягыңны «тәп» иттереп алдың булыр, сизми дә калырсың!» — диләр иде. Ә егет аяныч хәлен иптәшләреннән яшерә дә алмый, комачтай кызара да, учларына кат-кат төкереп, бүрәнәсен ярсып-ярсып юнарга тотына. Үзе әледән-әле: «Их, и-их!» — дип уфтана.

— Да, брат, хатын бу! — ди осталарның берсе.— Мондый хатын өчен пыяладан сарай салдырсаң да жәл түгел!

Шулай да бераз вакыттан соң Нәҗиянең килеп йөрүе осталарга ошамый башлады. Егет кызганыч, аннан болай да... әллә ничек. Нигә ул бертуктаусыз такылдап, кыска итәкләрен җилфердәтеп күз алдында әйләнә? Эшләргә кирәк ләбаса!

«Өй салуның ние бар, мүклисе дә чутлыйсы»,— дип җибәрәләр кайчакта. Идият абзый өчен бу, әлбәттә, алай түгел иде. Өй салдыруның, бигрәк тә хәзерге шартларда, никадәр катлаулы эш булуын ул бик яхшы белә иде. Бер җәйдә йорт бетереп керү өчен Идият абзыйның тәҗрибәсе, осталыгы, зур элемтәсе һәм киявенең исеме, дәрәҗәсе кирәк иде. Идият абзый бөтен осталыгын җикте, хуҗалык оешмаларында, колхозларда булган барлык эшнәлек җепләрен хәрәкәткә китерде, ә Мостафинның, үзе читтә торса да, һәр җирдә исеме алдан йөрде.

...Алты почмаклы зур бурага яңадан егерме дүрт эре бүрәнә кирәк булды: Идият абзый леспромхоз директоры белән сөйләште, Мостафин өчен икәнлеген аңлатты... һәм егерме дүрт бүрәнәне яңа бура каршына, яшел чирәмгә китереп аудардылар. Түбә калае бу тирәләрдә көндез шәм яндырып эзләсәң дә табыла торган нәрсә түгел иде. Аны, имеш, Ижевскига барып кына табарга була. Ләкин, бәхеттән, Мәскәү наряды белән каяндыр «Заготзерно»ның яңа салынып яткан складлары өчен калай килә. «Моста-

фин өчен» дигәч, бер өйне ябарлык кына калайны арттырып бирәләр. Кирпеч, пыяла, кадак кебек нәрсәләрнең дә җитмәгән кадәресе, сөйләшә белгәч, теге яки бу оешмалардан табыла. Сез белмәгән башыгыз белән тагын: «бу дәүләтне талау бит», дип уйлый күрмәгез. Бар да шундый законга туры китереп, шундый шома эшләнә ки, рус әйтмешли, черки борынын да тыга алмас...

Аннан шуны да онытмагыз: Мостафин бабасына әледән-әле: «Кара аны, бабай, андый-мондый законсыз эш булмасын!» — дип әйтә торды. Аның теләге йортын ничек тә хәрәмсез генә, соңыннан сүз булмаслык итеп салдыру иде. Идият абзый мондый кисәтүләрне ишеткәндә җилкәсен кашыды, тамагын кырды, авыз эченнән генә: «Борчылма, кияү!» — диде һәм «кайбер сулагай эшләрне» киявеннән яшереп тә калдырды. Дөресен генә әйткәндә, ул киявенең кисәтүләрен бик үк чынга да алып бетермәде. Нишләп чынга алсын ди, кияү ахмак түгел ич, белә ич ул йортының түбәсен кәгазь белән ябып булмасын, инде әйтә икән, соңыннан алай-болай сүз чыкса, «мин кушмаган идем», дип акланыр өчен генә әйтә ич ул. Зарар юк, Идият абзый түгел, ул кереп утырасы йорт әле. Салдыра белгәч, җавабын да бирә белер.

Шулай да йортны салу, кайбер материаллар табылмый тору аркасында, шактый озакка сузылды. Бары август башларында гына ул салынып бетте. Ләкин нинди йорт булып чыкты! Күрегез, таш фундамент өстендә эре ак бүрәнәдән алты почмаклы өй тора. Түбәсен яңа калай белән япкан, тик әле буялып өлгермәгән. Урамга дүрт тәрәзәсе карый. Тәрәзәләрнең әйләнәсе һәм башлары нәфис, матур итеп, бизәкләп эшләнгән. Зур итеп, кыеклап эшләнгән капканың кечкенәсеннән керүгә, таш түшәлгән юл туп-туры өч баскычлы болдырның ике якка ачылмалы ишегенә илтә. Болдыр үзе веранда сыман итеп эшләнгән, ягъни йорт алдына караган стенасына аның тоташ челтәр тәрәзә куелган... Әйтәсе дә юк, өй таза, чибәр, урамына бер!

...Инде шушы, «күрегез мине!» дигәндәй, әллә кайдан ук балкып торган өйне Мостафин, хуҗа буларак, килеп карагач, башта үзе дә аңлый алмаслык бер хәл кичерде; ул... куана алмады, ул бу өйгә һич катнашы булмаган чит кешедәй салкын булып калды... Өйнең бусагасыннан ул ниндидер бер кыенсыну тоеп, башын түбән иеп керде. Нәрсә булды аңа? Әллә осталарның: «Йә, хуҗа, рәхим ит, менә нинди өй салып бирдек без сиңа!» — дип әйтеп торган ялагай кыяфәтләреннән ул шулай уңайсызланып киттеме? Әллә бабасы Идият аб-

зыйның, нәкъ борынгы байгуралардай, өй болдырында горур басып торуы аның гайрәтен чигереп җибәрдеме — әйтүе читен иде.

Әмма Наҗиянең шатлыгы баштан ашкан иде. Сыңар аягында сикерә яшь ханым! Мостафинның кинәт аңа ачуы килеп китте. «Кем башына очына бу кадәр?» — диде ул эченнән, ярсып. Һәм Наҗиянең ташып барган шатлыгын бозасы, аны рәнҗетәсе, елатасы килде... Үзенең шушы аңлашылмас әшәке хәлен кешеләргә сиздермәс өчен, ул өйне аннан-моннан гына караштырды да: «Бүгенгә вакытым юк, иртәгә сөйләшербез»,— дип китеп тә барды.

Осталар кул сыртлары белән авызларын сыпырып калдылар; хуҗадан берәр чәшкә өмет иткәннәр иде алар... булмады бүгенгә.

Шул ук көнне кичен Мостафин ялгызы гына яңадан өен карарга килде. Әлеге көндезге әшәке настроение аңарда юк иде инде. Ашыкмыйча, озак кына ул өенең эчентышын карап чыкты. Әйтергә кирәк, яратты ул өен, чибәр, таза булуына сөенде, һәм, ничектер, якын итеп, кадерле итеп тойды ул аны... Бөтенләй үк борчылудан арынмаган, шул ук вакытта мавыктыргыч та, матур да булган хыялларга бирелеп, Наҗиясе янына кайтып китте.

Өйнең мичен чыгарып, идәнен, ишек-тәрәзәләрен буяп киптергәч, алар өченче сентябрьдә яңа йортка күчтеләр. Майпәрвәз ханым бу күченүнең бөтен йоласын җиренә җиткерергә тырышты: имеш, яңа йортка күчкәндә урамда кеше-фәлән очрамаска тиеш. Шуңа күрә ул кияве белән кызын караңгылы-яктылы урыннарыннан торгызды. Райком кучере Галәви атын җигеп килеп җиткән иде инде. Аның арбасына вак-төяк җиңел әйберләрне салып, халык торып урамга чыкканчы, тиз генә яңа йортка киттеләр. Килеп җиткәч, иң элек Майпәрвәз ханым үзе, киҗеле ашъяулык өстенә бер бөтен икмәк куеп һәм бер уч тоз салып, яңа өйнең бусагасыннан атлап керде.

— Ашлы-сулы булсын бу өйдә гомер итүчеләрнең тормышы! — диде ул, аз гына калтыранган тавыш белән бик тантаналы итеп.

Аннан инде «Районара йомырка базасының» машинасы белән калган җиһазларны ташып куйдылар. Ул көнне күчену-урнашу мәшәкате күп булды, бар да арыдылар, ләкин, шуңа карамастан Идият абзый белән Майпәрвәз ханым кичен тагын бер тавык, бер әтәч, бер чирек сөт һәм бөтен икмәк күтәреп, өйне котлый килделәр.

Шулай итеп, Мостафиннар өчен яңа өйдә яңа тормыш башланды. Тыныч, бәхетле, мул тормыш булырга тиеш

иде бу... Ләкин Мостафин үзе тынычланырга ашыкмады — гайбәтләр, сүзләр көтте ул. Бәлкем, Андреев та яңадан сүз кузгатыр, дип борчылып йөрде. Әмма өйне котлап кулын кысучылар булгаласа да, халык арасында йөргән гайбәтләрне килеп әйтүче булмады. Андреев та сүзсез иде, ягъни эштән башка бүтән нәрсә турында сөйләшми иде. Шулай да алар арасына кара күләгә ятты шикелле, Мостафин шулайрак сизә, ләкин мөнәсәбәтләре хәзергә искечә бара.

...Акрынлап күңеле үз урынына утыргач, Мостафин шул ук көзне бабасы симертеп суйган атның яртысына пай кертеп, аңа да кушылды.

## VII

Кайчак кешегә үз хәлен аңлау өчен кечкенә бер сәбәп тә җитә кала... Эш болай булды. Былтыр җәен Мостафин үзенең таза машинасында «Кызыл яр» колхозына барып чыкты. Нәкъ печән өсте иде. Колхоз председателен табып, аның белән икәү бер атта печән чабучылар янына киттеләр. Колхозның болыны авылдан дүрт-биш километр түбәндә, ике кечерәк елга тамагында иде. Алар барып җиткәндә, тугайда бер төркем хатын-кызлар аллыартлы тезелешеп, ирләрдәй аякларын аера төшеп һәм нык басып, бар да бер көйгә салмак кына селтәнеп, печән чабалар иде. Мостафин белән председатель атларын бер ялгыз каен төбенә бәйләп калдырдылар да шул чабучыларга таба киттеләр. Алдан чабып килүче урта яшьләрдәге таза, базык кына апай янына җитеп туктагач, апай соңгы тапкыр селтәнеп,куе үләнне чышлатып покоска егып салды да, тураеп, чалгысын сабы белән җиргә терәде һәм уң беләге белән тиргә баткан кара маңгаен сыпырып алды. Аннан Мостафинга карап: «Хуш килдегез!» — дигән төсле юмарт итеп бер елмайды:

— Эшләрегез уң булсын! — диде Мостафин.

— Рәхмәт, шулай булсын! — диде апай, батыр гына.

Шул арада башка чабучылар да, эшләреннән туктап, бер-бер артлы алар янына килә башладылар. Бар да кара янганнар, бер генә кат күлмәкләре тирдән чыланып аркаларына, иңбашларына ябышкан, киң ыштан балакларының берсен оек өстеннән төшереп салганнар, ә икенчесен оек эченә тыгып, шунда кайракларын кыстырганнар. Аларның күбесе урта яшьтәге апайлар иде, калганнары — җиткән кызлар һәм яшь киленнәр булырга тиеш. Ләкин араларында буйга кечкенә биш-алты үсмер кыз да бар иде.

Ундүрт-унбиш яшьтән дә артык биреп булмас үзләренә, ә шулай да чалгы күтәргән булганнар... Ләкин ник бер ир кеше булсын! Мостафин бу хәлгә бик гаҗәпләнде.

— Ирләрдән берәү дә юкмыни? — дип сорады ул.

Әлеге таза апай, бары күзләре белән хәйләкәр елмаеп:

— Чайкап эчәргә генә бер иребез бар,— диде.

— Кайда соң ул?

— Әле яңарак кына су буена бәрәңге юарга төшеп киткән иде.

— Нигә ул төшә, аның эшемени ул бәрәңге юу?

— Без аны аш пешерүче итеп куйдык,— диде икенче бер яшьрәк хатын.

Мостафин ни әйтергә белмичә башын чайкап торды, ә кызчыклар бер-берсенең артына яшеренеп, шырык-шырык көлешеп алдылар. Чыннан да кызык ич! Апайлар исә, «шулай, иптәш секретарь» дигән төсле, аңа турыкыю карап, сүзсез генә торалар.

Мостафин колхоз председателенә, моны ничек аңларга дип, усал гына карап алды. Председатель, күптән инде һәртөрле шелтәдән каешланып беткән утызлар тирәсендәге егет, бик өлгер җавап бирде:

— Бу бригадада алтмыш биш кешедән бары сигез генә ир. Так что...

— Ә кайда соң ул сигез баш ирең?

— Кайда булсын, үз эшләрендә. Икесе конюх, берсе тегермәндә, берсе бакча каравыллый, берсен әле районга сельпо өчен товар алып кайтырга җибәрдем, тагын...

— Берсе күрше авылда өйләнеп йөри,— дип өстәп җибәрде теге таза апай.

Бу юлы апайлар да көлешеп алдылар, ләкин Мостафин елмаймады да.

— Тулмады әле,— диде ул, күзләрен хәтәр кыса төшеп.— Тагын икесе кайда?

Председатель, аркасында борча йөргәндәй, калак сөякләрен уйнатып куйды.

— Тагын икесеме?.. Теге ни, әлеге Нурисламов, райфо инспекторы чакыртып алган иде.

— Ни өчен чакыртып ала ул? Ни эшкә?

— Ни эшкә дип... әллә ни зур эшкә түгел, пүчтәк кенә... Капкасын җил аударган диме шунда...

— Аңлашылды! — диде Мостафин, аның сүзен кырт кисеп, ләкин артык сорашып тормады. Мәсьәлә бик четерекле, урыны түгел, шуңа күрә председатель белән икәүдән-икәү генә калгач сөйләшергә булды. Шулай да ул, әлеге үсмер кызларга күрсәтеп, сорамыйча булдыра алмады:

— Ә бу... үсканнәрем дә печән чабып маташалармыни?

— Сез аларның буйларына карамагыз,— диде олырак яшьтәге бер апай.— Эшләп өйрәнгән кызлар алар, бездән бер дә калышмыйлар.

— Шулаймыни?

Председатель үзенчә мәсьәләгә ачыклык кертергә теләде:

— Аларның һәркайсы уналтыдан узган инде, так что, устав буенча минимумны тутырырга тиешләр.

— Синең бар белгәнең минимум,— диде олырак яшьтәге апай.— Алар бит күрше авылда укыйлар, менә хезмәт көне эшләгәч, кышын колхоздан ат соравы безнең өчен ансатрак була, диләр. Шуңа бит инде, кушканны да көтмичә, үзләре теләп эшкә чыгалар.

Бүтәннәрнекенә караганда кыскарак саплы, кечерәк чалгылар тоткан кызлар елтыр, тере күзләре белән Мостафинга туп-туры карап торалар иде. Аларның бөтен кыяфәте — көлемсерәгән йөзләре дә, тере карашлары да — гүя: «Һи, ничек кенә без эшлибез әле!» — дип әйтеп тора кебек иде.

Мостафин кызларны мактады, ә председательгә кышын мәктәпкә барыр өчен атны аларга отказсыз бирергә кушты.

— Эшләгән кешегә берни дә җәл түгел,— диде председатель, кинәт юмартланып.

Аннан Мостафин апайлардан ничек эшләүләрен, эш шартларын, нәрсә җитешмәвен сорашып торды. Апайларның күбесе шушында, печәнлектә үк куналар икән, тик яшь балалы апайлар гына авылга кайтып йөриләр. Иртән колхоз аларны ат белән китерә, ә кайтырга ат җибәрми икән. Арыган аяклар белән биш километр җирне тәпи-тәпи җәяүләргә туры килә, диләр апайлар...

Мостафин моның өчен председательгә шактый каты әйткәләде; председатель бүгеннән калмый көн дә ат җибәрергә булды. Шуннан соң апайлар көннәрнең бик эссе торуын, чәйнең күп эчелүен әйтеп, шикәр юклыктан зарландылар.

— Кибеткә әлеге тышсыз кәнфит тә бу арада кайтмый башлады,— диде апайларның берсе.

Бусы катлаулырак мәсьәлә иде. Мостафин ничегрәк җайлап әйтергә белмичә торган арада, председатель тагын өлгерлек күрсәтте:

— Апайлар, борчылмагыз,— диде ул,— бүген сезне яңа бал белән сыйлыйбыз. Әхмәтша бабайга мин умарталарын карап, бал алырга куштым, так что, чәйне тәмләп эчәрсез...

Апайларның кайберләре сүлпән генә рәхмәт әйттеләр, ә күбесе дәшмәделәр, күрәсең, председательләренең вәгъдә белән сыйларга ратуын яхшы беләләр иде. Хәер, кем белә, секретарь алдында биргән вәгъдәсен, бәлкем, үтәр дә. Аның кайчан бик юмартланып киткән чаклары да булгалый иде.

...Сөйләшеп тору озакка бармады,— председательнең аты бер урында тора алмыйча бик тыпырчына башлады,— аны кигәвен сырып алган иде.

Китәр алдыннан Мостафин:

— Ярый, апайлар, тырышып кына эшләгез,— диде.— Печән икмәк шикелле үк кирәк нәрсә, үзегез дә беләсез.

— Беләбез,— диде таза апай һәм нидер аңлатырга теләгәндәй өстәп куйды: — Эш бездән калмас!

Менә алар урыннарына таралдылар. Әле берсе, әле икенчесе, чалгысын арткарак терәп, сыртыннан алып һәм кырынрак тотып, «чыж-чаң, чыж-чаң» кайрарга тотындылар. Кайрап бетергәч, берәм-берәм башлаган покосларына төштеләр. Күп тә үтмәде, торналар кебек кыеклап тезелешкән апайлар бар да бер көйгә салмак кына селтәнеп чәчәкле тугай үләнен сул якларына, хәтфә тар палас сузгандай, салып бара башладылар. Иң очта әлеге үсмер кызлар, бала торналардай, олылардан калышмыйча, үз покосларын чабып киләләр иде. Беләкләрегез талмасын, рәхмәт төшкерләре!

Мостафин белән председатель ат янына килделәр. Ат, бичара, нишләргә белмичә бер артка чигенә, бер алга тартыла, койрыгын бертуктаусыз уңга-сулга селти, дүрт аягы белән дә алмаш-тилмәш корсагына тибә иде. Председатель тиз генә атның башын чишеп тезген очын тәртәгә бәйләде, һәм тирбәлеп торган тарантаска чак утырулары булды — чаптырып китеп тә бардылар.

Озакламый ат тар тугай юлына чыкты. Юлның ат таптаган сукмагы белән тәгәрмәчләр салган эзе буйлап биек үлән үскән; шул үлән эчендә атның аяклары да, тарантасның тәгәрмәчләре дә күмелеп бара... Тарантас егып узган үләннәр, сукрангандай, кыштыр-кыштыр шаулыйлар да, аннан янә берни булмагандай, артта тураеп калалар иде.

...Мостафин сүзсез, боек иде. Ниндидер күңелсез уйларга йотылган иде ул. Күзләре дә аның, ничектер, эчкә киткән, гүя, тышкы дөньяга түгел, ә күңелендәге уйларына төбәлгән. Күрәме ул алдында җәелеп яткан чәчәкле тугайны, күрәме анда-санда ялгыз утырган мәһабәт карт тирәкләрне, күрәме, ниһаять, озын керфекләр арасыннан караган зәңгәр күзләр төсле, зифа камышлар ара-

сыннан көнгә каршы елтырап яткан вак күлләрне? Әллә берни дә күрми, бары үзенең уйларын гына беләме?...

Шулай да аның күзләре гаҗәеп бер нәрсәгә төште: юлдан сул кулда, сазлыкка әйләнгән бер кечкенә уйсулыкта, күче белән сары чәчәкләр үсеп утыра. Тугайда нинди генә чәчәкләр булмый, ләкин болар тирәсендә аларның берсе дә юк. Ялгыз үзләренә бер семья булып үсеп утырган бу озын сабаклы һәм бармак бите хәтле кечкенә чәчәкләрнең сары төсе искиткеч ачык, якты иде. Эретеп тамызган гәрәбә тамчысыдай янып торалар иде алар...

Мостафин бу гаҗәеп чәчәкләрне күреп ихтыярсыз сокланды.

— Нинди тере, матур чәчәкләр! — диде ул, беренче кат телгә килеп.

Райком секретареның кәефен ачык белә алмыйча, шуңа пошынып һәм нидән сүз башларга белмичә шүрләбрәк барган председатель шунда ук ашыгып сорады:

— Кайсы чәчәкләрне әйтәсез, Мостафин абый?

— Әнә теге уйсулыкта үсеп утырган сары чәчәкләрне әйтәм.

— Ә-ә, аларны... әйе шул, матурлар...

— Ничек атала ул чәчәкләр?

— Бездә аларны «ут чәчәк» дип атыйлар.

— «Ут чәчәк». Исеме дә үзенә бик туры килә икән. Чыннан да уттай янып торалар бит.

— Анысы шулай,— диде председатель, бик үк килешеп бетмәгәндәй.— Ләкин бер төсенә карап кына «ут чәчәк» дип йөртмиләр аны...

— Ә тагын нәрсәсе өчен алай дип йөртәләр соң?

— Бик зәһәр булганы өчен... Менә син аны тотып иснәсәң, төчкертә ул, капсаң — авызны уттай яндыра, ышкысаң — тәнне боза. Так что, алама нәрсә, шуңа күрә мал да ашамый аны.

Мостафинны бик гаҗәпләндерде бу сүзләр; нинди көтелмәгән алдану: «ут чәчәк» — матур чәчәк, «ут чәчәк» — зәһәр чәчәк! «Ут чәчәк»кә кагылырга ярамый. Кагылсаң — әнә нишләтә ул! Белер-белмәс соклануы өчен Мостафинга хәтта уңайсыз да булып китте.

— Кара син аны,— диде ул, сүнгән тавыш белән.— Ишеткәнем дә, күргәнем дә юк иде әле мондый чәчәкне...

— Сазлыкта гына үсә бит ул,— диде председатель.

Тагын бер камыш баскан кечкенә күл кырында «ут чәчәкләр» күренде, ләкин Мостафин бу юлы аларга карамаска тырышты. Авылга кайтып җиткәнче бу председатель белән дә бүтән бер авыз сүз сөйләшмәде. Камыш-

лыга кайтып киткән чакта да ул аңа бернинди наказлар да, боерыклар да биреп тормады. Машинасының түренә кереп, елышып утырды да китеп тә барды.

...Бик әшәке иде аның рухи хәле. Оят та иде аңа, авыр да иде, кемнәрдер алдында гаепле дә кебек иде. Нидән бу? Әлеге кара янып печән чабучы апайлардан ояламы ул, шулар алдында үзен гаепле тоямы? Ихтимал. Ләкин бу аның өчен яңалык түгел бит. Сугыш елларыннан бирле хатын-кызларның колхозларда төп көч булып эшләп килүләрен ул бик яхшы белә. Хатын-кызларның нинди авырлыкларга чыдап, күпме фидакарьлекләр күрсәтүләрен ул моңарчы да үз күзе белән күреп килде. Эш нидә соң? Әллә шул йөзләреннән сабыйлык чырайлары да китеп бетмәгән яшь-яшь кызларның таза ирләр эшенә чыгып тотынуларын күрү аның бәгырен сыкратып җибәрдеме? Әйе, бу күз яше белән нечкәреп сокланырлык бер күренеш иде... Әмма бу күренеш тә аны мондый караңгы уйларга төшермәгән булыр иде, әгәр ул элекке Мостафин булса... Хикмәт нидә соң? Хикмәт шунда ки, аның үз тормышы көннән-көн халык тормышыннан ераклаша бара иде. Ул үзе, ничектер, икегә бүленеп, бер-берсенә каршы торган, бер-берсен аңламас ике кеше булып яши башлады. Чыннан да, менә ул үзләренең киләчәк укуларын кайгыртып печән чабучы кызларга сокланды, аларны кызганган булды, ә шул ук вакытта аның өендә сабанга җигәрлек яшь, таза хатын кыл кыймылдатмыйча ята. Хәер, бу кадәресе белән генә килешергә дә мөмкин булыр иде, аның хатыны эшләсә ни дә, эшләмәсә ни — теге кызлар өчен барыбер ич. Ә менә бер инспектор актыгының кызу эш өстендә колхоздан ике таза ирне алып китүе белән ничек килешергә? Моның өчен бит аны кайту белән чакырып алып, өстәл сугып: «Син колхозны таларга тотындыңмыни әле, сукин сын! Судка бирәм!» — дип өстенә җикерергә кирәк иде. Ләкин ул, Мостафин, сизеп тора: кулы ачудан йодрыкланса да, өстәл суга алмаячак, ярсуы эченә сыешмаса да, җикереп кычкырырга көче җитмәячәк. Чөнки ул үзе колхоз осталарыннан, капка гына түгел, өй салдырып кергән кеше, һәм теге нахалның шуны белеп, аның йөзенә мыскыллы көлеп каравы бар. Йә, җитәкче кеше өчен бу фаҗига түгелме?! Яки менә миләр кайнатырлык бүгенге эсседә сусыннарын ничек басарга белмәгән апайлар аңа шикәр юклыктан зарландылар. Ә бит аның өендә — ул белә — ике эшсез хатын, аналы-кызлы, потлап варенье кайнаталар. Хәер, кайнатмагае, чәнчелеп китсеннәр! Мәсьәлә анда

түгел. Мәсьәлә шунда: ул, райком секретаре, ай саен районга азмы-күпме килгән шикәрнең, шул апайларга барып җитмичә, каядыр эреп бетүенә юл куя. Чөнки апайларга дигән шикәр ниндидер хәрәм юллар белән аның үз өстәленә дә килә. Ул тик күрмәмешкә, белмәмешкә салына. Йә, кабахәтлек түгелме бу?

...Һәм менә шушы үзенең җаваплы исеменә, тоткан урынына һич ярамаган хәлне бик яхшы аңлау һәм шул хәл белән килешеп яшәү аның төп бәхетсезлеге иде. Нәрсә мәҗбүр итә соң аны мондый газаплы каршылыкта яшәргә? Нигә ул әле югалтып бетмәгән намусын, ирлек көчен җыеп, бу каһәр суккан каршылыктан чыгарга тырышып карамый?

Юк, карый ул, тик кайсы якка таба чыгарга — эш бары шунда гына.

Бер хакыйкать аның өчен хәзер ачык: «ут чәчәгенә» кызыгып ул сазлыкка керде һәм шунда батып калды. «Ут чәчәгенең» зәһәрен башта сизмәде, ә тора-бара сизсә дә, аңаияләшеп өлгерде. Хәзер инде ул Нәҗиясен өзелеп ярату гына түгел, аңа кол булыр дәрәҗәгә җитте, аның өчен куркып-калтыранып кына тора башлады. Ул, бабасы белән әбисенең котыртуларын тыңлап һәм Нәҗиянең таләбенә буйсынып, йорт салдырды. Озак та үтмәде, Андреевның әйткәннәре дөрескә килде: ул, Мостафин, йортка хуҗа түгел, ә йорт аңа хуҗа булып алды. Инде менә хәзер бик ачык белеп тора — Нәҗиясен дә, йортын да ул ташлый алмаячак.

Димәк, нишләргә кирәк? Бердәнбер чара — партия эшеннән китүдер, ахрысы. Бу уй Мостафин күңеленә соңгы вакытларда бик еш килә башлады. Чөнки тормышында һәм үзендә булган үзгәреш котылгысыз рәвештә шуңа таба илтә иде. Бала түгел, күрә ич ул! Элекке кебек эшендә иҗади рухлану юк инде, принципиаль гадел була алуын акрынлап югалтты, кешеләр белән ачык, саф күңелле була алмый башлады; ничектер, үз эченә йотылган яшерен кешегә әверелде һәм халыктан курка торган булды. Йә, мондый хәлдә ничек инде партия җитәкчесе булырга мөмкин ди? Тагын аның өчен иң куркынычлысы шул иде — тыштан никадәр генә ул үзенең исемен, дәрәҗәсен сакларга тырышмасын, әмма халык күзеннән акрынлап төшә баруын, коммунистларның аңа кырын карауларын, бер язучы әйтмешли, аркасы белән тоеп йөри иде. Һичничек котыла алмас кебек иде ул партиядәш иптәшләренең бу салкын, кырын карауларыннан, һәм вакыт-вакыт аның бөтенләй кешеләр күзеннән югаласы килеп китә иде.

... Менә бүген «Кызыл яр» колхозыннан кайтып килешли Мостафин үзенең аяныч хәлен тагын бер кат аеруча тирәнлек белән кичерде. Тагын бер кат үзенә: «Юк, булмый болай, ярамый болай, райкомнан китәргә кирәк!» —диде... Икенче төрле нәтиҗәне ул ясый алмый иде инде. Чөнки аның күңеленә кечкенәрәк берәр эштә эшләп, күзгә чагылмас гади бер кеше булып, үз өендә үзенең Нәҗиясе белән тыныч кына яшәү теләге бик нык тамыр җибәреп өлгергән иде.

Ләкин Мостафин хәленә төшкән кеше өчен, гадәттә, икеләнү, кыюсызлык хас була. Менә ул да шактый вакыт аптырауга төшеп йөрде. Аның үзе сорап партия эшеннән китәргә йөрәге җитми иде. Шуңа күрә ул сайлауларны көтәргә булды: ихтимал, шул чакта җәнҗалсыз гына төшеп калырмын, дип өметләнеп торды.

...Һәм без беләбез, Мостафин үзенең исәбендә ялгышмады: шул ук елны көзен партиянең райком конференциясендә ул райком составыннан төшеп калды. Үзе төшеп калу бер хәл — шаукымы аның Андреевка да тиеп узды. Күп кенә делегатлар аңа: «Иптәш Андреев, сез кайда идегез, нишләп сез Мостафинның мещанлык сазлыгына батып баруын күрмәдегез, ул йорт салдыра башлагач та, коммунист һәм җитәкче буларак, нигә аның белән принципиаль рәвештә сөйләшмәдегез?» — дигән каты сораулар куйдылар.

Андреев соңгы сүзендә бу сорауларга тулы җавап биреп үтмичә кала алмады, билгеле... Гадәттә ашыкмыйча тыныч кына сөйли торган Андреевның, «Мостафин мәсьәләсенә» җиткәч, шактый дулкынлануы сизелде. Күрәсең, ул үзе дә «Мостафин мәсьәләсен» авыр кичерә иде... Әйе, ул, Андреев, Мостафинга вакытында йогынты ясый алмавы өчен үкенә, аның шәхси тормышында эшләгән кайбер хаталарына карата йомшаклык күрсәтүен икърар итә. Дөрес, йорт салдыру мәсьәләсендә ул аңа иптәшләрчә кисәтү ясамады түгел, ясады, ләкин бу кисәтү аз булды, йомшак булды. Ни өчен, нидән ул, Андреев, политика теле белән әйткәндә, либераллык күрсәтте соң? Беренчедән, ул моны үзенең райкомда яңа кеше булуы, район шартларын һәм җитәкчеләрен ныклап белеп җиткермәве, шуңа күрә ашыгып нәтиҗә ясаудан сакланырга тырышуы белән аңлатты. Икенчедән, Мостафинга моңарчы бик ышануын, ихтимал, үзе үк кая таба баруын сизәр, исенә килер, чигенер дип өметләнеп торуын әйтте. Сүзенең ахырында ул Мостафинның килгән чакларында бик тырышып эшләвен, колхозлар белән җитәкчелек итүдә күп көч куюын әйтеп, хәзер дә әле аңа ышанычын

югалтып бетермәвен, шуңа күрә аны, әгәр ул хатасын бөтен тирәнлеге белән аңласа һәм үзе өчен дөрес нәтиҗә чыгара алса, райком составында калдыруны мөмкин дип табуын белдерде.

Делегатлар Андреевны бик игътибар белән тыңладылар, әмма Мостафинга яңадан ышануны мөмкин дип тапмадылар.

Кайбер алама эшләр эшләгән кешеләр, гадәттә, кинәт җимерелеп төшәләр, партиядән куылалар, җинаятьчеләр эскәмиясенә эләгәләр, төрмәгә китеп баралар. Мостафин белән, билгеле, андый бәхетсезлек булмады. Аның җинаяте юк иде, эшендә нинди дә булса зур хата эшләмәде ул, шулай ук «череп таркалуда» да аны гаепләмәделәр. Аңа син халыктан аерылдың, обывательгә әйләндең, партия эшенә ярамыйсың, диделәр. Һәм ул... төшеп калды.

Төшеп калуны көтеп алганга күрә, Мостафин йөрәгендә кузгалган хурлану, әрнү кебек хисләрне, башта әйткәнебезчә, көчләнеп булса да, басарга тырышты. Шулай да аның белән әллә ни булды: ул тәмам үз эченә йотылды һәм бөтенләй телдән калды, әйтерсең мәрткә китте. Бер ай буена ул бабаларына аяк атлап бармады һәм бер ай буена янында яткан Нәҗиясенә кагылмады, гүя аны тоюдан туктады. Бу хәлдән бик куркуга төшкән һәм иренең фаҗигасен бөтен тирәнлеге белән аңлаудан ерак булган Нәҗия, аңа сарылып, гадәтенчә иркә еламсырап: «Шакир, бәгырем, ни булды сиңа, ник бер сүз дә әйтмисең, ник күзләреңне ачмыйсың? Мин куркам, җаным, синең өчен куркам! Йә, күзеңне ач инде, йә, бер генә сүз әйт инде?» — дип ялварып та карады. Ләкин җансыз сындай хәрәкәтсез яткан Мостафин аңа бары:

— Сарылма! — дип кенә әйтте, һәм ул моны шундый итеп әйтте ки, Нәҗия берьюлы шым булып калды. Дөрес, Нәҗия дә тормышларындагы бу «көтелмәгән» үзгәрешне үзенчә авыр кичерә иде: әйе, бетте аның өчен секретарь хатыны булып, һаваланып йөрүләр...

Тик Идият абзый гына киявенең хәлен азмы-күпме дөрес аңлады булса кирәк. Һәрхәлдә, ул, гомерендә беренче тапкыр диярлек ир хокукы белән файдаланып, хатынына:

— Кияүне тынычлыкта калдыр, күзенә күренеп йөрисе булма! — дип бик нык кисәтеп куйды. Үзе исә, ниндидер сылтау табып, бер-ике атнага өлкә шәһәренә командировкага китеп барды.

Майпәрвәз ханым иренең кисәтүен, бәлкем, колагына да элмәгән булыр иде, ләкин киявен бер барып күргәч,

чыннан да вакытлыча посып, тынып торуны үзе өчен хәерлерәк булыр дип тапты. Тик ара-тирә ашыгып кына килеп-киткәләгән кызын юатыр өчен һаман аңа:

— Син, Нәҗия, бер дә борчылма, бар да җайланыр, бар да үзенең эзенә төшәр, Алла бирсә! Кияүнең райком кебек үзе бәрәкәтсез, үзе җәфалы җирдән китүе файдага гына булыр, дип — әйтә торды.

...Салкын, шыксыз, караңгы көзнең һич чиге булмастай тоелган бу бер ае эчендә Мостафин күңеленнән ниләр кичерде, күпме уйлар башыннан үткәрде — моны беркем дә әйтеп бирә алмас иде. Ниләр генә кичермәсен, күпме генә уйлар килеп китмәсен — болар бар да аның үз эчендә калды. Ниһаять, ул акрынлап терелә башлады, акрынлап иске хәленә кайткан кебек булды. Күрәсең, тау кадәр газап йотып, ахыр чиктә үзенең язмышы белән килеште.

Хәзерге вакытта Мостафин Камышлыда агач эшләре артеленең председателе булып тора. Аның артеле тугым һәм чана табаннары бөгә, шулай ук табуретка, өстәл, шүрлек кебек кайбер өй кирәк-яраклары эшләп чыгара.

Мостафинның, мәгълүм булганча, йорты бар, йортында сыеры бар, кош-кортлары бар. Артельгә кергәч, дуңгыз алып симертергә куйды. Йортын һәм терлекләрен ул үзе карый. Һәр көнне эштән кайткач ул, иске телогрейкасын кия дә, тизрәк шулар янына чыга. Җиңел аңа алар янында, башы кирәксез уйлардан буш, күңеле, йокыга талгандай, тыныч...

Шулай да ул шактый нык үзгәрде: чигә чәчләре агарып, йөзе суырылып, күзләре тоныкланып калды. Ничектер гәүдәгә дә чүгә, бөрешә төшкән кебек булды. Таза, көчле иргә хас элекке мәһабәт сын, горур килбәт юк инде. Гүя, аның бөтен кыяфәтенә якынлашып килгән картлыкның беренче салкын шәүләсе ятты.

Ә Нәҗия? Нәҗия ни: «ут чәчәктәй» һаман балкып тора ул. Аңа бит әле егерме өч яшь кенә. Хатын буларак ул тагы да матурланып, тулыланып китте, һәм торган саен пешә, тулылана барыр төсле. Элеккечә һаман очынып кына тора ул, балаларныкыдай ваемсыз, саф, алсу йөзендә бернинди уй әсәре юк, тәмле ашарга, матур киенергә, күп йөрергә ярата. Пөхтәлекне бик сөя, үзен бик карый белә, өен, урын-җирен дә бик чиста тота, ләкин кара эшне бер дә яратмый. Сыерны да күрше апайдан саудыра.

...Шакирын элеккечә бик ярата кебек, һәрхәлдә, Мостафин өчен ул һаман дәртле, кайнар хатын. Шикләнергә, борчылырга сәбәп чыкканы юк. Шулай да берара халык

телендә, Мостафинның Нәҗиясе раймагтагы кара мыеклы егет белән «чиерттерә» икән, дигән хәбәр йөргән иде. Дөрес идеме бу — тәгаен әйтүе читен. Ихтимал, гайбәт кенә булгандыр. Мостафин үзе аны ишетмәде, һәм без аның андый әшәке гайбәтне ишетмәвен теләр идек. Бик күп позицияләрен бирде ул Нәҗиясе өчен...

Тагын шул — Нәҗиянең менә дүрт ел инде баласы булганы юк. Врачлар аңа курортка барырга киңәш бирәләр икән. Ә Мостафинның ике күз кебек теләгән нәрсәсе — бала. Шуңа күрә ул, дуңгызны суеп саткач, Нәҗиясен курортка җибәрергә уйлап тора.

...Мостафинның киләчәк тормышын юрап тору файдасыз эш булыр иде. Тормыш юлы борылмалы да сырылмалы, кая илтеп чыгарыр ул — алдан әйтүе читен. Шуңа күрә, хөрмәтле укучы, рөхсәт итегез шушы урында нокта куярга.

*1954—1955*

# ЙӨРӘК СЕРЕ

# I

Таулар итәгеннән диңгезгә карап һәм куе яшеллеккә күмелеп утырган ак сарайлар шәһәре Сочига мин бүген көннең икенче яртысында килеп төшкән идем. Кулымдагы путевка буенча шәһәр читендәге «Дулкын» санаториена килеп җиткәндә, күләгәләр озынаеп, көндезге эсселек шактый сүрелгән иде инде.

Бүген килеп төшүчеләр өч-дүрт кенә кеше булганлыктан, безне кабул итү озакка сузылмады. Мин, ванна кереп, бүлмәгә урнашкач, өс-башымны алыштырып, санаторий паркына чыктым. Паркта һичкем юк, ял итүчеләр, күрәсең, барысы да диңгездә... Кичке ашка кадәр вакыт бар әле, миңа да диңгез буена төшкәндә ярар иде, ләкин нигәдер ирендем. Бина алдындагы түгәрәк мәйданчыкның бер читенә узып, шәм шикелле төп-төз кипарис төбендәге яшел эскәмиягә барып утырдым.

... Менә мин тагын Кара диңгез буенда, тагын шул ук «Дулкын» санаториенда... Аһ, никадәр кыска бу бер ел гомер! Гүя бер елдан түгел, ә бер тәүлектән әйләнеп килдем мин бирегә. Берәр үзгәреш эзләп тирә-ягыма күпме генә карансам да, таба алмыйм мин аны: бар да искечә, барысы да үз урынында... Чыннан да, нәрсә ул бер ел вакыт гасырлар буена акрынлап кына үзгәргән табигать өчен, яки кеше кулы тудырган материаль әйберләр өчен? Бу кипарислар, бу пальмалар, магнолияләр, «боек таллар», бу акация, лавр, олеандр куаклары, ун елдан соң килсәң дә, шулай тыныч кына үсеп утырмаслармыни? Бу ак бина үзенең ялт иткән тоташ тәрәзәләре белән, зиннәтле яка эченнән сузылган гүзәл йөз шикелле, шушы искиткеч купшы-матур яшеллек арасыннан түбәндәге зәңгәр диңгезгә илле елдан соң да шулай тын гына карап тормасмыни?.. Хәтта, мин әйтер идем, ел саен яңадан үстерелгән, исемнәрен белеп бетер-

гесез менә бу нәфис чәчәкләр дә, кайчан гына килсәң дә, нәкъ шул урыннарында, нәкъ бүгенгечә, мул яктылыктан һәм кешеләрнең назлы карашыннан , оялчан кызлардай, сөенешеп утырачаклар ич!

...Ләкин мин beләм, мин тоям — үзгәреш бар, үзгәреш булмыйча мөмкин түгел. Тормышның кануны шундый инде: бер ел эчендә генә түгел, күз ачып йомган арада да дөньядагы барлык җанлы-җансыз нәрсә күпмегәдер үзгәреп өлгерә. Мин аны, ул үзгәрешне, иң элек үземдә хис итәм: кеше күзенә чалынырлык яңа сыйфатларга баемасам да, һәрхәлдә, бер елга картайдым мин... Бер ел эчендә минем башымнан шактый хәлләр кичте, зур тарихи вакыйгалар шаһиты булдым, кемнәрнедер югалттым, нәрсәнедер аңладым, күпмедер тәҗрибә җыйдым... Һичшиксез, рухланган, куанган вакытларым булды, шулай ук бик борчылган-кайгырган чакларым да булмады түгел, булды. Кыскасы, күпме генә акыл сатма, әмма хакыйкать шул: бер ел вакыт буш ара булмаган ул!.. Ул тулы, шактый күп хәлләр белән тулы. Ләкин үтте инде ул бер ел вакыт! Алып китте үзе белән гомернең кечкенә бер өлешен, күз карашының күпмедер яктысын, йөрәкнең күпмедер ялкынын...

...Кадерле, бик кадерле ул үткән гомер! Бигрәк тә менә хәзергедәй, беркайчан да онытылмаслык хатирәләр урыны булган җиргә әйләнеп кайткач, аеруча тирән хис итәсең икән аны... Белсәгез иде, никадәр якын, кадерле миңа бу тын бакча, бу ак бина, бу яшел эскәмияләр!.. Ул Зөһрә, йөрде шул ук яктылык һәм күләгәләр белән чуарланган тын юлларда, ул Зөһрә, утырды шул бу яшел эскәмияләрдә... Нинди ачык булып барысы да күз алдыма килә!

...Әнә өченче каттагы, кырыйдан дүртенче балконга менә шушы кояш баер алдыннан ук чыгып баса торган иде. Диңгез түренә төшеп барган кояшның соңгы дәрт белән балкыган нурлары аны башыннан аягына кадәр яктырта. Дулкынланып иңбашына төшкән аксыл чәчләре һәм аяк йөзенә җиткән эре чәчәкле күк атлас халаты белән ул әллә каян ук балкып күренә... Менә куллары белән балкон читенә тотынып, ул күзләрен кыса төшеп, кояшны озаткандай, диңгезнең җем-җем уйнаклаган түренә тик кенә карап тора. Бу минутта мин түбәннән сихерләнеп аңа карыйм: «Әйе, дим, эчемнән, гомере буена ул менә шундый биеклектә, менә шулай нур эчендә балкып торса иде!»

...Сагыну никадәр ачы ләззәт икән ул! Тирән юксынудан күз карашымны нәрсәгә төшерергә белмичә, ялгызым боегып утырам. Һәр агачтан: «Сез аны бүген

күрмәдегезме?» — дип сорыйсым килә... Әйе, күпме без бу паркның тын, аулак аллеяларында йөрмәдек, күпме тапкыр без тау башыннан түбәндә киерелеп яткан бу чиксез диңгезгә карап тормадык! Менә хәзер мин шуларның барысын да — диңгезен дә, тавын да, йөргән сукмакларны да, иснәгән чәчәкләрне дә — барысын да яңадан күрәм, тик ул гына юк. Нигә бу кадәр мин аны юксынам, кем иде соң ул миңа?

...Мин бит инде, булды да үтте, акрынлап онытам, яңадан салкын, тыныч хәлемә кайтам, дип ышана башлаган идем. Ә менә бирегә килеп, суынмаган эзләргә тагын баскач, барысы да яңадан уянды, яңадан кабынды. Нишлим? Зөһрә — минем бик яшерен йөрәк серем иде. Үземдә генә сакланырга, үзем генә белергә тиешле серем иде ул... Әмма хәзер мин аны сөйләп бирмичә булдыра алмыйм. Кеше, күңелен бушатса, җиңеләеп кала диләр.

## II

...Әйе, без аның белән моннан нәкъ бер ел элек шушы «Дулкын» санаториенда таныштык. Беренче тапкыр мин аны, бирегә килеп төшкәч, икенчеме, өченчеме көнне күрдем. Ләкин бик кыска ара: мин ашханәгә кереп барганда, ул чыгып килә иде. Юл бирдем, яныммнан гына җыйнак-сылу гәүдәле ханым үтте, нәфис бер хуш ис сизелер-сизелмәс кенә борыныма бәрелеп үткәндәй булды, һәм сирень төсендәге ефәк күлмәгенең чак кына чыжлавын ишетеп калдым. Артыма борылып карыйсым килде, ләкин... яхшысынмадым.

Шуннан соң мин аны икенче көнне кичке ашка керер алдыннан шушы кечкенә мәйданчыкта күрдем. Читтәге эскәмияләрнең берсендә ялгызы утырып тора иде ул. Күрү белән мин аны таныдым, һәм ирексездән тукталып, аңа карап тора башладым. Ханым утыз-утыз өчләр тирәсендә булыр. Ак чырайлы ул, чәчләре дә кылган төсле аксыл, әмма шома түгел, ә күпереп, дулкынланып артка ятып тора. Кашлары нечкә, чәченә караганда шактый тонык... ә менә күзләре ни төсле — ерактан ачык күрә алмыйм. Әлбәттә, йә зәңгәр, йә соры булырга тиеш... Аксыл чәч, коңгырт кашка бүтән төс туры киләмени?!

...Төз аякларын берсе өстенә берсен куеп, кулына кечкенә кара ридикюль тотып, ул уйчан-тыныч кына утыра. Бөтен килбәтеннән үз дәрәҗәсен яхшы белгән маса-

юсыз табигый горурлык сизелеп тора. Гаҗәп тә түгел, чөнки биредәге ял итүче бүтән хатын-кызлардан яше белән дә, матурлыгы белән дә аерылып торганлыгын ул үзе дә, һичшиксез, белә булырга тиеш.

Шушы күзәтүдән соң мин ул ханымны тагын берике тапкыр күреп калдым, ләкин гел кичкә табан, гел шушы мәйданчыкта гына... Көндезләрен кайда була ул — билгесез һәм бу нәрсә мине ни өчендер беркадәр тынычсызлый иде.

Ахырда без аның белән врач кабинеты ишеге төбендә очраштык. Мин килгәндә ул креслода утырып тора иде. Кинәт үзен күргәч, нигәдер каушабрак киттем. Кыен иде моның сәбәбен аңлау, әмма бу каушау иртә яшьлегемдә кичергән, инде күптән онытылган сәер бер хисне хәтерләтеп куйды... Мин аның каршындагы буш креслога утырдым һәм, үземне киеренке хәлдә хис итеп, аңа туры карамаска тырыштым... Башта врач кабинетына бер яшь егет кереп чыкты, аңардан соң бер юан абзый кереп китте. Менә шул абзый безнең танышып китүебезгә сәбәпче дә булды. Кырык минут торды ул врач бүлмәсендә... Йә, ничек итеп кырык минут дәвамында бер-береңә сүз дәшмичә утырырга мөмкин? Ә коридорда без икәү генә калган идек... Иң элек ханым сабырлыгын җуя башлады. Берничә тапкыр ул миңа: «бу ни эш бу?» дигән төсле карап та алды. Аның шулай гаҗәпләнеп каравы мине дә, үзе белән бергә, көтү газабын кичерүче итеп тануын аңлаткандай булды. Мин, туң күчән булмасам, әлбәттә, телгә килергә тиеш идем. Һәм нидер әйттем (ялгышмасам, сабыр итмичә чара юк, нинди «авыру» кереп киткәнен күрдек ич, дидем шикелле).

Ханым, көлемсерәп:

— Аптырыйм, нинди бетмәс зары бар икән? — диде.

Шуннан без сөйләшеп киттек. Санаторий шартларында беренче сөйләшүнең стандарты билгеле инде: кайдан килдегез, ничәнче тапкыр килүегез, элек кайларда булган идегез, биредә сезгә ошыймы?.. Ханым үзенең Ульяновскидан килгәнлеген әйтте. Мин бу хәбәргә ничектер куанып, якташлар булып чыгуыбызны әйтмичә кала алмадым. Ләкин ул, артык кызыксыну күрсәтмичә, бары сорамый калу килешмәс дигән төсле итеп кенә: «Шулаймыни, кайдан соң сез?» — дип куйды. Мин: «Казаннан», — дигәч, ул: «Беләм Казанны, булганым бар», — диде. Ни өчендер мин аны Казаннан киткән кыздыр дип уйлаган идем. Инде «булганым бар» дигәнне ишеткәч, мин аңа бераз дикъкать белән карап тордым да ахырда: «Ульяновск сезнең туып-үскән җирегезме?» —

дип сорадым. Ул: «Юк, мин Уралдан»,— диде, ләкин шуннан артыгын әйтмәде.

Бу сөйләшү дәвамында мин тагын әлеге яшьлектә таныш булган, әмма күптән онытылган кичерешне — йөрәкнең акрын гына кысылып, ләззәтле авыртуын тойдым. Гаҗәп, нидән бу? Ханымның матурлыгы мине шулай яшүсмер кебек дулкынланырга мәҗбүр итәме?

...Әйе, сүз дә юк, ул чибәр иде. Якыннан аның йөзе бик чиста, тик кечкенә колакларыннан түбән яңак сөяге читендә ак мамык төкләр күзгә чагыла. Ләкин алар аңа бик килешәләр кебек, ничектер аны йомшак итеп, мөлаем итеп күрсәтәләр. Аз гына кайтарылып торган алсу иреннәре дә аның йомшак кебек, бик саф кебек, дорфаямьсез сүз әйтә алмыйдыр кебек... Алкаланып колак артларына төшкән куе аксыл чәче дә, ап-ак муены да, хәтта аз гына җәенкерәк борыны да — барысы да аңа тулаем бер сөйкемле йомшаклык биреп тора кебек. Тик күзләре генә икенче төрлерәк тәэсир калдыра: кашларының, чәченә караганда, коңгырт булуы, керфекләренең озын һәм кара булуы аның зәңгәр күзләрен караңгылап торган шикелле, һәм күләгәгә яшеренгән бу күзләр кешегә каяндыр ерактан сагаеп-сынап карыйлар кебек...

...Әнә шундый иде һич уйламаганда юлымда очраган бу ханым.

Ниһаять, теге абзый кырык минут торып врач бүлмәсеннән чыкты. Ханым, аңа карап, башын чайкап куйды. Абзый кеше, безне бар дип тә белмичә, гаҗәеп бер гамьсез тынычлык белән китеп барды. Ханым кабинетка кереп китте, ә мин, торып, коридор буйлап йөрергә тотындым.

...Ни өчендер вакыт-вакыт, бизгәгем килгәндәй, ихтыярсыздан чак кына калтыранып та куям — йөрәк дулкынлануданмы соң бу? Әллә нәрсә шунда, үз хәлемне аңлап та җитә алмыйм. Хәтта беркадәр үземә ачуым да килеп китә — яшүсмер түгел ләбаса мин! Шулай да салкын кан белән уйларга тырышам: ни өчен соң әле бу ханым минем игътибарымны үзенә шулкадәр бәйләп өлгерде? Әлбәттә, эшнең сере кара керфек, зәңгәр күзләрдә генә түгелдер инде. Юк, алардан тыш ул ханымда тагын нидер бар кебек... Әйтә алмыйм мин аны, хәзергә әле ул ачылмаган чәчәк бөресе шикелле... Әгәр ачыла калса, күңел күптән сагынып эзләгәнен табар төсле... Ихтимал, минем бу минуттагы дулкынлануым да шуны сизенүдән килә торгандыр.

...Шулай да мин, хәзерге «кабынуым» арзанлы, очраклы бер мавыгу булып чыкмасын өчен, хисләремне

мөмкин кадәр ныграк сынарга, һәрхәлдә, ханымның үзенә, очрашырга туры килсә, берни дә сиздермәскә дигән карарга килдем.

Бераздан йөзе аз гына алсулана төшкән ханым кабинеттан чыкты. Ул миңа елмаеп карады, гүя күзләре белән генә: «Сезне озак ялыктырмадыммы?» — дигән шикелле булды һәм җиңел адымнар белән китеп тә барды. Мин ни өчендер аңа башымны игәндәй иттем, аннан ишек төбендә ярты минут чамасы тукталып тордым да кабинетка кереп киттем.

## III

Санаторийның бер хосусияте бар: анда җыелган халык бер-берсен күрмичә тормыйлар. Таныш булмаска мөмкин, ай буена бер авыз сүз сөйләшмәскә мөмкин, әмма һәркемне күреп, танып өлгерәсең. Әгәр читтә, әйтик, театр-фәләндә, шуларның берсен очратсаң, «бу безнең санаторийдан» дип узасың.

Менә шунлыктан мин дә игътибарымны биләп өлгергән әлеге ханымны көн дә бер-ике тапкыр күрми калмый идем. Йә вестибюльдә, йә ашау-эчү залында, йә санаторий алдындагы шул кечкенә мәйданчыкта ул миңа очрый торган иде. Врач кабинеты янында бергә туры килеп, өстән генә булса да берникадәр сөйләшеп алганга күрә, мондый очрашу вакытларында мин аңа баш иеп, исәнләшеп уза идем. Һәм ул минем сәламемне алмыйча калмый иде. Ничек кенә булмасын, очраклы бер сөйләшүдән соң, без инде үзара танышлар кебек идек.

...Ләкин ни өчендер мин аны санаторий бинасыннан читтә, диңгез буенда яки паркта, бер дә очратмый идем. Билгеле инде, ял итүчеләр барысы да иртәнге аштан соң, җиңел киемнәрдән генә, зур сөлгеләрен култык асларына кыстырып, диңгез буена ашыгалар. Дөрес, ирләр һәм хатын-кызлар пляже анда аерым, ләкин йөрү юлы бер булгач, ул ничек тә очрарга тиеш иде. Әмма ул очрамый торган иде. Кайда ул, нишли, көн буена бушап калган бинада ялгыз ятамы, әллә вакытын төрле процедурага йөреп уздырамы — мин белә алмыйча аптырый идем.

...Яшерә алмыйм, мин аны күңелем белән һаман эзли идем, ул күренмәгәч, эчем пошып, юксынып йөри идем.

Бу хәлемнән, дөресен генә әйткәндә, үзем бер дә ризасызлык хис итмим, аңардан котылырга да тырышмыйм, киресенчә, шул юксынудан әллә нинди генә бер моңсу рәхәтлек таба идем кебек.

Әнә шулай көнозын күренмичә зарыктырган ханым, кичке аш алдыннан гына әлеге кечкенә мәйданчыкка чыгып, читтәге эскәмияләрнең берсендә ялгыз утырып торырга ярата иде. Мин аның каядыр шунда утырып торуын, күзем белән күрмәс борын ук, күңелем белән сизә идем. Һәм чыннан да алданмый идем, күрә идем, ләкин — гаҗәпләнмәгез — янына барырга ашыкмый идем. Бу курку да, уңайсызлану да түгел, бу — шундый тиз арада әсир итеп өлгергән кешегә якын барудан ихтыярсыз тыелып тору иде... Шуңа күрә мин, хәйран калган яшүсмердәй, аның күзенә чагылмаска тырышып һәм берәр төркем янына сыенып, ерактан гына аны күзәтә торган идем.

Беренче сөйләшүдән соң өчме, дүртме көн уткәч, мин аны кичкырын тагын шул кечкенә мәйданчыкта күрдем. Бу юлы ул якын эскәмияләрнең берсендә утыра иде, һәм мин ишектән чыгуга аның карашын очраттым. Бу караш, гади танышларча гына караш, минем тыелып маташуымны, ниһаять, сындырды. Баш иеп исәнләштем һәм һич икеләнүсез туп-туры аңа таба атладым. Рөхсәт сорап, янына утырдым. Миңа калса, ул мине шактый җылы каршы алды.

...Без, бернинди тартыну яки уңайсызлану кебек нәрсә хис итмичә, иске танышлардай сөйләшеп киттек. Ә аның өстендә бик гади генә итеп тегелгән, ачык изүле, кыска җиңле яшел күлмәк иде. Күкрәге өстендәге кечкенә кесәсенә ак ефәк кулъяулыгын төртеп кенә куйган... Бүтән берни дә юк. Тик сул кулының атсыз бармагында кызыл якут ташлы алтын йөзеге бар икән... Әйе. Һаман шулай аксыл чәчләре алкаланып йомшак ак муенына төшкән, һаман шулай кара керфекләре зәңгәр күзләрен күләгәләп торалар...

Мин аңардан: «Бу санаторий сезгә ошыймы, ияләшеп буламы?» — дип сорадым. Ул, нечкә коңгырт кашын күтәрә төшеп: «Ярыйсы,— диде,— башта бераз күңелсезрәк була инде, аннан ияләшеп китәсең»,— диде.

Мин:

— Сез диңгезгә йөрмисез, ахрысы? — дидем.

Ул:

— Врачлар берәр атна сабыр итәргә куштылар,— диде.

Мин:

— Санаторийдан көн буе чыкмыйча яту бик күңелсездер бит? — дидем.

Ул, чак көлемсерәп:

— Юк, мин санаторийда бикләнеп ятмыйм, мин йөрим, менә бу паркның бөтен почмакларын йөреп чыктым инде,— диде.

— Бер дә очратканым юк,— дидем мин, гаҗәпләнгән булып.

— Алайса без төрле вакытта йөрибездер,— диде ул, җәһәт кенә.

Аның болай диюенә каршы минем, моннан соң сезне ничек тә очратырга тырышырмын, диясем килде, ләкин арзанлы комплимент булып чыкмасын дип әйтмичә калдым. Шулай да сүз өзелмәсен өчен мин аңа мондый сорау бирдем:

— Ихтимал, сез ялгызлыкны яратасыздыр?

Ул, ни дип әйтим сезгә дигән төсле, бер иңбашын җиңелчә генә җыерып куйды.

— Мин дәваланырга килдем, врачлар нәрсә кушсалар, шуны эшлим,— диде ул, гади генә итеп, аннары аз гына уйланып өстәде: — Ә дөресен генә әйткәндә, ялгызлыкны мин яратмыйм... Яратам диючегә ышанмыйм да, чөнки кешеләр белән аралашмыйча бер генә көн дә яшәп булмый...

Ханымның болай кинәт кенә «ачылып» куюы мине беркадәр гаҗәпләндерде дә, куандырды да: нидән икән бу?.. Һәм аңардан тагы да күбрәген ишетәсем килеп, мин, читләтебрәк булса да, мәсьәләне үземчә «конкретлаштыра» төшәргә уйладым.

— Әлбәттә,— дидем мин,— кеше кешесез яши алмый, дөрес әйтәсез... Ләкин бу әле, ничек дим, гомуми кагыйдә... Шул ук вакытта һәркемнең характеры белән бәйләнгән үз кагыйдәсе дә булырга мөмкин. Берәүләр, мәсәлән, кешеләр арасында күбрәк булырга яраталар, йөрүдән, сөйләшүдән, яңа танышлар булдырудан кызык табалар. Икенче берәүләр исә, киресенчә, кеше күп җирдән качалар, компаниядә булырга яратмыйлар, берәү белән дә танышырга теләмиләр, кыскасы, үз эчләренә йомылып, аралашмыйча яшәүне артык күрәләр. Шунлыктан алар ялгызлыкны сөяләр, ялгызлыктан ямь табалар... Була бит шундый кешеләр дә?

— Ник булмасын, була, билгеле,— диде ханым.— Менә мин үзем дә шау-шулы компанияләрне яратып бетермим, шулай ук очраган берәү белән танышырга да теләп тормыйм. Нигә ул?.. Ләкин япа-ялгыз булудан да кызык тапмыйм. Юк, дөрес түгелдер ул, ялгызлыктан ямь табу... Вакытлыча гына булса — бер хәл, ә гел — мөмкин түгелдер.

Шулай диде ханым, һәм мин аңладым — ул үзенең карашын әллә нинди фәлсәфәгә төреп маташмыйча ачык, туры гына әйтергә ярата икән...

Бик беләсем килде аның кем булуын. Нинди профес-

сия иясе, нинди эш кешесе икән ул? Алама традиция буенча аның анкетасы белән танышу өчен түгел бу, юк, ә чын ихластан беләсем килеп кызыксынуым иде. Үзе татар кызы, үзе Уралдан, кем булырга мөмкин? Безнең заманда бит кайчак һич уйламаган профессия кешеләре очрап куялар. Ә бу ханымның бөтен кыяфәте укыган, интеллигент кеше булуын әйтеп тора. Чынлап та кем ул?

Турыдан-туры: «Сез кем?» — дип сорап булмый, әлбәттә, шуңа күрә мин бераз хәйләгә керешеп, ягъни әле генә безнең арада барган сүзгә бәйләбрәк, ханым авызыннан үземә кирәкне алырга чамалап карамакчы булдым.

— Беләсезме, характерга профессиянең йогынтысы да бик зур бит,— дидем мин.— Мәсәлән, укытучылар шәхси тормышларында сүзгә саран булалар. Ихтимал, сезнең дә ялгызлыкны яратмавыгыз профессиягездән киләдер?

— Белмим, белмим,— диде ханым, көлемсерәгән килеш, башын чайкап,— һич сынаган нәрсәм түгел.

— Юк, дөрес бу... фән дә шулай ди. Менә сез, мисал өчен, миңа кайда, кем булып эшләвегезне әйтсәгез, мин сезнең характерыгызны шактый дөрес билгели алыр идем дип уйлыйм.

— Шулаймы?

— Чынлап әйтәм.

— Ай-һай, булмас.

— Ә сез юри генә әйтеп карагыз: кем булып, кайда эшлисез? Сер булмаса, конечно...

Ханым һаман шулай көлемсерәп, башын кырын салды да, каядыр югарыга карап, дәшми калды. Аның бу торышы миңа: «Юк инде, күпне белсәгез, тиз картаерсыз!» — дип әйтә иде кебек. Мин инде җавап көтми дә идем. Кем шаярып сөйләшүне чынга алып утырсын, нинди хатын үзе турында дөресен әйтергә ашыксын!

Ләкин... ашыгыбрак нәтиҗә ясаганмын. Ул самими беркатлылык белән, хәтта башын да шулай назлы гына кырын салган килеш, әйтте дә бирде:

— Мин... связьда эшлим... Сезнең Казанда ничек диләр әле, элемтә диләрме? Менә шул инде алайса, мин элемтәче булам!

— Бик әйбәт,— дидем мин, артык ни әйтергә белмичә. Ничектер көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты әле бу. Хуш. Элемтәче икән, дип уйладым мин эчемнән. Ләкин шулай да кем була соң инде ул? Хат ташучы да элемтәче, телефонда утыручы да, телеграм кабул итүче дә элемтәче. Шуларның берсе микәнни инде бу... интересный хатын! Юк, булмас, алай гына булмас, бер дә туры килми.

— Ягез,— диде ханым шул арада.— Менә белдегез инде, ни диярсез икән?

— Ни дә булса әйтүе читенрәк шул. Элемтәче — бик гомуми бит. Конкретрак мөмкин түгелме?

— Конкретрак?

— Әйе. Кайсы тармакта, ниндирәк эштә дигәндәй?

Ханым, бер күзен кыскандай итеп, аз гына уйланып алды.

— Була, конкретрак та була,— диде ул.— Тармагы дисәгез — шәһәр телефон челтәре. Эшләгән җирем АТСта. Беләсезме АТСның нәрсә икәнен? Белсәгез, менә шул автомат телефоннарны карап эшләтүче инде мин.

— Алайса сез элемтә инженеры?

Ханым аз гына чыраен сыткандай итте.

— Ну шулай да булсын.

— Ни өчен... шулай да булсын?

— Ул кадәресен нигә әйтеп торырга инде, үзеннән-үзе ачык түгелмени?

— Гафу итегез, ә нигә туп-туры гына әйтмәскә?

— Ярый, анысы кечкенә мәсьәлә,— диде ханым, ашыгып.— Йә, менә конкрет белдегез инде, хәзер, бәлкем, минем характерны әйтеп бирерсез.

— Бу эшегезгә караганда,— дидем мин, тамак кыргалап,— сез кешеләрне бик яратырга тиешсез.

Ханым артка каерыла биреп, кычкырып көлеп җибәрде. Искиткеч матур тавыш колагым төбендә яңгырады. Ләкин мин бу тавышка игътибар итүдән бигрәк, аның шул хәтле рәхәтләнеп көлүенә гаҗәпләнә калдым: болай көлү гадәттә эчкерсез балаларга гына хас була.

— Шәп психолог икәнсез,— диде ханым, ридикюльдән яулыгын алып.— Бик дөрес әйтеп бирдегез, кешеләрне яратам мин, тик элемтә инженеры булмас борын ук ул гадәтем бар иде.

Шулай итеп, бераз көлкегә калып булса да, мин максатыма ирештем — ханымның эшен-һөнәрен белдем. Әмма шуның белән бергә мин аның ниндирәк кеше булуын да шактый дөрес сиздем шикелле. Ачык, аңлаешлы, якты бер кеше булып тоелды ул миңа. Ничектер җиңел, рәхәт иде аның белән сөйләшүе. Гаҗәп табигый итеп тота икән ул үзен. Күп хатыннар шикелле, укам коела күрмәсен дип, бер дә юкка һаваланып маташмый икән. Шул ук вакытта нидер менә — мөлаем гадилегеме, әллә кеше белән тигез хөр була белүеме, әйтә дә алмыйм —әйе, нидер менә аңа соклану-хөрмәт белән карарга мәҗбүр итә иде. Минемчә, аның янында тыйнаксыз, әрсез яки ясалма булырга һич мөмкин түгел иде.

Шундый иркен, күңелле сөйләшеп утырудан соң, мин кузгалыр алдыннан гына кыюланып, аның исемен дә сорадым. Ул бер дә көттермичә гади генә итеп:

— Зөһрә,— диде.

Мин ни өчендер үзалдыма акрын гына:

— Зөһрә, Зөһрә,— дип кабатладым.

Ул сөйкемле, хәйләкәр генә елмаеп:

— Нигә, әллә берәр танышыгызны исегезгә төшердеме минем исем? — диде.

Мин аны-моны уйламыйча, ихлас күңелдән:

— Юк, алай түгел... Зөһрә — бик матур исем, мәшһүр мәхәббәт легендасын хәтерләткән исем, шуңа кабатлавым,— дидем.

Ханым дәшмәде, күрәсең, ошатып бетермәде минем сүзләремне.

...Мәйданчыкта утыручыларның күбесе кичке ашка кереп киткәннәр иде инде — без дә кузгалдык.

## IV

Тагын берничә көн узды. Санаторий шартларына ияләштек, ял, дәвалану бер эзгә төште, көннәр, бер-берсенә охшап, сиздермичә генә үтә тордылар.

Инде миңа үз хәлемне аңлап карарга вакыт иде. Беренче дулкынланудан соң, ничектер, тынычланган кебек тә булдым. Гүя, күңелем күле өстеннән кискен җил кинәт кенә исеп узды да тынып калды ул... Ләкин бу вакытлы гына шулай иде шикелле. Ихтимал, куәтле давыл алдыннан була торган алдаучан тынлык кынадыр... Чөнки мин «аның» турында уйлаудан бер генә минутка да туктый алмый идем.

Була шундый хәл: беркайчан да үзең ишетмәгән, ләкин бар булып тоелган гаҗәеп матур көйнең бер килеп ишетелүен көтеп йөрисең. Һәм менә, көткән көй ишетелгән төсле булып, ниһаять, «ул» миңа очрады... Очрады һәм күпме шикләр, күпме каршылыклы уйлар да кузгатып өлгерде.

Мәхәббәт! Минем кебек төрле мәҗбүриятләр белән бәйләнгән кеше өчен ансат эшмени ул мәхәббәт! Телдән әйтелмәгән, кулдан язылмаган нинди рәхимсез тыюларга буйсынырга тиеш ул!

Мәҗбүрият дигәннән, Зөһрә ханым үзе бу җәһәттән нindiрәк хәлдә икән? Ире, гаиләсе бармы аның, юкмы? Ихтыярсыздан һаман шул турыда уйланам. Ә бәлкем, ул ялгыз ханымдыр? Безнең заманда ялгыз ханымнар шак-

тый еш очрый бит. Ни өчендер мин аның шулай ялгыз булуын телим, гүя ул миңа ниндидер хокук бирәчәк, ләкин ничек итеп моны белергә? Хәер, озак та үтми бу нәрсә үзеннән-үзе ачыкланды.

Шулай көннәрнең берендә, мин вакытсыз уянып, бик иртә торып бакчага чыктым. Күп булса, сәгать алтылар чамасы гына булгандыр, санаторий әле тирән йокыда, тик пумала һәм чиләк тоткан бер хатын гына түбәнге катның вестибюлен чистартып йөри иде. Бакчага чыгып, иртәнге табигатьнең йомшак тынлыгына сокланырга һәм җан дәвасыдай шифалы һаваны киерелеп-киерелеп суларга өлгерә алмадым, паркның төп аллеясы буйлап Зөһрә ханымның каяндыр кайтып килгәнен күрдем. Бик гаҗәпләндем мин бу хәлгә. Күзләремне ала алмыйча, аны көтеп тора башладым. Өстендә аның халат өстеннән генә кигән кыска жакет, башында ияк астыннан китереп бәйләгән шакмаклы йон косынка иде. Килеп җиткәч, ул миңа «хәерле иртә» диде, бит урталары аның кызарган иде, гадәттә күләгәләнеп торган күзләре, чык бөртегенә нур төшкәндәй, куанычлы елтырыйлар иде, ашыгып килгәнгә, ахрысы, түшләрен тирбәтеп, тирән сулый иде...

Мин гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча:

— Сез кайдан болай? — дидем.

— Почтадан,— диде ул.

— Почтадан? Бу кадәр иртә нинди йомышыгыз төште?

— Картым белән сөйләштем,— диде ул, минем күзләремә туп-туры карап.— Иртән бик ачык ишетелә, менә шулай кара-каршы сөйләшкән кебек...

Мин тынып калдым, шул ук вакытта ханым берәр нәрсә сизә күрмәсен дип куркып та куйдым. Нидер әйтергә кирәк иде, ләкин кинәт сөйләү сәләтемне югалткан кебек булдым. Ярый әле, бәхетенә йотылган ханым, аны-моны сизмичә (ә бәлкем, сизгәндер дә), үзе яңадан сөйләп китте:

— Башта ук шулай сөйләшеп куйган идек: ул мине телефонга һәрвакыт иртән чакырырга булды.

— Сезнең йокыгызны кызганмыйчамы? — дидем мин, ничектер бик аптыраган кеше сыман.

— Нәрсә ул йокы? Җан тыныч булганда, йокларга вакыт табыла.

— Нигә... җаныгыз бик үк тыныч түгелмени?

— Юк, тыныч, бик тыныч...

— Димәк, ул борчыла?

Зөһрә ханым, елмаеп, миңа хәйләкәр генә күз сирпеп куйды.

— Ул да борчылмый, тик... сагынам, ди, мескенем!

Һәм колак төбемдә кинәт көмеш кыңгырау яңгырап китте — шундый сихри итеп ханым бер көлеп куйды да ашыгып вестибюльгә кереп тә югалды.

Мин баскан урынымда бераз тынып тордым да аулак аллеяларның берсе буйлап акрын гына китеп бардым... Менә барысы да ачыкланды: ул ялгыз түгел, аның «карты» бар... Әйе, аның кебек чибәр хатынның ире булмыймы соң! Ахмак, башта ук моның шулай икәнен белеп торырга тиеш идең син!.. Булмас өметләргә юл куймаска, йөрәгеңдә кузгала башлаган хисне, көчәймәс борын, рәхимсез рәвештә буарга тиеш идең син! Кеше кешесе ул, хакың юк синең, хакың юк!

Ләкин... Дөресме бу? Йа Хода! Әйтерсең мәхәббәт минем «тукта, яратыйм әле» яки «юк, яратмыйм» дип үземәүзем сүз бирүгә карап йөри ул! Юк бит, юк! Аяусыз бер хакыйкать бар: мәхәббәт кешенең үзеннән сорап килми, сорап китми, ул ихтыярдан өстен көч... Йөрәгемә минем мәхәббәт чаткысы төште, ул көйрәргә тотынды, ниһаять, ул кабынды. Йә, әйтегезче, кемнең аны сүндерергә хакы бар, нинди көч аны сүндерә ала?.. Нигә суфиланып, үзүзеңне алдап маташырга?

Күземә бер эскәмия чагылды, шуңа барып утырдым. Гаҗәп, шундый бай, купшы табигатьтә кошлар аз, кошлар сайравы ишетелми. Инде вакытлары узып, сайраудан туктаганнар дияр идең, әле бит җәйнең башы гына, бездә бит әле бу чакта бакчалар, урманнар кошлар тавышыннан чыңлап торалар... Әллә ишеткән идем, әллә укыган идем — диңгез буенда сайрар кошларның булмавы елгалар юклыктан килә, имеш, чөнки тозлы диңгез суы аларга ярамый, шунлыктан монда калмыйлар, имеш. Бәлкем, дөрестер дә... Әйе, кошлар сайрамый, ә менә Зөһрә ханым ничек итеп көлде! Кошлар сайравына биргесез иде бу көлү! Әле дә булса колагымда яңгырап тора. Гүя ерактан үзенә чакырып торган сихри бер өн ул! Йә, ничек итеп шул дәшүгә таба барудан тыела алыйм мин, ничек итеп «аны» күрүдән ваз кичим мин?

Ни булыр, ни булыр?!

Шундый бер әкият ишеткәнем бар: гөлҗимеш куагы чәчәк аткач, сандугач тына, имеш, чөнки шуның чәчәгенә гашыйк булып, сайравын оныта, имеш. Шуның төсле мин саескан да эшемне-көнемне онытып барам. Кандидатлык диссертациямә аз булса да хәзерләнермен дип (мин үзем тарихчы, күптән тарих укытам), ярты чемодан әдәбият төяп килгән идем, шуларга тотынып караганым да юк. Безнең язучылар, мәхәббәткә дучар булган кеше таулар актара,дип язалар язуын, ләкин һәр очракта да алай

булып чыкмый, күрәсең! Әгәр шуннан мәхәббәткә каршы мәхәббәт булса, ул чакта эш башка, ул чакта, бәлкем, «таулар актарып» булыр иде.

Шактый гына вакыт үтте булса кирәк, бакча юлларында санаторийның чуар халкы күренә башлады, көлгән, сөйләшкән тавышлар ишетелде. Ул да булмый, бина алдындагы мәйданчыкта аккордеон тавышы яңгырады. Баянист Миша, көндәлек гадәтенчә, ял итүчеләрне иртәнге физзарядкага чакырып, беренче вальсны уйнап җибәрде.

Миңа да барырга кирәк иде... Әллә ничек шунда: мәхәббәт һәм физзарядка!.. Эч поша, йөрәк яна, күңелдә меланхолия, башта философия, шайтан алгыры! Ә син шул чакта йөгерергә, сикерергә, бөгелергә, сыгылырга тиешсең... Мәгънәсезлек, валлаһи!

Ләкин... мәхәббәт тотучылар өчен биредә аерым кагыйдә юк. Бәс, шулай булгач, барырга кирәк.

## V

Хәзер бәхәссез инде: мин Зөһрә ханымга гашыйк булдым, мин яратам аны. Өметсез, берни вәгъдә итмәгән мәхәббәт белән яратам мин аны... Моның өчен һич үкенмим, хакым юк дип хисемне йолкып ыргытырга тырышмыйм, әйдә, тирән бер ләззәт һәм газап белән татып калыйм дим. Дөрес, баштарак тыелырга, йөрәгемне тынычландырырга, мәхәббәтне акыл белән җиңәргә чамалап карадым, ләкин аңардан берни дә чыкмады. Ахыр чиктә мин, озак, газаплы уйлардан соң, бу «законсыз» туган, әмма шуңамыдыр аеруча кадерле булган үксез мәхәббәтемне, көчемнән килгән кадәр, Зөһрә ханымның үзенә сиздермәскә дигән карарга килдем.

Без һаман шулай үткән-сүткәндә очраша торабыз, ләкин әлеге иртән иртүк очрашып сөйләшүдән соң безнең арада яңадан сүз булганы юк иде әле. Ул чакта миңа бөтенесе ачык, Зөһрә ханым турында белер нәрсә калмады, хәзер инде очрашуның да, сөйләшүнең дә кирәге юк кебек тоелган иде. Ләкин икенче көнне үк мин бик нык ялгышуымны аңладым. Алай җиңел генә кул селтәүдән минем хәлем узган иде инде. Кая ул! Аеруча бер сабырсызлык белән мин аны юксына, сагына башладым. Сәгать саен, минут саен минем аны күрәсем килә иде. Күрәсем, сөйләшәсем, көлгәнен ишетәсем килә иде.

Якшәмбе көнне иртәнге аштан чыккач, мин аны уйламаганда икенче катның вестибюлендә очраттым. Исән-

ләштек. Минем бер планым да, ачык кына теләгем дә юк иде, шулай да аны туктатып, кыю гына мондый сорау бирдем:

— Зөһрә ханым, бүген сез нишләргә уйлыйсыз?

Ул көтелмәгән сораудан гаҗәпләнгән сыман миңа карап алды да иңбашын җыерыбрак:

— Нишләргә уйлыйм? — диде.— Бер дә әйтә алмыйм... Нигә сорыйсыз?

— Бүген — якшәмбе бит,буш көн, кая да булса барырга уйламыйсызмы дим?

— Юк, уйлаганым юк... Ә кая барасың?

Мин дусларча ихластан, әмма гади генә итеп:

— Зөһрә ханым, минем сезгә бер тәкъдимем бар,— дидем.— Әйдәгез, «Дендрарий»га барыйк... Көнозын буш санаторийда вакыт уздыру күңелсез булыр. Бер йөреп кайтырбыз.

Зөһрә ханым аз гына уйланып торды.

— Минем анда булганым бар инде,— диде ул, ничектер назлы-сүлпән генә итеп.— Үткән ел килүдә...

— Бигрәк тә яхшы,— дидем мин, өлгер генә.— Миңа паркны күрсәтерсез, минем әле анда булганым юк... Шуннан шәһәргә узарбыз, кайтканда — диңгез белән, глиссерда кайтырбыз. Күңелле булып калыр. Чын-чын.

Зөһрә ханым, читкә карап, тагын беraз уйланып торды: үзенчә ничегрәк итеп баш тарту турында уйланамы инде? Гаеп эш түгел ләбаса!

Ахырдан ул:

— Ярый алайса,— диде.— Тик сезгә бераз көтәргә туры килер, минем кереп, киенеп чыгасым бар.

— Рәхим итегез, пожалуйста... Мин сезне түбәндә көтәрмен.

Ул өченче катка менеп китте, ә мин, канатлар үскәндәй, түбәнгә ашыктым... Бина алдында арлы-бирле йөргәләп аны көтә башладым.

Ә санаторийда беркем юк диярлек, ял итүчеләр шәһәргә, паркларга, төрле җирләргә экскурсиягә таралышып беткәннәр. Бушап калган зур бинада ялгыз көн уздыру нинди күңелсез булыр иде. Ярый әле мин аны тәвәккәлләп чакырдым. Һәм аның риза булуы мине бер дә гаҗәпләндермәде. Ахыр чиктә без дә ял итүчеләр ич!

...Менә ул җиңел атлап ишектән килеп чыкты. Өстендә ак ефәктән җәйге костюм. Аякларында биек үкчәле кара елтыр туфлиләр... Яланбаш, тик чәчләрен артка җыеп, кызыл тасма белән бәйләгән. Кулында нечкә саплы кытай зонтигы...

Мин, туктап, сүзсез генә аны каршы алдым. Ул килеп җитте, минем онытылгандай һаман карап торуымнан, ахрысы, уңайсызланыбрак елмайды, миңа туры карамаска тырышып: «Киттекме?» — диде.

— Киттек!..— дидем мин, эчтән генә тирән сулап.

Без иң элек үзебезнең парк аша шәһәргә илтә торган асфальт юлга чыктык. Биредә бик әйбәт автобуслар йөреп торалар. Курорт шәһәрен буеннан-буена кисеп узган, ике ягыннан да төп-төз пальмалар тезелеп киткән бу зур юлда хәрәкәт гомумән бик көчле иде. Әледән-әле Хоста — Гагры ягына таба экскурсантлар төягән түбәсез ачык машиналар үтеп китәләр, ниндидер үзләренә генә хас тавыш чыгарып чапкан шәп, чибәр «Зим»нар, «Зис»лар, «Победа»лар бер-бер артлы узып кына торалар.

Без дә озак көтмәдек. Яңа автобус шома гына алдыбызга килеп туктады: утырдык, киттек.

«Дендрарий» паркы бездән шәһәргә таба. Юлы артык озын булмады, бишме-алтымы тукталышны узгач та без барып җиттек. Якшәмбе көн булгач, бирегә дә халык шактый күп килгән икән... Ике рәт колонналар тезеп, көянтә сыман ярым түгәрәк формада эшләнгән матур капка алдында бераз гына чират та бар иде. Бу хәл минем эчемне пошырып куйды. Дөресен әйтим, ишле халык арасында бер дә буталып йөрисем килми иде... Ләкин пошыну бушка булды... Иркен парк эченә кергәч тә халык төрле якка таралып та бетте.

Без башта төп аллея буйлап бераз югары күтәрелдек, аннан, уртасында канатлы амурлар басып торган түгәрәк фонтан янына җиткәч, сулга борылдык һәм озак та үтми үзебезне тып-тын, буш бер матур аллеяда күрдек... Биредә гомумән эреле-ваклы юллар бик күп икән. Аларның кайберләре борылып-борылып куе агачлыклар арасына кереп югалалар; кайберләре туры гына барып, йә берәр беседка, йә берәр фонтан янына илтеп чыгаралар... Кайбер аллеялар буйлап тик бер генә төрле агачлар үсеп утыралар. Һәм шул агачлар исеме белән аларны «Пальмалар аллеясы» яки «Кипарислар аллеясы», яки «Платаннар аллеясы» дип атап та йөртәләр икән.

Инде бу парк үзе тулаем нинди җир, нәрсәсе белән ул атаклы дисәк, кыскача гына шуны әйтергә була: «Дендрарий» дип бик күп төрле агачларны бер җиргә җыеп үстергән зур бакчага әйтәләр икән. Биредә дә дөньяның төрле почмакларыннан — Һиндстаннан, Кытайдан, Япониядән, Австралиядән, Африкадан, Америкадан китерелгән бик күп төрле гаҗәеп агачлар үсеп утыралар. Шунлыктан халык бирегә, матур урында ял итәр өчен

генә түгел, карап йөрер, хикмәтле нәрсәләр ишетер өчен дә килә. Бакчаның фәнни сотрудниклары, төркем-төркем халык ияртеп, шул гаҗәеп агачлар турында сөйләп йөриләр.

Без инде, төркемгә кушылып, экскурсовод тыңлап йөрмәдек. Дөрес, Зөһрә ханым башта, берәрсенә иярмибезме, дип сораган иде дә, мин көлгән булып, сез үзегез генә экскурсовод булырсыз инде, дидем. Миңа бит бөтенесеннән бигрәк аның белән икәүдән-икәү генә булу кадерлерәк, аның сүзен, аның тавышын ишетү кыйммәтрәк иде. Ә агачлар турында күбрәк беләсем килсә, бер җай табып, ялгызым гына килеп китәрмен әле...

Зөһрә ханым, минем сорашканны да көтмичә, «Дендрарий» турында белгәннәрен сөйли дә башлады. Нигә ул алай иткәндер инде: сүзсез йөрмәс өченме яки сүз кирәкмәгән якка кереп китмәсен дипме — хатын-кыз уен ничек сизеп бетерәсең.

Башта ул «Дендрарий»ның тарихы турында шундый кызык кына нәрсә сөйләде: имеш, революциягә кадәр бу бакчаның хуҗасы берәр тиенлек кенә китаплар бастырып сатучы бер нашир булган ди. Бакчадагы зур йортларны, матур беседкаларны һәм фонтаннарны, төрле җирләргә куелган статуяларны — барысын да шул кеше эшләткән ди. Хәтта хәзер үсеп утырган агачларның да шактый өлешен ул ерак илләрдән китерткән, имеш... Менә сиңа берәр тиенлек китап бастыручы!

Аннан Зөһрә ханым мине юлда очраган кайбер агачлар белән таныштыра башлады. Менә бер бик биек, төптөз, ботакларын түбән салындырып үскән агач янына туктадык. «Мамонт агачы» дип атала икән үзе... Америкадан килгән. Безнең якның ылыслы агачларына охшаган... Минем бер нәрсәгә исем китте: шушы, күтәрелеп карасаң, бүрек төшәрлек биек агачка бары утыз ике генә яшь икән әле. Гаҗәп! Зөһрә ханым әйтә, Америкада аларның шундый юаннары бар, ди, әгәр киссәң, түмгәге өстенә зур гына танцы мәйданчыгы ясап була, ди. Агач үзе ике мең ел яши икән... Менә бу, ичмасам, гомер!

Мин, әлбәттә, аңардан ишеткән бөтен нәрсәгә берсүзсез ышана идем, чын-чынлап гаҗәпләнә идем, чөнки ул сөйләгәч, барысы да дөрестер кебек иде. Бәлкем, ул аратирә әз генә арттырып та җибәрә торгандыр, ләкин зарар юк, аның шулай матурлау өчен өстәп җибәрүен тыңлау үзе дә күңелле ич!

Көн бүген искиткеч тын, якты. Һавада диңгез дымы нык сизелә, шуңа бераз бөркү дә... Акрын гына бара торгач, без «Кипарислар аллеясы»на килеп кердек. Җылы

якның иң сылу агачлары болар... Һәрберсе шәмдәй төп-төз утырганга күрә, аларның кара күләгәләре, тигез якты аралык калдырып, юлга аркылы ятканнар. Аллеяның буена карасаң, чиратлашып киткән бу якты-кара басмалар ничектер сөзәк кенә күтәрелгән мәрмәр баскычны хәтерләтәләр... Һәм без икәүдән-икәү генә шул мәрмәр баскычтан каядыр икенче бер сихри дөньяга күтәреләбез кебек...

Аллеяны үтеп, кечкенә аланлыкка чыккач, Зөһрә ханым тукталып, миңа әкәмәт кенә бер үсемлекне күрсәтте. Җирдән үк калын, озын кыякларын чыгарып үскән бу сыек яшел төстәге үсемлек агава дип атала икән. Болай карап торырга бер дә ямьле нәрсә түгел, әмма нинди гаҗәп гадәте бар икән аның... Зөһрә ханым әйтә, ул, ягъни агава, үз гомерендә бер генә тапкыр чәчәк ата, ди; чәчәген койгач, үзе дә һәлак була, ди.

Ихтимал, бу дөрес тә түгелдер, матур бер легенда гынадыр, ләкин ул мине тирәнтен дулкынландырып өлгерде. Ничектер менә күптән, бик күптән күңелемдә йөргән бер хыялның җанлы үрнәге булып күренде ул миңа... Әйе, үз гомереңдә бер мәртәбә чын-чынлап яратсаң иде дә шул ярату белән актык көнеңәчә бәхетле булып яшәсәң иде. Бик кадерле, бик тансык хыял бу минем өчен... Тормышта аның үрнәге бардырмы — белмим, әмма минем үземә ул бәхет насыйп булмады.

— Ошый, бик ошый миңа бу тәбәнәк үсемлекнең андый гадәте, дидем мин Зөһрә ханымга.

— Нинди гадәте?

— Менә сез әйткәнчә бер генә мәртәбә чәчәк атуы...

Зөһрә ханым гаҗәпләнгән сыман нечкә кашларын сикертеп куйды.

— Ни өчен?

— Кеше дә, дим, шушы үсемлек төсле, үз гомерендә бер генә мәртәбә мәхәббәт кичерсә иде.

— Нигә, мәхәббәтне берничә мәртәбә дә кичереп буламыни?

— Була икән шул, Зөһрә ханым!

— Һай, мин тиле! — диде Зөһрә ханым, көлеп.— Белми идем әле мин моны, белми идем... Яшь чакта бер чынлап яратасың да шуның белән тәмам, гомереӊ буена җитә шул дип уйлап йөри идем...

— Яшь чактагы беренче мәхәббәт бит ул, беләсезме, күп вакытта беренче исерү генә булып чыга,— дидем мин дә шулай шаярткан төслерәк итеп.— Ә чыны соңрак, акылга утыргач, ак белән караны аера башлагач килә... Тик, кызганычка каршы...

Мин әйтеп бетермичә, тирән көрсенеп, кулларымны гына җәеп җибәрдем, ә Зөһрә ханым шундук сорап куйды:

— Йә, нәрсә «кызганычка каршы»?

Мин «әйтергәме, юкмы?» дип тиз генә уйлап алдым. Ләкин артыгын әйтү ярамый иде, шуңа күрә бары:

— Кичегеп килә ул... чын мәхәббәт,— дидем.— Күп кенә хәлләрдә бик кичегеп килә.

Белмим ни өчендер, Зөһрә ханым озак кына дәшмичә барды. Ул уйчан иде, бу хәл мине берникадәр борчый да башлады. Әллә берәр төрле шик тудымы аның күңелендә?

Ниһаять, ул, үзенә ят бер фикерне кире кагарга теләгәндәй, башын чайкап әйтте:

— Юк, яшьлек мәхәббәтеннән дә саф, чын мәхәббәт булмыйдыр... Юк, ышанмыйм мин...

— Төрле кеше белән төрлечә була торгандыр инде ул,— дидем мин, аның белән бәхәскә керергә теләмичә, ә үзем эчемнән генә: «Их, Зөһрә ханым, әгәр мин сезгә башымнан кичергәннәрне сөйләп бирә алса идем, ихтимал, сез минем хәлемне аңлар идегез»,— дип уйлап куйдым.

Кинәт Зөһрә ханым минем җиңемә орынып:

— Карагыз әле! — диде һәм көрән төстәге бер кечкенә агачка төртеп күрсәтте. Агачның сокланып карарлык бер нәрсәсе дә юк иде кебек, шунлыктан аңа бер дә исем китмәде. Ләкин Зөһрә ханым һаман мине кызыксындырырга теләп:

— Сез аның язуын укыгыз! — диде һәм үзе үк нечкә бармагын күтәреп, агач төбенә кадап куйган кечкенә тактаны ягымлы тавыш белән өзеп-өзеп кенә укып чыкты: «Ти-яргә яра-мый, а-гу-лы!..» Бу сүзләргә ул ниндидер бүтән мәгънә салган кебек тоелды миңа, һәм мин дәшмичә калырга мәҗбүр булдым.

Без тагын күп кенә агачларны: тәүлегенә берәр метр үсә торган бамбукларны, яфракларының озынлыгы икешәр-өчәр метрга җиткән бананнарны, төрле-төрле гаҗәеп матур пальмаларны карап уздык. Зөһрә ханым, әле яңарак кына безнең арада шактый четерекле сөйләшү булып алганын оныткан шикелле, бик мавыгып шул агачлар турында сөйләп йөрде. Мин тыштан кызыксыну күрсәтсәм дә, уйларым, дөресен генә әйткәндә, хикмәтле агачлардан еракта иде. Тик лавр агачы гына бераз кызыксындырды. Бу агачның яфракларыннан, мәгълүм булганча, данлык таҗы үрәләр... Әгәр үзенә бер тәмле ис аңкытып торуын искә алмаганда, аның әллә нәрсәсе юк та кебек. Ни өчен аңа шундый дәрәҗә бирелгән? Зөһрә ханым әйтә, аның яфраклары мәңге яшел һәм бервакыт-

та да коелмыйлар, ди. Кул белән генә өзеп алырга була, ди... Чынмы икән бу?.. Ләкин бу туры килә: яулап алынган дан да бит мәңге шулай саргаймый да, коелмый да.

Йөреп арыгач, без калкулык битендәге бер эскәмиягә ял итәргә утырдык, аякларга рәхәт булып китте. Алдыбызда ачылган матур, җылы, сөйкемле күренешкә — яшел аланга, чәчәккә күмелгән куакларга, сап-сары юлларга карап, бераз тынып утырдык. Түбәндә, әлеге без узып киткән зур фонтан янында, халык кайнаша. Анда паркка килүчеләр төркем-төркем булып рәсемгә төшәләр...

Әнә бер зур гына төркем яшьләр фонтан алдына тезелеп маташалар. Берничәсе фонтан читенә дә менеп басты. Фотограф, кара япмасын бөркәнеп, төшерим дигәндә генә егетләрнең берсе, аягы таепмы, фонтан эченә төште дә китте... Моны күреп, Зөһрә ханым кычкырып көләргә тотынды. Тәмам онытылып, рәхәтләнеп көлә ул, ә мин шаккатып аның көлүен тыңлап тордым. Гаҗәп иде бу көлү, нәрсәгә охшатырга да белмим мин аны... Үзенә бер мелодия!

Зөһрә ханым, нидер сизенгәндәй, кинәт көлүеннән туктады да миңа борылып карады. Минем көлмичә тын гына утыруымны күреп, ул бик гаҗәпләнде.

— Сез әллә күрмәдегезме?

— Кемне, нәрсәне? — дигән булдым мин, юри аңламаган булып.

— Әнә ич түбәндә бер егет, фотограф: «Внимание!» дигәч кенә, фонтанга шуып төште дә китте.

— Ә, аны... күрдем.

— Ә нигә көлмисез? — диде Зөһрә ханым, балаларча беркатлылык белән.

— Минем өчен... кызыклысы анда түгел, биредә иде.

— Ниче-ек?

— Сезнең көлүегез белән сихерләндем,— дидем мин, мөмкин кадәр гади әйтергә тырышып.

Зөһрә ханым берьюлы җитдиләнеп китте, бераз дәшми утырды, аннан салкын гына сорап куйды:

— Комплиментмыни инде бу?

— Һич алай түгел,— дидем мин ашыгып,— саф дөресен әйтүем... Сез үзегез дә беләсез ничек көлүегезне... Беренче тапкыр ишеткән кешенең сихерләнмичә калуы мөмкинме соң?.. Ачуланмагыз миңа, мин әйткәнне сезгә әйтүчеләр күп булгандыр...

Белмим, ихлас күңелдән чыккан сүзләр тәэсир иттеме, әмма Зөһрә ханым йомшара төште һәм ничектер, ихтыярсыздан булса кирәк, гаҗәеп бер сүз ычкындырып куйды:

— Башкаларның әйтүен мин колагыма да элми торган идем.

Мин кинәт тынып калдым. Бик мәгънәле сүзләр булып ишетелде бу миңа... Ничек дип аңларга, ничек кабул итәргә моны? Нәрсә әйтмәкче ул моның белән? Зөһрә ханым үзе дә нидер сизенеп, минем ялгыш нәтиҗә ясавымнан курыккан төсле, тизрәк «төзәтергә» ашыкты:

— Сездән арзанлы комплимент яки дөрес булмаган нәрсә ишетәсем килми минем... Минемчә, сез алардан өстен торасыз.

Дулкынландырды мине бу сүзләр.

— Рәхмәт, Зөһрә ханым, рәхмәт, яхшы сүзегез өчен,— дидем мин, дулкынлануымны сиздермәскә тырышып.— Ышаныгыз, нәрсә генә әйтсәм дә, мин сезгә бары тик саф дөресен генә әйтәчәкмен... Ләкин... бер үтенечем бар: зинһар, сез миннән тартынмагыз, үзегезне иркен тотыгыз... Шулай яхшырак булыр.

Зөһрә ханым йомшак кына елмайды.

— Мин үземне бүтәнчә тота белмим... Өйрәнмәгәнмен. Ләкин... ләкин...— Ул күз кырые белән миңа хәйләкәр генә карап алды.— Бер эштә сак булырга туры киләчәк.

— Нинди эштә?

— Сезне бик сихерләргә ярамас, дим. Зарарлы ич ул, сихерләү!

Мин аның нәрсәгә ишарә ясавын аңладым.

— Юк, курыкмагыз, зинһар! — дидем мин, сөенеп.— Рәхәтләнеп көлегез! Чын-чын. Музыка да сихерли ич, ләкин аңардан кешегә ни зарар?

— Шулай да күп ярамый, әни «мәэмәй» итәр,— диде ул, сөйкемле генә назлангандай итеп, һәм урыныннан торды.— Киттек инде булмаса!

Парктан чыгышлый без «Мавритан беседкасы» аша үттек. Бу искиткеч матур архитектура үрнәге иде. Ул җирнең сөзәкләнеп төшкән бер җиренә ак мәрмәр колонналардан салынган берничә түгәрәк беседкадан гыйбарәт. Шундый ук мәрмәр колонналардан гына торган сөзәк коридор борылып беседкадан беседкага төшә. Ә тышкы яклап бөтен әйләнәсендә ерак илләрдән килгән гаҗәеп төрле агачлар һәм чәчәккә баткан куаклар үсеп утыра...

Беседкага килеп кергәч, үзеңне икенче бер дөньяга күчкәндәй хис итәсең. Борын заман, чит җирләр, чит халыклар хыялдан уза. Бер мәлгә үзеңне гарәп шаһларының гөлбостанында күргәндәй буласың... Кешенең кодрәте нинди зур! Таш өя һәм шуның белән хыялыңа канатлар бирә.

Без, Зөһрә ханым белән, беседкаларның һәр ташына, һәр бизәгенә сокланып карый-карый, акрын гына икенче башына килеп чыктык. Чыккан җиребездә ике яклап таш күтәртмәләр өстендә ике мәһабәт бронза арыслан ятып тора... Әйе, биредә аларның булмавы мөмкинме соң!

Бөтен күргәннәр өстенә бу беседкаларны да күрү кәефкә бик ошады. Эчке дөньябыз тагы да беркадәр матурлана, байый төшкән кебек булды. Кәеф дигәннән, Зөһрә ханым минем белән бергә килергә риза булгач, күңелемне аеруча бер рух күтәренкелеге биләп алган иде. Гүя менә гел шатланып, көлеп кенә йөрер төсле идем. Ләкин андый җиңел кәеф миңа килмәде. Ниндидер бер татлы моңсулыкка төренгән басынкы уйчанлык иде миндә... Ләкин шул ук вакытта искиткеч рәхәт тә иде миңа, гомеремдә беренче кат сөенеч тапкан үксез бала бәхетен татый идем мин... Тик моның тиздән үтәчәген белеп тору гына йөрәгемнең бик тирән, яшерен бер җирен чак кына сыкратып тора иде.

Башта сөйләшкәнчә, без диңгез белән кайтырга булдык. Моның өчен шәһәргә портка киттек. Якшәмбе көн булгач, халык кайда да күп иде, шулай да, артык зарыкмыйча, без буш глиссерны көтеп алдык. Глиссер — киң төпле, гаять тиз йөрешле моторлы көймә. Без менә шуңа утырып киттек.

Көн болай җилсез кебек булса да, диңгез өсте тыныч түгел иде. Офык түреннән ак чаллы дулкыннар салмак кына куышып киләләр. Безнең көймә шул дулкыннарның сыртына тияр-тимәс кенә очып бара. Кайчак зуррак дулкынга очрап, көймә сикереп-сикереп китә, дулкын аның төбенә яман шапылдатып сугып кала, шул чакта безнең эчебез кытыкланып киткәндәй була. Азрак шомлы да һәм бик күңелле дә!

Әмма иң күңеллесе — диңгездән яр буена карап бару иде. Таулар, таулар артында тагын таулар — алары ак башларын гына күрсәтеп торалар... Якындагы таулар, түбәләреннән алып итәкләренә хәтле, тоташ куе бөдрә яшеллек белән капланган; бу гаҗәеп урманда Мәскәү каеныннан алып Австралия эвкалиптларына кадәр үсәләр. Менә шул купшы яшеллек эченнән берсеннән-берсе матур ак сарайлар диңгез өстенә карап торалар. Алар күп, кайсылары зур, кайсылары кечкенә, кайсылары биектә, кайсылары түбәндә — һәм менә шулай һәркайсы, яшел хәтфә өстендә яткан асыл ташлар төсле, аерым-аерым күренеп торган өчен дә бу шәһәр искиткеч гүзәл, искиткеч мәһабәт.

Белмим, шушы карап туймаслык күренеш тәэсирендәме, янымда җылы беләге белән минем беләгемә терәлеп утырган Зөһрә ханым бу минутта миңа аеруча кадерле, аеруча якын булып тоелды. Ихтыярсыздан гаҗәпләнеп уйлыйм: ни өчен моның кебек шагыйранә бер җирдә мәхәббәт ямьсез, мәхәббәт кирәксез булырга тиеш? Кайда матурлык, шунда мәхәббәт булырга тиеш түгелмени? Чыннан да, әгәр мәхәббәт булмаса, дөньяның бу байлыгы, бу гүзәллеге кеше өчен үзенең кыйммәтен югалтмас идеме?.. Ихтимал, бу бик иске фәлсәфәдер, ләкин чын булырга тиеш, югыйсә минем кебек мәхәббәт тотучының башына кайдан килеп керер иде ул!

Ахырда без үзебезнең санаторий турына килеп җиттек. Көймә киң борылыш ясап, озын басмага янтыгы белән килеп туктады. Башта үзем чыгып, аннан Зөһрә ханымны кулыннан тотып чыгардым.

Акрын гына тауга күтәрелдек. Арыган идек, бер төштә утырып ял иттек. Күзне иркәләгән, хыялны әллә кайларга алып киткән диңгез түренә карап, сүзсез генә ял итеп утырдык. Юк, онытылмас бу көн минем өчен, онытылмас!

## VI

Менә минем килүемә ике атна да үтеп китте. Яхшы тәрбия, даими ял һәм дәвалану, шулар өстенә бай табигать, шифалы һава, диңгез һәм кояш акрынлап үзенекен итә: сәламәтлек ныгый, көч арта, кәеф яхшыра, рух күтәрелә — тагын ни кирәк? Шуңа күрә дә халык шат,- халык ваемсыз, уйный-көлә, йөри-кәефләнә. Ул ай чамасы вакыт эчендә үз өлешенә тигән бөтен мөмкинчелектән файдаланып калырга, рәхәтен күрергә тырыша... Һәм бик дөрес итә, ял итүченең моңа тулы хакы бар, асылда бит биредәге бөтен нәрсә аның үз байлыгы.

Тышкы яктан мин дә йөзләрчә ял итүчеләрнең берсе булып яшим, мин дә бөтен нәрсәдән канәгать, ныгытып ашыйм-эчәм, диңгезгә йөрим, кояшта кызынам, кыскасы, кешедән бер дә калышмыйм. Кәефем минем начар түгел. Сәламәтлек яхшыра, тән тазара, җаным шуны тоеп сөенә... Әмма рухым минем бүтәнчәрәк. Төшенке димәс идем мин аны... Юк, төшенке түгел! Ләкин ничегрәк дип аңлатырга? Тын кырлар өстенә яткан кичке шәфәкъ вакыты кебегрәк димме — үзем дә белмим. Һәрхәлдә, шуңа охшаган ниндидер бер моңсу тынлык эчемә тулган кебек минем... Башкалар төсле гамьсез, шат була алмыйм, күп нәрсә белән кызыксынмыйм да, күбрәк ялгыз буласым килә, ялгызым гына уйланып йөрергә гадәтләнә башладым.

Шуңа карамастан мин эч пошу, йөрәк сызлану кебек нәрсәне хис итмим. Хәтта рухымны биләгән әлеге кичке шәфәкъташ моңсу тынлык миңа сәер бер рәхәтлек бирә кебек... Ихлас! Кичке шәфәкъның да үз матурлыгы бар ич!

Табигать белән җан уртаклыгы тапкан кебек булдым. Бик иртә торып, аулак бакчага чыгам, буш аллеялар буйлап йөрим, туктап-туктап табигатьнең сулышына колак салып торам. Төрле өннәрне, төрле кыштырдауларны ишетеп, шуларның нидән булуын, кайдан килүен белергә тырышам. Кош-кортларны күзәтәм, чәчәкләргә тик кенә карап торам... Бернәрсә хакында уйламыйм да кебек, әмма акылымның өзлексез кемгә таба юнәлгәнен бик яхшы белеп торам.

Кайчак мин шушы иртәнге сәгатьтә «аның» зур аллея буйлап кайтып килгәнен күрәм. Мин беләм «аның» кая барганын, нишләгәнен... Ләкин моны яңадан инде аның үзеннән ишетергә теләмим. Күзенә чалынмас өчен тизрәк икенче юл белән китеп барам... Йөри торгач, берәр аулак эскәмиягә барып утырам да, терсәкләрем белән тезләремә таянып, уйга чумам. Озак уйлыйм, күпме вакыт узганын да сизмим... Үземчә тыныч, салкын кан белән уйларга тырышам.

...Мин беләм мәхәббәтемнең сәбәбен, мин зарыктым аңа, мин көттем аны... Менә ул килде. Әмма мин белмим, ни өчен ул, минем өметсез мәхәббәтем, Зөһрә рәвешендә килде миңа? Кем ул, нәрсәсе белән бу кадәр әсир итте мине — аңлаудан гаҗизмен. Әйтерсең ак күгәрчен кунды иңбашыма — борылып карарга да, үрелергә дә кыймыйм мин аңа.

Шул ук вакытта, гаҗәп хәл, ничектер бик үз, бик якын ул миңа, гүя элек-электән аралашып йөргән яхшы танышым ул минем. Гүя менә күреп торам аның кер төшмәс пакь, тыйнак хатын булуын, сизеп торам аның нечкә, саф йөрәген, белеп торам аның ялган сөймәс намуслы кеше икәнен... Нидән бу? Асылда бит мин аны бик аз беләм. Әллә инде үзен күрмәс борын ук мин аны хыялымда күптән тудырып өлгергән идемме? Хәзер исә менә шул зарыгып, кадерләп тудырганым кара керфекле, зәңгәр күзле, нәфис-сылу Зөһрә булып күз алдыма килдеме? Мәхәббәт кичерүчеләр, әйтегезче, буламы шундый хәл?

«Дендрарий» паркына барып кайтканнан соң без үзара гадирәк була башладык. Кайвакытта инде Зөһрә ханым үзе башлап минем яныма килә, миңа дәшә... Без йә чәчәкләр түтәле янында сөйләшеп утырабыз, йә бакча

эченә йөрергә китәбез... Телдән әйтә алмаган куанычым бик зур: ул мине үз итә, якын итә.

Һәм озак та үтми мин шуны сизә башладым: яман күзләрдән качкандай (ә яман күзләр кайда да бар алар) гүя ул миңа сыена, миңа ышыклана... Аның болай ышанып сыенуы минем өчен, әлбәттә, зур дәрәҗә. Тик шулай да эчемнән ачынып уйламыйча булдыра алмадым: язмыш мине һәрьяклап сынамакчы була, күрәсең!

Хәзер инде күбрәк аның сүз башлавын, аның сорашуын көтәм. Минем үзем турында кызыксынуын өмет итәм. Нигәдер вакыт-вакыт үземнең тормышым, үткәнем хакында аңа бик сөйлисем килеп китә иде. Ләкин ул ни өчендер аз кызыксына, аз сораша иде. Бигрәк тә минем шәхси тормышыма кагылудан ничек тә тыела иде кебек.

Мәсәлән, ни өчен ул миннән хатыныгыз бармы, балаларыгыз бармы, дип сорамый? Артык кызыксыну күрсәтәсе килмиме, әллә мине дә, кайберәүләр шикелле, үзен кызгандырасы килеп, хатынын яманларга тотыныр, дип куркамы? Юкка. Мин аңа хатынымны яманламас идем, чөнки хатын яманлаудан да мәгънәсез, түбән эш юк.

Сөйләсәм, мин аңа моңарчы һичкемгә тел тибрәтеп әйтмәгән үтә шәхси, яшерен бәхетсезлегемне, ихтимал, сөйләп биргән булыр идем. Мәхәббәтемне аклау йөзеннән түгел, юк, ә озак еллардан бирле эчемә җыелып килгән газаплы уйларны бушатыр өчен сөйләр идем. Әмма ул минем йөрәгемдәге ярага кагылмады, һәм мин аңа бәхетсезлегемне сөйләмәдем. Хәтта киресенчә килеп чыкты... Ләкин бу турыда вакыты җиткәч... Мин исә сөйләмичә калуым өчен менә хәзер һич үкенмим, чөнки семья фаҗигасен фаш итү миңа бернинди дә җиңеллек бирмәгән булыр иде, ә бәлкем, вөҗдан газабы гына алып калган булыр идем.

... Әйткәнемчә, мин мәхәббәтемне Зөһрә ханымның үзенә белдермәскә булдым. Димәк, хисләремне яшерер өчен, мин әкәм-төкәм шикелле бер дә кабырчыктан чыкмаска тиеш идем. Авыр вазифа.

Ләкин күпмегә чаклы яшеренергә мөмкин? Гомумән яшеренеп буламы? Хатын-кыз кебек сизгер җан көн дә диярлек очрашып торган ирнең йөрәгендәниләр кайнаганын үзе үк сизмиме?

Беркөнне без аның белән диңгездән кайтып килешли «җәяүлеләр сукмагында» очраштык. «Җәяүлеләр сукмагы» — диңгез яры буйлап берничә километрга сузылып киткән тар гына юл. Ул куе агачлыклар арасыннан, тау битенә бер күтәрелеп, бер төшеп, чокырлар аша са-

лынган тар күперләрдән узып, бормаланып бара. Юл бик матур, аның гаҗәеп аулак, тын урыннары бар. Анда утырып ял итәргә әледән-әле ак рәшәткәләрдән ипле эскәмияләр, юл буена махсус куелган һәм уртасыннан салкын су бәреп торган таш тәлинкәләр, төрле киек-җәнлекләрнең статуялары очрый...

Без шушы сукмак буйлап бераз баргач, ботакларын әллә кайларга җәеп җибәргән бер карт чинар төбендә эскәмиягә ял итәргә утырдык... Тирә-як тып-тын, шылт иткән тавыш юк, тик түбәннән диңгез дулкыннарының ярга ялкау гына килеп кагылулары ишетелә. Сукмак буенда бер җан иясе күренми... Биредә агачлар шундый биек, шундый юаннар — юл буен тоташ караңгылап, аз гына шомлы кыргый бер төс биреп торалар. Эсседән соң тымызык, дымсу күләгәдә утыруы бик рәхәт!

Минем кәеф әллә ничек кенә: диңгездә берничә тапкыр коенганга күрә бөтен тәнемдә тазалык, рәхәт җиңеллек тоям, шул ук вакытта күңелем нидер юксынып, үзеннән-үзе нечкәреп тора: җыр телим, шигырь телим...

Ә ул? Ә ул бик тыныч, гамьсез күренә... Бернәрсә турында да уйламый кебек, җитди сүзгә теләге юк кебек, тик шунда сыңар аягын селкеп утыра. Минемчә, ул бу минутта рәхәтләнә, үзенең матур булуын белеп, янында бер «мәҗнүн» утыруын сизеп, тормышның бай, тулы икәнлеген, аңа ни теләсә шуны бирергә әзер торуын күреп рәхәтләнә!

Бераз юкны-барны сөйләшеп утыргач, кинәт минем күңелемә якты бер уй килде.

— Зөһрә ханым,— дидем мин,— җырлагыз әле бер... Чын-чын. Сез матур җырлый торгансыздыр.

Ул назлы гына итеп сыңар кашын сикертеп алды, башын аз гына кырын салды.

— Мин җырлый белмим бит...

— Ышанмыйм, сез җырларга тиешсез!

Ул уйчан гына елмайды, бертын дәшмичә торды, аннан икеләнебрәк кабатлады:

— Белмим шул... Бер дә җырлаганым юк.

Мин тагы ныграк үтенеп сорый башладым:

— Ягез инде, Зөһрә ханым, үзегезне сынау өчен генә булса да бер җырлап карагыз... Мин ышанам... Минем бик ишетәсем килә... Ләкин сез мине юк дип белегез...

Һәм ул җырлады. Ихлас күңелдән үтенү тәэсир иттеме, әллә үзенең җырга сусаган чагы булгандырмы — әмма ул бик акрын гына итеп «Айлы кич»не җырлады.

Көлгән чакта искиткеч музыкаль яңгырашы белән сихерләгән тавышы аның җырлаганда ул кадәр үк бай

түгел иде шикелле... Бәлкем, бик акрын җырлаганга шулай тоелгандыр. Ләкин аның җырлавы минем өчен барыбер йөрәккә төшәрлек дәрәҗәдә нәфис, йомшак, матур иде. Мин тәмам онытылып тыңладым. Бигрәк тә көе аның үзәккә үтәрлек иде, гүя бу көй минем ләззәтле авырту белән сызлаган йөрәгемне, өметсез бәхет белән исергән хыялымны җырлый иде... Инде Зөһрәнең чак ишетелерлек итеп, сузып кына: «Әллә гашыйк булдым инде, чыкмыйсың уйларымнан», дип әйткән сүзләрен ишеткән чакта минем кинәт кенә күңелем тулып китте... Бу ни эш, тагын шул гына җитмәгән иде! Мин иренемне тешләп, башымны түбән идем...

Ул, җырлап бетерер-бетермәс, миннән борчылып сорады:

— Сезгә ни булды?

Тиз генә җавап бирүе авыр иде, бары тынычлана төшкәч, мин, аңа күтәрелеп карамаска тырышып, акрын гына:

— Борчылмагыз, Зөһрә ханым, берни дә булганы юк,— дидем.— Тик бераз... хыялга бирелеп киттем шикелле. Бары шул гына.

Ышандымы ул минем бу ялганыма, юкмы — әйтә алмыйм, ләкин нидер сизенде булса кирәк. Шушы хәлдән соң ул еш кына миңа (мин күрмәгәндә) төбәлебрәк карый торган булды һәм нидер сагаеп көтә башлады.

Шулай үтә көннәр, китәр вакытлар да якынлашып килә иде инде, һәм менә безнең арада, күп кенә очракларда була торган шикелле, һич уйламаганда-көтмәгәндә иң әһәмиятле сөйләшүләрнең берсе булып алды.

Кичке аштан соң без йөрергә киттек. Зур паркның бөтен юлларын күптән йөреп чыкканга күрә, мин Зөһрә ханымны санаторий артындагы тауга менәргә чакырдым. Зөһрә ханым риза булды, һәм без киттек. Паркның бер юлы шул тау итәгенә алып бара, аннан тар сукмак югары алып менә.

Без текә тауга ашыкмыйча, туктый-туктый гына мендек. Менеп җиткәч, безнең күз алдыбызда искиткеч матур һәм мәһабәт бер күренеш ачылды.

Кояш диңгезгә әле яңа гына батып өлгергән, бөтен офык буе, төньяк балкышы кебек, яп-якты нурланып тора. Күк белән диңгез кайда тоташа — аны күреп булырлык түгел. Ә болайрак таба диңгез өсте, вак кабырчыклар сибелгәндәй, яшькелт-зәңгәр төсләр уйнатып җемелди. Күк йөзе акрын гына агарганнан-агара һәм төпсезләнә бара...

Менә шул ак бушлыкта, төнге галәмнең беренче кар-

лыгачыдай, гаҗәеп бер якты йолдыз кай арададыр балкып, сөенә-сөенә җемелди дә башлады. Аны иң элек Зөһрә ханым күреп алды.

— Бу нинди йолдыз?

— Бу — Венера, безнеңчә — Зөһрә йолдыз.

— Шулмыни инде ул?

— Әйе, шул инде ул... Зөһрә йолдыз! Матурмы?

— Матур,— диде Зөһрә ханым, ничектер әкрен-кыюсыз гына.

Ә шулай да бу кечкенә мөлаем йолдыз астында дөнья нинди иркен, нинди чиксез! Диңгез, диңгез, диңгез! Ул гүя җирне кочагына алган, ул бөтен табигать өстеннән хакимлек итә. Ә баеган кояшның офыктагы балкышы сүнеп, караңгылык иңгәч, ул тагы да серлерәк, көчлерәк, мәһабәтрәк булып китте. Күк йөзе күксел бәрхеткә охшаган йомшак бер тонык төскә керде, анда «Зөһрә»нең эшләре күбәйде... Дөнья өстенә шул ерак йолдызлардан килгән тирән тынлык ятты. Таулар, гүя диңгезнең киң күкрәгенә башларын салып, йокыга талдылар...

Озак сихерләнеп карап тордык без бу серле, мәһабәт дөньяга. Аннан — артыбызда бер карт имән тора иде — шуның төбендәге артсыз, тәбәнәк эскәмиягә утырдык.

Сәер генә иде бу минутта минем хәлем: ни тоям, ни уйлыйм, ни телим — бернәрсә белмим. Тулы билгесезлек. Ә бит янымда «ул» утыра. Күреп торам аның тез өстенә салган кулын, сулаганда акрын гына тибрәнгән күкрәген, аз гына югары кайтарылган кара керфекләрен, ә шуларга әүвәлгечә тартылып тору үземдә тоймыйм. Битараф бер салкынлык. Сүрелә башлаумы бу? А, юк! Мин аны минут саен, секунд саен сөюдән туктый алмыйм инде. Тик кулым кыска, янымда гына утырса да, күктәге йолдыз кебек, минем өчен ерак ул... Ихтимал, менә шуны аңлаудан киләдер минем бу сәер, билгесез хәлем.

Сүзсез утыру, ахрысы, бик озакка китте, ниһаять, Зөһрә ханым үзе башлап дәште:

— Нигә сез болай бик тын утырасыз?

— Минме?

— Әлбәттә, сез.

— Әллә тагын,— дидем мин, балаларча ни әйтергә белмичә, аптырап.

Зөһрә ханым сәерләнеп иңбашларын җыерып куйды:

— Аңламыйм мин сезне... Берәр хәсрәтегез бармы соң сезнең?

— Юк шикелле...

— Алайса эш нидә? Әллә минем белән утыру сезнең өчен күңелсезме?

— Зинһар, алай дия күрмәгез, Зөһрә ханым! Моның дөрес түгеллеген үзегез дә беләсез ич...

Ул аз гына сүзсез калып торды, аннан тыныч-сабыр булырга тырышып:

— Аптырап кына әйтүем,— диде.— Кичерегез, әгәр урынсыз әйткән булсам... Тик әле сездәге үзгәреш бик гаҗәп тоелганга күрә генә...

— Нинди үзгәреш? — дидем мин, аның сүзен бүлеп.

— Нинди үзгәрешме?.. Башта сез бүтәннәр кебек нормаль генә бер кеше идегез, аннан... зур бер кайгыга дучар булгандай, көннән-көн башыгызны түбәнрәк салындырып йөри башладыгыз. Нидән бу? Нинди хәсрәт, нинди төшенкелек сездә? Шуңа гаҗәпләнәм.

— Зөһрә ханым, сез дөрес күрәсез, әйе, миңа нидер булды, тик ул хәсрәт тә, төшенкелек тә түгел... Ничек кенә аңлатыйм? — Һәм, сүз таба алмыйча, мин бөек шагыйрьнең бер юлын әйтеп бирдем: — Бик юашлатты мине яшерен сөюдән җан көю...

Зөһрә ханым кинәт ике куллап йөзен каплады.

— Җитәр, артыгын әйтмәгез!

Бу хәлдән мин тәмам аптырап, тынып калдым — шулкадәр көтелмәгәнчә килеп чыкты ул! Ләкин Зөһрә ханым үзен бик тиз кулга алды, башын күтәреп, чәчләрен сыпырып куйды, утырган җирендә турая төште. Йөзе аның бу минутта, эчке газабын көчләнеп басарга тырышкандай, киеренке-җитди, хәтта беркадәр усал да иде.

Шактый гына дәшми утырганнан соң, ул, ниһаять, телгә килеп, акрын гына болай диде:

— Идрис иптәш! (Бу аның миңа беренче тапкыр исемем белән дәшүе иде. Әмма «иптәш»е нигә кирәк инде — аның сүземени бу?!) Әгәр сезнең урында бүтән берәү миңа шул сүзләрне әйтсә, мин йә торып китәр идем, йә шаркылдап көлгән булыр идем. Ләкин... күрәсез, мин берсен дә эшли алмадым. Эшли алмадым, чөнки... сезнең сүзләрегез минем өчен коры, буш сүзләр генә түгел. Аңлыйсызмы сез шуны?.. Көлеп кенә карый алмыйм мин сезнең сүзләргә... Ходай хакы өчен моны исегездә тотыгыз!

— Сез сорадыгыз, мин әйттем, Зөһрә ханым,— дидем мин, юаш кына.

— Әйе, мин үзем сорадым, чөнки нидер сизенеп борчыла идем... Кеше нидән газаплана дип борчыла идем... Бер сүз әйттегез, мин барысын да аңладым, артыгы кирәкми.

— Ни өчен?

— Аңладым мин сезне, ышанасызмы, аңладым, шуның өчен... Ләкин сез дә мине аңларга тиешсез...

Зөһрә ханым аз гына тотлыгып торды да ашыгып, дулкынланып сүзен дәвам иттерде:

— Әйе, сез дә аңларга тиешсез минем хәлемне, минем, ничек дим, сезнең... хисегезгә мөнәсәбәтемне димме? Юк, алай да түгел, Ходаем, ничек дим?! Минем җавап бирә алмавымны аңларга тиешсез!

— Аңлыйм,— дидем мин, кабер эченнән әйткәндәй.— Аңлаганга күрә, сезне борчымаска, сездән ничек тә яшерергә тырыштым.

Башымны түбән иеп утырганга күрә, мин аны күрми идем, ләкин һәрбер хәрәкәтен, һәрбер сулышын сизеп торам. Менә хәзер дә ул җиңеләеп бер сулады шикелле, һәрхәлдә, тәмам үзгәргән тавыш белән җылы итеп:

— Сез — яхшы кеше,— диде.— Юкка гына мин сезгә ышанып йөрмәдем... Чынлап әйтәм.

Мин дәшмәдем.

— Ышаныгыз, сезнең кебек... кешенең газабын күрү миңа бер дә җиңел түгел.— Аның тавышы калтыранып куйган кебек тоелды миңа.— Без хатыннар, мондый чакта үзебез дә газапланабыз. Кешенең хәленә керәсе, аны юатасы килә. Ләкин ничек итеп? Бер яхшы сүз белән генә булмый бит?

Нәрсә бу? Нигә кирәк болар? Үзенчә кызгануы, юатырга теләвемени инде бу?.. Ләкин юкка гына, бичара, үзен көчләп маташа... Миңа кирәкми боларның берсе дә, кирәкми... Менә шулай тик кенә, тын гына утырырга да утырырга!.. Аннан вакыт җиткәч кузгалырбыз, кайтып җиткәч, баш иеп, бер-беребезгә тыныч йокы теләп аерылышырбыз. Безнең өчен реаль чынлык шул бит инде. Нигә бу кайгы уртаклашкан булып утыру? Кирәкми, акыллым, минем сиңа үпкәм юк... Әмма ләкин Зөһрә ханымның җаны чынлап та тыныч түгел иде, ахрысы, чынлап та нидер аны борчый иде булса кирәк... Күпмедер сүзсез тынып утыргач, ул эчке дулкынлануын сиздергән тавыш белән, әмма нәкъ якын кешесенә дәшкәндәй бик үз итеп, миңа болай диде:

— Телисезме, мин сезгә берәүнең башыннан кичкән... кызыклы бер тарихын сөйлим. Тыңлыйсыгыз киләме?

Нинди тарих, ни өчен миңа сөйләмәкче — бер дә төшенә алмыйм. Гомумән бернинди тарих та, чорт та тыңлыйсым килми минем... Ләкин... ул әйтә бит моны! Мөмкинме соң? «Сөйләгез, дидем, мин тыңлыйм», дидем.

— Шулаймы? Ярый алайса! — Зөһрә ханым һәм тын җыйгандай бер сулап куйды.— Тик сөйләү минем өчен, һай, авыр булачак, чөнки ул минем... үз тарихым. Моңарчы әле аны беркемгә дә, ишетәсезме, беркемгә дә

сөйләгәнем юк иде. Ә менә сезгә, ят ир кешегә, нигәдер сөйлисем килеп китте... Мин бит сезгә ышанам, бигрәк тә минем хәлемне дөрес аңларсыз дип ышанам... Ах, аңласагыз иде сез!.. Бик әһәмиятле бу минем өчен... Ләкин, сөйли белмәсәм, сез гаеп итмәссез инде, ярыйммы?

— Борчылмагыз, Зөһрә ханым, сөйләгез, мин сезне, шаять, аңлармын.

— Тик менә ничек башлап китәргә? — Ул кыюсыз гына елмайды, ни өчендер чәчләрен рәтләгән булды.— Бүген вакыт та соң инде, сөйләп бетерергә өлгермәм...

— Мин сезне һәр кич шушы урында тыңларга әзермен,— дидем мин, әллә аны, әллә үземне рухландырырга тырышып.

— Әйе, тарих озын, белмим ничек ерып чыгармын,— диде ул, үзалдына әйткәндәй, аннан аз гына уйланып торды, тирән зәңгәр күзләре белән миңа нидер сынап бер карап алды һәм тамак кыргандай итте дә акрын гына сөйләп китте. Башта ул дулкынланудан тотлыгыбрак сөйләде, ләкин бераздан тынычланып, эзгә төште — ягымлы тавыш белән ашыкмыйча гына сөйләгән сүзләре, тугай чишмәсе кебек, үз җае белән генә ага башладылар.

Бу — аның башыннан кичкән мәхәббәт тарихы иде. Үзе әйткәнчә, ул менә бүгенге кичне генә бетмәде... Безгә берничә тапкыр очрашырга һәм хикәяне дәвам итәр өчен шушы тауга менәргә туры килде.

Мин үземнең шәхси тормышымны Зөһрә ханымга сөйли алмадым — гаять авыр эш иде ул минем өчен... Ә менә Зөһрә ханым башыннан кичкәннәрне сөйләгәч, мин, ничектер, үз бәхетсезлегемне яңадан аеруча тирән сизгән кебек булдым. Әлбәттә, вакыйгалар бер-берсенә якын да килми, ләкин эчке мәгънә ягыннан билгеле бер уртаклык бар дияр идем. Хәер, алдан нәтиҗә ясаганчы, иң элек Зөһрә ханымның хикәясен тыңлыйк.

## VII

Зөһрә ханым сүзен болай дип башлады:

— Сезгә әйткән идемме икән, мин бит Чиләбе кызы... Мактанасым килгәндә, «Урал кызы» дип тә әйткәлим... Дөрес, Чиләбе тирәсендә Урал таулары юк, тигез дала, шулай да безне «Урал кешеләре» дип йөртәләр. Моны сезгә хәзер мактанасым килүдән әйтмим, ә башымнан кичкән хәлләрнең урынын күрсәтер өчен генә әйтәм...

Шулай, Чиләбедә туып, Чиләбедә үстем мин... Тигез, хәлле генә семьяда, нужа күрмичә, тыныч кына узды минем бала чакларым. Әти революциягә кадәр зур байларда приказчик булып торган, ә әнием кызлар мәктәбендә укыткан. «Мөгаллимә» дип йөрткәннәр аны. Матур бит? Ничектер менә бүтәннәрдән аерып, зурлап әйткән төсле... Әнием минем заманына күрә укымышлы, алдынгы хатыннардан саналган. Үзе әйтмешли, каралыкка, наданлыкка каршы көрәшкән. Алар, әтием белән әниемне әйтәм, спектакльләрдә, әдәби кичәләрдә катнашканнар. Әнием мандолинада уйнаган, матур гына җырлаган да, ә әтием иске байларны, муллаларны бик оста уйнаган, диләр. Читтән килгән артистлар бездә һәрвакыт кунак булып ятканнар. Җәйләрен Троицк далаларына кымызга барганнар. Хөррият елларында (әнием шулай ди торган иде) аеруча дәртләнеп, бөтен шәһәрне аякка бастырып, берөзлексез спектакльләр уйнап, концертлар куеп, «шәрык кичәләре» оештырып йөргәннәр. Бик күңелле, кызыклы чаклар иде ул еллар, дип әти белән әни әле дә сагынып сөйләштергәлиләр... Мин үзем аларның берсен дә белмим, чөнки мин туганда ул еллар үтеп киткән иде инде. Үземне белә башлаганда әти муллалар уйнап йөрүне күптән ташлаган, олыгайган, басылган бер кеше иде. Ул инде әллә кайчаннан бирле промкооперациядә җаваплы урында эшли һәм эшеннән бүтән нәрсәне белми дә, белергә дә теләми... Әни җидееллык мәктәптә укытып йөри иде әле, ләкин ул да инде әдәби кичәләрне оныткан, бар кайгысы, бар мәшәкате семьяга бәйләнгән иде...

Әнием миңа кулыннан килгән кадәр үзенчә дөрес, яхшы тәрбия бирергә тырышты. Кече яшьтән үк ул мине ана телендә укырга өйрәтте, аннары дүрт ел татар мәктәбенә йөртте. Аның кыз чагыннан ук җыеп килгән бай гына китапханәсе бар иде, шуннан сайлап кына миңа китаплар бирә торган иде. Бигрәк тә татар музыкасына мәхәббәт уятырга теләде ул миндә, моның өчен хәтта үзенең кайбер асыл әйберләрен сатып, өебезгә иске генә бер пианино да алып куйды... Шуның өстенә әле ул мине татар чигүләренә дә өйрәтте. Шулай итеп, әнием минем күңелемә үз халкыбызга мәхәббәт, үз культурабызга хөрмәт орлыгын салырга тырышты. Бушка китмәде шикелле аның бу тырышуы — шулай сизәм. Рәхмәт, бик рәхмәт инде аңа!..

Мин бик читкә кереп киттем шикелле... Менә бит ул сөйли белмәүнең бәласе!.. Гаеп итмәссез инде, бусы минем биографиямә кечкенә бер кереш булсын, ярыймы?

— Мин тыңлыйм, Зөһрә ханым!

Һәм, чыннан да, мин аны гаять бирелеп тыңлый идем. Ул шуны күрмиме? Күрә, әлбәттә, тавышыннан сизеп торам күргәнен. Хәзер инде ул бер дә каушамыйча сүзен башлап китте.

— 1939 елны мин урта мәктәпне бетереп, көзен институтка укырга кердем. 40 нчы елның язында Нәҗип Аитов Мәскәүдән Бауман институтын бетереп кайтты... Мин аны бала чагымнан ук белә идем. Аның әти-әниләре безгә күптән таныш, якын йөрешкән кешеләр иде. Мотаһар абзый, Нәҗипнең әтисе, тегермәннәр трестында эшләүче зур бер белгеч иде... Ул үзе бөтенләй укымаган кеше дип сөйлиләр иде, ләкин бик яшьтән үк шул иген тарттыру эшенә кереп киткән, бик авырлык белән үзенә юл салган, әле революциягә кадәр үк Троицк баеның зур паровой тегермәнендә управляющий булып эшләгән диләр... Тегермәннәр советка күчкәч тә ул һаман шул эшендә калган. Мәскәүдән бер зур кеше, чын булса Цурюпа диләр, аңа тияргә кушмаган, имеш. Соңыннан, нэп вакытында шикелле, аны Чиләбегә күчергәннәр.Менә шул заманнан бирле инде ул, әйткәнемчә, зур бер белгеч булып эшләп килә иде... Бик әйбәт, гадел кеше иде ул, хәзер дә мин аны оныта алмыйм, исемә төшкәндә миңа әллә ничек авыр булып китә. Еш кына, үз әти-әниемнең түгел, ә аның мине кичерүен тели торган идем... Әйе... Тагын алга йөгерәм шикелле...

...Инде әнисе Гайшә апа турында нәрсә дим? Менә сәүдәгәр гаиләсеннән чыккан, аш-суны бик яхшы белгән, исемле кешеләр белән йөрешергә яраткан бер тулы гына татар абыстаен күз алдыгызга китерсәгез, шул Гайшә апа булыр инде. Үзе ул бик зирәк хатын иде, теле дисәң — авызы белән кош тотар, ярыйм дисә — иблискә яучы булыр, инде кеше тикшерә башласа — энә күзеннән үткәрә торган иде. Кешеләрне ул икегә генә бүлеп йөртә: затлы һәм затсыз. Затлысы — бай яки укымышлы гаиләдән чыккан кеше, ә затсыз дигәне — надан, тәрбиясез, дөнья күрмәгән халыктан чыккан кешеләр... Аның бөтен хыялланганы да үзенең Нәҗибен «затлы» кызга өйләндереп, «затлы» кешеләр белән туганлашу иде... Соңыннан, эшләр бик тирәнгә киткәч, мин еш кына, Гайшә апа минем хакта алданмый микән, дип уйлана торган идем.

...Ике гаилә кайчан йөрешеп киткәннәрдер — ул кадәресен хәтерләмим, ләкин үземне белә башлаганда безнең гаиләләр бер-берсенә бик якыннар иде инде. Аннан аралар да ерак түгел иде, әледән-әле алар безгә, без аларга кереп йөри идек... Ул чакларда әле Нәҗип белән минем арада дуслык дип әйтерлек берни дә юк иде. Ул — үсмер

малай, ә мин җиде-сигез яшьлек кенә кызчык идем. Минем өчен ул зур абый иде, дәшәргә, сөйләшергә курка идем мин аңардан... Ә ул миңа бөтенләй игътибар итми иде шикелле, чөнки сүз катып, минем белән берәр сөйләшкәнен һич хәтерләмим. Әйбәт тужурка-чалбар, ялт иткән кара ботинкалар кигән нәзек-озын гына «егет» кайта керә, чыга китә, ә мин — яланаяк чабып йөрүче, кыска күлмәкле чандыр гына кызчык — аның күзенә чалынмас өчен берәр яры посып кала идем... Тагын шуны хәтерлим: ара-тирә әтиләр аның хакында Нәҗип бик акыллы бала, үзен бик әдәпле тота, яхшы укый да икән, ерак китәр, зур кеше булыр, дип сөйлиләр иде. Ә мин ниндидер гаебем бар шикелле өнсез генә тыңлыйм һәм эчемнән: нигә малай булмадым икән, мин дә ерак китәр идем, дип уйлый идем.

...Мин алтынчыда укыганда, ул вузга китте, мин урта мәктәпне бетергәндә — ул Мәскәүдән инженер булып кайтты... Кайту белән Чиләбенең зур бер заводында эшли дә башлады.

Бу инде чыннан да утырып җиткән чын егет иде. Ул торышы дисеңме, ул кыланышы дисеңме — нәкъ менә, Гайшә апа әйтмешли, «зат иясе»неке кебек, бер дә бәясен төшерерлек түгел, ә үзе шундый җитди, горур — янына барырга куркырсың...

Мин дә туташ булып җиткән идем инде һәм аңа ихтыярсыздан кызыксынып карый идем. Дөрес, Мәскәүдән каникулга кайтып йөргән чакларында да мин аны еш күрә торган идем. Ләкин ул вакытларда әле, күңелемдә җиткән кыз хисләре уянмаганга күрә, мин аңа, хәзерге шикелле, ниндидер эчке бер кызыксыну белән карый белми идем. Ул минем өчен бары Нәҗип абый иде, тартына идем мин аңардан, хәтта бераз гына шүрли дә идем. Аннары ул үзе дә мине җитеп килгән кыз итеп күрми иде шикелле; күрсә, сизмичә калмас идем инде. Әллә аның күзенә, гомумән, кызлар күренми идеме? Хәтерлим, әнисе Гайшә апа, безгә кергән саен, мактанып «зарлана» торган иде: «И-и, Нәҗибемнең бер генә дә кызларда кайгысы юк шул, бар белгәне китап, укый да укый, укып арыса, приемник боргалап утыра. Үзем дә аптыраем инде. Иптәшләре кайчан чибәр-чибәр кызлар ияртеп киләләр, шуларга да бит менә һич кенә бер исе китми, ахирәт!..» Ә безнекеләр, бигрәк тә әти, Гайшә апаның сүзен куәтләп: «Нәҗип үз дәрәҗәсен белә ул, юкка-барга алданмас!» — диләр иде.

Мондый сүзләр яңа күзе ачылып килгән, хыялланырга яраткан яшь күңел өчен җитә кала иде: Нәҗип абый

миңа бирәүгә дә охшамаган көчле һәм серле кеше булып күренә иде. Менә шунлыктан, ахрысы, Мәскәүдән ул инженер булып кайткач, мин аңа кызыксынып кына түгел, курка-курка гына сокланып та карый башладым.

Ул буйга-сынга, төскә-биткә дә шактый чибәр егет иде. Уртадан биегрәк, чандыр; гәүдәсен бик туры тотып, башын күтәрә төшеп йөри; йөзе какча, маңгае калку, чәче йомшак, аксыл; күзләре соры, кечкенә, туры карап булырлык түгел, чөнки алардан салкын бер җитдилек сирпелеп тора. Әйтерсең ул күзләр кешегә бары үзенә буйсынырга кушып кына карыйлар. Башта гына түгел, соңыннан да мин аның күзләренә туры карый алмадым.

Тагын нәрсә?.. Әйе, онытa язганмын: аның шушы үзенә күрә чибәр генә, һавалы кыяфәтен бернәрсә — әнисенекенә охшаган кечкенә очлы ияге бозып тора иде. Әллә ничек менә, шул кечкенә ияк аның җитди йөзенә көйсез, үпкәләүчән бала чырае биреп торган кебек... Хәер, бөтен җире дә килеп беткән кеше аз буладыр инде ул. Аннары бит яшь чакта, бер күзең төшкәч, кешене ничек тә матур итеп күрергә тырышасың. Ә мин инде аны шактый идеаллаштырып күрә башлаган идем.

Зурларның Нәҗип турындагы мактау, соклану сүзләре бер дә нигезсез түгел иде. Институтны уңышлы бетереп кайту өстенә, ул эшкә кергәч тә бик тиз үсә, танылa башлады. Аның турында талантлы инженер дигән сүз чыкты, озак та үтми цех начальнигы итеп күтәрделәр үзен... Әти әйтә, аңарда көчле кул бар, ди... Мин моңа ышана идем, хәтта эчемнән генә аның өчен горурлана идем... Нигә — үзем дә белмим, тик «көчле» дигән сүз мине ничектер сихерле иде кебек.

Ул кайтып, берничә ай вакыт үткәч тә, мин үз тирәмдә сәер генә хәлләр күрә башладым. Иң элек Гайшә апа безгә гадәттәгедән ешрак керә торган булып китте. Болай да тасма телле хатын хәзер мине гел юмалап кына, гел «Зөһрә чибәрем», дә «Зөһрә иркәм» дип кенә тора. Очлы күзләрен бер дә миннән алмый, әйтерсең менә бөтен җиремне тикшереп чыга, ә мин үземне кая куярга белмим, кызарам-янам, әмма ачуым килми, тик вакыт-вакыт әллә кая качып китәрдәй булам.

...Әни минем өстем-башым турында күбрәк кайгыртырга тотынды. Үзем сорамастан, йә яңа күлмәклек ала, йә костюмлык ала. Нигә бу, дигәч, син җиткән кыз ич, үзең аңларга тиешсең, ди. Әтием исә минем алда һаман Нәҗипне мактый, ишетеп кайтканнарын бер дә сөйләмичә калмый. Бу шулкадәр юри, мин белсен дип эшләнгән шикелле тоела иде, хәтта уңайсызланудан торып китә-

сем килгән чакларым да була иде. Аннары берничә тапкыр әти белән әнинең үз бүлмәләрендә озак кына сөйләшеп ятуларын да сизеп калдым. Нәрсә турында сөйләшүләрен һич белмәсәм дә, йөрәгем кысылып, эссе-ле-суыклы булып, бу тикмәгә түгелдер, сүз тәгаен минем хакта барадыр дип уйлый идем.

Менә бу хәлләрнең барысыннан да мин эшнең кая таба барганын сизмичә калмадым, әлбәттә. Мин чын-чынлап борчыла башладым. Йөрәгем минем тынычлыгын җуйды. Әллә ничек менә язмышымда зур бер үзгәреш булырга торган кебек. Нинди үзгәреш ул — минем өчен табышмак түгел... Үзем мин ул үзгәрешне телим дә, шул ук вакытта аңардан куркам да кебек, ышанам да мин аның булуына, ышанмыйм да шикелле... Күңелемне авыр бер шик гел борчып тора башлады: бу — картлар теләге генә түгелме, алар гына моны кузгатып йөрмиләрме? Әгәр шулай гына булса, хурлык бит бу минем өчен! Гафу итәчәк түгелмен бит мин аларны моның өчен! Әмма шул ук вакытта картлар теләге, картлар эше генә булыр дигән уй һич башыма сыймый. Әтием — артист, әнием — укытучы булган кеше, ничек инде алар кызларының чын уен, чын теләген белмичә торып, аны кемгәдер «бирергә» җыенсыннар ди? Үзләре бит алар гомер буе искелектән көлеп, шуны хурлап килгән кешеләр... Шулай ук мондый эшне Нәҗипнең әти-әниләреннән дә һич көтеп булмый. Нәҗип бит алар табып биргән кызга гына «ярар, мин риза» дип әйтәчәк егет түгел ләбаса! Эшнең сере нәрсәдә соң, Ходаем?

Сез, бәлкем, ә Нәҗип үзе, диярсез. Ул бар бит, ул сезне күрә бит, сезнең арада сүз булырга тиеш бит, дип әйтерсез. Әлбәттә, шулай. Беләсезме, бу хәлләр башлангач, мин инде кошчык шикелле куркып-калтыранып аңардан гел нидер көтә торган булып киттем. Мин инде аның һәр сүзенә, һәр карашына әһәмият бирә торган булдым. Йөрәгендә ни аның, уенда ни — тизрәк беләсем, тизрәк төрле шикләрдән котыласым килә...

Ләкин сез мине дөрес аңлагыз: бу әле мәхәббәт түгел, бу бары кыз баланың язмышына хуҗа буласы кеше белән соң чиктә кызыксынуы гына иде. Йөрәгемдә аңа карата чын мәхәббәт бармы, юкмы — ул кадәресен мин белмим әле... Әгәр ул миңа: «Мин сезне сөям, сезгә өйләнергә телим»,— дисә, минем җавабым ничек булачак — анысын да белми идем әле...

Әмма ул горур, аз сүзле, үзен салкын тота торган егет иде, шуның өстенә, әйткәнемчә, эшкә йотылды, иртә китә, кичләрен соң гына кайта, һәм без бик сирәк очраша идек.

Ә ике йорт арасында ниндидер сөйләшүләр бара, нәрсәдер эшләргә җыеналар, мин моны сизеп торам, һәм бу хәл мине торган саен ныграк борчый иде.

Менә шулай җанымны кая куярга белмичә, эчтән төрле шикләр белән газапланып йөргән чагымда, һич көтелмәгәндә, әнием белән минем арада гаять җитди бер сөйләшү булып алды. Көтмәгәндә, дим, чөнки борчылып көткәнемне нәкъ менә әнием авызыннан ишетермен дип һич күңелемә китергәнем юк иде. Ни ишетсәм дә, Нәҗипнең үзеннән ишетермен дип йөри идем... Ничек булды ул диегез. Көннәрдән бер көнне мин, кичкырын гына институттан кайтып, ялгызым гына ашарга утырдым. Бераздан каршыма әнием килеп утырды. Әти кайтмаган иде әле, аулак, тын бүлмәдә без икәү генә идек. Әнинең йөзенә карагач та, мин ниндидер зур сүз буласын сизеп алдым — моңарчы бер дә күренмәгән бик җитди кыяфәт иде аңарда... Минем йөрәгем кысылып куйды, тәнем буйлап бизгәк калтыравы йөгереп үткәндәй булды. Әнием бераз дәшми утырды, кулы белән ашыкмыйча гына эскәтерне сыпыргалады, аннан акрын-сабыр гына болай дип сүз башлады:

— Кызым,— диде,— сүземне игътибар белән тыңла: соңгы вакытта без синең киләчәк бәхетең турында кайгырта башладык. Сиңа бик әйбәт пар табылып тора... Кем турында әйтүемне, шәт, үзең дә аңлыйсыңдыр?

Мин дәшмәдем. Әнием дәвам итте:

— Сүз Нәҗип турында бара, кызым... Егет, үзең беләсең, бик әйбәт, бик акыллы, яхшы гаиләдә яхшы тәрбия күреп үскән... Белеме бар, һөнәре бар, киләчәге бик өметле, бик матур булыр кебек... Әнә хәзердән үк ничек күтәрелеп бара! Андый кеше сирәк очрый ул, кызым... Әтиең белән без менә аны синең өчен бик мәгкуль егет дип табабыз, әйе... Син үзең дә безнең белән килешерсең дип ышанабыз. Шулай түгелме?

Мин тагын бер сүз дә әйтә алмадым, тик башымны гына түбән ия төштем. Әнием нигәдер авыр гына сулап куйды.

— Әлбәттә,— диде ул,— тормышка чыгу, бүтән берәү белән тормышыңны бәйләү йөрәк эше ул, ә йөрәккә кушып булмый, ул үзе аны теләргә тиеш. Без моны аңлыйбыз, сине һич ихтыярсызларга теләмибез, әмма шулай да синең сүзеңне ишетәсебез килә. Безгә калса, син аны, Нәҗипне, дим, ярата алыр идең. Дөрес түгелме?

Бик кыен иде минем хәлем, әллә ничек кенә, һич зиһенемне җыя алмыйм, ләкин нидер әйтергә кирәк. Һаман дәшмичә калу ярамый бит инде... Ахырда үземне

көчләп дигәндәй, уйлап түгел, ә телемә килгәнгә күрә генә: «Мин бит укыйм әле»,— дип кенә әйтә алдым.

— Беләбез,— диде әнием,— сине укуыңнан һич аерырга теләмибез, син институтны бетерергә тиешсең. Без аларның үзләренә дә шулай дидек...

Бик гаҗәеп булып ишетелде бу сүзләр миңа, үзем дә сизмәстән: «Кемнәр алар?» — дип сорап куйдым.

— Кемнәр булсын! Нәҗипнең әти-әниләре,— диде әнием.

Шуннан мин әллә ничек менә, үземне һич белештермичә, бәйдән ычкынган шикелле, кинәт кыздым да киттем.

— Аңламыйм мин бу эшне,— дидем мин, гаять дулкынланып.— Нәҗипнең үзеннән бер сүз ишеткәнем юк, ә сез мине аңа бирергә җыенасыз, әти-әниләренә нидер вәгъдә итәсез... Бу ничек була инде бу?.. Бәлкем, Нәҗип тә минем шикелле берни белми торгандыр, бәлкем, аның миндә уе да юктыр... Көлкегә калдырмакчы буласызмы?..

Мин сүземне әйтеп бетерә алмадым, яшьләремә буылып, үксеп елап та җибәрдем.

Әниемнең йөзе үзгәреп китте, курыкты булса кирәк, ләкин тынычлыгын җуймады.

— Кызым, сабыр,— диде ул, йомшак кына.— Тынычлан... йә, тынычлан... Безнең беркемгә дә, бернинди дә вәгъдә биргәнебез юк. Аллам сакласын, синнән узып, синең теләгеңне белмичә торып, андый эшне эшләргә безнең башыбызга тай типмәгән ләбаса. Белеп тор: бөтен эш синең үз ихтыярыңда, син ничек теләсәң, шулай булачак!.. Ә Нәҗипкә килгәндә инде, ул үзе әти-әниләренә бу хакта күптән әйтеп куйган. Әгәр Зөһрә, дигән, мине яратса, миңа чыгарга риза булса, мин бик шатланып аңа өйләнер идем, дигән... Ул миңа бик ошый, бүтән берәүне дә теләмим, дигән... Менә шуннан соң инде аның әти-әниләре безгә дә сүз ачтылар...

Мин түзмәдем, тагын кызып әнинең сүзен бүлдем:

— Ни өчен Нәҗип үзе минем белән сөйләшми, нигә әнисе аша сүз йөртә? Яучы җибәреп, сездән генә сорамакчы буламыни? Алайса хәзердән әйтеп куям: мин биктә утыручы кыз түгел, яучысын куып чыгарырмын... Яучысына: мин — комсомолка, диярмен, егетегез бер илле ел соңга калган, диярмен...

Әни, ничектер, кызганыч кына елмайды, башын кагып: «Дөрес, кызым, яучы килсә, шулай итәрсең»,— дигән булды.

Күрәсең, аңа да җиңел түгел иде, ә бәлкем, сүзне җайсызрак башлап, мине бу хәлгә җиткерүе өчен үкенеп тә

куйгандыр... Шактый сүзсез тынып торды. Күзләре боекланды, йөзенә тирән уй чыкты. Ана йөрәге бит, ниләр генә кичермидер ул!.. Аңа карап, мин инде балаларча әйтеп ташлаган сүзләрем өчен үзем дә үкенә башладым.

Аннан әнием ничек тә йомшак булырга тырышып, шуның белән бергә, аңласын, җитсен моңа дигәндәй, бик җитди итеп миңа болай диде:

— Зөһрә, кызым, син юкка борчылма. Эш син уйлаганча түгел. Яучы да килмәс, сине көчләүче дә булмас... Инде Нәҗип үзенең ниятен башлап эти-әниләренә әйткән икән, бу бер дә гаеп эш түгел ич. Әгәр шуннан берәр егет сиңа өйләнергә теләвен әйтсә, син дә, вәгъдә биргәнче, иң элек безгә әйтмәс идеңмени? Бу бит ата-анага хөрмәт дигән сүз. Бигрәк тә моның кебек зур эштә ата-анадан узып яки алардан яшереп эш итәргә ярыймы соң — үзең уйлап кара. Нәҗип акыллы, тәрбияле бала, шуңа күрә иң элек эти-әнисенә әйткән дә... Бер дә гаеп түгел бу, кызым, бер дә гаеп түгел... Ә ул синең белән сөйләшәчәк, әлбәттә, сөйләшәчәк. Моны аның өчен берәү дә эшләмәячәк... Инде мин бу хакта сүз ачканмын икән, сиңа алдан белгертеп куясым килде. Кинәт булмасын, уйлый тор, дидем. Аңла, кызым, син зур, бик зур сынау алдында торасың. Син үзең хәл итәчәксең... Йөрәгең ничек кушса, шулай эшләрсең, әмма акылың белән дә үлчәп кара. Без этиең белән Нәҗипне сиңа лаек кеше дип табабыз, ләкин моны көчләү дип аңлама. Безнең бар теләгебез сине бәхетле итеп күрү, безгә ышан син, күз нурым!..

Мин инде бүтән бер сүз дә дәшмәдем, кулым белән күзләремне каплап, башымны игән килеш тын гына утыра бирдем. Ахырда әнием торып, миңа акрын гына: «Бар, ят инде булмаса»,— диде дә үзе өстәл өстен җыештырырга кереште. Аягыма баскач, чынлап та мин үземнең хәлсезлегемне сиздем һәм бүлмәмә кереп бикләндем.

Кичерешләрем минем бик каршылыклы иде. Миндә хурлану да бар иде, Нәҗипкә ачу килү дә бар иде, шул ук вакытта мактаулы егеткә, әнием әйтмешли, «лаек булуым» өчен кинәнүме, сөенүме кебек нәрсә дә бар иде. Хәтта, беләсезме, ул миңа ничектер якыная төшкән кебек тә булды. Үзем дә соң аны телим түгелме, дип уйладым мин ихтыярсыздан... Әмма боларның барысына да бигрәк минем җанымны әнием үзе, аның әйткән сүзләре авырттырып тора иде. Бик ачык хис иттем мин аның ана йөрәген. Нигә кыздым, нигә кычкырдым мин тиле!.. Бәхилләтер өчен генә булса да, кире чыгып, алдына тезләнеп: «Әнием бәгырем, кичер, барысына да, барысына да мин риза!» — дип әйтәсем килде.

Күрәсең, нервыларым артык нык какшагандыр инде, түзмәдем, караватыма йөзтүбән капланып, кайнар яшьләремә ирек бирдем. Бу минем җиткән кыз булып беренче елавым иде, тик, кызганычка каршы, соңгысы булмады.

Шул кичтән минем кыз тормышымда яңа бер чор башланды. Кайгысыз, ваемсыз көннәр бетте, кинәт кенә берничә яшькә олайган кебек булдым, урынлы-урынсыз шаяру-көлүдән тыела башладым, хыялый кешедәй әледән-әле онытылып тирән уйларга бирелеп китә торган булдым. Ә уйлар күп иде, бик күп иде, хәтта моңарчы уйлап өйрәнмәгән башым авыртырга тотына иде... Күңелем һич тыныч түгел, юктан да борчылып, куркып тора, әйтерсең менә бүлмәмә кемдер кергән дә яшеренеп кенә мине күзәтә, ә мин вакыт-вакыт шуны сизеп, кинәт сискәнеп китә идем.

Инде соңыннан ниләр булганын сөйләргә керешкәнче шуны әйтим әле: әнием Нәҗипнең үтенүе буенча минем белән сөйләшкән икән — ахырдан шул билгеле булды. Нәҗип үтенечен әнисе аша җиткергән. Ни өчен дисәгез, үзе сөйләшер алдыннан, дипломатлар теле белән әйткәнчә, почва зондировать итеп куярга теләгән. Йә, акыллы егет түгел диегез сез аны!

Зөһрә ханым сүзеннән туктады, кечкенә кул сәгатенә карап алды.

— Һай, сәгать ун булган! — диде ул һәм ашыгып урыныннан торды.— Әйдәгез, югыйсә санаторийга кертмәсләр үзебезне...

Зөһрә ханымның болай куркып капыл кузгалуы ничектер бер мәлгә кыз чагын хәтерләтеп җибәргән кебек булды миңа.

— Дәвамы кайчан булыр соң? — дидем мин, аның артыннан иярә-иярә.

— Дәвамы иртәгә,— диде ул җитез генә.

Без таудан төштек, паркка килеп кердек. Аллеяның ике ягына тезелгән гаять төз, озын кипарислар бастырып куйган кара шәмнәр шикелле торалар. Ә «шәмнәрнең» очында искиткеч чиста зәңгәр күк... Җылы якның бик күп нәрсәсе онытылса да, шушы кара кипарисы белән зәңгәр күге беркайчан да онытылмас кебек... Аллея эче шактый караңгы, күп нәрсәне ачык шәйләп булмый, тик ниндидер яшькелт-якты бөҗәкләр генә, төшеп калган йөзек кашларыдай, юл читендә елтырап күренәләр. Караңгы булганлыктан, мин Зөһрә ханымның терсәгеннән сак кына тотып бара башладым.

Якты мәйданчыкка килеп чыктык. Эскәмияләрдә ха-

лык күп иде әле, безнең шикелле йөрүчеләр төрле яктан һаман кайта торалар... Зөһрә ханым, биредә тукталып тормыйча, минем белән саубуллашты да бүлмәсенә кереп китте.

Аңардан соң арлы-бирле йөренеп карадым, бераз гына утырып та торган булдым, ләкин ялгызым кызык тапмагач, мин дә кереп ятарга булдым.

...Әлбәттә, йокы тиз генә килмәде — күптән инде йокысызлык белән интегәм. Бу юлы Зөһрә дә үз бүлмәсендә йоклый алмыйча ятадыр кебек тоела иде миңа... Хәтта уйларыбыз да бер үк юнәлештә түгелме икән әле? Мәсәлән, мин, гаҗәеп кызыклы бер китап укый башлаган кебек, шуның дәвамы турында уйланам; ул да, ихтимал, үзендә кузгалган хатирәләрне хыялыннан кичереп, сөрмәле зәңгәр күзләре белән түшәмгә карап ята торгандыр.

Икенче көнне дә без, алдан сүз куешкандай, тагын шул тауга киттек. Акрын гына менеп җиткәч, туп-туры әлеге карт имән төбендәге эскәмиягә барып утырдык. Кояш баемаган иде әле, ләкин күп калмаган инде, тиздән алтын шар диңгезгә бата башлар... Кояштан ярга чаклы диңгез өсте, алтын йөгерткәндәй, күз явын алып җем-җем уйнаклап тора. Моннан корт шикелле генә булып күренгән җитез глиссерлар, нурга чумып алгандай, шул алтын сукмакны аркылы кисеп узалар да артларында озын ак эз калдырып чабалар. Еракта, кояштан күп сулда, офыкка якын ике мачталы бер кораб күренә; барамы ул, тик кенә торамы — моннан белеп булырлык түгел.

Килеп утыруыбызга берничә минут үтеп китсә дә, Зөһрә ханым һаман сүзсез иде әле. Бүленгән хикәяне башлап китү ансат түгел, күрәсең... Искә төшерү генә җитмидер, рухың белән үткән хәлләргә яңадан кайта алу кирәктер.

Менә ул җиңелчә генә сулап куйды. Акрын гына:

— Сез көтәсезме? — дип сорады.

— Зарар юк, Зөһрә ханым,— дидем мин.— Сез борчылмагыз, күпме кирәк, мин шулкадәр көтәргә риза.

— Ә-нә шул тик кенә торган корабтан бер дә күземне ала алмыйм,— диде ул, көлемсерәп.— Әгәр ул кузгалса, бәлкем, мин дә сөйләп китәр идем.

— Ул тик тормый, бик ерак булганга күрә, без аның баруын сизмибез генә...

— Шулаймыни? Ярый алайса! — Ул тагын аз гына тынып торды да, ерактагы корабка һаман караган килеш, ниһаять, хикәясен башлап китте: — Әнием белән сөйләшкәннән соң, минниләр кичергәнемне әйткән идем инде. Ул көннәрдә мин Нәҗипне яратаммы, аңа чыга-

сым киләме дип уйланудан бигрәк, ул килерме, кайчан килер, нәрсә әйтер, ничек итеп әйтер, дип уйлана идем. Нигә яшерергә?! Һәрбер кыз бала белән дә ул шулай буладыр инде... Ә минем кызлык абруем өчен аның үз авызыннан чыккан тәкъдиме бөтен нәрсәдән әһәмиятлерәк иде. Әгәр ул әти-әниләремә үзенең теләген белдереп тә миңа һаман әйтмичә йөрсә, мин кырт кисеп аңардан баш тартырга әзер идем кебек... Гүя менә аңа бер срок бирелгән, әгәр ул шул срокны үткәрсә, бар да бетәчәк!

Шул ук вакытта мин аның белән сөйләшүдән эчемнән генә куркып та тора идем. Хисләрем минем аңа карата ачык түгел, җавабым минем әзер түгел — нәрсә диярмен мин аңа? Ләкин, кабатлап әйтәм, ни генә булмасын, мин аның килүен көтәм, сүз башлавын көтәм... Шундый инде минем хәлем!

Егет үзе сиздеме минем бу хәлемне, әллә аңа тизрәк җиткерүче булдымы, белмим, ләкин ул үзен озак көттермәде. Беренче якшәмбедә үк кичкырынрак бу безгә, ничектер көн дә була торган кеше сыман, кисәк кенә килде дә керде. Мин үз бүлмәмдә идем, ишектән кереп, безнекеләр белән исәнләшүенә, тавышыннан танып алдым. Шундук әллә ничек коелдым да төштем, йөрәгем, куркытылган кош кебек, дөп-дөп тибә башлады... Өйдә булуымны сиздермәскә теләгәндәй, баскан урынымда тындым да калдым. Бәхетсезлеккә каршы, бүлмәнең ишеге ачык иде, хәзер менә түргәрәк узды исә, ул мине күреп алырга тиеш иде.

Әти белән әнием аны бик ачык йөз белән каршы алдылар. Бигрәк тә әнием ике кулын җәеп каршылады. Пальтосын да үзе алып элмәде микән әле...

Нәҗип, чишенгәч, түргә узып утырды, ләкин минем бүлмәмә карамады. Алар үзара сөйләшә башладылар, ә мин баскан җиремдә һаман катып тора бирдем. Чыгып исәнләшергәме, юкмы — тәмам аптырауга төштем. Йә, юләр түгел диегез инде мине! Безнең өйгә беренче генә килүе түгел бит аның, бала чагымнан ук беләм бит мин аны, ә менә... югалдым да калдым. Ярый инде, әниемә рәхмәт, ул, минем хәлемне белгәндәй, залдан кычкырып дәште:

— Кызым, Нәҗип килде!

Мин:

— Ә, шулаймыни? — дигән булдым, кемдер төртеп җибәргәндәй кызу-кызу гына атлап залга чыктым. Нәҗип урыныннан торды, без күрештек. Ул кире утырды, ә мин бүлмә уртасында тагын нишләргә белмичә аптырап калдым. Битләремә әйтерсең ут капты, пешереп янарга тотындылар.

Әни кеше бик сизгер була бит, шунда ук ул миңа эш кушты: «Кызым, чәй әзерлә!»

Ләкин Нәҗип сәгатенә карап алды да:

— Рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез,— диде.— Мин Зөһрәне киногa чакырырга дип кенә кергән идем... Әгәр мөмкин булса...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, мин дә чыга башлаган җиремнән туктарга мәҗбүр булдым. Әтием җәһәт кенә: «Эчәрбез әле, эчәрбез»,— диде, ә үзе бик мәгънәле итеп миңа карап алды. Баш тартырга һич ярамаганлыгын мин шунда ук аңлап алдым, ләкин нәрсә дип әйтергә — бу кадәресен уйлап табарлык түгел идем. Тагын әнием ярдәмгә килде:

— Кызым, вакытың бармы синең?

— Бар,— дидем мин, оялып, икеләнеп кенә.

Әтием яңадан Нәҗип белән нидер сөйләшергә кереште, ә мин, инде нишлим дигән бала төсле, әниемә карадым. Әнием гаҗәп тыныч, гади генә итеп миңа:

— Бар алайса, киен! — диде.

Мин бүлмәмә кереп киттем. Ишекне ябып куйдым да кечкенә өстәлем янына барып утырдым... Бөтен нәрсәдән — безнекеләрнең ничек итеп аны каршы алуларыннан, әтиемнең бик мәгънәле итеп карап куюыннан, әниемнең шундый оста, сак кына минем белән «идарә» итүеннән, ә егетнең миңа карамаска тырышып, бары әти белән генә сөйләшкән булып утыруыннан — мин берьюлы аңладым: ул минем белән сөйләшергә килгән! Кино, әлбәттә, сылтау гына... Ходаем, менә көткән сәгатьләрең дә килеп җитте. Куанаммы мин моңа — әйтә алмыйм, тик, күргәнегезчә, коелдым да төштем, аптырадым да калдым. Нигә болай булды соң минем белән, нигә бу кадәр мин, тиле, башымны җуйдым, әллә шул алдан белеп, көтеп йөрү ярамадымы — һич менә төшенә алмыйм. Ләкин хәзер миңа ничек тә тынычланырга, ничек тә үземне кулга алырга кирәк иде... Акылымны, һич югы, бераз җыярга кирәк, югыйсә мин аның сүзләрен ничек аңлармын да сорауларына ничек итеп җавап бирермен?

«Ул» залда мине көтеп утыра, әти-әнием дә: «Бу кызый ник бик озаклады?» — дип, эчләреннән борчыла торганнардыр, ә мин башымны иеп утырам да утырам. Ни өчен утырам, Хода белсен, ә ашыгырга кирәклеген үзем бик яхшы белеп торам.

Ахырда торып, киенә башладым. Күптән түгел генә тектереп алган күк йон күлмәгемне кидем, ефәк оек кидем, кара замш туфлиләремне кидем... Чәчемне тарап

күперттем... Аз гына пудра салдым. (Ул чакта мин бизәнми идем әле...) Ә «Красная Москва»ны мул итеп сөртендем, чөнки хуш исне электән үк ярата идем... Шулай киенеп-бизәнеп маташа торгач, бераз тынычланган кебек тә булдым.

Аннан залга чыктым. Бу юлы Нәҗип, күзләрен тутырып карап, мине каршы алды. Әйе... Минем киемнәрем алай модныйлардан булмаса да, үземә бик килешә иде. Чын әгәр!.. Киң итәкле, тар билле яңа пальтом да, аксыл соры тиеннән теккән йомшак бүрегем дә миңа бик килешеп тора иде. Мин киемнәремне ярата идем, кадерләп кенә тота идем...

Зөһрә ханым әллә ничек моңсу гына итеп елмаеп куйды.

— Һай, кыз чаклар! Үтте инде, үтте... Хәзер менә шул кыз чагымнан сакланып калган юк кына берәр әйберне күрсәм, кулыма алып үбәм, күкрәгемә кысам, син һаман элеккечә, ә мин күпме үзгәрдем инде, дим... Гафу итегез!

Ул башын борды. Бераз тып-тын калып торгач, акрын гына:

— Сез көлмәгез, яме! — диде.

— Ни сөйлисез, Зөһрә ханым,— дидем мин, бик дулкынланып,— мөмкинме соң, ярыймы соң!

Ул түшләре күтәрелгәнче тирән итеп бер сулады да, тынычланган шикелле булып, яңадан бүленгән хикәясенә кайтты:

— Нәрсә сөйли идем әле?.. Ә, әйе... Өстемә киендем, чыгып китәргә җыена башладык... Әтием Нәҗипкә: «Кинодан соң рәхим итегез!» — диде. Миңа да: «Кызым, кунакны чәйгә алып керерсең!» — диде.Мин дәшмәдем, бу хәтле яхшатлануына аз гына ачуым да килеп куйды.

Урамга чыккач, беркадәр сөйләшмичә бардык, аннан ул, «рөхсәтме» дип, мине култыгымнан алды. Кышкы кич йомшак, тын иде, якты төшкән җирләрдә салкын кар тыныч кына җемелди иде.

Без шәһәр уртасына таба киттек. Кая барабыз — белмим, һәрхәлдә, кинога түгелдер инде дип уйлыйм. Ә ул шулай да мине шәһәрнең иң яхшы киносына алып барды. Үзенчә сылтау гына булып калмасын дигәндер инде... Һәм, көндәгечә, бу кинода билетлар бөтен сеансларга да сатылып беткән иде.

Шуннан без үзәктән читкәрәк, аулак урамнарга кереп киттек.

Башта сүз бер дә көйләнә алмады. Мин бит аның нәрсә турында сүз ачарга тиешлеген белеп торам, шуңа күрә

үзем бер сүз әйтергә кыймыйча, бары көтәм... Ә ул минем шулай көтүемне сизеп, кай очтан, ничегрәк башлап китәргә белмичә азаплана иде, ахрысы... Мондый нечкә эштә алдан белеп тору егетнең дә, кызның да хәлен бер дә җиңеләйтми икән.

Кыскасы, бераз ык-мык килү, анысы-монысы турында сүз кузгаткалап алудан соң, Нәҗип акрынлап үзенең эш хакында сөйли башлады... Шуны әйтим, ул бик күп русча кыстырып сөйли иде, кайчак бөтенләй русчага күчеп китә, белмим инде аның сүзләрен сезгә ничек җиткерермен... Әйе, менә шул, үзенең заводын мактады, эшенең бик интересный булуын әйтте. Перспектива бик яхшы, диде. Көн-төн эшлим, һич буш вакытым калмый, ләкин зарланмыйм, эшемне бик яратам, диде.

Шулай эше турында шактый мавыгып, ләкин ашыкмыйча гына сөйләгәннән соң, ул, ничектер, бер җайдан шома гына үзенең «личный» тормышына күчте. Ул инде сукмагын тапкандай эшлекле кыяфәт белән үз-үзенә бик ышанып сөйли иде. Артык җәелеп тормыйча, ялгызлыктан «скучать» итүен әйтте, бар да бар, тик тормыш дустым (үзенчә әйткәндә, «подруга жизни») юк, диде. Бәләкәй генә фәлсәфә дә сатып алды: ягъни безнең бу напряженный (татарчасы «киеренке» буламы әле?), кызу заманда тормыштан артта калмас өчен, үзеңнең личный тормышыңны да акыл белән рациональный иттереп оештыра белергә кирәк, диде. Бик җитди итеп, бу юләр кызыйның башына нык кына кереп утырсын дигән төсле итеп әйтте ул моны...

Сүз башланып киткәч тә, безнең арада ул дәү, мин кечкенә, ул белә, мин белмим дигән төслерәк бер аерма туды. Ахрысы, шунлыктан минем һаман сүзсез генә тыңлавым аны бер дә борчымый иде кебек... Менә сөйли торгач, ул шундый ук эшлекле тон белән үзенең өйләнергә теләвен әйтте. Миңа бераз гына эссе булып китте, башымны түбәнрәк идем һәм тагын дәшмичә калдым. Шуннан соң гына ул минем тып-тын баруыма игътибар итте. Бу хәл егетемне тугара төште, ахрысы, сүзеннән аз гына туктап торырга мәҗбүр булды. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды: берни булмагандай, һаман элеккечә эрелеген һәм тынычлыгын саклап, тик аз гына тотлыгып, миңа болай диде:

— Та-ак вот, Зөһрә, син, конечно, ишеткәнсеңдер бу турыда... Хәзер менә үзеңә әйтәм: мин өйләнергә решил. Еще конкретнее — мин, дорогая, сиңа өйләнергә решил!

Белмим, бәлкем, һәрбер егет өйләнергә теләве турында шулай бик җитди итеп, коры итеп әйтә торгандыр —

ишеткәнем юк. Бу кадәресе мине артык гаҗәпләндермәде, хәтта «дорогая, сиңа...» дигән сүзләре йөрәгемне кысылып куярга мәҗбүр итте, әмма шуның артыннан ук «решил» дигән сүзен ишеткәч, мин кинәт өшеп киткәндәй булдым. «Решил» — ни дигән сүз бу? Бик уңайсызланып-оялып булса да, ихтыярсыздан сүзен бүлеп сорадым:

— Туктагыз... Ни өчен миңа, ни өчен бүтәнгә түгел, әйтик, Фатыймага, Суфиягә яки Верага, Нинага түгел?

Һич көтелмәгән сорау булды бу аңа, берни аңламыйча, ләкин чынлап торып:

— Ә кемнәр алар? — диде ул.

Мин теләмичә генә көлемсерәп куйдым.

— Кемнәр икәнен белмим, тик әле мисал өчен генә әйтүем.

— А-а, вон как! — Ул кашларын җыерды, минем «шаяртуымны» яратмады, күрәсең.— Зөһрә, мин синең белән серьезно сөйләшәм.

— Мин дә уйнап сөйләмим.

— Нигә алайса мондый кирәкмәс сораулар? Син беләсең: минем кызлардан бер танышым да юк.

— Шуның өчен генәме?

— Нәрсә шуның өчен генәме?

Аның сүзен кабатлау авыр булса да, әйтмичә тыела алмадым:

— Миңа өйләнергә... решить итүегез.

Ниһаять, егетемә барып җитте булса кирәк.

— Ну, конечно, аның өчен генә түгел,— диде ул үпкә катыш җитдилек белән.— Что син! Главное, син миңа ошыйсың, Зөһрә, менә ни өчен мин сиңа өйләнергә телим.

— Шулаймыни?

— Әйе, ышаныгыз, искренно әйтәм.

— Рәхмәт! Ләкин өйләнер өчен бер ошату гына җитәме соң?

Егетем иңбашын җыерып куйды шикелле.

— Мин, бу — главное, дидем. Ошаса — өйләнәләр, ошамаса — юк. Не так ли?

— Ә... ярату?

— Бик наивная икәнсең син, Зөһрә! — диде ул, көләргә тырышып.— Ошатам, значит яратам. Яратмасам, ошатмас идем. Ясно?

...Әйе, ясно! Әмма егетемнең йөрәк «серен» болай эскәк белән берәмләп кенә тартып алу миңа бик авыр да, бик оят та иде.

— Гафу итегез, Нәҗип,— дидем мин, пошынып,—

әллә ничек шунда... Сезгә барысы да ясно, ә миңа ачык түгел... Мин сезнең чын хисләрегезне кайдан белим, беренче генә тапкыр сөйләшәбез ич!

Шуннан ул берьюлы барысын әйтеп бетерергә һәм үзенчә «ачыклык» кертергә теләп булса кирәк, һәр сүзенә басым ясап, «синнән» «сезгә» күчеп, миңа болай диде:

— Зөһрә, аңлагыз, мин пустойга сөйләнеп йөрүче түгел. Әгәр инде мин сезгә өйләнергә теләвемне әйтәм икән, значит, бик нык уйлап, сезгә булган чувстволарымны точно белеп әйтәм. Да. Белегез яратуымны мин сезгә сүздә түгел, ә эштә күрсәтермен. Да... Романтика, конечно, матур нәрсә, но мин реально уйларга яратам. Миңа өйләнергә кирәк. Менә мин сезгә предложение ясадым, инде сездән туры җавап көтәм!

Ходаем, мин дә мин, ә минем йөрәгемдә ни — ул турыда ләм-мим. Аннан нинди тон белән сөйли бит ул! Рәхим итеп тыңлагыз да кушканны эшләгез! Бу рәвешчә сөйләшкән кешегә мин шунда ук: «Җавабым шул — мин сезгә чыкмыйм!» — дип әйтергә тиеш идем, ләкин ни өчендер юаш кына:

— Нәҗип, кызык сез, моның кебек җитди мәсьәләне бер сөйләшүдә генә хәл итеп буламыни? — дидем.

— А почему булмый?

— Ничек булсын ди! Мин сезне, ә сез мине яхшылап белмисез бит әле...

— Юк, мин сезне беләм,— диде бу, үз-үзенә бик ышанып.

Минем ачуым килеп китте:

— Аның каравы, мин сезне белмим!

Шуннан без шактый гына сөйләшмичә бардык. Егет нидер сизенеп, тавышын да йомшарта төшеп, үзе сүз башлады:

— Ярый, пусть сезнеңчә булсын. Мин көтәргә риза. Җавап өчен күпме вакыт кирәк сезгә? Только точно әйтегез.

— Тәгаен әйтә алмыйм. Аннан... мин укыйм бит әле...

— Беләм. Учитываю. Миңа бит, Зөһрә, только сезнең сүзегез кирәк. Ә фактически өйләнү — сез теләгән чакта булыр. Важно минем белеп торуым, ә сезгә мин институтны бетерергә, конечно, возможность бирермен.

Мин бер сүз дә дәшмәдем. Йә, нәрсә әйтәсең? Бу сөйләшүне мин никадәр көтеп алдым, әмма болай булып чыгар дип һич тә күз алдыма китермәгән идем. Йә, әйтегезче, кыз кешенең күңеленә ятарлык, йөрәген талпындырырлык нәрсә генә ишеттем соң мин?.. «Өйләнергә решил...», «Ошатам, значит, яратам...», «Возможность

бирермен...» — йә, шушымы инде егет кешенең гомерлек яры, дусты итәргә теләгән кызына беренче тапкыр әйтә торган сүзләре?! Билгеле, мин боек идем, сүлпән идем, салкын идем, хәтта шушылай булуым өчен үземә беркадәр ачуым да килә иде. Янымда, мине ипле генә култыклап, яхшы киенгән, матур, сылу егет бара, ә мин нидер югалткан бала төсле башымны түбән иеп, җавап бирергә иренеп, аның белән янәшә атлыйм... Бик кыен иде миңа!

Шулай да ул берничә минутка калыбыннан чыккандай тәкәббер эрелеген онытып, нәкъ менә мәхәббәт кичерүче яшь егеттәй, минем йөрәгемне дулкынланып кысылырга мәҗбүр иткән бер талпыну ясап ташлады. Безнең капка төбенә килеп туктагач, ул сыңар кулы белән генә мине иңбашымнан кочаклап алды. Мине үпмәкче була, ахрысы, дип, бераз артка каерыла төштем. Ләкин ул үбәргә үрелмәде, ә мине ныграк үзенә таба тартып, эчке бер ягымлы тавыш белән әйтте:

— Зөһрә, Зорочка, дорогая моя, пойми, яратам мин сине... Искренно телим синең белән... ну... бергә булырга. Бәхетле булырга!.. Ышанасыңмы?

— Әйе, ышанам,— дидем мин, кыюсыз гына.

— Умница ты моя! Я так и знал, что ты меня поймешь. Рәхмәт, рәхмәт!.. Ну, а кайчан җавап?

— Нәҗип,— дидем мин, нигәдер кинәт елыйсым килеп,— син мине ашыктырма. Уйларга бир.

— Но озак көттермәссең бит?

— Ярар.

Ул мине тагын да үзенә якынрак тартты. Инде үбә дип котым алынды. Ләкин ул тыйнак, әдәпле егет иде, бары иелә төшеп, колагыма акрын гына:

— Бел, Зөһрә, без бәхетле булырбыз,— диде.

Мин, аның белән килешкәндәй, башымны гына кактым.

Мин керергә булдым; ул минем кулымны кат-кат кысып, хәерле йокы теләп, озатып калды.

Әнием миңа ишек ачты, мин аңа күтәрелеп карамаска тырышып, тизрәк үз бүлмәмә уздым... Төнлә белән мине бераз бизгәк тотты; күрәсең, салкында озак йөрү дә ярамагандыр инде... Иртәнчәк әнием читләтеп кенә булса да сорашыр дип бик курыккан идем, ләкин теш елтыратып ник бер сүз әйтсен! Ана кеше кирәк чакта дәшми дә тора белә икән!

Хәер, үз әнием генә түгел, аз гына сизгерлеге булган ят кеше дә ул көннәрдә миңа дәшми, кагылмый торырга тиеш иде. Мин үзем дә аңлый алмаслык гаҗәеп бер хәл

кичерә идем... Менә хәзер, күпме еллар узганнан соң да аны, ягъни шул чактагы хәлемне, дөрес кенә әйтеп бирә алмам шикелле...

Ни булды соң минем белән?

Мин, шушы көнгәчә әле беркемне дә сөймәгән, бер генә егеттән дә чын мәхәббәт сүзе ишетмәгән һәм бер генә егетнең дә ирене иренемә тимәгән унсигез яшьлек кыз, кинәт иргә чыгу ихтималы алдында торып калдым. Мин моны теләми идем әле, мин моңа берничек тә әзер түгел идем, ләкин шуңа карамастан иргә чыгу хәзер котылгысыз бернәрсә булып тоела башлады миңа...

Сез инде бу нинди каршылык диярсез, үзегез егетнең килүен, сөйләшүен, тәкъдим ясавын көттегез, ә хәзер әнә ни сөйлисез, дип гаҗәпләнерсез. Бөтен бәхетсезлек тә шунда шул: көттем, тыңладым, ә ишеткәч... ишеткәч, аңлыйсызмы, йөрәгемдә аңа карата чын мәхәббәт хисенең туа алмавын белдем. Менә шуннан башланды бөтен газапларым, бөтен шикләрем...

Ә газапларым нидән соң?

Мин аның белән мавыктым, мин аңа сокланып карый башладым. Ул — мактаулы егет. Аның хакында сөйләнгән сүзләр минем күңелемә кереп утырдылар. Ул төскә-башка да чибәр генә кеше, һәрбер кыз аның белән янәшә булуны үзе өчен бәхеттән санаячак... Минем йөрәгемдә, аңа карата зур хиснең кечкенә чаткысы бар кебек иде, һәм якыная, белә төшкәч, көчәеп, ялкынланып китәргә тиеш кебек иде... Әмма мин гаеплемени соң — көчәймәде ул чаткы, ялкынланып китә алмады. Хәтта бөтенләй сүнде шикелле... Һәм бу минем өчен зур газап иде.

Нәрсә сүндерде — моның чын сәбәбен мин шул чакта гына аңлый алмадым. Дөрес, аның үз-үзенә артык ышанган, тәкәббер, коры кеше булуы мине гел этәреп, куркытып тора иде, ләкин бу әле чын сәбәп булырга тиеш түгел. Шулай ук аның мине әсир итәрлек, эретерлек итеп сөйли белмәвеннән дә күреп булмый иде моны... Юк, чын сәбәп каядыр тирәндә ята иде.

Ә шикләрем?.. Шикләрем исә, бәлкем, мин ялгыша торганмындыр, дип уйланудан килә иде. Әлеге шул чаткының тәмам сүнүенә ышанасым килми, вакытлы гынадыр бу, дип үземне юатырга тырышам. Алай гына да түгел, мин аның яңадан кабынуын тели идем, киләчәгем хакына, әти-әнием хакына ихлас күңелдән тели идем.

Шуңадыр инде мин аның турында бертуктаусыз уйлана идем. Йөргәндә дә, аудиториядә утырганда да, аша-

ган-эчкәндә дә ул минем хыялымнан чыкмый иде. Ә кышкы озын төннәрдә сәгатьләр буена керфек какмыйча уйланып ята торган идем. Үземчә аны аңларга тырышам, гел яхшы яклары турында гына уйларга тырышам, тыштан гына ул шулайдыр, ә эчтән әйбәт, җылы, йомшак кешедер дип үземне ышандырырга тырышам... Ул бит миңа, яратуымны эштә күрсәтермен, диде, без бәхетле булырбыз, диде. Шулай әйтүен исемә төшерәм дә сөенеп куям. Нигә, дим, ул бит аңлы, акыллы кеше, мине матур итеп ярата белмәсмени, дим, мине чынлап та бәхетле итә алмасмыни, дим. Бик, бик ышанасым килә иде шуңа...

Кыскасы, ничек тә әлеге чаткыны йөрәгемдә кабындырып, көйрәтеп җибәрергә тырышам... Әгәр кабына калса, гүя миннән дә бәхетле кеше дөньяда булмаячак!

Ләкин... ләкин күпме генә үземне көчләсәм дә, көйләсәм дә, тоймый идем мин аның кабынуын, тоймый идем. Чаткы урынына, йөрәгем төбендә эреми яткан боз кисәген тоя идем... Белсәгез, шулкадәр авыр, шулкадәр авыр иде миңа!.. Нишлим соң, нишлим дип, өзгәләнеп, ачы яшьләр белән мендәремә капланган чакларым аз булмады минем...

Сезне бу сөйләгәннәрем гаҗәпләндермәсен — ул бит башта ук минем аңыма миңа өйләнергә тиешле кеше булып кереп утырды. Нидән бу?.. Өйләнү яки кияүгә чыгу яшьләрнең үзләренә генә кагылган никадәр үтә шәхси эш булмасын, әмма моны хәл иткәндә эти-әнинең йогынтысы искиткеч зур була икән. Бигрәк тә бу кыз бала өчен шулай. Тик сез моны ирексезләү дип аңлый күрмәгез. Ирексезләү юк ул, юк, ләкин әнә шул йогынты нәтиҗәсендә үз-үзеңне мәҗбүр итү бар.

Мин әле газап утында, минем әле Нәҗипкә җавап биргәнем юк, җавабым әзер дә түгел, ә минекеләр дә, аныкылар да безнең «эшне» инде хәл ителгәнгә санап торалар. Һәрхәлдә, менә тиздән хәл ителәчәк дип бик нык ышанып торалар. Егетнең кыз белән сөйләшүе аларга билгеле, ә кызның риза булачагына шикләнмиләр. Чөнки безнең кебек бәхетле «пар килү» булырга да мөмкин түгел, эзләп торасы да юк... Дөрес, кызның авызыннан «риза» дигән соңгы сүз ычкынганы юк әле, ләкин ул аны, һичшиксез, әйтер, әйтергә тиеш. Үз бәхетен аңламаска, аның башына тай типмәгән бит!

Менә шундый хәлдә идем мин... Бөтен уй-хәсрәтләрем үз эчемдә, уртаклашыр кешем юк, булса да — бу кадәр тирән серләремне әйтә алмас идем, тик шунда тиле кәккүк кебек ялгызым миңрәүләнеп йөрим дә йөрим.

Егетем көтә, әти-әнием көтә, бар да көтә, ә мин, селкенүдән туктаган маятник шикелле, ни ары, ни бире!

Минем бу хәлемне иң элек әнием сизенде. Ана күзеннән яшеренеп буламыни? Күрә ич ул: «бәхетле» кызының йөзендә нигәдер шатлык балкымый, боек аның йөзе, моңсу аның күзләре... Әлбәттә, бу тикмәгә түгел иде. Дәшми йөрсә дә, күңеле һаман борчылган, ахрысы,—ниһаять, үзе сүз башларга мәҗбүр булды.

Бер кичне әнием миннән гүя болай гына сорап куйды:

— Зөһрә, син Нәҗипкә соңгы сүзеңне әйтмәдеңме әле?

Сәер генә булып ишетелде миңа аның бу соравы, чөнки минем бит аңа моңарчы Нәҗип белән сөйләшүемне әйткәнем юк иде әле. Хәер, мин гаҗәпләнеп тормадым инде, туры гына:

— Юк әле, әйткәнем юк,— дидем.

— Алай икән... Нигә сузасың инде, кызым? — диде әнием, йомшак кына.

— Ашыгыч түгел бит, әйтермен әле...

Нигәдер минем бу турыда сөйләшәсем килми иде. Ләкин сизәм: әнием миннән нидер ишетергә тели; бераз дәшми торгач, ул тагын сорап куйды:

— Бәлкем, миңа әйтерсең, кызым... Нинди уйда йөрисең соң син?

Бу сорауга туп-туры җавап бирү минем өчен бик авыр иде, өлгермәгән, әзер түгел иде әле ул, ләкин күп уйлап тормыйча, үзеннән-үзе килеп чыккан гаҗәеп бер дөреслек белән әйттем дә бирдем:

— Әни, бәгырем, Нәҗипне ярата алуыма ышанмыйм мин...

Әнием бичара берьюлы тынып калды. Ябык иңбашларын бөкрәйтеп, озак кына бер ноктага текәлеп торды, аннары күтәрелеп, тирән моңсу-уйчан күзләре белән миңа туры карап, акрын гына сорады:

— Чынлап әйтәсеңме, кызым?

— Әйе,— дидем мин, башымны иеп.

— Ни өчен ышанмыйсың?

— Белмим, әнием...

— Юк, шулай да ни өчен?.. Миңа гына әйтергә ярыйдыр бит инде.

Мин җавап бирә алмадым. Әллә ничек менә тагын бер генә сүз әйтү дә минем өчен бу минутта зур таш күтәрүдән дә авыррак иде. Әйтәсем килмәүдән дә түгел, ә юк, сүзем юк, уйларым каядыр юкка чыктылар да куйдылар, әйтерсең фаш булудан куркып качтылар... Күзләрен миннән алмыйча көтеп торган әнием сиздеме шушы хәлемне —

яңадан кайтарып сорамады. Тик авыр гына көрсенеп куйды да үпкәсез-нисез тыныч кына итеп әйтте:

— Болай булгач, кызым, ашыкмавың хәерле. Үкенечкә булмасын, уйларга кирәк... Нечкә эш, йөрәк эше, бик нечкә эш... Әйе, көчләп булмый аны, вакыт бирергә кирәк аңа!.. Иншалла, үз җае белән ачылыр ул!.. Ләкин бик үтенәм синнән, кызым, зинһар, яхшылап уйла, һәрьяклап уйла. Сүз бит киләчәк бәхетең турында бара... Безнең фикерне син беләсең инде. Безгә калса, Нәҗип начар егет түгел...

Мин ихтыярсыздан чыраемны сыттым, әнием сүзен әйтеп бетермичә туктарга мәҗбүр булды.

Бу сөйләшүдән соң ул гел диярлек күңелсезләнеп йөрде. Дөресен генә әйткәндә, аның хәле минекеннән дә авыррак иде. Миндә бер кайгы, ә аңарда?.. Мине көйләсенме, әтиемне тыңласынмы, Нәҗипне уйласынмы? Аннары ул үзе минем Нәҗипкә чыгуымны тели бит, үзенчә мине бәхетле итәсе килә, ә мин шуны «аңламыйм». Күпме уйлар, күпме шикләр кичермидер ул шуның аркасында...

Әтием мескен әниемне бик кысрыклый иде шикелле, әледән-әле алар арасында зур, кызу сүз барганлыгын мин сизенә идем.

Берничә көн узгач, әнием тагын минем белән сүз башлады. Бу юлы ул миңа әтием белән сөйләшүен һәм әтинең мәсьәләгә ничек каравын әйтеп бирде. Дөресрәге, әтием үзе аңа, син ана кеше, кыз балага якынрак торасың, сезгә үзара сөйләшүе ансатрак, менә минем сүзләремне түкми-чәчми Зөһрәгә җиткер, дип кушкан икән.

Ул болай дигән:

— Без көчләп бирүчеләр түгел. Зөһрә чыга икән, һичшиксез яратып чыгарга тиеш. Ләкин Зөһрә ратуны аңлыймы, аның нәрсә икәнен беләме? Ул яшь әле, бу мәсьәләдә ялгышуы бик мөмкин... Чын ярату ул бары бер йөрәк эше генә түгел, ул — акыл эше дә. Ратканда, кешене кашына да күзенә генә карап яратмыйлар. Мондый ярату балалыктан чыкмаган яшүсмерләрдә генә була. Ратканда, кешенең акылын да, характерын да, кем булуын да, ниһаять, эшен-кәсебен дә яраталар. Боларның барысын да йөрәк әллә сизә, әллә юк, ә менә акыл аңларга, акыл белергә тиеш. Кеше үз хисенә үзе хуҗа була ала. Димәк, ярату хисе дә кешенең үз ихтырында, теләсә — ярата ала, теләмәсә — юк.

Зөһрә менә шуны аңларга тиеш. Ул Нәҗипкә кылтыклап киногa йөртүче тәти егет итеп кенә карамаска, ә үзе белән бергә гомер итәчәк, тормыш корачак дусты, ире, булачак балаларының атасы итеп карарга тиеш. Әгәр

шулай караса, ул Нәҗипнең яратмаслык бер җирен дә тапмас. Яратыр өчен, бәхетле булып торыр өчен Нәҗиптә бөтен сыйфатлар бар: акыл, әдәп, тәрбия, белем, дәрәҗә, яхшы һөнәр һәм бигрәк тә бик өметле матур киләчәк...

Ниһаять, Зөһрә безнең сүзгә дә колак салырга тиеш. Без аның бәхете өчен тырышабыз. Без аңа караганда дөньяда күбрәк торган кешеләр, безгә ышанырга тиеш ул... Минем соңгы сүзем шул: тыңласа — уңар, тыңламаса — үзенә үпкәләр!

Күрәсез, нинди туры әйтелгән сүзләр! Ачык, бөтен бер фәлсәфә. Әгәр бу фәлсәфә дөрестән дә һәркемгә ярый торган булса, һәркемне ышандыра алса, ни яхшы булыр иде. Тормышта мәхәббәт фаҗигасе дигән нәрсә бетәр иде ул чакта! Шулай түгелме?.. Акылың аша үзеңә: «Менә бу кешене ярат!» — дип боерык бирәсең дә шуның белән эшең дә бетә. Нинди ансат, нинди рәхәт!

Әтиемнең сүзләренә каршы мин бер сүз дә әйтмәдем, әйтә алмадым, чөнки ул сүзләр алдында мин көчсез идем. Ләкин аның фәлсәфәсе минем шикләремне таратмады, газабымны һич киметмәде. Нихәл итим соң? Мин бит Нәҗипне начар кеше димим, мин бит аның яхшы якларына күз йоммыйм... Әмма ничек аңа иргә чыгарга, гомергә аныкы булырга?.. Ул бит минә бирегә, йөрәгемә кереп утыра алганы юк!.. Ә кушалар, ә яратып була, чыгып була, диләр...

Әнием әтиемнең сүзләрен әйтеп бетергәч, үзеннән өстәп берни дә әйтмәде, берни дә сорамады, тик бары: «Уйла, кызым!» — дип, аркамнан йомшак кына сыйпап куйды... Күземә мөлдерәп яшьләрем килде, шулай да... еламадым мин. Күрәсең, язмышым белән килешә башлаган идем инде.

Әйе, бу сөйләшүләрдән соң, мин Нәҗип хакында тагын, тагын яхшырак итеп, җылы итеп, якынрак итеп уйларга тырыша башладым. Инде үземә үзем: «Мин аны яратырмын!», «Мин аны ярата алырмын!» — дип тукый торган булдым. Шуңа, шул ярата алуыма ышану, һич булмаса, ышанам дигән иллюзия кирәк иде миңа... Югыйсә «мин риза!» дигән сүзне әйтергә ничек телем әйләнер?

Без еш очраша алмый идек. Ул шәһәрдән җиде-сигез километр читкә эшкә йөри, ә мин укуларымнан бушый алмый идем. Шулай да атна саен очрашмыйча калмыйбыз... Ул безгә килә, башта әтием, әнием белән бер ярты сәгать чамасы сөйләшеп утыра, аннан без чыгып китәбез.

Ул гел бертөрле: гадәтенчә эре-горур, гәүдәсен бик

туры, башын бик текә тота, иреннәре нык кысылган булыр, ни генә әйтмәсен — тавышын һич үзгәртмәс, кычкырып көлмәс, кыска итеп, өзек-өзек кенә сөйләшер... Кәефе аның яхшымы, начармы — белеп булырлык түгел. Ә болай үзе миңа шактый игътибарлы, рөхсәт сорап кына култыгымнан ала, саулыгымны сораша, укуым белән кызыксына, киного-мазар илтсә — буфетка алып керә, пирожный яки яхшы конфетлар белән сыйлый. Ул үзе дә тәмле-төмлене ярата торган иде, тәмәке тартмый иде, тәмәке урынына кесәсендә ирис конфетлары йөртә иде.

Ләкин аның шулай тыштан бик игътибарлы булып, һәр теләгемне үтәргә әзер торып минем арттан ухаживать итүендә үзен миңа өйләнәчәк егет итеп танытырга тырышуы бик нык сизелә иде. Ә бу нәрсә мине ничектер бәйли, үземчә табигый булырга ирек бирми иде. Мин онытылып көлә дә, телемә килгәнне туп-туры гына әйтеп бирә дә алмый идем. Нигә инде гадирәк, якынрак, җылырак булмаска? Мин дә бит аңа, канат астына керергә торган чебеш кебек, елыша, якыная төшәр идем, җылыныр идем, йөрәгемдәге әлеге боз да, бәлкем, эрер иде. Юк шул, юк!.. Баш бик текә, иелеп күзләремә карарга иренә.

Шуның өстенә аның сүзсез генә миннән җавап көтеп йөрүе, ә минем шуны гел белеп торуым мине һәрвакытта киеренке бер хәлдә тота иде. Нигә ул сорамый, нигә шул хакта сүз ачмый, үзенчә мине ирексезләргә теләмиме? Болай үз иркемә куйса бит ул, ихтимал, беркайчан да минем җавабымны көтеп ала алмас.

Хәтта мәхәббәт турында сөйләшү дә безнең арада булмый иде. Гүя аның өчен бер сөйләшү белән хәл ителгән мәсьәлә иде ул, яңадан кабатлап торуның кирәге юк. Аның миңа өйләнәсе килә, ул шуны ярату дип белә... Ә миңа килгәндә инде, ул мине яраткач, мин дә аны, һичшиксез, яратырга тиешмен дип уйлый иде, күрәсең...

Шулай итеп, айдан артык вакыт үтеп китә. Без һаман йөрибез. Йөргән саен без кешеләр күзенә генә түгел, ничектер үз-үзебезгә дә вәгъдәләшкән кыз белән егет шикелле булып күренәбез, ә минем исә һаман әле соңгы сүземне әйтә алганым юк. Ахырда бу хәл аны борчый башлады булса кирәк, бер кичне ул миңа ярым шаярту белән:

— Зөһрә, мин бит сезнең приговорыгызны көтәм, әллә оныттыгызмы? — диде.

— Юк, онытканым юк,— дидем мин.

— Алайса нигә сузасыз, в чем дело?

— Җавабым әзер түгел...

Ул бик гаҗәпләнеп иңбашларын җыерды һәм: «Странно!» — дип куйды. Йөзе аның караңгыланып китте, иреннәрен тагын да кыса төшеп, шактый вакыт сүзсез калып торды. Үз теләгенә җиңел ирешеп өйрәнгән кеше өчен минем бу хәтле «сузуым» белән килешүе, чыннан да, авыр иде, ахрысы. Шул ук вакытта мине ихтыярсызларга да ярамый — менә бит ул ничек! Мин хәтта аны бер мәлгә кызганып та куйган кебек булдым.

Аннары ул кашларын җыерып, җитди итеп, ләкин тавышын ничек тә йомшартырга тырышып, миңа болай диде:

— Зөһрә, дорогая, сез мине газапламагыз. Мин билгесез положениедә булуны яратмыйм... Это очень тяжело!.. Ни әйтсәгез дә, тиз арада окончательно өзеп әйтегез. Прошу! Ярыймы?

Мин «ярый» дип вәгъдә бирдем.

Шуннан соң мин үзем дә уйлана башладым: чынлап та, нигә мин сузам, нигә кешене зарыктырып йөртәм? Барыбер әйтмичә котылып булмый бит инде. Ничаклы тизрәк булса, шулчаклы хәерлерәк булмасмы?.. Бәлкем, барысы да ачыкланыр, бәлкем, бу шик-газаплар баштан китәр.

Тәвәккәлләргә кирәк, әйе, тәвәккәлләргә кирәк. Икенең берсен әйтергә кирәк. Тик кайсын, кайсын соң, Ходаем?

Сез инде минем җавабымны алдан ук сизеп торасыздыр. Әйе, мин аңа җавап бирдем, уңай җавап бирдем, мин... ризамын, дидем, тик ашыктырмавын үтендем...

Зөһрә ханым сүзеннән туктады, күңеле тулып, бугазына төер килде шикелле, ефәк кулъяулыгын алып, иреннәренә китерде һәм шул хәлдә озак кына тынып утырды. Дымлы зәңгәр күзләре аның каядыр еракка төбәлгән иде, һәм йомды исә, яшьләре мөлдерәп агып төшәр төсле иде... Бу минутта аңа ни дә булса әйтүнең кирәксезлеген сизеп, мин дәшмәскә, туры карамаска тырышып утырдым.

Ниһаять, Зөһрә ханым, телгә килеп, хәлсез акрын тавыш белән:

— Сез гафу итегез,— диде,— арыдым, ахрысы, мин... кайтыйк... калганын бүтән вакытта сөйләрмен инде.

Мин, бер сүз әйтмичә, бары: «Әйдәгез!» — дип, аны кулыннан йомшак кына тотып торгыздым. Шул чакта башын күкрәгемә кысып, чәчләреннән сөеп аны юатасым килде. Кызганыч иде ул миңа...

Кайтып, Зөһрә ханымны санаторийга кертеп җибәргәч, мин, кире борылып, буш аллеялар буйлап киттем. Йокы-

сызлык, йокысызлык изә. Менә шулай арыганчы бер йөреп кайтмасам, күземне йома да алмыйм... Күбрәк утлар сүнгән юлларда йөрим. Кара бәрхеттән төн. Кайдадыр таулар. Кайдадыр диңгез. Күктә ерак йолдызлар... Бөтен галәмендә кеше язмышында һич кайгысы булмаган ваемсыз тирән тынлык һәм тынычлык. Ә мин берөзлексез «аның» турында уйланам. Һич тынычлана алмыйча, үземне кая куярга белмичә уйланам. Вәгъдә биргән. Риза булган. Чын ярату сыз, бергә кушылуны зарур иткән, бәхетле иткән чын мәхәббәттән тыш! Аһ, беләм бит мин соңыннан ни буласын! Мин үзем дә заманында шулайрак өйләнгән идем. (Дөрес, берәү дә кыстамастан.) Яңа институт бетергән врач кызга, югары белемле дип, профессиясе яхшы дип, ата-анасы да шәп кешеләр дип өйләнгән идем. Әйе, барысы да бар иде, тик «кечкенә» бер әйбер — чын мәхәббәт кенә юк иде. Әнә шул тышкы сыйфатлардан күзем томаланды, шулар белән исерүемне — ярату бу дип алдандым. Нәтиҗәдә мин гомерлек үкенеч, гомер буена чын мәхәббәткә сусап, эчтән сызып яшәү! Йә, моңардан да зур бәхетсезлек булырга мөмкинме?..

Беләсезме, искиткеч бер ачыклык белән мин Зөһрәнең нәкъ унсигез-унтугыз яшьлек кыз чагын күрәм... Күрү генә түгел, мин аны хис итәм, һәр карашын, һәр сүзен аңлап торам. Әйтерсең бу минем үз яшьлегем, яшьлегемә кайтуым. Белсәгез иде, нинди шомландырырлык дәрәҗәдә рәхәт, баш югалтырлык дәрәҗәдә татлы икән ул яшьлеккә кайту!.. Бик күптән бер нечкә шагыйрь: «Йөгереп уйныйсым, ятып елыйсым килә»,— дип язган иде. Нәкъ менә шуның шикелле: сөенечеңнән котырып тилерердәй, алдануыңнан үксеп елардай буласың.

## VIII

Икенче көнне без тауга менә алмадык — төшке аш вакытында очрашкач, Зөһрә ханым, башым авырта, кәефем юк, дип зарланып торды. Иреннәре агарган, күз төпләре уелган, ә үзе күңелсез, боек иде. Мин, билгеле, аңа кәефе яхшырганчы беркая да чыгып йөрмәскә киңәш бирдем.

Буш вакыт әрәм үтмәсен өчен, күптән уйлап йөргән бер теләгемне үтим дип, төшке аштан соң шәһәр музеена киттем. Барган бер шәһәремдә мин музейларны карамыйча калмый идем, чөнки һәр җирнең музее тарих белән кызыксынган кешегә бик күп яңа материал бирә торган иде.

Бу кечкенә курорт шәһәренең дә музее шактый бай булып чыкты. Тарих бик борынгыдан башланган. Биредә моннан бик күп мең еллар элек бу тирәдәге тау тишекләрендә яшәгән кыргый кешеләрнең тормыш эзләрен күрәсең. Биредә, залдан залга күчә-күчә, шул ук таулар итәгендә гүзәл бер шәһәрнең тууын, үсүен күз алдыңнан кичерәсең. Кыскасы, кызыксынып карар нәрсә җитәрлек иде монда... Мин һәр залда озак тукталып, барлык экспонатларны, панорама һәм рәсемнәрне, витринадагы тарихи документларны ашыкмыйча гына карап йөрдем. Минем игътибарымны революция вакыйгаларын һәм гражданнар сугышын чагылдырган материаллар аеруча җәлеп иттеләр. Таулар арасында кысылып утырган шушы кечкенә генә шәһәрдә Совет власте Петроград белән бер үк вакытта диярлек урнашкан икән. Бу җирнең дә үз революционерлары, үз каһарманнары булган. Коралын да тапканнар, байрагын да күтәреп чыкканнар... Ә гражданнар сугышы башлангач, алар җирле халыктан отрядлар оештырып, тауларда акларга каршы сугышып йөргәннәр. Менә бит ял итәр, рәхәт чигәр өчен генә туган һәм күпчелек халкы да килеп-китүчеләрдән генә торган курорт шәһәренең нинди кызыклы, бай революцион тарихы бар булып чыкты.

Карап йөри торгач, мин вакытның күпме узганын да сизми калганмын. Музейның ябылыр вакыты җиткән икән — әдәп белән генә шуны минем исемә төшерделәр.

Урамга чыксам, тәмам караңгы төшкән. Ихтыярсыздан гаҗәпләнә калдым: ничек әле мин бу хәтле онытылып киткәнмен?.. Күрәсең, өйдәге гадәтем монда да мине биләп алган.

Ә өйдә минем иң зур юанычым — эш. Эшкә бирелсәм — дөньямны онытам. Мактанып әйтүем түгел, эшсез берәү дә тормый, эшне һәркем ярата (әгәр күңеленә ошаса), ләкин минем өчен эш дигән нәрсәнең аерым әһәмияте дә бар. Бөтен җан сырхауларына каршы бердәнбер шифалы дәва ул минем өчен... Күп кенә еллардан бирле мин моны сынап киләм инде...

...Менә кайтырга чыккач та күңелемдә «ул» терелде. Ничек әле мин «аны» онытып торганмын — шуңа гаҗәпләнәм. Хәер, бу оныту булмаска тиеш, чөнки бөтен рухыма «аның» кереп сеңгәнлеген мин һәрвакыт диярлек тоеп йөрим. Тик әле игътибарым вакытлыча бүтән нәрсәләргә күчеп торды. Бары шул гына... Әмма тормышыңда сиңа бик якын, бик кадерле берәүнең барлыгын тоеп яшәгән хәлдә эшләү, иҗат итү нинди зур

бәхеттер инде ул! Йә, ничек мәхәббәт турында хыялланмыйсың ди!

Икенче көнне инде мин аның белән очрашуны сабырсызланып көтә башладым. Ахрысы, сагынып та өлгердем. Аннары өзелеп калган хикәянең дәвамын тизрәк ишетәсем килә иде. Моңарчы сөйләгәннәрен искә төшергәч, җанны борчыган сораулар туды: шул яратмаган егетенә «ул» чыкканмы, юкмы? Хәзер «картым» дигәне кем? Әгәр Нәҗип булса, телефон белән сөйләшкәннән соң «аның» йөзенә, күзләренә чыккан куанычны ничек аңларга? Яратмыйча чыгып та шулай бәхетле булып китәргә мөмкин микәнни?

Бу соңгы сорауның дөрес җавабын табу минем өчен аеруча әһәмиятле иде.

...Кичкырын без яңадан үзебезнең карт имән төбенә киттек. Тауны ашыкмыйча гына менеп, бераз хәл алгач, Зөһрә ханым сүзен әкрен генә болай дип башлады:

— Мин сездән бер нәрсәне аңлавыгызны үтенер идем. Моңарчы сөйләгәннәрем дә, менә хәзер сөйләргә җыенганым да минем үземне аклау, бүтәннәрне гаепләү өчен түгел. Һич юк. Мин башымнан кичкәннәрне нәкъ булганча, берни яшермичә, берни арттырмыйча сөйләргә тырыштым. Ләкин моңарчы чәчәкләре генә иде әле, хәзер исә җимешләре башлана... Ә минем дөрес итеп кенә түгел, ачык-туры итеп тә сөйлисем килә. Сез ят кеше, ир кеше, шуңа күрә миңа кайбер нәрсәләрне сөйләве бик кыен булачак. Ләкин сез мине гаеп итмәссез дип ышанам?

— Тыныч булыгыз, Зөһрә ханым, һич шикләнмәгез ул хакта,— дидем мин, агаларча юатып.

Ул, ак кулының сыртын маңгаена куеп, аз гына уйланып торды. Аннары кулын алды, башын күтәрә төште.

— Әйе, менә шулай! — диде ул, ничектер батырайган төсле булып.— Мин Нәҗипкә чыгарга ризалык бирдем. Яшерен бер өмет белән эшләдем мин моны: ризалык биргәч, үземне аныкы дип саный башлагач, бәлкем, ул миңа якын булып китәр, бәлкем, акрынлап яратып китәрмен, дип уйладым. Халыкта, мәхәббәт туйдан соң килә, дигән сүз бар бит. Шуның шикелле, араны вәгъдә белән беркеткәч, аннан бергә тора башлагач, ул үзеннән-үзе иң якын, иң кадерле кеше булып китәр, дип ышанасым килде. Әтием әйткәнчә, мәхәббәтне теләү юлы белән бар итмәкче булдым...

Башта ул шулайрак булыр кебек тә тоелды. Мин күңелемә һаман бер уйны — «мин аныкы, мин аныкы!» дигән уйны беркетергә тырыштым. Мин үземне тәнем-җаным белән чыннан да аныкы итеп хис итәргә теләдем. Ми-

нем йөрәгем гүя аңа ачылып тора иде... Ул да беренче көннән үк миңа үзенеке итеп карый башлады. Әйе... Вәгъдә биргәннән соң икенче очрашуда ул мине беренче тапкыр кочаклап үпте. Мин кулларым белән аның күкрәгенә ныграк терәлсәм дә, каршылык күрсәтмәдем... Яшерә алмыйм: шул чакта минем кыз йөрәгем моңарчы татымаган бер кайнар ләззәттән эрегән кебек булды, ничектер миңа кинәт кенә ул миңа бик якын булып китте.

Инде минем, күкрәгенә башымны салып, аңа сыенасым гына калды шикелле... Әгәр ул һаман шулай гадиякын, җылы-йомшак була белсә иде, ихтимал, миндәге бу үрелеп, омтылып тору вакытлы гына булып калмас иде, ихтимал, чын, тирән ярату хисенә әйләнеп китә алыр иде... Әмма юк шул!.. Кешесе ул түгел икән. Үрә баскан калыбыннан чыкмады, сизмәде, күрмәде.

Мин хәзер дә торып-торып гаҗәпләнәм: ничек итеп егерме алты яшьлек егет шулкадәр салкын канлы, картайган йөрәкле, тәмам утырып, ныгып җиткән кеше була алды икән?.. Ник бер яшьлек ялкыны, яшьлек юләрлеге, яшьләрчә очыну, сөенү, шаяру, көлү аңарда булсынчы!.. Акыл, исәп, бәхәссез хакыйкать, мәңге үзгәрмәс кагыйдә —менә аның утыртып куйган маяклары. Шул маяклар уртасыннан чыгу юк, чыкты исә, ул томана сукыр шикелле юлдан язарга тиеш!

Сүз таба алмыйм, шуңа күрә русчалап әйтәм — баштан ук ул үзен миңа карата покровитель итеп куйды. Мин шундый берни белмәгән бала инде, ул менә минем һәр адымымны күзәтеп һәм төзәтеп кенә торырга тиеш, янәсе... Еш кына ул миңа: «Зөһрә, син белмисең», «Зөһрә, син мине тыңла!», «Не будь наивной», «Не будь смешной»,— дип әйтергә ярата торган иде. Озак та үтми, ул үзенең өстенлеген күрсәтүдә шул дәрәҗәгә барып җитте ки, миңа хәтта әти-әнием алдында шелтә ясый торган булды. Әгәр минем көйсезләнеп әнием белән бераз гына сүзгә килүемне ишетеп калса, ул карт учительдәй башын чайкап: «Ай-һай, разве әнигә каршы әйтергә ярый? Нехорошо, нехорошо!.. Син зурларны тыңларга обязана»,— ди иде. Аптырый идем, гаҗәпләнә идем мин моңа. Ачуыма чыдый алмыйча: «Тыгылма син!» — дип кычкырасым килә иде. Ә икәү генә калгач, эчемнән ачынып аңа: «Син, дустым, үзеңә кагылмаганны күрмә, менә миңа кара, мине күр, миңа елмай, назлап бер үп, ичмасам!» — дип әйтәсем килә иде.

Үбү дигәннән, оят булса да әйтим, ул моңа да алай бик юмарт түгел иде. Йөргәннән соң, аерылышкан чакта, салкынча тыгыз ирennәре белән бер суырып үбә дә

шуның белән тәмам!.. Әле яңа сүз куешкан иң бәхетле чакларда сөю-иркәләүгә болай саран булган кеше өйләнгәч үзен ничек тотар? Санап кына үпмәсме, һәр үбүен бүләк итү дип санамасмы?.. Зинһар, сез мине ялгыш аңлый күрмәгез — бу минем үзем бик теләүдән әйткән сүзләрем түгел. Беләсезме, ул бит миннән бер генә тапкыр да: «Яратасыңмы мине?» — дип сорамады. Шуңадыр инде менә ихтыярсыздан күңелемә, ул мине җаны, йөрәге бар кеше итеп күрә белмидер, ә үзе теләгән чакта файдаланырга мөмкин булган бер әйбер итеп кенә миңа карыйдыр дигән уй килә иде... Өшеп, чирканып китә торган идем мин андый чакларда; тизрәк, тизрәк үземнән куарга тырыша идем мин ул ямьсез, чиркандыргыч уйларны... Ләкин, нишлисең, күңел бит, ниләр генә килеп китми аңар!

Инде минем авыздан вәгъдә ычкынгач, Нәҗип безнең өйгә иң кадерле кеше булып йөри башлады. Ак җәймә җәеп кенә каршы алмыйлар иде аны. Бигрәк тә әтием аның алдында бишкә бөгелә иде. Хәер, минем үземә карата да Нәҗипнең әти-әниләре тарафыннан шундый ук гаҗәп яхшы, якын мөнәсәбәт иде. Аеруча бер җылылык белән алар миңа: «Киленебез түгел, кызыбыз булырсың»,— дип кенә торалар иде. Әле туйны уйлаган да юк, ә Нәҗипнең әтисе Мотаһар абзый миңа бармак бите хәтле генә алтын сәгать бүләк итеп бирде. Бу олы, таза кешенең сүзсез генә тирәнтен, кызы кебек итеп яратуы минем йөрәгемә төшә торган иде, нинди генә хөрмәт күрсәтсәм дә аз булыр кебек һәм миңа баглаган өметләренең җимерелү ихтималын уйласам, үземне аның алдында чиксез гаепле итеп тоя башлый идем.

Кыскасы, ике як та бик бәхетлеләр, безгә дә ихлас күңелләреннән бәхет телиләр, хәер, безнең бәхетле булачагыбызга шикләнмиләр дә... Тик мин генә ачыла алмыйм, мин генә тынычлана алмыйм, төрле газаплы шикләрдән котыла алмыйм. Тагын иң куркытканы шул — әлеге, вәгъдә биргәч, аны якын итеп хис итә башлармын, ярата башлармын, дигән өметем бер дә вөҗүдкә ашмас төсле... Бетәр, сүнәр төсле...

Көн үткән саен, атна үткән саен мин Нәҗипне ныграк белә барам һәм... белгән саен мин аны аңлый алмыйча азапланам. Кем ул, нинди кеше? Моның җавабын табу ул чакларда минем өчен, ай-һай, авыр мәсьәлә иде... Кеше күреп, кеше танып өйрәнгәнмени әле мин?!

Соң, нәрсәсе белән ул миңа ошамый, мине үзеннән этә-реп, биздереп тора иде?

Әгәр мин аның салкын-тәкәббер булуы, чамасыз мин-

минлеге, шуның аркасында мине кешечә җылы, матур итеп ярата белмәве дип әйтсәм, бу гына аз, бу гына җавап була алмый. Бу кадәресен мин башта ук белдем, белеп кабул итәргә тырыштым... Ә менә аның төп кешелек сыйфаты нидән гыйбарәт — шуны аңлыйсым, шуны тотып аласым килә. Чөнки шунсыз тынычлана алмам кебек, чөнки бу мактаулы кешенең үзәгендә нииндидер миңа ят нәрсә бар кебек... Нәрсә соң ул?.. Мәсәлән, аның үзалдына ап-ачык куйган максаты бар: ул зур кеше, дәрәҗәле, исемле кеше булырга тиеш. Моңа ирешү юлын да бик ачык сызып куйган: башта ул үз заводында күтәрелергә, ничек кенә булса да заводның җитәкчеләреннән берсе — йә баш инженеры, йә баш конструкторы булырга тиеш. Аннан инде ул киң юлга чыгачак һәм, бәлкем, Мәскәүнең үзенә дә барып җитәчәк.

Нәҗип моны миңа һич яшермичә, туп-туры сөйли иде. Һәм, игътибар итегез, шул теләкләренә ирешәчәгенә һич кенә дә бер шикләнми иде. Аның бу кадәр үз-үзенә нык ышануына, максатын бу кадәр ачык куеп, шуңа салкын исәп белән тайпылмыйча бара белүенә мин шаккатып гаҗәпләнә идем. Нинди көч, нинди ихтыяр аңарда, нинди нык кеше ул! — дип, чын-чыннан аңа соклана идем... Беләсез инде, бездә бит андый биеккә омтылган кешеләр һәрвакыт мактала торганнар иде... Әйе, соклана идем, баш иярга әзер идем, әмма күңелем ятмый иде, чөнки еш кына ул миңа шул максатларына ирешер өчен теләсә нинди әшәкелеккә барыр, теләсә кемне таптап узар төсле булып күренә иде. Шундый чакларда аңардан тәмам җаным бизеп, хәтәр бер кешедән котыласым килгәндәй, тизрәк үзеннән качасым килеп китә иде.

Йә, әйтегез инде, фаҗига түгелме бу минем өчен? Йә, нинди мәхәббәт турында сүз булырга мөмкин?.. Йа Рабым!

Кинәт Зөһрә ханым ике куллап йөзен каплады. Мин курка калдым:

— Зөһрә ханым, ни булды сезгә, куегыз, кирәкми,— дидем, ничек тынычландырырга белмичә.— Борчылмагыз бу хәтле, үткән ич инде ул!

Зөһрә ханым, бераз дәшми торганнан соң, йөзен ачты, башын читкә борып, тирән генә сулап куйды.

— Әйе, үтте алар,— диде ул, акрын гына.— Ләкин, күрәсез, ул чактагы газапларым һаман әле йөрәктән чыгып бетмәгән икән... Хәерле булсын!.. Вакыт күпме соң инде?

Мин сәгатемә карап алдым.

— Унынчы ярты.

— Бераз утырырга була икән әле...

— Әгәр арымаган булсагыз.

— Сөйләп бетерергә кирәк ич... Әйе, менә шул инде... Яшь кенә булсам да, мин аның кем икәнлеген дөрес сизенгәнмен. Йөрәгем белән, дим... Әйе, безгә ят, ялган кеше иде ул. Чөнки аның эчендә үзе, үз мәнфәгате турында исәп корудан башка бүтән бернәрсә дә юк иде — тоймадым мин аны... Ләкин ул чакта әле мин Нәҗипнең кем икәнлеген акылым белән ачык аңлап, телем белән дөрес итеп әйтеп бирә алудан ерак идем... Бик катлаулы, авыр мәсьәлә иде ул минем тәҗрибәсез башым өчен... Ә менә хәзер әйтеп бирә алам... Хәер, сезгә болай да ачыктыр инде, аның кем булуы, дим, шулаймы?

— Сез аны, карьерист иде, димәкче буласыз?

— Әйе, әйе, нәкъ үзе... Бик дөрес әйттегез. Карьерист иде, беткәнче карьерист иде, тик кызганыч, шул чакта мин аның чын йөзен менә болай дөрес итеп билгели белмәгәнмен... Заманга бик оста яраклашкан акыллы карьерист иде шул! Коточкыч кеше!.. Менә хәзер хәтерлим, хәзер төшенәм: сөйләшкәндә ул еш кына кызыл сүзләр кыстырып җибәрергә ярата иде, үзенең политикадан хәбәрдар булуын күрсәтергә ярата иде. Бигрәк тә этием белән сөйләшеп утырган чакларында ул политиканы белүе белән ялтырарга тырыша иде... Ә мине, ышанасызмы, аполитичный булуда гаепли иде. Билләһи әгәр!.. «Син, Зөһрә, политикадан отстаешь!» — ди торган иде ул миңа, «кара аны!» дигән төсле итеп... Мин хәтта курка кала идем. Соң, дөрестән дә, политика турында алай бик уйланмый идем шул. Бар борчылганым — ялган сөйләмим дә, берәүгә дә зарарым тимәсен дә, кеше күзенә начар күренмим! Һәр җан иясен кызгана торган, һәркемгә бәхет тели торган чагым иде минем... Ә калганы турында ничектер уйлый белми идем... Дөрес әйтә иде ул миңа: «Син, Зөһрә, берни белмисең, син бик наивнаясың»,— дип. Белмәгәнмендер шул. Әмма йөрәгем дөрес сизенгән, йөрәгем алдамаган мине...

Инде нишләргә миңа? Чигенергә, вәгъдәмне кире алыргамы? Мөмкинме бу?.. Әйтергә генә ансат бит ул, вәгъдәне кире алу! Күпме җәнҗал кубачак. Күпме авыр сүз ишетергә туры киләчәк. Ә Нәҗип миңа ничек карар, ә аның әти-әниләре?.. Менә сиңа мактаулы кыз Зөһрә туташ, димәсләрме? Моның кебек игелексез нәрсәнең булганнан булмавы яхшы, димәсләрме?.. Нәҗип инде минем дәлилләремне тыңларга да теләмәячәк, бары кашларын җимереп, нәфрәт белән: «Клятвопреступница!» — дип кенә әйтәчәк. Ул моның кебек зур сүзләрне, гәрчә

дөреслеккә һич туры килмәсә дә, әйтергә ярата торган иде. Ләкин боларның барысыннан да бигрәк, мине һаман әле төрле шикләр борчый иде. Бәлкем, ялгыша торганмындыр, бәлкем, бу сизенүләрем аны ныклап белмәүдән киләдер, үтәр алар, бәлкем, ияләшеп, яратып китәрмен дип уйлана идем. Өмет дигән нәрсәне бер дә югалтасы килми бит!

Аннан инде тора-бара минем күңелемә ихтыярсыздан гаҗәеп бер теләк килә башлады: һай, мин әйтәм, берәр сәбәп чыксын иде дә без өйләнешә алмый калсак иде! Ләкин нинди генә сәбәп чыгарга мөмкин?

...Нәҗип миңа үзенең тәкъдимен 41 нче елның февраль башларында ясады. Мин вәгъдәне аңа март урталарында бирдем. Һәм менә минем иң авыр газапка дучар булып йөргән чагымда кинәт сугыш башланды. Әйе, сугыш...

Зөһрә ханым үзе генә ишеткән ниндидер бер өнгә колак салгандай, башын кырынайтып, йомыла язган күзләрен югарыга төбәп, бер мәлгә тынып калды. Тирәюньдә җылы якларда гына була торган искиткеч бер тирән тынлык иде. Бу тынлыкта «сугыш» дигән сүз урынсыз кебек, мәгънәсе юк кебек, аны ничектер тоеп та, аңлап та булмый кебек... Зөһрә ханым исә галәмне иркәләп җылы кочагына алган шушы юаш, хәвефсез тынлык аша гүя узып киткән сугышның ерактагы дәһшәтле гөрелтесен тыңлый иде. Мин сизеп торам: сугыш аның язмышында гаять зур роль уйнаган булырга тиеш... Һәм дәшергә, кыймылдарга куркып, аның сүз башлавын көтәм. Менә ул кузгалып куйды, кул сырты белән маңгаен сыпырып алды.

— Кичерегез,— диде ул, талчыккан тавыш белән.— Мин бик тәфсилләп тормам инде, арыдым, сезне дә арыттым бугай... Сугыш турында бит күпме генә сөйләсәң дә сүз бетәчәк түгел. Үзегез дә күреп үткәргәнсез инде аны... Шуңа күрә, артык җәелмичә,ниләр булганын гына әйтәсем килә. Әйе... Сугышның беренче көннәреннән үк мин курку катыш өметләнү белән Нәҗипне армиягә алырлар дип көттем. Ул үзе дә бик куркып, борчылып йөрде. Никадәр үзен яшерен, нык тотарга өйрәнгән кеше булмасын, аның шул куркуы йөзенә үк бәреп чыкты,— бөтенләй сөреме коелып, агарып калды бу... Хәтта берара мине онытып торды — атна-ун көнме безгә аяк басмады. Әйе, баш кайгысы аның өчен бөтен нәрсәдән дә өстенрәк иде... Аннан ул, үлем җәзасыннан котылган кешедәй, безгә балкып килеп керде: егетемә бронь биргәннәр, ул заводта калачак!..

Ә заводлары беренче атналардан ук корал эшләүгә күчте. Нәҗип баш-аягы белән эшкә чумды, кайбер көннәрне тәүлекләп заводтан кайтмас булды. Эш дигәндә ул үзен аямый торган кеше иде, эшли белә торган кеше иде. Ә сугыш аның кебек көчле, энергияле кешеләрне аеруча тиз үстереп җибәрде. Шул елның көзендә үк аны заводның баш инженеры итеп куйдылар... Шулай бит ул, берәү үлә, берәү көн күрә дигәндәй, кайчак кеше үзе дә сизмәстән кинәт кенә максатына ирешеп куя. Хәер, моны Нәҗипне яманлап әйтүем түгел — ул булмаса, аның урынында бүтән булыр иде... Ә Нәҗип үз урынында иде, һичшиксез, ул монда — заводта файдалырак иде.

Сугыш башланып, бер ай да үтмәде, безнең институтны госпиталь иттеләр. Августта инде институтның ябылуы билгеле булды, студентларның күбесе фронтка китте, ә кызларны төрле җирләргә — госпитальләргә, фабрика-заводларга — урнаштыра башладылар. Ә мин шул чакта тоттым да кыска сроклы элемтәчеләр курсына язылдым. Хәтерлисезме, сез миннән, характерыгызны билгелим дигән булып, профессиямне сораган идегез? Минем элемтәче булып китүем менә шуннан башланды инде. Тик сугыштан соң миңа аның институтын да бетерергә туры килде.

Әйе. Мин ул курсларга яшерен бер өмет белән язылдым, чөнки курсларны бетергәч, безне фронтка җибәрергә тиешләр иде. Әтиләрем минем бу эшемне белгәч, бик курыктылар һәм мине бик каты шелтәләделәр... Мин инде көч-хәл белән: «Мондый вакытта тик ятып булмый бит, иптәшләремнән оят»,— дип, ничек тә акланган булдым.

Нәҗипнең дә, билгеле, кәефе бик кырылган иде. Шулай да ул миңа каты бәрелүдән тыелды, белә — вакыты андый түгел, тик гадәтенчә минем баш очымнан каядыр читкә карап:

— Конечно, понимаю,— диде,— ну мин сине үзебезнең заводка устроить иткән булыр идем. Причем, яхшы эшкә...

— Белмәдем шул,— дигән булдым мин, беркатлылык белән. Миңа ничек тә песи булып кына, артык шикшөбһә кузгатмыйча, курсларга йөрергә кирәк иде.

Ләкин Нәҗип нидер сизенде булса кирәк, озак та үтми, бу минем алга бик җитди итеп тизрәк өйләнешеп тора башлау мәсьәләсен китереп куйды. Таләбе бик нык моның, күрәм, ике як та ашыктырырга киңәш биргәннәр булырга тиеш... Минем хәл тагын читенләшеп китте. Нишләргә?.. Туп-туры баш тартырга көчем җитми —

вәгъдәм бар, ә риза булырга... юк, мөмкин түгел. Мин бит яшерен өмет белән йөрим. Ярыймы соң! Мондый хәлдә минем Нәҗипкә каршы әйтерлек бердәнбер дәлилем — ул да булса сугыш үзе иде. 41 нче елның көзе — нинди шомлы вакыт иде бит ул!

— Нәҗип, үзең дә беләсең ич хәлләрне,— дидем.— Хәзер тора башлауның ни кызыгы да ни яме бар?.. Сабыр итик. Бу куркыныч вакыт үтеп китсен, өлгерербез...

Нәҗип, сабырсызланып, шуңа күрә бөтенләй русчалап, миңа каршы төште:

— Дорогая, нельзя быть паникером... Да, положение тревожное, но... жизнь продолжается. Кешеләр өйләнәләр дә, туалар да, үләләр дә... Потом учти, мине заводтан беркая да җибәрмиләр... Я тут буду воевать... Если серьезно говорить, син именно хәзер миңа чыгарга тиешсең. Мой тыл — это моя семья. А без крепкого, надежного тыла нельзя успешно воевать. Понимаешь, Зорочка?

— Аңлыйм, ләкин бит...

— Ну что «ләкин бит»?

— Сиңа шул минем хатын булуым гына кирәкмени инде?

Нәҗип минем беләгемнән каты гына кысып, үзенә тартып куйды:

— Да, именно шулай... Разве плохо?

— Белмим тагын,— дидем мин салкын, гына,— ләкин сиңа тыл булыр өчен генә иргә чыгуны аңламыйм мин... Синеңчә, шул гынамыни инде минем тормыштагы урыным?.. Бигрәк тә хәзерге кебек коточкыч авыр бер вакытта...

— Ах, вон как! — диде ул, башын чөеп.— Патриотизм, долг перед Родиной и так далее... Похвально! Что же, синең дә фронтка китәсең киләмени?

— Көлмә, Нәҗип,— дидем мин, ни өчендер кинәт күземә килгән яшьләрне чак тыеп,— җибәрсәләр, һичшиксез китәр идем...

— Что син, дорогая, көләргә уйлаганым да юк,— диде ул, ашыгып; сизеп алды, ахрысы, болай санламыйча сөйләшергә ярамаганны; ныграк елыша төшеп һәм моңарчы һич булмаган рәвештә юмалап сөйләргә керешге: — Зөһрә, акыллым, син беләсең... ни... Родина ничек әле? Ватан. Әйе, Ватан минем өчен дә бик кыйбат. Ватан өчен мин бөтен... ну бөтен жертвага әзер. Даже, сине миннән аерып җибәрсәләр дә, кажется, сүз әйтмәс идем... Но, дорогая, пойми, Ватан алдындагы святой ниебезне... бурычыбызны без монда да үти алабыз бит. Менә мин, передовойдагы солдат шикелле, заводта эшлим. Теләсәң,

син дә эшләрсең, бергә эшләрбез, и это будет выполнением нашего патриотического долга перед Родиной... Но главное вот в чем, дорогая: син бит миңа сүз бирдең, сүз!.. Шулай булгач, эш нидә? Сүздә тору — это же святая обязанность! Не так ли? Ә хәзер, по-моему, вакыт җитте: безгә бергә тора башларга кирәк. Моны мин генә түгел, синең әти-әниең дә, минекеләр дә бик телиләр. Без барыбыз да синең соңгы сүзеңне көтәбез... Зорочка, милая моя, надо с этим считаться!

Йә, нәрсә әйтим инде мин бу сүзләргә каршы? Әйе, бар да миннән көтәләр. Мин моны бик яхшы аңлап, күреп торам. Вәгъдәмне кире алырга җөрьәт итмәгәч, мин аларны тыңларга, мин, ниһаять, Нәҗип белән тора башларга тиеш түгелмени?.. Күпме сузсаң да, ахыры бар ич! Алар хаклы, әйе, хаклы, ә минем күңелемдә яшерен сер итеп йөрткән әнә шул өметемнән башка бүтән чарам юк...

Кыскасы, мин Нәҗиптән курслар беткәнче генә сабыр итеп торуын сорадым, ә курслар бер айдан бетәргә тиеш иде. Ул ни сәбәптәндер җиңел генә риза булды.

Әмма шулай да мин никадәр беркатлы юләр булганмын. Янәсе, мыштым гына укып йөрим дә, бетергәч, көннәрдән бер көнне фронтка китеп барам инде, ә Нәҗип тә, этием-әнием дә чарасыздан килешеп: «Хәерле булсын, исән-сау йөреп кайт!» — дип, мине озатып калалар инде. Бүре дә тук, сарык та бөтен!

Курсларны бетергәч, мине тоттылар да әйбәтләп кенә үзебезнең шәһәр телеграфына эшкә җибәрделәр. Нигә фронтка түгел, дигәч, курслар начальнигы: «Сезнең хәзергә анда кирәгегез юк, биредә резервта булырсыз»,—диде. Соңыннан белдем: бу турыдан-туры әтием тырышлыгы белән эшләнгән икән... Үземә бу хакта ник бер сүз әйтсеннәр, астан гына әнә шулай эшләделәр дә куйдылар.

Күрәсең, язмышка буйсынудан башка бүтән чара калмады... Шулай уйлый башладым мин, адашкан кеше төсле, тәмам аптырап-йөдәп беткәннән соң... Гаҗәпләнмәгез, тик дөрес аңларга тырышыгыз мине... Вәгъдә бирелгән, егетем көтеп йөри, әти-әнием ышанып тора, хәтта әнә шул сугыш үзе дә мине тизрәк бер карарга килергә ашыктыра кебек. Чыннан да, бик төпченеп, нечкәләп тора торган чакмыни?.. Бик кечерәеп калды бит хәзер андый шәхси мәсьәләләр.

Чын ярату хис итмим икән, күңелем тармый икән, нишлим соң инде?.. Аның каравы, ул мине ярата, һичшиксез яратачак, мин моңа ышанам. Андый кеше хатын кадерен белергә тиештер дип, уйлыйм, аңа бит «ныклы тыл» кирәк.

Һәрбер җиткән кыз кияүгә чыгарга тиеш. Бу табигый нәрсә. Кыз кеше шуңа алдан хәзерләнеп, шуны көтеп йөри. Ләкин кайчак бит кызлар, алай бик тирән мәхәббәт кичермәстән, ничектер ансат кына чыгалар да куялар. Һәм уңышлы чыгып куялар, зарланмыйлар, әйбәт кенә тора башлыйлар. Минем белән дә шулай булып китмәсме?.. Кем белә, чыгып караганым юк бит әле... Иярләшермен, җайлашырмын, мәхәббәт насыйп түгел икән, нишлим, ирем итеп, баламның атасы итеп якын күрергә тырышырмын.

Кече яшьтән үк мин ялган белән ирексезләнүне күтәрә алмый идем. Әмма хәзер мин шундый бер хәлгә куелган идем ки, ихтыярсыздан әнә шулай үземне алдарга, үземне ирексезләргә мәҗбүр булдым.

Озын сүзнең кыскасы, без яңа ел башыннан бергә тора башларга булдык. Вакытның бик авыр, хәлләрнең мөшкел чагы булуга карамастан, безнекеләр туй сыман кечкенә бер мәҗлес тә үткәрергә булдылар. Шуңа хәзерлек башланды. Әтием аннан-моннан табып, азык-төлек ташырга тотынды. Әнием минем кирәк-яракларымны барларга керешТе... Нәҗипләр ягы да безнең туйга хәзерләнәләр иде... Әмма ләкин туйны күрү берәүгә дә насыйп булмады. Әйе, чынлап әйтәм, була алмыйча калды безнең туй...

Нигә бу хәтле миңа гаҗәпләнеп карыйсыз? Сабыр итегез, хәзер барысын да белерсез. Башын сөйләгәч, ахырын яшереп булмас инде.

* * *

Нигә гаҗәпләнеп карыйсыз, ди ул! Әйе, гаҗәпләнеп карыйм, гаҗәпләнмичә мөмкин түгел. Күпме шик-газаплардан, каршы торулардан соң, яратмаганын белә торып, үзен көчли-көчли Зөһрә ханым, ниһаять, Нәҗип белән кушылырга риза була! Шул ук вакытта туебыз булмыйча калды, ди. Ничек аңларга соң моны?

Әгәр теге вакытта мин үземнең хәлне сөйләп биргән булсам, ул да бик гаҗәпләнер иде. Яратмыйча торып, ничек өйләндегез соң? — дияр иде. Ә бит безнең эш катлаулырак булды. Без үз-үзебезне дә, бер-беребезне дә алдаган идек ул вакытта. Юк мәхәббәтне бар дип белдек. Дөресрәге, яшьлек дәрте белән кабынган вакытлы мавыгуны без мәхәббәт дип уйладык. Менә нәрсә безне төзәтә алмаслык зур хата ясарга мәҗбүр итте. Аның, ягъни чын мәхәббәтнең асылда юклыгын без соңыннан, тора-бара, айлар-еллар үткәч кенә белдек. Анда да әле мәхәббәтнең юклыгын икърар итәргә көчебез җитмичә, эчтән генә күпме газап кичереп, һаман яши бирдек. Ләкин иллю-

зия, иртәме-соңмы, барыбер төтен кебек тарала ул! Менә таралды. Хәзер мәсьәлә ачык — без ялгыш кушылганбыз. Әмма моны аңлаудан, эш узгач, ни хәер?

...Төзәтә алмаслык хата, дидем. Белмим, Зөһрә ханым үзенең хатасын соңыннан төзәтә алгандырмы, юкмы, әмма күпләр, бик күпләр ялгыш өйләнешүне төзәтә алмыйча гомерләре буе газап чигеп, күңелсез итеп, ямьсез итеп яшәргә мәҗбүр булалар. Өйләнешү бит ул — ике кешенең язмышын бергә төенләп бәйләү дигән сүз. Ә бу төен торган саен ныграк тартыла һәм чияләнә бара. Теш белән дә чишеп булмый башлый аны. (Бигрәк тә төенгә балаларның да язмыш җепләре кереп чуалганнан соң.) Шул ук вакытта кеше чын мәхәббәтне теләүдән, сагынудан, өмет итүдән туктый алмый — иң тыйнак, иң тәкъва кеше өчен дә бу шулай. Йә, фаҗига түгелме бу? Димәк, хатаны ясамаска кирәк аны, ясамаска! Бары ир белән хатынны тиң иткән, дус иткән, җаннарын җанга бәйләгән, сүрелми-бетми торган мәхәббәтнең булуына ышанган хәлдә генә кушылырга, гаилә корырга ярый. Шунсыз — гомерлек үкенеч!

Зөһрә ханымның, күрәләтә торып, хата адым ясарга җыенуы, әлбәттә, мине гаҗәпләндерде.

Ләкин ул... безнең туй булмыйча калды, диде. Башын сөйләгәч, ахырын яшереп булмас инде, диде. Моны ничек аңларга? Тагын ниләр булган? Гаять кызыклы иде бу!

Зөһрә ханым нечкә кашларын җыерып, иреннәрен кысып, беравык тынып торды. Аннары, ныклы карарга килгәндәй, башын текә генә күтәреп, яңадан сүзен башлады — тавышы да аның ныгый төшкән кебек булды.

— Әйе, сөйләми булмас,— диде ул, кабатлап.— Беләсезме, кайвакытта очраклы гына бер сәбәп кешенең язмышын шундый үзгәртеп җибәрә, шундый үзгәртеп җибәрә менә, яңадан иске хәленә кайтуны ул инде уйлый да алмый. Хәер, ни өчен мин моны, баштан ук акланып куярга теләгәндәй, әйтеп торам?.. Минем эшем — бары ни булганын яшермичә дөрес итеп сөйләү генә ич, шулай түгелме? Ә хөкем итү — анысы инде сезнең эш...

Менә шулай, әйткәнемчә, безнең туй 42 нче елның башында булырга тиеш иде. Ә 41 нче елның ахырында менә нәрсә булды: 5 декабрьдә, Конституция көнендә, Нәҗипләр заводы Культура сараенда бер кичә үткәрмәкче иде. Зур завод, бай завод, шунлыктан авыр вакыт дип тормыйча, искечә бер бәйрәм итеп алырга булганнар... Нәҗип мине менә шул бәйрәм кичәсенә чакырды. Үзе ул, кайтып йөрергә бушый алмам, диде, миңа сәгать җи-

дедән дә калмыйча килеп җитәргә кушты. Ә завод шәһәрдән сигез километр читтә иде.

Көннәрнең иң кыска чагы, бик тиз караңгы төште. Мин эштән кайткач, ашамый-эчми, тиз-тиз киенеп, китәргә әзерләндем. Өйдән чыкканда, сәгать җиденче егерме минут иде инде.

Ашыга-ашыга шәһәр уртасына киттем — заводка илтәсе трамвайларның туктый торган җирләре шунда иде... Бәйрәм кичәсенә барасы булгач, мин аягыма яхшы туфлиләр белән ак ботылар кигән идем. Ә көн бик тә суык иде. Ун минуттан шәһәр уртасына җитеп, трамвай көтә башладым. Кызу килгәнлектән мин суыкны артык сизмәдем, килеп җиткәч тә әле аңа игътибар итмәдем... Көтәм, биш минут, ун минут көтәм, ә трамвай юк та юк. Төн караңгы, бер генә тычкан уты да күренми. Бик шомлы иде бит ул чакта: тоташ караңгылыктан йөрәк өзгеч һава тревогалары... Шәһәр өстен салкын томан каплаган, бөрешкән кешеләр кинәт томан эченнән килеп чыгалар да шунда ук тагын югалалар. Сизәм, суык акрынлап үтә, бигрәк тә аякларым туңа башлады... Трамвай көтүчеләр дә бик аз, килеп туктаганнары ике-өч минут кына торалар да, суыктан куркып, тизрәк китеп баралар. Ә мин көтәм дә көтәм. Шактый вакыт узды шикелле инде... Шул чакта мин үземнән ерак түгел бер хәрби кешенең күн итекләрдән шыгыр-шыгыр басып, әрле-бирле йөргәнен шәйләп алдым. Ул да трамвай көтә, ахрысы. Мин аңа, әлбәттә, игътибар итмәдем. Хәрби кешеләрнең күп заманы, берсен дә күрәсем килеп тормый, үз кайгым кайгы әле монда. Аякларыма суык тәмам үтте булса кирәк, бармакларым чеметтереп сызларга тотынды. Нишләргә соң?.. Иң яхшысы — җәяүләп тизрәк китәргә кирәк иде, ә мин, утыртып куйган казыктай, һич кузгалмыйча, бер урында торам да торам... Хәрби кеше дә, ачу китереп, шыгыр-шыгыр һаман әрле-бирле йөри дә йөри... Кем ул, нигә ул гел йөренеп тора? — дип, ихтыярсыз уйланам... Итекләрдән генә бит, шуңа күрә йөренеп торадыр, дип эчемнән, һәм үземнең дә аның кебек әрле-бирле йөрисем килә. Ләкин мин кузгалмыйм, ул йөргәнгә күрә кузгалырга теләмим... Йөрәгем әрнеп, Нәҗипкә ачуым килә башлады: кайтып алырлык булмагач, нигә ул мине чакырды, нигә мине бу зәмһәрир суыкта катып беткәнче трамвай көтәргә мәҗбүр итә? Чәнчелеп китсен үзе дә, кичәсе дә, кайтам да китәм, дим рәнҗеп... Ләкин... гаҗәп менә — урынымнан һич кузгала алмыйм. Бу инде минем чын-чынлап туңа башлавым иде. Шул чакта хәрби кеше яныма килеп басты.

— Туташ,— диде ул русча, батыр гына.— Нишләп сез биредә торасыз?

Мин күз кырыем белән генә аңа карап алдым. Теләмичә генә:

— Ә нигә ул сезгә? — дидем, аннан ничектер бала шикелле йомшарып, хәлсез тавыш белән: — Трамвай көтәм,— дип өстәдем.

— Көтмәгез, трамвай тиз булмас, кайдадыр авария.

Мин дәшмәдем, ләкин бу аны бер дә аптыратмады шикелле.

— Сезгә хәзер үк китәргә кирәк, сез тәмам туңгансыз,— диде ул, һаман шулай батыр, кыю гына.

Мин ихтыярсыздан бу тавышка буйсынган кебек булдым. Хәер, тискәреләнеп тору юләрлек булыр иде — суык минем үзәгемә үткән иде инде... Мин кузгалдым, ләкин чак кына егылып китмәдем: аякларым атларлык түгел иде. Егет шунда ук мине беләгемнән тотып алды. Мин беләгемне ычкындырмакчы булып карадым — көчем җитмәде, телем белән дә берни әйтә алмадым, исерек кешедәй егет ярдәме белән хәлсез генә атлап киттем.

— Юк, ярамый болай,— диде егет, эчке пошыну белән үзалдына сөйләнеп.— Хәзер үк берәр җиргә кереп, аякларыгызны җылытырга кирәк.

Ерак түгел генә бер зур гостиница бар иде, шуның ишеге төбенә җиткәч, егет минем беләгемнән ныграк тотып:

— Менә шунда керәбез! — диде.

Мин туктадым, актык көчемне җыеп дигәндәй, беләгемне тартып алдым да, еларга җитешеп, көчкә-көчкә генә: «Нишлисез сез?» — дидем.

Егет минем күзләремә текәлде. Чын борчылу һәм шелтә белән карый иде аның күзләре. Ниһаять, катгый итеп, хәтта бераз ачулы да итеп, ул:

— Туташ, урынсыз җирдә киреләнмәгез,— диде.— Мин солдат кеше, аяк өшетүнең нәрсә икәнен сездән яхшырак беләм. Хәзер үк җылыга керергә кирәк. Әйдәгез!

Мин кат-кат башымны селектем: «Кирәкми, кирәкми»,— дидем, күгәргән иреннәремне чак тибрәтеп, һәм китә башладым. Шушы китүдән инде мин китеп барган да булыр идем, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шул минутта шәһәрнең төрле ягыннан завод гудоклары үкерергә тотындылар: һава тревогасы!.. Менә гаҗәп бит ул, берәр хәл булырга булса, сәбәбе чыга да тора... Шуннан хәрби кеше, бер сүз әйтмичә, яңадан беләгемнән сак кына, әмма каты тотып, мине ишектән алып кереп тә китте. Икенче катка алып менде. Аннары озын коридор

буйлап алып китте. Шул арада мин үзем белән ни булганын аңларга тырыштым, нишлим мин, кая барам, дип котым чыгып уйландым, ә үзем һаман аның ихтыярына буйсынып бара бирдем... Менә ул бер бүлмә каршына җитеп туктады, кесәсеннән ачкыч чыгарып, ишеген ачты да үрелеп ут кабызды. Аннары мине кулымнан тотып, тәрәзәсе зур кара япма белән капланган бүлмәгә кертте, тиз генә бер урындык алып, шуңа утыртты. Шинелен дә салып тормыйча, идәнгә тезләнеп, минем ботыларымны, туфлиләремне салдырды да ике куллап әле бер аягымны, әле икенче аягымны уарга тотынды. Мин ничектер тәмам хәлсезләнеп калдым, иреннәрем: «Кирәкми, кирәкми!» —димәкче булып көчкә кыймылдыйлар, ләкин тавышым үземнән китми, тик күзләремнән мөлдерәп яшьләрем генә тәгәри. Ә ул авыруны коткаручы врач сыман, сүземә дә, яшемә дә карамыйча, һаман уа да уа. Аякларым минем чынлап та һичнәрсә тоймас булып калганнар иде. Ләкин ул берникадәр кызу-кызу гына уганнан соң, аякларым чәнчеп-чәнчеп авырта башлады. Мин хәтта кычкырып та куйгаладым. Ул: «Сабыр, сабыр»,— диде һәм тагы да катырак басып уарга кереште. Бераздан аякларым җылы тойды, чәнчеп авырту бетте, ләкин сулкылдап сызлый башлады.

— Йә, ничек? — диде ул, тезләнгән җиреннән минем йөземә карап.

— Сызлый,— дидем.

— Алайса бик әйбәт,— диде бу һәм идәннән торды... Минем ботыларымны алып, җылымса батарея өстенә бастырды, шуннан соң гына шинелен салды, гадәтләнгән җитезлек белән гимнастеркасын киң каешы буйлап ике якка сыпыргалады, бармаклары белән генә чем-кара чәчләрен тараштырып куйды. Миңа карап бер елмайды да: «Инде сезгә кайнар чәй кирәк»,— диде һәм өстәлдән киң төпле зәңгәр чәйнекне алып чыгып та китте...

Ходаем, нинди хәлгә юлыктым мин? Үзем ни уйларга да белмим, тик гомердә күрмәгән-белмәгән ят ир бүлмәсенә болай кереп утыруның никадәр килешмәгәнлеген аңлыйм, шуңа гаять пошынам, әмма... әмма шул ук вакытта бу эшем өчен ничектер менә үкенә алмыйм... Алай гына да түгел, бу кешенең мине үзенә көчләп алып керүе минем өчен яхшы булды кебек, аякларымны гына түгел, ул хәтта йөрәгемне җылытып җибәрде кебек... Әле төрле шикләрдән котыла алмасам да, күңелем ничектер тыныч...

Менә ул җәһәт кенә килеп керде дә беренче сүз итеп миңа:

— Инде хәзер өстегезне салыгыз,— диде.

— Юк, юк,— дидем мин, ашыгып.— Мин хәзер китәм.

— Шуңа күрә салырга кирәк тә, салмыйча утырсагыз, чыгу белән туңа башларсыз. Кая, бирегез!

Мин, кыюсыз гына урынымнан торып, өстемне салдым. Ул пальтомны элеп куйды. Минем өстемдә киң итәкле, озын тар җиңле, билемне кысып торган соры йон күлмәк иде. Ул миңа бик ятып, килешеп тора иде. Пальтомны салгач, үземне ничектер шәрәләнгән төслерәк хис иттем: һәрбер ир кешенең миңа игътибар белән карамыйча калмавын мин белә идем инде.

Ә ул кулы белән ымлап кына мине өстәл янына чакырды һәм зур эмаль кружкага өч-дүрт шакмак шикәр салып, куе кайнар чәй ясап, алдыма куйды.

— Эчегез!

Аннан үзе, мин тартынмасын дипме, бүлмә буйлап әрле-бирле йөрергә тотынды.

Кружканы учларыма алдым, иренемә китердем, ләкин ул бик кайнар иде — авызым пешә язды. Кайнарга тигәч, бөтен тәнем кинәт калтыранып китте, әллә ничек рәхәт булып китте.

Беренче тапкыр мин курка-курка гына игътибар белән егеткә карадым. Ул урта буйлы, киң генә җилкәле, сыны — нәкъ хәрбиләрнекечә төз, җыйнак, йөзе шома, кара тутлы, башкортныкына тартым киңчә-түгәрәк, ләкин борыны бик туры, күзләре кечкенә, елтыр кара, кашлары да куе кара, чәче дә, әйткәнемчә, чем-кара... Үзенчә матур гына бер егет иде ул.

Менә ул, йөргән җиреннән башын чайкап, көлеп куйды.

— Кала уртасында туңып үлә яздыгыз бит! — диде ул.— Беләсезме, күпме вакыт сез суыкта басып тордыгыз?

— Юк, белмим.

— Нәкъ 35 минут. Кая бармакчы идегез?

Мин җавап бирмәдем... Егет кабатлап сорамады, тик мине юатырга теләгәндәй:

— Зарар юк, хәзер чыгып бетәр,— диде.— Кайнар чәй куып чыгарыр... Суыкны, дим...

Аннан ул минем каршыма килеп утырды, күзләремә туры карады.

— Сез татар кызымы?

— Әйе.

— Исемегез?

Мин әйтимме, юкмы, дип, бераз шикләнеп тордым, шулай да әйтергә булдым:

— Зөһрә.

— Зөһрә? Үзегезгә бик килешә торган исем икән,— диде ул, тулы иреннәре арасыннан ак тешләрен күрсәтеп.— Ә минем исемем — Бәхетгәрәй. Минем агайлар барысы да Гәрәйләр: Арыслангәрәй, Солтангәрәй, Дәүләтгәрәй... Миңа, юньлесе калмагач, Бәхетгәрәй дип кушканнар. Ләкин мин «Бәхетен» алып ташладым... Ничек булып чыгар бит әле, алдан ук тагып кую уңайсыз кебек.

— Сез башкортмы?

— Атай — башкорт, инәй — типтәр... Ә сез эчегез, суытмый эчегез!

Мин бераз эчеп куйдым, ул тагын кайнарын өстәде. Үзе бала өйрәткән шикелле һаман:

— Пешә-пешә эчәргә кирәк, җылысы бөтен тамырларга китсен,— дип кыстый торды.

Чынлап та, мин әле бер дә җылынып китә алмый идем. Эчемдә боз яткан кебек, әледән-әле калтыранып куям, әледән-әле аркам кымырҗып китә, яңадан туңа башлаган шикелле булам, тик битем генә уттай яна — шуны сизәм. Авырып кына китмәсәм ярар иде, дип куркып та куям. Шул ук вакытта үзем гел бернәрсә турында уйланам: бу егет кем, каян килеп чыкты ул, ни өчен мине сагалап торды?

Ул чакларда әле погон дигән нәрсә юк, хәрби кешеләрнең якаларында төрле билгеләр генә була торган иде, ә мин аларга карап, званиеләрне тәгаен аера белми идем. Моның якасында ике шакмак. Кем булырга тиеш? Һәрхәлдә, зур исемледән түгелдер, кечерәк бер командир булса кирәк... Тагын күкрәгендә зур гына «стрелок» билгесе дә, бер Кызыл Йолдыз ордены бар. Димәк, армиягә кичә-бүген генә алынган яшьләрдән түгел инде бу...

Шулай да ничек кенә итеп беләсе икән: каян килеп чыкты да бу башкорт егете, ни өчен сагалап торды мине? Сораргамы? Юк, мөмкин түгел, булдыра алмыйм. Ләкин ул үзе минем нәрсә турында борчылып уйлавымны сизде булса кирәк. Нидер исенә төшергәндәй, үзалдына көлеп куйды да:

— Кызык кына килеп чыкты бит әле,— диде.— Кем уйлаган, ә?.. Мин инде трамвайны көтмичә китеп бармакчы идем, шул чакта сезгә күзем төште... Сез әллә ничек кенә бик тын, бик боек басып тора идегез. Нигә, мин әйтәм, бу туташ чатнама суыкта болай тик кенә, бер дә селкенмичә тора, берәр хәсрәте бармы соң моның, дим. Нишләрсез икән, дип көтәргә булдым. Ә сез торасыз да торасыз. Борчыла башладым, хәтта ачуым да килә башлады, ни булган моңа, туңдыра бит бәләкәй аякларын,

сизми микәнни, дим. Шуннан түзмәдем, яныгызга барып дәшәргә булдым... Ачуланмыйсызмы миңа?

Мин, акрын гына башымны селкеп:

— Юк,— дидем.

Кыз чагымда мин хәрби кешеләрне яратып бетерми идем, ни өчендер ятсына идем, курка идем алардан. Түшләрен киереп, үрә катып йөргән бу кешеләр хатын-кызга бик җиңел карыйлардыр төсле тоела иде миңа. Моңарчы минем бер генә хәрби кеше белән дә танышканым юк иде әле.

Хәзер менә шул хәрбиләрнең берсендә, аның аулак бүлмәсендә чәй эчеп утырам. Чынлап та кызык ич! Дөрес, мин карчыга баласыдай бик сак, бик уяу утырам, егетнең бер сүзен дә, бер хәрәкәтен дә күздән ычкындырмыйм. Аз сөйләшәм, ни дә булса сорарга-белергә кыймыйм. Ул да бик алай чәчелеп тормый, еш кына сүзсез кала, әледән-әле торып йөренә, тагын килеп утыра һәм минем күзләремә туры караганда ничектер онытылып киткәндәй була. Хәйран калу, аптырау, тирән уйга төшү, аннан айнып китү чагыла кебек иде аның кечкенә күзләрендә.

Ул миңа бер комплимент та әйтмәде, юри ярарга тырышу кебек нәрсә күрсәтмәде, ләкин шуңа карамастан мин кыз йөрәгем белән аңа бик ошавымны, дөресрәге, торган саен ошый баруымны сиздем. Чынлап курка калдым мин бу хәлдән һәм ихтыярсыз сөенгән кебек тә булдым.

Мин кешене бер күрүдә генә таный белми идем. Киресенчә, кеше минем өчен күп вакытта табышмак иде, һәрбер яңа кеше миндә төрле уйлар кузгата, тәгаен бер фикергә килә алмыйча йөди идем. Ә бу егетне исә мин бик тиз таныдым шикелле. Ничектер бик ачык, аңлаешлы кебек иде ул миңа... Бернинди яшерен нәрсәсе юктыр төсле, таза күкрәгендә саф йөрәк тибәдер төсле. Үзе бик гади, сүзләре чын — беткәнче аңа ышанырга ярыйдыр кебек, ул сине бервакытта да алдамас, беркайчан да рәнҗетмәс кебек... Менә шундый кешенең канаты астына сыенсаң иде!.. Әмма алдана калсаң, Алла сакласын, нинди коточкыч һәлакәт булыр иде!

— Йә, җылындыгызмы инде? — дип сорады ул миннән.

Беренче тапкыр аңа елмаеп баш кактым мин. Бик күңеле булды, ахрысы, шуңа, ничектер менә сөенеп, сөеп карады ул минем күзләремә...

Ни өчендер нәкъ шушы минутта мин Нәҗипне хәтерләп, сискәнеп киттем. Нишләп утырам мин? Ул бит мине эзләп кайтыр, безнекеләрне аякка бастырыр, ми-

лициягә хәбәр итүләре бар... Тизрәк, тизрәк китәргә кирәк!

— Вакыт күпме? — дип сорадым мин, кабаланып.

Егет кулындагы зур сәгатенә карап алды.

— Унынчы унбиш минут.

Мин ашыгып урынымнан тордым.

— Китәсез дәмени инде? — диде ул.— Җылынып та җитмәгәнсездер...

— Юк, юк, җылындым,— дидем мин, эчемдә бизгәк калтыравы бетмәсә дә, ләкин бусы инде өшүдән булмаска тиеш иде.

Ул минем ботыларымны алып бирде, пальтомны алып кидерде, аннан үзе киенә башлады. Аның озатырга җыенуын күргәч, мин каушый калдым. Урамда берәр таныш очраса? Ярамый, ярамый.

Кыенсынып кына, мин аңа:

— Сез озатып мәшәкатьләнмәгез инде,— дидем.

Ул миңа төбәлеп карады да, уемны аңлаган шикелле, йомшак кына:

— Борчылмагыз, мин сезне бер генә квартал озатырмын, ярыймы? — диде.

Минем яңадан «кирәкми, озатмагыз» дип әйтергә телем әйләнмәде... Киенеп бетеп, бүлмәдән чыгар чакта гына ул мине ишек төбендә туктатты.

— Зөһрә,— диде ул, минем җиңемнән сак кына сыйпап.— Сезне бик күрәсем киләчәк, тагын бер генә тапкыр очрашыйк!

Мин башымны идем, йөрәгем еш-еш тибә башлады. Шунда ук, кирәкми, ярамый, дип әйтергә теләдем, ләкин үзем дә сизмәстән:

— Белмим шул,— дип куйдым.

— Үтенәм. Тыңлагыз мине, очрашыйк! — диде ул, әллә ничек минә йөрәккә үтеп керерлек итеп.

— Белмим, белмим,— дидем мин, үрсәләнеп, һәм ашыгып бүлмәдән чыктым.

Урамга чыгу белән суык мине өтеп алгандай итте, бөтен тәнем кымырҗып китте, куырылдым, дер-дер калтырый башладым. Әллә суык шундый рәхимсез инде, әллә нервыларым тәмам урыннан кузгалган... Егет мине култыгымнан алды, мин каршылык күрсәтмәдем, күрсәтерлек көчем дә юк иде. Ярый әле урамнар караңгы...

Кызу-кызу атлап бер чатка җиткәч тә, ул үзе башлап туктады.

— Инде ялгыз гына китәсез... Курыкмассызмы?

— Юк, юк, рәхмәт! Хушыгыз! — дидем мин, калтыравымны көчкә тыеп.

— Хушыгыз, хуш! — диде ул, минем кулымны аз гына җибәрмичә торып, аннан тавышын акрынайтып, йөземә иелеп әйтте: — Иртәгә мин сезне җидедән сигезгә кадәр шул остановкада көтәрмен!

Мин, бер сүз кайтарып әйтмичә, кызу-кызу китеп бардым. Кайтышлый юлда кечкенә бер ялган корган булдым. Бу минем беренче тапкыр ялганларга мәҗбүр булуым иде, ләкин дөреслек катыш ялган иде, шуңа күрә әнием: «Нигә болай бик иртә, кызым?» — дип каршы алгач, мин бер дә каушамыйча:

— Трамвай булмады. Көтә-көтә туңып беттем, ахыры түзә алмагач, бер иптәш кызыма кереп җылынып чыктым,— дидем.

Әнием: «Карасана, ничек начар булган. Нәҗип бик борчылгандыр инде»,— дип сөйләнә-сөйләнә, чәй урыны хәзерләргә керешә. Мин, артык аны-моны әйтеп тормыйча, тизрәк үз бүлмәмә ашыктым. Һаман калтырыйм-өшим, бар теләгәнем — җылы-йомшак урын!.. Кыз кешене беләсез инде, тынычланып, ни булганын уйлар өчен дә аңа җылы урын кирәк ич!

Нәҗип безгә икенче көнне генә эшкә китешли керде. Мин әле яңа гына урынымнан торган идем. Әнием ишек аша гына: «Кызым, Нәҗип килде»,— дигәч, ашыгып киенә башладым, чәчемне рәтләдем, тиз генә көзгегә карап алдым. Мин каушамый идем, юк, каушамый идем, тик йөрәгем еш-еш тибә һәм кирәгеннән артык кабаланам...

Рәтләнеп бетеп, ишек төбендә туктап бер тын алгач, мин залга чыктым. Нәҗип ялгыз гына утыра. Җитди, салкын күзләре белән каршы алды ул мине... Күрәм, егетемнең мыегы нык чуалган. Шулай да мин каушамадым, киресенчә, аның шундый салкын, чәнечкеле кыяфәтен күргәч, үзем дә ничектер усалланып киткән кебек булдым. Нәкъ менә һөҗүм көткән песи баласы кебек...

Бу, исәнлек тә сорап тормыйча, коры гына:

— Ни булды сиңа? — диде.

— Берни дә булмады,— дидем мин, аңа туп-туры карап.

— То есть ничек булмады? Ә вечерга килмичә калуыңны ничек аңларга?

— Син шулай дип сора, ник килмәдең диген... Трамвай булмады, менә шул. Кырык минут көттем, шундый суыкта...

— Странно! — диде ул, иңбашын җыерып.— Трамвай булмаса бит, попутный машиналар йөреп тора. Ни өчен...

Мин аңа әйтеп бетерергә бирмәдем. Кинәт ачуым кузгалып:

— Сөйләмә! — дидем.— Машина артыннан чабарга мине кем дип белдең? Бик илтәсең килгәч, кайтып алалар аны.

— Минем вакытым булмады.

— Ә минем ни гаебем бар? Мин бит син чакырганга күрә генә бармакчы идем. Караңгыда, суыкта, җәһәннәм астына... Ни булды, имеш? Ни булганын беләсең килгәч, кичә үк...

Кинәт бугазыма төер килеп тыгылды, иренемне тешләп, ярты сүземдә тукталып калдым. Ул күзләрен кыса төшеп, миңа озак кына карап торды, ләкин артык бер сүз дә әйтмәде, бары әдәп йөзеннән генә юаткан булып:

— Син нервничать итмә, тынычлан,— диде.— Мин киттем хәзергә, кич сөйләшербез.

Ул китте, ә мин бүлмәмә кердем дә мендәргә капландым. Юк инде, юк, булмаса булмый икән, Ходаем!.. Каян бу кадәр тәкәббер корылык, салкын әдәплелек, бәхәссез өстенлек аңарда? Каренин булыр бу, Каренин! Бәләкәй, өтек, кызганыч Каренин!.. Ичмасам, чынлап торып ачулана да белмәде бит!.. Битлек төсле җансыз чырае, салкын корычтай күзләре белән бәгыремне генә өшетеп китте. Ә мин көтмәдеммени аны?.. Кичә кайтып яткач, һәр кыштырдаган тавышка колак салып яттым бит. Сабырсызланып, елап, өметләнеп көттем мин аны! Менә килер дә йөрәгемдә купкан давылны басар, мине айнытыр, мине иске хәлемә кайтарыр дип ышанып көттем. Ә ул нишләде, нишләтеп, нинди хәлдә калдырып китте ул мине?

Соңыннан, эш узгач инде, мин кат-кат уйландым. Әгәр шул кичне ул килеп, күренеп кенә китсә дә, минем язмыш бу хәтле тиз, кинәт үзгәреп китмәгән булыр иде. Барысы да искечә калыр иде: туй да булыр иде, мин дә хәзер бәхетлеме, бәхетсезме, инженер Нәҗип хатыны булып йөрер идем... Моны сез тагын үкенү дип аңлый күрмәгез. Юк, алай түгел. Бу минем шул чакта саламга ябышып, котылып калырга теләвем генә иде. Әгәр шуннан Нәҗип килсә дә, мине юатса да, бөтенләй икенче кешегә әверелеп, минем белән бик җылы, якын булса да, ихтимал, барыбер коткарып кала алмаган булыр иде... Тәгаен әйтә алмыйм, ләкин мин аның килүен бик теләгән идем.

Хәрби егет минем күңелемнән бер генә минутка, хәтта

бер генә секундка да чыкмады. Авыр, саташулы төн үткәрдем, юньләп йоклый алмадым, ара-тирә йокыга талып киткән чагымда да ул онытылмады-югалмады, гүя гел баш очымда утырып торды... Бәхетгәрәй!.. Әллә нинди бер сихри көч бар кебек бу исемдә... Бәхетгәрәй! Әйтче, кем син? Ни өчен син миңа очрадың? Ни өчен миңа дәштең, үзеңә алып кердең, тезләнеп аякларымны җылыттың, онытылып күзләремә карадың?.. Кем җитәкләп чыгарды сине минем юлыма? Әллә, чынлап та, бәхетемме син минем, Бәхетгәрәй?

Юк, юк, саташу бу, хыял бу! Йолкып ыргытырга кирәк моның шикелле тиле хыялларны!.. Әле соң түгел, әле соң түгел!

Бөтен калган акылымны җыеп аңларга тырышам: ни булды миңа? Нинди давыл купты минем йөрәгемдә? Мәхәббәт булмаса — нәрсә? Гомеремдә беренче тапкыр мин мондый хәлне кичерәм. Минем әле чын сөюне татыганым юк, әмма бик, бик татыйсым килә. Ләкин шушылай ут шикелле кинәт дөрләп кабынамыни ул? Шушылай бөтен җаныңны-тәнеңне беткәнче биләп аламыни ул?.. Белмим, белмим, тик бернәрсәне ачык сизәм — Бәхетгәрәй менә монда, йөрәгем үзәгендә!

Башта мин аны яңадан күрү турында уйларга да курыктым. Мөмкинме соң! Минем хәлдә, Аллам сакласын!.. Очрашуны бер генә минутка күз алдыма китерсәм дә, эсселе-суыклы булып китә идем. Ул гынамы соң, менә болай оныта алмыйча газаплануым да инде миңа зур җинаять, әшәкелек булып тоела иде.

Ләкин аның «көтәрмен» дигән сүзе, гел чакырып торган тавыш шикелле, көне буе колагымнан китмәде. Кулымнан тотып тартучыга карышкандай, мин йөз генә тапкыр үземә: «Бармыйм!» — дип әйтмәгәнмендер.

Кич якынлаша, кич якынлашкан саен тынычлыгымны җуя барам, гүя менә язмышымның хәлиткеч минутлары җитеп килә.

Сәгать алтыда эштән кайттым. Аннан-моннан гына ашап алдым да бүлмәмә кереп бикләндем, нәкъ менә балалар төсле инде, әйтерсең бикле ишек мине тотып калачак!

Бервакыт сәгатемә карасам, җиде тулып, сигезенчегә киткән. Үземне белештермичә сикереп урынымнан тордым... Кинәт бер уй мине сискәндереп җибәрде: Ходаем, тышта бик суык бит, көтә-көтә өшеп бетәр ич ул! Җитмәсә, аягында күн итекләр генә...

Тиз генә өстемә киендем. Гаҗәпләнеп караган әниемә:

— Мин иптәш кызыма барам,— дидем.

— Нәҗип килер бит,— диде әни.

— Килсә — көтәр, көтмәсә — иртәгә керер. Ә миңа бармыйча ярамый,— дидем мин, әллә каян килгән бер кыюлык белән.

Әни, бичара:

— Ай, кызым, килешмәс бит, ярамас бит,— дип калды, ә мин ашыга-ашыга чыгып киттем... Һәм шушы китүдән инде мин кире иске хәлемә борылып кайтмадым... Юл киселде...

Зөһрә ханым тирән итеп бер сулады, кечкенә бәрхет ридикюленнән хуш исле ефәк кулъяулыгын чыгарып иреннәренә китерде һәм шул хәлдә уйга чумып калды. Мин сак кына аның хәрәкәтсез, озын кара керфекләренә, тонык ак йөзенә карадым: бернинди үкенү-газап кебек нәрсә сизелми иде бу йөздә, тик бик ерактагы вакыйгаларга читтән күзәтеп караган төсле тыныч уйчанлык кына чагыла иде.

— Сез гафу итегез,— диде Зөһрә ханым, торышын үзгәртмичә, салкын бер тынычлык белән.— Мин ул кичне үзем белән ниләр булганын сезгә сөйләп бирә алмыйм. Гомумән, беркемгә дә мин аны сөйли алмыйм. Тик шуны гына әйтә алам: Бәхетгәрәй, чиксез куанып, «Зөһрә, Зөһрә» дия-дия, мине каршы алды. Мин, юләр кызый, үземчә, эчемнән катгый карарга килеп, ягъни барам да: «Мине суыкта көтеп йөрмәгез»,— дип әйтәм дә шунда ук кире борылып китәм дип барган идем... Ләкин... кая инде ул! Әллә ничек менә, берьюлы биләде дә алды ул мине... Яман суык иде, урамда йөрергә мөмкин түгел иде, халык булган җиргә дә барырга ярамый иде, һәм ул мине үзенә алып китте.

Без бик озак утырдык... Чәй эчтек... Белмим, ничек, нәрсәдән башланып киткәндер, утыра торгач, мин аңа бөтен хәсрәтемне сөйләп бирдем. Бөтенләй билгесез, ят кешегә! Күрәсең, бик тулган инде, күрәсең, беркемгә сөйләргә көчем җитмәгәнне ни өчендер аңа сөйлисем килгән инде... Ә ул тыңлады мине... Сүземне бүлмичә, хәсрәтемне җиңеләйтергә ашыкмыйча, ничектер үзалдына тирән уйга калып, тыңлады ул мине. Аннары сак кына кулымнан алып, бераз сыйпап торды, тик шуннан соң гына бик гади итеп, бик якын итеп ул миннән:

— Зөһрә, сез миңа ышана аласызмы? — дип сорады.

Мин телем белән җавап бирә алмадым, мин хәтта,

зәгыйфь ток бәргәндәй, эчемнән калтыранып куйдым, әмма... ышанмыйча булдыра алмавымны, алай гына да түгел, ышанасы килүемне, шуны теләвемне ничектер менә бөтен барлыгым белән тоеп тора идем. Томалана башлаган аңым белән тик бернәрсәне генә аңларга өлгердем: ул инде минем йөрәгемә хуҗа!

Йә, шуннан артыгын ничек әйтим? Ләкин белегез, ул кичне түккән яшемне мин бүтән беркайчан да түкмәдем. Барысы да — мәхәббәтем дә, сафлыгым да, көчсезлегем дә — барысы да кайнар яшьләр булып чыкты йөрәгемнән! Бер генә кыз баланың да минем хәлгә юлыгуын теләмәс идем мин, юк, теләмәс идем...

Зөһрә ханым тагын тукталып калды һәм таш сын шикелле һич кыймылдамыйча катып торды... Яңадан сүзен башлаганда аның тавышы, бугазына нидер утыргандай, тәмам карлыккан иде.

— Ә дүрт көннән соң ул фронтка китте. Шулкадәр тиз китеп барасын алдан әйткән идеме ул миңа, юкмы — хәтерләмим. Хәер, аның хәзер һичбер әһәмияте юк иде. Дүрт көннән китәме, дүрт атнаданмы — барыбер китәргә тиеш. Бу кадәресен мин ачык белә идем... Мин аны озатырга вокзалга төштем. Ул бик борчулы иде, һаман нидер көтеп минем күземә карый, нидер әйтеп юатасы килә кебек, ләкин җөрьәт итми, курка кебек. Ә миндә үпкә дә юк, ачу да юк, үземне җәлләтәсем дә, муенына ташланасым да килми. Әллә ничек шунда берни аңламыйм да, тоймыйм да кебек... Күрәсең, өермәдәй исеп узган баш җитмәс хәлләрдән соң, мин беркадәр әйле-шәйлерәк булып калган идем.

Поезд кузгалыр алдыннан мин аңардан бары бер сүз сорадым:

— Кайтырсыңмы?

— Кайтырмын,— диде ул, миңа бик туры карап; саф, хәйләсез күзләре дә аның: «Ышан!» — дип әйтә иде төсле. Аннан көлемсерәп өстәде: — Үтермәсәләр әгәр...

— Әйтмә, әйтмә шул сүзне! — дидем мин, кинәт өзгәләнеп.

Ул көлеп юатырга ашыкты:

— Йә, йә, Зөһрә, борчылма син, үлемнең хәзер миңа кулы күтәрелмәскә тиеш.

Поезд кузгалганда, мин аның күкрәгенә капландым, күпмедер вакыт онытылып тордым. Шул чакта аның нәкъ колагым эченә бик җылы пышылдап кына:

— Көт, яме! — дип әйткән сүзләрен ишеттем.

Ул китте, ә мин... мин аның беркем белмәгән, берниндиди закон белән беркетелмәгән хатыны булып калдым. Хәер, нигә мин болай дим? Болай дип әйтергә минем ни хакым бар? Әйтерсең без, алдан сөйләшеп, бергә торырга килешеп кушылган кешеләрбез. Әмма... мин аныкы хәзер... Мин аны яраттым — кояш шаһит! Ә ул?.. Ә ул: «Көт, яме!» — диде минем йөрәгемә. Һәм мин аны көтәчәкмен, дөньяның асты өскә килсә дә, көтәчәкмен!

Ләкин сез күз алдыгызга китерә аласызмы минем хәлемне? Авыр дию генә аз аны. Ул кадәресен әйтеп торасы да юк... Ничек кенә аңлатыйм?.. Әйтик, бер җирдә ай тотыла, икенче җирдә торучылар айның тотылганын күрмиләр, ул алар өчен һаман яктыра әле — минем хәлем дә нәкъ шуның төсле иде. Мин — тотылган ай, минем өчен бөтенесе җимерелде, бөтенесе бетте. Ә бүтәннәр өчен — барысы да искечә әле, барысы да үз урынында: мин кияүгә чыгасы кыз, менә тиздән, Алла бирсә, вәгъдәләшкән көн килеп җитәр, туй булыр, без, бәхетле яшьләр, ике йортның да фатихасын алып, матур гына тора башларбыз... Бүтәннәр өчен әнә шулай иде, шул өметләр, шул хыяллар белән яшиләр, шуңа әзерләнәләр иде. Хәтта Нәҗип тә берни сизмичә калды. Ләкин алар өчен дә ай тотылачак, дөнья караңгыланачак, алар да, бүген булмаса, иртәгә, минем белән ни булганын беләчәкләр. Моны үзем, үз авызым белән аларга әйтеп бирергә тиешмен... Нинди коточкыч авыр, газаплы сынау булачак бу минем өчен! Хәер, өлешеңә чыккан көмешең, ул хакта сөйләп торуның кирәге дә юктыр дип уйлыйм. Тик сузарга ярамый, сузу хәтәр, бик тә хәтәр!

Мин әле булган эшкә үкенми идем, дөресрәге, үкенү газабына дучар ителмәгән идем. Бар хәсрәтем — ничек итеп үз хәлемне аңлатып бирү турында гына иде... Әлбәттә, мин бөтен хакыйкатьне әйтеп бирергә җыенмый идем, аңа көчем җитмәсен белә идем... Әмма вәгъдәмне кире алыр өчен, туйны булдырмас өчен миңа бик көчле, ышандырырлык сәбәп табарга кирәк... Нинди сәбәп? Ничек итеп? Берәр хәйлә корыргамы, авыруга сабышыргамы, бүтәнне яратам дияргәме? Тагын кемгә әйтергә —әниемәме, әллә туп-туры Нәҗипнең үзенәме? Кем мине тизрәк аңлар, кем?..

Яшьлек — тилелек шул! Мин көн-төн баш ватам, уфтанам — ут йотам, ә кешеләр йөземнән эчемдәгеләрне укый башлаганнар инде. Гаҗәпмени? Ашавым — ашау түгел, йокым — йокы түгел, өрәк шикелле йөрим, берәүгә

дә күтәрелеп карый алмыйм, ә Нәҗиптән, төрле сылтау табып, тәмам кача башладым. Үзеннән-үзе бөтенесе ачылып бара.

Бер кичне әнием, ниндидер йомыш тапкан булып, минем бүлмәмә керде. Аны-моны караштыргач, ул миңа күз төшереп алды да гүя болай гына сорап куйды:

— Кызым, әллә ничек төсең качкан, авырмыйсыңдыр бит?

— Юк шикелле, әни,— дидем мин.

Әнием миңа сынабрак карады.

— Алайса нидән икән бу?.. Соңгы вакытта ашавыңның да юне юк. Эчем поша минем... Әллә берәр хәсрәтең бармы? Әйт, яшермә.

Бу соравы белән әнием минем йөрәгемә туп-туры карагандай итте, мин хәтта эчемнән тетрәнеп куйдым. Каушавымнан бары:

— Белмим,— дип кенә әйтә алдым.

Инде әнием миннән күзен бер дә алмый иде.

— Ай-һай, кызым, нидер яшерәсең син миннән. Белмим, имеш! Сүзмени бу... Ә кем белә соң?

Мин дәшмәдем, ләкин шул минутта күңелемә кинәт, әллә барысын да әйтеп биримме, дигән уй килде. Бу бит мин көткән минут, хәзер әйтә алмасам, кайчан әйтермен?

Ул арада әнием, авыр сулап, тагын үзе сүз башлады:

— Аңламыйм мин сине, аңламыйм! Тиздән туегыз булырга тора. Берәү булса шатлыгыннан дөньяга сыймыйча йөрер иде. Ә син, хыялый кешедәй, тәмам сүнеп, күләгә төсле йөрисең. Бигрәк тә соңгы көннәрдә... Йә, килешәме бу? Нәҗиптән яхшы түгел ләбаса. Кешенең күңеленә әллә ни килүе бар...

— Килсә килер инде,— дип куйдым мин, нидер уйлаган хәлдә, үзем дә сизмәстән.

— Тиле,— диде әнием, ачуланып.— Сөйләшә дә белмисең. Булачак иреңә шулай...

Шушы сүзне ишетү миңа җитә калды, әйтерсең җан җиремә тиде — үземне белештермичә кинәт кабынып:

— Минем ирем булмас ул! — дидем.

Әнием шаккатып ике кулын берьюлы миңа селтәде.

— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!.. Ни сөйлисең?

Ә мин артык тыела алмыйча, тизрәк бөтенесен әйтеп бетерергә ашыгып, сөйләп киттем:

— Әнием, бел, мин Нәҗипкә чыкмыйм, чыгарга теләмим... Ярый әле үзең сүз башладың, ничек әйтергә белмичә йөри идем... мин газапланып беттем, киптем, сар-

гайдым, көн яктысын күрмәс булдым... Мин башта ук аңа чыгарга риза түгел идем, мин аны яратмый идем. Сезне тыңлап, сезнең өчен генә мин вәгъдә бирергә мәҗбүр булдым. Яратып китмәмме дип өметләндем... Ләкин юк, булмый икән, булмый икән, ярата алмыйм икән... Менә нидән минем авыруым, менә нидә минем хәсрәтем!

Күрәсең, мин бик кычкырып сөйли идем,— әнием берничә тапкыр мине туктатырга омтылды:

— Чү, чү, акрын, акылдан язасыңмы әллә?!

Ләкин мин тыела алмый идем инде, шулай да аңа буйсынып, ахрысы, тавышымны акрынайта төштем:

— Әле соң түгел, әле эш узмаган... Туй булмаска тиеш!.. Мин вәгъдәмне кире алам. Мин гомерем буена бәхетсез булырга теләмим. Юк, теләмим! Көчләмәгез мине, көчләмәгез!

Әнием, бичара, кәгазь кебек агарды, хәлсезләнеп урындыкка утырды. Бик озак телгә килә алмыйча торды. Аннары сүнгән тавыш белән:

— Үтердең син мине, кызым, үтердең! — диде.

Мин, аның аягына егылудан чак тыелып:

— Әни, бәгърем, нишлим соң? — дидем.

Әнием гүя мине ишетмәде дә; урындыгының читенә тотынып утырган килеш, башын салындырып бераз дәшми торды да үзалдына сөйләнгәндәй:

— Юк, башыма сыймый, аңламыйм, акылым җитми,— диде.— Нәрсә соң бу? Ничек болай була соң бу? Вәгъдә бирүеңә тиздән бер ел... Чыгар көнең килеп җитте... Инде мә, рәхим ит! Барысын аудар да ташла... Ни карадың соң син моңарчы? Ни уйлап йөрдең? Юк, Зөһрә, аңлый алмыйм мин моны. Синең белән нидер булган, нидер яшерәсең син миннән... Әйтеп бетер!

Мин артык түзә алмадым:

— Әни, бәгырькәем, зинһар, сорый күрмә! — дидем дә, өстәлгә капланып, бөтен гәүдәм белән калтыранып үксеп-үксеп еларга тотындым. Минем белән истерика булды. Әни тиз генә торып, миңа көчләп дигәндәй, бер йотым су эчерде, аннары башымны күкрәгенә кысып: «Җитәр, тукта, җитәр, тукта!» — дия-дия, мине ничек тә тынычландырырга тырышты... Ярый әле, әтием өйдә юк иде.

Акрынлап мин басылдым, шулай да үксеп сулкылдавым тиз генә бетмәде. Бу минем иң соңгы елавым булды. Шуннан соң инде бүтән бер тамчы яшь тә миннән чыкмады.

Болай истерикага җитеп елавым әниемне куркытса да, аның күңелен бер дә йомшартмады шикелле. Ул уйчан, хәсрәтле, җитди-салкын булып калды. Мин бераз тынычлангач, ул миңа болай диде:

— Бел, Зөһрә, бу эшеңнең иң зур җәзасы минем башыма төшәчәк. Бөтен хурлыгы миңа булачак... Онытма шуны...

Аннан бераз көтеп, сорап куйды:

— Бәлкем, әле кире уйларсың?

Мин акрын гына башымны селектем.

— Алайса,— диде әни,— үзең әтиеңә аңлатырсың. Миннән булмый...

Шундый бер мескенлек белән әйтте ул моны, кинәт ана йөрәгенең ачы газабы бөтен тирәнлеге белән миңа ачылган кебек булды. Бәгърем телгәләнде, әмма телем тибрәнә алмады...

Шуның белән сүз бетте, әнием үз бүлмәсенә китеп ятты. Шул кичтән аның башы сызлый башлады.

Ә икенче көнне иртән әти мине үз янына чакырып алды. Ул үзенең челтәр төпле борынгы креслосында утырып тора иде. Сүзне тыныч башлады:

— Син кичә әниеңә нәрсә дип әйттең?

Әти — кирәген генә сөйләргә гадәтләнгән кеше, шуңа күрә аның туры соравына туры җавап бирергә кирәк иде. Гәрчә аңардан бик курыксам да, үзе кебек тыныч булырга тырышып, мин турысын гына әйтеп бирдем:

— Нәҗипкә чыкмыйм, дип.

— Чыкмыйсың? Нәҗипкәме?

— Әйе.

— Сәбәп?

Ни өчендер каушабрак:

— Мин... яратмыйм аны,— дидем.

— Чепу-ха! — диде әти, зәһәр елмаеп, һәм урындыгын шыгырдатып куйды.— Яратмыйм! Кара син аны! Кисейная барышня! Ничего, хатыны булгач, яратырсың.

— Ә мин аның хатыны булмыйм.

Әти миңа күзенең агы белән карады, бераз иреннәрен кыймылдаткалап торды, гүя сүз табу куәтен югалтып җибәрде.

— Так, так,— дип торды да көч белән, һәр сүзенә басым ясап әйтте: — Син, ахмак кызый, нәрсә эшләгәнеңне беләсеңме? Аңлыйсыңмы син: бу юләрлегеңнең ахыры ни белән бетәчәк, ә?.. Бер ел буена вәгъдә куешып йөреп, чыгар көн килеп җиткәч кенә баш тарту, беләсең-

ме, чем пахнет? Берәү дә бит синең «яратмыйм» диюеңне чынга алмаячак. Һәркем, бу кызый намусын югалткандыр, дип уйлаячак. Сизәсеңме син моның хурлыгын?.. Юк, кызгынасы, без сиңа башбаштакланырга юл куймабыз!

Әтиемнең бу кадәр рәхимсез сөйләшүе минем ачуымны китерә башлады.

— Көчләп бирер идегезмени? — дидем мин, кыюланып.

— Көчләп бирергә дә хакыбыз бар,— диде әти, кресло тоткасына учы белән каты сугып.— Вәгъдә биргәнчегә кадәр син ирекле идең... Шул чакта нечкә хисләрең турында уйлар идең. Ә вәгъдә биргәч — точка! Вәгъдә —иман, яратып бетермәсәң дә чыгарга тиешсең! Әгәр инде ахмаклык эшләргә чамалыйсың икән, без үзебезнең ата-ана хокукыбыз белән файдаланырга мәҗбүр булачакбыз. Без синең абруең өчен дә, киләчәк тормышың өчен дә җаваплы кешеләр. Без сиңа үзеңне дә, безне дә хурлыкка төшерергә ирек бирмәбез.

Әти үзен мең мәртәбә хаклы саный — мин моны яхшы аңлыйм. Ул үз сүзендә искиткеч нык тора торган кеше — бу да миңа бик яхшы билгеле. Шулай булгач, ул мине аңлаячакмыни? Арада упкын, төпсез упкын... Шул упкын аша дәшкәндәй, мин, ике кулымны күкрәгемә куеп:

— Әтием, зинһар, мине тыңла әле! — дим.— Нәҗипкә вәгъдәмне ихтыярсыздан бирдем. Сез кыстаганга күрә бирдем. Башта ук яратмый идем мин аны... Сүз биргәч, яратып китмәмме дип уйладым... Ләкин юк, ярата алмыйм икән, аз гына да, ичмасам, ярата алмыйм икән. Йә, шулай булгач, ничек итеп мин аңа чыга алыйм?

— Хыял, романтика, балалык, әллә нәрсә бу! — диде әти, тәмам кызып.— Мәхәббәткә бозык караш! Ахмак караш!.. Нәҗип кебек кешене яратмыйча мөмкин түгел... Бүтәннәр аның чабуына ябышырлар иде әле. Нарком булырлык кеше ул! Хәер, нәрсә сөйләп торырга? Эш беткән, син аныкы булырга тиеш, вәссәлам!

— Юк, әти, аңла, булмый ул,— дидем мин, үземне нишләтергә белмичә.— Үтерсәгез дә мин аңа чыга алмыйм.

Әти, беренче тапкыр күргәндәй, әллә нинди сәер, ят бер караш белән миңа төбәлде. Шулай кадалып, күпмедер дәшми торды да, чыраен сытып, муенын суза төшеп, акрын гына сорады:

— Әйт дөресен, кем белән буталдың?

Мин агарынып, яшен суккандай, бер мәлгә катып калдым, аннан ике кулым белән йөземне капладым да атылып чыгып киттем.

Нинди хурлык, нинди хурлык! «Кем белән буталдың?» Әгәр бит аның шиге нахак булса, мин үземне нишләтмәс идем. Ләкин... кайдан бу шик? Ни өчен алар минем ел буена сузылып килгән газапларымны күрмәделәр дә «буталуымны» бик тиз сизеп алдылар? Яратмыйм, чыкмыйм, дигәнгә күрәме?.. Соң бит бу минем үз эшем, йөрәгем эше ләбаса! «Буталу» — алар таккан кешене яратмау, ә бүтән берәүне яратып китү нәтиҗәсе ич. Нигә алар шуны аңламыйлар, нигә көчлиләр, нигә?.. Хәер, бу «нигә»ләрнең җавабын эзләп торудан хәзер файда юк...

Әти белән сөйләшкәннән соң, мин ничектер усалланып киттем... Бәгърем катты. Каяндыр тәвәккәллек килде, һәм мин шул ук көнне барысын да Нәҗипкә әйтеп, эшне берьюлы бетерергә булдым. Көндез аңа шалтыратып, кайчан кайтасын белдем һәм кайтышлый ук безгә керергә куштым. Әлбәттә, мин Нәҗипнең мине дөрес аңлавына ышанмый идем, ләкин бу кадәресе минем өчен барыбер иде инде. Тизрәк белсен дә, тизрәк... бетсен!

Хәзер аны өйгә кертергә ярамый иде — килер вакыты якынлашкач, мин үзем киенеп каршы чыктым. Озак та үтми ул килеп җитте. Мин, әйдә, бераз һавада йөрик, дип, аны урам буйлап алып киттем. Нәҗип болай каршы алуга гаҗәпләнә калды һәм туп-туры:

— Нәрсә булды, әллә өйдә берәр күңелсезлек бармы? — дип сорады.

— Бар,— дидем мин.

— Нәрсә, әллә Заһидә апа авырыймы?

Мин бераз дәшми бардым. Нәрсәдән башлап, ничек дип әйтергә? Ул бит инде миңа шактый якын булып әверелгән кеше... булачак ирем... Әнә ул ничек пошынып әнием турында сорады. Ә мин хәзер аңа коточкыч нәрсә әйтергә тиешмен. Кинәт йөрәгем авыртып кысылды, укенүдерме, икеләнүдерме — белмим нидер — бәгъремне тырнап куйды. Бер мәлгә үземне аның алдында искиткеч гаепле итеп хис иттем... Белсәгез, никадәр авыр иде миңа бу минутта!

Ләкин... әйтергә кирәк, баскан урынымда җир йотса да, әйтергә кирәк. Ничек тә гадирәк, тынычрак булырга тырышып, аңа:

— Бездә җитдирәк хәлләр булды әле,— дидем.

— Тагын нәрсә?

— Безнең туй булмаска тора бит, Нәҗип...
— Ничек алай, кем аркасында?
Мин тирән итеп бер тын алдым.
— Минем аркада.
— Синең аркада? Аңламыйм, хоть убей!
— Мин сиңа чыкмаска булдым, Нәҗип...
Нәҗип, баганага килеп бәрелгәндәй, еш-еш күзләрен йомгалап алды.
— То есть как? Миңа,— ул кулы белән күкрәгенә төртеп күрсәтте,— миңа чыкмаска?.. Шутишь что ли?
— Юк, шаяртмыйм, Нәҗип, дөресен әйтәм.
— Что за чертовщина! — диде ул, тукталып.— Как понять? Ни өчен?
Мин, аның кешелек намусы уянмасмы дип, мөмкин кадәр дусларча йомшак итеп сөйләп бирергә теләдем:
— Нәҗип, дөрес аңларга тырыш мине... Һәрбер өйләнүнең нигезендә чын мәхәббәт ятарга тиеш — шулай түгелме? Ә миндә, үзең дә сизгәнсеңдер, сиңа карата беркайчан да чын, тирән ярату булмады. Мин озак газапландым, бик күп уйландым һәм менә чынлап ярата алмавыма тәмам ышангач... сиңа чыгудан тыелып торырга булдым.
— Ә вәгъдә?
— Мәсьәлә вәгъдәдәмени! Сүз бит безнең киләчәк тормышыбыз турында бара. Ә яратусыз...
Ул ярсып минем сүземне бүлде:
— Вәгъдә бозу — подлость. Бу — во-первых. Во-вторых, яратмагач, вәгъдә бирмиләр аны...
— Әйе, мин гаепле,— дидем мин, башымны иеп, акрын гына.— Ләкин мин ышанган идем... яратып китмәмме дип ышанган идем. Нишлим?.. Минем ихтыярымдамыни ул?
Нәҗип сабырсызланып чыраен сытты, тагын усал сүз әйтә башлады, шуннан мин, белсен барысын да тизрәк дигәндәй, ашыгып аны бүлдем:
— Нәҗип, аңла, талашудан файда юк хәзер, мин инде бүтәнне яратам...
Нәҗип кинәт сүзсез калды. Йөзе бердән таштай катып киткән кебек булды, тирән итеп еш-еш сулый башлады. Күпмедер шулай телгә килә алмыйча барганнан соң, бу үзалдына әйткәндәй:
— Понятно! — дип куйды һәм шунда ук үзенең тәкәббер-салкын кыяфәтенә кереп, прокурор шикелле, сорашырга тотынды: — Күптәнме сез бүтәнне яратасыз?

Мин, юләр, аны-моны абайламыйча, юашланып кына җавап биреп бардым:

— Юк, бик күптән түгел.

— Кем ул?

— Бер хәрби кеше.

— Так, так... Кайда таныштыгыз?

— Анысы сиңа нигә кирәк инде...

— Гафу, бу минуттан мин сезнең өчен «син» түгел,— диде бу, салкын нәфрәт белән.

Кинәт телемне тешләгәндәй булдым — шулкадәр уңайсыз булып китте миңа... Гарьләнүемнән нишләргә белмичә шунда ук аны ташлап китәсем килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, нидер тотып калды.

— Кайда ул кешегез? — диде бу тагын.

Мин дәшмәдем.

— Сездән сорыйм?

Башымны читкә борып, иренемне тешләгән килеш, сүзсез бара бирдем. Шуннан Нәҗип минем алдыма чыгып басты да туп-туры йөземә карап:

— Сез просто...— диде, ягъни хатын-кыз өчен иң авыр, иң кабахәт сүзне әйтте. Битемә әйтерсең пычрак идән чүпрәге белән китереп сукты... Үзе кисәк кенә борылып китеп барды, ә мин, йөрәгемне тотып, баскан урынымда катып калдым...

Зөһрә ханым аз гына тыңлагандай итте, ләкин шунда ук, торышын һич үзгәртмичә — һаман шулай давылга каршы торган кеше төсле, башын артка каерыбрак, күзләрен яртылаш йомып — карлыга төшкән тавыш белән яңадан башлап китте:

— Тагын ни сөйлим?.. Фаҗиганең ахыры шул: өйдә һич чыдап булмаслык атмосфера туды. Әнинең кисәтүе дөрескә чыкты: бөтен авырлык, бөтен газап аның өстенә төште. Әти аны рәхимсез рәвештә талады һәм барлык гаепне аның өстенә аударды. Янәсе, ул мине тәрбияли дә белмәгән, карый да белмәгән, саклый да белмәгән.

Әнием чынлап урынга ятты. Бер ай авырды ул. Мин аны карадым, ләкин ул, телдән язгандай, бер генә тапкыр да миңа «кызым» дип дәшмәде. Тик терелә башлагач кына аның күңеле эреде, яңадан ана мәхәббәте уянды, күзләрен тутырып-тутырып миңа карый торган булды. Бу эчкә баткан моңсу күзләрдә мин кичерү генә түгел, элеккегә караганда да минем өчен тирәнрәк борчылу, кызгану һәм йөрәккә төшәрлек сүзсез ярату күрә

идем... Күкрәгенә ятып елыйсым килгән чакларым аз булмады, ләкин мин елаудан узган идем инде.

Әмма эти... эти мине бик озак кичерә алмады. Елга якын диярлек ул минем белән сөйләшмәде. Бер өй эчендә торып без очрашмаска тырыша идек. Бергә утырып ашау-эчү бетте; ул залга килеп керсә, мин чыгып китәм, мин керсәм, ул чыгып китә торган иде... Башта ул мине, бәлкем, өйдән дә куган булыр иде, ләкин әнинең авыруы аркасында гына тыелып калды шикелле.

Ләкин шулай да вакыт дигән нәрсә үзенекен итә. Аның өчен дә бит мин бердәнбер кыз. Нәҗип кебек шәп кияүне югалту аңа нихәтле авыр булмасын, ә ата мәхәббәте барыбер өстенлек алырга тиеш иде. Кыскасы, акрынлап кына ул да миңа йомшарды. Йөзеннән ачулы караңгы чырай китте, исемем белән дәшә башлады. Әмма ул минем ни эшем, ни тормышым белән кызыксынмас булды. Гүя аның кыяфәте миңа: «Инде үз җаеңны үзең кара»,— дип әйтеп тора иде.

Тагын ни сөйлим?.. Әйе, тагын шул: әнием авыргач, миндә беренче мәртәбә ачы үкенү хисе кузгалды. «Нишләдем мин, нишләдем мин!» — дия идем, чәчләремне йолкырдай булып... Ни хакым бар иде минем әниемне мондый хәсрәт утына салырга, әтиемне яртылаш картайтырга?.. Бөтенесен бәхетсез иттем, үземнең сафлыгымны югалттым, ә шулар бәрабәренә ни таптым, ни алдым?.. Шундый уйлар белән бәгърем телгәләнгән чакта мин аңа эчемнән: «Нинди зур явызлык эшләп киттең син миңа!» — ди торган идем, ләкин, ышанасызмы, һичбер үпкәсез, ачусыз. Әйе, мин аңа ачулана алмый идем. Бары аны гына гаепләргә хакым юклыктан түгел бу, ә башка, тирәнрәк сәбәптән иде... Вакыт узды, үкенү басылды, газап онытылды, ә Бәхетгәрәй йөрәгем түрендә утырып калды. Бу — мәхәббәт иде.

Айлар узды, еллар узды, ә мин аны һаман көттем. Мәҗбүр булганга күрә генә түгел, юк, кешеләр бар иде, теләгәндә иргә дә чыгып була иде, ләкин мин Бәхетгәрәемне көттем.

Бары өч-дүрт көн генә бергә булуга карамастан, ул ничектер миңа үзенең туып үскән җирләрен дә сөйләп өлгергән иде. Дим буеннан мин, дигән иде, атаем — умартачы, дигән иде... Миннән ул: «Бал яуганны күргәнең бармы?» — дип сорый иде. Мин «юк» дигәч, ул дәртләнеп сөйләп китә иде: «Чынлап та бал ява, иртәнге чык белән юкә, имән яфракларын өзеп ялап йөри идек. Тукта, менә

безнекеләргә кайткач, мин сине баллы яфраклар белән сыйлармын әле...» — ди иде... Шушы авыр, газаплы көннәрдә аның мине юатырга теләп сөйләгән сүзләреннән, үзе генә түгел, туып үскән җире дә якты булып, ягымлы булып, чәчәкле булып күңелемә сеңеп калды... Мин, кояш чыкканын көткән шикелле, сугыш беткәнен көттем, мин үземне урамга баллы яфрак җыярга алып барачак абыемны көткән шикелле аның кайтуын көттем.

Әгәр шул чакта бу хыялларымны берәрсенә сөйләсәм, ул кычкырып көлгән генә булыр иде. Узып барышлый гына очраган, аннары каядыр ут эченә китеп югалган солдат кешене көтеп утыру, әлбәттә, «чистый юләрлек» иде. Ай күрде, кояш алды! Юк ул. Китте дә эзе суынды. Әмма ул минем йөрәгемнән китмәгән иде. Әмма аның колагым эченә җылы пышылдап: «Көт, яме!» — дигән сүзләрен мин онытa алмый идем, юк, оныта алмый идем.

Бөтен сугыш буенча ниләр уйлап, ниләр кичергәнемне, нинди хәлләр күрергә туры килгәнне сөйләп тормыйм инде. Ул үзе озын бер хикәя. Ләкин бөтен авырлыклардан иң авыры минем өчен билгесезлек иде. Беләсезме, Бәхетгәрәй белән хат язышырга мөмкин түгел иде бит. Ул үзе шулай аңлатып китте: «Мине хат язышып булмый торган җиргә һәм эшкә җибәрәләр»,— диде.

Ләкин һич көтелмәгән гаҗәеп бер хәл булды. Аның китүенә ел чамасы вакыт узгач, мине көннәрдән бер көнне военкоматка чакырып алдылар. Бардым. Әлбәттә, үземә чират җитте, ахрысы, дип бардым, тик ни өчен повестка юк — шуңа гына беркадәр аптырадым.

Баргач, миңа бер кабинетка керергә куштылар. Кердем. Түрдә, зур язу өстәле артында майор погонлы берәү утыра. Тап-такыр башлы, күзлектән — хәрби кешегә дә охшамаган. Күзлеге өстеннән бик дикъкать белән карап, каршы алды бу мине, кулы белән генә урын күрсәтте. Мин утыргач, бераз дәшми торып, ахырда сорады:

— Сез Зөһрә Мусина буласызмы?

— Әйе.

— Яныгызда берәр документыгыз бармы?

Мин паспортымны чыгарып суздым. Алып карады, аннан кире бирде.

— Беләсезме, мин сезне ни өчен чакырттым?

— Юк, белмим.

Майор тагын сүзсез генә миңа бераз карап торды. Мин бик киеренке хәлдә идем, нигә ул миңа бу кадәр сынап карый, дип борчыла идем. Әмма шулай да аның

якты соры күзләрендә ниндидер бер җылылык барлыгын сизмичә калмадым.

— Мин сезгә,— диде ул, тыныч кына,— берәүнең сәламен тапшырырга тиешмен.

Минем йөрәгем тибүдән туктаган кебек булды. Тыным кысылып, көчкә генә:

— Кемнән? — дидем.

— Бәхетгәрәй Сәфәровтан.

Мин өнсез калдым. Мин... Мин әллә нишләдем. Зиһенем бетте дә куйды, ишеткәнемне көчәнеп тә аңламый торам — нәрсә диде соң ул? Секундның күпмедер өлешендә булды бу акылымны җуеп тору, аннары исемә килеп, бөтен гәүдәм белән майорга таба омтылдым.

— Бәхетгәрәйдән? Бәхетгәрәй Сәфәровтан?

— Әйе, әйе. Бәхетгәрәй Сәфәровтан,— диде майор, башын кагып.

— Ничек, кайдан, кем аркылы? Әллә үзегез күрдегезме?

Майор йомшак кына елмайды.

— Юк, кызганычка каршы, юк. Миңа бары, сезне чакырып, аның сәламен тапшырырга куштылар.

— Кемнәр?

— Кемнәрме? Анысы инде, хөрмәтлем, сезнең өчен артык әһәмиятле түгелдер дип беләм.

— Кайда соң ул... Бәхетгәрәй?

Майор чәнчә бармагы белән баш түбәсен тырнап алды.

— Гафу итегез, иптәш Сәфәровның кайда икәнен мин белмим. Ләкин ул исән-сау һәм сезгә кайнар сәламен җибәрә. Менә шул.

Ниһаять, мин аңладым: артыгын белергә мөмкин түгел һәм сорашып тору ярамый да. Майорның сүзсез, әмма игътибарлы сабыр кыяфәте үзе үк миңа шуны сиздереп тора иде кебек... Ләкин... ләкин болай гына әллә ничек бит, бу гына бик аз бит, нишлим инде, Ходаем?! Торып китә алмыйм ич инде мин шушы көе генә!

Ахырда бердәнбер әйтер теләгем күңелемә килде:

— Ә аның үзенә миннән сәлам тапшырып буламы?

— Сездәнме?.. Шактый читен эш бу, шулай да булыр дип уйлыйм. Булыр.

— Алайса, зинһар өчен, сез аңа минем сәламемне җиткерегез! Минем ни... ни...

— Сез тыныч булыгыз, тыныч!

Мин артык бер сүз дә әйтә алмадым, күзләремә яшьләрем килеп тыгылды да, ике кулым белән йөземне

каплап, ишеккә ташландым... рәхмәт кенә дә әйтә алмадым.

...Атналар буе айный алмый йөрдем мин бу хәбәрдән. Әллә нишләтте ул мине, гүя биеккә, бик биеккә күтәрелгән кошка әйләндерде. Берьюлы дөньям киңәеп, күз алларым яктырып китте. Моңарчы мин өметләремне кайнар теләгем белән генә саклап килгәнмен икән, хыял белән генә яшәгәнмен икән, ә хәзер... хәзер исә бу реаль чынлыкка әверелде. Бәхетгәрәй минем өчен бар ул, минеке ул, һич шикләнмичә теләсә кемгә мин аны «ирем» дип әйтә алам хәзер!

...Инде мин военкоматтагы әнә шул аз сүзле, сөйкемле майор абыйның тагын чакырып алуын гына көтеп йөри башладым. Шушы көтү мине яшәтә дә, эшләтә дә, теләсә нинди авырлыкка түзәргә дә куша иде. Мин, әлбәттә, берәү әйтмәсә дә, үзем чамалап, Бәхетгәрәйнең бик еракта, илебездән читтә булуын, гаять авыр, җаваплы эш алып баруын аңлый идем. Миңа хәбәр җибәрүнең дә никадәр катлаулы эш булуын, әллә нинди борылмалы юллар белән генә килеп җитүен төшенә идем. Шуңа күрә үземне сабырсызланудан, борчылудан ничек тә тыярга тырыша идем. Ышанычым бик көчле иде, ерак йолдыздан килгән нур шикелле тагын килер әле аның сәламе, дип, үземне гел юата тора идем.

Дөрестән дә, күп айлар үткәч, майор абый мине чакырып, Бәхетгәрәйнең икенче сәламен дә тапшырды. Әлбәттә, беренче чакырудагы шикелле артык бер сүз дә әйтмәде, хәер, мин артыгын сорашып та тормадым — Бәхетгәрәй исән, Бәхетгәрәй мине онытмый — миңа шул җиткән!

Ләкин шулай да, алдашасым килми, вакыт-вакыт мин тынычлыгымны җуя идем... Коточкыч сугыш бара бит! Бәхетгәрәй белән берәр хәл булмасмы, бу дәһшәтле, авыр көрәштән исән-имин генә котылырмы дигән шик-борчылу кинәт күңелемне яулап ала иде. Күңелгә килгән — алга килә, диләр. Шуны уйласам, кояш сүнгәндәй, бөтен дөньям караңгыланып китә, үземне кая куярга белмичә өзгәләнә башлый идем.

Майор абый тагын бер чакырып алгач, мин әнә шул тилереп борчылуымны, ягъни Бәхетгәрәем исән-сау калырмы дигән газаплы шигемне истә тотып, аңардан сорадым:

— Ул кайтырмы?

Ләкин майор моны икенче төрлерәк аңлады булса кирәк, бик мәгънәле елмаеп, күзлеген елтыратып:

— Конечно, кайтачак! — диде.— Һич кенә дә шикләнмәгез, сезнең яныгызга кайтмыйча каламы соң ул!

«Рәхмәт, мең мәртәбә рәхмәт сезгә! — дидем мин эчемнән.— Бик дөрес әйтәсез, абый җаным: миңа, минем яныма кайтмый кала аламы соң ул?»

Сүзнең көче искиткеч зур икән. Майор әнә шулай дип әйткәч, шомлы шик кайчан гына, ничек кенә күңелемдә кыймылдый башламасын, мин үз-үземә: «Юк, юк, кайтырга тиеш, кайтачак!» — дия идем, нindидер бер юләр ышану белән.

Һәм ул кайтты. Сугыш бетеп бер ел узгач, кайтты ул минем кара егетем, минем Бәхетгәрәем!.. Олыгайган, чигә чәчләре агарган, ике каш арасына тирән сызык яткан, әмма кечкенә күзләре, һаман элеккечә җылы бөрки — шундый ук гади, шундый ук табигый ул... Мин бит аны юньләп белергә дә өлгермичә калган идем, ә дүрт елдан соң каршыма килеп баскач — ышанасызмы — искиткеч үз, якын, кадерле булып күренде ул миңа!..

Зөһрә ханым тынды, тирән дулкынлануын яшерергә теләпме, елмаймакчы булды, ләкин елмаю чыкмады, башын чайкады да күзләрен йомды.— «Кичерегез!» дияргә өлгермәде, озын керфек очларыннан энҗе бөртегедәй ике яшь тамчысы, ак йөзендә туктала-туктала, акрын гына тәгәрәп төште. Мин өнсез идем, мин бер сүз дәшәргә җөрьәт итмәдем, һәм кирәкми дә иде ул. Хәзерге минутның таләбе бу... Тимик, кеше шундый газаплар бәрабәренә алган бәхетен үзе генә беткәнче кичерсен!

Әнә шулай тәмамланды Зөһрә ханымның хикәясе. Сөйләр алдыннан ул миңа бик борчылып: «Ах, аңласагыз иде сез!» — дип әйткән иде... Аңладым шикелле мин аны. Һәрхәлдә, миңа бик күптән билгеле булган бер хакыйкатьне раслады ул: мәхәббәтсез яшәү — бәхетсезлек. Ләкин мәхәббәт йөрәк эше. Бернинди исәп-хисап, мәҗбүрият, көчләү, ялыну-ялвару белән тудырып булмый аны. Туса ул, чәчәк бөресе ачылгандай, бары үзеннән-үзе һәм үз вакыты белән генә туа ала... Зөһрә ханымның бәхете — ул шуны вакытында сизә белгән, аңлый белгән һәм гомерлек үкенечтән, ә бәлкем, зур бәхетсезлектән котылып кала алган.

Өч көннән соң мин аны шәһәр вокзалыннан озатып калдым. Халык күп иде, шау-шу күп иде, барысы да: китүчеләр дә, озатучылар да — ял итүче халык, дөнья кайгысы юк, шатлык та уен-көлке, кәрзин-кәрзин җи-

мешләр, бәйләм-бәйләм чәчәкләр... Зөһрә ханымның да кулында кучкыл кызыл һәм ап-ак чәчәкләр бәйләме.

Соңгы минутлар. Бирегә төшкәндә генә безнең арада, моңарчы сөйләшкәннәрнең дәвамы буларак, тагын сүз кузгалган иде. Хәзер исә Зөһрә ханым, дулкынланып, соңгы сүзләрен әйтеп бетерергә ашыга:

— Сезнең йөрәгегездә миңа карата нинди хис уянганын сиздем мин... Әмма сез аны телдән әйтмичә яхшы иттегез. Рәхмәт моның өчен... Күрдегез инде, мин үземнең мәхәббәтемә яратмау аша килдем, икенче төрле әйткәндә, иң элек ярата алмауның нәрсә икәнен татыдым, аннан инде мәхәббәтемне таптым... Шуңа күрә ул миңа бик кадерле, күз алмасыдай саклыйм мин аны...

Минем әйтер сүзем юк инде, тик болай гына сорап куйдым:

— Зөһрә ханым, әйтегез әле, сезнеңчә, нәрсә ул мәхәббәт?

— Мәхәббәтме? Мәхәббәт — яраткан кешеңне бәхетле итү ул...

Зөһрә ханым моны һич уйлап тормастан әйтте. Мәхәббәткә, бәлкем, мең төрле җавап бардыр, әмма бу аның җавабы, аның иманы иде.

Ниһаять, поезд кузгалыр вакыт җитте. Зөһрә ханым миңа кулын сузды. Мин түбәнчелек белән иелеп, аның кулын үптем, соңра күтәрелеп күзләренә карадым... Күзләре аның, озын коңгырт керфекләр күләгәсеннән караган зәңгәр күзләре, соңгы мәртәбә миңа гүя: «Кичерегез!» — ди иде.

Поезд китте. Мәңге яшел җирнең кояшын, диңгез дымын, чәчәкләрен, шат кешеләрен алып китте. Миңа татлы газап, гомергә онытылмас әче сагышлы гүзәл хатирә калдырып китте.

Вокзал мәйданына чыккач, мин: «Нишләргә? Кая барырга?» — дип шактый уйланып тордым. Аннан җәяүләп кенә шәһәргә таба киттем. Минем бернинди планым да, максатым да юк иде. Бара-бара шәһәрне узып, диңгез буендагы паркка җиткәч, аякларыма ияреп дигәндәй, яр башындагы бер кечкенә кафега кердем. Ачык террассаның читендәге буш өстәлләрнең берсенә барып утырдым.

Түбәндә, киерелә биреп, очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп ята. Бу кичке сәгатьтә нинди тыныч һәм нинди юаш ул. Әйтерсең беркайчан да аның котырып чайкалган,

үкереп улаган чагы булмаган... Кемне алдыйсың син, диңгез?

Кояш яңа гына баеган иде. Күтәрелеп карасам, агарынып калган күк йөзендә, кай арададыр калкып өлгергән Зөһрә йолдыз тын гына балкып тора. Нәкъ каршымда... Юанычым минем!

Язмыш менә тагын мине шул ук «Дулкын» санаториена китерде... Бер ел — безнең хыялыбыз алдында нинди кыска, нинди көчсез ул!.. Бөтенесе, бөтенесе күз алдыма килде дә басты. Суынмаган эзләр... Әйе, суынмаган эзләр!.. Шул эзләр әнә диңгезгә дә алып төшә, шул ук эзләр әлеге тау башындагы карт имән төбенә дә алып менә... Юкка гына мин: «Вакыт — һәрнәрсәдән шифалы дәва, үтәр, басылыр, онытылыр»,— дип үземне юатып маташканмын икән. Менә барысы да яңадан терелде...

...Мин аны оныта алмыйм, мин аның үзен дә, тавышын да оныта алмыйм. Күптән сагынып көткән көй булып очрады ул миңа... Очрады, шушы тын юлларны минем белән бергә таптады, көлде-җырлады, гыйбрәтле үткәнен сөйләде, аннары вакыты җиткәч, ак, кызыл чәчәкләр бәйләмен күкрәгенә кысып, миңа кулын изәп китте дә барды. Үз дөньясына, үз тормышына, үз бәхетенә!.. Гомергә, мәңгегә! Инде юк ул минем өчен... Әмма, әйтегезче, дуслар, йөрәккә төшкән көйне тиз генә, ансат кына онытып буламы соң?

*Казан—Бөреле,*
*1957 ел, август*

# РӘШӘ

# I

Тугызынчы майның таңында Зөфәр Сабитов гаҗәеп бер төш күрде: имештер, ул ят бер дала буйлап ялгызы каядыр китеп бара. Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез һәм очсыз-кырыйсыз. Үләннәре саргаеп кипкән, кара туфрагы, чатнаган чуендай, яргаланып беткән. Бик эссе, бик коры, төпсез күктән кызган тимердәй ап-ак кояш туп-туры аның күзенә карый... Кайсы якка гына борылмасын ул, бу тере кояш ни өчендер һаман аның каршысына чыга, үртәп көлгәндәй, күзләрен чагылдыра, берөзлексез яндыра, көйдерә, имеш.

Кая таба бара ул, мәгъripкәме, мәшрикъкамы — ачык кына белми дә, имеш, ләкин барырга кирәк, бармыйча ярамый, чөнки монда туктап калу һич мөмкин түгел. Һәрхәлдә, ул бу котсыз даланы ничек тә үтеп, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ниндидер яңа бер дөньяга барып чыгарга тиеш. Шунда ул үзенең бәхетен табачак. Һәм берәүгә дә әйтмичә, берәүне дә ияртмичә ялгызы гына чыгып китүе дә бары шуның өчен генә, имеш.

Баштарак аңа тигез дала буйлап атлавы бер дә күңелсез, авыр булып тоелмады. Киресенчә, бу иркенлектә, бу тынлыкта бару рәхәт тә кебек иде. Аннары ялгызлык та аны артык борчымый иде әле, ничек кенә булмасын, юлдашка эт шикелле аңа ияргән гамьсез кояш бар иде. Ләкин тора-бара очы-кырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады. Кайчан бетәр бу, кайчан бер чиге күренер, нигә бер кош, бер әрлән заты да очрамый?! Тагын бу шоп-шома күктән шым гына ияреп барган «юлдашы» да бик мәкерле, явыз булып чыкты. Хәзер ул Зөфәрнең нәкъ менә баш түбәсен кыздыра, шундый кыздыра, әйтерсең юри миен кайнатып чыгарырга тырыша... Зөфәр кипте, янды, хәлдән тайды, үлеп эчәсе килә башлады. Атлаган саен көчәя барган бу сусауга һич кенә дә түзәрлек түгел иде, коточкыч авыр иде, чатнап

кара янган иреннәре бертуктаусыз: «Су... су... су!» — дип, үзлегеннән кыймылдый иде.

...Күпмегә сузылган булыр иде бу газап, чыдый алган булыр идеме ул, юкмы, әмма томаланган, шашарга җиткән күзләре алдында кинәт җем-җем уйнаклап яткан түп-түгәрәк, зур бер күл ачылды. Су, су, йа Хода!.. Бу шулкадәр чын иде, шулкадәр якын иде, гүя менә суның йомшак дымы аның йөзенә килеп тигәндәй булды. Зөфәр кара көйгән иреннәрен ялап алды, тирән итеп, өзеп-өзеп сулый башлады һәм ашыгып-кабаланып атларга тотынды. Күл бик якын кебек иде, тигез җирдән үк башланып киткән сай читләре агарып, ә эчтәрәк, тирәнрәк урыннары зәңгәрләнеп тора кебек иде. Тик аның аргы чите генә ачык күренми; анда биек камышлармы, текә ярлармы бар кебек, ләкин алар барысы да күз үтә алмаслык күгелҗем томан белән өртелгән иде. Бәлки, шундадыр инде аны көткән сихри дөнья!.. Менә тиздән,тиздән ул барып җитәр, тукталып тормастан шабыр-шобыр күлгә кереп китәр, ут капкан башын суга тыгар, кушучлап якты суын, салкын суын эчәр, эчәр, көлә-көлә, елый-елый эчәр...

...Нәкъ шул чакта кемнеңдер урам яктан зал тәрәзәсен бик каты итеп кагуы ишетелде. Төш кинәт өзелде, Зөфәр, сискәнеп, күзен ачып җибәрде. Бу ни хикмәт, кем болай дөнья җимерә? Ул ни дә булса уйлап өлгергәнче, залда яткан әнисе Таибә абыстай торып тәрәзәгә барган иде инде.

— Кем ул, ни булды, пожармы әллә? — диде карчык, куркынган тавыш белән.

Урамнан бер хатынның бик кабаланып нидер кычкыруы ишетелде. Зөфәр күпме колагын салып ятса да, аның сүзләрен аера алмады, тик ахырдан көлепме, елапмы җибәрүен генә ишетеп калды. Ул да булмый, бүлмә ишегендә Таибә абыстай күренде. Аның йөзенә карау белән Зөфәр ниндидер гадәттән тыш хәл булганын сизеп алды.

— Улым, тор әле,— диде Таибә абыстай, әкрен генә, серле һәм сөенечле бер тавыш белән.— Әнә күрше Митриләрнең килене килгән, сугыш бетте, ди...

— Сугыш бетте?..

— Әйе, сугыш бетте, ди, хәзер генә радиодан әйттеләр, ди, нишләп ятасыз, ди... Йа Рабби мәүләм, бу көннәрне дә күрергә насыйп иттең, рәхмәтеңнән ташламадың бәндәләреңне...

Зөфәр шунда ук урыныннан сикереп торды һәм ашыгып киенә башлады. Төш онытылды, юкка чыкты. Сугыш беткән! Беткән! Точка! Зөфәрнең кычкырып көләсе

килде, күкрәгендә тантана һәм ярсу тыгызлана башлады, ашыгудан кулларын күлмәк җиңенә кертә алмыйча азапланды. Әнисенә кычкырды:

— Әни, давай чәеңне! Тизрәк бул!

Киенеп бетәр-бетмәс залга чыкты, урам тәрәзәсенә барды һәм хәйран калды: урамда чуп-чуар халык иде. Капка төпләрендә төркем-төркем хатын-кызлар басып торалар, нидер сөйләшәләр, көләләр, күзләрен сөртәләр. Алар тирәсендә бала-чагалар сикерешәләр. Урам буйлап яшь-җилкенчәкләр тыз-быз йөриләр, каршы очрашканда кочаклашалар, үбешәләр. Ә вакыт бик иртә иде әле, кояш шәһәр өстенә яңа күтәрелеп кенә килә...

Менә ул көн, менә кайчан килеп җитте ул күпме курку-шомланулар, күпме яшерен өметләр белән көткән көн! Бетте, шушы минуттан курку да, шомлану да — барысы да бетте, җилкәдән әйтерсең Һималай тавы төште!

Зөфәр җиңел генә атлап кухняга чыкты. Җиңгәсе Сәкинәнең урыны буш иде, тик киң караватта биш яшьлек Фәрит кенә, бөек вакыйгадан хәбәрсез, кул-аягын ташлап, йоклап ята иде.

— Җиңги кайда? — диде Зөфәр.

— Кайда булсын, урамда...

— Ә балалар? Хөршид?

— Алар да шунда, тордылар да бәрелә-сугыла чыгып чаптылар. Күк капусы ачылганмыни,— диде Таибә абыстай, азрак сукранып; күрәсең, барысының да өй ташлап чыгып китүләренә аның хәтере калган иде.

— Күк капусы ачылудан да болайрак бу, әни!

— Анысы шулай инде, шулай,— диде Таибә абыстай, тизрәк килешеп.— Әйттем исә кайттым, көенечкә генә була күрмәсен!

Зөфәр чәйгә утырганчы радионы борып куйды. Шунда ук Левитан тавышы яңгырады. Менә ничәнче тапкыр инде ул Гитлер Германиясенең капитуляция шартларына кул куюын тапшыра иде. Һәм аның тавышы, гүләп торган чаң шикелле, көчле-дәһшәтле булып, һәр сүзе искиткеч ачык-тантаналы булып яңгырый иде. Тарихның бөек сәгате!

Шуның артыннан ук хөкүмәтнең тугызынчы май көнен —Җиңү көне, бәйрәм көне итеп белдерүен тапшырдылар. Димәк, бүген заводлар, учреждениеләр эшләмәячәк. Аның каравы, Зөфәрнең эше тыгыз булачак, чөнки ул сәүдә кешесе, сәүдә белән җитәкчелек итүче, ә мондый көнне сәүдә точкалары, бигрәк тә азык-төлек магазиннары ачык булырга, шаулатып сату итәргә тиешләр. Бу көнне көтеп, складларда саклап тоткан ара-

кы-виноларны, азмы-күпме кондитер, бакалея нәрсәләрен тизрәк точкаларга чыгарырга кирәк.

Таибә абыстай кайнатып биргән чәйне Зөфәр кухняда гына утырып эчте дә бүлмәсенә кереп киенергә тотынды. Әшкә барса да, бәйрәмчә булсын дип, чиккән якалы ак күлмәген, элүдә генә торган соры костюмын, җәйге туфлиләрен киде. Барысы бер төстән, бер иштән диярлек, тик менә зәңгәр кепкасы гына күренешне шактый боза иде. Ярый инде, баштанаяк бертөследән киенер вакытлар алда әле...

...Капкадан чыгуга иң элек аңа сеңелесе Хөршид ташланды. Арык кыз нечкә беләкләре белән аның муенына үрелеп, артык дулкынланудан сүзләрен бутап, нидер әйтергә тырышты:

— Абыем җаным, бетте, котлыйм, абыем җаным...

Зөфәр аның көзге яфрак кебек калтыранган юка гәүдәсен сыңар кулы белән генә кочып алды:

— Бар, хәзер үк кереп, өстеңә киеп чык! Тәмам өшегәнсең бит.

— Мин янам! — диде кыз, абыйсына тагы да сарыла төшеп.

— Бизгәгең кузгала торгандыр, бар, бар, хәзер үк кер! — диде Зөфәр, аны куалап.

Бер читтәрәк, күрше хатыннар уртасында, иңенә шәлен салган Сәкинә җиңгәсе тора иде. Хатыннар берберсен бүлеп, барысы берьюлы диярлек, шаулап сөйләшәләр, кинәт кенә көлеп тә, хәтта елап та җибәрәләр, ә җиңгәсе исә башын кагып кына тора, ара-тирә күзен сөрткәләп ала, әмма аның йөзе яшь кызларныкыдай тәмам нурланып, алсуланып киткән иде. «Менә кемгә бәйрәм бүген!» — дип уйлап куйды Зөфәр. Ире, иркәе фронттан кайтачак бит аның!.. Шулай була күрсен инде. Зариф солдат, Зөфәрнең абыйсы, сугышның соңгы атналарына кадәр исән-имин иде әле. Герман җиренә кергәч тә, эшем әйбәт, трофейный ротада хезмәт итәм, дип язган хатлары һаман килеп торды.

Урам буйлап барганда капка төпләрендә басып торган кайбер хатын-кызлар яки олы яшьтәге ирләр Зөфәргә әдәп белән тыйнак кына: «Исәнмесез, күрше! Котлы булсын Җиңү бәйрәме!» — дип дәшеп калдылар. Зөфәр үзе дә аларга елмаеп, зәңгәр кепкасын күтәрә төшеп, баш иеп узды. Шулай ул бу дөнья! Әле кайчан гына шушы күршеләре аны, сәламләү түгел, бөтенләй күрмәмешкә салыналар иде яки яшерен бер дошманлык белән артыннан карап калалар иде. Янәсе, бөтен кеше тегендә, ут эчендә, ә ул тап-таза килеш монда йөри... Ни өчен ком-

мерсантка мондый оҗмах, имеш? Билгеле, авыр иде бу ят итеп, дошман итеп карауларны күтәрүе, әмма тешен кысып булса да, аңа чыдарга туры килде. Ә хәзер бетте, бетәргә тиеш, хәзер фронт та юк, тыл да юк — бөтен кеше бертигез. Һәм ул бүгенге көннән берәүдән дә шүрләмичә, һәркемнең йөзенә туры карап йөри алачак.

Трамвай йөри торган зур урамга чыккач, Зөфәр тагы да ныграк гаҗәпләнә калды: монда инде халык, төркем-төркем булып кына түгел, ә тоташ бер елгадай, трамвай юлының ике ягыннан шәһәр уртасындагы мәйданга таба агыла иде. «Бу ни тамаша? — дип уйлады ул. — Эшкә дисәң, барысы да бер якка таба баралар, демонстрация дисәң, бернинди тәртип юк!» Ләкин бу чыннан да халыкның бернинди чакырусыз, өндәүсез, үзеннән-үзе туган, шуңа күрә сафларга тезелмәгән шатлык демонстрациясе иде.

Сугыш елларында тузып беткән тармвайлар бу иртәдә дә селкенеп, дөбердәп йөриләр иде. Зөфәр, шуларның берсенә утырып, эшләгән җиренә китте. Эшләгән җире — зур бер заводның эшчеләр тәэминаты идарәсендә. Менә шунда ул сәүдә бүлегенең мөдире булып сугыш башыннан ук эшләп килә иде.

Трамвайга утырып барган чакта Зөфәр бүген таңда күргән әлеге сәер төшен хәтерләде. Нинди төш булды соң бу? Көйгән дала, эссе кояш, сусызлыктан тәмам әлсерәп, интегеп, ялгыз баручы ул, Зөфәр — кайдан килеп керде бу аңа?.. Һәм нәрсәгә юрарга соң мондый куркыныч һәм куандыргыч төшне? Аның үләргә җитеп сусаудан тонган күзләре алдында җем-җем уйнаклап яткан гаҗәеп матур күл ачылган иде бит. Хәтта ул аның сусыл исен, салкынча дымын тоя башлаган иде. Тик, кызганычка каршы, төш иртәрәк өзелеп калды. Әгәр аны сискәндереп уятмасалар, ул барып җиткән булыр идеме икән, юкмы икән? Хәер, бу кадәресе әллә ни әһәмиятле дә түгел. Күл үзе — аның сусавын басачак саф, салкын сулы күл үзе бар иде бит, бик якын иде, димәк, төшне бары тик яхшыга, бәхеткә генә юрарга кирәк. Менә бүген туган көн шул төшнең дәвамы түгелме соң, теге күл шикелле аның алдында киләчәк бәхете кинәт ялтырап ачылды түгелме соң?!

Зөфәр килеп җиткәндә завод алдындагы мәйдан халык белән шыгрым тулган иде. Заводның эшләмәячәген белсәләр дә, монда, җитәкчеләрдән алып бөтен сменаларның эшчеләренә кадәр, барысы да җыелганнар иде. Мәйдан шау-гөр килеп тора. Әллә ничә җирдә баян уйныйлар, әллә ничә җирдә түгәрәкләнеп бииләр, җырлый-

лар, төрле җирдә заводның карт эшчеләрен, фронттан кайткан кешеләрне шаулап-көлеп һавага чөяләр. Шундый төркемнәрнең берсендә Зөфәр дистәләрчә кулларның майор Симаковны мәтәлдереп чөюләрен күреп алды. Кыш уртасында гына фронттан кайткан бу кулсыз майор заводның кадрлар бүлеге начальнигы булып эшли башлаган иде. Ничектер тиз арада гына ул зур коллективның күзгә күренгән бер кешесе булды да китте. Моның сере фронттан күкрәгеn орден-медальләр белән тутырып кайтуында гына түгел иде шикелле, ә үзен идарә тирәсендәге ялагай бюрократлар арасында гаҗәп кыю, бәйсез тотуында иде булса кирәк. Шуңадыр, ахры, гади халык, батыр табылды дигәндәй, аңа авып та киткән иде.

Зөфәр аны чөйгән якка барып тормады (кулсыз майор белән очрашырга яратмый иде ул), ә халыкны ерып, туры гына завод идарәсенә таба узды. Ишек төбендә идарә кешеләре белән кул биреп күреште, һәркайсын бәйрәм белән котлады, аннары бер читтәрәк ниндидер ят кеше белән сөйләшеп торган, таза гәүдәсенә иркен кара пальто, башына яхшы хәрби фуражка кигән завод директоры янына барып, түбәнчелек белән, аңа кулын сузды:

— Владимир Иванович, рөхсәт итегез сезне котларга, әйе, Бөек Җиңү белән, бөек бәйрәм белән!

— Сезне дә шулай ук, Зуфар Мубаракович! — диде директор, кулын биреп, ләкин янындагы кеше белән сүзен бүлеп тормады.

Шуннан соң Зөфәр идарәгә — үзенең бүлмәсенә кереп китте дә телефонга утырды һәм сәүдә точкаларына шалтырата башлады. Бәйрәм настроениесе гүя тышта торып калды, һәм ул гадәттәге рәсми эшчәнлек белән магазин директорларына төрле боерыклар бирергә, ә кайберләрен шелтәләргә тотынды. Үзе ул боерыксыз эшләргә өйрәнгән кеше, шуңа күрә бүтәннәрнең бер сүздән тел төбен аңламауларына ачуы килә. Нәрсә чыгарырга, күпме чыгарырга, күпмесен калдырып торырга — барысын да чәйнәп сал син аларга!

Менә директор да аның белән рәсми коры гына исәнләшкән булды. Ә бит ул Зөфәрсез — сыңар кулсыз! Зөфәргә бер ымлавы җитә, һәм Зөфәр аңа, кирәксә, күгәрчен сөтен дә табып китерә. Югыйсә ул аны, бронь бирдерә-бирдерә, сугыш буена саклап тоткан булыр идемени? Тот капчыгыңны! Ә җылы сүзе, якты чырае үзенә булсын. Зөфәр алар өчен чапмый. Эшенә күрә әҗере бар икән, аңа шул җиткән. Һәркемнең үз исәбе — дөньясы шул!

Ике катлы буш бинаның коридор очындагы бер бүлмәсендә ялгызы шактый утырганнан соң, Зөфәр урамга чыкты. Завод алдында халык калмаган иде инде. Киткәннәр. Мөгаен, шәһәр үзәгенә табадыр, анда бүген ни дә булса булмыйча калмас. Әнә башка заводларның да кешеләре урам тутырып шул якка таба баралар. Тиз кулдан гына язган лозунглар, юлбашчыларның май демонстрациясеннән калган портретларын күтәргәннәр —шуларны баш өсләрендә тибрәтә-тибрәтә нигәдер бик ашыгып атлыйлар. Зөфәр дә шул агымга ияреп китте. Ләкин аның ашыгасы килмәде. Ул тынычланып өлгергән иде инде. Тантанага катнашып китүдән бигрәк, шул тантананы күзәтеп бару аның өчен кызыграк кебек иде. Гомумән, ул кешегә ияреп кабынырга, очынырга, кыскасы, экстазга бирелеп китәргә яратмый иде. Һәр эштәге шикелле хиссият мәсьәләсендә дә үлчәү-чаманы ярата иде.

Дамбага җиткәч, ерак араны җәяү үтмәс өчен, ул шыгрым тулы трамвайларның берсенә эләгеп китте. Кремль астында төшеп калды, ашыкмыйча гына Бауман буйлап атлады... Монда халык, халык, ерып үтәрлек тә түгел. Ә Кольцода! Мәхшәр купкан диярсең! Бөтен мәйдан чайкалып, өзлексез гү-ү итеп тора. Кешеләр балык косягы шикелле ышкылып, сугылып, һаман бер тирәдә уралалар, бер-берсен кочаклап алалар, үбеп китәләр. Зөфәрне дә ялгыш кына каршысына килеп чыккан әллә кемнәр кочып алдылар, колагына: «Туганкай, җиңдек, бетте!» —дип кычкырып уздылар. Ул бу мәхшәрдән ничек тә тизрәк ычкынырга теләде. Йорт стеналары буйлап, көч-хәл белән Куйбышев урамына үтә алды һәм Ирек мәйданына таба атлады... Филармониягә җитәрәк, кинәт җирдән калыккандай, аның каршысына Рәшидә килеп чыкты. Килеп тә чыкты: «Зөфәрем!» — дип, егетнең муенынннан кочып та алды. Бөтен гәүдәсе белән сарылып, күпмедер вакыт сеңеп торды. Аннары кинәт кенә артка каерылды һәм иртәнге чыктай дымланып елтыраган, исәрләнгән күзләре белән Зөфәргә төбәлде.

— Ник син көлмисең, еламыйсың, Зөфәрем? — диде ул, балаларча чын гаҗәпләнү белән.

Зөфәр көлеп куйды:

— Булды, Рәшидә, барысы да булды, ләкин без ирләр бит, туктый да беләбез.

Рәшидә тагын аның күкрәгенә капланып, юатуын теләгәндәй, еламсырап, кайнар пышылдап әйтте:

— Ә мин әллә нишләдем, Зөфәрем, әллә нишләдем. Шатлыгымнан тилерәм дип торам, ышанасыңмы? Бөтен дөнья бәхете кинәт өстеңә аусын әле!.. Үләрсең, хәсрәттән үлмәгәнне шатлыктан үләрсең!.. Йа, Ходай!..

Зөфәр аның тузгыган чәченнән сыйпап, ирләрчә салмак кына юатырга тырышты:

— Рәшидә, аңлыйм, ләкин тилерергә дә, үләргә дә ярамый. Алары күп булды инде, ә хәзер яшәргә дә яшәргә кирәк.

— Нигә син бу кадәр акыллы, Зөфәр! — диде Рәшидә, күтәрелеп, егеткә сәер генә бер карап алды, аннары кычкырып көлеп җибәрде: — Зөфәр, мин сиңа бер яңа хәбәр әйтимме?

— Йә, әйт.

— Сугыш бетте, сугыш! Ишетәсеңме?.. Безнең Җиңү белән, безнең Җиңү белән!.. Менә шуның өчен сиңа, менә шуның өчен...

Һәм ул аяк очларына басты да, үрелеп, Зөфәрнең иреннән, битеннән тиз-тиз үбәргә тотынды. Зөфәр бер мәлгә югалып калды, яннарыннан гына бәрелеп, сугылып узган кешеләрнең көлеп, шул ук вакытта бик аңлап карауларын тойгандай булды, шуңа азрак уңайсызланып та куйды. Җитмәсә, бер шаян егет: «Ныграк үзенә, ныграк, бәгыренә үтсен!» — дип тә узды... Ниһаять, Рәшидә үбүеннән туктады, күкрәгеен тибрәндереп, тирән итеп сулап торды, аннары, бәхетеннән бөтенләй онытылып булса кирәк, үпкә катыш назланып сорады:

— Ә син мине?

— Ә мин сине моның өчен ашап бетерермен әле,— диде Зөфәр, шыпырт кына, тирә-ягына каранып.— Әйдә, киттек, бергә йөрибез!

— Ә юк! — диде Рәшидә, аз гына чигенеп.— Без бүген халыкка җырлап йөрибез. Әнә машина да көтә.

Зөфәр аның кулыннан тотмакчы булды:

— Ә миңа кайчан җырларсың?

— Кара син нинди эгоист!.. Юк инде, дустым, бик тыңлыйсың килсә, әнә халык белән бергә тыңларсың... Ярый, мин киттем! — Һәм кинәт кенә борылып, халык арасына кереп тә югалды.

Ах, хәерсез, качты бит! Ә Зөфәрнең бүген Рәшидә белән бергә аулакта гына бик буласы килгән иде. Көне, көне — шатлыгын, мәхәббәтен, рәхәтен дигәндәй, икәүдән-икәү генә татый торган көн ич бу!.. Әллә артыннан барыргамы икән?

Зөфәр, үрелеп, халык аша урамның икенче ягына карады. Анда, ачык машина өстендә, кайберләре баян аскан, кайберләре авыл яшьләре булып киенгән, ә күбесе үз киемнәреннән, филармония артистлары күренәләр иде... Менә Рәшидәне дә берничә кул машина өстенә тартып алдылар. Бер кәләпүшле егет аны иңбашыннан

кочаклады, бу якка карап, йодрык та селеккән шикелле булды. Чыр-чу киләләр, көлешәләр, шайтаннар!.. «Юк, ярамас,— диде Зөфәр, эченнән генә,— барсаң, буй күрсәтеп, сер сынатып кына калырсың». Ул башын иде дә акрын гына Ирек мәйданына таба китеп барды.

Ләкин кая гына барма, халык та халык — ерып йөрерлек тә, бернәрсә күреп булырлык та түгел. Ахырда бу шау-гөр килеп, чайкалып торган халык диңгезе эчендә бәреләсугыла йөрү Зөфәрне тәмам арытты. «Ярар, булды, җитеп торыр»,— диде ул үз-үзенә һәм аулак урамнарның берсенә чыкты да Лядской бакча аша җәяүләп кенә кайтыр якка китте. Аның ашыйсы да килә иде, азрак ял да итеп аласы килә иде һәм бигрәк тә үзалдына гына уйланып кайтасы килә иде.

Сугыш бетүе һәркемнең, шул җөмләдән Зөфәрнең дә язмышын кинәт яшендәй урталай ярып узды. Берсе бетте, икенчесе туды. Кичәгенәк кенә әле башка тормыш иде, сугыш законы хөкем сөргән тормыш иде, ә бүгеннән бөтенләй икенче тормыш — тыныч заман тормышы башлана. Хәзер, берсеннән икенчесенә күчкәндә, киләчәк турында да ашыкмыйча тыныч кына уйлый башларга ярый иде.

...Киләчәк!.. Сугыш китергән иң авыр, иң газаплы бер заманда кешеләрнең бердәнбер юанычы, өмете, татлы хыялы иде ул... Әмма ничегрәк итеп күз алдына китерергә мөмкин соң бу киләчәкне?.. Башта ук Зөфәр өчен бер хакыйкать көн кебек ачык иде: бу сугыштан, көн саен меңнәрчә адәм баласын йотып торган бу гарасаттан котылып калган кеше, һичшиксез, бәхетле булачак! Ягъни исән калу факты үзе генә дә кешегә: «Бәхетлемен!» — дип әйтергә хокук бирәчәк... Ләкин Зөфәргә хәзер бу бәхет кенә аз иде инде. Ул — реалист, аныңча, баш исән булу гына чын бәхет түгел әле. Исән калган баш ничек яшәр —менә хикмәт нәрсәдә. Ә ул моның серен белә инде: бәхет — үзең теләгәнчә яшәү, бәхет — матди һәм рухи бәйсезлек ул.

Бәс, шулай икән, Зөфәр дә киләчәк тормышын үзе теләгәнчә бәйсез, иркен, мул итеп корып җибәрергә тиеш. Һәрхәлдә, ул бөтен көчен, сәләтен җигеп, шуңа омтылырга тиеш.

Моның өчен хәзер аңа ике конкрет мәсьәләне тизрәк хәл итәргә кирәк булачак. Берсе — акчаны малга әйләндерү, ягъни йортмы-квартирамы сатып алу; икенчесе — аңа терәк һәм теләктәш булырлык әйбәт кенә кызга өйләнү... Беренчесе кыен булмас кебек, әмма икенчесе?..

Сугыш Зөфәр өчен артык рәхимле, юмарт булып чыкты. Башын да аяды, малын да бирде, өстәвенә аны сөйгән ярлы да итте. Бу — Рәшидә. Филармониянең ярлы, ялгызак бер артисткасы. Гаҗәеп бер хатын!

## II

...Рәшидә Сафина... Рәшидә Сафина... Шушы сылу-чибәр артистка белән һич уйламаган җирдә танышуын, гаҗәеп сәер бер шартларда әллә ничек кенә аның белән якын бәйләнешкә кереп китүен Зөфәр хәйран калып, ләззәт утында янып, менә күпме тапкырлар инде күз алдыннан кичерә... Гомумән, ул Рәшидә турында уйламыйча тора алмый. Бу кабынып уйлануда Рәшидәне сагыну да бар, аңа соклану да, аны теләү дә бар, тик уйлап-уйлап та нечкә күңелле артистканы аңлап бетү һәм беткәнче яратып китү генә юк. Җан тели дә, язык җибәрми дигәндәй, гел менә сагынып омтылу белән сагаеп тыелу арасында хәзергә кадәр яшәп килә ул. Ике ел тулып узды бит, ике ел!

Ә вакыйга менә ничек булды.

1943 елның январь ахырларында Зөфәр Бөгелмә юлы өстендәге кечкенә бер станциягә үзенең тәэминат эшләре белән командировкага килеп төште. Үтә салкын, шыксыз, караңгы бер көн иде. Җыен хәрбиләрне һәм бик аз санлы гына командировочныйларны төяп, фронтка таба ашыгып баручы эшелоннарга юл бирә-бирә, акрын гына өстерәлеп килгән поезд бу станциядә ничектер аз гына тукталып торды да китеп тә барды. Пассажирлар вагоннардан чыгып та карамадылар. Хәер, чыгудан ни мәгънә? Ул чакларда станция тирәләре бик җансыз һәм бик күңелсез була торган иде. Вокзал бparty биналары ягылмый, утлар яндырылмый, буфетлар эшләми, рәшәткә буенда сөт, каймак, тозлы кыяр, пешкән бәрәңге сатучы хатыннар булмый һәм тирә-як авыллардан килгән атлар да җыелып тормый иде. Алыр нәрсә дә, күрер нәрсә дә, белер нәрсә дә юк. Чыксалар, шул яшь солдатлар гына чыгып, чибәр кызлар очрамасмы, шуларга бер җылы сүз катып булмасмы, дип, станция тирәсеннән шыгыр-шагыр бер әйләнеп керәләр иде. Бу юлы алар да шыгырдап керергә өлгерә алмый калдылар.

...Поезд китте, вокзал алдында Зөфәр берүзе диярлек торып калды. Ни сәбәптәндер бу сәгатьтә монда бүтән бер поезд да, бер эшелон да юк иде; тезелешеп киткән буш юллар арасында мазут таплары җәелгән пычрак кар

гына елтырап ята һәм салкын телеграф чыбыклары гына моңаеп өзлексез шаулый... Ник бер кеше, ник бер хәрәкәт күренсен... Һич югы, берәр олаучы-мазар күренмәсме, дип, Зөфәр рәшәткә буена да барып карады. Юк, олаучы түгел, адашып йөрүче эт тә юк. Шуннан соң ул кире борылып килде дә, бусагасы төбенә шадраланып тайгакшома, пычрак кар каткан, тупса ярыкларына бәс утырган, юньләп ябылмый да торган авыр, зур ишекне көчкә ачып, вокзал эченә керде... Вокзал эче дә тыштан аергысыз салкын, караңгы, котсыз, буш иде. Ләкин шулай да Зөфәр анда дүрт кешене күрде. Аларның өчесе хатынкыз, берсе ир кеше иде. Кызлар бер почмактарак, ягылмаган галанка мич тирәсенә бөрешеп утырганнар, ә ир кеше иңбашларын уйнаткалап, тире бияләйләрен бер-берсенә суккалап, әрле-бирле йөренеп тора иде. Кыяфәтләренә һәм өс-башларына карагандa шәһәр кешеләре булырга тиешләр. Хәер, өс-башлары аларның бик чуар һәм бик иләмсез иде. Кызлар, салкынга бирешмәс өчен, бар булганнарын юка пальтолары астыннан өсләренә киеп бетергәннәр, ахрысы — барысы да тәпән шикелле юаннар, барысы да сырган чалбардан һәм киез итекләрдән, башларына кайсы шәл чорнаган, кайсы малахай бүрек кигән... Әмма шулай да кызлар бик нык өшегәннәр булса кирәк, шәмәхә төсенә кергән иреннәре үзлегеннән калтыранырга гына тора. Тик ир кеше генә ул хәтле үк куырылып төшмәгән. Кием-салымы да аның тазарак, башында эче-тышы мех малахай бүрек, өстендә калын тышлы, сырган эчле, каракүл якалы пальто, аягында зур соры киез итек; бүрегенең колакларын төшереп бәйләгән, якасын торгызган, билен тар каеш белән ныгытып буган; шуңадыр инде ул: «Юк, бирешмибез әле!» — дигән төсле дәртләнеп йөреп маташа.

Зөфәр бер читтәрәк тукталып, болар кемнәр икән, дип, аларга карап торган чакта, шул тире бияләйле кеше үзе аңа килеп дәште:

— Агай-эне, кай тарафлардан килеп чыктыгыз әле сез монда?

Зөфәр аның болай шактый әрсез һәм дорфа итеп соравыннан гаҗәпләнеп, беравык ни әйтергә белмичәрәк торды. Аннары көлемсерәп кенә әйтеп куйды:

— Кай тарафтан килүем сезнең өчен барыбер түгелмени?

— Барыбер түгел шул. Әйтегез турысын гына — сез Казаннанмы?

— Әйе, Казаннан.

Моны ишетүгә,егет тиз үк бияләйләрен салды.

— Бик шәп. Алайса чыгарыгыз әле үзебезнең Казан дөкәнен!

— Нәрсә ул?

— Шуны да белмисезме? Ну махра, Маһиракай!..

— Мин тартмыйм бит.

— Их, Гитлерның анасын өшкерим! Нинди кеше сез?.. Әллә ир түгелме сез?

— Ирен ир, ну шулай да тартмыйм.

Егет «Китегезсәнә!» дигән шикелле, нәфрәтләнеп кулын селтәде дә бияләйләрен киде. Шул арада мич тирәсендәге кызлар да Зөфәргә игътибар итеп алдылар. Яхшы пальто, күн түбәле каракүл бүрек, эт тиресеннән озын куныччлы унты кигән һәм бер беләгенә зәңгәр тышлы бәрән толыбын салып, икенче кулына кара чемодан тоткан, бик тук кыяфәтле, таза егет берьюлы аларның кызыксынуын уятты булса кирәк, шунда ук ике кыз, торып, Зөфәр янына килделәр.

Кызларның бүрек кигәне, түгәрәк битен Зөфәргә күтәреп, елмаеп, балаларча сузыбрак аңардан сорады:

— Абый-й, сез Казаннанмыни-и?

— Әйе, Казаннан шул,— диде Зөфәр, аның тавышына көйләнебрәк.

— И-и, кара аны! Менә бәхет! Йә, ниләр бар соң Казанда, абый?

— Ни булсын... Бар да искечә.

— Анда да бик суыкмы?

— Бик суык.

— Ә фронттан нинди хәбәрләр бар?

— Кичә-бүгенгесен генә белмим. Ә гомумән алганда хәбәрләр бик яхшы. Идел буендагы хәлләрне ишеткәнсездер инде?

— Ишеттек, абый җаным, ишеттек! — диде кыз, бердән ялкынланып.— Шатлыктан тилерә яздык, еладык та, көлдек тә!

Зөфәр аңа бик җитди генә бер карап алды. Ә кыз үз нәүбәтендә: «Әллә ышанмыйсызмы?» — дигән төсле, аңа тагы да турырак, батыррак итеп карады. Зөфәр, уңайсызланып, сүзне икенчегә борды:

— Сез үзегез дә Казаннан, ахрысы?

— Әйе, Казаннан. Өч атна инде... Сагындык, кайтасыбыз килә.

— Шулаймыни? Ә нишләп йөрисез соң монда?

— Без филармониядән. Концертлар биреп йөрибез.

— Ә, алай икән? Артистлар, димәк? — Ул, танырга теләгәндәй, кызларның әле берсенә, әле икенчесенә төбәлеп кенә карап алды.

Башына шәл чорнаган, какча битле, зур кара күзле икенче кыз шул чакта аңардан сорап куйды:

— Сез, абый кеше, кая барасыз?

— Ничек... кая барасыз?

— Шушы станцага килүегезме, әллә моннан бүтән җиргә китәсезме, дип соравым.

— Ничек дим. Монда да эшем бар. Ләкин миңа иң элек Турай авылына барырга кирәк иде.

— Турайга? — диде кыз, кинәт яктырып, аннары артына борылып, мич янында утырган өченче кызга кычкырып дәште: — Рәшидә апа, карале, менә Турайга барам, ди бу абый...

Рәшидә дигәннәре, торып, ашыкмыйча гына болар янына килде. Ул, күренеп тора, башкаларына караганда яшькә дә олырак, буйга да озынрак, өс-башы да аның пөхтәрәк иде. Килүгә иң элек ул баш кагып кына Зөфәр белән исәнләште. Аннары шешенкерәк кабаклары арасыннан елтыраган кечкенә коңгырт күзләре белән Зөфәргә бик туры-җитди итеп бер карады да, шунда ук тип-тигез тешләренең очларын гына күрсәтеп, сөйкемле генә елмаеп куйды.

— Турайга барасызмыни? Безгә дә нәкъ шул авылга бүген барып җитәргә кирәк бит,— диде ул, бик гади генә итеп.

Зөфәр бер мизгел аңардан күзләрен алалмыйча торды. Әллә ничек менә, кызның бер үк вакытта диярлек бик җитди-туры итеп каравы һәм матур-сөйкемле итеп елмаюы аны гаҗәпләнеп, югалып калырга мәҗбүр итте. Чибәр артистканың ирләр белән сөйләшкәндә күрсәтә торган, юри өйрәнеп алган бер сыйфаты идеме бу — моны тиз генә аңлау мөмкин дә түгел, әмма ничек кенә булмасын, аның ул сыйфаты Зөфәргә беренче караштан ук бик самими һәм бик табигый булып тоелды...

— Эш нидән тора соң? — диде ул, ниһаять, исенә килеп.

Рәшидә кара тарткан нечкә кашларын чак кына сикертеп куйды:

— Билгеле инде нидән торганы... Ат таба алмыйбыз.

Ул арада бая кулын селтәп киткән егет тә килеп сүзгә кушылды:

— Беда, брат! Бүген генә күрше станциядән товарный поездның тамбурына утырып килдек. Суы-ык, җилекләргә үтте!.. Мин, ат эзләп, авыл буенча чабарга тотындым. Юк кына бит... Мондагы колхоз председателенә бардым. Атыбыз бар, кешебез юк, ди. Мондый суыкта ат башына балачага утыртып җибәрә алмыйм, ди... Бер агач аякны тап-

кан идем, анысы илтеп кайткан өчен аракы сорый. Аракы! Аракы булса, мин үзем чанага җигелер идем әле...

Зөфәр көлемсерәп куйды:

— Инде нишләргә уйлыйсыз?

— Нишлик, утырабыз менә вокзал саклап...

— Без бик өшедек,— дип, балаларча еламсырап әйтеп куйды әлеге башлап килгән бүрекле кыз.

Рәшидә Зөфәргә якынрак килә төште:

— Карагыз әле,— диде ул, Зөфәрнең күзләренә тагын бик туры карап,— бәлки, сез табарсыз? Без үз өлешебезне түләр идек.

Зөфәр, бу әллә нинди менә акрын гына эчкәре үтә торган хәтәр караштан ихтыярсыз телсез калып, әмма бирешмәскә тырышкандай батыраеп, үзе дә аңа беравык текәлеп карап торды. Һәм гаҗәп хәл — кызның җитди карашы үзгәрмәстән йөзе тагын яктыра башлады, нечкә кашлары тибрәнеп куйды, тулы иреннәре әллә елмаерга, әллә нидер әйтергә теләп, кыймылдаган кебек булды. Ах, шайтан алгыры, уйный белә бит бу чибәр артистка!

Зөфәр, тирән генә сулап, башын читкә борды:

— Белмим шул,— диде ул, икеләнеп.— Читен мәсьәлә.

— Сез табарсыз, әгәр теләсәгез,— диде Рәшидә аңа, күптән белгән кешесенә әйткәндәй бик гади генә итеп.

Кызның бу сүзләре Зөфәрне гаҗәпләндерде һәм уйланырга мәҗбүр итте. Әлбәттә, ул табачак. Тик менә... кирәк микән болар белән юлдаш булырга? Үзе дә аңлап җитмичә, нәрсәдәндер, ни өчендер бераз гына шүрли кебек... Ул янында сүзсез генә җавап көтеп торучы күшегеп беткән кызларга, җилкәсен җыерып, бөрешеп төшкән егеткә бер карап алды (әмма Рәшидәгә караудан юри тыелды) һәм шунда ук ныклы карарга килде: һичшиксез алып китәргә кирәк боларны! Әйдә, миннән бер изгелек булсын! Эш белән йөриләр ич, мескеннәр!.. Һәм аңарда кинәт гаҗәеп бер энергия, кыюлык уянган кебек булды.

— Яхшы! — диде ул, өзеп кенә.— Мин хәзер бер җиргә барып киләм. Әйберләрне сезнең янда калдырып торырга ярыймы?

— Ә, пожалысты! — диде егет, өтәләнеп.

Рәшидә артык бер сүз дә әйтмәде, бары тик әлеге шул сихри елтыр күзләрен генә: «Менә сез нинди әйбәт кеше!» — дигән төсле, җылы бөркеп, сирпеп куйды. Кызлар исә куанычларыннан биешеп тә алдылар:

— Рәхмәт, абый җаным, рәхмәт!

— Рәхмәте соңыннан, әле атның табылганы юк бит,— диде Зөфәр һәм чемоданы белән толыбын кызларның мич буенда торган әйберләре янына илтеп куйды.

...Вокзалдан чыккач, ул туп-туры сельпо председателенә китте. Бу аның күз күргән кешесе. Әгәр өендә булса, Зөфәр өчен барысын да эшләргә тиеш, әлбәттә.

Ул чалбар кесәсен капшап карады: чиста спирт тутырган солдат флягасы тирән кесәдә бик әйбәт утыра икән. Председательгә бераз салып бирергә була. Дөрес, сельпо кешесе үзе дә алама сырецны таба торгандыр, ләкин бу түгел инде. Бу — әҗәл даруына йөри хәзер...

Зөфәр, үзе эчмәсә дә, заводның чиста спиртын юлга һәрвакыт берәр литр алып чыга. Чемоданында тагын бер савыты бар әле аның... Шул нәрсә акча яки сүз үтмәгән җирдә эшне көйләп җибәрергә ифрат ярдәм итеп куя бит, шайтан алгыры!

...Киң, буш урамнан салкын карны шыгырдатып атлый-атлый, Зөфәр вокзалда көтеп калган артистлар турында да уйлап барды. Нинди хәлдә йөриләр, мескеннәр! Кош оча алмаслык суык, өс-башлары юка, тамаклары да, билгеле, ач инде аларның... Быелгы, кырык өченче елның кышы бигрәк тә авыр килде, хәерсез! Сугышның беренче елында фронтта эшләр бик мөшкел булса да, тылда ярыйсы иде әле. Колхозларда икмәк бар иде, халыкның үзенең дә иске запасы, мал-туары бар иде. Хәзер киресенчә: фронтта хәлләр яхшырды, эш җиңүгә таба китте, әмма... тылның хәле бик начарланды. Колхозлар тәмам бөлде, ир-ат калмады, икмәк юк, халык ачыга яки бер бәрәңгедә утыра... Һәм менә бөтен ил сөремен коеп, тешен кысып яшәгән бервакытта бу бичаралар, халыкка культура хезмәте күрсәтәбез, дип, ачлы-туклы, өшеп-катып йөргән булалар. Йә, халыкта җыр кайгысымы соң хәзер! Шуны үзләре күрмиләр микәнни? Хәер, көчләп җибәргәч, йөри торганнардыр инде. Ләкин шунысы гаҗәп — бер дә сыкрау-сыктану сизелми үзләрендә тагын. Йөзләре күм-күк, күзләре ач, ә шулай да көлгән булалар, шаярган булалар, җитмәсә әле, катып-туңып бетүләренә карамастан, ерак юлга чыгарга ашкынып торалар... Ә ул Рәшидә дигәннәре тагын? Рәшидә... Рәшидә!.. Күпме мөлаемлык, җылылык, нәфислек, хәйләкәрлек, иркәлек бөркелеп тора аңардан!.. Һәм шулар, спектр аша үткән яктылык шикелле, төрле төсләргә кереп барысы берьюлы чагыла үзендә... Юк, чынлап та, нәрсә бу — аңа, Зөфәргә карата гына шулай юмартланып яктырдымы ул, әллә сүзен тыңлатыр өчен бары уйнап кына кылануы булдымы?.. Каян гына беләсең соң аны?.. Хәер, чибәр артистка юри кыланса да һич гаҗәп түгел! Токымнары белән шундый халык инде алар, ир дигән көчсез бәндәне үзләре өчен менә шулай йөгертә беләләр!

...Зөфәрнең бәхетеннән, сельпо председателе өендә булып чыкты. Ә бер сәгатьтән ике ат вокзал алдына килеп тә туктады. Чаналарның берсе җиңел кошевка, икенчесе киң үрәчәле гади чана иде... Һәркайсында икешәр толып та ята иде.

...Артистлар күтәренеп, шаулашып вокзалдан чыктылар.

Зөфәр аларга:

— Хәзәйкәнең самовары әзер, берәр стакан кайнар чәй эчеп чыгыйк, югыйсә юлда туңарбыз,— диде.

Ир артист, икеләнеп-пошынып:

— Бик шәп булыр иде дә ул, соңга калырбыз, чорт возьми! — диде.— Көтәләр бит безне анда...

— Ә без аяк өсте генә... Әйдәгез, толыпларны кимичә генә утырышыгыз!

Рәшидә, арада өлкәнрәкләре буларак, артлы чанага утырды. Калганнары үрәчәле чанага тезләнделәр. Зөфәр бер аягын читкә салындырып кына Рәшидә янына утырды. Самовар куеп торучы хәзәйкә өенә кузгалып киттеләр...

Анда, бик ашыкканга күрә, чишенмичә генә икешәр стакан сөтле кишер чәе эчтеләр. Берәү дә азык-төлеген чыгарып тормады. Булыпмы, булмыйчамы, Зөфәр моны белмәде дә. Дөрес, аның чемоданында шикәре дә, мае да бар, бер кирпеч икмәге дә бар иде, ләкин хәзер дүрт кеше алдына чыгарып куйсаң, валчыгы да калмаячак. Әлбәттә, ул мондый юмартлык күрсәтергә теләмәде.

Коры гына чәйдән дә бик хуп булып, аз гына җылынып, кызарып, безнең артистлар яңадан атлар янына чыктылар. Зөфәр аларга толыпларны өләшеп бирде, әйбәтләп, саламга күмелебрәк утырырга кушты. Рәшидәгә ул үзенең бәрән толыбын кидерде, чанага утырткач, аякларын салам белән күмештереп куйды. Рәшидә каршы сүз әйтү түгел, боларның барысын да нәкъ шулай булырга тиешле бернәрсә итеп кенә кабул итте... Зөфәр үзе, күп кенә җирдән эче иелеп беткән, тышсыз толыпны киеп, тар чанага кысылып һәм кызга борыла төшеп утырды да ат тотучыга кузгалырга кушты. Тимер табанлы чаналар сыкы кунган юл өстеннән, авыр ыңгырашып кына, кузгалып киттеләр.

Станция авылыннан чыгуга караңгы төшеп, күз тәмам бәйләнде. Җир өстен томанлы суык каплап алды. Тирәюньдә нәрсә бар, үр меңәләрме, сырт төшәләрме — аерырга һич мөмкин түгел иде. Тик аларның күз алларында, толып якасын баш түбәсенә хәтле күтәреп, кузлада утырган рус агаеның киң аркасы гына күренеп бара. Үле

тынлык, әйтерсең салкын томан бөтен җанлы-җансыз табигатьне, тавыш-өнне, тирән су төбедәй, каплап-йотып алган... Бары ара-тирә чана табанының авыр итеп чыжылдавы һәм атның пошкырып-пошкырып куюы гына ишетелгәли. Алар үзләре дә сөйләшмиләр, толып якалары белән капланып, җылы тыннарын эчтә сакларга тырышалар. Шулай да Зөфәр күршесе турында гел уйланып, уйланып кына түгел, ничектер аны тоеп бара. Бик якын, янәшә генә бит!.. Бу тою аңа тансык, рәхәт, ул аны гүя эчтән җылыта һәм кызга отыры якынайта кебек... Шуңадыр инде Зөфәр суыкны бөтенләй сизми диярлек, хәтта вакыт-вакыт эсселәнеп китеп, толыбын җилбәгәй ачып җибәрәсе килә, тик астыртын суык битне-борынны өшетеп ташлар дип кенә курка.

Шактый юл киткәч, Зөфәр әллә ничә кат кием аша Рәшидәнең акрын гына калтырануын сизеп алгандай булды. Өши күрәсең, дип пошынып уйлады ул, һәм толып якасын кайтарып, кызга иелә төшеп сорады:

— Нәрсә, сезгә суык үтә башладымы әллә?

— Юк, сизмим әле хәзергә,— диде Рәшидә, толыбы эченнән генә.— Ә нигә?

— Шулай тоелды миңа... Калтырыйсыз кебек...

Рәшидә, бераз дәшми торып, акрын гына әйтеп куйды:

— Ул болай гына... Эчтә җылы калмаган бер дә.

Зөфәр дөрес чамалап алды бу сүзләрнең мәгънәсен: җылы юк — димәк, озак вакыт рәтләп ашаган-эчкәннәре юк! Бәлки, алар бүген әле валчык та капмаганнардыр. Бер кишер чәе белән генә тәндә җылы саклап булмый шул! Зөфәр артистканы кызганып куйды һәм, юлдашларча кайгыртучанлык күрсәтәсе килеп, әйтте аңа:

— Бик өши башласагыз әйтегез, Рәшидә, ярыймы? Берәр чарасын табарбыз.

— Рәхмәт,— диде Рәшидә, ишетелер-ишетелмәс кенә.

Мондый суыкта кышкы юл аеруча озын булып тоела. Барып җитә алмыйча күзләр тона. Күпме киттек, күпме калды икән, дип, юлчы гел шул хакта гына уйланып бара. Рәшидә акрын гына эчкә үткән рәхимсез суыктан бөтенләй оеган кебек булды, селкенмәде, тавышын чыгармады, ә Зөфәр, аның өчен борчылып һәм әледән-әле башын сузып, алга карый башлады. Ниһаять, бер өч сәгатьтән соң алар сирәк-мирәк кенә утлары күренгәләгән караңгы Турайга барып керделәр. Авыл уртасындагы зур гына бер иске йорт каршысына җитеп туктадылар. Бу колхоз идарәсе иде. Чанадан иң элек Зөфәр төште. Ләкин калган юлчыларның берсе дә нигәдер кыймылдамый,

күрәсең, бик нык өшегәнлектән алар кузгалырга да куркып утыралар иде... Зөфәр, чаналарга карап, бераз таптанып торды да иелеп кенә Рәшидәгә дәште:

— Килеп җиттек бугай.

— Ә, шулаймы? — диде Рәшидә, авыр йокыдан уянган кешедәй сүлпән генә, һәм толып якасыннан башын чыгарды.— Алайса Яруллинны чакырыгыз әле монда.

Ләкин ул арада Яруллин дигәннәре, арткы чанадан төшеп, бөкрәеп һәм толып чабуларын җирдән сөйрәтеп, үзе Зөфәр янына килде.

— Кара әле, җаным,— диде Рәшидә аңа,— син үзең генә кереп әйт инде, безне иң элек фатирга илтеп куйсыннар.

— Ы, ыйе шыл! — диде Яруллин, өшегән авызын көчкә кыймылдатып, һәм алар Зөфәр белән идарәгә кереп киттеләр.

Унлы лампа белән тонык кына яктыртылган зур бүлмә уртасында аларны кыска тун, сырган чалбар кигән өлкән яшьтәге бер абзый каршы алды. Зөфәр сүзне үзе башлады:

— Председатель сез буласызмы?

— Мин булам.

— Исәнмесез! Менә артистларны алып килдем.

— Бик әйбәт. Көтәбез,— диде председатель, кул биреп.

— Башта аларны квартирага урнаштырасы иде.

— Һм... Клубта халык көтеп утыра бит... Нишлик икән, болай фатирыбыз әзер югыйсә.

— Безгә квартирага бармыйча ярамый,— диде Яруллин, сүзгә кушылып. — Әйберләрне куясы, өс-башны да алыштырасы бар, так што...

— Ярый алайса, түлке озак юанмассыз инде... Ничә кеше соң сез?

— Дүрт кеше,— диде Яруллин тиз генә, аннары Зөфәргә карап, сорап куйды: — Сез аерым төшәсездер бит?

Зөфәр беравык ни дияргә белмичә аптырап калды. Суйды бит бу юньсез үзенең урынсыз соравы белән!.. Нишләргә, ни дип әйтергә? Бер дә уйламаган иде Зөфәр бу турыда, дөресрәге, бергә килгәч, бергә булырбыз, дип, ничектер ваемсыз гына ышанып килгән иде... Инде менә чыга бел положениедән! Ә аның хәзер һич кенә ялгыз аерылып каласы килми иде, шуңа күрә ул аптыравын бер дә сиздермичә, кул селтәп кенә әйтеп куйды:

— Ярар, мин дә сыярмын әле шунда...

— Сыярсыз, өй иркен,— диде председатель һәм, караңгы почмакка борылып, дәште: — Мәчтүрә, бар, илт үзләрен Гыйззәт картларга.

Почмактан озын кара бишмәт, шәл өстеннән бүрек кигән бер апай күтәрелде. Якынрак килеп, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә җәһәт кенә карап алды:

— Бүтәннәрегез кайда соң?

— Тышта, чанада яталар әле,— диде Яруллин.

— Әйдәгез алайса!

Өчәүләшеп чыгып киттеләр. Апай алгы чананың күчәренә аякларын салындырып кына утырды. Кузгалдылар. Бер тар тыкрыктан икенче урамга чыгып, каракаршы салынган өйнең җилкапкасы төбенә килеп туктадылар.

Апай, капканың аркылы тыккан кендеген тартып, эчкәре узды да, болдырга менеп, ишекне дөбердәтә башлады. Шунда ук урамбаш өйдә басып кына куйган лампаны күтәрделәр булса кирәк, кечкенә тәрәзәсе сап-сары яктырып китте. Кемдер ишеккә чыкты.

— Мәликәттәй, кунакларны каршы ал! — дип кычкырды апай аңа.

Юлчылар, чаналарыннан төшеп, әйберләрен күтәреп, ашыга-ашыга ишеккә килделәр. Караңгы өйалдын узып, апайның: «Әйдәгез, монда»,— дигән тавышына ияреп һәм әллә никадәр суык иялртеп, өйгә кереп тулдылар. Аларны кечкенә буйлы бер әби каршы алды:

— Әй, Алла бәндәләре! Шәйхулла әйткән әртичләр сезмени инде ул?

— Без, әбекәем, без! Рәхимегезне боерып, кабул итәсез инде, булмаса! — диде Яруллин, дәртле күренергә тырышып.

— Итмичә ни, итәбез! Әйдә, узыгыз,уз, мескенкәйләрем!

Кызлар өсләреннән салып ташладылар да тиз үк зур җылы мичкә барып сөялделәр һәм, куллары белән генә түгел, битләре белән дә сыланып, калтырана-чиркана, җылынып азапландылар. Ләкин Яруллин шунда ук аларны ашыктыра да башлады:

— Ягез, кызлар, тизрәк булыгыз! Мич кочаклап торырга вакытыбыз юк, председатель абзый озак юанмаска кушты.

— Тукта, ашыктырма ул хәтле... Аз гына җылы керсен эчкә! — диде кызларның берсе, түше белән мичкә терәлеп, ә икенчесе еламсырап әйтеп куйды:

— Капкалап аласы иде бит, эчем эчкә ябышты инде, Ходаем, күпме түзәргә кирәк.

— Түзәбез инде, сылуым, түзәбез! — диде Яруллин, аны юатып.— Башкача мөмкин түгел, сәгать менә сигез тулып киткән.

Мичтән иң элек Рәшидә аерылды:

— Киттек, кызлар... Тизрәк башласак — иртәрәк кайтырбыз.

Аннары ул, әби янына барып, аны иңбашыннан кочаклап алды:

— Әбекәем, бәгырем,— диде балаларча юмаланып,— без кайтуга өй җылы булыр бит?

— Җылы булыр, кызым. Сез киләсен белгәч, бүген ике тапкыр ягып уздырдым.

— Менә рәхмәт, әбекәем!.. Без кайтуга кайнаган самовар да булыр бит?

— Анысы да булыр, кызым!

— Чәй янына әле, бәлкем, берәр җылы аш та булыр, ә, әбекәем? — диде Рәшидә, тагы да юмалана төшеп, һәм Зөфәргә хәйләкәр генә күз кысып куйды.

— Әй, татлы тел! — диде әби, кәефле генә көлеп.— Әмәлләрбез инде берәр нәрсә, әмәлләрбез сезнең кебек иркә кунакларга.

Рәшидә аны кысып үбеп алды да, җиңеләеп, шатланып, әйберләрен барларга тотынды. Кызлар кече якка кереп, сырган чалбарларын салып чыктылар. Өс-башларын рәтләп, әзрәк төзәтенеп алдылар. Биш-ун минуттан бары да әзерләнеп, кечкенә чемоданнарын кулларына алып, ә Яруллин гармун тартмасын иңенә асып, ашыга-ашыга чыгып та киттеләр.

Чыгар алдыннан гына Рәшидә Зөфәрдән сорап куйды:

— Сез безнең белән бармыйсызмыни?

— Мин... соңгарак,— диде Зөфәр, дусларча баш кагып кына.

Бөтен күргән-ишеткәннәре аның күңелендә бу тыйнак һәм чыдам артистларга карата гаҗәпләнү катыш соклану хисе тудырып өлгергән иде. Тагын ни беләндер аларга, бигрәк тә Рәшидәгә файдалы буласы килә иде. Рәшидәнең әледән-әле аңа игътибар итүе һәм дәшүе аны ихтыярсыздан дулкынландыра башлаган иде инде. Ул һаман бер нәрсә турында уйлана: нидән икән бу игътибар, нидән килә икән бу үз иткәндәй җылы итеп карау? Әллә чынлап та алар арасында яшерен якынлык җебе бер-берсенә сузылып өлгердеме?.. Ничек моны аңларга, ничек моны белергә?

Артистларның җилкапкадан кызу-кызу чыгып киткән аяк тавышлары тынуга, Зөфәр карчык янына килде һәм иплән кенә сүз башлады:

— Мәликә әби... шулай бит әле?

— Ийе, улым, ийе.

— Мәликә әби, үзең дә ишеткәнсеңдер, кызларыбызның көне буе ашаган-эчкәннәре юк бит... Өшеп-катып килделәр, әнә тагын валчык та капмыйча чыгып та киттеләр... Клубтан кайткач, бик әйбәт кенә ашатырга кирәк булыр инде үзләрен.

— Кирәк инде, кирәк. Тик менә аптыраган әле,— диде карчык, уйга калып.— Үзебез дә бик өзелеп торабыз шул, улым! Нишләрбез икән соң?

— Син, Мәликә әби, рәтлә инде, рәтлә... Тап бер җаен!

— Булмаганны каян табасың. Әнә Шәйхулла председателебез, сезнең киләсене белгәч, бербөтен икмәк белән азрак май җибәргән иде... Ул гына ни, йөрәккә ятмас шул. Булмаса, үземнән берәр чуен бәрәңге пешерермен... Нишлисең, хәзинәдә бары белән инде.

— Менә нәрсә, Мәликә әби, мин сине буш итмәм. Үзеңә азрак чәй-шикәр бирермен. Акчасын да түләрмен... Син инде безгә итле аш пешер... Итең бардыр бит?

Чәй-шикәр дигәнне ишеткәч, карчыкның колаклары торды. Күптән инде аның чын грузин чәен күргәне юк, ә чәй карчык кешегә әҗәл даруы белән бер инде ул! Әмма ит тә бик кызганыч, әүвәлге шикелле чоланда түшкәсе белән асылынып тормый... Шулай да бераз ыкмык итебрәк торганнан соң, ул йомшара төште:

— Шулпа тәмләндерү өчен генә тоткан итебез барын бар да бит, нишлим икән соң? Үзебездән өзеп бирергә туры килә инде...

— Син кызганма, әби! Итсез тормассыз әле... Әйтәм ич, буш итмәм. Ә чәй белән шикәрне, теләсәң, мин сиңа хәзер үк биреп куям. Минем күчтәнәчем булыр.— Һәм ул чемоданын алып ача да башлады.

Карчыкның икеләнүе, ниһаять, юкка чыкты:

— Ярый алайса,— диде ул, бердән юмартланып.— Яхшы кешеләрдән газиз җан да кызганыч түгел дигәндәй, булмаса, бер чирек каз турап өйрә пешерермен үзегезгә.

— Менә рәхмәт, әбекәем, менә рәхмәт! — диде Зөфәр һәм карчыкның кулына илле граммлы бер төргәк чәй белән биш-алты зур шакмак шикәр тоттырды.

Бу эшне җайлагач, Зөфәр клубка барырга дип ашыкмыйча уйланып кына киенә башлады. Билгеле, барасы килә аның, тик шулай да бер нәрсә борчый аны: ул белә, клубта торганы хатын-кыз булачак. Менә шул ирләре яки уллары фронтка китеп беткән хатын-кызларның инде аңа: «Бу нинди әвендәй тап-таза ир монда йөри?» — дип гаҗәпләнеп, шикләнеп, ят күреп караулары мөмкин. Бу нәрсәне аның авыл җиренә чыккан саен сизгәне бар...

Бер дә яратмый ул моны, һәм хатын-кызлар җыелган җирдән ераграк булырга тырыша торган иде... Әлбәттә, берәүнең дә аңарда эше булмаска тиеш, берәүдән дә ул куркып тормый торуын, ләкин шулай да ни өчендер борчылмыйча булдыра алмый иде. Менә хәзер дә ул шул хакта уйлап алырга мәҗбүр булды.

## III

Клуб дигәннәре урамга кырынрак утырган, манарасы киселгән иске мәчет бинасы икән. Ихатасы-мазары юк, тирә-ягы ап-ак кар яткан буш ялан... Киң генә такыр сукмак, урам юлыннан аерылып, клубның шул яланга караган болдырсыз ишегенә алып бара.

Зөфәр килеп җиткәндә аның тирәсендә кеше-кара күренми һәм хәрәкәт-тавыш ишетелми иде. Тик бозланып каткан кечкенә тәрәзәләрендә зәгыйфь яктылык, сары тап булып, тонык кына чагыла иде. Концерт инде күптән башланган булырга тиеш.

Зөфәр тышкы ишектән туп-туры тамаша «залына» барып керде. Ягылмаган, ярым караңгы бу «зал» халык белән шыгрым тулы иде. Бик еш итеп тезелгән озын, тар эскәмияләрдә туннан, сырмадан, шәл чорнаган, бүрекләрен батырып кигән, хәтта бияләйләрен дә салмаган хатын-кызлар, яшүсмерләр, бала-чагаларр тыгызланып утырганнар. Ара-тирә генә олы яшьтәге агайлар һәм карт бабайлар да күренә. Егетләр, ир уртасы кешеләр бөтенләй юк диярлек... Түрдәге тәбәнәк кенә сәхнәнең нәкъ алдында бердәнбер асылмалы калай лампа яна, бары шул гына сәхнә эчен һәм алгы рәтләрне азрак яктыртып тора...

Зөфәр килеп кергәндә сәхнәдә Яруллин, кыңгыраулы гармунын уйната-уйната, фашистлар турында такмак әйтә иде. Шуңа күрә Зөфәргә игътибар итүче дә булмады. Ул стена буйлап кына сәхнәгә таба узды да алгы эскәмиянең очына гына кысылып утырды.

Яруллин такмагын әйтеп бетерде, ләкин, ни сәбәптер, халык кул чапмады. Зөфәр аптырый калды: нидән бу, әллә ошатмадылармы? Алай дисәң, егет бик матур уйнап, бик дәртле җырлады бит! Халык шылт та итмичә тыңлап утырды. Хәер, моның сере бик тиз ачылды: монда кул чабу гадәте юк икән, монда артистны киеренке бер җитдилек белән гаять бирелеп тыңлыйлар һәм шунлыктан кул чабуны хәзерге авыр шартларда килешми торган бер уен-балалык дип саныйлар икән... Әгәр артист-

ның чыгышы ошаса һәм аны яңадан чыгарасылары килсә, моны төрле яктан кычкырып, туп-туры үзенә әйтәләр икән... Яруллин җырлап беткәч тә нәкъ әнә шулай булды — аз гына тынып торганнан соң, кешеләр тойгы-теләкләрен төрле яктан кычкырып әйтә башладылар:

— Рәхмәт, туганкай, рәхмәт!

— Ачтың күңелләребезне!

— Кабатла әле тагын бер генә, кабатла!

— Сорыйбыз, сорыйбыз!

...Яруллин бер-ике тапкыр баш иде дә, киерелә биреп, гармунын тартып куйды. Халык шунда ук тып-тын булды. Алар гаҗәп тыйнак, әдәплеләр иде.

Бу юлы артист, гармунына кушылып, бик моңлы гына бер авыл көен җырлады:

Борыламын да карыймын
Су юлы миләшенә;
Күтәрмен, бәгырем, карамый
Ятларның киңәшенә.
Коела миләш чәчәге
Чиләккә, суларыма;
Күзләрем алмый карыймын
Кайтасы юлларыңа.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Зөфәрнең артында гына бер кызмы, яшь хатынмы бик тыелырга тырышып, ләкин тәкате җитмичә иелеп төшеп үкси башлады. Аңа ияреп тагын кайберәүләрнең ихтыярсыздан сулкылдап куюлары ишетелде. Ә бер олырак яшьтәге хатын йөрәгеннән бәреп чыккан тирән әрнү белән өзгәләнеп әйтеп ташлады:

— Ай, газизләрем! Тилмереп, кан җылап көтәбез шул, көтәбез!

Аңа каршы ниндидер бер агай басынкы тавыш белән акрын-йомшак кына: «Сабыр, килен, сабыр!» — дип куйды.

Җыр бетте. Караңгыда утырган халык бер мизгел тып-тын булып торды. Әйтерсең алар хыяллары белән бу иске мәчет эченнән бик еракка иң кадерле якыннарын, өметләрен, бәхетләрен эзләп киткәннәр иде. Һәм гүя әнә шул ерактагы фронтның карлы далаларына, бозлы сазлыкларына, кара урманнарына барып тапкан, кавышкан газиз якыннарыннан аерыла алмыйча, кире бу салкын ялгызлыкка кайтырга кодрәтләре җитмичә утыралар иде.

...Әйе, мондый хәлдә ду килеп кул чабу мөмкин дә түгел иде. Күпмедер вакыт үткәч кенә хатын-кызлар рәхмәтләрен әйтеп, Яруллиннан тагын кабатлавын үтенделәр. Ләкин монда артист белән тамашачылар арасын-

да бик табигый гади генә мөнәсәбәт урнашкан иде. Бернинди артык кысташу, шаулашу юк. Артист кулын күтәрдисә, барысы да шунда ук тыналар, ул ни әйтсә, шуңа берсүзсез риза булалар. Әле дә Яруллинның шаярып кына ялваргандай: «Апайлар, җиңгиләр, минем дә хәлемә әзрәк керегез инде, менә... эһем-эһем, тамагым чистый кипте бит, җитмәсә, безгә монда чиләк белән су да куярга онытканнар... Ләкин сез тыныч булыгыз, мин әле сезгә уйнармын да, җырлармын да... бүген кич безнеке ич!» —диюенә каршы, хатын-кызлар: «Ярый алайса, ярый, үзеңә кара инде, җаным!» — дип, шунда ук килештеләр һәм тынып та калдылар.

Хәер, бу ару-талуны белмәс артистның сәхнәдән чыгып торган чагы булмады диярлек — ул бер үк вакытта кемнең чыгасын әйтеп торучы да һәм чыккан берсенә алмаш-тилмәш ике гармунда уйнап торучы да иде. Хәзер дә менә ул сәхнә түренә таба бер-ике генә адым атлаган булды да, кире борылып килеп, үзенең яңа ролен үтәргә тотынды:

— Инде, кадерле апалар, җиңгиләр, сеңелләр, күңелләрне дә бер ачып җибәрик, башлар күтәрелә төшсен!.. Яшь артистларыбыздан Асия Биктимерова белән Зөбәйдә Саттарова. Төрле халык биюләре... Башладык!

Сәхнәнең ике як кырыена эленгән иске чаршау артыннан берсе авыл кызы, икенчесе авыл егете булып киенгән биючеләр йөгереп чыктылар. Башта куышып китеп, аннан кара-каршы торып, тыпыр-тыпыр бии дә башладылар. Бусы татарча булды. Шуннан соң, киемнәрен алыштырмыйча гына, егете бөеренә таянып, кызы иңбашын уйнаткалап һәм бармак шартлаткалап, икесе дә «ысс... ыс» дигән сәер бер тавыш чыгарып, башкортча биеп күрсәттеләр. Бусы да матур-шома гына килеп чыкты. Моңардан соң алар, чаршау артына яшеренеп кенә, берсе алъяпкычын салып, яулыгын косынка итеп бәйләп, икенчесе тиз генә камзулы белән түбәтәен ташлап һәм башына фуражка каплап чыктылар да, тузанлы идәнне бик яман дөбердәтеп, «эх, эх!» дип кычкыра-кычкыра биергә тотындылар. Бусы инде русча «Барыня» иде.

Яшь артистлар халыкның сораганын көтеп, кыстатып тормадылар — бөтен «репертуарларын» бер тоташтан күрсәтеп бирделәр. Һәм, чыннан да, кәефләрне беркадәр үзгәрттеләр дияргә ярый; тамашачыларның йөзләре яктыра төште, күзләрендә дәрт сыман нәрсә кабынды, хәтта биючеләр куптарган тузаннан клуб эче дә ничектер җылыныбрак киткән төсле булды.

...Биючеләрдән соң сәхнәгә, ниһаять, Рәшидә чыкты.

Зөфәр бөтен игътибарын биреп, йотлыгып караган хәлдә аны каршы алды һәм, ул сәхнәдән чыгып киткәнчегә чаклы, аңардан инде күзләрен аера алмады. Шушы минуттан барысы да — караңгы, салкын клуб эче дә, янәшәсендә генә тыгызланып утырган тамашачылар да, хәтта гел күз алдында селкенеп торган Яруллин да аның өчен югалган кебек булды.

Рәшидәнең өстендә киң итәкле, тар җиңле, ябык якалы кара-зәңгәр озын күлмәк иде. Бу күлмәк аның билен бик нечкә, күкрәген тулы, иңбашларын йомры итеп күрсәтә иде. Әйтәсе дә түгел, артистка, ябыклыгына карамастан, нәфис-сылу гәүдәле иде — Зөфәр иң элек менә шуңа игътибар итте. Аннары бераздан ул чын гаҗәпләнү белән тагын шуны күреп алгандай булды: әлеге төрле хисләр чагылышы артистканың тиз үзгәрүчән ак йөзендә генә түгел, гүя менә сылу гәүдәсендә дә сизелә кебек, ничектер менә гәүдәсе дә аның хис белән тулы һәм һәрбер хәрәкәтеннән моны тоеп була кебек иде.

Менә ул, җиңел генә атлап, сәхнәнең кырыена ук килеп басты. Өшүдәнме, дулкынланудanмы, иңбашларын җыерып куйды, башын текә генә күтәреп, асылмалы лампага карап алды, аннары гадәтенчә туп-туры төбәлеп, шылт та итмичә көтеп утырган халыкка беравык карап торды, бары шуннан соң гына борыла төшеп һәм башын чак кына кагып, Яруллинга ишарә ясады.

Яруллин кычкырып: «Татар халык көе «Тәфтиләү» — диде һәм утырып зур баянын акрын гына суза башлады. Рәшидәнең күзләре берьюлы уйчанланып, ничектер эчкәре киткән кебек булды, йөзенә моңсу җитдилек чыкты — һәм менә һичкемне, һичнәрсәне күрмәс булып, саф, нечкә тавыш белән җырларга тотынды... «И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?» ...Бу көйнең моңын һәм бу сүзләрнең мәгънәсен телдән генә әйтеп биреп бетерерлек түгел иде. Бу көйгә, бу сүзләргә бөтен бер зур халыкның гүя барлык йөрәк зары, саф вөҗданы, ачы нужасы, авыр хезмәте, кара бәхете, якты өмете, кырлары-яланнары, таулары-урманнары, күлләре-сулары, сандугач-былбыллары, караңгы көзләре, язгы таңнары — барысы-барысы бергә җыелган, бергә үрелгән, бер киң дәрьяга әверелеп ага да ага иде... Тамашачы да гүя менә шуның дулкыннарында тирбәлә-тирбәлә агып китте. Барысы онытылды, барлык фани уйлар «дөнья читлегеннән» каядыр бик биеккә, бик еракка очты... Җырның беренче сүзләре үк инде тамашачы күңеленең иң нечкә кылына барып кагылды, исертте-сихерләде, һәм күпләрнең күзләреннән, үзләре дә сизмәстән, җылы яшьләре агып

төште. Бу гади елау түгел иде, бу күңелләр төбеннән күтәрелгән бик изге, бик кадерле олы бер хиснең саф чишмәдәй саркып чыгуы иде.

Җыр беткәч тә кешеләр өнсез калгандай, һич селкенмичә, тып-тын утырдылар. Рәхмәт белдереп, яңадан кабатлауны сорап кычкыручы бер генә кеше дә булмады, хәер, бу кирәкми дә иде. Шушы өнсез утыру, шушы яшьтән чыланган йөзләр һәм сихерләнгәндәй җырчыга хәрәкәтсез төбәлгән күзләр барысының да күңелләре ни белән тулганын бик ачык әйтеп тора иде... Һәм Рәшидә, көчле алкышка рәхмәтен белдергәндәй, аларга яктырып елмайды, хәтта аз гына башын да иеп куйды. Ул әле җырлаячак иде, дәртләнеп, шатланып җырлаячак иде.

...Яруллин торып: «Юксыну»,— диде һәм, кире утырып, баянының нечкә телләренә басып кына тавыш бирде. Рәшидә яктыга үрелгәндәй йөзен күтәреп, бөтен гәүдәсе белән алгарак омтыла төште һәм уң кулын күкрәгенә якын китереп, шуннан сосып алгандай тирән сагыш-моң белән җырлый башлады:

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Бу — соңгы вакытларда гына халык арасына таралган һәм бик тиз арада күңелләрне биләп алган җыр иде. Көе аның композиторныкы, сүзләре — шагыйрьнеке, әмма халыкның үз иҗаты шикелле телдән телгә күчеп, бөтен җирдә җырлана башлаган иде. Вакытның рухын, кешенең күңеленә тулганын әйтеп бирә белгән җыр гына мондый бәхеткә ирешсә ирешә торгандыр...

...Менә хәзер дә Рәшидә авызыннан чыккан «Юксыну» тыңлаучыларга аларның үз юксынуы, үз сагышы, үз зары булып ишетелде. Бердән алар җырга йотылдылар, бары бер кодрәткә — бер исерткеч тойгыга буйсынган шикелле җырчыдан күзләрен аера алмыйча, аның һәр сүзен аңлап, йөрәкләреннән кичереп утырдылар. Хатын-кызлар арасыннан тагын кайберәүләре, сагыш белән тулы күңелләре чайкалып түгелгәндәй, тәкатьсездән үкси башладылар.

Хәтта Зөфәрне дә бу җыр тетрәтмичә калмады. Дөрес, аның юксыныр кешесе юк иде, сугыш китергән михнәтгазап аның күңеленә авыр таш булып ятмаган иде, әмма шулай да янындагы кешеләрнең тирән кичереше аңа да күчте булса кирәк — берара бугазы төбенә каты төер ки-

леп тыгылды. Ләкин бу төерне ул ничек тә йотарга тырышты, чөнки бу минутта Рәшидәнең акрын гына кыймылдаган тулы иреннәре, тирән илһамлану белән балкыган йөзе, аз гына дымланып каядыр еракка төбәлгән күзләре аның өчен үзе бер җыр, үзе бер сихер иде.

...«Юксыну»дан соң «Туган ил», «Хатлар язам», «Сибелә чәчәк», «Яз да була», «Арча», «Шомыртым», «Эрбет», «Фирдәвескәй», «Сания» — берсе артыннан берсе агылып кына торды. Рәшидәнең бу кадәр армый-талмый җырлавы гаҗәп иде. Киресенчә, яңа җыр башлаган саен үзе ул ничектер рухлана, дәртләнә, ә тавышы отыры көчәя, иркенәя барды. Инде соңгы җиңел җырларга күчкәч, ул, тәмам канатланып киткәндәй, иңбашларын җиңел генә уйнатып, тибрәнеп, талпынып җырлады. Һәр җыры аның тыңлаучыларны беткәнче биләп алды; моңландырды да, уфтандырды да, кабындырды да һәм күз яше аша көлдерде дә ул аларны!

Иң соңгы җырын аеруча бер ялкынлану белән башын артка чөя биреп, кулларын җәеп, аяк очына күтәрелә төшеп җырлап бетерүгә, Рәшидә үзе дә исереп киткәндәй чайкалып куйды һәм күзләрен йомып, кулын маңгаена куеп, беравык хәрәкәтсез калып торды. Шул чакта халык аны рәхмәт-мактау сүзе белән күмеп ташлады:

— Яшә, чибәркәй, мең яшә!

— Безнең сынык күңелләребезне юаттың-куандырдың, рәхмәт төшсен үзеңә!

— Былбыл да син , син дә былбыл икәнсең!

— Безнеке кебек сугыш кырларында йөргән ярың булса, исән-сау кавышырга насыйп итсен!

Рәшидә сискәнеп уянгандай күзләрен ачты, ни ишетәм дигән төсле бер мизгел аптырап-югалып торды, аннары кичерү сорагандай нәүмиз генә елмаеп, ике кулын да күкрәгенә куеп, халыкка кат-кат башын иде... Һәм иң соңгы минутта гына, әллә сөенечен аңлатырга теләп, әллә бүтән бер серен сиздерәсе килеп, ул нурлы күзләре белән Зөфәргә ничектер җылы-якын да, аз гына хәйләкәр дә итеп карап алды. Бу караштан Зөфәр тагын эсселәнеп китте, тагын, ни уйларга да белмичә, аптырап калды.

...Концерт бетте. Халык, тар эскәмияләрдән торып, акрын гына тарала башлады. Бер төркем кызлар, турыдан гына атлап, сәхнәгә, артистлар янына менделәр. Колхоз председателе, карсак буйлы, зур башлы Шәйхулла абзый, Яруллин янына барып аның кулын кысты, ә Яруллин аңа, кызып, кулын болгап нидер сөйләргә тотынды.

Зөфәр, халыкның чыгып беткәнен көтеп, стена буенда ялгызы гына басып торды. Бик гаҗәеп һәм бик көчле

тәэсир калдырды бүгенге концерт аңарда... Әлбәттә, Казанда аның сирәк-мирәк кенә концертларда булгалаганы бар иде, әмма моның кебекне гомерендә һич күргәне юк иде. Дөресен генә әйткәндә, сәнгатьнең нинди зур кодрәткә ия булуын ул бары менә шушы салкын, караңгы, иске мәчет эчендә генә күрде, аңлады, хәйран калды... Юньләп исемнәре дә билгеле булмаган, болай карап торырга йолкыш кына дүрт артист халыкны нишләтте? Гаҗәеп бит бу, гаҗәеп!.. Халык гүя ач булуын, ялангач булуын, нинди авыр михнәттә яшәвен тәмам онытты; елады, көлде ул, һәм иң гаҗәбе — тирән рухи бер канәгатьләнү алып, гүя эчләренә тагы да зур сабырлык, чыдамлык, батырлык җыеп таралды ул!.. Инде кайткач, һәркайсы коры чәен, иписез бәрәңгесен тыныч кына ашап-эчеп ятачак. Менә, нишлисең, рәхимсез сугыш китергән нужаны күтәрер өчен һәм сыгылып төшмичә яши-эшли алыр өчен кайчагында кешегә үзебезнең җыр, гади халык җыры да искиткеч зур көч-кодрәт бирә икән.

...Кайтырга чыктылар... Чалт аяз күктә түп-түгәрәк һәм ап-ак тулган ай тора. Шундый якты-якын ул —өстендәге әлеге көянтә-чиләкле кызны хәтерләткән күксел шәүләсе ап-ачык күренә һәм, бик теләгәндә, шуңа ничектер менә барып җитеп булыр иде кебек тоела... Шыгырдап торган коры салкын... Авыл өсте зәңгәрсу-якты... Чатнап бүрәнә шартлаганы ишетелеп кала... Салкын тешкә тия, өскә сылана, әмма эчкәре үтәргә бик ашыкмый кебек... Атлавы җиңел, аяклар үзләреннән-үзләре йөгерергә торалар.

Алдан, өч артистканы озатып, кызлар төркеме китте. Алардан бер илле адым арттарак калып, Яруллин, колхоз председателе һәм Зөфәр шагыр-шогыр атлыйлар... Яруллин бияләе белән авызын каплабрак, председательгә бертуктаусыз сөйләп бара (клубта ук башланган сүзнең дәвамы булса кирәк):

— Анысы шулай инде аның, Шәйхулла абзый... Халык канәгать булып калса, безнең өчен дә зур шатлык ул, конечно... Артистны шул яшәтә, шул йөртә бит инде. Так что ул яктан без үзебез дә бик канәгатьбез... Ну шулай да, Шәйхулла абзый, син — председатель, ә мин шушы кызларны ияртеп, аларга баш булып йөрүче бер кеше: давай, ачык кына сөйләшик әле. Тыйнакланып, оялып тора торган чак түгел. Гаеп итмә! Озын сүзнең кыскасы, син инде безне, абзый кеше, коры рәхмәт белән генә сыйлап җибәрмә, ярыймы!

Председатель бияләй сырты белән бәсләнгән мыекларын сыпырып куйды:

— Нишләп коры рәхмәт кенә булсын! Түлибез, дидем ич, иртәгә акчасын сполна алырсыз.

— Һәй, Шәйхулла абзый, нигә инде юри аңламаган булып кыланасың? Ул хактамыни сүз? Акча, имеш! Ә беләсеңме, артистның шушы концерт өчен алган акчасы, Казанга кайткач, бер кәтелүк бәрәңгегә дә җитми бит. Шуның өчен өшеп-катып ачлы-туклы йөрсенмени ул?

Шәйхулла абзый нигәдер җавап бирмәде, Яруллин да бераз дәшмичә барды... Артистларны бәхилләтү мәсьәләсе хәзер генә булып үткән бик күркәм эшнең шактый күңелсез ягы иде, билгеле... Ләкин моның шулай булуына Зөфәр бер дә гаҗәпләнмәде, район тирәсенә чыккан һәрбер кешенең ничек тә азык табарга тырышуын ул бик яхшы белә иде, шуңа күрә Яруллинның да «теләнүен» бик хаклы дип тапты һәм аны яклыйсы килде:

— Әйе, халыкка мондый зур хезмәт күрсәтүчеләрнең бәясен белергә кирәк,— диде ул, җитди генә.— Колхозның келәте бөтенләй бушап калмагандыр әле, Шәйхулла абзый, саранланып тору килешмәс!

Шәйхулла абзый авыр гына сулап куйды:

— Һи, туганнар, булса, кем саранланып торыр иде... Барысын да биреп бетердек бит, барысын да кырып-себереп... Үзегез дә беләсез хәлләрне... Дөрес инде, сезнең кебек тансык кунакларны буш кул белән генә озату килешеп бетмәс, анысын үзем дә уйлаган идем уйлавын, тик әле безнең крестьян гадәтен беләсез — алдан кычкырырга яратмый ул... Ярый, хәерле булсын, кәнсиртегез бик ошады, бәхилләтми ярамас. Түлке он өмет итмәгез, он юк, иллә-мәгәр ит-майдан бераз күчтәнәч куярбыз.

— Менә рәхмәт, Шәйхулла абзый! — диде Яруллин, бердән җанланып.— Безгә ни генә бирсәң дә бата, талымланып тормыйбыз, рәхмәттән башка сүз юк, вәт шул! Тик син гаеп итә күрмә инде, яме? Нишлисең, положение!

— Беләм, туган, беләм! — диде председатель, башын кагып.

Артистлар төшкән йорт каршына килеп туктадылар. Бу суыкта озак басып торырлык түгел иде, Шәйхулла абзый, ике куллап бүреген батыра төшеп, китәргә җыенды.

— Элекке чак булса, болай гына аерылышмас идек, әзер табынга кайтып, бераз чәйләп-мәйләп утырыр идек тә бит, ни, үзегез әйтмешли, плаженья! — диде ул, көлемсерәп.— Ярар, соңгы очрашу булмас әле, иминлек кенә кайтсын!

— Һии, дошманны җиңгәч — иминлек кайткач, балда-майда йөзәрбез әле, Шәйхулла абзый!

— Алла бирсә! Ярар, хәзергә хуш иттек!

— Хуш, Шәйхулла абзый, хуш!

Председатель китеп баргач, Яруллин өйгә керешли, Зөфәр алдында махсус акланырга теләгәндәй, ашыгып әйтеп куйды:

— Саран, чукынган карт! Сорамасаң, үзе белеп бирәсе түгел. Ә соңыннан кызлар мине битәрләргә тотынырлар. Үзем өчен генә булса, сорап та тормас идем.

Зөфәр моңа каршы бер сүз дә әйтмәде — егетнең хәйләсе бик өстә ята, шуңа күрә эченнән генә тынды.

Алар өйгә килеп кергәндә, кызлар өсләреннән салганнар, зур калай тазга яньчелгән җиз комганнан берберсенә җылы су коеп, кулларын юып торалар иде. Өстәлгә киҗеле ашъяулык ябылган, тәлинкә-кашыклар һәм түп-түгәрәк бөтен бер икмәк куелган иде.

Егетләр дә чишенеп ташладылар, кулларын юдылар, аннары барысы да өстәл янына уздылар. Яруллин утырмыйча ук кулына тизрәк пычак алды.

— Каяле, ипекәйне, күкрәккә терәп, үзем телим әле булмаса,— диде ул, изге бер эшкә тотынгандай тантана белән.

Ә кызларның берсе, балаларча түземсезләнеп, кулын чәбәкли башлады:

— Әбекәй безне ни беләндер сыйлый, ни беләндер сыйлый! Сизәсезме, исе таралган! Әллә каз маенда пешкән ботка инде?

Казан янында торган әби, сабыр гына елмаеп:

— Әз генә түзегез, кызлар, әз генә,— диде.— Хәзер белерсез.

Зөфәр барысыннан соң гына өстәл янына килеп утырды. Ничектер үзлегеннән аның урыны тагын Рәшидә белән янәшә туры килде. Гүя менә язмыш үзе алар турында кайгыртып кына тора диярсең!

Яруллин һәм кызлар ипи телемен тозлап ашарга да тотындылар. Тик Рәшидә генә сузылмады.

— Туктагыз әле, нигә коры икмәккә ташландыгыз? — диде ул.— Яруллин, безнең бит маебыз булырга тиеш.

— Ә, ийе, ийе,— диде Яруллин һәм, тиз генә торып, бер бәләкәй капчыктан ике төргәк алып китерде. Берсе аның кәгазьгә төргән атланмай кисәге, икенчесе — чүпрәккә төргән дуңгыз мае — шпик булып чыкты. Ләкин атланмай шакылдап туңган, пычак та үтәрлек түгел иде... Ә шпик туңмаган, Яруллин аны вак кына телемнәргә кискәләде.

— Менә инде, кызлар, телисезме-юкмы, шушы тырышып чаба торган хайванны авыз итеп карыйсыз. Коры икмәк кенә үтмәсә, конечно...

Зөфәр дә чемоданнан үзенең азыкларын — зур гына кисәк пешкән итен, савыты белән маен, кап белән шикәрен чыгарып, өстәл уртасына куйды.

— Һу, болай булгач, лафа! — диде Яруллин, кулларын угалап.— Бүген туй итәрлек сый бар икән бездә...

Кызлар чыркылдашып көлеп җибәрделәр — аларның кәефләре ни сәбәптәндер бик күтәренке иде, юктан да көләргә генә торалар иде. Зөфәр исә, нигәдер кызара төшеп, бары елмайган булды.

Шул арада Мәликә әби өстәлгә олы табак белән аш китереп куйды. Яруллин шунда ук кашык тыгып аны бутап карады.

— Өйрә! Валлаһигазим, өйрә! Җитмәсә, каз өйрәсе!

— Боты миңа, боты миңа! — диде әлеге түземсез кыз, сикергәләнеп.

— Синең үз ботың да бик шәп! — диде Яруллин аңа.

Кыз авызын сузып кына: «Һи, оятсыз!» — дип куйды, бер мәлгә нәүмизләнеп калды, ләкин чынлап ачулана белмәде тагын; дөрестән дә, бала табигатьлерәк иде бу түгәрәк битле, яшькелт-соры күзле биюче кыз... Ә Яруллин, аңа һич игътибар итеп тормастан, гаҗәпләнеп шаулый бирде:

— Юк, чыннан да нинди күк капусы ачылды соң әле бүген безгә, әбекәем, ә?

— Менә дәү абыегыз сезнең өчен тырыштырды инде,— диде карчык, күзе белән генә Зөфәргә ишарәләп.— Аның сые бу, рәхим итегез!

Барысы да Зөфәргә беркадәр аптырап та һәм шуның белән бергә ихтыярсыз куанып-яратып та карадылар. Рәшидә исә аеруча бер дикъкать һәм җылы соклану белән аңа бөтенесеннән дә озаграк карап торды шикелле... Кызның янәшәсендә генә кырын утырган Зөфәр бу карашны бик ачык тойды, әмма тынычлыгын сакларга һәм мәсьәләне уенга әйләндерергә тырышып:

— Барыгыз да ашыгып чыгып киттегез ич! — дигән булды.— Шулай итеп, теләсәм-теләмәсәм дә, әби белән эшне миңа җайларга туры килде... Рәхмәтебезне аңа әйтик, югын бар итеп дигәндәй, әзерләде менә.

— Рәхмәтебезне икегезгә бүлеп бирәбез, шулай дөресрәк булыр,— диде Яруллин, урыныннан торып.— Йә, кайсыгыз соса башлый?

— Үзең инде, үзең,— диделәр кызлар.

— Бисмиллә алайса! Тотыгыз тәлинкәгезне, кем, Зөфәр иптәш, шулай бит әле?

Зөфәр башын кагып кына раслады да Рәшидәнең тәлинкәсен алып сузды. Рәшидә, «кирәкми» дигәндәй, тәлинкәсенә үрелеп куйды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

— Әһем, әһем! — дип тамак кыргалады Яруллин.— Бусы да бик дөрес!

Бер уңайдан ул калган кызларга, шуннан соң гына Зөфәргә һәм үзенә аш салып чыкты. Шул чакта Зөфәр күптән күңелендә булган бер нәрсә хакында уйлап алды: тәкъдим итсәм, килешерме-юкмы, Рәшидә ни дияр? Аннары икеләнебрәк кенә әйтте:

— Беләсезме нәрсә: без инде юл килгән кешеләр, өшедек тә, ачыктык та, әллә, мин әйтәм, аш алдыннан аппетит өчен генә, теге ни, шифалы суны кабып алабызмы? Ничек уйлыйсыз?

Шунда ук күбесе сүзнең нәрсә турында барганын төшенеп алсалар да, бер мәлгә аптырашып калдылар. Бу алар өчен хәзерге шартларда артык дәрәҗәдә көтелмәгән бер тәкъдим иде. Яруллинның күзләре берьюлы түгәрәкләнеп китте, ә теге кыз чын гаҗәпләнү белән ашыгып сорады:

— Нинди шифалы су ул, абый?

— Улмы?.. Ул ни... спирт, чип-чиста спирт... бераз гына бар иде.

— Һии, агай-эне! — дип кычкырып ук җибәрде Яруллин, бөтен бите-күзе белән көлеп.— Сорап торасың тагын!.. Чыгар үзен, чыгар, дустым! Нәкъ инде менә шул зәмзәм суы гына җитми иде безнең бу табынга...— Һәм ул, учына төкереп, кулларын угалый да башлады.

— Син шауламале! — диде Рәшидә аңа, тавышын әкренәйтеп.— Әбидән яхшы түгел.

— Рәшидә, май кап!

Зөфәр, торып, пальто кесәсеннән флягасын алып килде. Анда юлчыларга эчергәннән соң калган яртыдан күбрәк спирт бар иде әле. Әбидән, «дару эчәргә» дип, чокыр һәм бер чүмеч салкын су сорап алдылар.

...Эчүне дә тагын Рәшидәдән башладылар. Зөфәр чокырга яртылаш спирт салды, Яруллин су белән тутырды. Рәшидә, «куркам» дип, җилкәсен генә җыерып куйды, ләкин карышып, кыстатып тормады. Әбинең кече якка узганын көтеп алды да, тиз генә чокырны күтәреп, беткәнче эчеп тә җибәрде... Ул чыраен сытмады, тик авызын ача төшеп, сулыш алмыйча торды, күзләренә мөлдерәп яшь килде һәм, ниһаять, ике куллап йөзен каплады...

Калган кызларга да шулай салып бирделәр. Бик батыраеп эчкән булдылар кызлар, ләкин эчүгә, кармак йоткан балык шикелле, сынсыз калдылар. Берсе хәтта «аһ!» дип тә куйды.

Яруллинга инде Зөфәр чокырны тутыра язып салып бирде. Артист, эчүнең югары классын күрсәтергә теләп булса кирәк, спиртны су кушмыйча гына бик тыныч кыяфәт белән эчеп җибәрде. Шунда ук чүмечкә капланды, чәчи язды, бөтен бите җыерылып килде һәм, борыны пешкән мәчедәй «пырых-пырых» итеп, башын чайкап торды... Кызлар, бөгелә-сыгыла, шаркылдап көләргә тотындылар:

— Утлы күмер йоттыңмы әллә, Яруллин абый-ый?

— Ничева! — диде Яруллин, сер сынатмаска тырышып, һәм кулы белән битен бер сыпырган иде — иске кыяфәтенә кайтты да куйды.

Артистның «пешүеннән» файдаланып, Зөфәр үзенә чокыр төбенә генә салды да шуны тиз генә су белән тутырды... Кызлар көлешеп туктагач, ул чокырын күтәреп, башлыча Рәшидәгә ымлап, ләкин барсына да әйткән төсле итеп: «Сезнең саулыкка, кызлар!» — диде дә ашыкмыйча гына эчеп бетерде... Шушы кечкенә нәрсә дә аның авторитетын кызлар алдында тагын да күтәрә төште: әйе, әдәпле дә ул, игътибарлы да ул, үзен әнә ничек тота да белә, эчә дә белә... Кыскасы, сабыр, тыйнак һәм бик акыллы булырга тиеш бу зур, таза, юмарт абый!

...Фляга төбендә аз гына калганын Зөфәр Рәшидәгә салмакчы булган иде, ләкин йөзе мәк чәчәгедәй кызарып, кечкенә күзләре томаланып киткән Рәшидә ике кулын берьюлы күтәреп каршы төште:

— Юк, юк, кирәкми!

Хәер, кызларга бик җиткән иде, ач карынга эчкән ярты гына чокыр спирт аларны кинәт кенә исертте дә куйды. Шулай итеп, калганын Яруллин кыстатмыйча гына эчеп бетерде.

...Бер тын каз өйрәсен бик тәмләп, йотлыгып ашадылар. Тәлинкәләре ялт иткәч, тагын өстәп салдырдылар. Көне буе үт җыеп буш яткан һәм спирттан котырынып киткән ач карын һич кенә туя белмәс кебек иде... Тиз арада зур табакны «каплап» куйгач, Яруллин икмәк белән шпигын «бөгә» башлады, кызлар тарсынып кына булса да Зөфәрнең итен капкаларга тотындылар. Тик Рәшидә генә һаман тыелып маташты. Зөфәр аны гел кыстый торды, ахырда үзе бер кабырганы алып, аның кулына тоттырды.

— Менә бу кызларга ярый, ичмасам! — диде Яруллин, авызы тулы килеш.— Ату бот, имеш!

— Белмисең икән шул,— диде Рәшидә, сыңар кашын гына сикертеп.— Кызларга канат бирәләр.

— Ни өчен канат?

— Тизрәк кияүгә китсен өчен.

— Ә-ә! Ну, белмим, канат түгел, пропеллер куйсалар да тиз генә китә алырсызмы икән, ай-һай! Җәтмәдәге балык төсле сөзелеп калдыгыз бит.

Кызлар дәртсез генә көлештеләр, ә Рәшидә ваемсыз гына әйтеп куйды:

— Насыйбы табылыр әле.

Шушы сөйләшүдән күпмедер соңрак Зөфәр үзенең беләгенә Рәшидәнең, әллә юри, әллә ялгыш кына, иңбашы белән орынуын сизеп алды. Кинәт кенә егетнең йөрәгенә җылы кан йөгерде, бик рәхәт булып китте аңа... Менә шулай озак кына терәлеп, дулкынландырып торуын теләде ул аның... Үзе исә, гүя якын ук килгән асыл кошны куркытмас өчен, артык хәрәкәт ясаудан тыелып, тик кенә утыра бирде.

Әби тәлинкә-кашыкларны җыеп алгач, өстәлгә чәшкеләр тезде, Шәйхулла абзый җибәргән бер йомарлам майны да китерде, аннары кайнап торган самоварны китереп куйды... Әбинең үзен дә чәйгә утырттылар. Сөйләшә-сөйләшә чәй эчәргә тотындылар. Кәефләр яхшы иде, тамак туеп, күңелләр көрәеп, хушланып киткән иде. Сүзнең төрлесеннән гәп күп булды. Зөфәр бүгенге концертны искә төшереп, артистларны, аеруча Рәшидәне мактады. Шушындый авыр бер вакытта халыкның җырны, уенны искиткеч яратуына чынлап гаҗәпләнүен әйтте. Моның сере нәрсәдә икән, диде.

— Халыкта тормышка мәхәббәт бик зур, менә аның сере нәрсәдә,— диде Яруллин, мәгълүм бер хакыйкатьне әйткән төсле өзеп кенә.

— Яхшы, шулай да булсын, ләкин бит җыр тыңлап утырыр өчен кайгы-хәсрәт, авырлыкларны онытып торырга кирәктер, минемчә.

— Җыр үзе инде барысын да оныттыра ул.

— Ә минемчә, болай ул,— диде Рәшидә, уйланып кына, — җыр, бәлки, оныттырмый да торгандыр, хәтта кайгы-хәсрәтләрне көчәйтеп тә җибәрәдер. Җырның шундыйлары да бар бит. Мин инде аны үзем беләм. Ләкин нинди генә җырны алма, ул барысыннан элек кеше күңелендә тормышка мәхәббәт уята, кешедә яшисе килү теләген көчәйтә... Шулай булгач, кеше, җыр тыңлаганда, кайгы-хәсрәтне дә ничектер менә татлырак итеп кичерә, еласа, күз яше дә аның ул хәтле әче булмый һәм барыбер җиңеләеп кала. Бүген мин менә «Тәфтиләү»не җырладым, «Юксыну»ны җырладым, ә халык миңа: «Рәхмәт, кызым, күңелләребезне бушаттың, хәсрәтләребезне җиңеләйттең!» — дип кычкырды. Нигә, дөрес түгелмени?

— Дөрес, дөрес! — диде Зөфәр, Рәшидәнең фикеренә кушылудан бигрәк, аның ягымлы һәм гади итеп сөйләвенә сокланып.

— Туктагыз әле, менә әбидән сорап карыйк, әби нәрсә әйтер бит әле,— диде Яруллин.— Йә, әби, чын дөресен генә әйтеп бир үзләренә!

— Ни әйтим мин,— диде әби, кыюсыз гына елмаеп, аннары бераз уйланып торды да өстәп куйды: — Авыл кешесенең юанычы ни, шул җыру инде, белеп сөйлисез.

Рәшидә шатлыгыннан кулын чәбәкләп алды:

— Бик тә дөрес сүз таптың, әбекәем! Әйе, юаныч шул, юаныч!

— Хуш, мин дә килешәм моның белән,— дигән булды Яруллин, киерелә биреп.— Әмма шулай да мәсьәләгә икенче яктан да килеп карыйк. Әйт әле, әби, ничә малаең Гитлерга каршы китте?

— Өчәү... өчне озаттык.

— Ә бабайны озатмадыңмы?

— Бабайларга чират җитмәде бит әле,— диде әби, Яруллинга туры һәм мәгънәле генә карап.

Кызлар ихтыярсыздан көлешә башлаганнар иде дә, ләкин нидер сизенепме, әллә килештермичәме, шунда ук тынып калдылар.

— Сөйләшә белмисең, Яруллин! — диде Рәшидә, коры гына, аннары үзе әбидән йомшак кына сораша башлады: улларыңнан хат-хәбәр киләме, исәннәрме, өйләнгән егетләр идеме, алар өчен бик кайгырып, ут йотып тормыйсызмы, картың кайда, исән-саумы, колхозда эшлиме-юкмы?

Карчык татар хатыннарына хас бер тыйнаклык һәм сабырлык белән, самовар борыны өстеннән бармагын йөртеп, һәммә сорауларга да ашыкмыйча тыныч кына җавап биреп утырды: әйе, уллары хәзергә, Аллага шөкер, исән-саулар, хатлары килеп тора, тик Идел буенда сугышкан кече улыннан гына менә бер ай инде хат-хәбәр юк, шуңа бик пошынып торалар; улының зурысы гына өйләнгән егет икән, калган икесен өйләндерергә өлгермәгәннәр... Нишлисең инде, түзәсең, уфтанмаска тырышасың — ил белән килгән афәт ич!.. Тик явыз дошманның тизрәк муены сынсын иде дә, балалар кайтып күзгә күренсеннәр иде — көн-төн ялварып теләгән, өмет иткән нәрсә шул гына инде, шул гына!

Картымы?.. Карты болай ару әле, аяк-кулы таза, каравылда тора, төннәрен колхоз амбарларын саклый...

— Ходай җан биргәнгә юнь бирә,— диде әби, кыскача хикәясен шулай уфтанусыз, тыныч кына тәмамлап.— Көн

итү бик авырга калса да, барына шөкер итеп торабыз әле, мондый чакта зарлану язык булыр, нишлисең инде!

Шушының белән табын янында гомумән сүз бетте. Әбидән ишеткән, тормышның үзе кебек чын, гади, ләкин эчке киеренкелек, тирән мәгънә белән тулы сүздән соң хәзер инде бүтән нәрсә хакында гәп сатып яки шаулап-көлеп утыру килешми дә һәм кирәксез дә иде. Аннары вакыт та бик соң иде, ашагач-эчкәч авырайтып та җибәрде, гаять талчыккан тән һәм арыган баш, утырган җирдә үк калгып китеп, йокы сорый башлады... Шуңа күрә кунаклар, артык сүз озайтып тормыйча, әбигә зур рәхмәтләр әйтеп, өстәл тирәсеннән кузгалдылар. Яруллин, бая ычкындырган дорфалыгын төзәтергә теләп булса кирәк, әбинең аркасыннан кагып, сөеп алды:

— Мәликә әби, җаным, бездән сиңа бер генә теләк: өч улың да тап-таза килеш кайтып, синең шушы кечкенә гәүдәңне киң күкрәкләренә кыссыннар, яме!

Әби көлгәндәй итте, ләкин кинәт күңеле тулганга күрәме, акрын гына: «Рәхмәт, улым!» — диюдән башка сүз әйтә алмыйча, күзләрен йомгалап, башын гына кагып куйды.

Инде кемнәр кайда, ничек яту турында кайгырта башладылар. Өйнең зур ягында бер генә агач караватс тора иде. Кече якта сәке бар икән, менә барлык урын шул гына иде. Ләкин аптырап калмадылар. Иң элек Яруллин мич башы белән кызыксынды: сыеп буламы, әгәр сыеп булса, аның өчен мич башыннан да рәхәт урын юк. Ул шунда май кебек эреп, изрәп йоклаячак.

Ике биюче кыз кече яктагы сәкегә ятарга булдылар. Зөфәргә караватны тәкъдим иттеләр, ләкин ул аңардан баш тартты: «Өй бик җылы, мин эссене бер дә яратмыйм, толыбымны җәеп, идәндә генә ятам»,— диде ул... Шулай итеп, карават Рәшидәгә калды. Дөрес, башта ул кызлар белән сәкегә ятмакчы иде, ләкин анда, карчыкның савыт-сабалары да торганга күрә, өч кеше өчен тыгызрак булып чыкты.

Кыскасы, кем кайда яту мәсьәләсе шулай тиз генә һәм ансат кына хәл ителде. Әби мендәр, юрган, иске киемнәр өләшкән арада, кызлар ишегалдына чыгып, озак та үтми, суыктан өтелгәндәй, куырылышып керделәр. Тиз генә үзләренә һәм егетләргә урын җәйделәр. Шуннан соң, кызларга чишенеп ятарга ирек бирер өчен, Зөфәр белән Яруллин да тышка чыгып киттеләр.

Бераздан алар әйләнеп кергәч, әби дә иске өйгә чыгып китте. Кышын карт белән карчык шушы якта гына торалар икән, бүген инде кунакларга урын бирер өчен

иске өйне дә ягып җылытканнар. «Картның таң беленгәч кайтасы бар, аны ашатып-эчертәсе бар, кеше өстеннән йөрү килешми бит, сез иркенләп, тыныч кына йоклагыз»,— диде әби чыгып китәр алдыннан.

...Яруллин мич башына үрмәләде, ә Зөфәр утны сүндерде дә, чишенеп, җылы күлмәк-ыштаннан гына калып, толып җәйгән һәм зур колакчын мендәр салган идәнгә сузылды. Әби биргән иске, әмма чиста одеял өстеннән пальтосын ябынды... Бер биш минуттан сәкедәге кызлар да, мич башындагы Яруллин да сеңделәр. Хәзер аларны туптан атсаң да уятып булмас кебек иде... Өйдә тирән тынлык урнашты... Ләкин Зөфәрнең йокысы, бик арыган булуына карамастан, ни сәбәптәндер тәмам качкан иде. Ул кулларын баш астына куеп, ачык күзләре белән түшәмгә карап, чалкан ята. Туңган тәрәзәләр аша өй эченә тулган айның сыек зәңгәр шәүләсе җәелгән һәм шушы көндезге су төбен хәтерләткән тонык-тын шәүлә тышта һаваның бик яман суык булуын сиздереп тора кебек... Ара-тирә генә өй бүрәнәсенең ыңгырашып ярылуы да ишетелеп куйгалый... Ләкин Зөфәр боларны күрми дә, ишетми дә шикелле — уйлары аның бөтенләй башкада.... Рәшидә, Рәшидә — менә кем аның хыялында, менә кем турында уйланып ята ул бу зәңгәр тынлыкта! Һич көтмәгән-уйламаган җирдән килеп очраган бу кызмы-хатынмы үзе дә, аның мөнәсәбәте дә серле табышмак булды Зөфәр өчен... Ярты тәүлек эчендә кеше шулкадәр тиз күңелне биләп, хыялны котыртып өлгерер икән — Зөфәрнең мондый хәлгә беркайчан да тап булганы юк иде әле. Чынлап та, кем ул Рәшидә: фәрештәме, гыйфритме? Аның үртәгәндәй көлемсерәп, дәшкәндәй назлап карaулары, йә игътибарсыз гына, йә якын-җылы итеп әйткән сүзләре, әллә ялгыш кына, әллә үзе теләп аңа терәлеп утырулары нәрсәне аңлата, нәрсәгә ишарә ясый, уен гынамы бу яки чын бер хистәнме — ничек моны аңларга, ничек саф дөресен генә белергә?.. Ә иртәгә алар аерылышачаклар, Зөфәр үз юлы белән, алар үз юллары белән китәчәкләр. Һәм Зөфәр берни белми калачак. Ләкин белмичә калырга ярыймы соң, белмичә калу соңыннан күңелдә зур үкенеч тудырмасмы?

Менә ул, Рәшидә, ике адымда гына агач караватта йоклап ята.. Әмма... йоклыймы икән ул?.. Нигәдер бик тын ята... Тукта, әгәр аның да йөрәге Зөфәрнеке шикелле үк урыныннан купкан булса, күңеле аныкы төсле үк исәрләнгән булса, ул чагында... ул чагында, ихтимал, ул да йокыдан калып, тын алырга куркып, аны көтеп ята торгандыр. Килерме-юкмы, дип, әйе, килерме-юкмы,

дип... Зөфәр хәтта эсселәнеп китте. Ничек ул мондый ихтималның булуын уйлый белмәде әле? Аның бит шушындый кыска очрашу вакытларында ир белән хатынның бер-берсен яратып, бер-берсен теләп кушылуларын ишеткәне бар. Йә, шуның кебек тиле бәхетнең менә хәзер дә булуы мөмкин түгелмени? Юк, чынлап та, мөмкинме, түгелме? Ничек моны белергә? Әллә янына барып карыйсы микән?.. Тәвәккәл таш йоткан, ди, аңардан гына ни булыр? Куса куар, әмма тавыш чыгармас, юк, чыгармас. Бөтен булып үткәннәрдән соң моны хәтта күз алдына китерүе дә читен... Аннары ул аны җәберләргә бармый ич... Тик иелеп дәшер генә ул аңа һәм аның бер күз карашыннан барысын да аңлап алыр. Кит, дигәнен дә көтмәс, кире чигенер... Әлбәттә, бу кире чигенү бик авыр булачак, хурлыклы рәвештә куылу белән бер булачак, ләкин — нишләмәк кирәк — моның кебек уңай форсат бүтән беркайчан да туры килмәячәк бит!

...Менә Рәшидә караваты өстендә кузгалып куйды. Йокламый, йоклый алмый, күрәсең, ул да!.. Мөгаен, көтә торгандыр — шулай тоела Зөфәргә, нигәдер шулай тоела... Ниһаять, ул кыюланып торып утырды. Ләкин шунда ук үз хәрәкәтеннән үзе курка-шикләнә калды: юк, буламы соң, тузга язмаганны! Тилелек ич бу! Ни өчен ул аны көтәргә тиеш. Кайдан мондый ышаныч, кемгә саный ул аны?.. Барырсың, хур булырсың, оятыңнан керер урын тапмассың... Аннары, килешәме соң Зөфәр кебек үзен тыйнак, акыллы итеп таныткан кешегә мондый әрсезлек, түбәнлек?

Әмма шулай да ул кире ятмады, башын иеп утыра бирде. Үз намусы алдында акланырга тырышып, тирән уйга калып утырды... Рәшидә аның өчен хәзер очраклы бер хатын гына түгел иде, Рәшидә аның йөрәген җилсетте, нәфесен котыртты, көчле кызыксыну уятты, һәм Рәшидә үзе моңа сәбәпче булды. Бәс, шулай икән, Зөфәрнең чын дөресен белеп калырга хакы юкмыни? Ул бит шуның өчен генә барырга тели дә!.. Әгәр кумаса, әгәр иреннәреннән бер үптереп кенә яки берәр вәгъдәле җылы сүз пышылдап кына кире җибәрсә дә, ул барысын да аңлар иде, шуннан үзе өчен тиешле нәтиҗәне ясый белер иде.

Менә Рәшидә тагын кузгалып куйды... Юк, артык икеләнеп тору мөмкин түгел иде — Зөфәр бик сак кына торып басты. Өй эчендә тулган су төбедәй яшькелт-зәңгәр яктылыкта өрәк шикелле күпмедер вакыт тик кенә басып торды... Тынлык, бар да тирән йокыга киткәннәр. Бернинди хәвеф-хәтәр юк кебек... Шулай да Зөфәрнең

тез буыннары хәлсезләнде, чигә тамыры нишләптер суга башлады... Болай торып булмый бит инде, ахырда ул җылы оекбашлары белән шуышып кына караватка таба атлады. Бер, ике, өч адым... Менә ул караватянында. Рәшидә ак маңгаен гына ачык калдырып, йөзен юрган белән каплаган килеш кырын яткан. Күзләре йомык, сулышы тигез — йоклый, ахрысы... Зөфәр аның йөзенә якын ук иелеп, чак-чак кына ишетелерлек итеп, бары бер сулыш белән генә пышылдап дәште:

— Рәшидә!

Һәм гаҗәп хәл — Рәшидә шунда ук, юрганын күтәрә төшеп, күзләрен ачты. Бер мизгелдә сискәнү, каушау һәм... сөенү чагылып үткәндәй булды бу кечкенә дымлы күзләрдә... Бер сүз әйтмәде ул, тик урын биргәндәй, такта стенага таба елыша төште... «Көткән!» дигән уй яшендәй яктырып узды Зөфәр күңеленнән һәм, сак булырга кирәклеген дә онытып, тиз генә юрган астына керде.

...Керү белән кызны үзенә тартып, кочаклап алды. Рәшидә ничектер берьюлы аның киң күкрәгенә сыланып, кечерәеп, сеңеп калды. Йөзен күтәрде һәм аларның иреннәре, күптән бер-берсен көткәндәй, комсызланып кушылдылар... Зөфәрнең бу минутта зиһене гаҗәп айнык иде; кызга ул исенә килергә вакыт бирмәде...

...Аннары алар хәлсезләнеп озак кына тик яттылар. Зөфәрнең култык астына башын яшергән Рәшидә тәмам тынган-оеган иде... Аның хәлен бик беләсе килә егетнең, әмма сөйләшү мөмкин түгел... Ахырда ул сакланып кына Рәшидәнең чәчләреннән, битеннән сыйпый башлады... һәм аптырый калды: кызның күз төпләре, борын буйлары яшькә чыланган иде. Нидән бу, үкенәме, рәнҗиме әллә югыйсә?.. Зөфәр, күтәрелә төшеп, аның күзләренә карады. Әмма уелып калган, талчыккан бу күзләрдә ул тирән бер гаҗәпсенү аша чагылган бәхетле-оялчан сөю генә күрде... Һәм Рәшидә күзләрен яшерергә теләгәндәй тагын аңа сарылды, ә Зөфәр аның иягреннән тотып, аз гына тоз татыган иреннәреннән үпте... Кыз акрын гына егетнең күкрәгеннән этәрде. Бу китәргә ишарә иде... Зөфәр, сак кына караваттан төшеп, үз урынына китте.

Вакыт бик соң иде инде, тәрәзәләрдә таң шәүләсе беленә башлады. Өй эче дә ничектер агарына төшкән кебек булды. Каяндыр, абзарлар эченнән, суыкта күшегеп беткән әтәчнең карлыгып кычкырганы ишетелде.

Зөфәр беркадәр вакыт булып үткән хәлгә хәйран калып ятты-ятты да акрын гына оеп, тирән йокыга киткәнен сизми дә калды.

## IV

Ул иртәне арыган-йончыган артистлар, гадәтләре буенча, бик озак йокладылар. Кышкы көн кыстатып, иренеп кенә яктырды, кереп, борчып йөрүче булмады; алар өчен бу саваплы йокы иде.

Тик идәндә яткан Зөфәр генә иртә уянды. Аны мыштым гына суык кытыклый башлаган иде, хәер, электән иртә торып өйрәнгәнгә күрә, болай да аның уяныр вакыты җиткән иде инде.

Бик табигый буларак, ул күзләрен ачу белән Рәшидәне исенә төшерде. Хәтта аңарда шундый бер тойгы иде ки, гүя менә йоклаганда да ул аны онытып тормаган, ничектер үз янында аны гел хис итеп яткан кебек иде... Булган эшкә яңадан аның исе китте, яңадан бөтенесен күз алдыннан кичерде. Торырга кирәклеген дә онытып, селкенмичә уйланып ятты. Ләкин инде татлы хиссияткә бирелеп ятудан бигрәк, ул айнык акыл белән булып үткән хәлне ничек тә аңларга тырыша иде. Барысыннан элек күңеленә һаман бер сорау кат-кат килә торды: ничек кенә булып чыкты соң бу? Ни өчен Рәшидә аны кабул итте? Чын яратуданмы, әллә... болай гынамы?.. Ире бармы аның, юкмы? Булса, кайда ул, кем ул?

Әлбәттә, бу сорауларның берсенә дә хәзергә җавап юк... Хәер, эш булып узганнан соң аларга җавап эзләп торуның кирәге дә юк шикелле... Ләкин Зөфәр уйламыйча, эзләмичә булдыра алмый, мөмкин түгел, чөнки Рәшидә аның өчен бер кич белән генә бетмәде әле, бу башы гына булды әле, искиткеч матур, ләззәтле, дәртле дәвамы булырга тиеш әле!.. Сизеп тора ул моның шулай буласын, югалтырга теләмәячәк ул аны, юк, теләмәячәк! Артистка аның өчен эссе якның хөрмәсе кебек гаять ят җимеш, сезонный җимеш, шуңа күрә дә ул аеруча кадерле, тансык булырга тиеш.

Ничек җырлый иде әле кичләрен кәләпүш сырганда әнисе Таибә абыстай?

Тәрәзә төпкәем рәва җимеш,
Рәва җимеш хәләл, имеш.
Рәва җимеш хәләл, имеш,
Хәләл җефтең булам, ди, имеш.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Хәләл, имеш, димәк, өзеп-өзеп, тәмләп кенә капкаларга ярый дигән сүз!.. Ә менә инде «хәләл җефет» мәсьәләсенә килгәндә, бу бик читен, четерекле мәсьәлә, бик нык уйлануны сорый торган, хәер, уйлар өчен әле

һич өлгермәгән, пешмәгән мәсьәлә... Рәшидәне бөтен җаны-тәне белән яратып киткән тәкъдирдә дә ансат кына чишеп булмаячак аны, чөнки ул мәсьәлә аның башка максат-хыялларына, уй-теләкләренә барып тоташа. Юк, хәзергә бу хакта баш ватуның һич мәгънәсе юк, хәзергә бары кабынган утны сүндермәү, саклау, көчәйтү турында гына уйларга ярый.

Шулай күпмедер вакыт уйланып, шуның белән бергә яңадан Рәшидә янына барасы килеп ятканнан соң, Зөфәр, ниһаять, торды, сак кына киенде һәм чыгып китәр алдыннан аяк очына гына басып, артистканың караваты янына барды. Рәшидә кулларын кушырып, шулар өстенә битен салып, бөтәрләнә төшеп тыныч кына йоклый иде... Каты йоклый иде,ахрысы, юрганы шуып, аркасы бераз ачылганын да тоймый иде... Зөфәр бик сак кына аның аркасын япты, иелеп кенә чәченнән үпте. Рәшидә берни сизмәде, селкенмәде.

Берәүне дә уятмыйча гына чыгып киткәч, Зөфәр туры гына колхоз идарәсенә барды, Шәйхулла абзый белән сөйләшеп утырды. Аның бу колхоздан наряд буенча күпмедер солы чыгартасы бар иде, башта менә шул солыны станциягә кайчан озату турында сөйләшеп, эшне өзеп куйды. Аннары инде, җаен туры китереп, кичәге концерт турында да сүз кузгатты. Артистларның җырларын, биюләрен мактап утырды, шуның белән бергә, Шәйхулла абзыйга азрак басым ясау нияте белән булса кирәк, аларның авыр хәлләрен әйтергә дә онытмады. Шуннан соң тагын бераз анысын-монысын сөйләшкәләп алгач, күрше авылга китәр өчен бер-ике сәгатьтән ат җибәрүләрен сорап, фатирына кайтып китте.

...Ул кайтканда артистлар торганнар, юынып-киенеп иртәнге чәйгә утырырга әзерләнеп торалар иде. Зөфәр килеп керү белән сабырсызланып бары бер нәрсәне уйлады-көтте: Рәшидә аңа ничек итеп, нинди күз белән карар?.. Нишләп китәр ул күзләре очрашкач?..

Нәкъ ул килеп кергән чакта гына Рәшидә, урам як тәрәзә төбенә кечкенә көзге куеп, чәчләрен төзәтеп утыра иде... Керүченең кем икәнен шунда ук белсә дә, ул борылып карамады, эшеннән ихтыярсыз тукталып та калмады, гомумән, ни хәрәкәте, ни торышы белән берни дә сиздермәде. Тыныч кына чәчен рәтли бирде һәм эше беткәч кенә торып, ишеккә таба борылды... Аларның күзләре очрашты... Бер генә мизгел Рәшидә, «Сезмени бу?» дигәндәй, үтә җитди итеп бер карап алды, әмма шул секундта ук гадәтенчә елмаеп җибәрде.

— Менә яхшы булды бит әле... чәйгә кайтып җитте-

гез,— диде ул, бүтән һичбер кайгысы булмаган кешедәй, бик гади генә итеп.

Нәкъ кичә вокзалда очраган, юлда килгән, бергә ашап-эчеп утырган Рәшидә иде ул бүген дә! Һаман шул ук күзләрен кыса төшеп, бик туры итеп карау, көтмәгәндә генә яктырып китеп елмаю һәм менә шулай бик гади-үз итеп кенә дәшү — бары шул гына! Әйтерсең алар арасында берни дә булмаган, әйтерсең аларның хәзер берсен берсенә бәйләгән, дөньяның иң якын кешеләренә әйләндергән, тиз генә онытырга да, юкка чыгарырга да мөмкин булмаган тирән серләре юк!.. Зөфәр аның бу кадәр үзен табигый тота алуын күреп, аптырап калу гына түгел, хәтта күңеленнән бераз шикләнеп-борчылып та куйды. Дөрес, ул хатын-кызны бик аз белә иде. Хәлбуки эчке хисләрен, бигрәк тә мәхәббәтләрен, хатын-кыздан да оста яшерә белүче юк бит ул дөньяда! Зөфәр, кемнәндер ишеткән Сөләйман патша сүзләрен исенә төшерде: «Һавада кош эзе, ташта елан эзе, хатыннарда ирләр эзе калмый»,— имеш. Хатын-кызның йөрәген күрә белмәгән кеше өчен бу бик хикмәтле сүзләр иде.

...Өстәл тирәсенә утырыштылар. Әби олы табак белән булары чыгып торган чикмәнле бәрәңге китереп куйды. Рәшидә, яшь хозяйка сыман чәчәкле яулыгын урталай бөкләп, кашлары өстенә төшеребрәк бәйләгән килеш, самовар янына үзе чәй ясарга утырды. Көн яктысында алар барысы да аз гына бүтәнчәрәк, ачыграк күренәләр иде. Мәсәлән, әлеге тынгысыз биюче кызның кичтән шактый кара булып күренгән чәче хәзер бакыр сыман коңгырт-җирән булып чыкты. Рәшидәнең йөзе ул хәтле үк ак түгел, ә саргылтрак икән, күзләре дә алай бик кечкенә түгел, ә шактый зур да, яктырак та икән, тик әле кыса төшеп караганга күрә генә шулай сөйкемле кечерәеп кала икән. Әмма ул бүген аеруча чиста, нәфис иде. Тулы күкрәкле юка гәүдәсе дә, тар гына йомры иңбашлары да, озынчарак ак муены да, тулы-алсу иреннәре дә ничектер менә аның тәмле-тансык хатын булуын сиздереп, назлап сөясе килүне котыртып, гел үзенә тартып тора иде. Зөфәр, бу вәсвәсәле тойгыны берничек тә җиңә алмыйча, гел янып, дулкынланып утырды.

Рәхәтләнеп йокы туйдырганнан соң, барысының да кәефләре бик әйбәт иде. Ашыкмыйча тәмләп кенә ашадылар-эчтеләр, авызлары бушап тормаса да, һаман җыен кызык сөйләшеп утырдылар. Ничектер сүз туры килеп, биюче кыз Зөфәрдән:

— Ә сез, абый, төнлә идәндә өшемәдегезме? — дип сорап куйды.

Әлбәттә, бу аның нидер сизенеп соравы түгел иде. Шулай да Зөфәр, аңа күтәрелеп карарга кыймыйча, чәен болгаткан булып кына:

— Юк, өшемәдем,— диде.— Аста толып, өстә пальто, рәхәтләнеп йокладым.

Яруллин шунда ук үзенең борычлы сүзен кыстырып өлгерде:

— Өшесә, барып сезнең уртага ятыр иде. Мин үзем андый чакта ике кыз арасына кереп җылынырга яратам.

— Абый син түгел бит ул,— диде кызларның берсе, ә икенчесе өстәп куйды:

— Безнең арага Рәшидә апа да сыймады әле.

Рәшидә иптәшләренең бу гөнаһсыз сөйләнүләренә бер генә сүз белән дә катнашмады. Ул тырышып чәй ясау белән мәшгуль булды. Шулай да Зөфәр бераздан аңа күтәрелеп карагач, ханымның бер як авыз читендә сизелер-сизелмәс кенә серле елмаю чагылуын күреп алды. Нәрсә аңлата иде бу елмаю — моны белү мөмкин түгел иде... Чын борчылу белән Зөфәр эченнән генә: «Шулай ук берни дә белмичә китеп барырга туры килер микәнни, хәерсез?» — дип уйлап куярга мәҗбүр булды.

Чәйдән соң Яруллин, ашык-пошык киенеп, колхоз идарәсенә йөгерде. Шәйхулла абзыйның кичәге вәгъдәсен исенә төшереп, ул чыгып киткәндә генә:

— Кызлар, теләктә торыгыз! — диде, кабаланып.— Карттан бүген безгә гошер тияргә тиеш, тик берәр яры чыгып кына сызмасын!

— Бар, бар, председатель сине көтеп утырмас! — диделәр кызлар, аны куалап.

Бүген инде алар үзләре чыгып йөрмәскә, җылы өйдә генә ял итеп, вак-төяк эшләрен карап утырырга булдылар. Чәй урынын җыештыргач, кайсы кулына китап алды, кайсы энә-җеп алып, ертык-сүтеген типчергә тотынды.

Зөфәрнең Рәшидә белән бер-ике генә авыз сүз булса да сөйләшеп аласы килә иде. Ләкин ничек кенә эшләргә моны? Өйдә теге ике кыздан уңайсыз, тышка да чакырып чыгару кыен, мөмкин түгел... Ахырда ул, караватбашында чемоданын ачып, әйберләрен актарып торган Рәшидәгә якын ук килде дә тавышын әкренәйтә төшеп әйтте:

— Мин тиздән китәм... Бәлки, Казанда очрашырбыз, сезгә үземнең телефонны калдырыйммы?

— Әйе, әйе, калдырыгыз! — диде Рәшидә, ашыгып.

Зөфәр блокнот битенә үзенең эш телефонын һәм фамилиясен язып бирде.

— Сез шәһәргә кайчан кайтасыз?
— Бер-ике атнадан.
— Мин сезнең шалтыратуыгызны көтәрмен.
— Әйе, әлбәттә...

Болай ашыгып, кыска гына итеп җавап бирүеннән Зөфәр Рәшидәнең эчке дулкынлануын сизмичә калмады. Шуның аркасында ямьсез шикләре бердән таралып киткәндәй булды, алай гына да түгел, бу әйбәт, рәхәт дулкынлану аның үзенә дә күчте кебек...

Озак та үтми, әби кереп, колхозның аты килеп җитүен хәбәр итте. Зөфәр киенә башлады. Киенеп беткәч, әбигә рәхмәт әйтеп, акча бирде. Аннары кызлар белән кул биреп саубуллашты, шуннан соң Рәшидәгә таба борылды. Ләкин ул да булмый, Рәшидә үзе аның каршысына ук килеп, һич каушамыйча һәм шик кузгатмыйча, бары гади кайгыртучанлык күрсәткән булып кына Зөфәрнең пальто якасын төзәтергә тотынды:

— Менә шулай кирәк, шулай итсәң, җылырак була! — диде ул, шушы гади генә сүзләренә гаҗәп җылы бер интонация салып һәм шул ук вакытта якты күзләре белән Зөфәрнең күзләренә: «Син! Син бит бу!» — дип әйткән төсле итеп, тутырып бер карады. Менә шулай һичкемдә шик кузгатмыйча, бары Зөфәрнең үзенә генә йөрәгендәге хисен аңлата белде ул!.. Зөфәр, рәхмәт әйтергә дә көче җитмичә, куанычлы елмаеп, башын гына кагып торды. Тик саубуллашкан чакта гына: «Син дә аңлап кал, җаным!» — дигән төсле, Рәшидәнең кулын ике тапкыр каты гына итеп кысып куйды. Аннары чемоданы белән толыбын алып, ишеккә таба атлады. Кызлар да, иңнәренә пальтоларын салып, аны озата чыктылар.

Кояшлы, коры салкын көн иде... Көннең никадәр суык булуын шул ук кояш үзе әйтеп тора: аның ике ягында ике колак... Мондый чакта авыл җирендә: «Бүген кояшка да колак чыккан, ай-һай суык икән!» — диләр тәҗрибәле агайлар.

Зөфәр борылып Рәшидәгә;

— Сез, бар, керегез инде! — диде һәм җиңел, кызу адымнар белән капка төбендә көтеп торган атка таба китте. Иске кошевка чана янында муенына ишеп шәл чорнаган, тире тун өстеннән соры чикмән кигән уналтыунҗиде яшьлек үсмер егет аны көтеп тора иде. Зөфәр толыбын киеп чанага утырды, үсмер егетне дә үз янына утыртты, һәм бик арык, зур туры ат ялкау гына кузгалып, бары бер-ике тапкыр сыртына чыбыркы төшкәч кенә, дөя шикелле, алпан-тилпән юыртып китте... Болдырдагы кызлар юлчыларга кул болгап калдылар.

## V

Зөфәрнең Турай авылында Рәшидә Сафина белән очрашып танышуы әнә шулай төгәлләнде... Әмма ләкин әүвәл-ахыры түгел иде әле бу, соңыннан Казанда аның шактый кызыклы дәвамы да булды.

Әйе, Рәшидә!.. Зәһәр суыктан качкан яз кошыдай килде дә керде бит Зөфәрнең тормышына... Керде дә бөтенесенә хуҗа да булып алды. Йөрәк тә әсир, акыл да богаулы, планнар да чуалды. Хәзер менә үзеңне шул татлы әсирлектән коткарып кара инде! Юк, мондый җәтмәгә беркайчан да эләккәне юк иде әле аның...

Дөрес, Зөфәр Рәшидәгә чаклы да хатын-кызсыз тормады. Бик мактанырлыктан булмаса да, үзенә күрә аның да «романнары» булгалады. (Утыздан узганчы ялгыз ир булып йөргән кеше өчен бу әллә ни гаҗәп эш түгел, билгеле...) Ләкин алар барысы да хәтәр-хәвефсез, эзсез-ярасыз дигәндәй үттеләр дә киттеләр. Чөнки андый «романнарда» ул үзе баш герой, үзе чын хуҗа иде, шуңа күрә бары тик аның хөкеме йөрде.

Мәсәлән, кайчандыр ул универмагта эшләүче Мәрьям исемле кара, чандыр гына бер хатын белән шактый гына вакыт якын бәйләнештә булып алды. Ләкин аның эчүдән башы чыкмаган ире, ниһаять, нидер сизенә башлагач, Зөфәр Мәрьям белән ике араны тиз генә өзде дә куйды. Бернинди кызганусыз һәм үкенүсез!

Яки менә шуннан соң буфетчы Вера белән булып алган «романны» искә төшерергә мөмкин. Вера төскә-биткә чибәр генә, гәүдәгә тулы-тыгыз гына, ирсез ялгыз гына, утызга да җитмәгән хатын иде. Баш-күз тонып, аңа тәмам капланырга да була иде. Ләкин Зөфәр буфетчы хатынның артык әрсезлеген, оятсызлыгын һәм эчкәләргә яратуын белеп алгач, ике дә уйламыйча, тотты да нокта куйды. Чөнки «романның» ахыры бик күңелсез булып бетәчәген вакытында сизде ул.

Кыскасы, Зөфәр бервакытта да, хатын кирәк бит, дип башын җуймады, нәфес тезгенен кулыннан ычкындырмады, ара-тирә берәрсе белән якын бәйләнешкә кереп киткән чакларда да, исеменә яки эшенә куркыныч туа башласа, шунда ук тыела белде һәм чигенә алды...

Тик менә Рәшидә белән генә бүтәнчәрәк килеп чыкты. Хәер, моның шулай булуы гаҗәп тә түгел, чөнки Рәшидә теге Мәрьям-Вералардан чагыштырмас дәрәҗәдә өстен тора, чөнки беренче очрашу минутыннан ук ул Зөфәрдә көчле тәэсир калдырды, ничектер аның күзенә саф, гүзәл, якты булып күренде. Ихтимал, шуңадыр инде Зөфәр гел бер

нәрсә турында сабырсызланып уйлады: Рәшидәнең ире бармы-юкмы, ни өчен ул аны шулай ансат кына кабул итте, яратуданмы, әллә болай гынамы?.. Турайдан ул Рәшидәнең үз авызыннан берни ишетергә өлгермичә китеп барды. Ә күңел дигән нәрсә су өсте кебек гел үзгәреп кенә тора: бер яктыра, бер караңгылана, бер тынычлана, бер дулкынлана, кыскасы, әллә ниләр уйлап бетәргә мөмкин иде. Дөрес, кайвакытта ул болай баш ватып азапланмас өчен үзенчә ачык кына нәтиҗәгә дә килгәндәй була иде; ягъни Рәшидә — артистка бит ул, ә артистка, Зөфәр карашынча, хис кешесе, ни кылансам да, миңа килешә, дип уйлаучы, шунлыктан инде ул үзе теләгән эштән тыелып тормый, кирәк икән, җиңел генә эшли дә куя, янәсе... Ләкин... чынлап та, Рәшидә нәкъ менә шундыймы — бу әле билгесез, бу әле яңадан расланусы сорый иде.

Озын сүзнең кыскасы, Зөфәр Рәшидәнең авыллардан кайтуын түземсезлек белән көтеп йөрде, җаны-тәне белән аны сагынып яшәде. Бу сагынып көтүдә Рәшидәне бик теләү, югалтасы килмәү генә түгел, аны тизрәк аңлау, тизрәк белү өчен ашкынып тору да бар иде. Казанга кайткач, Рәшидә аңа шалтыратырмы, аның күзенә күренерме-юкмы — Зөфәр өчен бу бик тә әһәмиятле иде. Әгәр шалтыратмаса, яңадан күзгә күренмәсә — ул чагында ни уйларга кала? Ә вакыт... вакыт үтә дә үтә, ике атнадан кайтырга тиеш иде, хәзер инде ай тулып килә. Шулай ук Рәшидә дә бер генә төнлек... Ләкин юк, ашыгып нәтиҗә ясарга һич ярамый икән!

...Нәкъ март башларында Рәшидә үзенең дөньяда барлыгын белдереп, ниһаять, аңа шалтыратты.

Зөфәр телефон трубкасын алып «тыңлыйм» диюгә, ерактан хатын-кыз тавышы ишетелде.

— Алло, миңа Зөфәр Сабитов кирәк иде.

Шунда ук ул тавыш иясенең Рәшидә булуын танып алды һәм, дөньясын онытып, ике кулы белән дә трубкага ябышты:

— Рәшидә, сезме бу? Тыңлыйм мин, тыңлыйм!

— Әйе, бу мин, Зөфәр абый! Исәнмесез!

— Исәнмесез, Рәшидә, исәнмесез! Кайчан кайттыгыз?

— Бер ун көн була инде...

— Шулай күптәнмени? Ә мин көтәм дә көтәм...

— Вакыт булмады, Зөфәр абый! Кайту белән төрле эшмәшәкатькә тардым, хатын-кызның беләсез...

Рәшидәнең шундый сагындырган сөйкемле тавышы ерактан гүя җылы-назлы дулкын булып килә иде. Һәм шул дулкын әйтерсең Зөфәрнең йөрәгенә килеп кагыла иде.

— Мин инде оныттыгыз, ахрысы, дип курка да башлаган идем,— диде ул, аз гына үпкәле пошыну белән.

— Юк, нишләп онытыйм!.. Онытсам, шалтыратмас идем...

— Рәхмәт, Рәшидә, рәхмәт! — Зөфәр тавышын әкренәйтә төште.— Ләкин безгә тизрәк очрашырга кирәк бит, Рәшидә.

— Шулаймы?.. Белмим шул, ничек булыр икән!

— Нигә алай дисез, аңламыйм! Безгә бит очрашырга кирәк, шулай түгелме?

— Әйе, әлбәттә,— диде Рәшидә, аз гына көттереп.— Тик менә белмим: кайда, ничек...

Зөфәр «сез»дән «син»гә күчте:

— Анысы өчен борчылма! Тик әйт кенә, кайчан синең вакытың булыр?

— Минекеме?.. Ничек дим, мин хәзергә буш әле...

— Алайса болай сөйләштек,— диде Зөфәр, киеренке, әмма эшлекле тавыш белән.— Иртәгә син миңа тагын шушы вакытларда шалтырат. Мин шул чакта сиңа кайда очрашуыбызны тәгаен әйтермен. Ярыймы?

— Ярый, мөмкин...

Зөфәр тирән итеп бер сулап куйды һәм, аз гына тынып торганнан соң, моңарчы тыеп килгән дулкынлануын телефон аша җиткерергә теләгәндәй, учы белән трубканы ышыклап, акрын-йомшак кына итеп әйтте:

— Рәшидәм, тыңлыйсыңмы... мин сине бик-бик сагындым!

— Шулаймыни? — Трубкада кычкырып көлгән куанычлы тавыш яңгырады.— Һай, мескенем!

— Көлмә, Рәшидә! Саф дөресен әйтәм...

— Ышанам, ышанам!.. Йә, ярый алайса, хәзергә...

— Хуш, Рәшидә, хуш! Ләкин иртәгә шалтыратырга оныта күрмә!

— Юк, онытмам!.. Хуш!

Сөйләшү өзелде, әмма сөйләшү кабызган шатлык һәм өмет Зөфәрнең йөрәгендә отыры дөрләп кенә калды. Шул ук көнне ул, эшеннән бик соңга калып кына ычкынуына карамастан, туп-туры Хәмит дустына китте. Хәмит ялгызак бер егет ул, ләкин бик яшьтән түгел инде, шул Зөфәр чамасы — утыз ике-утыз бишләр тирәсендә булыр. Характерлары белән бер-берсенә капма-каршы булсалар да (ә ихтимал, шуңа күрәдер дә), алар, чынлап та, бик дуслар. Эш-хезмәтләре дә бер диярлек: Хәмит тә гел сәүдә тирәсендә чуалып йөргән егет. Ләкин ул, Зөфәр кебек, бер урында озак оялап утырырга яратмый, шулай ук зуррак эшкә, дәрәҗәлерәк урынга да һич исе китми.

Аңа, кечкенә булса да, үз башына ялгызы гына эшли алырлык урын булсын. Шуңа күрә дә ул әлеге базар арасындагы тактадан гына корылган, прилавка астыннан гына кереп йөри торган вак ларекларны бик ярата. Монда ул үзе хуҗа, теләсә ни вакытта ача, теләсә ни вакытта яба, теләсә кайда йөри... Яратып саткан товары — галантерея. Бу үзе күп, үзе вак, үзе арзан товарны сатуның нечкә серләрен ул бик яхшы белә һәм Ходай бирмеш көн мул гына «чумараны» кесәсенә сала бара.

Ләкин бу кешенең иң гаҗәп ягы оста сәүдәгәр булуында түгел иде. Сәүдә өлкәсендә ул бик вак балык, мәсәлән, Зөфәр кебек җаен белән чагыштырганда чабак кына... Әмма шуңа карамастан аны шәһәрнең бөтен сәүдә галәме белә, сәүдә галәмне генә түгел, бик күп оешмаларның, учреждениеләрнең җитәкчеләре, министерство кешеләре аны беләләр. Ул ярты шәһәр белән таныш, бу танышлар арасында нинди генә кәсеп иясе юк, хәтта галимнәрдән һәм язучылардан да кемнәрнедер белә, шулар белән дә үз кешедәй кул бирешеп, исәнләшеп йөри, имеш.

Хикмәт нәрсәдә соң?

Аның исеменә тагылып йөри торган, кушамат дисәң —кушамат түгел, ләкин гаҗәп сәер бер өстәмәсе бар: «Әйттем-бетте». Ягъни Әйттем-бетте Хәмит! Кайсы Хәмит? Әйттем-бетте Хәмит!.. Һәм бөтен танышлары аны шулай дип кенә беләләр, шулай дип кенә йөртәләр.

Кайдан килеп тагылган бу колак ишетмәгән әкәмәт өстәмә безнең галантерейчы егеткә? Мәсьәлә шунда ки, безнең егетебезнең гаҗәеп бер сыйфаты бар: ул кешеләргә һәртөрле хезмәт күрсәтергә ярата. Сәүдәсенә караганда да ныграк ярата, бик теләп, рәхәтләнеп кеше йомышы артыннан чаба, шуңардан чынлап торып ямь, кызык таба. Тик моны ялагайлыктан килгән куштанлык, ягъни кем ни кушса, шуны урталай сынып үтәргә тору дип аңламаска кирәк. Юк, һич алай түгел, үз кадерен, үз дәрәҗәсен бик белә торган горур-һавалы егет ул Хәмит... Гадәттә аның алдына баш иеп киләләр. Гадәттә, килгән кеше үзе түбәнчелек белән генә: «Хәмит туган, зинһар, дип әйтәм, миңа шуны гына эшли алмассыңмы икән?» — дип сорый аңардан.

Хәмит карый әле: сораучы кем, кайдан килгән, кем җибәргән аны, киләчәктә аның үзеннән нәрсә көтәргә мөмкин? (Аның кагыйдәсе: хезмәткә каршы хезмәт, бүтән берни дә түгел.) Бары менә шуларны үзе өчен ачыклагач кына, бер дә ашыкмыйча, бәйсез, горур кыяфәт белән соңгы сүзен әйтеп куя:

— Яхшы, эшләрбез!

Күп вакытта үтенеч белән килгән кеше ышанып бетмәгәндәй кабатлап сорый:

— Эшләрсезме?

Менә шул чагында инде Хәмит үзенең телләргә кереп киткән мәшһүр сүзен, мөһер баскандай, өзеп кенә әйтеп ташлый:

— Әйттем — бетте!

И, вәссәлам! Кабатлап сорама, эшне генә бозарсың. Димәк, ул әйттеме — бетте, эш булачак! Моңардан да зур гарантиянең булуы мөмкин түгел.

Әнә шундый кеше ул Әйттем-бетте Хәмит! Ярым сәүдәгәр, ярым арадаш! Талантлы, үткен-зирәк, әмма чиктән тыш индивидуалист, үзенчә «хөрлек» сөюче һәм үз рәхәте өчен генә яшәүче оясыз-нисез бер ялгызак кеше... Зөфәр менә шул кешегә ашыкты.

Кольцодан ерак түгел Островский урамындагы таш йортның өченче катындагы бүлмәгә Зөфәрнең күп тапкырлар килгәне бар иде. Юлын бик яхшы белә, кирәксә, йомык күз белән дә караңгы баскычтан күтәрелеп, киндер тышлы ишекне таба ала иде... Күршеләрдән аерым, туры гына коридорга чыга торган бу бүлмәгә ул Мәрьямне дә китереп йөртте. Верочканы да еш кына ияртеп китерде, кыскасы, бу аның «гыйшык» эшләре өчен генә хезмәт итүче яшерен оясы иде. Төп хуҗа — Әйттем-бетте Хәмит исә, Зөфәргә бик бирелгән киң күңелле дус буларак, бервакытта да аңардан бүлмәсен дә, ятар урынын да кызганып тормады. Гадәттә ул: «Әйдә, алып килсәң килерсең инде, чукынган күпец!» — дип, ачусыз гына мыгырдана да бүлмәсен теләсә күпме вакытка калдырып китә торган иде. Үзе ул преферанс сугарга ярата, кайдадыр хәрбиләрдән һәм карт артистлардан якалашып уйный торган кешеләре бар, шулар янына китсә, тәүлекләп тә югала торган иде.

Зөфәр килеп кергәндә, Хәмит пружиннары, арык мал янбашыдай, аннан да моннан төртеп чыккан «турецкий» диванда тетелеп беткән «Шерлок Холмс»ны укып ята иде... Баш кагышып кына исәнләштеләр. Зөфәр түргә узып утырды, ә Хәмит диваннан, рәнҗегән тавышлар чыгартып, аякларын салындырды. Киерелеп, авызы каерылганчы бер иснәде:

— Ни... нишләп болай соң гына?

— Йомышым бар сиңа,— диде Зөфәр, пальто төймәләрен ычкындырып.

— Бик ашыгычмыни?

— Әйе, бүген сөйләшеп куярга кирәк, иртәгә мин сине әллә күрәм, әллә юк.

— Хуш, тыңлап карыйк, нинди ул хәтле килеп терәлгән йомыш икән?

Зөфәр аз гына дәшми торды. Аның бу юлы мәсьәләне уен-көлкесез, җитди итеп, йөрәк эше итеп, яхшылап аңлатасы килә иде. Чөнки сүз Рәшидә белән очрашу турында барачак, димәк, бу очракта Хәмит тә гадәтенчә бары алама итеп кенә уйламасын. Шуны истә тотып, Зөфәр сүзен дусларча җитди-сабыр гына башлады:

— Беләсеңме, Хәмит, мин сиңа бер серемне ачарга тиешмен. Моңарчы ул хакта әйтергә ничектер җае чыкмады. Ә хәзер менә... әйтәм, әйтмичә булдыра алмыйм. Тик син, зинһар, дөрес аңларга тырыш. Мин моннан ай ярым элек, командировкада чакта, бер бик әйбәт, бик... порядочный ханым белән таныштым...

— Бүлмә кирәкме? — диде Хәмит, ваемсыз гына аның сүзен бүлеп.

— Нинди кеше син! — диде Зөфәр, ачынып.— Сөйләгәнне дә көтмисең, сыразы әллә нәрсәгә борасың!

— Борып торасы калмаган монда, мәсьәлә ачык! Сиңа бит хәзер шул... порядочный хатынны алып килер өчен аулак урын кирәк, нигә, дөрес түгелмени?

— Ну, шулай да булсын ди, ләкин син аңла, утын булмасаң, сүз бик җитди эш турында бара. Миңа ул хатын белән чынлап аңлашырга кирәк, чөнки... чөнки бер ай буена мин аның турында гына хыялланып яшәдем. Әйтәм ич, ул бик интересный, бик яхшы хатын...

— Яхшымы-яманмы, карамы-җирәнме — минем өчен барыбер,— диде Хәмит, һич исе китмичә.— Миңа киләсе хатын түгел.

Зөфәр, ниһаять, өметен өзеп кулын гына селтәде:

— Ярар, сиңа сүз әрәм итеп торудан мәгънә юк... Эт таласын үзеңне! Тик иртәгә сәгать җидегә бүлмәң буш булсын, вот шул!

— Рәхим ит! Әнә запасной ачкычны алып китсәң дә була...

Зөфәр өстәлдә яткан ачкычны кесәсенә салды да урыныннан торды.

— Ник әле болай, начальниклар төсле, приказ биреп кенә качасың? — диде Хәмит, урыныннан кузгалмыйча гына.

— Ә сиңа шул приказ гына үтә дә инде, адәмчә сөйләшүне аңламыйсың син.

— Ялгышасың, җан Зөфәр! Миңа иң элек мәсьәләнең деловой ягын хәл итеп куярга кирәк иде, аннары инде, эш юктан, фәлсәфәсен дә тыңларга була. Кем ул интересный ханым, ничек таныштың, нәрсәсе белән ул сине болай тиз генә сихерләп өлгерде? Сөйләп җибәр, булмаса.

Зөфәр акрын гына башын чайкады:

— Юк, хәзер сөйли алмыйм инде, гайрәтемне чигерден... Тик шуны гына әйтәм сиңа: ул хатын турында мин начар уйлый алмыйм... гашыйк булдым шикелле мин аңа... Син шуңа ышанасыңмы?

— Ник ышанмаска?.. Син дә кеше ич, өстәвенә өйләнмәгән егет... Ләкин, минем белүемчә, син гашыйк булыр өчен хатын түгел, ә кул тимәгән кыз эзли иден шикелле...

— Эзләп кенә табылмый икән шул, көтмәгәндә юлыңа килеп чыга икән ул!

— Шулаймыни?.. Кара син аны!.. Хәерле каза булсын!.. Ансыз — дөнья сансыз дигәндәй, миннән фатиха алайса!

— Фатихаңны башыңа капла! Сиңа сөйләгән мин дурак! Ярар, киттем әле мин...

— Ну, бар, бар... Ләкин исеңдә тот — мин бүлмәмдә ниләр булганын белеп торырга тиешмен... Кем белә, сез может монда ялган акча сугып ятарсыз?!

Зөфәр, кызарынып-бүртенеп:

— Иблис син! — диде дә, ачу белән кулын селтәп, ишеккә юнәлде, ә Әйттем-бетте Хәмит «турецкий» диванын шыңгырдата-шыңгырдата кычкырып көлеп калды.

Урамга чыккач та Зөфәр тиз генә тынычлана алмыйча барды. Менә шушы кешенең бүлмәсенә ул Рәшидәне алып килергә тиеш инде. Нишләмәк кирәк, бүтән чара юк. Әлбәттә, Хәмитнең үзен Рәшидә күзенә ничек тә күрсәтмәскә кирәк булыр. Ул сизенә, Рәшидә аның дусишләрен яратмаячак. Хәмит кебек кешеләр белән чуалуын белсә, аның үзенә дә шикләнеп, әллә ни уйлап каравы мөмкин. Гомумән, Рәшидә кебек бөтенләй икенче даирәдән килгән, нечкә табигатьле хатын белән ничек тә сак кыланырга, үзеңне тыйнаграк, акыллырак тотарга кирәк булачак.

Икенче көнне кич, алдан сөйләшү буенча бер кино алдында очрашкач, Зөфәр Рәшидәне Хәмит бүлмәсенә алып килде. Хуҗа кеше — уңган егет — бүлмәсен җыштып һәм җыештырып чыгып киткән иде... Зөфәр башта Рәшидәнең өске киемен салдырып элеп куйды, аннары үзе чишенде... Чишенеп беткәч, бүлмә уртасында басып торган Рәшидәнең каршысына килде дә, бер сүз әйтмәстән, аны иңбашыннан кочаклап үбә башлады. Рәшидә, башын читкә борып, акрын гына:

— Туктагыз! — диде һәм, Зөфәрдән аерылып, өстәл янына барып утырды.

Зөфәр урындык алып, аның каршысына урнашты.

Һәм алар сүзсез генә бер-берсенә карап тора башладылар. Бу сүзгә кадәр күзләре белән бер-берсен сынау, бер-берсенең йөрәген укырга теләү иде. Әйе, асылда бит бу аларның беренче тапкыр икәүдән-икәү генә аулакта очрашулары һәм менә шулай күзгә-күз карашып танышулары иде... Була икән шул моның кебек гайре табигый хәл дә: башта кешеләр, үзләре дә аңламаган ниндидер бер сукыр кодрәткә буйсынып, әллә ничек кенә якынаеп куялар, аннары инде бер-берсен аңларга, белергә тырышалар... Менә хәзер Рәшидә белән Зөфәр дә нәкъ шуның төсле бер хәл кичерәләр иде.

Теге вакытта, иске мәчет сәхнәсендә һәм Мәликә әби өендә, Рәшидә Зөфәр күзенә ничектер яшькә дә, төскә дә кызлар сыманрак булып күренгән иде. Хәзер исә бер дә шикләнмичә аны егерме биш-егерме алты яшьләрдәге ханым дип танырга мөмкин иде; кара чәчләрнең уртадан ачып таралган һәм артка өеп куелган булуы да, күз төпләренең уелыбрак торуы да, хәтта кызыл кофтасының өстендә иркен генә утыруы да аның кыяфәтен әнә шулай олысымак итеп күрсәтә иде... Әмма туры, ачык карый торган коңгырт-кара күзләре, яктырып китәргә торган чиста йөзе, тибрәнергә торган нечкә кашлары белән ул шул ук Рәшидә иде, соклandyрып, дулкынландырып торучы җанга тансык Рәшидә иде.

Тик менә Зөфәр үзе бу минутта Рәшидә күзенә ниндирәк булып күренә икән соң? Егет өстендә таза-тулы гәүдәсенә бик килешле утырган зәңгәр бостоннан әйбәт костюм, ак күлмәк, кара галстук... Аның муены-бите ап-ак шома, киң маңгае да ак мәрмәрдәй бик чиста, кыска гына калдырып китәргән коңгырт-аксыл чәчләре ефәктәй йомшак... Һәм Рәшидәнең җылы бөркегән күзләреннән сизә ул — ханымга аның бу кыяфәте бик ошый кебек, таза ирлек көче һәм басынкы-сабыр карашы ханымны да аңа тарта, дулкынландыра кебек... Юк, алар бер-берсе турында ялгышмаганнар шикелле... бер-берсенә ошыйлар, пар килгәннәр шикелле. Ләкин ни өчендер Рәшидәнең күзләре бүген уйчанрак та, моңсурак та кебек. Нидән икән бу?.. Зөфәр сакланып кына аның озынча ак кулларын үзенең зур учларына алды һәм йомшак-акрын гына:

— Рәшидә, ник берни дә сөйләмисең? — диде.— Безнең бит сөйләшер сүзебез күп булырга тиеш.

Рәшидә, җиңел генә, бер сулап куйды.

— Әйе, күп шул... Ахрысы шуңадыр, нидән башларга да белеп булмый... Сез сөйләгез!

— Миндә дә шул ук хәл! — диде Зөфәр, ханымның кулын сыйпап.

Тагын беразга тынып калдылар, аннары Рәшидә, күптән күңелендә йөргәнне беләсе килеп булса кирәк, кинәт кенә кыюланып сорап куйды:

— Зөфәр абый, әйтегез әле, сез кем?

Зөфәр ни өчендер пошынып аңа карады. Рәшидә ашыгып өстәде:

— Әллә ни уйлый күрмәгез! Кайда, кем булып эшлисез дип кенә соравым... Мин бит әле сезне бөтенләй белмим.

— Әйе, дөрес, безнең чынлап танышканыбыз юк шул әле... Мин, Рәшидә, бер заводның ОРСында эшлим. Сәүдә бүлегенең мөдире булып... Бу сезгә ошап бетмидер инде?

— Нигә алай дисез?

— Сез — искусство кешесе, ә мин әлеге берәү дә яратмаган сәүдә работнигы... Аралар бик ерак ич!

— Минемчә, аның һич әһәмияте юк. Тик кеше үзе яхшы булсын.

— Дөрес әйтәсез... Мин дә шулай уйлыйм, Рәшидә. Төрле профессиядә эшләп тә бер-береңне... аңларга мөмкин ич?

— Әйе,— дип кенә куйды Рәшидә, бүтән нәрсә турында уйга калгандай. Аны тагын нидер борчый иде шикелле... Ниһаять, ул йөзен читкә борып, акрын гына сорады: — Сез... ялгыз кешеме?

Бу юлы Зөфәр бик теләп җавап бирергә ашыкты:

— Әйе, мин ялгыз кеше, Рәшидә... Минем әнием бар, фронтта абыем бар, ләкин үзем хәзергә ялгыз әле.

Моңа каршы Рәшидә бүтән бер сүз дә әйтмәде, әмма аның йөзеннән шундук ниндидер бер соры пәрдә төшкән кебек булды. Зөфәр үз нәүбәтендә: «Ә сез ничек?» — дип сорамакчы булган иде дә, ханымның пәрдәдән ачылуын күреп һәм аннары үземә зарар итмим дигән бик яшерен бер уйдан чыгып, сорамыйча, тыелып калды. Аның исәбенчә, бу сорауны бирергә иртәрәк иде әле.

...Алар тагын шактый гына сүзсез тынып тордылар. Тагын Рәшидәнең ике каш арасы җыерылып, нечкә кашлары тынгысыз тибрәнеп куйды. Күрәсең, тагын ниндидер бер беләсе килгән нәрсә җанын борчып тора башлады. Ахырда ул, тәвәккәл иткәндәй, Зөфәрнең күзләренә туры гына карап, ләкин борчылуын сиздергән тавыш белән тотлыгыбрак сорады:

— Ә сез... сез минем турыда ни уйлыйсыз?

Зөфәр аның бу соравын дөрес аңлады: асылда бу Рәшидәнең үзе турында хөкем ишетергә теләве иде.

— Минме? Мин, Рәшидә, синең хакта бик яхшы уй-

лыйм,— диде Зөфәр, җитди, ләкин мөмкин кадәр йомшак итеп.

— Шундый... хәл булганнан соң дамы? — диде Рәшидә, күзләрен йомып, әкрен генә.

— Әйе, әлбәттә... Ни генә булмасын, мин синең хакта начар уйлый алмыйм, Рәшидә!

— Шулаймы? — Һәм Рәшидә сөенеп аңа елмайды.

Зөфәр кисәк кенә омтылып аңа үрелде, ләкин Рәшидә аның кулын туктатты:

— Кирәкми!

Егет үзенең ашыга төшүен бик тиз сизеп алды, шунда ук кире чигенде һәм озак кына тыелып утырырга мәҗбүр булды. Әйе, Рәшидә бүген бүтәнчәрәк иде шул! Ятсыну яки тарсыну кебек нәрсә һич сиздермәсә дә, киресенчә, бик мөлаем, җылы булып күренсә дә, ул бүген үзен Зөфәрдән беркадәр ерак тотарга тырыша иде. Күрәсең, беренче якынлык әле хатын-кыз өчен гел хиссияткә бирелеп, кочагын ачарга әзер тору дигән сүз түгел; күрәсең, теләмәсәләр, барысын онытырга да, яңадан кабатламаска да аларның кодрәтләре җитә...

Һәм алар күбрәк бер-берсенең күзләренә карашып, шул карашлары белән бер-берсен тикшереп-сынап һәм телдән әйтелмәгән кадәресен аңлатырга тырышып, озак кына сөйләшеп утырдылар. Зөфәр теге вакытта үзе Турайдан киткәннән соң, аларның кайсы авылларда булуларын, ничек йөрүләрен, кайчан кайтуларын сорашты. Бу, әлбәттә, бик әдәпле, бик тыйнак сөйләшү иде, әмма ләкин иң чынын, иң кирәген сөйләшү түгел иде, чөнки бу минутта аларның күңелләрендә бөтенләй икенче уй, икенче хисләр иде. Сүз хәзер бары мәхәббәт турында, бер-берсен сагыну турында барырга тиеш — шул гына аларның күңелендә хәзер, әмма... Һаман нидер тота, кыюсызлыкмы, ялган оятмы телләрен һәм хәрәкәтләрен бәйләп тора иде. Моны аеруча тирән-үткен итеп Зөфәр сизеп утыра, һәм ничек кенә тыелып, әдәп саклап утырмасын, Рәшидә барыбер аны үзенә тарта, барыбер аның тулы иреннәре, күкрәкләре, тар юбкасы аша түгәрәкләнеп беленеп торган төз аяклары аны гел борчып-котыртып тора иде... Белә бит инде ул аны, татыды бит инде, шулай булгач, нигә кирәк бу тыелып азаплану, ялган әдәп саклап маташу? Рәшидә үзе дә сизми дисеңме?.. Юк, сизә булыр, сизәргә тиеш... Әнә бит Зөфәрнең тилмереп каравыннан ул да, барысын төшенгәндәй, исереп китеп, онытылып карый башлый ич!.. Чынлап та иң кадерлесен, иң сакларга тиешлесен кызганмады лабаса, асылда бит инде ул аныкы, йә, ни югалта ул хәзер?!

Шулай уйлады Зөфәр һәм үзенчә бик хаклы дип тапкан шул уй-хисен, тыелгысыз дәртен салмак-киеренке, әмма йомшак тавышы белән дә, ялварулы, әмма көйдергеч карашы белән дә Рәшидәнең йөрәгенә ничек тә үткәрергә, ничек тә аны үзенеке төсле үк хәлгә китерергә тырышты, һәм, ахырда, кара-каршы шундый бер «көйләнүне» сизеп булса кирәк, ул аның кулларыннан тотып, үзенә тарта башлады. Рәшидә зәгыйфь кенә каршылык күрсәтеп, ләкин «барыбер инде!» дигәндәй, ихтыярсыз буйсынып, акрын гына урындыгыннан күтәрелде. Зөфәр, тиз генә торып, аның иңбашыннан кочаклап алды. Ханым бер мәлгә хәлсезләнеп, гүя актык мәртәбә авыр, газаплы үкенүдән: «Нишләдем мин, нишләдем?» — дигән төсле, йөзе белән Зөфәрнең күкрәгенә капланып торды. Һәм шулай аз гына мескенәеп, онытылып торганнан соң кисәк кенә кыюланып башын күтәрде, батыраеп, дымлы күзләре белән егетнең күзләренә төбәлде һәм аяк очларына басып, кибеп киткән иреннәре белән егеткә үрелде.

Аннары алар урын өстендә озак кына тынып, уйланып, ара-тирә сөйләшеп яттылар. Шул чакта Зөфәр, шушы минуттан үзен ничектер өстен, хуҗа бер кеше итеп сизгән хәлдә, Рәшидәдән шәхси тормышы турында (дөресрәге, ире бармы-юкмы — шул хакта) сорашып алды. Рәшидә бу хакта сөйләргә бер дә теләк сиздермичә бераз уйланып, көттереп ятты, шуннан соң гына артык җәелмичә кыска гына сөйләп бирде: әйе, аның ире булган. Фин сугышы алдыннан ул бик яшьли генә берәүгә, ачыграк әйткәндә, опера театрының бер музыкантына иргә чыккан... Ленинградтан килгән кеше булган икән ул үзе.... Менә шул ире, фин сугышы башлангач, киткән. Ләкин ул аннан кире борылып кайтмаган, шактый вакыт хәбәрсез торганнан соң, мин монда урнаштым, Казанга кайта алмыйм, теләсәң үзең кил, дип хат кына язган... Рәшидә, билгеле, аның артыннан бармаган, чөнки ул татар артисткасы, татар сәнгатендә эшләргә тиеш.... Шулай итеп, музыкант белән аның арасы өзелгән... Үкенми ул үзе бу эшкә, оныткан инде ул аны, чөнки башта ук аларның бәйләнешләре ныклы була алмаган. Музыкант коточкыч эгоит булган, Рәшидәне аңламаган, аңларга да теләмәгән, гомумән, аңа син кем дә мин кем дип бик югарыдан гына караган. Әйе, менә шул... Яшьлекнең үкенечле хатасы — газабын инде ул үзе генә белә!

Шулай тыелып кына, әрнүен-үкенечен эченә йотып кына сөйләп бирде Рәшидә башыннан кичкәнен. Авыр һәм ямьсез тәэсир калдырды аның бу сөйләгәннәре

Зөфәрдә... Дөрес, башта кыска гына бер ара аның күңелендә Рәшидәне кызгану тойгысы уяна язып куйды. Ләкин бик тиз бу күбәләктәй зәгыйфь тойгыны ачу, нәфрәт, көнчелек кебек аюдай зур усал тойгылар басып китте. Көнчелек аның ирлек горурлыгын күсе кебек кимерә башлады, ә музыкантка җен ачулары кабарды: менә шул бурзай чәйнәп ташлаган чеби хәзер аның янында ята түгелме соң?! Әмма Зөфәр эчендәгесен тиз генә тышка чыгара торган кеше түгел, шуңа күрә бер сүз, бер хәрәкәт белән дә ул йөрәгендә купкан тойгыларын сиздермәде, тик салкын бүрәнәдәй кирәгеннән артык җансыз тын калып, иреннәрен кысып, чалкан ята бирде. Рәшидә, билгеле, аның хәлен ачык сизде һәм, үз нәүбәтендә, дәшмичә, орынмыйча ни булып бетәсен генә көтеп ятты. Зөфәр алдында ул үзен һич гаепле итеп тоймый иде, нәрсә өчен булса да акланырга кирәк дип тапмый иде, ләкин шуңа карамастан Зөфәрне нигәдер азрак кызгана да, ихтыярсыздан, аны югалтмыйм дип курка да иде. Әллә ничек менә шушы авыр сөйләшүдән соң ул аны бик бирелеп, бик саф итеп яратыр иде кебек.

...Алар арасында бу хакта шул көнне дә, соңыннан да бүтән сүз булмады. Зөфәр Рәшидәнең үткәненә юри яңадан кайтырга теләмәде, вакчыл-көнче булуга караганда, искитмәгән горурлык күрсәтүне отышлырак дип санады, шуңа күрә эчен тырнаган ямьсез тойгыларны ничек тә басарга һәм Рәшидәгә мөнәсәбәтен үзгәртмәскә тырышты, әмма шуның белән бергә үзе өчен бик җитди нәтиҗәне ясап та куйды: юк, Рәшидә аңа лаек хатын түгел! Ул инде өйләнмәгән егет башы белән ниндидер бер килмешәк ташлап киткән шактый җилбәзәк хатынны үзенә гомерлек яр итмәячәк! Аның кебек кешегә, вакыты җиткәч, кул тимәгән чәчәктәй саф кыз да табылыр... Асылда бит бу аның күптән күңелендә йөрткән чын теләге, татлы хыялы — аны инде филармония артисткасы гына үзгәртә алмаячак.

Ләкин, әнә шундый нәтиҗәне ясап куюга карамастан, Зөфәр Рәшидәне тиз генә ташларга һич уйламый да иде. Ни өчен ташларга? Аның кебек ялгызакның бер «күңел юаткычы» булырга тиеш түгелмени? Ничек диләр әле, сөяркә, диләрме? Әйе, нәкъ менә үзе!.. Ә Рәшидә сөяркә булыр өчен бик тә уңай, бик тә кулай хатын инде. Үзе япа-ялгыз, үзе чибәр-сылу, үзе яшь артистка — мондыйны бит кешеләр махсус эзләп тә таба алмыйлар! Юк, ташлау түгел, аны ничек тә сакларга, саклау гына түгел, кадерләп тотарга да кирәк иде әле. Күпмегә кадәр бу

сузылыр — ул хакта алдан юрап куймаска да мөмкин, вакыт үзе күрсәтер.

Алар Хәмит бүлмәсендә әледән-әле очраша торган булдылар. Рәшидә шәһәрдә чакта бу очрашу шактый еш кабатланды, ә гастрольгә чыгып киткән чакларында озак кына өзелеп тә торгалады. Мондый вакытларда Зөфәр аны бик юксынып, сагынып көтә иде. Ничектер ул аңа бик ияләште... Аның эштән башка бүтән бер кызыгы да булмаган шактый күңелсез тормышына Рәшидә ниндидер ямь-яктылык алып килә иде. Уйламыйча, сагынмыйча, теләмичә тора алмый иде ул аны! Һәм озак торып очрашкан минутларда «сайрар кошын» иркәләп-сөеп туймый иде ул... Ә соңыннан борчылып уйлана иде: бу ни хәл бу, бик тирәнгә китте түгелме соң бу, ахыры ни белән бетәр моның?! Хәер, мондый борчылу бик тиз яңадан сагына башлауга әйләнеп кала иде. Акыл исәбе түгел, йөрәк таләбе көчле чак иде шул әле!

Рәшидә исә Зөфәрнең кайнар «мәхәббәтеннән» тәмам сихерләнеп, шуңа чиксез куанып, беткәнче аныкы гына булып йөри бирде. Билгеле инде, ул үзен сөяркә итеп танудан бик ерак иде, хәтта андый нәрсә бер генә тапкыр булсын аның күңеленә дә килмәде... Киресенчә, бик сәер башланган бу якынлыкны ул ихтыяри, тигез, шунлыктан чын, саф мәхәббәт дип уйлый иде. Асылда бит ул Зөфәрнең нинди кеше булуын, нинди уй, нинди теләкләр белән яшәвен бөтенләй белми дә иде.

Менә шуңа күрәдер инде егетнең әледән-әле сынап: «Яратасыңмы?» — дип, соравына каршы Рәшидә балаларча бик самими итеп, гел бер үк сүзләр белән җавап кайтара иде:

— Әйе, яратам!

— Ни өчен яратасың?

— Ни өченме? Әллә тагын... Моны әйтеп буламы икән соң? — Ул, чыраена җитдилек бирергә тырышып, кашларын җыерган була, ә үзенең шук йөзеннән шат көлү пырхылдап очарга гына тора.— Син әнә нинди дәүсең, тазасың, ә үзең бик сабырсың, йомшаксың... мин бит тупас ирләрне бер дә яратмыйм... әйе, күңелең йомшак, мөгамәләң йомшак... миңа рәхәт синең белән... Менә ни өчен яратам шикелле мин сине, акыллы, сабыр, җирән кашкам! — Һәм шаркылдап көлеп, ул иркә песидәй егетнең киң күкрәгенә сыена иде.

Бу аның бәхетле минутларында шаярып сөйләнүе иде. Ләкин бер кичне нәрсәдәндер борчылып уйга калган чагында ул үзенең гамәлен Зөфәргә бик җитди-ачык итеп тә әйтеп бирде:

— Мин беләм, Зөфәр, синең миңа ничек каравыңны,— диде ул, әкрен-моңсу гына.— Ансат кына кулыгызга төшкән хатын-кызга сез, ирләр, гомумән, бик түбән карыйсыз... Аңламыйсыз сез аларны... Йә, ни өчен мин сине беренче килүеңнән үк... кабул иттем?.. Ир кирәктән дисең инде син, телдән әйтмәсәң дә, эчеңнән шулай уйлыйсың. Хәер, синең урынында кайсы ир дә шулай уйлар иде... Ә бит мин авыл-район җирләрендә һаман йөреп торам, төрле кешеләр белән очрашырга туры килде миңа, синең кебек мыштым гына үрмәләп килүчеләр аз булмады, ләкин мин аларны тибеп кенә очыра идем... Ә бу юлы... бу юлы мин алай эшли алмадым... Ходаем, ни булды соң миңа, ничек соң мин шулай... онытылдым?.. Белмим, белмим!.. Тик шуны беләм: син беренче күренүдән үк әллә ничек менә күңелемне җилсеттең... яхшы кеше, ягымлы кеше булып күрендең син минем күземә, Зөфәр!.. Ләкин ул гына аз әле, ул гына җитми әле... Бер хатын да, кеше миңа ошады дип кенә, акылын җуймый, юк!.. Тагын нидер кирәк иде, әйе, нидер кирәк иде... Хәтерлисеңме, акыллым, Турай клубында мин җырлап бетергәч, халык миңа ни диеп кычкырды?.. «Безнеке кебек сугыш кырларында йөргән ярың булса, исән-сау кавышырга насыйп итсен»,— дип кычкырды бит! Ә минем юк, көтәр беркемем дә юк, мин ялгыз!.. Ялгыз, ялгыз!.. Әгәр минем көтәр кешем булса иде, мин, намусыма түгел, кигән туфлиемә дә тузан бөртеге төшермичә, аны көтәр идем, биш ел да, ун ел да, гомерем буена да көтәр идем. Ләкин юк шул, юк, кәккүктәй ялгыз мин! Аңлыйсыңмы син шуны, Зөфәрем-?! Акланырга тырыша дип уйлый күрмә, Зөфәр! Юк, мин акланырга теләмим, аклана белмим, тик шул чактагы хәлемне аңлатыр өчен, мин сиңа бөтенесен ачыктан-ачык сөйлим генә... Син бел, барысын да бел!.. Әйе, мин ялгыз хатын, миңа әле егерме дүрт яшь кенә, үзең күргәнчә, елның җиде-сигез аен авылларда йөрүче, кайткан чакларында бер карчыкның юеш почмагында торучы, ятарга үз караваты да булмаган билгесез бер артистка — менә мин кем. Әмма минем мәхәббәткә һәм бәхеткә хакым бар иде. Миңа җылы кирәк иде, юаныч көттем, күңелем эчкерсез дуслыгы кирәк иде... Мин көттем, күңелем белән бик күптән көттем... Ниһаять, син очрадың... Мин беренче караштан ук гашыйк булуга ышанмыйм, әмма салкын вокзал эчендә син каршыма килеп баскач, йөрәгем, сискәнеп, миңа: «Менә ул кеше!» — диде... Әйе, нииндидер бер тетрәнү, уяну, сагаю бөтен эчемне өшетеп, эсселәндереп узды... Менә ничек башланды ул... Ә син безнең белән ачык кына, йомшак кына сөйләштең. Авыр хәлебезгә ке-

реп, тизрәк атлар да табып китерден... Өстемә толыбыңны бирдең, аякларымны салам белән урадың, юл буе салкыннан өшемиме бу, дип кайгыртып бардың. Һа, ир кешенең әнә шундый эчкерсез яхшылыгын хатын-кыз аңлый белә ул, бәяли белә, дустым!.. Әгәр шул чакта син бер генә хәрәкәт яки сүз белән үзеңнең берәр яшерен теләгеңне сиздергән булсаң, ант итеп әйтәм, безнең арада һични булмас иде. Алай гына да түгел, минем йөрәгем шунда ук йомылган булыр иде, син минем өчен югалган, беткән булыр идең... Ышанасыңмы?.. Ләкин син фатирга төшкәч тә, концерттан кайтып, ашап-эчеп утырган чакта да үзеңне гаҗәп тыйнак, әдәпле тота белдең. Миңа бик игътибарлы булдың, хәер, бер миңа гына түгел, безнең барыбызга да чын кешечә бертигез була белдең... Һәм минем күңелем шуңа балаларча сөенеп, сиңа һаман тартыла, якыная барды... Тик син моны дөрес аңла, Зөфәр, дөрес аңла, бу бик саф, гөнаһсыз, керсез хис иде. Юк, мин сиңа ир итеп кенә караудан, сине ир итеп теләүдән бик, бик ерак идем. Мин гүя кеше таптым, кешегә сокландым, шул кешенең үзе, җылы-йомшак мөнәсәбәте миңа тансык иде, миңа кадерле иде...

— Ә соңыннан? — диде Зөфәр, сак кына.

— Мин беләм синең нәрсә уйлап соравыңны, Зөфәр,— диде Рәшидә, ашыгып; кинәт аның күзләренә яшь килеп тулды, һәм ул бугазына күтәрелгән төерне йотып куйды.— Ашыкма, мин сөйлим, барысын да... Син белергә тиешсең... Әйе, ул төнне мин дә йоклый алмыйча яттым. Синең йокламавыңны белеп, һәр кыймылдавыңа колак салып яттым... Көттемме мин сине? Әйе, көттем, яшермим. Мин бит үзем дә тынычлыгымны җуйган идем. Хәтта син миңа тиярсең дигән курку да күңелемә килмәде... Нишлим, үзе егылган еламас, диләрме, менә шул инде... Әйе, мин сиңа ачулана да, рәнҗи дә алмадым, чөнки ул син идең, син булганга күрә генә мин... синеке булдым... Әмма шул хәлдән соң минем ниләр кичергәнемне белсәң иде!.. Әле кочагыңда чакта ук инде мин шул минуттан сиңа буйсынган зәгыйфь бер хатын булып калуымны тойдым. Кинәт үземне кызганудан күземә яшьләрем килде, һәм йөрәгемә авыр бер төер утырып калды... Хәзер дә ул төернең беткәне юк. Ләкин шул кичтән соң мин синең өчен яши башладым, Зөфәрем!.. Барысы да сиңа, барысы да синең аша гына. Хатын-кыз мәхәббәте шулай ул — үземә дими, аңа булсын, ди. Бәхетне дә, рәхәтне дә үзе биреп кенә таба ала... Тик... тик үкенечкә генә булмаса ярар иде!..— Һәм Рәшидә әкрентирән сулап башын иде, тынды, бүтән кузгалмады.

Аның бу беренче һәм соңгы мәртәбә рәхимсез ачыклык белән сөйләгән сүзләреннән Зөфәр үзе дә ни әйтергә белмичә озак кына тынып утырды. «Әйе, мәсьәлә шактый катлаулы икән!» — дип, ихтыярсыздан уйланып калды ул һәм Рәшидәнең моңарчы күпме үкенү, икеләнү газаплары кичереп килгәнлеген үз күзе белән күргәндәй булды. Кеше кайгысын тыңлап, йөрәгенә якын алып өйрәнмәгән булса да, ул Рәшидәне чынлап кызганды һәм аңа тагын да йомшаграк, игътибарлырак булырга кирәк дигән фикергә килде... (Әйе, онытсын бичара үзенең бу әрнү-үкенүләрен, югыйсә икесенә дә кыен ич болай!) Шуның белән бергә, реаль уйлаучы кеше буларак, ул Рәшидәнең ялгызлыктан зарлануыннан икенче бер нәтиҗә дә ясап куйды: тормыш хәзер бик авыр, кытлык-мохтаҗлык бик зур, бигрәк тә артистка кеше бу мохтаҗлыкны авыр кичерәдер, димәк, аңа аз-маз ярдәм дә иткәләргә кирәктер... Ихтимал, Рәшидә үзе дә моны эченнән өмет итеп йөридер... Ничек кенә булмасын, хатын-кыз бүләк алырга ярата ул... Шулай хөкем итте Зөфәр. Элек тә бу хакта уйланганы бар иде, хәзер исә уңай форсат чыкты дип исәпләде.

Һәм озак та үтми бер очрашуларында ул Рәшидәгә маркизет күлмәклек китерде. Рәшидә моңа бик куанды, күктәй ачык зәңгәр маркизетны кат-кат тотып та, сүтеп тә, өстенә каплап та карады. Бик килешә икән, диде, выходной күлмәк тектереп була икән, диде, аннары, күпме тора соң бу, дип тә сорады. Зөфәр аңа, ваемсыз гына, күпме торганын сорама, мин сиңа бүләк итеп китердем, диде. Рәшидә моны ишеткәч, берьюлы җитдиләнеп, хәтта караңгыланып китте.

— Юк, мин синнән бүләк кабул итә алмыйм,— диде ул, салкын-коры гына.

Зөфәр, артык гаҗәпләнүдән, бераз ни әйтергә белмичә торды.

— Туктале,— диде ул, күзләрен зур ачып.— Ни өчен алмыйсың? Мин бит шаярып әйтмим... Чын ихластан сиңа бүләк итеп китердем!

— Рәхмәт, ышанам, ләкин барыбер ала алмыйм! Әйтмәгән булсам, белеп тор: түләүсез мин синнән төймә дә алачак түгелмен!

— Бу ни өчен тагын?

— Шулай. Намусым кушмый. Хурланам... Бүләк түгел, түләү бу... Юк, юк, кирәкми...

— Гаҗәп, гаҗәп! — диде Зөфәр, шаккатудан кулларын җәеп.

— Бер дә гаҗәпләнер урын юк монда! — диде Рәшидә,

нигәдер һаман кыза һәм гасабиләнә барып.— Без тигез кешеләр! Беләсеңме шуны — тип-тигез кешеләр!.. Мәхәббәтемне бирәм, мәхәббәтеңне алам, әмма өстәү кирәкми, түләү кирәкми... Андыйлардан түгел мин!

Аның кашлары тартылды, күзләре кинәт яшь белән тулды һәм, Зөфәр каршы бер сүз әйтте исә, һичшиксез, үксеп елап та җибәрер иде. Зөфәр нәкъ кирәк минутта тыела белде. Хәер, Рәшидәнең һич көтелмәгән яктан бу кадәр кинәт ачылып куюы аны шундый гаҗәп-хәйранга калдырды ки, гомумән ни дә булса аңлаудан һәм әйтә алудан ул ерак иде әле. Тик күпмедер вакыт үткәннән соң гына урындык аркасында эленеп яткан маркизетка ымлап, сорап куйды:

— Кире алып китиммени инде?

— Юк, нигә, калдыр... Мин акчасын түләрмен...

— Ә мин нинди йөз белән синнән акча алыйм? Шул хакта да уйладыңмы син?

Рәшидә килеп Зөфәрнең иңбашына кулын салды — ул инде бераз тынычлана төшкән иде.

— Үпкәләмә! Мин бит сине гаепләмим, акыллым! Беләм, син ихлас күңелдән мине куандырырга теләгәнсең... Рәхмәт моның өчен, рәхмәт! Ләкин син дә мине аңла инде: кабул итә алмыйм мин бүләк, бигрәк тә синнән, бигрәк тә хәзергедәй авыр чакта...

Зөфәр, кабаланып, аның сүзен бүлде:

— Ну, ярар, бүләк булмасын, бүләк түгел, ди, ярдәм... Ярдәм итәргә генә минем хакым бардыр бит инде?.. Моны җиде ят та бер-берсенә эшли...

Рәшидә, ихтыярсыз елмаеп, Зөфәргә бармак янап алды:

— Һай, хәйләкәр дә соң үзең! Ярдәм, имеш!.. Ярый алайса, дустым, ярдәмгә мин дә каршы түгел... Менә нинди әйбәт материя табып китергәнсең, бик кыйммәт тормаса, мин аны алып калырмын. Шушы инде синең миңа зур ярдәмең булыр. Зөфәрем табып бирде, дип мин аны куана-куана киеп йөрермен! Дөресме?

Зөфәр артык бәхәскә кереп тормады, чөнки Рәшидәнең үз сүзендә нык торачагы көн кебек ачык иде. Уйлый белгән кешегә бу кечкенә вакыйгадан шактый гыйбрәтле нәтиҗәләр ясарга мөмкин иде: Зөфәрне иң нык гаҗәпләндергәне — Рәшидәнең үз абруен һәм горурлыгын саклауда искиткеч катылык күрсәтүе булды. Көтмәгән иде ул моны, һич көтмәгән иде... Әгәр артистканың тормышы шәптән булса, бер хәер иде. Югыйсә көнен көнгә чак ялгап, бик авырлык белән генә алып бара бит!.. Беренче генә очрашулары түгел — Зөфәр моны күптән

сизеп-күреп өлгергән иде инде. Кайбер килүләрендә Рәшидә күңелсез, боек була, озак кына башын тотып хәлсезләнеп утыра. «Ни булды, әллә авырыйсыңмы?» — дигәч, тизрәк елмаерга тырышып: «Юк, авырмыйм, болай гына»,— дип әйткән була торган иде. Ләкин, никадәр генә яшермәсен, бу хәлсезләнеп, боегып калуның сәбәбе, нигездә һаман шул авыр мохтаҗлыктан, туры гына әйткәндә, ачлы-туклы торудан килеп чыкканлыгын белү бер дә кыен түгел иде. Соңга табарак Зөфәр Хәмит бүлмәсендә икесе өчен генә сый да әзерли башлаган иде. Плиткада бик әйбәт төсле кофе кайнатып ала, табынга ак күмәч, май, шикәр, ит яки балык консервысы ачып куя һәм кунагын каршысына гына утыртып, сыйларга тотына иде. Шул чакта Рәшидә, бичара, нихәтле генә күңелсез булмасын, бөтенләй икенче кешегә әверелеп китә иде. Юк, ул ашка ташланмый, юк, бик әдәп саклап, матур итеп, нечкә бармаклары белән аз-аз гына алып ашый, әмма шул сыйларга кагылу белән аның кәефе нәкъ балаларныкы төсле булып үзгәрә иде. Шунда ук сөйләнә, көлә, шаяра башлый, ә ашап туйгач, хәтта: «Синең өчен генә!» — дип җырлап та куйгалый иде.

...Һәм менә шул хатын Зөфәрнең китергән бүләген алмады, катгый рәвештә кире какты!.. Әйе, гыйбрәт бу... Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар — шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!

Рәшидәнең Зөфәрне әнә шулай гаҗәп-хәйранга калдырган чаклары аз булмады. Бриллиант кисәгедәй йә үзәге, йә берәр кырые белән кинәт нур чәчеп, чагылып куйгалый иде ул... Аеруча хыял матурлый торган иде аны...

Зөфәрнең юмарт мәхәббәтеннән һәм сыеннан кәефе бик яхшырып киткән минутларда ул үзенең кадерле хыялларын, хыял иткән максатларын дәртләнеп сөйләргә тотына иде... «Мин лирик героиня булырга телим»,— ди иде ул Зөфәргә, бик зур серен ачкандай итеп.— Эстрада җырчысы булып йөрүдән тәмам туйдым, аннары ул мине һич канәгатьләндерми, минем сәхнәдә уйныйсым килә, төрле-төрле образлар тудырасым килә, аңлыйсыңмы?.. Бу минем хыялым, сугыш кына бетсен, мин барыбер театрга күчәчәкмен... Әйе, менә әйтте диярсең! Миндә бит теге ни, әлеге драматический талант бар, беләсеңме син шуны?.. «Гроза»дан Катеринаны яки «Мәкер вә мәхәббәт»тән Луизаны мин сиңа шундый итеп уйнап күрсәтер идем, җанкисәгем... Һо! Чәчләрең үрә торыр

иде!.. Ышанасыңмы, юк, әйт, ышанасыңмы?.. Алайса менә шул!.. Үзебезнең әйберләрдәнме?.. Үзебезнең әйберләрдән «Галиябану»ны бик яратам. Галиябануны уйнаганым да бар... Телисеңме, мин хәзер сиңа аны уйнап күрсәтәм, юк, телисеңме?»

Һәм ул, җавап та көтмичә тиз генә торып, кыек яулыгын татар кызларыча башына бөркәнеп, җиңел генә атлап тәрәзә кырыена бара. Шунда ук бөтен хәрәкәт-кыланышы белән нәфис-сылу Галиябануга әверелеп уйный да башлый. Искиткеч үзгәреш!.. Урамнан исемен атап җырлаучыларны ишеткәч, нәкъ менә кыр кәҗәседәй куркып-сагаеп та калган, сөенеп-очкынланып та киткән, борчылып-сабырсызланып та көткән унсигез яшьлек саф, садә авыл кызы күз алдына килә дә баса. Инде ул, тәрәзә яңагына ышыклана биреп, Хәлиленә каршы әкрен генә, дулкынланып, тибрәнеп кенә җырлап та җибәргәч — бетте, моның кебек тулы иллюзияне сәхнәдә дә сирәк күрерсең!.. Әйе, бар икән, бар икән үзендә илаһи, чын талант, кодрәтле талант!..

Рәшидә үзе дә шуны ачык тоеп, шуңардан әйтеп бетергесез сөенеп, Зөфәр янына атылып килә дә, алдына утырып, муеныннан кочып ала.

— Сәнгатьне яратасыңмы син? Театрны яратасыңмы син, абыем? Әллә артистканың үзен генә яратасыңмы? — ди ул, балаларча сыенып-сыйпаланып.

— Яратам, яратам, сине дә, театрны да, Галиябануны да — барыгызны да яратам! — ди Зөфәр, Рәшидәнең яшьләнеп киткән күзләреннән үбә-үбә.

Һәм иң гаҗәбе — һич риясыз әйтә ул моны, шушы минутта хис иткәнен әйтә, чөнки бу минутта ул үзе дә ничектер икенче төрлерәк кеше булып китә иде. Шушындый гүзәл, ак хыяллы, нечкә, пакь җанлы бер хатынның якын, ышанычлы кешесе булу аны ничектер үз күз алдында үстереп җибәрә, күңелен әйбәт бер горурлык белән тутыра иде. Алай гына да түгел, бүтән бервакытта да татырга туры килмәгән, бары чын матурлыктан, якты уйлардан гына килергә мөмкин булган аеруча тирән, олы бер бәхет кичергән кебек тә була иде ул...

Һәм менә шундый чакларында Зөфәр, артисткага «сөяркә» итеп кенә каравын онытып, әгәр сорасам, Рәшидә миңа иргә чыгар идеме икән, дип тә уйлый торган иде. Бу хакта алар арасында бер генә тапкыр да сүз булганы юк; егет кирәк тапмагач, кыз бервакытта да үзе башламый инде, билгеле... Ләкин, Зөфәр исәбенчә, Рәшидә аңа чыгар иде, бик теләп чыгар иде, чөнки Рәшидә аны ярата, аңа ышанып карый. Моны исбат итеп торасы да юк...

Дөрес, Рәшидә «торгашларны» бер дә яратмый, сәүдә тирәсенә оялаган кешеләрнең күбесен жуликлар дип саный, ләкин Зөфәрне ул «торгаш» дип белми иде. Киресенчә, Зөфәр зур заводның ОРСында бүлек мөдире булып эшләгәч, ул аны дәүләт ышанычын казанган җаваплы работник дип исәпли иде. Һич шикләнмичә, гадел, намуслы, яхшы кеше дип уйлый иде ул аның хакында... Бер дә гаҗәп түгел, чөнки Зөфәр, болай өстән караганда, әйбәт кеше иде, аннары, киресенчә, гомумән ул үзен иң уңай яктан күрсәтә дә белә иде. Рәхим ит, ул игътибарлы да, ачык йөзле дә, йомшак телле дә, тыйнак, сабыр да, кыскасы, милый человек!

Шуның белән бергә ул гаять сак кеше дә иде, бервакытта да артыгын сөйләмәс, күбрәк бик акыллы итеп дәшмичә торыр, шуңа күрә дә ул Рәшидәне рәхәтләнеп тыңлады, тәэсирләнде, сокланды, әмма үзенең уй-теләкләрен аңа һичкайчан сөйләмәде — иң яратып, нечкәреп, күңеле белән беткәнче ачыласы килеп якынайган чакларында да йомык-бикле булып калды... Акыл искиткеч уяу иде аңарда!

Әйе, тормыш схемаларны вата. Йөрәкләр бергә, тәннәр бергә, ә теләкләр үзгә, уйлар башка! Зөфәр өчен Рәшидә, күпме генә ул аны яратмасын, һаман шулай мәхәббәткә юмарт, уңай сөяркә булудан — узмады, чөнки аның идеалы Рәшидә түгел иде. Ә менә кешегә бик ышанучан, кеше турында бары яхшы итеп кенә уйлаучан, беркатлы садә-самими яшь ханым өчен исә Зөфәр бик әйбәт, бик сөйкемле егет иде, һәм ул аны ир итеп кенә түгел, күңеленә ошаган кеше итеп тә чын ихластан бирелеп яратты. Өйлән, ал мине, дип әйтергә кыймады, әлбәттә, ләкин шулай да эченнән генә һаман өмет итте булса кирәк...

1944 елның җәендә Рәшидә, башка артистлар белән бергә фронтка барып, ай ярым чамасы сугыш кырларында йөреп кайтты. Кайткач ул Зөфәргә фронтта күргәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирде. Төрлесеннән — куркынычыннан, кызыклысыннан — бик күп нәрсә җыеп кайткан икән үзе дә. Тик кавышу шатлыгыннан булса кирәк, күбрәк кызыклысын, ул, мин сиңа әйтим, солдатларның аларны искиткеч сөенеп, кочаклап-күтәреп каршы алуларын, концертларны балалардай йотлыгып тыңлауларын, ул, мин сиңа әйтим, зур-зур командирларның, хәтта генералларның аларны гаять хөрмәтләп йөртүләрен, бик шәп сыйлап кунак итүләрен, инде шуның өстенә тагын аңа, Рәшидәгә, бер йөзләп кешенең гашыйк булуын, хәтта бер яшь кенә подполков-

никның болар киткән чакта, кап-кара куркыныч пистолетын чыгарып, моңа сузуын, «Нигә бу миңа?» — дигәч, тегенең кулын йөрәгенә куеп: «Ханым, ташлап киткәнче атып китегез!» — дип ялварып әйтүен — һәм башкаларын, һәм башкаларын, гадәтенчә ялкынланып, бик матур тасвирлап сөйләде ул... Һәм аның шушы эчкерсез ышанып сөйләгән сүзләреннән Зөфәр үзе өчен бары бер генә нәтиҗә ясый алды: «Юк инде, артистка белән башың бәйләнә күрмәсен! Гомергә уртак хатынның ахмак ире булып йөрерсең шунда!..» Күп кенә ирләр төсле, чын мәхәббәтнең һәртөрле хыянәт-түбәнлекләрдән саклавын ул белми дә, аңламый да иде.

Сугыш беткән көннәрдә аларның мөнәсәбәтләре әнә шундый хәлдә иде. Ике төрле кеше, ике төрле мәхәббәт асылда, ләкин, ничек кенә булмасын, алар бер-берсенә бик нык бәйләнгәннәр иде инде. Сугышның бетүе исә алар арасындагы бу бәйләнешкә һичшиксез зур йогынты ясарга, аны теге яки бу якка үзгәртеп җибәрергә тиеш иде. Бигрәк тә Зөфәр, тыныч шартларга килеп эләккәч тә, үзенең күптәнге җитди планнары турында уйлана башлады. Рәшидә мәсьәләсе арткарак күчте. Ләкин якынлык өзелмәде, ул тик бераз сүрелә генә төште. Кыскасы, алар арасындагы тарихның башы булды, дәвамы булды, әмма ахыры юк иде әле.

## VI

Сабитовлар Суконныйдагы аулак урамнарның берсендә, ике катлы бүрәнә йортның түбәнге катында барысы бер гаилә булып торалар иде. Ниндидер бер вак купецтан калган бу йорт, ишле халык тору аркасында һәм соңгы егерме биш-утыз ел эчендә һичбер ремонт-мазар күрмәгәнлектән, шактый нык тузган иде инде. Түбә калае тутыгып, күп җирдән тишкәләнгән, нигез өстендәге бүрәнәләре һәм тәрәзә аслары яртылаш черегән, ә болдыр баскычлары күптән череп, чалышаеп беткән иде. Йорт үзе дә, тезләнергә җыенган дөядәй, алга таба чүгә башлаган иде. Хәер, бу урамдагы эреле-ваклы агач йортлар барысы да диярлек йә алга, йә бер янтыкка таба чалышаеп торалар. Картайган, тузган иске Казан урамы! Мондый урамга килеп керсәң, ничектер, борынгы заманга әйләнеп кайткан шикелле буласың.

Зөфәр сугышка чаклы ук әле үзенә квартирмы, өйме сатып алу турында исәп тотып йөрде. Сугыш вакытында бу теләкне гамәлгә ашыру бик ансат иде, йортларын са-

тучылар күп булды, һәм азык бәяләренә нисбәтән арзан гына алырга да мөмкин иде. Ләкин Зөфәр, төрле исәпләрдән чыгып, мондый зур тәвәккәллек сорый торган эштән ул чагында тыелып торуны хәерлерәк күрде. Хәзер исә, сугыш бетү белән, йорт сатып алу мәсьәләсенә ул чынлап тотынды. Аныңча, бу эшне хәзер озакка сузарга ярамый иде. Бердән, йортларның бик кыйбатланып китүе мөмкин, икенчедән, кулда зур сумма акча асрап яту да файдалы эш түгел... Дөнья хәлен белеп булмый, акчаның малга әйләнә торуы хәерлерәк...

Җәйгә чыгу белән Зөфәр, абыйсының кайтып җитүен дә көтмичә, ышанычлы кешеләре аша йорт караштыра башлады. Сатарга теләүчеләр бар иде, аңа төрле җирдән йортларның төрлесен тәкъдим итеп карадылар. Ләкин Зөфәр күңеленә ошаганы һаман табылмады. Бигрәк тә ул күбесенең районын яратмады. Татар ягыннан яки Суконный тирәсеннән аның аласы килми иде. Татар ягында кайчандыр аларның матур, җыйнак кына үз өйләре бар иде, ләкин нэп ахырында әтиләренең түләнмәгән налогы өчен аны «чүкечтән» сатып җибәрделәр. Күп кенә авыр хатирәләр белән бәйләнгән җиргә Зөфәрнең яңадан әйләнеп кайтырга күңеле тартмый иде. Гомумән, ул сазлык буенда утырган Татар бистәсенең үзеннән дә һәм кайбер вакчыл, көнче кешеләреннән дә бик бизгән иде. Шулай ук Суконный тирәсе дә аның өчен кулай түгел. Монда да аларны белүче көнче күзләр һәм озын телләр шактый күп. Шуңа күрә ул булачак йортын шәһәрнең яшеллеккә бай югары өлешеннән, урыслар арасыннан эзләтте.

Зөфәр өчен бу эштә Курамшин дигән карт бик тырышып йөрде. Курамшин андый-мондый гына татар карты түгел иде. Чын булса, ул заманында коммерческий училище бетергән, Уралдагы бер татар миллионерында доверенный булып эшләгән кеше икән. Моны ничектер аның тышкы кыяфәтеннән үк сизеп була иде. Эре сөякле, озын буйлы бу кеше кайчандыр бик мәһабәт — таза булганга охшый; хәзер дә әле, йончып, шиңеп бетсә дә, һәм киң аркасы бөкрәеп чыкса да, гүя борынгы килбәтен сакларга теләп, гәүдәсен ничек тә туры, ә ап-ак чәчле зур башын текә тотып йөрергә тырыша. Тирән сызыклар ярып төшкән кызыл чырайлы битен һәм киң ияген шоп-шома кырып, ә җәенке борынын күмә язган ап-ак калын мыегын, борынгы генералларча, як-якка сузып, тарап йөртә. Тавышы көр, сөйләгәндә гөрелдәп чыга; үзе русчага шундый оста, шундый саф, чиста итеп сөйләшә — татар ке-

шесе дип тә белмәссең. Гомумән, аңарда татарныкы дип әйтерлек берни дә юк иде.

Тик картның өсте-башы бик начар. Ел әйләнәсе диярлек бер пальтода йөри, ул да шул доверенный чагыннан ук калган булса кирәк, эче тәмам телгәләнеп, җиң очлары, чабулары кыршылып, зур төймәләре яртылаш сынып беткән. Әмма тышлыгы гомерлек бер драптан булганга күрә, һаман әле картның эчке ялангачлыгын яшереп, тышкы килбәтен саклап йөртә. Бу пальто картны, ахрысы, каберенә дә озатып куяр... Ләкин өс-башы никадәр начар булмасын, аны барыбер заманында бай да, шәүкәтле дә булган бер кеше итеп танырга мөмкин иде.

Карт Зөфәрләрдән ерак түгел, бер йортның ярым подвалында карчыгы белән генә тора. Аның бүтән беркеме дә юк. Дөрес, бердәнбер генә улы булган, ләкин гражданнар сугышы вакытында ул да яшьли генә аклар армиясенә алынып, Себер шәһәрләренең берсендә тифтән үлеп калган. Карт үзе дә, шактый икеләнеп торганнан соң, бигрәк тә улын эзләп табу өмете белән, ахыр чиктә генә акларга ияреп китеп барган, ләкин Читага хәтле барып җитсә дә, малаен да тапмаган, барлык малыннан да язган һәм мең бәла белән Казанга кайтып егылган... Менә шул заманнан бирле ул Казан шәһәрендә торып маташа. Баштарак аңа хезмәт итәргә мөмкинлек бирәләр, аннары тора-бара аның өчен юллар бикләнә. Чит элемент! Шуннан соң «чит элемент» ачтан үлмәс өчен Сорочий тирәсендә йөреп, иске-москы алып-саткалап, шуның белән «көн итә» башлый.

Зөфәрләрнең әтиләре Мөбарәкша абзый исән чакта Курамшин карт аның белән дә шул Сорочийда танышып китә, һәм Мөбарәкша үлгәннән соң да ул Сабитовлар өчен күз күргән бер кеше булып кала. Сугыш елларында карт күбрәк Зөфәр тирәсендә йөреп туена. Хикмәт шунда, борынгы байлыкны күргән карт әйбер танырга бик оста иде; асыл ташларның чынмы-ялганмы икәнен, фарфор, хрусталь кебек зат әйберләрнең чын сыйфатын һәм кайсы илдән чыкканлыгын, өй җиһазларының нинди агачтан һәм нинди стильдә эшләнгән булуын бер карауда әйтә дә бирә. Шәһәрдә әле иске өй байлыклары кулларында бераз сакланган борынгы сәүдәгәр яки чиновник семьялары һаман табылып тора, шул ук вакытта соңгы елларда гына күтәрелгән, акчаны күп тапкан, ләкин байлыкны күрмәгән дә, танымаган да яңа интеллигент семьялар һаман күбәеп бара. Курамшин карт менә шулар арасында, әйбер танучы буларак, арадашлык итеп, бер-

әүләренә сатышып, икенчеләренә алышып йөри... Зөфәр дә картның нәкъ менә шул якларын бик оста файдалана: ОРС магазиннарыннан алып кайткан кыйммәтлерәк әйберләрен әлеге яңа «байларга» карттан илтеп саттыра, яки бөлгән иске байлардан үзенә кирәк зат нәрсәләрне таптырып ала.

Зөфәр бу картның тик бер генә ягын өнәп бетерми — карт салырга ярата. Кулына аз гына акча керде исә, ашаудан бигрәк, эчү ягын карый. Әгәр шушы кимчелеге булмаса, ул бу кадәр хәерчелеккә төшеп, тетелеп тә йөрмәс иде. Әмма шулай да Зөфәр аны үз яныннан кумый иде: ничек кенә булмасын, заманында коммерческий училище бетергән, доверенный булган, зур байлыклар белән эш иткән кеше бит ул! Хәтта кызганып та куйгалый иде. Бигрәк тә карчыгыннан шушындый бер кыска гына хикәятне ишетеп калгач, бу кызгану аңарда көчәйде: Курамшин картның яшь чагында төшкән бер рәсеме бар икән. Рәсемдә ап-ак катыргы яка, ак күкрәкчә өстеннән бик шәп кара фрак кигән, киң күкрәкле, тулы ак чырайлы, кап-кара кашлы һәм кап-кара мыеклы гаҗәп чибәр-сылу бер кеше басып тора, ди... Һәм менә карт исереп кайткан чакларында шул рәсемне каршысына алып утыра икән. Утыра икән дә, карап тора-тора, исе китеп: «Минме соң бу? Әллә мин түгелме? Минем дә шушындый чакларым булды микәнни?» — дип, чын күз яше белән еларга тотына икән.

...Карчыгы бу хикмәтне гади бер нәрсә итеп кенә сөйләсә дә, Зөфәрнең хәтеренә ул бик нык кереп утырды. Картлык, бәхетсез картлык әшәке нәрсә, моны бервакытта да истән чыгарырга ярамый.

Июль аеның эссе бер көнендә, төштән соң Курамшин карт әлсерәп, юан таягы белән шакылдап, Зөфәрләргә килеп керде. Аның өстендә чабулары сәленеп төшкән, керләнеп беткән киндер пиджак, тез башлары ямаулы кара чалбар, ә аягында җәен-кышын салмый торган тире оек белән эчсез галош иде. Ишектән керүгә, ул гөрес итеп табуреткага утырды һәм читләре сәлперәеп төшкән фетр эшләпәсен салып, җилләнергә тотынды. Аның муенындагы һәм маңгаендагы буразнадай тирән сызыклары кара тир белән тулган иде.

Өйдә Зөфәрнең әнисе — Таибә абыстай үзе генә иде. Карт, бераз сулыш алганнан соң, читтәрәк сүзсез басып торган абыстайга дәште:

— Бикә! (Ул аңа әллә яхшатланып, әлә үзенчә мыскыл иткән булып, борынгы морзаларча гел шулай дип дәшә торган иде.) Бикә, берәр стакан гына чәең булмасмы? Киптем...

Таибә абыстай, ашыкмыйча гына кузгалып:

— Булыр,— диде, аннары чүпрәк белән кухня өстәленең клеенкасын сөрткәләде,— якынрак утыр!

Карт, табуреткасын тартып, өстәлгә якынрак килде. Абыстай ак самовардан юан корсаклы чәйнеккә су агызып, шуны плитә өстенә куйды. Чәй салды.

— Мондый эсседә нигә бу хәтле газапка тарып йөрисең? — диде абыстай.— Зөфәр дә бит әле тиз генә кайтмый.

— Эш,— диде карт, авыр сулап.— Срочный эш чыкты... Ә Зөфәр тиздән кайтыр, мин аңа шалтыраткан идем.

Абыстай карт алдына стакан белән чәй куйды. Карт эссене тоймас калын иреннәре белән шунда ук стаканга орынды. Бер-ике йотып алгач, тәлинкәгә салып, шапырдатып эчәргә тотынды. Дөресрәге, чәйне тәлинкәдән ул суырып кына алды. Абыстай икенчесен ясап бирде дә, җитәр сиңа дигән төсле, бер читкәрәк китеп утырды. Карт монысын артык кабаланмыйча гына эчеп бетерде, һәм шуннан соң аңа тәмам хәл керде булса кирәк — тураеп, бер җиңел генә сулап куйды, аннары кесәсеннән яулык сыман керле чүпрәк чыгарып, битен-муенын әйбәтләп сөртергә тотынды.

Картның чәй белән генә мәшгуль булуын сүзсез карап утырган абыстай, ниһаять, телгә килде:

— Нинди эш чыкты соң? Әллә йорт турындамы?

Биредә шуны әйтергә кирәк, алар күптәнге танышлар булсалар да, бер-берсе алдында бәйсез горурлык саклап маташалар иде. Карт үзенең кайчандыр Таибә абыстай кебек талчукчы хатыннарны чүпкә дә санамаган шәүкәтле чакларын исеннән чыгармый иде; ә абыстай үзенең хәзерге өстенлеген, картның алар кулыннан икмәк ашап йөргән бер хәерче булуын гел исендә тота иде. Ләкин алар арасындагы бу бер-берсенә карата булган эчке нәфрәт бервакытта да тышка бәреп чыкмый иде. Киресенчә, алар үзара мөнәсәбәттә бик әдәпле кыланырга тырышалар иде.

— Әйе, бикә,— диде карт, көр тавышы белән гөрелдәп.— Бер... дворец табылып тора бит әле... Әгәр насыйп булса!

— Йорт түгелмени?

— Йорт инде, дворец шикелле йорт!

— Алай икән. Хәерле булсын. Кайдарак инде ул?

— Шәп җирдә, бикә, бик шәп җирдә!.. Йорт үзе дә, утырган җире дә әйтерлек кенә дә түгел, шәп! Бүтән аның кебекне табу, ай-һай!.. Тик менә...— Карт башын селкеп куйды.

— Тик нәрсә?

— Охотниклар күп.

— Кемнәр?

— Ну, карап йөрүчеләр, алырга теләүчеләр.

Таибә абыстай, авызын бөрештереп, бераз тынып утырды. Ул кешеләрнең сүзләрен тиз үк чынга алырга ашыкмый иде. Аныңча, бер эштә дә, аеруча сату-алу эшендә, хәйлә шәргыйсез булмый, моны инде, Мәнди анасы да белә. Шуңа күрә абыстай, карт әйткәннәрнең күпмесе дөрес, күпмесе ялган, ялганы нәрсәдә икән дип, уйга калды. Ләкин шул чакта Зөфәр үзе кайтып керде... Ул килеп керү белән карт та, абыстай да урыннарыннан тордылар.

— Ә, Гайсә абзый, килеп җиттең? — диде Зөфәр, аңа кул бирмичә генә.

— Да, брат! — диде карт, йодрыгы белән мыегының бер очын гына сыпырып.— Карт алаша кебек абынасөртенә булса да килеп җиттек әле.

— Йә, нишләп карт алаша? Руслар әйтмешли, боевой конь!.. Әйдә, узыйк миңа.

Зөфәр картны үзенең бүлмәсенә алып керде. Каракаршы утырып, сүз башладылар. Карт Зинин урамында бер йортның сатылачагын әйтте. Зөфәр иң әүвәл йортның хуҗасы кем булуын, ни өчен сатарга теләвен сорашырга тотынды. Бу аның кагыйдәсе — кем белән эш итәчәген ул алдан белеп торырга тиеш.

Карт белгән кадәресен сөйләп бирде: йортның төп хуҗасы борын Казанда шактый дан тоткан Ушаков фамилияле бер адвокат булган. Ул үзе күптән үлгән инде. Аның варислары һәм йортның хәзерге хуҗалары булып карчыгы, ике кызы һәм бер улы калганнар. Кызларының берсе Саратовта тора икән, улы — врач, хәзерге вакытта хәрби хезмәттә икән әле. Йортта әниләре карчык үзенең кияүгә чыкмыйча картайган өлкән кызы белән икәү генә торалар. Дөрес, сугыш вакытында алар янына Мәскәүдән күчеп килгән бер-ике гаиләне керткән булганнар, ләкин алар инде кире кайтып киткәннәр. Бу җәһәттән бик уңай — сатып алучы буш йортка барып керәчәк.

Ә сатуның сәбәбе?.. Сатуның сәбәбе шул — әлеге врач уллары Киевта урнашып калачак икән. Казанга кайтмаячак, ди. Карчык белән карт апасы үзләре генә монда зур йорт биләп тора алмаячаклар, әлбәттә. Менә шуңа күрә дә варислар, аталарыннан калган бу йортны сатып, акчасын үзара бүлешергә уйлаганнар. Карчыкны улы үз янына Киевка алып китәчәк, ә карт апалары Саратовка сеңелесе янына күчмәкче булып тора шикелле...

Менә Курамшин картның белгәннәре шул... Болар барысы да дөрес булырга тиеш, чөнки искедән калган мондый интеллигент кешеләрдә хәйлә-мазар һич булмый, имеш. Карт әйтә, алар Чехов геройлары кебек гаҗәп беркатлы, дөньяви эшләрдән тәҗрибәсез, бик гади, инсафлы кешеләр, ди.

Зөфәр авыз кырые белән генә елмаеп куйды. Картның борынгы интеллигентларны гел шулай мактавын аңа күп ишетергә туры килде. «Чехов герое» кебек дигәне дә шул итәгендә песи йоклатып, тузган роман укып утыручы карчык үзе генәдер иде. Ә аның улы-кызлары... болар башка ялан җимешләре булырга тиеш.

— Кем сата йортны, карчык үземе?

— Юк, карчык түгел. Главный наследник Сергей Леонидович үзе кайткан,— диде карт, бик мөһим хәбәр ирештергәндәй, горур-әре генә.

— Ул инде сез әйткән, кем, Чехов герое түгелдер, шәт?

Карт, кинаяле көлүне сизсә дә, җавапны җитди итеп бирде:

— Бик благородный кеше, Зөфәр туган. Дөрес, ул яшь әле, сезнең чамада булыр. Ну...

Зөфәр аның сүзен бүлде:

— Ярар, Гайсә абзый, вакыты җиткәч күрербез без аны. Ә йорт үзе ничегрәк?

— Йорт — шәп! Господин адвокат аны бик таза, бик чибәр итеп салдырган.

— Куптәнме?

— Әйтүләренә караганда, унынчы елларда салынган булырга тиеш. Ләкин йорт таза. Борынгы эш. Яңадан бер илле ел «эһ» тә итмичә торырлык әле.

— Алай икән.

— Менә үзегез дә күрәсез. Мин бит инде...

— Ышанам, Гайсә абзый... Что же, уйлап карарга кирәк булыр.

— Озакка сузарга ярамый, Зөфәр туган! Без болай да соңгарак калдык. Йорт тирәсендә дәртләнеп йөрүчеләр бар.

— Язганы булыр, Гайсә абзый! — диде Зөфәр, гадәтенчә, исе китмичә генә.

Карт Зөфәрнең бу ваемсыз тынычлыгыннан гаҗәпләнебрәк калган төсле булды, бераз дәшми торды, аннары икеләнебрәк әйтеп куйды:

— Анысы шулай... Ләкин, минемчә, сез тизрәк барып карарга тиешсез. Сүзне башлый торырга кирәк. Мондый эштә моментны ычкындырырга ярамый бит... Үзегез беләсез!

— Беләм! — диде Зөфәр һәм уң кулы белән тезен ышкып, беравык уйланып торды. Әйе, ул белә: яңа алучының килеп чыгуы, гадәттә, электән карап-сатулашып йөрүчеләрнең тәвәккәллеген арттырып җибәрә, алар тизрәк кул сугарга ашыга башлыйлар. Шул ук вакытта алучы күбәя башласа, хуҗаларның да аяк терәп маташулары көчәя. Мондый очракта эшне ничек йөртергә — яхшылап уйларга кирәк. Бәлки, сатучыны да, конкурент-алучыларны да саташтырыр өчен тагын берәр кешене «уенга» кертергә кирәк булыр. Һәрхәлдә, ул үзе ашыгып эш итмәскә тиеш. Син сатучының авызына карама, сатучы синең авызыңа карап, көтеп торсын!

Шуның белән бергә карт сүзе дә дөрес: карап-сөйләшеп йөрүчеләр бар чакта моментны ычкындырырга ярамый, нәкъ вакытында ике арага барып керә белергә кирәк. Әлбәттә, йорт аңа ошаган тәкъдирдә генә бу исәпләрне истә тотарга ярый.

Зөфәр йортның бәясен сорашып тормады. Сатылачак нәрсәне үз күзең белән күрмәс борын бәясен сорау күп вакытта саташтыра гына: йә гайрәтне чигерә, йә, киресенчә, ашыгырга мәҗбүр итә. Иң дөресе, әүвәл кичекмәстән барып карарга, әгәр ошый калса, сүзне башларга, хуҗаларны өметләндерергә кирәк... Һәм алар карт белән шулай килештеләр дә: иртәгә кичкә табан адвокат йортын барып карарга булдылар.

## VII

Зинин урамы. Бер очы рус зиратыннан башлана, икенче очы ниндидер бор чокырга барып терәлә. Урам түшәлмәгән, канау буйларын куе үлән басып киткән, тик ике як тротуарга гына плитә-плитә ак таш җәелгән. Агач күп. Койма буйларында карт тирәкләр, юкәләр очрый, һәр йортның түрендә җимеш бакчасы күренә. Борынгы өяз шәһәрендәге шикелле аулак, тын һәм тыныч.

...Шәһәрне күп таптаган Гайсә карт Зөфәрне Суконныйдан җәяүләп кенә менә шушы Зинин урамына алып менде. Зөфәрнең моңарчы бу якларда бер дә булганы юк иде, шуңа күрә ул зур кызыксыну һәм игътибар белән тирә-ягына каранып бара. Әйе, урам аулак, тыныч, яшелleккә бай. Монда күбесе бер яки ике катлы агач йортлар икән. Ләкин Суконныйдагы шикелле искереп, тузып, чалышаеп бетмәгәннәр. Әле бик таза, нык утыралар. Еш кына бик пөхтә-матур итеп салынганнары да очрый. Андыйларны күргәндә Зөфәр көнчелек, уфтану аша гаҗәп

бер ләззәтләну хис иткәндәй була. Әйтерсең билгесез-ят, шуңа күрә дә тансык-мавыктыргыч матур бер тормыш аның күз алдыннан беленер-беленмәс кенә чагылып уза. Гайсә карт әйтә, заманында бу урамнарда зур чиновниклар, бай интеллигентлар һәм шәһәрдә кыш уздыручы помещик-дворяннар торганнар, ди. Менә шулар яшәгән тормышның һаман да әле шушы йортлар тирәсеннән китеп бетмәгән зәгыйфь шәүләсе үзен ничектер сиздерә кебек. Алай дисәң, күптән, бик күптән аларның моннан эзләре суынды бит инде. Бик күптән бу йортларда бүтән кешеләр — тегеләрне куып чыгарган кешеләр торалар. Моны инде һәрбер зуррак йорт яныннан узганда бик ачык күреп була; өйләрнең эчләрен вак тартмаларга бүлгәләгәннәр, ишегалларын иске такталардан корыштырган чалыш-чолыш кетәкләр, утын сарайлары белән тутырганнар, ә кайбер йортларның капка-коймаларын сугыш елларында каерып-сүтеп, ягып бетергәннәр. Бу кадәресе инде Зөфәр өчен шәүлә түгел, ә күзгә бәрелеп торган чынбарлык, һәм ул алар яныннан: «Иясез малны эт җыймас!» — дип, эченнән генә көенеп уза. Шулай да Зинин урамында Зөфәрнең күзен иркәләрлек, хыялын уятырлык йортлар да аз түгел иде әле.

Бара торгач, Гайсә карт аны шундый йортларның берсе алдында туктатты:

— Шушыннан гына үзенә бераз карап торыйк әле,— диде ул, нигәдер тавышын әкренәйтә төшеп.

Каршы якта ике катлы зур йорттан озын гына койма белән аерылган һәм үзенә башкарак утырган бер катлы агач йорт күренә иде.

— Шулмы? — дип сорады Зөфәр.

— Әйе, нәкъ үзе, әйбәтләп кара! — диде карт.

Биек кенә таш нигез өстендә такта белән тышлап, сарыга буяган, парадный ишеге һәм дүрт тәрәзәсе урамга караган йорт тора. Зөфәрнең күзе һәм игътибары менә шуңарда... Сүз дә юк, йорт бик таза, бик чибәр күренә. Беренчедән, шактый зур икән ул, тәрәзәләре дә зур, якты, эче дә бик иркен, якты булса кирәк; икенчедән, күптән салынган булуына карамастан, ул, нәкъ яңа йортлардай ничектер балкып, горур кыяфәт саклап, бик төз, туры утыра. Аннары йорт художество элементларыннан да мәхрүм түгел икән: кәрниз буйлары, тәрәзә башлары, артык чуарламыйча гына, челтәр өлге белән бизәлгән, ә болдыр баганалары нечкә биллэп, гөмбәз чыгарып эшләнгән — болар һәммәсе йортка тыйнак бер нәфислек биреп тора...

Ләкин шулай да Зөфәр йортның кайбер искергән-тузган җирләрен дә күрмичә калмады. Мәсәлән, кайчандыр

кызылга буяган калай түбәсе инде каралып, уңып беткән. Бәлкем, тишкәләнгән урыннары да бардыр әле. Аннары вакытында бик таза эшләнгән капка-койма да хәзер шактый тузган инде; капкасы бөтенләй артка таба авышып тора. Димәк, болар барысы да яңартуны сорый.

Шул рәвешчә, кулларын артка куеп, Зөфәр йортка озак кына карап торды, картка бер сорау да бирмәде һәм йорттан алган тәэсирен дә берничек тә сиздермәде. Бары кузгалырга вакыт җиткәнне аңлатып:

— Йә, күрдем... булды,— дип кенә куйды.

Шуннан соң алар, урам аша чыгып, йортның парадный ишегенә юнәлделәр. Карт звонокны баскач, шактый көттереп, берәү ашыкмыйча гына ишеккә килде.

— Кем ул?

— Мария Николаевна, бу мин, Гайса Мухаметович,— диде карт.

Ишек тавышсыз гына ачылды. Баштанаяк карадан киенгән озын, чандыр карчык аларны бик җитди чырай белән каршы алды. Карт түбәнчелек белән башын иде.

— Рөхсәт итегез, Мария Николаевна.

Карчык юл бирде. Карт белән Зөфәр тоташ челтәр тәрәзәле иркен коридорга уздылар.

— Мин сезгә яңа кеше алып килдем,— диде карт.

Карчык, бер сүз әйтмәстән, аларга кара клеенка белән тышланган өй ишеген ачты. Башта алгы бүлмәгә, аннары сул кулдагы ак ишектән зур гына залга уздылар. Карчык аларга кулы белән генә утырырга ишарә ясады. Кунаклар, рәхмәт әйтеп, ишек төбендәрәк торган урындыкларга утырдылар.

— Сәламәтлегегез, кәефегез ничек, Мария Николаевна? — диде карт, чын әдәп һәм кайгыртучанлык күрсәтеп.

Карчык, юка иреннәрен ачар-ачмас кына, кыймылдатып куйды:

— Рәхмәт, зарарсыз.

— Яхшы, бик яхшы. Бирсен Алла! Без картлар өчен сәламәтлек хәзер иң зур байлык бит инде... Ә Надежда Леонидовна белән Сергей Леонидович та, шәт, исән-саулардыр?.. Мин аларны күрмим.

— Рәхмәт, исән-саулар... Шәһәргә чыгып киткәннәр иде, тиздән кайтырга тиешләр.

— Бик хуп... Менә, хөрмәтле Мария Николаевна, әйткәнемчә, мин сезгә яңа кеше алып килдем. Ул да үзенә йорт эзли. Рәхим итеп, ышанып дигәндәй, кабул итегез!

— Безнең ышанмаска хакыбыз юк,— диде карчык, нидер аңлатырга теләгән коры рәсмилек белән.

— Әйе, әйе, бик дөрес. Сез беләсез, мин ни җитте кеше ияртеп йөрмим.

Шулай да карт, һавалы карчыкның соңгы сүзләреннән һәм, гомумән, бүген үзен шактый кырыс тотуыннан нидер сизенеп, шуңа бераз борчылып, Зөфәргә карап алды. Зөфәр исә, берни сизмәгәндәй, тыныч кына утырып тора иде. Хикмәт шунда, карт алып килгән кешесен, бу өйдәге күптәнге кагыйдә буенча, иң элек исем, фамилиясен, кем булуын әйтеп таныштырырга тиеш иде. Ул моны эшләмәде, чөнки Зөфәр баштан ук алай таныштыруны тыеп куйды. Соңыннан, эш барып чыгардай булса гына, үзенең кем икәнлеген әйтергә рөхсәт итте. Бу инде Зөфәрнең гадәттән тыш саклыгы иде. Ә менә карчыкның соңгы җавабы картка: «Мин бит әле сезнең кемне алып килүегезне белмим»,— дигән мәгънәдә аңлашылды. Ләкин Зөфәрнең ваемсыз, тыныч кына утыруын күргәч, карт яңадан карчыкка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды:

— Мария Николаевна, алайса Сергей Леонидович кайтканчы сез безгә йортны карый торырга рөхсәт итегез!

Карчык икеләнеп кенә иңбашын сикертеп куйды:

— Телисез икән, пожалуйста, рөхсәт!

— Әйе, әйе, күрсен, танышсын, тәртибе аның шулай инде, Мария Николаевна,— диде карт, һәм алар урыннарыннан тордылар. Зөфәр өйне иң элек тышкы яктан карап чыгарга теләвен белдерде. Өчәүләшеп ишегалдына чыктылар.

...Уртача гына зурлыкта ишегалды. Өйнең түр почмагыннан күрше коймага чаклы ук сары рәшәткә белән бүленгән. Рәшәткә эчендә куе бакча. Нәкъ каршыда, күрше ихатага арты белән, ике катлап тоташтан салынган берничә ишекле, өсте такта, асты бүрәнә озын каралы тора. Ишегалдында плитәләп ак таш җәелгән, ләкин, кеше аз йөргәнлектән булса кирәк, таш араларыннан юлюл озын үлән бәреп чыккан.

Зөфәр, шул үләннәргә сокланыпмы, гаҗәпләнепме карый-карый, ишегалдының уртасынарак узды. Аның игътибарын шунда ук түрдәге куе бакча җәлеп итсә дә, ул аңа таба барудан юри тыелып, өйнең үзен карый башлады... Өй бу яктан шактый искергән, таушалган булып күренә иде. Хәер, өйнең төп бурасы түгел, ә аңа тоташтырып салынган озын коридорның такта стенасы һәм кухнядан чыга торган аерым болдырның баскычлары череп тузганга охшый иде. Бу, әлбәттә, тулай күренешне беркадәр боза, ләкин аңлаган кеше өчен әллә ни зур кимчелек юк монда. Иң әһәмиятлесе — өй үзе таза булсын. Һәм ул күрер күзгә чыннан да бик таза кебек иде.

Цементлаган таш нигездә нык утыруы шуны күрсәтә. Аннары өй, бер урам яктан гына түгел, бөтен яктан да такта белән тышланган икән. Тик такта астындагы бүрәнәләр ничегрәктер инде? Мондый чакта берәр тактаны куптарып карау да ярый шикелле, ләкин Зөфәр менә хәзер үк ул хакта үз белдеге белән генә сүз кузгатуны килештермәде.

Йортны әйбәтләп караганнан соң, Зөфәр, ниһаять, бакчага таба атлады. Бакча, бакча!.. Күптән хыял иткән нәрсәсе түгелме соң бу аның?.. Моңарчы үзе торган өйләр тирәсендә ул бер агач та күрмәгән иде. Бала чагыннан ук табигатьне, үсемлекләрне белмичә үсте ул. Шуңа күрә дә бик тансык, бик кадерле ул аңа. Йорт алырга уйлагач та күңеле белән аның бакчалы яки, һич югы, бакча үстерерлек урнысы булуын теләгән иде. Һәм менә хәзер өйнең үзеннән дә ямьлерәк, кадерлерәк төсле булып аның алдында карт бакча күкрәп утыра.

Зөфәр ишегалдын аркылыга бүлеп узган рәшәткәнең кечкенә капкасына килде. Бик аз гына тукталып торды, аннары тәвәккәлләп капкадан эчкәре атлады. Карт белән карчык та аның артыннан иярделәр. Бу урында шуны әйтергә кирәк, алар Зөфәргә үзе теләгәнчә карап йөрергә тулы ирек биргәннәр иде. Зөфәр үзе дә хәзергә һични турында сорашмыйча, шәхсиян нинди тәэсир алачагын белер өчен, бары үз күзе белән генә карап узарга тели иде.

...Бакча шактый зур гына икән, кимендә бер сигез сотый җир биләп тора булса кирәк. Ул өй почмагыннан башланып, арткы урамдагы йортларның бакчаларына барып терәлә. Рәшәткә капкадан кергәч тә, сулда өйнең сирень куаклары белән яртылаш капланган ике тәрәзәсе һәм шулар белән янәшә иркен генә терраса күренә. Террасадан чәчәк түтәлләренә баскыч төшә. Ә түтәлләрдән киң генә сукмак бакчаны буеннан-буена кисеп, иң түргә кадәр сузылып китә.

Зөфәр шул сукмакка чыгып басты да тирә-ягына каранып тора башлады. Ул, билгеле инде, бакчачы түгел, күп агачларны танып та җиткерми, ләкин шулай да бакчаның карт булуын, бик куерып киткәнлеген, гомумән карау җитмәгәнлеген сизмичә калмады. Монда чатлы-ботлы бик җәелеп үскән, яртылаш корып беткән, инде утынга гына ярарлык карт алмагачлар да бар иде, монда, әнә түр койма буенда, тәмам куерып, корыган ботаклары киселмичә тоташ чытырманлыкка әверелгән чиялек тә бар иде, урта бер җирдәге ачыклыкка утыртылган карлыган, крыжовник куаклары да күптән бер-берсенә то-

ташып, юанаеп, кара чыбыкка әйләнеп беткәннәр иде. Җитмәсә, бер почмакта карт юкә әллә никадәр җирне күләгәләп тора, ул гына да түгел, җимеш бакчасына аяк бастырырга ярамаган мәрҗән агачы да каралтыларга якынрак рәшәткә буенда рәхәтләнеп үсеп утыра иде.

Чын бакчачы килсә, ул, әлбәттә, бу бакчаның яртысын утап ташлаячак, чөнки шунсыз җимеш ашап булмаячак. Ләкин Зөфәр моны белми иде әле... Ул бары бу карт бакчаның шигъриятен генә күрде. Шушы искергән, картайган, ташландык хәлгә килгән тын бакчадан аңа ничектер борынгы дворян интеллигентының инде мәңге кире кайтмас тормышы аңкыгандай булды. Беркадәр моңсу сагыш белән шул тормышның югалуын кызганып куйды. Әгәр дә хуҗа була калса, ул үзе бу йортка, бу бакчага нинди тормыш алып киләчәк — шул хакта уйлап алды.

Моңарчы карар шәүлә төсле сүзсез генә ияреп йөргән карчык, аның бу минуттагы уй-кичерешләрен сизгәндәй, ниһаять, телгә килде:

— Сезне, кем дим, бакчаның хәзерге күренеше артык гаҗәпләндермәсен. Сугыш вакытында без өлкән кызым белән икәү генә калдык. Карарга көчебез җитмәде, хәер, карауның файдасы да юк иде. Бездә эвакуированныйлар тордылар... Югыйсә бакчабыз элек бик матур, бик тәртипле иде. Файдасын бик күрә идек. Хәзер дә әле уңган хуҗа, бераз тәртипкә китерсә, бу бакчадан зур доход алачак.

Зөфәр башын кагып:

— Шулайдыр инде, шулайдыр! — дип кенә куйды.

Ошамады аңа интеллигент карчыкның торгашларча әйткән соңгы сүзләре... Аныңча, Зөфәрне бары доход кына кызыксындыруы мөмкин, янәсе. Гафу итегез, ул әле доходтан башка кайбер бүтән нәрсә, мәсәлән, матурлык турында да хыяллана ала. Нәкъ менә шундыйрак хыял хәзер генә аның күңеленнән кичеп үтте түгелме соң? Юк, җиләк-җимеш сатып «доход» алу турында түгел иде бу хыял, зуррак иде ул, канатлырак иде...

Бакчаны күздән кичергәч, алар терраса аша яңадан өйгә керделәр. Зөфәр терраса алдында зур түтәл булып, тәмам ачылып, янып утырган ал, кызыл, зәңгәр, сары чәчәкләргә карап кына узды. Табигый, аның бу үзенә һич таныш булмаган матур чәчәкләр янында тукталып, һич югы исемнәрен генә сорап беләсе килсә дә, карчык, бу кеше чәчәк тә танымый икән әле, дип уйламасын өчен, дәшмәде.

...Ике якка ачылмалы пыяла ишектән зур гына бүлмәгә кергәч тә карчык үзе өйнең эче белән таныш-

тыра башлады. Бу беренче бүлмәне ул столовая (аш бүлмәсе) дип атады. Монда бераз тукталганнан соң, каршыдагы ишекне ачып, икенче кечерәк бүлмәне күрсәтте. Бусы элек балалар бүлмәсе булган икән. Моннан кире чыгып, сул ишектән кухняга алып керде. Кухня зур, иркен, тик стена-түшәме бик каралган,— ахрысы, күптән аңа агарту-чистарту тимәгән. Шунда ук тагын бер кечкенә бүлмәгә күз салдылар. Бусы карчык горничная (асрау кыз) бүлмәсе дип атады.

Кухнядан прихожийга чыгып, каршы ишектән зур залга уздылар. Монда да уң яклап ике ишек тора; берсе —адвокатның элекке кабинетына, икенчесе — йокы бүлмәсенә алып керә. Аларны да карап чыктылар.

Шулай итеп, бу өйдә, кухнядан башка, алты бүлмә бар икән. Аларның тулы мәйданы, карчык дөрес әйтсә, йөз унике квадрат метрга җитә икән. Сарай димәслек тә түгел! Хәзерге шартлар күзлегеннән караганда бу инде күп, бик күп! Зөфәр чынлап торып гаҗәпләнде: ничек итеп адвокаттан калган дүрт кешелек гаилә шушы кадәр мәйданны үзләре генә биләп торганнар? Берәү дә тимәгән үзләренә, берәү дә кысрыкламаган — күрәсең, бай адвокат совет өчен дә файдалы кеше булгандыр инде...

Зөфәр, карап кына узган арада, өйнең эчтән ни хәлдә сакланган булуына да игътибар итәргә тырышты. Шик юк, өй эчтән дә шартына җиткереп, нык итеп, пөхтәләп эшләнгән иде. Идәне — имән паркет, түшәме — шкатурлы, стеналары — майлы буяу белән буялган, тәрәзә-ишекләре — бөп-бөтен, башта ничек утыртылган булсалар, шул килеш торалар. Тагын нәрсә? Зөфәр, күпме каранса да, өйнең бер генә почмагында да дым тарткан, каралган җирен күрмәде. Дөрес, бөтен бүлмәләрнең дә түшәмстеналары бик керләнгән инде, ләкин буясын буяп, агартасын агартып җибәрсәң, өй эче яңадан көлеп торачак!

Карап йөрүне тәмамлагач, өчәүләшеп залдагы элекке урыннарына чыгып утырдылар. Шактый гына вакыт үтеп китсә дә, төп сөйләшер кеше — карчыкның улы ни өчендер һаман кайтып җитә алмады. Ә карчык утыргач та шуны белдерде:

— Мин сезгә әйтергә тиешмен ки, сатып алу шартлары турында бары Сергей Леонидовичның үзе белән сөйләшәсез!

Хәер, Зөфәр өчен сүзне хәзер үк шартлардан башлауның кирәге дә юк иде. Аңа, моннан чыгып, Гайсә карт белән киңәшергә һәм үзалдына әйбәтләп уйларга кирәк иде әле. Тик кайбер мәсьәләләрне ачыклар өчен генә аның

карчыкка берничә сорау бирәсе килде. Шул теләген белдереп, рөхсәт алгач, ул сораша башлады:

— Минем белүемчә, бу — үзегез салдырган йорт, шулаймы?

— Әйе, шулай.

— Кайчан салдырган идегез?

— Мәрхүм ирем моны 1908 елны салдырды.

— Күптән икән инде...

— Әйе, тиздән кырык ел тула. Шушында гомер иттек, шушында картайдык,— диде карчык, аз гына күрсенү сиздергән горурлык белән.

— Үз оянда тыныч картаю күңелле эштер инде ул,— диде Зөфәр, карчыкның сүзен куәтләп һәм көлемсерәп өстәде: — Ләкин йорт та, сезнең белән бергә, шактый ук «картайганга» охшый.

— Әйе, дөньяда картаймаган, тузмаган берни дә юк,— диде карчык, җитди тынычлык саклап.— Әмма сез белергә тиешсез, һәрнәрсәнең үз срогы була бит. Мәсәлән, бу йорт сезнең үзегезгә генә түгел, балаларыгызга да җитәчәк әле.

— Шулаймы?

— Күрдегез ич.

— Әйе, күрдек. Ләкин без әле сезне борчырга мәҗбүр булырбыз — тагын килербез, тагын карарбыз. Ә хәзер минем шуны беләсем килә: йортка төп варис кем?

— Төп варис мин, әлбәттә. Ләкин балаларымның да законлы өлешләре бар бу йортта.

— Алар барысы да сатарга ризалыкларын бирәләрме?.. Сез гафу итегез, бу минем өчен бик әһәмиятле.

— Аңлыйм,— диде карчык.— Тыныч булыгыз, без бу эшне үзара килешеп эшлибез. Соңыннан сезгә претензия белән килүче булмаячак.

— Яхшы, бик яхшы,— диде Зөфәр, башын кагып...— Рәхмәт, мин канәгать. Тик менә яшь хуҗаның үзен күрә алмадык. Минем дә вакытым чикле. Шуңа күрә мин сездән үтенер идем: йортның бәясен, сату шартларын менә Гайсә Мухаметович аша миңа тапшырсагыз иде. Икенче очрашканда шуны алдан белеп килү безнең сөйләшүләрне ансатлаштырыр һәм тизләтер дип уйлыйм.

— Пожалуйста, телисез икән, алай да мөмкин. Гайса Мухаметович безнең өчен дә ят кеше түгел...

— Баш өсте, баш өсте, мин һәр ике якның да хезмәтен үтәргә, ышанычын акларга әзермен,— диде карт, баш иеп һәм кулын күкрәгенә куеп. Элекке доверенный өчен мондый зур эшкә катнашу үзенә күрә бер бәхет тә һәм горурлык та иде.

Зөфәр, урыныннан тормыйча гына, түбәнчелек белән:
— Ә хәзер безгә кузгалырга рөхсәт итегез! — диде.

Карчык аңа: «Бу нинди әдәп иясе?» — дигәндәй, шактый гаҗәпләнеп карады һәм беренче тапкыр юка иреннәре белән генә елмайгандай итте.

— Нишлим, сезне артык тотарга хакым юк.

Зөфәр башын иде.

— Хушыгыз!

— Хушыгыз!

Карчык аларны парадный ишегенә чаклы озата чыкты һәм артларыннан таза ишекнең тимер келәсен шылдырып калды.

Карт белән Зөфәр, урамга чыккач, азрак сулга киттеләр дә, урам аша үтеп, каршыдан йортка тагын бераз карап тордылар. Аннары акрын гына кузгалып, үз юллары белән атладылар. Карт таягы белән шакылдап, Зөфәр исә башын иебрәк, үзалдына уйланып, алар шактый гына ара сөйләшмичә бардылар. Тик берәр квартал чамасы киткәч кенә Зөфәр әйтеп куйды:

— Бу йорт белән мин нишләрмен?

Карт гаҗәпләнеп аңа карады — Зөфәрнең сүзләре: «Нигә кирәк ул миңа»,— дигән мәгънәдәрәк ишетелде аңа.

— Моны син әйтәсеңме, Зөфәр туган? — диде ул, туктала биреп.

— Әйе, мин әйтәм, Гайсә абзый... Чынлап та, нишләрмен мин ул йорт белән?

— Соң, алай булгач, ни өчен әле без шәһәр бетереп йорт эзләп йөрдек? Кирәккә күрәдер бит?

— Әйе, кирәккә күрә,— диде Зөфәр, һаман уйланып барган килеш, ашыкмыйча гына.— Ләкин мондый кеше күзенә бәрелеп торган бай, зур йорт эзләмәгән идем мин. Кечерәк, гадирәк булсын, дигән идем.

Карт җиңел сулап куйды.

— Шул гынамы хәсрәтең?.. Юкка борчыласың, туган! Насыйп булып ала калсаң, бер дә үзеңнән артмас әле.

— Ала калсаң!.. Алуын алырсың, ә алгач нишләрсең? Бу заманда андый йорт хуҗасы булу — уен эш түгел ул... Керердән элек, чыгуыңны уйларга кирәк.

— Ул кадәресен үзең беләсең инде,— диде карт, килешкән сыман; аңа ничек тә йон уңаена сыпырырга кирәк иде: — Кара, кара, үкенечкә булмасын. Әмма, миңа калса, кечкенә йорт хуҗасы булдың ни, зурныкы булдың ни — барыбер, мужик әйтмешли, ике чабата бер кием. Аннары, нишләп әле бу йорт синең күзеңә ул хәтле бик зур булып күренде? Алты бүлмәле булгангамы? Һи, Зөфәр туган, элек заманда моның кебек йортта урта кул

чиновниклар тора иде. Хәзер генә бит ул бер бүлмәгә алты кешене тыгалар...

— Менә шуңа күрә дә Зөфәр Сабитовның берүзенә генә алты бүлмәле йорт бик күп булыр шул, Гайсә абзый!

— Нигә алай дисең? Син берүзең генә түгел ләбаса! Солдаттан кайтасы абыең бар, сеңелең җитеп килә, үзеңнең өйләнәсең бар. Курыкма, бер метры да артып калмас.

— Метрын кеше башына бүлеп тормаслар,— диде Зөфәр, көрсенеп.— Сабитов әнә нинди йорт алган, каян килгән бай ул, дип шауларлар... Беләсең хәзерге кешеләрне, барысын да бик тиз күрәләр.

Бераз вакыт сөйләшмичә бардылар. Карт Зөфәрнең ни өчен, нәрсә уйлап борчылуын, әлбәттә, аңлый иде. Сәүдә-тәэминат кешесе бит ул. Капкынга эләгүдән курыккан төлке кебек гел генә тирә-ягына ялт-йолт карарга, шомланырга, уяу булырга мәҗбүр. Киләчәкне алар беркайчан да хәтәр-хәвефсез генә күз алларына китермиләр, ахрысы... Һәм Зөфәрнең дә менә болай икеләнеп маташуы картның эчен чынлап пошыра иде. Йөреп-йөреп тә бу эш барып чыкмаса, ул сакал сыпырып калачак! Хәлбуки аның да үзенә күрә саклап йөрткән өмете бар: шушындый зур алыш-бирешне уңышлы төгәлләүдә катнашлык күрсәтеп, мул гына «комиссионный» каерып булмасмы дип хыяллана ул. Бары шуның өчен генә авыру аякларын көчкә сөйрәп, шәһәр таптап йөри бит... Ичмасам, карт көнендә үзенең дә, карчыгының да өс-башын рәтләп, ашау-эчүләрен бераз юнәйтеп калыр иде. Бәлкем, эчүдән дә тыелыр иде. Хәерче бер тиеннәре эчүгә китә бит ул, ишлерәк акчаны һәрвакытта саклыйсы килә, игелеген күрәсе килә. Сыналган нәрсә инде ул. Бай чагында авызына да алмады бит! Ах, бу хәерчелеккә калган көн, аракы түгел, агу эчәрсең!

Юк, Ходай үзе генә моның кебек өметле эшне өзә күрмәсен инде... Бу акыллы башның күңеленә тәшвиш салмасын иде дә аңа тәвәккәллек бирсен иде!

Шулай эченнән генә борчылып һәм уйланып алганнан соң, ул яңадан сак кына сүз башлады:

— Алла ни кушса, шул булыр, Зөфәр туган. Син шәригатькә яки законга сыймый торган эш эшләргә җыенмыйсың. Хәлең җитеп, тәвәккәллисең икән, берәү дә гаеп итмәс. Сатып торалар, алып торалар — тыйган кеше юк. Изге эш ул. Тик син миңа шуны әйт: йортны ошаттыңмы соң?

Зөфәр җавап бирергә ашыкмады. Картның ни өчен болай аны акрын гына көйләп-җайлап маташуын чамалый

иде ул һәм менә шуңа ничектер каршы торасы килә иде. Хәер, карттан яшеренеп торуның мәгънәсе юк, шуңа күрә, бераз уйланган булып, ахырда, дөресен генә әйтеп бирде:

— Әйе, Гайсә абзый, йорт миңа бик ошады. Карап торырга, һичшиксез, таза, чибәр йорт. Шуннан яхшысын, бәлки, табып та булмас. Ләкин, Гайсә абзый, син карт, тәҗрибәле кеше, миңа саф чынын гына әйт әле: ышанып алырлык йортмы ул, тыштан гына шулай күренмиме, алданмабызмы?

Карт башта тамак кыргалап куйды, аннары үзенең чынлап та объектив, гадел икәнлеген күрсәтергә теләп, салмак кына сүзен башлады:

— Алла шаһит, Зөфәр туган, мин сиңа әйтсәм бары саф дөресен генә әйтәчәкмен. Бер бөртек тә шигең булмасын. Әйе, бик хаклы сорыйсың: тыштан чибәр, эчтән черек түгелме? Кайчакта шулай да була бит ул... Ләкин, Зөфәр туганым, күңелең тыныч булсын: бу — һич андый йорт түгел, менә сиңа чал чәчем!.. Күптән беләм мин аны, карчыкның иске-москыларын Сорочийга күп ташыдым, ә сатылу хәбәрен ишеткәч, эчен генә түгел, астын-өстен тикшереп, карап чыктым. Ышанасыңмы, егерме дүрт вершоклы шыңгырдап торган нараттан ике аршын тирәнлектәге таш фундамент өстенә салынган йорт ул! Ник бер чери башлаган яки корт төшкән җире булсын менә! Идән, түшәм такталары тора-тора какланып беткән, кадак та керерлек түгел. Ә идән астындагы базы, бәдрәф чокыры цементлап эшләнгән, белдеңме?.. Гомерлек инде, гомерлек! Ходай кушып, алырга язсын да, игелеген күреп торырга насыйп булсын!

Әлбәттә, картның бу әйткәннәре Зөфәр өчен көтелмәгән сүзләр түгел иде. Ул үзе дә йортның таза, яхшы икәнлегенә ышанып өлгергән иде инде, әмма шулай да карт кимчелекләре турында да әйтсә, аңа бәлки җиңелрәк булыр иде. Югыйсә йорт аның күңелен һәм хыялын бик тиз һәм бик нык били башлады. Ә ул болай бик ансат кына шуның колы булып китәргә теләми иде. Уйларга, айнык акыл һәм тыныч җан белән бик нык уйларга кирәк иде әле аңа...

Алар арасында бүтән сүз булмады. Чехов базарына җиткәч, карт Суконныйга төшеп китте, Зөфәр исә туры гына шәһәр үзәгенә таба китеп барды.

...Берничә көн узды. Шушы кыска гына вакыт эчендә Зөфәр каты бер сынау кичерде. Нәтиҗәсе шул: бер генә көн, бер генә сәгать тә ул Зинин урамындагы сарыга буялган, кызыл түбәле йорт турында уйламыйча тора алмый башлады. Хәер, бүтәнчә булуы мөмкин дә түгел иде.

Барыбер ул йорт сатып алырга тиеш, бу аның өчен күптән хәл ителгән мәсьәлә, ә инде заманнан өркү, курку-сагаюлар, никадәр генә җитди сәбәп булмасын, аны хәзер тыя да, туктата да алмый иде.

Адвокат йортын ул әнисе Таибә абыстай белән дә бергә барып карады, тагын берничә ышанычлы кешесен илтеп, аларга да күрсәтте, барысы да йортны бик яраттылар, берсе дә Зөфәрнең гайрәтен чигерерлек нәрсә әйтмәде. Һәм йорт Зөфәрне, ниһаять, башы-аягы белән үзенә әсир итте. Хыялы аның котырып эшли башлады. Ул инде аңа хуҗа, ул инде аны яңадан өр-яңа хәленә китергән, эчен шәп җиһазлар белән тутырган һәм шунда рәхәтләнеп торып ята. Салмак йөрешле мәһабәт дивар сәгатедәй әйбәт итеп көйләнгән тук, тыныч тормыш ашыкмыйча гына ага да ага... Һәр көнне иртән бик пөхтә киенеп, Зөфәр Сабитов эшкә китә, туры гына эштән кайта, бакчада казына, террасада, үз җиләгеннән кайнаткан варенье белән, тәмләп кенә чәй эчә, газеталар караштыра, аннары иркен, чиста бүлмәдә рәхәтләнеп ял итә. Койма биек, капка таза, ишегалдында озын тимерчыбыкны шаулатып усал эт йөри, һәм хуҗаның дөньясында гаме юк, дөньяның аңарда эше юк! Менә бу хөрлек һәм бәйсезлек, ичмасам!

...Озак та үтми сөйләшүләр башланды. Гайсә карт йортның бәясен әйтә килде. Ул китергән бәя күпләрнең кайнар хыялын сүрелдерерлек, гайрәтен чигерерлек иде: Ушаковлар йортка дүрт йөз мең сорыйлар! Гади хезмәткәрнең төшенә дә кермәгән бу сумма Зөфәрне, башта хәйран калдырса да, чынлап торып куркыта алмады. Җаны теләгән — елан ите ашаган, ди, чынлап тәвәккәлләгәндә Зөфәрнең моңа көче җитәрлек иде. Шулай да ул хуҗалар белән аяк терәп сатулашырга булды.

Ләкин Гайсә карт мактап йөдәткән «иске заман интеллигентлары» сату-алу эшендә хәзерге заманның эт каешына әйләнгән коммерсантыннан бер дә ким булып чыкмадылар. Карчык, карчыктан да битәр аның военврач улы, йортларының нинди мөлкәт булуын, хәзерге акчаның чын бәясен белеп, әйткән бәяләрендә бик каты тордылар. Әлбәттә, тал тоткан җирдән генә сынмый, шуны аңлап, хуҗалар сөйләшкән саен биш-ун меңләп кенә төштеләр, ләкин Зөфәр әйткәнгә якын да килмәделәр, Зөфәр исә башта ике йөз мең бирде, аннары акрынлап ике йөз илле меңгә менде, ә хуҗалар өч ярымнан бер карыш та төшмәс булдылар. Шулай итеп, килешер өчен ара бик ерак иде әле.

Ә көннәрнең берендә Гайсә карт, тыны бетеп, Зөфәргә яңа хәбәр алып килде: Себердән кайткан кемнәрдер йорт-

ка «ике дә сиксәнне биргәннәр», имеш. Карт моның дөреслегенә ант итеп ышандырды. Ул гына да түгел: «Ике дә сиксәнне биргәч, өчкә җиткерүләре көн кебек ачык, эш менә-менә очланырга тора!» — дип, бик нык кисәтеп әйтте... Хәзер инде Зөфәр йә чигенергә, йә күз йомып тәвәккәлләргә тиеш иде. Һәм мөмкин кадәр тизрәк.

## VIII

Икенче көнне Зөфәр, алдан хәбәрләшү буенча, карчыкның улы военврач Ушаков Сергей Леонидович белән Хәмит дустының бүлмәсендә икәүдән-икәү генә очрашты. Бүтәннәр катнашыннан башка гына, күзгә-күз сөйләшеп, Зөфәр эшне, ниһаять, нәтиҗәле ахырына җиткерергә булды. Кара-каршы утырышкач, сүзне дә ул җитди, эшлекле төстә, әмма мөмкин кадәр гади, тәкәллефсез булырга тырышып башлады:

— Сергей Леонидович, биредә икәүдән-икәү генә очрашуның максатын сез дә, шаять, аңлыйсыздыр. Минемчә, безгә билгеле бер нәтиҗәгә килергә вакыттыр инде... Әйдәгез, чын джентльменнарча, ачык һәм туры гына сөйләшик.

— Рәхим итегез! — диде Ушаков, салкын әдәп белән.

Өр-яңа кительдән, иңбашына ак укадан тар гына погоннар таккан бу төскә шактый чибәр, ләкин озынча ак чыраенда һәм соры салкын күзләрендә әллә нинди генә бер кырыс тәкәбберлек сизелеп торган яшь кеше үзен гаҗәп һавалы һәм бәйсез тотарга ярата иде. Гомумән, бу Ушаковлар дигән халыкка ни сәбәптәндер әнә шундый чамасыз горурлык, йомыклык һәм тискәрелек бик хас иде. Зөфәр баштарак, бу миңа карата гына шулайдыр инде, үзләренчә мине сәүдә күсесенә санап, кимсетеп карауларыдыр, дип борчылып азапланды. Хәзер исә ул моңа игътибар итеп тормаска булды.

— Минем саф дөресен генә беләсем килә, Сергей Леонидович,— диде Зөфәр, тавышын-ниен бер дә үзгәртмичә генә.— Әйтегез әле, йортыгыз өчен соңгы мәртәбә сезгә күпме бирделәр?

— Моның ни әһәмияте бар? Сез үз бәягезне бирегез,— диде Ушаков.

— Бар, Сергей Леонидович! Әгәр без ачык сөйләшсәк, нәтиҗәгә тизрәк ирешербез.

— Яхшы! — диде Ушаков, аз гына дәшми торганнан соң.— Безгә ике йөз сиксән меңне бирделәр.

Зөфәр, урындык аркасына авыша төшеп, бертын аңа

туп-туры карап торды. Ул: «Дөресме бу?» — дип кайтарып сорарга теләмәде, ул мондый зур эштә Ушаковның гадел, туры булуына бер шиксез ышанырга теләде. Шулай яхшырак. Бигрәк тә, хуҗаның әйткәне Гайсә карт китергән хәбәр белән бер булып чыкты. Шуны да исәпкә алып һәм үзе врач, үзе хәрби кешенең алдашу кебек түбәнлектән ерак торырга тиешлеген уйлап, Зөфәр һич икеләнмичә Ушаковка, ниһаять, әйтте:

— Рәхмәт, дөрес сүзегез өчен, Сергей Леонидович! Гәрчә сез әйткән бәһа гадәттән тыш зур булса да, мин ышанырга мәҗбүрмен... Инде рөхсәт итегез миңа да соңгы сүземне әйтергә: яшермим, йортыгыз миңа ошады, мин чын алу теләге белән карап-сатулашып йөрдем һәм менә хәзер арага килеп кергән икенче берәүләргә аның китеп баруын теләмәс идем. Кыскасы, Сергей Леонидович, сезгә актык сүзем шул: йортыгызга миннән төгәл өч йөз мең!.. Йә, ни дисез? Килештекме?

Ушаков, акрын гына, ләкин ничектер икеләнебрәк башын селекте. Аның шушы икеләнүен сизеп калу Зөфәрне бераз өметләндереп җибәрде.

— Ягез, йә, хөрмәтле Сергей Леонидович, баш селкеп тормагыз. Ышаныгыз, миннән дә артыгын бирүче булмас сезгә... Килешик!

Ушаков тагын башын селекте:

— Юк, булмый!

Зөфәр кашларын җыера төшеп аңа карады:

— Ә ничек була соң?

— Без үзебезнекен әйттек,— диде Ушаков,— өч йөз илле меңнән төшмибез.

— Мин моны күптән ишеттем,— диде Зөфәр, авыз кырые белән генә елмаеп.— Мин сездән яңа сүз көтәм, Сергей Леонидович!

— Бәя мәсьәләсендә нинди яңа сүз булырга мөмкин? Бәя һәрвакытта бер, тәгаен була ул.

Зөфәр, бу кешенең тискәрелегенә ачуы килә башласа да, тынычлыгын һәм йомшак мөгамәләсен сакларга тырышып, аңа таба иелә төште:

— Менә нәрсә, хөрмәтле Сергей Леонидович, хәтерегез калмасын, әмма сату-алу эшенең тәртипләрен мин сезгә караганда яхшырак беләм дип уйлыйм...

— Әлбәттә. Моңа мин ышанам! — диде Ушаков, ниндидер ямьсез кинаяне сиздергәндәй, башын чөя биреп.

— Юк, сез башта тыңлагыз әле... Һәрбер сату-алу эше билгеле бер килешүгә ирешү белән тәмамлана ул. Ә бу нәрсә сатучының гына түгел, алучының да теләгеннән тора. Шулай булгач, бәянең дә үзгәрмичә хәле юк. Тал

да бит тоткан җирдән генә сынмый. Берәү арттыра, берәү төшә — бары шулай гына килешүгә ирешеп була. Йә, дөрес түгелме?

— Бәхәсләшмим, ихтимал, шулайдыр... Ләкин сез әйткән бу кагыйдә минем өчен закон түгел. Гафу итегез! Йортка без дүрт кеше хуҗа, бәя мәсьәләсендә үзара сөйләшеп куйган чигебез бар, төшәсен төштек, артыгы булмый!

— Димәк, сез алдан билгеләп куйган шул «чиккә» җиткерсәләр генә йортыгызны сатасыз инде, җиткермәсәләр —сатмыйсыз... Шулай аңларга кирәкме сезнең сүзегезне? — диде Зөфәр, хәйләкәр бер көлү белән Ушаковка туп-туры карап.

Ушаков көтелмәгән бу сораудан бераз аптырабрак калды. Аннары, җавап таба алмагач, аптыравын яшерер өчен генә әйтеп куйды:

— Без сата алуыбызга ышанабыз.

— Ышанырга була... Ләкин шулай да сез өмет иткәнне бирмәсәләр, нишлисез? Сатмыйсыз һәм Казаннан китмисез, шулаймы? Әгәр шулай икән, ул чагында сез хаклы — сөйләшеп, сатулашып торуның һич хаҗәте юк, йортыгызга үзегез генә хуҗа буласыз да каласыз.

— Ни өчен алай дисез?

— Ни өченме? Чөнки берәү дә сез көтеп яткан «чиккә» барып җитмәячәк. Юк, булмаячак ул!

Ниһаять, Зөфәрдә коммерсант усаллыгы һәм мәкерлеге уянды. Сүзләрен дә ул, үзенең һичшиксез хаклы булуына ышангандай, көлемсерәп кенә, әмма каты итеп, өзеп әйтә башлады. Шуның белән бергә тыштан һаман да бик әдәпле булып калды. Дөресен әйтергә кирәк, болай сөйләшү тәҗрибәсез Ушаковка тәэсир итмичә калмады. Ничектер, үзе дә сизмәстән, ул һавалы тискәрелеген һәм ныклыгын акрынлап кына җуя башлады. Шулай да әле аның һич бирешәсе килми иде:

— Сез бүтәннәр өчен сөйләмәгез,— диде ул, элекке кырыс тәкәбберлеген сакларга тырышып.— Бүтәннәр, бәлки, җиткереп кенә түгел, арттырып та бирерләр.

— Бирмәячәкләр! Менә ике кулымның берсен сайлап кисегез — бирмәячәкләр!.. Йортыгызның күренеп торган кырык-илле мең сумлык ремонты бар. Шулай булгач, нинди юләр аңа шулкадәр акча салсын, ди? Акчаны да бит түтәлдә үстермиләр... Аннары шуны да исегездә тотыгыз: сезнең йорт бер хуҗа өчен бик зур ул, ә ике хуҗага бүләрлек түгел. Менә шунлыктан карап йөрүчеләр күп булса да, тәвәккәлләп алырга торучы юк диярлек...

— Ник булмасын, бар.

— Кем? Теге Себердән кайткан кешеләрме? Ләкин алар да бит әле мин биргәнне бирергә тормыйлар.

— Алар бирәчәк...

— Их, Сергей Леонидович, гаҗәп беркатлы кеше икәнсез сез... Неужели, аларның хәйләсен сизмисез, уйлап карагыз әле. Ни өчен алар ике йөз сиксән меңдә туктаганнар? Чөнки сезнең дә ташлама ясавыгызны көтәләр. Сез төшмичә торып, алар арттырмаячаклар. Ихтимал, алар да мин биргән өч йөз меңгә чаклы акрынлап менәрләр, ләкин бу аларның «түшәме» булачак. Егерме мең ул — сатулашыр өчен калдырган запаслары, бу минем өчен көн кебек ачык. Сез дә шуны бик яхшы белеп торыгыз.

Ушаков моңа каршы бер сүз дә әйтә алмады. Ул ачык бер гаҗәпләнү һәм кызыксыну белән Зөфәргә карап тора башлады. Бу караштa ихтыярсыздан Зөфәрнең шундый оста, ышандырырлык итеп фикер йөртүенә соклану да чагыла иде кебек... Зөфәр үзе дә, моны яхшы сизеп, беркадәр вакыт дәшмичә тыныч кына утырды. Аннары акрын-сабыр гына яңадан сүзгә кереште:

— Менә шулай, хөрмәтле Сергей Леонидович, аңлаштык шикелле, инде хәзер сүзне түгәрәкләсәк тә ярый торгандыр. Һәрхәлдә, мин әйтәсемне сезгә бик туры һәм ачык итеп әйттем... Ышаныгыз, максатым минем берничнди ялган-хәйләсез, иң гадел рәвештә сезнең белән килешү иде. Мөмкинме шундый килешү — хәзер бөтен эш сездән тора.

— Ни өчен миннән тора? — диде Ушаков, гаҗәпләнгән булып.

— Әйе, бары тик сездән тора,— диде Зөфәр, катгый рәвештә.— Соңгы сүз сезнеке. Ташлама ясасагыз, без, ихтимал, килешә алырбыз. Кабатлап әйтәм, килешә алырбыз!.. Юк икән, без аерылышабыз, һәм яңадан очрашусөйләшүләр булмаячак. Тик сез шуны белегез: алам дип дәртләнеп торган кешене ычкындыру һәрвакыт үкенечкә була ул.

Ниһаять, Ушаков Зөфәрнең тимер кулын чынлап торып сизде: кара син, әдәпле, сабыр гына сөйләшкән булып, ничек рәхимсез рәвештә акрын гына кыса белә ул! Гаҗәп, кайдан килгән, нинди кеше соң бу?.. Ушаков хәтта кайчандыр әтисе сөйли торган борынгы хәйләкәр астыртын купецларның нәкъ берсен ап-ачык күргәндәй булды. Ләкин безнең заманда кайдан гына мондый кеше килеп чыга, ничек итеп хәзерге шартларда яши ала ул, җитмәсә, менә ничә йөз мең акча түләп, аларның, бөтен шәһәргә билгеле Ушаковларның, йортын сатып алырга әзер тора?! Юк, чынлап та әллә нәрсә бу! Сугыш үтте,

кешеләр дүрт ел буена кан, үлем эчендә йөрделәр, ә менә монда, аның каршында, шуларның берсен дә күрмәгән тук, таза коммерсант утыра!

Ушаковта кинәт Зөфәргә карата ихтыярсыздан тирән нәфрәт-ачу күтәрелә башлады, ләкин ул бу тойгыны ничек тә басарга тырышты. Моменты андый түгел. Язмыш кушуы буенча ул хәзерге минутта — йорт сатучы, ә бу кеше — сатып алучы, һәм сүз дә бик конкрет мөһим нәрсә турында бара. Димәк, шул хакта гына уйларга да кирәк. Ә ныклап уйлар өчен сәбәп җитәрлек. Беренчедән, Зөфәрнең көчле дәлилләре аңа шактый нык тәэсир итте, икенчедән, Зөфәр кебек килешергә бик теләп торучы, хәзергә аңардан да югарырак бәя бирүче чынлап та юк иде. Теге кешеләргә күпме ышанып торырга мөмкин, алардан өмет иткәнне ишетеп булырмы-юкмы — хәзергә әле караңгы, билгесез. Менә шуларның барысын да ул тиз генә уйлап алды. Нишләргә? Әллә форсаттан файдаланырга микән?

Ушаков Зөфәргә күтәрелеп карады һәм аның тыныч кына, хәтта «ихтыярыгыз!» дигән төсле битараф бер кыяфәттә утыруын күргәч, ничектер, үзеннән-үзе тәгаен карарга килде.

— Беләсезме, кем, иптәш Сабитов,— диде ул, Зөфәргә туры карамаска тырышып,— мин сезнең дәлилләрегезне игътибар белән тыңладым. Аларның кайберләрен исәпкә алырга була, ләкин кайберләре белән һич килешеп булмый. Мәсәлән, сез, йортка без сораган бәяне бирәү дә бирмәс, дип ышандырырга тырыштыгыз. Мин моның белән килешә алмыйм, әлбәттә. Әгәр вакытым иркен булса, мин аны дүрт йөз меңнән дә кимгә сатмас идем, чөнки безнең йорт ул хакка гына торырлык. Ләкин, кызганычка каршы, бердән, минем вакытым чикле; икенчедән, сезнең бер дәлилегез белән килешмичә булдыра алмыйм: әйе, килешер өчен сатучы тарафыннан да бераз ташлама кирәк. Менә шуңа күрә генә мин, гәрчә туганнар ризалыгыннан башка булса да, бары сезнең белән килешергә теләп, беркадәр ташлама ясауны мөмкин дип саныйм. Кыскасы, минем соңгы сүзем шул: өч йөз утыз мең! Калганы, сезнең ихтыярыгыз!

Зөфәр җәелеп бер елмайды:

— Менә бу миңа ошый, Сергей Леонидович! Бу, ичмасам, чын егетләрчә эш итү! Димәк, без килешә алабыз. Ләкин минем тагын бер кечкенә үтенечем бар: әйдәгез, гадел булсын өчен, без илле меңне нәкъ уртага бүлик. Сез егерме биш меңгә төшегез, мин егерме биш меңгә арттырам, һәм без кулларны сугабыз! Ышаныгыз, өч йөз

егерме биш меңне биргәч, миңа тагын биш меңне өстәү берни түгел. Сез дә шулай ук әллә ни югалтмыйсыз. Кабатлап әйтәм, мин моны бары гаделлек өчен генә сорыйм! Килештекме — һәм ул йомшак ак кулын сузды.

Ушаков, аз гына икеләнеп торды да, тәвәккәлләп башын какты:

— Риза! — һәм бармак очлары белән генә Зөфәрнең учына сугып алды.

...Нәкъ шул минутта бүлмә хуҗасы Хәмит кайтып керде. Ул боларны каршы алгач та, юри сылтау табып, чыгып киткән булган иде; инде менә Зөфәргә нәкъ кирәк чакта гына, ишек артында көтеп кенә торгандай, килде дә керде.

Керү белән ул:

— Йә, ничек, килештегезме? — дип сорады.

— Килештек! — диде Зөфәр, җиңелчә генә бер сулап.

— Котлыйм, котлыйм алайса! — диде Хәмит, кулларын уа-уа.— Бик әйбәт, бик изге эш эшләгәнсез! Хәере белән... Мондый чакта шампанский күтәрәләр шикелле. Ә, иптәш военврач?

Ушаков, бу елгыр кешенең кем икәнлеген тәгаен белмәгәнгә һәм аның кисәк кенә килеп керүен дә, ни өчен болай дәртләнеп шатлануын да аңлап җитмәгәнгә күрә, сагаеп кына җавап бирде:

— Белмим шул...

Зөфәр, моны сизеп, Хәмиткә сабыр итеп торырга кушты һәм Ушаковка мөрәҗәгать итте:

— Сергей Леонидович, безгә үзенең бүлмәсендә иркенләп сөйләшергә түбәнчелек белән рөхсәт иткән бу иптәш, Хәмит Нуриевич, минем бик якын дустым. Аңардан яшерен бер эшем дә юк... Сез дә, миңа ышанган шикелле үк, аңа һич икеләнмичә ышана аласыз.

— Яхшы,— дип кенә куйды Ушаков, баш кагып.

— Хәзер исә безгә,— дип, сүзен дәвам итте Зөфәр,— менә хөрмәтле хуҗа алдында, сөйләшүне тәмамларга кирәк булыр. Дөресрәге, безнең килешүне беркадәр рәсмиләштереп куярга кирәктер, дип уйлыйм. Сезнеңчә ничек?

— Минемчә дә шулай инде ул... Тик моның өчен нотариальный конторага барырга кирәк була торгандыр.

— Барырбыз, анысы качмас. Ләкин менә шушы сәгатьтә без, үзара гына булса да, килешүне беркетеп куярга тиешбез.

— Ничек итеп?

— Моны гадәттә задатка бирү-алу юлы белән эшлиләр. Димәк, мин дә сезгә задатка бирергә тиешмендер инде, шулай түгелме?

Ушаков иңбашын җыерды.

— Белмим, ихтыярыгыз. Әгәр сез алу-сатуны тиз арада нотариальный контора аша рәсмиләштерергә риза икәнсез, задатканы бирмәсәгез дә була. Мин сүземдә торачакмын.

— Моңа мин бик ышанам,— диде Зөфәр, кулын күкрәгенә куеп.— Ләкин сез дә минем тарафтан тыныч булып торсагыз иде дим.

— Алайса, пожалуйста, мин каршы түгел,— диде Ушаков, саран гына елмаеп.

Зөфәр дә елмайган булды.

— Задатканы гадәттә саткан кеше үзе сорый торган иде, ә монда киресенчә килеп чыкты. Ну, зарар юк! Барыбер мин бирәсе акча ич ул!.. Ә хәзер, Сергей Леонидович, рәхим итеп расписка языгыз.— Зөфәр аның алдына блокнот битен ачып куйды һәм авторучкасын чыгарып сузды.

Ләкин Ушаков ручканы кулына алырга ашыкмады.

— Сабыр итегез,— диде ул, Зөфәргә туры гына карап.—Иң әүвәл мин сезнең белән бер нәрсәне ачыкларга тиешмен: алу-сатуны рәсмиләштерү һәм исәп-хисапны өзү кайчан булачак?

Зөфәр өчен бу иң четерекле мәсьәлә иде. Ул әле аны үзе дә хәл итеп куя алмаган иде. Дөрес, аның бүгеннән үк акчаны тулысынча түләп, эшне өзәргә кодрәтеннән килә, әмма... бер бик җитди мәсьәләне уйлап хәл итәсе бар. Нинди мәсьәлә ул — Зөфәр аны бары үзе генә белә, һичкемгә әйтергә ярамый торган түгел, ләкин уйлап хәл итәр өчен вакыт кирәк. Шуңа күрә ул, сәбәбен әйтмичә генә, Ушаковтан өч атна мөддәт сорады. Ушаков моңа риза булмады.

— Юк,— диде ул, башын чайкап,— мин ул хәтле көтә алмыйм. Булмый. Мин монда вакытлы гына кеше.

Ахырда, сөйләшә торгач, унике көнлек вакыт билгеләделәр. Әгәр шул вакыт эчендә Зөфәр эшне өзмәсә, йорт хуҗасы Ушаков үзен килешүдән азат итеп санаячак һәм задатканы кире кайтарып бирәчәк.

Бу турыда сүзне шулай тәмамлагач кына Ушаков, ниһаять, расписканы язарга булды. Ручканы кулына алгач: «Күпмегә?» — дип сорады ул; Зөфәр, аз гына уйланып: «Кырык меңгә языгыз!» — диде.

Ушаков расписка язган арада, Зөфәр чалбарының эчке ягына тегелгән кесәсеннән зур гына төргәк чыгарды. Ике кат пергамент кәгазьгә, аннары кара материягә төреп, сары шнур белән аркылыга һәм буйга әйбәтләп бәйләгән төргәкне чиште дә, гел бишәр йөзлекләрдән генә торган

һәм унар-унар итеп бөкләнгән акчаның төгәл сигез кисәген санап, Ушаков алдына салды. Калган ике кисәген яңадан төреп, шул ук кесәсенә тыгып куйды. Ушаков һәр кисәкне ашыкмыйча гына санап чыкты. Зөфәр белән Хәмит аның бу эшен бик игътибар белән карап тордылар; ахрысы, шуңардан военврачның бармаклары аратирә калтыранып та куйгалады, ләкин йөзе-чырае һаман да тыныч булып калды... Санап бетергәч, ул сигез кисәк акчаны ике-өчкә бүлеп, төрле кесәсенә тыкты һәм бары шуннан соң гына язылган распискага имзасын салып, числосын, елын куйды.

...Эш төгәлләнде, торып кул кысыштылар, расписка Зөфәрнең эчке кесәсенә кереп урнашты, һәм килешүчеләр арасында ничектер кинәт кенә сүз дә бетеп китте. Гүя аларның һәркайсы хәзер генә үтәлгән эшнең нәтиҗәсе турында үзалдына эченнән генә нидер уйлана иде.

Хәер, бу тынып тору озакка бармады. Өлгер Хәмит шундук урыннан сикереп торды да чын дәртләнү белән кычкырып:

— Ну, кадерле дуслар,— диде,— теләсәгез ни әйтегез, иллә мәгәр моның кебек зур эшне болай коры гына калдырырга ярамый. Юарга кирәк, обязательно юарга!

Тегеләр бер-берсенә карашып өлгергәнче ул инде кеч-кенә буфеттан өстәлгә өч бокал алып куйды һәм... чынлап та бер шешә шампанский чыгарды. Гаҗәп! Кайдан килгән бу, дүрт ел буена күздән югалып торган, көмеш башлы алтын эчемлек? Моны инде, белсә, бер Алла да Хәмит үзе генә белә торгандыр...

...Менә ул сул кулының өч бармагы белән (ике бармагы аның төптән үк юк иде) шешәнең муеныннан ипләп кенә тотты да, уң кулы белән җитез генә тимерчыбыгын сүтеп, бөкесен сак кына кузгата башлады. Кинәт бөке шартлап атылды, шешә авызыннан сузылып ак төтен чыкты, ә Хәмит тиз генә бокалны күбек белән тутырды. Аннары калган икесенә дә, бер тамчысын да түкмичә, тутырып салды.

— Ягез! — диде ул, бокалны тантаналы күтәреп...— Бу зур килешү ике якның да бәхетенә булсын!

— Рәхмәт. Шулай булсын! — диде Зөфәр, акрын гына.

Чәкешеп эчтеләр. Ушаков, беренче кат дигәндәй, ачыграк елмаеп әйтеп куйды:

— Да-а! Казанга кайтып, шампанский эчәрмен дип уема да китермәгән идем. Кайдан таптыгыз моны?

— Безнең Казанда табылмаган нәрсә юк,— диде Хәмит, горурлана биреп.

— Шулаймы? Ләкин мин монда сырец-аракыдан башка нәрсә күргәнем юк иде әле.

— Һи, иптәш военврач, эзли белергә кирәк, эзли белергә... Эзли белсәң, күгәрчен сөтен дә табып була.

Ул кунакларының бокалына тагын бер кат салып чыкты. Шуны аягүрә генә эчтеләр дә хуҗага рәхмәт әйттеләр. Ушаков фуражкасын алды. Зөфәр белән алар яңадан каты итеп кул кысыштылар.

— Хәзер инде сезнең килешүне шайтан үзе дә боза алмас! — диде Хәмит.

— Ни өчен? Шампанский белән юганга күрәме?

— Юк, сез көлмәгез әле, иптәш военварч! Хикмәт бер шампанскийда гына түгел, хотя аның да эшне беркетеп куя торган көче бар... Главное, сезнең килешү минем алда, минем фатиха белән булды. Ә мин фатиха биргән эш бервакытта да сүтелмәс ул!

— А-а, алай икән, моңа мин бик шатмын! — дигән булды Ушаков, башын ия төшеп.

— Шулай шул менә, иптәш военврач! — диде Хәмит тә аның көенә тәкәллефле горурлык белән һәм кунагын тышкы ишеккә чаклы озата чыкты.

Зөфәр тәрәз каршына узды һәм, кулларын артка куеп, урамга карап тора башлады. Ләкин күзләре урамда булса да, уйлары һаман шул бер нәрсә тирәсендә сүлпән генә әйләнә иде. Әйе, менә ул, ниһаять, зур эш башкарды. Гаять зур эш! Әле кичәгенәк кенә бу хыял иде, ә бүген конкрет гамәлгә әверелде. Киләчәк язмышы өчен моның әһәмиятен хәзер генә күреп тә, аңлап та җиткерүе читен кебек. Бәхеткә, уңышка була күрсен!.. Ә шулай да ул, бик теләгән эшне үтәвенә карамастан, нигәдер үзендә чын канәгатьләнү тоймый әле. Киресенчә, әллә нинди менә җан бушлыгы, җан сүлпәнлеге тойган кебек... Гаҗәп. Үз гомерендә ул нинди тәвәккәл эшләр эшләмәде, әмма артыннан һәрвакыт зур канәгатьләнү, үз-үзенә ышану һәм җиңеләеп калу татый торган иде. Ә бүген менә шулар юк. Нидән соң бу болай, хәерсез?

Хәмит әйләнеп кергәч тә ул тәрәзә каршында әнә шулай уйланып, иңбашларын салындырып, тын гына басып тора бирде. Хуҗа егет өстәлдән шешә белән бокалларны җыеп алды, урындыкларны стена буена күчерде, шуннан соң гына ул Зөфәргә төбәлеп бер карады да гаҗәпләнеп дәште:

— Син нәрсә, брат, канатларыңны салындырдың әле?

— Әллә тагын... Юк шикелле,— диде Зөфәр, ялкау гына.— Просто, арыдым бугай...

Ләкин Хәмит моңа ышанып бетмәде — дустының ба-

сып торышында ул бер арыганлык кына түгел, ничектер боегып калу да сизә иде. Шуңа күрә сорамыйча булдыра алмады:

— Үкенмисеңдер бит?

— Нәрсәгә?

— Нәрсәгә дип, менә хәзер генә эшләгән эшеңә?

— Нишләп үкеним, ди, юләр! Бала түгел лә мин!

Ул Хәмиткә йөзе белән борылды:

— Тик, беләсеңме, дускай, бу шундый зур эш, мин сиңа әйтим, уйланмас җиреңнән уйланырга да, даже... борчылырга да туры килә. Йорт, диләр аны!

— Беләм инде, беләм, конечно, шалаш түгел. Уйланырсың да, борчылырсың да, өч йөз егерме биш меңне чыгарып салгач... Тик син үкенә күрмә, дус кеше!.. Җенем сөйми үкенүне... Мин үзем берәр билгесез хатын янында кунып чыксам да үкенмим. Булган эш булган!

Зөфәр, әллә ничек кенә бик ясалма итеп, шаркылдап көлеп куйды:

— Ха-ха! Булган эш булган дисең, ә!.. Дөрес әйтәсең, чорт возьми, булган да беткән, чыгарган да җибәргән, чабуына ябышмаган! — Зөфәр бармак сырты белән күзен сөрткәләде дә тагын уйланып, аз гына тынып торды.— Ә монда, брат, эшнең башы гына әле, ахыры ни булып бетәр — билгесез. Бу сиңа кунып кына чыгу түгел, ә гомерлеккә кереп утыру... Хәер, гомерлеккәме?

— Зөфәр, мин сине аңламый башладым әле! — диде Хәмит, чынлап гаҗәпләнгәндәй, аңа әрсез-туры гына карап.— Син бит моңарчы торткан җирдән өзә торган егет идең, нәрсә булды? Күңелең тартмыймы, куркасыңмы, акчаңны кызганасыңмы? Алайса эш узмаган әле, тотасың да задатканңны кире аласың, вәссәлам!

«Күңелең тартмыймы, куркасыңмы?» — бу сүзләре белән Хәмит Зөфәрнең үзенә-үзе дә икърар итәсе килмәгән шиген тотып алгандай булды. Ләкин Зөфәр күңеле төбендә кыймылдарга маташкан ул шикне, әлбәттә, һич сиздерергә теләмәде, юри батыраеп җавап бирергә ашыкты:

— Ялгышасың, дус кеше! Миңа берни дә булганы юк. Теләдем — алдым, кеше авызыннан тартып алдым. Алты бүлмәле, җимеш бакчалы йорт менә монда — минем куенымда хәзер! Нинди үкенү булырга мөмкин!

— Алайса бик әйбәт, сүзем бетте, игелеген күр! Сиңа бит шул кирәк тә инде — йорт-җирле, чибәр кәләшле, бала-чагалы солидный тормыш! Менә ирешәсең...

— Ә сиңа кирәкмимени?

— Юк, миңа кирәкми. Мин бервакыт та өйләнмәячәкмен, и йорт та алмаячакмын. Нигә ул богаулар миңа? Кайтып ятарга бер бүлмәм булса, миңа шул җиткән. Тик кесәмдә ике сберкенәгә йөрергә тиеш. Ике кенәгә — ике канат ул, менә шул чагында инде мин теге ни... ирекле кәккүк!

— Кәккүк! Шәп кәккүк, тик борын гына карчыганыкы...

— Теләсә кемнеке булсын, әмма ирекле кош ул!

— Ай-һай! Кычкыруына караганда, Ходай биргән «иректән» бер дә риза түгел шикелле... Юк инде, мулла Хәмит, мин кәккүк төсле бүтәннәр оясына күкәй салып йөрергә теләмим. Минем барысы да үземнеке булырга тиеш.

— Мин дә шуны әйтәм бит! Эш нидән тора? Ояң булды, ярың бар, тик әйдә...

— Кемне әйтәсең, нинди яр ул?

— Рәшидә соң?

— Ә син бит аны күргәнең юк.

— Һи, иптәш, мин шушы бүлмәмә килеп йөргән хатынны күрми тораммы соң!

Зөфәр, кашларын җыерып, шактый сагаеп калды.

— Ләкин ул сине белми бит.

— Анысы неважно... Так вот, ояңа күрә нәкъ үзе, алтын күкәй салып бирерлек асыл кош Рәшидә ханым Сафина!.. Шулаймы әле?

— Рәшидә, Рәшидә! — Зөфәр авыр гына сулап куйды.—Кадерен белерме икән соң ул мин үргән ояның?

— Җүләр, сорап торасың тагын, җәннәт итәр ул синең ояңны... Миңа туры килсә иде шундый хатын! — диде Хәмит, тәмам әсәрләнеп.

— Ий-е! — дип сузды Зөфәр, үзалдына гына.— Бик ансат кына этеп кертмәкче буласың син мине җәннәткә!

— Ә синең аяк терәп торасың килә инде, ә?

Зөфәр озак кына дәшми торды; Хәмиткә аның бик үк ачылып бетәсе килми иде, ләкин, бер сүз чыккач, дустына кайбер шиген азрак әйтәсе дә килә иде.

— Рәшидәне син белмисең,— диде ул, ниһаять, җитди генә.— Шуны онытма, ул — артистка, аның хыяллары бөтенләй башкада. Гаилә бәхетен аңардан көтүе читен, минемчә...

— Бәхет! Нинди бәхет турында хыялланасың син? Асравың шикелле буйсынып кына торса, чолгауларыңны юса, ел саен корсак үстереп йөрсә — шушымы синең өчен бәхет?

— Син алай бик упрощать итеп ташлама әле, егет! —

диде Зөфәр, кызыбрак.— Асрау алу турында түгел, ә хатын табу турында сүз бара, өйләнү турында!.. Ә хатын ул синең җаныңа да, тормышыңа да кереп утыра, бөтенесенә үзең кебек үк хуҗа булып ала, вәт нәрсә ул өйләнү! Җаныңны да, малыңны да дигәндәй, белер-белмәс теләсә кемгә тапшырып булмый, иптәшкәй!.. Хәер, сиңамы соң, таз кәккүккә, өйләнүнең нәрсә икәнен аңлау!

Ләкин Хәмиттән болай кимсетеп-хурлап кына котылу мөмкин түгел иде. Бер усалланып китсә, ул да кызганып тора белми иде.

— Син — татар, просто татарлыгыңа барасың,— диде Хәмит, нәфрәт белән.— Икенче берәү булса, бөтен нәрсәсен — җанын да, байлыгын да — Рәшидә кебек хатынның аягы астына салыр иде!

— Ихтимал! — дип кенә куйды Зөфәр һәм яңадан тәрәзәгә борылды. Аның инде бу сүзне тизрәк бетерәсе килә иде. Ләкин Хәмит аның аркасына булса да үз сүзен әйтеп бетерергә ашыкты.

— Рәшидә дә бит байлыктан мәхрүм түгел. Причем, акчага табылмый торганы... Ул синең токмач белән йокыдан башканы белмәгән тормышыңа шатлык, матурлык, җыр, музыка алып килер иде.

— Һәм син шуның бәрабәренә чолгауларыңны үзең юып, үзең аңа асрау булып торыр идеңме? — диде Зөфәр, көлгән булып, кирәкмәгәнне әйтеп ташлаганын шунда ук сизде, ләкин соң иде инде.

— Дурак син, Зөфәр, вот нәрсә! — диде Хәмит, кулын селтәп.— Канат юк синдә, масштаб юк. Үзеңнең шул коммерсияңдә катып калгансың, бүтән тормышны күрмисең дә, белмисең дә... Просто, Рәшидәнең сукырлыгына гаҗәпләнәм.

— Шаярма, Рәшидә бер дә сукыр түгел ул.

— Шулай да сине яратамы?

— Нигә, мин яратмаслык кешемени?

Хәмит, ни әйтергә аптырагандай кулларын җәеп, иңбашын гына җыерды:

— Белмим инде, нәрсәң белән генә син аны әсир иткәнсеңдер?!

Зөфәр кинәт Хәмиткә таба борылды — аның йөзе агарган, күзләре эчке ярсудан зураеп киткән иде.

— Белмәсәң, әйтим алайса,— диде ул, буыла төшеп.— Мин үзем аны яраттым, өзелеп яраттым!.. Менә ни өчен Рәшидә миңа әсир булды, миңа мөкиббән китте... Мәхәббәт, диләр моны!.. Һәм мин теләсәм, Рәшидәне бүгеннән өемә җитәкләп китерә алам...

— Соң, шулай булгач, эт талаган юләр...

Ләкин Зөфәр Хәмиткә авыз ачарга ирек бирмәде, бу хакта сүзне шуның белән беткәнгә санап һәм тиз генә үзен кулга алып:

— Җитте, Хәмит! — диде.— Бүтән — ләм-мим! Вакыты ул түгел. Беләсең ич, минем башта хәзер нинди кайгы... Берьюлы ике куян артыннан чабып булмый!.. Тик синнән үтенеч шул: бу йорт мәсьәләсен берәүгә дә чишми тор. Аңлыйсыңмы, берәү дә белмәскә тиеш.

— Рәшидә дәме?

— Әйе, ул да...

— Кара, син аңардан куркасың да икән әле,— диде Хәмит, гаҗәпләнгән булып.

— Что значит, куркасың? — диде Зөфәр, гасабиланып.— Мәсьәлә куркуда түгел, ә алдан ук дөнья шаулатасым килми, менә шул!.. Вакыты җиткәч, белергә тиешле кешеләргә үзем дә әйтермен. Только синнән чыкмасын, кара аны!

— Ярый, ярый! — диде Хәмит, ике кулын да селтәп.— Моңарчы бит әле серләреңне чишмәдем, янамасаң да була.

— Янамыйм, ә дусларча сорыйм!

— Булды инде, булды! Безнең кендекләр береккән икән, нишлисең, «дусларча» соравыңны да үтәрбез!

Зөфәр үтә сынап Хәмиткә бер карап торды да, сүз әйтмәстән, кисәк кенә борылып, ишеккә атлады. Хәмит аптырабрак җилкәсен кашыды:

— Хуш дип тә әйтмисең, ә?

— Хуш, сау бул! — диде Зөфәр, ишектән чыгып беткәч кенә.

Менә шулай инде алар. Очрашкан саен ызгышып китмичә калмыйлар. Күп вакытта моңа Хәмитнең усал теле гаепле. Ләкин, үзе үк әйтмешли, аларның кендекләре чынлап та бик нык береккән. Сугыш вакытында күп эшләре бергә булды, бергә таптылар, бергә йоттылар... Шулай да Хәмит Зөфәр каршында күбрәк бурычлы. Сәүдә эшендә шактый түбән баскычта торганга күрә, ул Зөфәрнең ярдәменә һәрвакыт мохтаҗ булып килде. Зөфәр аның дуамал башын кайбер бәлаләрдән йолып алып калды, үз системасына кертмәсә дә, әйбәт кенә җирләргә дә урнаштырды, акчалата да ярдәм иткән чаклары булды. Менә шунлыктан Хәмит, «дуслык» хакына, үзен аңа буйсынырга, аның таләпләрен үтәргә мәҗбүр дип саный иде.

## IX

Ушаковлар белән килешеп, задаткасын биреп куйгач та Зөфәр алдына гаять җитди бер мәсьәлә килеп басты: йортны кем исеменә яздырып алырга?.. Уйлап-уйлап та менә шуны хәл итә алганы юк әле. Һәм иң авыры — бу хакта ул ялгызы гына баш ватарга мәҗбүр. Эшләгән-йөргән җирләрендә дус-ишләре күп булса да, ул аларга бөтен серен дә ачып бетерергә җөрьәт итми, курка... Абыйсы әле фронттан кайтып җитмәгән, бердәнбер киңәшер кеше — әнисе карчык, ләкин моның кебек үтә катлаулы мәсьәләдә ул нәрсә генә әйтә ала? Ә мәсьәлә шундый ки, аны дөрес хәл итү белән киләчәк тормыш та, хәтта язмыш та бик нык бәйләнгән. Моны Зөфәр үзе генә аңлый, чөнки ул үзенең кем булуын, ничек итеп баюын бер генә минутка да исеннән чыгармый. Ул белеп тора: аның хәлендә ярты миллион сумлык йорт сатып алу, көне-сәгате белән дигәндәй, үзенә карата төрле сүз-шик тудыру булачак. Ә нигә кирәк бу, нигә шәһәр шаулатырга, нигә төрле кирәкмәс кешеләрнең (мәсәлән, Симаков кебекләрнең) шиген уятырга? Юк, мондый эштә җиде кат үлчәп, бер кат кисмичә һич тә ярамый. «Чукынган заман,—диде ул, эченнән ачынып,— курыкмыйча, яшеренмичә бер генә нәрсә дә эшләп булмый бит!»

Кыскасы, үзен шик астына, йортын куркыныч астына куймас өчен, ул, вакытлыча булса да, кемнеңдер артына посарга, кемнедер «хуҗа» итеп тотарга тиеш. Тик менә кемне? Аның иң якын, иң ышанычлы ике кешесе бар: әнисе һәм абыйсы. Менә шулардан ул кайсын сайларга белмичә аптырый. Мәсьәләнең җитдилеге һәм нечкәлеге шунда ки, аларның кайсысы беткәнче гадел булыр да Зөфәрне бердәнбер хуҗа һәм баш итеп таныр. Әйтик, абыйсы кайтып та өлгерсен, ди, ләкин Зөфәр аның белән уртак тел таба алырмы — әйтүе читен. Аннары ул риза булган тәкъдирдә дә аңа ышанып бетәргә мөмкинме? Ул үзе дә бит мал дигәндә акны-караны аермый торган кеше — соңыннан йортыңа чынлап торып хуҗа булып алмасмы? Кайда гарантия? Туганлык һәм намус печатьле кәгазь түгел, судка күтәреп илтә алмассың!

Инде бер әни карчык кала. Аңардан да ышанычлы кеше булырга мөмкинме соң? Уйлап торасы да юк кебек, әмма шулай да Зөфәр уйлана һәм тәгаен бер карарга килә алмыйча йөдә-азаплана. Бөтен мәсьәлә шунда ки: әнисенең Зөфәрдән башка тагын ике газиз баласы — солдаттан кайтачак улы белән үсмер кызы бар; үз исеменә

яздырылган Зөфәр йортыннан менә шуларга да ул өлеш чыгарырга теләмәсме?

Зөфәр шулай төрле исәпләр белән баш ваткан арада уйламаган, көтмәгән яктан дигәндәй, кызыклы гына хәлләр дә булып алды.

Ушаков белән сөйләшеп кайтканнан соң, икенче көнне үк, аңа ах-вах итеп, Гайсә карт килеп керде. Карт тау менгән ат шикелле бик кайнарланган иде:

— Карале, Зөфәр туган, сез тегеләр белән килешкәнсез икән ләбаса! — диде ул, утырыр-утырмас.

— Әйе шул,— диде Зөфәр, картның кыяфәтеннән һәм сүзеннән шактый гаҗәпләнеп.— Нигә? Әллә берәр хәл булдымы?

— Ә мин... мин? — диде карт, таягының башы белән күкрәгенә сугып...— Ничек итеп сез мине оныттыгыз, ә, миннән башка аны эшләдегез, ә?

Зөфәр тагы да ныграк гаҗәпләнә калды:

— Аңламыйм. Нигә, синнән башка эшләргә ярамый идемени?

— Мин бит посредник, аңлыйсызмы, посредник... Мин сиңа йорт табып биргән кеше, тегеләрне сатарга, сине алырга димләгән кеше... Йә, мине читтә калдырып, сез ничек килешә алдыгыз?

Зөфәр картның ни өчен болай дулавын, ниһаять, аңлаган кебек булды.

— Карале, Гайсә абзый,— диде ул, тынычланып,— берәүнең дә сине читтә калдырганы юк. Просто, шулай килеп чыкты. Миңа йорт хуҗасы белән аулакта, икәүдән-икәү генә очрашырга кирәк иде. Монда үземә алып килергә теләмәдем, синең подвалыңа да илтеп булмый бит инде аны... Читтә сөйләшергә туры килде. Менә шул. Юкка кызасың, картым, алучы белән сатучы килешкән чакта посредникның булуы бер дә шарт түгел бит.

— Нәрсә дидең? Шарт түгел, дидеңме? Ничек ул алай? — Картның зәгыйфь күзләреннән, еламаса да, яшь ага башлады.— Мин карт сөякләремне өстерәп нәрсә өчен йөрдем соң? Мин үз хакымны алырга тиешме-түгелме? Син бит, Зөфәр, мондый эшнең тәртипләрен беләсең, йә, әйт!

Зөфәр аз гына көттереп җавап бирде:

— Әйе, сиңа йөрүең өчен бераз комиссионный тиярга тиеш... Алырсың.

— Алырсың! Әйтергә ансат! Кемнән, кайчан, күпме? Моны бит әнә шул килешү вакытында сөйләшеп куялар. Ә хәзер чыпчык куып йөр инде... Кайсыгыз бирә?

— Комиссионныйны гадәттә саткан кеше бирә, Гайсә абзый, үзең беләсең...

— Ә-ә, алай икән!.. Һе, Ушаковлардан теләнеп йөрергә кирәк икән!.. Ә алар, знать не знаем, әнә алган кеше түләсен дип җибәрсәләр, ә?

— Җибәрмәсләр.

— Как җибәрмәсләр? Килешү юк, сөйләшү юк. Отказ, вәссәлам!.. Менә шуның өчен дә шул килешү вакытында посредник обязательно булырга тиеш. Кем күпме бирәчәк — шунда хәл ителә ул... Хәтта договорга аерым пункт итеп языла торган иде ул элек, беләсең килсә!.. Юк, Зөфәр Мөбарәкович, начар эшләдегез, ямьсез эшләдегез... Рәнҗеттегез мин гарип картны, рәнҗеттегез!.. Бит мин шушы сәләмәләремне өстемнән ташлый алмаммы дип, шул юеш, сасы подвалдан башымны алып чыга алмаммы дип йөргән булдым. Йа Хода! Мин дә бит заманында Ушаковларныкыннан да шәбрәк йортларда торган кеше... Шуны аңларга кирәк иде, һич югы...

Зөфәрнең йөзе бердән караңгыланып китте:

— Карале, Гайсә абзый, сине берәү дә рәнҗетергә уйламый. Ашыгып еларга тотынма әле... Җайларбыз. Үзем сөйләшермен.

Карт дәшә алмады, бары керле яулык белән битенкүзен генә сөртеп утырды. Зөфәр, бераз көтеп, сорап куйды:

— Син үзең соң күпме өмет иткән идең?

— Хәзер инде, эш узгач...

— Юк, шулай да?

Карт тагын кинәт батыраеп китте:

— Әйтим алайса: миңа, Зөфәр Мөбарәкович, килешү бәясенең өч проценты тиярга тиеш... Күпмегә килештегез? Өч йөз егерме биш меңгәме? Менә шуннан үзең исәпләп чыгар!

Зөфәр, көлемсерәп, башын чайкап торды:

— Сиңа, Гайсә абзый, андый акчаны берәү дә бирмәс!..

— Бәддогадан курыкмасагыз, бирмәссез! — диде карт һәм торып, ничектер, бик бөкрәеп, саубуллашмыйча чыгып ук китте.

Зөфәрнең картка шактый ачуы килеп калды. «Җан көеге, синең генә кайгың иде монда!» — дип, эченнән сүгеп ташлады ул аны... Әмма шул ук вакытта ихтыярсыздан картны кызганып та куйды. Ничектер менә аның яшен генә агызып тавышсыз елавы, рәнҗеттегез гарип картны, рәнҗеттегез, дип ачынып әйткән сүзләре, ниһаять, балаларча үпкәләп, олы гәүдәсен бөкрәйтеп чыгып китүе, вөҗдан шелтәсе сыман, гел күзе алдыннан китмичә торды. Шуның өстенә ул картның соңгы вакытта гомумән бик өшәнеп китүен, шуңа карамастан үзенчә

һаман тырышып йөрүен һәм ни өчен, нәрсә өмет итеп йөрүен дә уйламыйча булдыра алмады. Болай да төрле шик-уйлардан борчылып, шомланып торган күңеле аның кеше каргышыннан, кеше бәддогасыннан чынлап та курка калды. «Юк, ярамас, язык булыр, картны бәхилләтергә кирәк!» — диде ул үз-үзенә, ниһаять.

Ләкин Гайсә карт җәнҗалын бик тиз арада икенче бер зур вакыйга күмеп китте. Хикмәт шунда, моннан ай ярым чамасы элек үк Зариф абзыйдан: «Безнең елларны җибәрә башладылар, иншалла якын атналарда миңа да чират җитмәсме дигән өмиттә торам, сез дә бер Алладан шуны сорагыз!» — дип язган хаты килгән иде. Билгеле инде, аның кайтуын өйдәгеләр барысы да бик зарыгып, шатланып, борчылып көтәләр иде. Һәм менә нәкъ беренче августта Зөфәрнең күз күргән бер танышы килеп, аларга: «Зариф абзый Юдино станциясендә вагон саклап, кайта алмыйча ята»,— дип хәбәр итте. Бу гаҗәп сәер хәбәрне ишетү белән Зөфәр, Сәкинә җиңгәсен ияртеп, шунда ук Юдинога китте. Барсалар, чынлап та Зариф абзый ниндидер начальникның Германиядән немец җиһазлары төяп җибәргән вагоны белән Юдинога кайтып җиткән, ләкин зур станциянең бер тупигына эләгеп, шуннан ычкына алмыйча ята икән. Керләнеп-тузып, сакал-мыек басып беткән солдатны иң кырыйдагы юлларның берсеннән эзләп табалар һәм шатланышып, елашып күрешәләр. Ярый әле, Зөфәрнең кая барса да белешләре очрап тора — ул шулар ярдәмендә абыйсын вагоны-ние белән тиз генә тупиктан чыгарып, Казанга алып кайта.

...Сугыш кырыннан мондый «азаплар» белән кайтып кергән Зариф солдат өендә нинди зур шатлык, нинди зур бәйрәм булганын әйтеп торасы да юк. Зөфәрне исә абыйсының аяклы-куллы, мал-мөлкәтле булып күзгә күренүеннән дә бигрәк, нәкъ менә кирәк чакта кайтып җитүе аеруча нык сөендерде. Хәзер инде алар, ике туган, бергәләп сөйләшә дә, киңәшә дә, кирәк икән, хәрәкәт тә итә алачаклар.

Ул абыйсына мунча кереп, ял итеп, хатыны, бала-чагалары белән сайрашып үткәрергә бер генә көн ирек бирде. Икенче көнне үк инде аны аулакка чакырып, алда торган зур эш хакында сүз кузгатты... Озак бикләнеп утырдылар алар. Өч ел буена фронтта, дөресрәге, тыловой частьларда, башын саклап калу хәсрәте белән йөргән, хәзер исә дөньяны кочагына җыеп алырдай булып кайткан Зариф акыллы энесенең ашыкмыйча гына, төпле итеп, шома итеп сөйләп биргән ниятен бик хуплап каршы алды һәм үзе дә бу йорт мәсьәләсе белән бик

кызыксынды. Бүгенгене иртәгәгә калдырмый торган кешеләр буларак, алар шул ук көнне йортны барып та карадылар. Баштанаяк гражданскийдан бик пөхтә киенеп барган Зариф (әнесе аңа капитан Ушаков күзенә гади солдат булып күренергә киңәш бирмәде), бик эре генә кулларын артына куеп, башын кырын салып, йортның эчен-тышын җентекләп карап чыкты. Хуҗаларга берни сиздермәде ул, әмма урамга чыккач, Зөфәргә туптуры әйтте:

— Шәп, бик шәп йорт тапкансың, Зөфәр туганым! Үзе таза, үзе чибәр, игелеккә язган дәүләт була күрсен! Зурлыгы да ике семьяга полный җитәрлек, урыны-җире дә бик матур, бик иркен, әлхасыйль, килмәгән җире юк моның...

Ләкин йортның бәясе Зарифның котын ала язды:

— Атакай гынам, өч йөз егерме биш мең! — диде ул, шаккатып.— Бу бит... бу бит Пралумныйда магазин ачып җибәрерлек капитал! Китче, зинһар, бер йортка шулкадәр түлиләрме соң!

Аның башта болай исе-акылы китүе бер дә гаҗәп түгел иде. Өч елдан артык армиядә буш ашап, буш эчеп йөргәнлектән, абзый кеше тылдагы чамаларны бераз онытып җибәргән иде. Хәер, аңа хәзерге мең сумның элекке йөз сумга да тормаганлыгын, ә яхшы йортларның бүгенге көндә биш-алты йөз меңнән дә кимгә табылмаганын төшендереп бирү Зөфәр өчен әллә ни авыр булмады.

Кыскасы, йорт килешенгән, задаткасы бирелгән — сүз ул хакта түгел хәзер. Сүз Зөфәр куйган мәсьәлә турында барырга тиеш: нишлибез? Ул, Зөфәр, үзе генә алсынмы йортны, әллә икәүләп алу хәерлерәк булырмы? Үзе генә алган тәкъдирдә йортны кем исеменә яздыру дөресрәк булыр?

Озак киңәштеләр алар. Зөфәр абыйсын акрынлап өлешкә керү ягына аударырга тырышты — ник дисәң, ул берәүне дә, бигрәк тә Зарифны семьясы белән, бары вывеска өчен генә, өенең түренә бушлай кертеп утыртырга теләми иде. Зариф үзе дә, исәпли-уйлый торгач, өлешкә керү ягына таба ава башлады. Барыбер аңа да, иртәме-соңмы, йортлы булырга кирәк, ә моның кебеген әллә табып була, әллә юк. Җыеп алып кайткан төрле алтын-көмеш әйберләре, кием-салымнары, машина әнәсе кебек вак-төяк нәрсәләре аңа шактый акча китерергә тиеш, хатын кулында сакланып ятканы да бар әле, һәрхәлдә, тәвәккәлләсә, көче җитәчәк. Җитмәсә, алар ике туган ич, килешә алырлар.

Шулай итеп, һәрьяклап сөйләшеп аңлашканнан соң,

Зариф риза да булып беткән иде, ләкин нәкъ менә шул чакта һич уйламаган кеше кинәт кенә бөтен эшне бозды да куйды. Бу — Зарифның хатыны Сәкинә иде.

...Электән дә ишле семьяда үзен бик итагатьле итеп, юаш, сабыр гына тоткан, ә Зарифы кайткач, бәхетеннән майдай эреп-сөенеп, кемгә ничек кенә ярарга белмичә йөргән хатын, иренең ниятен белеп алгач, пәри алыштыргандай, ана поши кебек усалланды да китте. Зариф йорт алу турында беренче кат сүз ачкач та, ул ничектер бердән ярсып: «Юк, бу эш булмас! — диде.— Мин моңа асла риза түгел,— диде.— Миңа алтын сараең да кирәкми, балаларым белән шушында калам, чыкмыйм»,— диде... Аның кинәт болай ярсып, кырт кисеп әйткән сүзләре Зарифны бөтенләй таңга калдырды. Бу ни хикмәт, бу ни тамаша, нишләп әле бу, койрыгы ишеккә кысылган мәчедәй, котны алып күтәрелде дә бәрелде? Ләкин моның сере бик тиз ачылды. Баксаң, бичараның бөтен өмет иткәне, бөтен күңеле-җаны белән теләгәне — каенанасыннан, каенесеннән аерылып, ниһаять, үзләре генә бер гаилә булып яшәү икән. Һәрбер килен шикелле, ул да хадимәлектән котылу, үз башына үз ирке белән яшәү турында гел хыялланган икән... Һәм ул, бичара, үз хокукын яклар өчен усалланып каршы тору гына түгел, кичләрен йокларга яткач, иренең муенына сарылып елыйелый да һаман шул ук нәрсәне Зарифына тукыды: «Үзебез генә бер иркенләп торыйк инде, үз көнебез, үз рәхәтебез өчен генә бер торып карыйк инде... Кайчанга чаклы мин каенана көен көйләп, энеләреңә бил бөгеп яшәрмен? Килен генә булып торыр өчен яшь чакларым үтте бит инде, үз балаларым җитеп килә, алар өчен торасым килә минем... мин дә кеше ләбаса!»

Зариф, аны тынычландырырга теләп: «Менә Алла бирсә, яңа йортка күчкәч, Зөфәр үзе дә өйләнер, синең өстән эш-мәшәкать төшәр, карт килен булып, командовать итеп кенә торырсың!» — дип тә карады. Ләкин Сәкинә моның кебек юатып маташуларны ишетергә дә теләмәде. «Һи, сөйлисең тагы! — диде ул, ачынып.— Зөфәрне мин белмиммени? Зөфәр аксөяк бит ул, аның үзен карарга бер кеше кирәк. Аннары, үзеңә генә әйтим, аның әртискәсе бар дип сөйлиләр, өеңә шул әртискәсен китерсә, нишләрсең? Тагын шуның асравы булыргамы? Юк, җаным, булмый, булмый, кыстама мине, рәнҗетмә! Бөтенесенә хезмәтче булырга теләмим мин, җитәр, көчләмә, риза-бәхил түгелмен!»

Шулай ялварды, шулай куркытты ирен Сәкинә... Абзый кеше бик нык уйга калды. Дөрес, баштарак ул, ир-

хуҗа буларак, ачуланып-боерып кына хатынын сындырмакчы булып карады, ләкин Сәкинә сыну түгел, отыры ныграк каршы торды. Болай эш чыкмагач, яхшылык белән күндерергә тырышып карады, ләкин Сәкинәгә бу да һич тәэсир итмәде. Хәер, дөресен генә әйткәндә, Зариф Сәкинәнең йөрәгеннән чыккан сүзләренә каршы торырлык үз дәлилләрен китерә дә алмады. Хак сүзгә җавап юк, дип белмичә әйтмәгәннәр, күрәсең! Шуның өстенә яңа кайтып кушылган чагы да булгач, яңа хатын кадерле, тансык иде, кызганмыйча һәм хисаплашмыйча мөмкин түгел иде, кыскасы, абзыебыз акрынлап йомшара-йомшара, ахыр чиктә хатынының таләбенә буйсынырга мәҗбүр булды.

Соңрак, өйдәгеләр бу хәлне белеп алгач, бик аптырашып калдылар. Әниләре Таибә абыстай килененең иренә баш бөкмичә шундый зур эшкә аяк чалуын һич аңларга да, кичерергә дә теләмәде. Ачуланып-каргап та, сыкранып-рәнҗеп тә ул киленен ничек кенә битәрләмәде; ир хакын санламауның бик зур гөнаһ булуын да әйтте, бәддога белән дә куркытты, кешеләрдән оялырга да өндәп карады, үлгәндә бәхиллегемне бирмәм дип тә какшатырга тырышты, ләкин боларның берсе дә Сәкинәгә тәэсир итмәде. Ул үз сүзендә таш кебек какшамас булып калды.

Тик Зөфәр генә, җиңгәсенең каршы килүенә бик кәефе кырылса да, бу бәхәс-низагыга тыгылуны кирәк тапмады. Җиңгәсе белән аның арасы алай бик җылы да, бик салкын да түгел иде, гомумән, ул аңа сүзсез-нисез бер мәхлук итеп югарыдан карарга өйрәнгән иде, һәм менә шул йомыкый гына хатынның кинәт үз хокукын мондый батырлык белән яклавы аны чынлап торып гаҗәпләндерде һәм борчуга салды. Ул сизде: өч бала анасын елата-елата, муенчаклап дигәндәй, яңа йортка өстерәп илтү хәерлегә булмаячак, әлбәттә. Шуңа күрә ул бәхәскә тыгылмады, абыйсын котыртып маташмады, уйлап торды да кулын гына селтәде.

Ахырда, тагын бер кат уйлашып киңәшкәннән соң, йортны Таибә абыстай исеменә алырга булдылар. Карчыкның фани дөнья белән артык алыш-биреше юк, билгесез һәм гөнаһсыз бер кеше, бәс, шулай булгач, төрле гайбәт-сүзләрдән, хәтәр-хәвефләрдән курыкмаска да мөмкин. Эш юридик яктан ныгытылгач, кешеләр теләсә ни сөйләсеннәр, тик законга сыйсын!

Шундый карарга килгәч тә Зөфәр әнисе алдына үзенең таләбен куйды. Ягъни йортны алу белән бер үк вакытта Таибә абыстай үзенең васыятьнамәсен язып, улы

Зөфәрне йортка бердәнбер тулы хуҗа итеп калдырырга тиеш... Карчык, әлбәттә, моны аңлый иде, моңа риза булырга тиешлеген белә иде, тик улының яңа йортка барып кермәс борын ук васыятьнамә язарга ашыктыруы аңа бер дә ошамады. Бик хәтере калып, хәтта рәнҗеп ул Зөфәргә: «Нигә, син мине тизрәк кабергә илтеп тыкмакчы буласыңмыни? — диде.— Ашыкма, вакыты җиткәч үзем дә Ходай каршына китәрмен. Ә син иң әүвәл эшеңне бетер, өеңә күч, аннан соң да васыятемне алырга өлгерерсең. Миңа ышана торгансыңдыр бит?»

Ләкин Зөфәр әнисенең бу сүзләрен колагына да эләргә теләмәде. Барысының да дәгъвасын тыңлау аны, ниһаять, туйдырып бетерде. Җитәр! Болай да күп чигенде. Ә бу мәсьәләдә инде ул бер карыш та чигенмәячәк. Мал — бәгырь ите, диләр!.. Һәм ул бәхәскә кереп тормыйча, әнисе исеменнән васыятьнамәне бер таныш юристыннан яздырып алды да, китереп, карчык алдына салды. «Әни, мин сиңа яңадан йөз ел гомер телим,— диде ул, салкын-тыныч кына,— әмма шушы кәгазьгә кулыңны куясың!.. Шунсыз — йорт юк!» Таибә абыстай беравык ни әйтергә дә белмичә улына шаккатып карап торды, аннары Зөфәр сузган каләмне, бисмилла әйтеп, калтыранган кулына алды.

...Менә Ушаковлар белән вәгъдәләшкән көн дә килеп җитте. Инде бөтен эш тә хәл ителгән иде, кирәкле документлар барысы да әзерләнгән иде, һәм Зөфәр вәгъдәләшкән көннең кичендә бер чемодан акча күтәреп, Хәмит дусты белән абыйсын ияртеп, Ушаковларга барды да шаһитлар алдында алар белән исәп-хисапны өзеп кайтты.

Ниһаять, күптәнге хыялына иреште шикелле ул... Зинин урамындагы таза, матур, бакчалы йорт аныкы хәзер!

## X

Сентябрь башында Ушаковлар кырык ел торган өйләреннән чыгып киттеләр... Инде яңа хуҗалар килеп керергә тиеш... Йорт — җансыз нәрсә, ул — дәшми, берни дә дәшми, җиргә үскәндәй тик кенә һәм тын гына тора... Әмма бөтенләй үк җансыз микән ул?

Менә иске хуҗалар чыгып китүгә өч таза хатын килделәр дә Ушаковлардан утырып калган гомерлек тузанны себереп чыгардылар, каты киндер белән бусага-баскычларына хәтле әйбәтләп юдылар, ишек-тәрәзәләрен ачып, бөтен бүлмәләрен җилләтеп киптерделәр. Ә икен-

че көнне Таибә абыстай иртә таңнан торып, урамда кешекара очраганчы, буш өйгә бер бөтен икмәк белән бер чирек сөт китереп куйды. Аннары Камәретдин мулланы чакыртып, өйнең түрендә Коръән укытты. Шуннан соң гына Зөфәр (ул мулланың күзенә күренмәде дә) ике атта йорт әйберләрен ташыта башлады.

...Күченү ярты көндә тәмам булды, кичкә табан булышкан кешеләр дә, Зариф белән Сәкинә дә ашап эчкәннән соң үзләренә кайтып киттеләр, һәм ялан кадәр өйдә Зөфәр дә Таибә абыстай һәм Хөршид кенә торып калдылар. Бер кич кундылар, ике кич, өч кич кундылар һәм акрынлап яңа урында торып киттеләр... Ләкин, шуны әйтергә кирәк, башта алар бик сәер хәл кичерделәр... Алты бүлмәгә өч кеше, ә китергән җиһазлары бер залны тутырырга да җитмәде. Шуңадыр, ахры, беренче көннән үк аларны ниндидер бер ят, өнсез, әмма колагын салып торган авыр бушлык чорнап алды. Моңа ияләшүе бик читен иде. Хәтта алар вакыт-вакыт берберсен югалталар иде. Таибә абыстай еш кына: «Хөршид, кайда син?» — дип, бүлмәдән бүлмәгә кыштыр-кыштыр кызын эзләп йөри, ә Зөфәр исә өй эче аеруча тынып калган чакларда: «Болар нишлиләр икән?» — дип, әнисе белән сеңелесен күрер өчен үз бүлмәсеннән әле кухняга, әле аш бүлмәсенә чыгып карый иде... Шактый гына вакытлар шулай яңа урынга, ялгыш килеп эләккән кешеләр төсле, җайлаша һәм ияләшә алмыйча йөдәделәр. Гүя менә Ушаковлар өе яңа хуҗаларны юри таныргა теләми кебек иде.

Өчесе дә өйдә чакта әле бу ят, өнсез бушлыкка артык игътибар итмәскә дә мөмкин иде, әмма инде Таибә абыстай үзе генә торып калган чакларда аңа бик тә авыр була торган иде. Һәр көнне иртән иртүк Зөфәр парадный ишектән чыгып, салмак кына атлап эшенә китеп бара. Аннары бераздан пөхтә генә киенгән унөч-ундүрт яшьлек арык кына кыз Хөршид шул ук ишектән чыга да, кечкенә портфелен селкә-селкә, мәктәпкә йөгерә... Аның артыннан ишекнең келәсе шалтырап бикләнә, һәм зур, буш өйдә биш-алты сәгать буена Таибә абыстай япаялгыз гына торып кала... Килгән кеше юк, киткән кеше юк, күршеләрдән берәү дә аяк атлап керми, җитмәсә, урамы да тып-тын, әллә нидә бер генә кеше-кара узып китә —шуңадыр инде өй, эчтән генә түгел, тыштан да ничектер үлек, ташландык булып күренә иде. Таибә абыстай күбрәк үзенең бүлмәсендә, сандык өстендә аякларын бөкләп, тәсбих тартып утыра. Ул куркак хатын түгел, өрәк, өй иясе кебек нәрсәләрнең булуына ышанып та

бетми, гомумән юк-бар нәрсәләр турында уйламаска тырыша, әмма шулай да шомлана, шомланмыйча булдыра алмый... Зур өйнең әле бер башыннан, әле икенче башыннан ниндидер кыштырдау, ниндидер сәер өн ишетелгән кебек була яки аргы бүлмәләрнең берәрсендә кемдер йөргән шикелле тоела — карчыкның йөрәгенә әкрен генә салкын үрмәли, аркасы буйлап әледән-әле кымырҗу йөгереп уза, һәм ул кузгалырга, төшәргә куркып, эченнән бөтен белгән догаларын кабатлап, сандыгы өстендә утыра да утыра...

Әлбәттә, мондый хәл озакка барырга тиеш түгел иде. Моңа Зөфәр дә бик борчыла иде. Бигрәк тә ул, көн буена җан әсәре барлыгын сиздермәгән өйгә жуликлар кереп, карчыкны чүкеп чыга күрмәсеннәр дип курка иде. Моның кебек эшләр шәһәрдә ара-тирә ишетелгәләп тора, Алла сакласын, уйламаган җирдән әллә ни булып куюы бар... Шуңа күрә карчык янына иптәшкә тизрәк берәр кеше табарга кирәк иде. Кыскасы, озак та үтми, Сәкинә ярдәмендә Яңа бистәдән олы гына яшьтәге бер хатынны Таибә абыстай янына табып китерделәр... Ләкин бу вакытлы чара, Таибә абыстай моңа гына һич канәгать түгел, аның күптән уйлап йөргән бик җитди үз исәбе бар иде әле...

Көзге салкын явымлы кичләрнең берсендә ул, намазлыктан гына торып (бу өйгә күчкәч, абыстай нигәдер бик диндар булып киткән иде), улы Зөфәр янына кереп утырды. Ниндидер кәгазьләр актарып утырган Зөфәр әнисенә сәерсенеп кенә карап алды; ак батист яулыгын ияк астыннан китереп бәйләгән карчыкның йөзендә зур сүзгә керешер алдыннан гына була торган басынкы-сабыр, җитди бер чырай иде. Күлмәгенең озын, киң җиңнәрен тарткалап, бераз дәшми торганнан соң, ул акрын гына сорап куйды:

— Мин синең эшеңне бүлмимме?

— Юк, әни, юк,— диде Зөфәр, тыңларга әзер торуын аңлатып.

— Алайса минем сиңа сүзем бар иде.

— Сөйлә, әни, сөйлә! — Зөфәр кәгазьләрен бер читкәрәк этәрде дә әнисенә борыла төште.

Таибә абыстай әүвәл бер кулын өстәлгә салды, аннары алдына карап кына сүзен башлады:

— Ни әйтәсемне, улым, үзең дә сизенә torгансыңдыр инде... Беренче кузгатуым гына түгел, моңарчы да әйтә килдем, хәзер инде, шаять, Алладан вакыт җиткәндер...

Зөфәр дөрестән дә сүзнең нәрсә турында баруын си-

зеп алды, ләкин шулай да бераз гаҗәпләнә төшеп, юри сораган булды:

— Сүз ни турыда соң, әни, нәрсәгә вакыт җиткәндер дисең?

— Соң инде белгән өстенә сорамасаң...— диде карчык, үпкәләгән сыманрак итеп, аннары туп-туры гына әйтте дә бирде: — Өйләнергә вакыт, дим, өйләнергә!.. Кайчанга кадәр сузмакчы буласың? Ярамый бит болай, Аллага шөкер, ир уртасы булып җиттең бит инде... Һәр җимешнең үз вакыты дигәндәй, моның да бит бер чиге булырга тиеш ләбаса! Кызлар гына утырып кала дип уйлама. Егет кеше дә, вакытын бер уздырып җибәрсә, ямен-кызыгын югалта...

— Анысы шулайдыр да бит, әни,— диде Зөфәр, маңгаен ышкып,— ләкин һәр эшнең үз җае бар ич! Әле кайчан гына, күпме акча салып, шушы йортны алдык... Өстеөстенә булмый бит. Азрак баш-күз алыйк, хәл җыйыйк, аннары инде бу хакта да уйлашырбыз.

— Уйлашырбыз! Ходаем, әле һаман уйламакчы гына буласың икән!.. Юк инде, Зөфәр улым, уйланудан эшкә күчәргә вакыт җитте, бик җитте... Моңарчы болай да, әле сугыш бетсен, әле нигезебез булсын дип, төрле сылтау белән сузып килдең. Хәзер эш нидән тора? Менә, игелеген күрергә насыйп итсен, гомерлек нигезгә хуҗа булдың. Инде шушы нигездә әйбәтләп оя үрергә кирәктер ләбаса, ата-бабадан калган йола ич ул!.. Югыйсә үзең ятим, өең ятим, караучың юк, хезмәтчең юк, йә, нигә ярый бу?.. Ничек асрарсың син бу йортны?.. Аннары минем хәлемә дә керергә тиешсең син. Күпмегә чаклы бу казармы хәтле өйдә мин ялгыз башым каңгырап утырырмын...

— Әни, син хәзер ялгыз утырмыйсың ич, әнә үзеңә иптәшкә Мәймүнә апаны китердек.

— Мәймүнә!.. Мәймүнә кем ул хәтле миңа! Бүген бар, иртәгә юк дигәндәй, аңа исәп тотып булмый бит. Сиңа хатын, безгә килен кирәк монда. Сине тизрәк өйләндерү турында сүз бара, аңлыйсыңмы шуны?

— Аңлыйм, әни, аңлыйм!

— Аңласаң шул!.. Чарасына керешик. Әгәр үзеңнең күздә тоткан кешең булмаса, без табышып бирербез. Кызларга кытлык заманы түгел, менә дигән җирдән берәр яхшы ата-ананың инсафлы баласын бик җиңел табарбыз, Аллаһы бирсә! Тик эш сиңа гына терәлеп калмасын... Әйткәнемне тыңла, улым, тыңла!

Зөфәр, маңгаена таянып, шактый гына вакыт уйланып утырды. Бу кузгатылган мәсьәлә турында аның бик

тирән яктан үз теләге, үз фикерләре булса да, хәзергә әнисе белән бәхәскә керүне ул кирәк тапмады. Тирән генә бер сулап куйды да, ниһаять, әнисенә йомшак кына болай диде:

— Әни, әйткәннәреңнең барысы белән дә килешәм, каршы килмим... әйе, миңа өйләнергә кирәк. Әмма ләкин бу минем өчен гаять җитди мәсьәлә, хәзер генә өзеп тәгаен сүз әйтүе бик читен... Шуңа күрә син миңа уйланырга вакыт бир, уйлыйм әле мин, аннары бер җай белән үзем сиңа соңгы сүземне әйтермен. Шулай килештекме?

Таибә абыстай, бик үк канәгать булып бетмәсә дә, килешмичә булдыра алмады. Шулай да ул торып чыгар алдыннан сукраныбрак әйтмичә түзмәде:

— Һай, артык нечкәлисең, улым! Өйләнү кебек эштә бераз күзне йомыбрак тәвәккәлләү дә кайчак хәерлегә була ул! Үзең генә очына чыга алмасаң, Аллага тапшырырга кирәк. Ярый...

Әйе, әгәр дә ул, Зөфәр, күзен йомып тәвәккәлли алса, яраткан кешесе күптән аның янында булыр иде инде. Әмма... күзне йомып та, тәвәккәлләп тә булмый шул! Хәтәр, рискованно!.. Ихтимал, Рәшидә кебек якты, нәфис хатынны ул бүтән таба да алмас. Әгәр аңа өйләнә калса, теге иблис Хәмит әйтмешли, сылу артистка үзе белән бу йортка шатлык, җыр, музыка алып килер иде. Аның үзе кебек уен-көлке, җыр-музыка яратучы ваемсыз артист халкы өеңә килеп тулыр иде. Көн дә кәеф-сафа китәр иде. Табып, китереп, сыйлап кына өлгерт!.. Йә, шулмы ул хыял иткән тормыш? Нәрсә белән бетәр иде моның ахыры?..

Ярый, алай ук булмасын да ди. Хәзер заманы да, кешеләре дә бөтенләй башка. Рәшидә үзе дә андый җиңел тормышка өйрәнмәгән, нужа әчесен шактый күп эчкән хатын... Ир җилкәсенә салынып, курчак булып, эшсез рәхәттә генә яшәргә теләмәвен кат-кат әйткәне дә бар. Башы-күзе шул сәхнәсе, уены, җыры белән томаланып беткән. Кыскасы, җилкәңә менеп атлана торган хатыннардан булмаячак.

Ләкин, икенче яктан, аның әнә шулай үз дигәнчә яшәргә, бәйсез булырга омтылуы куркыта. Ышанып, яныңа алырсың, тормышыңа кертерсең, ә ул сине аңламас, син дигәнчә яшәргә риза булмас. Һәрхәлдә, синең хөкемеңә буйсынып, синең теләкләрең белән килешеп, итагатьле хатын булып кына торуны аңардан көтүе читен, бик читен... Үзенә күрә түгел, ниндидер гаделлек, тигезлек сөюче ярлы бер тәкәббер бит ул!

Юк, яратам дип, аңа башны бәйләү шактый риско-

ванный эш булыр иде. Җитмәсә, кешедән калган хатын бит әле ул. Бик эчне тырный торган күңелсез нәрсә бит монысы да... Инде, күзне йомып ала башласаң, әнисе дә, барлык туганнары да мондый хәл белән һич килешергә теләмәячәкләр, теш-тырнаклары белән каршы торачаклар.

Димәк, Рәшидәгә исәп тотарга ярамый. Өйләнер өчен бүтәнне эзләргә кирәк булачак. Күптән инде аның бу мәсьәләдә хыял иткән, ягъни үзенә һәр яктан да кулай булырлык яшь, чибәр кыз табу теләге бар иде — менә шуңа ирешергә кирәк. Ә моның өчен ул иң элек Рәшидә белән ике араны ничектер җайлап кына, авырттырмыйча гына өзәргә тиеш. Ләкин ничек итеп?.. Рәшидә бит ул!.. Ничек итеп?..

## XI

Яңа йортта Сабитовларга күңелсезрәк, бушрак булса да, ниһаять, беренче озын кыш та үтеп китте. Яз килде. Тыныч, хәвефсез яз иде инде бу... Халык, арба басып киткән түмгәкне яңадан өяргә керешкән кырмыска күчедәй, мәш килеп үзенең илен-көнен торгызырга, рәткә кертергә тотынды. Зөфәр дә тормышка аеруча бер сусау һәм дәрт тоеп, яңа нигезен үзе теләгәнчә әйбәтләп, матур, нык итеп кору уе белән яна башлады. Иң элек ул, кар китеп, җир кипкәч тә, йорт-җирен төзәтү, тәртипкә китерү эшенә кереште. Башта ике оста яллап, капка-коймасын өр-яңадан эшләтте; койма буй җитмәслек биек, капка бик таза булып чыкты. Сабитовларның эчке дөньясын хәзер берәр ярыктан сыңар күз белән дә карау мөмкин түгел иде. Аннары малярлар китертеп, капка-коймасын сарыга, өй түбәсен яшелгә буятып җибәрде. Йорт бердән яктырып, матурланып китте. Зөфәр эшкә барышлый да, кайтышлый да ихтыярсыздан тукталып, сөенеп-сокланып карап торудан тыела алмый иде — аның йорты бөтен урамына ямь биреп тора хәзер!..

Ихтимал, күрше-тирәне һәм үткән-сүткәннәрне йортның матурлыгыннан да бигрәк моның хуҗасы кем, кайдан таба ул барысын да дигән сорау кызыксындырадыр. Ләкин бер дә гаҗәпләнерлек нәрсә юк монда: дәүләт заводы һәм аның меңләгән эшчеләрен тәэмин итәргә тиешле ОРСы, сугыш китергән бөлгенлеккә карамастан, бик бай иде әле. Андый байлыктан бер тәэминатчының, әйтик, түбәсен буярлык кына олиф белән буяу табу ни тора ул?! Диңгездән бер тамчы гына!

Бер үк вакытта Зөфәр каяндыр бер бакчачы карт та-

бып китерде дә шуңа җимеш бакчасын рәткә кертергә кушты. Мулла кыяфәтле, чиста, йомры гына карт башта бакчаның түренә хәтле узып, игътибар белән бөтенесен бер карап чыкты; чыккач, кулларын артка куеп: «Айһай, тәмам хәшәрәтләр оясына әверелгән икән бу!» — дип, башын селкеп торды; бары шуннан соң гына бишмәтен салып, җиңен сызганып һәм саплы пычкы, кәкре пәке белән коралланып, эшкә тотынды. Һәр агачка ул ни өчендер «мәхлугым» дип дәшә иде, нидер сөйләнә-сөйләнә аны әйләнеп карап чыга иде, шуннан соң һич кызганмыйча «мәхлук»ны ботарларга тотына иде. Берике көн эчендә карт кисеп ташлаган ботаклардан рәшәткә буенда зур бер өем хасил булды. Зөфәр баштарак, бу мөселман бакчаны утынга кисеп бетерә бит, дип, чынлап курка калды. Ләкин иртәрәк борчылган икән, картның ботарлавыннан соң һәр агач, һәр куак җыйнакланып, берберсеннән аерылып, бөтен бакча эче иркенәеп, яктырып китте. Карт кечкенә ак сакалын кәкре бармаклары белән астан өскә тараштырып, Зөфәргә әйтте: «Менә, кем, Зөфәр туган, бакчаңда хәзер җил дә йөрер, кояш та күп, җимеш тә мул булыр, Алла насыйп итсә!» — диде һәм тагын агачларны ничек карарга, кайчан ашларга, кайчан сугарырга кирәклеген әйткәләп төшендерде дә, шуның белән эшен беткәнгә санап, тиешле акчасын алып китеп тә барды.

Зөфәр, билгеле, өенең эчен дә җиһазларга онытмады. Шәп-шәрә алты бүлмәне тутырырга күп кирәк иде әле, шулай да комиссионный магазиннардан төрле мебель алгалап, аннары Гайсә карт аша да кайбер нәрсәләр тапкалап, өен төрле иштәге җиһазлар белән бераз тутырды. Әлбәттә, Зөфәр күреп тора, бу әле зәвыклы, культуралы итеп җиһазлау түгел, өе аның антиквар кибетенә охшабрак китте, ләкин хәзергә башка чара юк, заманасына күрә ярап торыр, диде.

Таибә абыстай улының берьюлы бу хәтле эшләр актарып ташлавына эченнән генә бик сөенеп йөри иде. Ул моны егетнең, ниһаять, өйләнергә җыенуыдыр инде дип, үзенчә яхшыга юрады. Тик менә улының күздә тоткан берәр кызы бармы-юкмы, булмаса — кайдан, кемне табарга — шушы хакта борчылып уйлана иде. Бу турыда ул зур улы Зарифка да сүз салып куйды. Таибә абыстай фикеренчә, мондый йортка ни җитте кызны гына җитәкләп китерергә ярамый, тапкач-тапкач, яхшы нәселдән, мал кадерен белердәй тырыш, уңган, инсафлы кыз табарга кирәк.

Зөфәр үзе өйләнү мәсьәләсендә тәгаен бер фикергә

килмәгән иде әле, шулай да вакыт җиткәнлеген сизә иде инде. Менә күпме эшләр башкарды, күпме акча тотты, йорты эчтән дә, тыштан да әнә ничек матурланды, әмма шуңа карамастан Зөфәр чын канәгатьләнү тоя алмый, чөнки аңа һаман нидер җитми кебек, йорты да элеккечә һаман буш, җансыз кебек иде. Күрәсең, бу зур йортка җан өрер өчен, бу йортта чын тормыш татып яшәр өчен тагын бер яңа кеше — җанга якын яшь, чибәр хатын кирәктер инде. Шунсыз тормышы да, күңеле дә түгәрәкләнмәячәк, ахрысы.

Ләкин шушы уйларга бирелеп йөргән чакта гына Зөфәрнең аяк асты кинәт кенә бер тетрәп куйды. Хикмәт шунда, Зөфәр йорт тирәсендәге эшләрен бетерүгә, һич көтмәгән җирдән госконтроль кешеләре килеп, ОРСның бөтен системасында зур ревизия үткәрергә керештеләр. Билгеле инде, көне-сәгате белән дөнья мәшәкатьләре, өйләнү кайгылары Зөфәрнең башыннан берьюлы очтылар. Дөрес, коелып төшмәде ул, ревизияләрне күргәне бар, ләкин, бердән, бу юлы аның бик капыл булуы, икенчедән, заводтагы «актив» саналып йөргән, бик күпне белүче һәм бик төпченергә яратучы кайбер кешеләрнең ревизия эшенә тартылуы Зөфәрне шактый нык борчуга салды. Болар инде мондый чакта, җәнлек ауларга катнашучылар шикелле, гаҗәп зур тырышлык күрсәткән булалар. Аннары алар, шушы җирдәге кешеләр буларак, әллә кайчангы эшләрне дә исләрендә тоталар һәм казып чыгарырга әзер торалар. (Ә казып чыгарырлык эшләр юк түгел иде.) Шуның өстенә тагын алар, шул ук активистлар, Зөфәр кебек кешенең мәгыйшәтен дә яхшы ук беләләр бит; аның былтыр гына зур йорт сатып алуын да, быел шуны яңартып йөрүен дә ревизия ясаучылар колагына бик әйбәтләп тукыячаклар, билгеле.

Зөфәр үзе материаль җаваплы кеше түгел, аның эше — ОРСның сәүдә точкаларына гомуми җитәкчелек итү, шул точкаларны товар белән тәэмин итеп тору; теге яки бу точкада растрата, җитмәүчелек ачылса, аны Зөфәрдән таптырмаячаклар. Моның өчен җавап бирүче «точка» мөдире яки директоры бар. Ләкин шул директордан: «Кая куйдың, кем белән ашадың?» — дип буып сораулары мөмкин. Зөфәр өчен һәртөрле күңелсезлекләрнең менә шул яктан килеп чыгуы ихтимал.

Әлбәттә, вак-төяк растрата, җитмәүчелекләр генә аны куркытмый. Тик менә күмәкләшеп «ашау» бик хәтәр нәрсә. Мондый нәрсәне ача калсалар, эшне, һичшиксез, тикшерү органнарына бирәчәкләр. Мәсьәлә бик җитдиләшеп китәчәк. Дөрес, эшнең аңа кадәр барып җитмәве

дә мөмкин, чөнки, бердән, ОРС җитәкчеләре үзләре үк моңа юл куймаска тиешләр, ник дисәң, алар үзләре дә кардан ак, сөттән пакь түгелләр; икенчедән, әлеге точкалардагы материаль җаваплы кешеләр дә, ямьсез эшләр ачыла калса, бөтен гаепне бары үз өсләренә алырга тиешләр, ник дисәң, совет законы үзе үк ялгыз ашаучыларга — җәзаның рәхимлерәк, ә күмәкләп ашаучыларга катырак булуын кисәтеп тора. Аннары сәүдә работниклары арасында язылмаган бер кагыйдә бар: бәлагә юлыккан кешене исән калучылар һәрвакытта йолып алырга тырышалар. Һәм, әйтергә кирәк, күп кенә очракта бу тырышып йөрүнең теге «бичара»га шактый зур файдасы да тиеп куя: йә ул бөтенләй котылып кала, яки инде, китеп барса да, «сәфәре» бик кыска булып чыга.

Ләкин шулай да бу исәпләргә генә таянып, бөтенләй үк гафил булып торырга ярамый иде. Зөфәр ревизия килгән көнне үк кичен, абыйсы аша, Хәмит дустын үзенең өенә чакыртып алды. Түр бүлмәгә бикләнеп утырдылар. Зөфәр дустын ОРСтагы хәлләр белән кыскача гына таныштырды һәм аның алдына ике төрле бурыч куйды: беренчедән, ревизия ясарга килүчеләрнең баш кешесенә берәр төрле юл табып булмасмы? Ягъни ниндирәк кеше ул, кемнең сүзе үтә аңа, гомумән, җайга килердәй кешеме?

— Кыскасы, үзең аңлыйсың инде,— диде Зөфәр,— ревизиянең нәтиҗәләре бик каты булмаган тәкъдирдә, без ул иптәшне бервакытта да онытмас идек. Икенчедән, промтовар магазины директоры Сөнгатуллинны һәм азык складының мөдире Волковны бүгеннән калмый кисәтеп куярга кирәк: кулларында запас акча тотсыннар, ревизиянең нәтиҗәләре тәмам ачыкланмыйча торып, аңлатма бирергә ашыкмасыннар, гомумән, телләрен тешләп кенә йөрсеннәр. Алар моны үзләре дә белергә тиеш, әлбәттә, ләкин исләренә төшермичә ярамый, чөнки каушап бутала һәм бүтәннәрне бутый башласалар, соңыннан эшне төзәтүе авыр булачак. Әйләнгән саен минем янга йөгереп килмәсеннәр, ә сүзләре булса, синең аркылы гына җиткерсеннәр. Мин, положением буенча, ревизиягә булышучы кеше хәзер — шуны онытмасыннар.— Сүзен тәмамлап, Зөфәр ахырдан гына әйтеп куйды: — Только син, дус кеше, ревизор мәсьәләсендә сак була күр, яме!

— Өйрәтмә син мине,— диде Хәмит, дорфа гына. Аннары бераз уйланып торгач, дәртле генә башын күтәрде.— Ярый, миннән эш калмас. Конечно, ревизорга юл табу ансат булмаячак, ну ничево, сукыр тычкан эзеннән йөреп

карыйк әле, шәт, берәр йомшак җирен капшарбыз. Ревизор да чуеннан түгелдер әле.

Зөфәр, көлемсерәп, кулын сузды:

— Алайса әйттем-бетте?

Хәмит аның учына сугып алды:

— Әйттем-бетте! Мать якасын!

Һәм ул, сугышчан задание алган оперуполномоченный төсле, такыр башына зәңгәр кепкасын каплады да, кәкре аяклары белән нык-нык басып, җитез генә чыгып та китте.

Зөфәр ревизия барышында үзен бик тыныч тотты. Башта ул ревизия кешеләре белән, дәрәҗәсен саклап, әмма ачык йөз күрсәтеп, әйбәт кенә сөйләште, аларга кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә әзер торуын белдерде, исәп-хисап эшләрендә булышыр өчен үзенең аппаратыннан кешеләр дә бирде.

Ревизия өч көн дәвам итте. Барлык точкаларда да товар калдыгын исәпкә алдылар, соңгы ярты ел эчендә күпме товар кайткан, күпмесе сатылган, күпме акча тапшырылган — шуларны исәпләп чыгардылар. Ләкин ревизияне алып бару бик авыр иде, чөнки сугыш шартлары аркасында сәүдә-тәэминат эшләре гаять катлауланган иде. Азык-төлек белән тәэмин итү карточный система буенча бара, товарларга ике төрле бәя яшәп килә. Шуның нәтиҗәсендә бухгалтерия исәп-хисабы да бик катлауланып, чуалып беткән иде. Әмма шуңа карамастан өч көнлек ревизия дә ОРСның сәүдә точкаларында шактый зур кимчелекләр ачып өлгерде. Монда бозу да, әрәм-шәрәм итү дә, читкә тарату да, турыдан-туры урлау да бар иде. ОРС җитәкчеләренең шул точкалар аша үз-үзләрен тәэмин итү белән чамасыз шөгыльләнүләре дә бик ачык күренеп тора иде. Кайбер материаль җаваплы кешеләрнең өстенә зур гына суммаларга барып баскан җитмәүләр дә чыкты. Әмма бу кешеләр югалып калмадылар: каяндыр ниндидер документлар, актлар табып чыгардылар, шуның белән өсләренә чыккан җитмәүләрне киметә алдылар, ә калган кадәресен шунда ук акча кертеп капладылар.

Кыскасы, ревизия башта бик каты тотынса да, соңга таба аның эше акрынлап йомшара барды. Нәтиҗәдә, беркем өчен дә баш китәрлек зур куркыныч тумады. Ревизиянең йомгакларын бер генә сүз белән болай дип әйтергә мөмкин: кимчелекләр күп, ОРС малын ашау бар, әмма зур җинаятьләр юк.

Дөрес, ревизия озаграк һәм тирәнрәк казынса, тотып судка бирерлек җинаятьләрне дә тапкан булыр иде.

Ләкин аңа алай озак казынырга вакыт бирмәделәр: югарыдан кемнеңдер боерыгы буенча эшне кызу тотарга мәҗбүр булдылар. Бу Хәмитнең «сукыр тычкан эзеннән йөрү» нәтиҗәсе булырга тиеш иде.

Шулай итеп, ОРСның кайбер җитәкчеләре һәм сәүдә работниклары өстенә җыелган куе кара болыт яшьнәмичә-күкрәмичә генә таралды. Берәүне дә чатнатып сукмады. Тик Зөфәр өчен генә ул бөтенләй үк хәвеф-хәтәрсез үтеп китмәде. Әле ревизия башланмас борын ук аның, ниһаять, фаш ителүен, януын көтеп торучылар булган иде. Егет бөтен сугыш буенча ОРСны имеп ятты бит, бу юлы койрыгына басарлар дип уйлаганнар иде. Аннары ревизия барышында әлеге завод оешмаларыннан катнашучылар да аның берәр кыек эшен чокып чыгарырга тырышып карадылар, ләкин тырышып та берни таба алмадылар. Дөресен генә әйткәндә, андый нәрсә Зөфәрнең гамәлендә юк та иде, чөнки ул бервакытта да үз инициативасы, үз кулы белән дәүләт малына үрелмәде. Нигә ул? Сәүдә бүлеге мөдиренә, бигрәк тә аның кебек оста коммерсантка, сугыш шартларында үзен тәэмин итәрлек кенә юллар болай да, Аллага шөкер, җитәрлек иде.

Инде теге яки бу точкада зур гына товар җитмәү фактлары ачылган икән, моны да аңардан таптырып булмый. Моның өчен җаваплы кеше — точканың директоры, бары аңардан гына сорап була. Ә директор ОРС малын кая куйган, кем белән ашаган — ул аны инде үзе генә белә. Ул әйтмәсә, син аңардан келәшчә белән дә тартып алалмыйсың.

Кыскасы, Зөфәр Сабитовның ОРСны имеп килүе, күпләр фикеренчә, бәхәссез булса да, аңа тотып бәйләнерлек сәбәпләр табылмады.

Ләкин шулай да берише каныгучылар ревизия ачкан бөтен кимчелекләр һәм җитешсезлекләр өчен барлык гаепне аның өстенә генә аударып, ахыр чиктә шул сылтау белән аны урыныннан бәреп төшерергә чамалап карадылар. Әйе, Зөфәр, сәүдә бүлеге мөдире буларак, сәүдә точкаларындагы хәлләр өчен мораль җаваплы кеше, бу хакта ревизия актында да бик ачык әйтелгән, һәм шунлыктан аңа куркыныч юк түгел иде. Дөрес, завод һәм ОРС җитәкчеләренең аңа мөнәсәбәтләре яхшы, аңа зур белгеч итеп карыйлар һәм аның белән бик хисаплашалар иде. Юкка гына бит аны сугыш буена броньнар бирел, саклап тотмадылар. Бу юлы да алар аны якларга һәм сакларга тиешләр, чөнки, бердән, ул аларга бик кирәк кеше, икенчедән, кимчелекләр өчен бары бер ул гына гаепле түгел икәнлеген бик яхшы белеп торалар.

Ләкин тормыш бик катлаулы һәм четерекле нәрсә. Кайчагында кешеләр бераүгә дә әйтергә ярамаган эчке исәпләрдән чыгып, бәлагә таручыга кинәт кенә мөнәсәбәтләрен үзгәртәләр һәм, ярдәм кулын сузасы урында, аны төпкә үк батырып җибәрәләр. Төрлесен көтәргә мөмкин.

Шуны әйтергә кирәк, Зөфәргә каныгучылар арасында аеруча бер килешмәс усалы, үткен тешлесе бар иде. Бу кеше сугыш ахырында гына фронттан кайтып, заводның кадрлар бүлеге начальнигы булып эшли башлаган сыңар куллы майор Симаков иде. Аның кыяфәтендә үк инде утны-суны кичкән чын хәрбиләргә хас кырыс бәйсезлек, кискенлек һәм кыюлык сизелеп тора иде. Тыныч хезмәт кешесе булып алгач та ул, гел баштанаяк хәрби формада, погоннарын да салмыйча, күкрәгенә барлык орден колодкаларын тагып йөрде. Тик китель кесәсенә тыгып йөргән буш җиңенә карап кына аның сугыш белән, ниһаять, алыш-бирешен бетергән кеше булуын белергә мөмкин иде.

Менә шул кеше Зөфәрне беренче күрүдән үк яратмады, ничектер беренче караштан ук ул аның кем икәнлеген сизеп алгандай булды. Иң элек ул Зөфәрне күргәч тә: «Бу ак калач төсле егет монда ничек сакланып яткан»,— дип бик гаҗәпләнде, аннары, якыннанрак белгәч, сәүдә бүлеге мөдире турында бик катгый һәм бик ямьсез нәтиҗә ясап куйды: «Тыл күсесе! Халуй!..» Билгеле инде, ул Зөфәрнең гадел, намуслы кеше булуына тамчы да ышанмады һәм бөтен җирдә, бөтен кеше алдында аны әнә шулай — «Күсе! Халуй!» дип кенә атап йөртә башлады.

Зөфәр үзе дә сыңар куллы майорның аңа ничек каравын бик тиз белеп алды, әмма артык гаҗәпләнмәде — мондый начар карауларны аның татыганы бар иде инде. Әлбәттә, кадрлар начальнигының аңа бүредәй каравы бик ямьсез, бик күңелсез нәрсә, эчне бик пошыра бу, ләкин Зөфәр, моңа артык игътибар итмәскә тырышып, элеккечә тыныч кына йөри бирде. Ул хәтта эченнән генә, усалланып: «Бу герой фронттан алып кайткан гадәтләрен куып маташа, бөтен кешене дә үз аршынына үлчәмәкче була, тукта, менә безнең мондагы казанда ныграк кайнасын әле, үзе үк тиресен алыштырыр»,— дип тә уйлый иде. Әмма, шулай уйласа да, сөлек булып эченә оялаган ямьсез шомлану аңа барыбер тынгылык бирми иде.

Ревизия нәтиҗәләрен партбюро утырышында тикшергәндә Симаков Зөфәрнең чын йөзен үзенчә бик нык

фаш итәргә тырышты. Хәрбиләрчә бик туры басып, йодрыклаган таза кулы белән һаваны кисеп-кисеп сөйләде ул:

— Солдат йөрәгем белән сизеп әйтәм мин, сезнең ул Сабитов дигән кешегез ОРСны имеп ятучы бер торгаш булырга тиеш. Ревизия ачкан безобразиеләрне ул белмәгән, аның катнашы юк, дигән сүзгә мин һич ышанмыйм. Белмиме соң!.. Белү генә түгел, директорлар белән бергәләп ашаган ул! Фактлар юк, дисез. Ә өч йөз егерме биш меңгә йорт сатып алу факт түгелмени? Шушы үзе генә дә аның кем икәнлеген фаш итмимени? Һәм, гомумән, ул, минемчә, ышанычлы кеше түгел, җинаяте булса да, булмаса да, аны ОРСта калдырырга ярамый, алыштырырга кирәк. Берәр честный коммунистны куярга кирәк аның урынына. Безнең ОРС системасында халык малын имеп, баеп ятучыларга урын булмаска тиеш!

Майор Симаковның бу кискен, әмма дәлилләргә бик йомшак сүзләренә кушылучылар булды, дәшми калучылар булды, каршы чыгучылар да табылды. Дөрес, Зөфәр Сабитовны берәү дә честный кеше ул дип якламады, ләкин күпләр фикеренчә, аны партиясез булган өчен генә яки йорт сатып алган дип кенә урыныннан алып ташлауны таләп итүе дә читен иде. Кеше күптән эшләп килә, күренеп торган җинаяте юк, димәк, тотылмаган — карак түгел!..

Кыскасы, сүзләр күп булды, фикерләр икегә бүленде, һәм менә иң ахырдан гына, ниһаять, завод директоры телгә килде. Моңарчы мәсьәләгә үзенең мөнәсәбәтен берничек тә сиздермичә, йончыган кыяфәт белән, күзләрен яртылаш йомып утырган бу аттай зур гәүдәле кеше салмак кына сүзен башлауга һәркемнең игътибарын биләп алды:

— Мин Зөфәр Мөбарәкович Сабитовның,— диде ул,— безнең ОРСта ничек эшләвен дә һәм, иптәш Симаков әйткәнчә, күпме «имүен» дә беләм. Һәм мин моны чагыштырып, икенче төрле әйткәндә, балансировать итеп карыйм: кайсысы шуның, яхшы хезмәтеме, начар гадәтеме, кешенең эшчәнлегендә алдан йөри? Кайсысы безгә күпме файда, күпме зарар китерә? Бары шуннан соң гына нәтиҗә ясыйм. Бераз үткән хәлләргә кайтып карыйк. Менә 1942 ел. Цехта эшчеләр ачтан егыла. Заводның нормаль эшләве өчен, фронт заказларын вакытында үтәү өчен, беренче чиратта, азык кирәк... Корыч та бар, энергия дә бар, станоклар да әйләнеп тора, әмма азык җитми, азык җитмәгәч, производительность юк, заданиеләр үтәлми. Менә шундый гаять авыр бервакытта Зөфәр Мөбарәкович безне азык белән тәэмин итүдә гаҗәп зур уңганлык, ты-

рышлык, оперативность күрсәтте. Бу, иптәшләр, патриотик хезмәт иде, һич арттырып әйтмим. Чөнки азыкның вакытында табылып, кайтып торуы безгә фронт заказларын срогында үтәп барырга бик зур ярдәм итте. Ләкин шул ук вакытта каяндыр районнардан вагонлап азык китерткән кеше үзе өчен берәр түшкә ит яки күпмедер анда он алып калмаган дисезме? Юк, алган ул. Тотмасак та без моны беләбез. Җинаятьме бу? Әлбәттә, җинаять. Ләкин хикмәт шунда, тәэминат эшендәге кешеләрнең күбесе, үз кулларында булгач, алмыйча, ашамыйча түзмиләр. Чөнки шартлары шундый. Ә менә аның урынында бүтән бер кеше Сабитов шикелле үк эшли белер идеме — монысы икенче мәсьәлә. Кайберәүләр ашыйлар да эшеңне дә харап итеп китәләр — без андыйларны да күп күрдек. Шулай булгач, безгә нишләргә: Сабитовны куаргамы яки сакларгамы тиеш идек? Әлбәттә, сакларга тиеш идек, чөнки ул безгә бик кирәк кеше иде.

Директор зур шәрә башын артка таба сыпыргалап, аз гына тынып торды да янә салмак кына сүзен башлап китте:

— Менә хәзер кайберәүләр Сабитовны урыныннан бушатуны таләп итәләр. Беспартийный, диләр, ышанычлы кеше түгел, диләр, ОРСны имеп ята, диләр. Билгеле, үз кулында булгач, имә дә торгандыр, безнең хәзерге сәүдә системасында моның өчен мөмкинчелекләр бик күп әле... Ләкин Сабитов үзе, конкрет алганда, күпме ашаган, без моны белмибез, кулыбызда материал юк, һәм без аны тотып судка бирә алмыйбыз. Ә болай гына, фәләнфәсмәтән дип кенә чыгарып җибәрсәк, аны ун җиргә чакырып алачаклар. Беспартийный дип тормаячаклар. Хәер, аның беспартийный булуы яхшырак та, чөнки партийный башы белән «ашаса» тагы да әшәкерәк булыр иде,— диде директор, мәгънәле генә елмаеп.— Менә ни өчен мин иптәш Симаков таләбе белән һич килешә алмыйм. Юк, Сабитов кебек тәҗрибәле работникны чыгарып җибәрергә ярамый. Ул әле безгә бик кирәк. Ләкин мин моның белән Сабитовның кимчелекләренә күз йомыйк, гаепләрен кичерик дип әйтергә җыенмыйм. Һич юк... Менә ревизия ачкан җитешсезлекләр турында без аңа нык кына кисәтү ясарга тиешбез. Мин әле үзем бу хакта аның белән сөйләшәчәкмен. Ә инде безнең ОРСта, гомумән, законсыз «ашаулар», урлаулар бетсен өчен җәмәгать контролен көчәйтергә кирәк. Сәүдә работникларын куып бетерү ул иң ансат юл, ә менә аларны тәрбияләү, аларның эшенә көн дә күз-колак булып тору — бусы инде шактый авыр юл, әмма бердәнбер дөрес юл...

Билгеле инде, берәү дә аңа каршы чыкмады, хәтта Симаков та, чыраен сытып, телен тешләргә мәҗбүр булды. Завод директорларының авторитетлары һәм хокуклары гаять зур иде, аларның әйткәннәре закон булып йөри иде, һәм Симаков, яңа кеше булса да, моны бик яхшы белә иде. Әлбәттә, директорның әйткәннәренә карап кына аның Зөфәр турындагы фикере һич үзгәрмәде, ләкин бюрода утыручылар барысы да, ихластанмы-түгелме, «хуҗа» сүзенә кушылгач, хәзергә аңа да тыелып калудан башка чара юк иде. Бөтен хикмәт шунда ки, директорның ашыкмыйча, җайлап кына, әмма бик төпле итеп сөйләгән сүзләренә каршы куярлык дәлилләре аның җитәрлек түгел иде — ә Зөфәр кебек оста яраша һәм яшеренә белгән карьеристны ялангач кул белән генә якасыннан алып булмаячак икән. Димәк, вакыт кирәк, фактлар кирәк... Ләкин бу ихтыярсыз чигенү Симаковның солдат табигате өчен бик авыр иде булса кирәк, гүя менә бөтен кырыс кыяфәте белән ул: «Туктагыз, мин сезгә әле мактаулы коммерсантыгызның кем икәнлеген бер килеп күрсәтермен!» — дип әйтеп тора иде.

Шулай итеп, майор Симаковның кисәк кенә сикереп сугарга азаплануыннан Зөфәр Сабитовка берни дә булмады, директор үзе аны яклап калдырды, куркыныч үтте, яңадан тыныч көннәр килде. Билгеле инде, ул соңыннан барлык тәнкыйть-кисәтүләрне берсүзсез кабул итте, эшен яхшыртырга вәгъдәләр бирде, ләкин шуның белән бергә үзе өчен генә тиешле нәтиҗәләрне дә ясап куйды: моннан соң бик сак булырга, Симаков кебекләр тирәсендә бик уяу йөрергә, «хуҗаларга» тагы да ныграк елышырга, үз кулы астындагы кешеләргә катырак торырга, ә чамасыз комсызлана башлаган кайберәүләрдән котылырга да кирәк булачак. Кыскасы, эш интересы белән баш интересын гел бергә килештереп барырга тиеш ул. Оста җитәкчелекнең сере шунда бит!

Асылда исә егетнең корган планнары, теләк-уйлары берсе дә үзгәрмәде. Һичшиксез, моннан соң да аның тормышы иске эздән барачак, ягъни әйбәт кенә эшләп, үз рәхәте өчен яшәргә тиеш булачак.

Зөфәр уенча, бу бер аның гына кагыйдәсе түгел. Барлык кешеләр дә тормышта шул кагыйдә буенча яшиләр. Уку, белем-һөнәр алу, зур урынга, карьерага омтылу — барысы да кешенең иркенрәк, мулрак, рәхәтрәк яшәргә теләвеннән килә. Хәтта кайберәүләр, денем өчен түгел, көнем өчен, дип, партиягә дә керәләр — Зөфәр андый бәндәләрне дә белә. Кыскасы, тырыша-тырмаша, этләшә адәм баласы.

Билгеле инде, Зөфәр, кешенең яхшы тормышка омтылуын, шуңа ничек тә булса ирешүен бары аның үз эше, үз сәләтеннән, үз тырышлыгыннан гына килсә килә ала дип карый иде. Барлык кешеләр өчен дә ниндидер бертигез бәхетнең булуына һәм шул уртак бәхетне бергәләп табаргамы яки ясаргамы мөмкин булуына ул ышанмый иде.

Ләкин ул бер нәрсәне бик яхшы белеп тора: яшәр өчен, тормышны үзең теләгәнчәрәк корыр өчен, һичшиксез, агым уңаена агарга кирәк, заманга аркылы килүдән сакланырга кирәк, һәрвакытта уяу, тыйнак, мыштым булырга кирәк. Бу, аныңча, үзең өчен яшәүнең иң дөрес юлы!

Зөфәр, көн яктысы күрми торган ярканат кебек сукыр булса да, төлкедәй сизгер кеше иде. Аңардагы бу сизгерлек заманга да яраклашып, үз максатына ирешергә дә тырышып яшәү аркасында гаҗәп камилләште. Эшен бик шома йөртте, куркынычны алдан күрә белде, хәтәрхәвефләрдән тайпылып кала алды.

Менә хәзер дә бит куркыныч узып китте. Димәк, ул эшен оста алып бара белгән, үзен яхшы яктан күрсәтә алган. Киләчәктә дә әнә шулай акыллы булырга кирәк. Хезмәте аның әйбәт, бәрәкәтле урын, тик артык комсызланып кына китәргә ярамый. Үзара гына әйткәндә, совет сәүдәсенең мөмкинчелекләре бик зур аның; мәсәлән, теге яки бу товарга кытлык булып торган чагында сәүдә работнигының килер чыганагы һәрвакытта иркен булачак. Аннары бит инде аның, крепость шикелле, нинди чибәр, зур йорты бар. Бу йорт хакына нәфесне бераз тыярга да була. Тик менә шул таза йорт эчендә аңа, удельный князь шикелле, үзе теләгәнчә рәхәтләнеп торырга гына язсын иде.

## XII

Беркөнне Зөфәрләргә эштән кайтышлый Зариф абыйсы килеп керде. Зөфәр залдагы түгәрәк өстәлдә ниндидер эш кәгазьләре карап, счет салып утыра иде. Зариф зал ишеген ачып, башын сузып кына исәнләште:

— Нихәл, туган?

— Ә, абый, исәнме, әйдүк! — диде Зөфәр, урыныннан кузгала башлап.

— Юк, син утыр, утыр,— диде Зариф, ашыгып.— Мин әни янына кереп чыгам әле.

Һәм ул, елт итеп, эчке бүлмәләргә таба китеп тә бар-

ды, Зөфәр аның кулындагы һәрвакыт үзеннән калдырмый йөртә торган кара сумкасын гына күреп калды.

Зөфәр, бу сумканы абыйсы кулында гел генә күрсә дә, аңа һич игътибар итми иде. Хәлбуки кара сумка бервакытта да буш килми — Зариф аңа ни дә булса салып китерә һәм энисе кулына биреп калдыра иде. Моны алар бары икесе генә беләләр, хәтта Зөфәрдән дә яшерә торганнар иде. Бүген дә Зариф кара сумкасына дүрт баш каракүл тиресе салып китерде һәм, шуларны энисенә тапшырыр өчен, тизрәк Зөфәр яныннан узып китте. Ә Таибә абыстай бу тиреләрне, элек китерелгән бүтән әйберләр янына кушып, яшереп куярга тиеш... Шулай итеп, абзый кеше Зөфәр өенә, хуҗаның үзенә сиздермичә генә, динамит ташыган шикелле, хәрәм мал ташый иде.

Бер ун-унбиш минут вакыт узгач, Зариф яңадан энесе янына әйләнеп керде:

— Аптырыйм мин сиңа, Зөфәр! — диде ул, кәефле тавыш белән кычкырып.— Өеңә кайткач та баш ватып утырасың. Нигә кирәк ул, төкер син аларга, кантор эше канторда калсын. Монда менә дәүләтеңнең рәхәтен күр!

— Булмый бит, абый! — диде Зөфәр, ялкау гына елмаеп.— Канторда тынычлык бирмиләр, кайбер эшләрне менә шулай өйгә алып кайтып, аулакта карап, тикшереп утырырга туры килә.

— Анысы шулайдыр инде... Ә нәрсә тикшерәсең соң?

— Ревизия материалларын өйрәнеп утырам. Бездә күптән түгел ревизия булып узды бит, әйткән идем шикелле.

— Ие, әйткән идең, бугай. Йә, ничегрәк узды соң ревизия? Алай-болай сиңа кәсәфәте тимәдеме?

— Ничек дим? — Зөфәр җиңелчә генә иңбашын җыерып куйды.— Бераз тиде инде, ләкин алай аяктан егарлык булмады.

— Бирсен Алла!

— Күбрәк кеше аркасында, билгеле.

— Һе, шулаймы? Кара син! Нәрсә, сиңа төртеп күрсәтүчеләр табылдымыни?

— Андыйлар да булды. Аннары кайбер точкалардагы директорларның зур гына гөнаһлары да ачылды.

— Нишләгәннәр алар?

— Нәфесләренә хуҗа була белмәгәннәр, менә шул. Ә миңа алар өчен җавап бирергә туры килде.

Зариф хәйләкәр генә күзен кысып һәм көлемсерәп энесенә бер карап куйды:

— Ие,— дип сузган булды ул.— Нәфес — шайтани нәрсә инде ул. Аны тыю бик читен шул!

— Читен булса да тыярга кирәк. Шайтан муеныңа бер атланып алса, базга да илтеп төшерүе бар.

— Сиңа әйтүе ансат ул, менә мондый йортка хуҗа булып алгач ни... Аннары нәфес дигәнең кешедән күрмәли котыра бит әле ул!

— Син, абый, әллә уйнап, әллә чынлап сөйләшәсең, аңламыйм! — диде Зөфәр, җитди генә.— Ни дигән сүз ул, кешедән күрмәли? Юк, кешегә карап түгел, заманга карап эшне йөртә белергә кирәк. Менә мин сиңа да саграк булырга, итәгеңне җыебрак йөрергә киңәш бирер идем.

— Ә мин сак булмыйча нишләгән?

— Ул кадәресен үзең беләсеңдер инде... Тик шуны исеңдә тот: сугыш тудырган «хөрлекләр» бетәчәк, хөкүмәт сәүдә эшендә дә тәртип урнаштырачак, ә ревизияләр моннан соң отыры ешрак һәм катырак булачак.

— Бик әйбәт, без аңа каршы түгел,— диде Зариф, исе китмичә генә.— Әмма ләкин мин бит комиссионныйда эшлим, дәүләт сәүдәсенә бер катнашым да юк.

— Комиссионныйны да син үзең ачмагансың, аның да хуҗасы бар. Шул ук дәүләт. Так что, без барыбыз да бер хуҗа алдында җаваплы.

Зариф җилкәсен кашып алды:

— Анысын беләбез инде, безнең совет җаныңа да, малыңа да хуҗа инде ул. Аның күзенә чагылудан Ходай үзе сакласын! Ярый, киңәшең өчен рәхмәт! Ә хәзер тераска чыгып, бер хозур кылып утырыйк әле, сиңа әйтәсе важный сүз дә бар иде.

— Нинди сүз? Шушында гына әйтеп булмыймыни?

— Әни анда чәй хәзерли калды, ә минем сүзем табында гына сөйлисе тәмле сүз ул!

Зариф абзый, мыек очын бөтереп, энесенә хәйләкәр генә күз кысып куйды. Зөфәр, торып, кәгазьләрен газета белән каплады да, абыйсына ияреп, террасага чыкты.

Бакчаның чынлап та бик хозур чагы иде. Ул тәмам куерып, матурланып өлгергән. Аның беренче җимешләре — чияләр кара-кучкылланып, кура җиләкләре тулып, кызарып килә инде. Иртә өлгерә торган алмаларга да сусыл сарылык йөгерә башлаган. Хәзер шуларның чак сизелерлек хуш исе бөтен бакчага җәелеп бара. Менә күп тә үтмәс, бу татлы хуш ис күрше йортларга, урамга да тарала башлар... Әйе, Зөфәр бакчасының көннән-көн көчлерәк җимешләнә, пешә, аңкый торган чагы җиткән хәзер.

Зариф абзый террасага чыккач, бакчага бер күз салу белән, кычкырып: «Сөбеханалла!» — диде һәм пиджак

төймәләрен ычкындыра-ычкындыра ашыгып җиргә төште, сукмак буйлап китте. Әүвәл карт әнис төбенә туктап, аякларын аера биреп, инде бер як бите түгәрәкләнеп кенә кызара башлаган алмаларга сокланып карап торды. Аннары койма буенарак узып, чия агачы янында тукталды. Владимировский сорт дип йөртелгән бу шактый биек агачны итәгеннән очына кадәр чия сырып алган иде. Уңса да уңар икән! Абзый, хәйран калып, башын селкеп торды, мәшалла, диде, күз генә тия күрмәсен, диде, шуннан, чияләрнең кара-кучкылланып өлгергәннәрен генә озын-нечкә сабакларыннан өзеп-өзеп, бисмилла әйтеп, капкаларга һәм авызына килгән әче су белән бергә тәмләп-тәмләп кенә йотарга тотынды. Төшләрен, әрәм булмасын дигәндәй, учына гына төкереп барды. Шулай бераз авыз иткәннән соң, җирән мыекларын сыпыргалады да, Зөфәргә борылып, гаҗәпләнү катыш серле генә итеп сорады:

— Нишләтәсең инде син бу байлыкны?

Зөфәр көлемсерәп ике кулын җәйде:

— Нишләтим? Тозлап булмас инде. Ашарбыз, вареньесын кайнатырбыз, киптерербез, ә калса тагын, бәлки, сатарбыз да.

— Сата калсаң, башта миңа әйтергә онытма, яме! — диде Зариф, энесенә ничектер мәгънәле генә карап.

— Что син, абый! — диде Зөфәр, нигәдер бераз кызарып.— Кем дип белдең мине? Рәхим итеп кил, теләгән кадәр җый, аша, барыбызга да җитәр әле монда.

— Ә, шулаймы? Монысы өчен рәхмәт!.. Мин дә бит сине сынар өчен генә әйткән булдым. Бая нәфесне тыярга кушкан идең, тукта, мин әйтәм, моның үзенеке ничегрәк икән, дим, шуны гына беләсем килде. Үпкәләмә тагын!

— Юк ла! Вак мәсьәлә, сынарлык та, сынатырлык та эш юк монда!

— Алай димә. Кеше бит баеган саен комсызлана бара.

Зөфәр дәшмәде. Алар кире өйгә таба борылдылар. Зариф җиңел адымнар белән алдан китте, ә Зөфәр, кулларын артка куеп, аның артыннан иярде. Ул абыйсының тап-такыр кырган башына һәм кызыл җилкәсенә карап, уйланып барды. Абыйсы аңа бик шәбәеп, җиңеләеп, хәтта яшәреп тә киткән төсле күренә иде. Өсте-башы аның һәрвакыт чиста һәм пөхтә, бите гел ит кенә ашап торган кешенекедәй кызыл да шоп-шома, майлы иреннәрен шәрә калдырып кырган нечкә җирән мыекларын егетләрчә бөтереп кенә йөртә, кыскасы, бөтен торыш-кыяфәте яхшы аранда солыда гына торган тук, уйнак алашаны хәтер-

лэтэ — күрәсең, абзыйның комиссионный магазинда эшләре чынлап та бик шәптән бара иде. Ләкин Зөфәрне бер нәрсә гаҗәпләндерә: аерым тора башлагач, абзый кеше ни өчендер аңа үзенең эше-гамәле турында бер дә сөйләмәс, элеккечә киңәш-уңаш итмәс булды. Үзенчә сер сынатмаска маташуымыдыр инде? Аннары, очрашып сүз чыкканда да, менә бүгенгедәй, гел төрттереп тә үчекләп сөйләнә башлады. Ахрысы, абзыйның эчен, үзенә сиздермичә генә, көнчелек кимерә иде. Борынгылар сүзе — җан кардәш булса да, мал кардәш түгел, шуның зәхмәтедер инде бу, дип, Зөфәр борчылып уйланырга мәҗбүр булды.

Террасада сеңелләре Хөршид чәй урыны әзерләп йөри. Өстендә аның кыска итәкле ситсы күлмәк, аягында озын оек белән үкчәсез туфли. Тасмасыз, калын гына итеп үргән ике толымының берсен алга, күкрәге өстенә салындырып куйган. Аны әтиләре мәрхүмгә охшаган, диләр. Күзләре дә, кашлары да, чәчләре дә чем-кара. Матур, сылу булмакчы. Ләкин бик чирләшкә ул, шуңа күрә үзенә һаман әле бер дә ит кунмый. Гомумән, абыйларының игътибарын үзенә һич җәлеп итмичә, өнсез-мыштым гына үсеп килә бу кыз бала. Кышын укый, җәен әнисе яныннан китми, тик бу йортка күчкәч, бакча түренә китеп, шунда ялгызы китап укып утырырга гадәтләнде.

Өйдән Таибә абыстай бик борынгыдан сакланып килгән, шуңа күрә үзе генә тотып йөртә торган, авызы җиз кыршаулы, зәңгәр пыяла шикәр савытын күтәреп чыкты. Карчык чыгуга, Зариф аңа кычкырып дәште:

— Әни, чия-кураларыгыз тәмам өлгереп җиткән икән ләбаса, мин сиңа әйтим! Биргән икән Ходай үзе дә уңышны, ничек җыеп бетерерсез?

— Ие шул, — диде Таибә абыстай, сабыр-тыйнак кына. — Аллага шөкер, үзебезнең җиләк-җимеш өлгергән көнне дә күрдек... Син менә киленне балалары белән безгә җибәрер идең. Килеп, җыешып, вәринҗә кайнатышып китсен иде.

— Үләт җыксын ла киленеңне, — диде Зариф, кинәт кызып. — Аның аркасында шушындый дәүләтнең өлешенә керә алмыйча калдым.

— Хатын сүзенә иярмиләр аны... Хатынның, ни аның, чәче озын, акылы кыска — белмичә әйтмәгәннәр.

— Дурак булдым шул, дурак булдым! Теге вакытта әйтми-сөйләми генә, шалт Хупҗамал дигәндәй, кул сугып, эшне өзеп кенә куясы калган да бит, ни, дурак булдым шул!

— Үкенмә ул хәтле, абый! — диде Зөфәр дә, сүзгә ку-

шылып.— Бәлкем, хәерлегәдер. Йортсыз тормассың әле.

— Тормыйм, Аллаһы бирсә, тормыйм! — диде Зариф, урындыгы өстендә киерелә биреп.— Бераз мая гына җыйыйм. Ие, менә шул... Канешно, синеке кебек пулат кирәкми миңа, иллә мәгәр, шушындый бакчалыны эзләп табачакмын.

Таибә абыстай — диндар карчык, пошынып кына әйтеп куйды:

— Алладан сора, игелеккә язганы булсын, диген.

— Анысы шулай инде, әни, шулай... Алланы да оныт-мыйбыз аны... Ие, э-э!

Чәйгә утырдылар. Эссе көн инде сүрелеп, сүнеп бара. Кояш каршыдагы кыеклар өстеннән генә сузылып карый, агач башлары талгын гына яна, терраса алдындагы георгиннар, нәркизләр, резедалар да, хәл кергәндәй, иелгән башларын күтәрә төшеп, ачылыбрак киткәннәр, алар әйләнәсендәге кичләрен генә терелә торган ак тәмәке чәчәкләреннән искиткеч хуш ис тарала башлаган — бал урынына чәйгә кушып эчәрлек! Тик бөтенләй тынып, оеп калган һава гына шактый бөркү иде, шуңадыр инде куе чәй аеруча тәмле, эчкән саен сусын ачыла гына бара. Маңгайга, муенга, беләкләргә таза тир бәреп чыга... Башта ук пиджагын салып утырган Зариф абзый, ниһаять, изүен чиште, подтяжкасының ике ләмкәсен дә төшерде, җиңнәрен тартып куйды. Таибә абыстай да яулыгын чишеп, артка кайтарып бәйләде, тир белән чигәсенә ябышкан чал чәчләре аның көмешләнеп елтырады. Тик Зөфәр генә тирләмәде, киндер күлмәгенең чиккән якасын да ычкындырып тормады, ул чәен суытып кына эчә иде.

Бер-ике чынаяк эчкәч тә, Таибә абыстай кызына әйтте:

— Хөршид, сиңа җитеп торыр, кызлар чәйне күп эчмиләр. Бар, әнә бакчада йөр! Ятканда мин сиңа каймак бирермен. Болай да кибеп барасың.

Зөфәр шунда ук чамалап алды: димәк, җитди сүз булачак. Чөнки әнисе берәр сүз башларга уйласа, иң элек Хөршидне шулай табыннан озата иде.

— Әни, алайса мин Люсяларга керәм, китап алыштырасым бар,— диде Хөршид, кыюсыз гына урыныннан торып; аңа табын яныннан куылгандай китү һәрвакыт бик уңайсыз, кыен була торган иде.

Таибә абыстай аның артыннан каты гына әйтеп калды:

— Озак торасы булма!

Хөршид өйгә кереп киткәч тә, Зариф абзый сорап куйды:

— Лусә дигәне кем?

— Күршедәге инвалид кызы,— диде Таибә абыстай,

авыр гына көрсенеп.— Болай ипле, юаш кына кыз үзе, тик атасы, мәлгунь, бик эчә... Хөршидне бер дә кертәсем килми дә бит, нишлисең, күршедә бүтән тиңнәре булмагач...

— Эчә дигәннән, Гайсә картның эше кәкәй бит,— диде Зариф абзый, ияк астын кашып.

— Ни булган аңа тагын?

— Ни булсын, бер эчеп кайтуында подвал баскычыннан мәтәлеп төшкән. Хәзер кан косып ята икән... Сәкинә хәлен белергә кергән иде. Базлары караңгы, карчык сукыр, картын карый алмый, прәме харап, ди эшләре...

Зөфәр борчылып абыйсына карады.

— Ник больницага салмыйлар, тизрәк больницага салырга иде...

— Врач килгән, караган да киткән. Кузгатырга ярамый, дип әйтә, ди... Салып торуның кирәге калмаган, ахрысы... Убшем, очлый тормышын бывший доверенный!..

— Менә сезгә гыйбрәт! — диде Таибә абыстай, улларына алмаш-тилмәш карап.

Зөфәрне бу хәбәр шактый пошынып уйланырга мәҗбүр итте. Йорт алганда арадаш булып йөргән картка ул, вәгъдә иткән акчаның яртысын гына биреп, калганын соңыннан бирермен, дигән иде. Ә карт яңадан килеп, сорап йөрмәде — әнә ни булып киткән икән үзе белән... Кеше кайгысы — киштәдә. Шуңа Зөфәрнең вөҗданы кузгалып, ничектер эче сызланып куйды.

Аз гына уңайсыз тынлыктан соң Таибә абыстай, ниһаять, Зөфәргә карап сүз башлады:

— Менә абыең бик мөһим бер хәбәр белән килгән бит әле, тыңлыйк үзен.

— Кемгә? Сиңамы, миңамы? — диде Зөфәр, сүлпән генә.

— Ишеткәч, белерсең! — диде Таибә абыстай, коры гына.— Йә, сөйлә, улым!

Зариф, урындык аркасына ята биреп, тамак кыргалап куйды:

— Ыһ-һым. И-е... Мин бит әле сиңа бик шәп бер кыз димләмәкче булып торам, туганкай!

— Рәхмәт! Ләкин мин синнән кыз сораганым юк шикелле.

— Йә, сез адәм төсле генә сөйләшегез әле. Көлке эш түгел бу,— диде Таибә абыстай, ачулана башлап.

— Дөрес, әни,— диде Зариф, шунда ук килешеп, һәм Зөфәрнең тезенә орынып алды.— Менә нәрсә, туган, син башта әйбәт кенә тыңла, аннары инде үз сүзеңне әйтерсең.

— Пожалысты, мин тыңларга әзер,— диде Зөфәр, башын кагып, ә Зариф ашыгып сүзен дәвам иттерде:

— Сиңа бит инде башлы-күзле булырга бик вакыт. Өйләнү синең алда торган иң важный бер эш хәзер, шулай түгелме?.. Менә без дә әни белән гел шул турыда кайгыртабыз. Монда синең әйтеп торуың да кирәкми, әниең белән бертуган абыең сиңа бу эштә булышмаса, кем булышыр!.. Синең кайгың — алар кайгысы, менә ничек бит ул! Дөрес әйтәмме?

— Ышанам. Ләкин син мәсьәләгә якынрак кил әле, абый! — диде Зөфәр, каядыр бакча түренә карап.

— Мәсьәләгәме? Мәсьәлә шул инде: өйләнер өчен кыз табарга кирәк. Дөрес бит?

— Дөрес булса кирәк.

— Бигрәк тә синең кебек асыл егеткә кызның да асылын табарга кирәк. Шулай түгелме?

— Монысы белән дә килешәм.

— Менә инде, алайса, мин сиңа кызның нәкъ әнә шундый җәннәт хурыдай асылын таптым да, беләсең килсә!

— Кем ул?

— Гамбәр. Гамбәр туташ! — диде Зариф абзый, ничектер серле-тантаналы итеп.

Зөфәр, башын чайкап, ихтыярсыз көлемсерәп куйды:

— Гамбәр?! Да-а! Беренче ишетәм мондый сәер исемне...

— Кругом килгән инде! — диде Зариф, кулларын җәеп.— Кругом! Төс-баш ягыннан да, әдәп-әхлак ягыннан да, әти-әнисе ягыннан да — ну, менә бер генә дә килмәгән җире юк туташның! Ышанасыңмы?

— Кайдан таптың соң син аны?

Зариф абзый урындыгын Зөфәргә якынрак тарта төште.

— Аның этисе, Җиһанша абзый, безнең системада эшли. Әнә теге Татсоюз астындагы зур комиссионныйда, алтын-көмештән приемщик булып... Бик кәттә кеше. Күп сөйләмәс, әмма дөньяны күп күргән, бик күпне белә үзе... Әле теге елларны торгсинда, аннары сугышка каклы ювелирторгта эшләгән. Череп аккан бай булырга тиеш... Ийе... Менә беркөнне мин моның янына кергән идем. Канторкага таянып, сөйләшеп торабыз. Магазинны әбидкә яптылар. Шул чакта өф итеп киенгән яшь кенә бер сылу кыз килеп керде... «Әти, менә сиңа ашарга китердем»,—ди бу Җиһанша абзыйга. Зур сумкасыннан ап-ак эскәтергә төргән кечкенә кәстрүлне алып, әтисе алдына куйды... Карап торам мин бу кызга, ну менә, Зөфәр туган, шундый да чибәр, шундый да сөйкемле бу-

лыр икән адәм баласы!.. Күзләре чем-кара, кашлары нечкә, керфекләре озын, түбән генә карап тора үзе... Ә буе-сыны — гөл сабагы инде, гөл сабагы! Килмәгән бер генә җире дә юк!.. Озак тормады кызый, әтисеннән күпмедер акча сорап алды да чыгып китте. Кәстрүлдә күпереп торган пәрәмәчләр булып чыкты. Җиһанша абзый мине дә кыстады... Ие, э, э! Кыз чыгып киткәч, Җиһанша абзыйга әйтәм, күз тимәсен, бик матур туташыгыз бар икән, мин әйтәм. Әйе, ди Җиһанша абзый, төпчегебез бусы, менә үстереп җиткердек инде, ди... Шул чакта кылт итеп син искә төштең, Зөфәр, син!.. Карале, дим, эчемнән генә, әгәр сиңа насыйп кыз булып куйса бу туташ, дим, ә, шайтан алгыры?! Моңардан да шәпне эзләп торасы да юк ич!.. Дөресме?.. Шулай да Җиһанша абзыйдан читләтеп кенә сорашам: укыймы, эшлиме, әнисе янында гына торамы?.. Әтисе әйтә, урта мәктәпне бетерде, ди, аннан частный рәвештә музыкага өйрәнде, ди, хәзергә әле өйдә генә тора, ди. Мин әйтәм, җиткән кызны озак асраудан мәгънә юк, Җиһанша абзый, берәр әйбәт кенә кеше кулына тапшырырга кирәк, дим. Анысы шулай инде, ди Җиһанша абзый, үзебез дә ул хакта уйлаштырабыз, язганы тагын ни булыр, ди... Һи, уйламыйлармы соң инде, тим паче ир затына менә мондый кытлык бер заманда?.. Беләсеңме, Зөфәр туган, бу эшкә чынлабрак тотынганда, берьюлы ике куянны атып булачак монда. Кызлы да, маллы да булып калырсың, валлаһи! Төпчекләре бит, бүтән юк, уйлап-чамалап кара!.. Вәт менә сиңа шул!

Зариф абзый тавышын бер көчәйтеп, бер әкренәйтеп, дәртләнеп һәм тирләп бу озын сүзен, ниһаять, сөйләп бетергәч, ике куллап битен-күкрәген кат-кат җилләде дә суынган чәенә иелде. Зөфәр абыйсының сүзләрен тыштан артык кызыксыну күрсәтмичә тыңлады, сораулар бирергә ашыкмады һәм ни уйлаганын сиздермичә тыныч кына утыра бирде. Таибә абыстай, шуңа бераз пошынып булса кирәк, дәү улының сүзләрен куәтләргә ашыкты:

— Улым, абыең әйткәннәрне ишеттең инде,— диде ул, җитди генә сүзен башлап.— Син яхшы гына колак салсаң иде. Аллаһы Тәгалә үзе безгә шулай туры китереп, юл ачып тормыймы? Белмәссең, тәкъдиргә язылган булса. Мин үзем дә белешеп-сорашып карадым. Бер дә күңелгә ошамас нәрсә ишетмәдем. Бик әйбәт гаилә, бик әйбәт кешеләр икән. Кызның әнисе, кем, Мәфтүхә ханым да бик җитеш гаиләдән чыккан, бик уңган, бик акыллы бер хатын икән. Ире Җиһанша турында менә абыең әйтте инде. Андый дөнья күреп, бөтенлек белән

торган кешеләрнең баласы да, билгеле, күркәм, инсафлы булырга тиеш. Йә, ни дисең, улым?

Зөфәр, иңбашын җыерып, сүз таба алмыйчарак торды:

— Ни диим? Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт! Ләкин бу мәсьәләдә эти-әнисенә карап кына хөкем итеп булмый ич! Ул кыз минем өчен, руслар әйтмешли, капчыктагы мәче бит әле. Күрмичә-нитмичә!

— Сөйләп бирдем ич инде: кыз — мировой, үзе шундый нәгызь!..

— Анысы тагын ничек була?

Зариф абзый куллары белән нидер ишарәләп күрсәтмәкче булган иде дә, әнисенә карап алгач, тыелып калды.

— Юк, шулай да әллә ничек кенә килеп чыга әле бу,—диде Зөфәр, ихтыярсыз елмаеп.— Борын заманның байбәтчәсен өйләндерергә җыенган шикелле...

Таибә абыстай, хәтере калып, улының сүзен бүлде:

— Берәү дә сине алай өйләндерергә җыенмый. Ә димләү ул ата-бабадан килгән йола. Кыз сайлаганда эти-әнисенә дә, нәсел-нәсәбенә дә караганнар борын акыллы кешеләр. Оясында ни — очканында шул, дип белми әйтмәгәннәр.

— Ярый, әни, үпкәләргә торма. Мин бит аларның берсенә дә күз йоммыйм. Тик кызны күрмичә торып, мин сезгә бернәрсә дә әйтә алмыйм.

— Алайса син кызны карап карарга ризасың? — диде Зариф, ашыгып.

— Ничек инде ул «карап карарга?» — диде Зөфәр, чыраен сытыбрак.— Сыер яки кәҗә түгелдер бит ул?.. Минемчә, танышып карарга кирәк. Анда да бик уңай җае чыкса гына...

— Май кап! — диде Зариф һәм әнисенә, дәшмә дигәндәй, күз кысып куйды.— Мин моны шундый итеп җайлармын, ничек танышканыңны үзең дә сизмичә калырсың, энекәш!

— Әлбәттә, Гамбәр туташ өчен дә бу шулай булырга тиеш!

Һәм Зөфәр: «Ярый, җитеп торыр бу хакта!» — диясе килгәндәй, кисәк кенә урыныннан торып, бакчага төшеп китте. Зариф аның артыннан кычкырып калды:

— Һи, туган, аны гына беләбез инде. Курыкма, бөтенесе шито-крыто булыр!

Зөфәр, бакча түренә узып, тәбәнәк кенә бер эскәмиягә утырды. Әйтергә кирәк, бу өйләнү турындагы сөйләшү аңа шактый авыр-ямьсез тәэсир итте. Ничектер, менә әнисе белән абыйсы аның үтә шәхси эшенә дорфа рәвештә

тыгылалар, аны ирексезлиләр кебек тоелды, һәм аңарда үзлегеннән диярлек каршы торасы, тыңлыйсы килмәү хисе уянгандай булды. Ләкин бу мондый очракларда тумыйча калмый торган, әмма иртәме-соңмы үтеп китәчәк вакытлы бер хис иде. Асылда исә Зөфәр бүгенге сөйләшүнең әһәмиятен дә, кирәклеген дә бик яхшы аңлый иде. Өйләнү — аның алдында торган зарури бер мәсьәлә ул. Аңардан качып булмаячак.

Бакча түрендә ялгызы гына утырып, бераз тынычлангач та ул ихтыярсыздан Гамбәр туташ турында уйлана башлады... Гамбәр туташ! Бу исемнең үзендә үк ниндидер хыялны котырта, күңелне тарта торган бер сихер бар кебек. Мондый исемле кыз чынлап та бик оригинальный булырга тиештер инде ул... Абыйсы да үтереп мактады бит: хур кызы кебек, диде, күзләре зур, керфекләре озын, диде, түбән генә карап тора, диде, аннары авызына сулар китереп: «Бик нәгызь»,— дип тә җибәрде. Нәрсә була икән ул... нәгызь? Бик җиткән, бик пешкән дип әйтүе булдымы инде, Хода белсен!..

Төпчек кенә кыз икән, музыкага да өйрәнгән икән. Бәлки, чынлап та гөлчәчәктәй гүзәл, нәфис, оялчан, назлы бер туташтыр ул, Гамбәр?! Юк, аңа игътибар итмичә һич мөмкин түгел.

Шулай ук әти-әнисе турындагы сүзләр дә игътибарга бик лаек. Торгсин, ювелирторг, алтын-көмеш — боларның берсен дә исәптән чыгарырга ярамый, әлбәттә. Һичшиксез, уйларга, чынлап уйларга кирәк бу көтелмәгән димләү турында. Ихтимал, табылырга торган бәхет шул үзедер инде...

Шулай уйлады, шулай хыялланды Зөфәр, һәм күңеленнән, Гамбәр, Гамбәр дип акрын гына кабатлап утырган чакта кинәт бик ачык булып, йөрәген сискәндереп, аның күз алдына Рәшидәсе килеп басты.

## XIII

Ул аны күптән күргәне юк иде инде. Соңгы тапкыр алар апрель ахырында — Рәшидә язгы чәчү өстендә концертлар биреп йөрер өчен филармония бригадасы белән авылларга чыгып китәр алдыннан очрашканнар иде. Хәзер июль уртасы, димәк, өч айга якын вакыт үтеп киткән. Рәшидә, билгеле, әллә кайчан ук кайткан булырга тиеш. Ә Зөфәр моңарчы аны табарга да, күрергә дә тырышып карамады. (Рәшидә исә соңгы вакытларда үзе башлап шалтыратмый иде инде.)

Шуны әйтергә кирәк, Зөфәр Рәшидәне үзе өчен лаек хатын дип тапмагач һәм аңа өйләнү дигән нәрсә күңелендә булмагач, ике арадагы мөнәсәбәт шулай акрынлап өзелер дигән өметтә йөри иде. Ул моны, билгеле, бик тели дә иде, шуңа күрә, күпме генә озак вакыт узмасын, ничек тә очрашудан, күрешүдән тыелырга тырыша иде. Ләкин шуның белән бергә ул аны һич оныта алмый иде, сагына иде һәм менә вакыт-вакыт, бөтен салкын исәпләрне бер читкә ташлап, тизрәк Рәшидәне табарга, аның белән бергә булырга ашкына иде.

Рәшидә Зөфәрнең болай бер ераклашып, бер якынаеп йөрүен ничектер сизеп бетерми иде. Иң элек ул үзе, еш кына гастрольләргә чыгып киткәнлектән, икешәр-өчәр ай югалып тора иде. Аннары очрашкан чакларда Зөфәр аны чын сагыну белән иркәли-сөя иде, ә озак вакыт күренмичә торуын эше-мәшәкате бик күп булу белән аңлата иде. Шулай итеп, Рәшидәнең күңелендә уяна башлаган бөтен шикләре, үпкәләре тарала да бетә иде. Ләкин шулай да яшь ханым соңгы вакытларда беркадәр үзгәрә төште; электәге кебек очрашу шатлыгыннан күбәләктәй очынып тормый ул, Зөфәрнең сөюләрен артык дәртләнмичә ничектер әчке бер тыелу белән кабул итә — гомумән, күңелендә гел борчып торган авыр уе бар шикелле, үзен шактый моңсу-басынкы тота иде. Зөфәр аңардагы бу үзгәрешне сизмичә калмады, әмма барыбер киселәсе сынык булгач, ул хакта борчылып та тормады.

Инде менә горизонтта Гамбәр туташ күренүгә, ул кинәт Рәшидәне исенә төшерде. Алай гына да түгел, яшь туташ юньләп күзенә дә чагылырга өлгермәс борын, каршысына, гүя аны каплап, бөтен сокландыргыч килбәте белән Рәшидәсе сүзсез-тын гына калкып чыкты. Бу хәлгә Зөфәр үзе дә гаҗәпләнә калды. Ләкин сәбәбен эзләп тормады, бары тизрәк аны күрәсе килде... Билгеле, салкын акыл белән уйлаганда Зөфәр моны теләмәскә, теләгән тәкъдирдә дә күрү-очрашудан һичшиксез тыелырга тиеш иде. Чөнки Гамбәр туташ белән танышырга торганда Рәшидәне күрү һәм сүнеп барган ялкынны яңадан көйрәтеп җибәрү аның өчен хәерлегә булмаячак иде. Әмма шуны сизсә дә, ул күрергә теләде, йөрәге белән генә түгел, хәтта акылы белән дә теләде, гүя менә Рәшидәне күрмичә торып, ул Гамбәрне дә дөрес аңламас, дөрес бәяли белмәс кебек иде.

Һәм кинәт туган бер тәвәккәллек белән ул филармониягә шалтыратып, Рәшидәне эзли башлады. Бары икенче көнне генә туры китереп, аның белән гадәтенчә җылы-

йомшак кына сөйләште һәм сәгать өчләрдә Ленин бакчасында очрашырга сүз куешты.

Ул көнне Зөфәр эшеннән бик иртә кузгалды. Кечкенә кабинетын бикләп алды да, ишек төбендә утырган секретарь-машинисткага үзенең точкаларда буласын, аннары шәһәргә кайбер эшләр белән китәсен, шуңа күрә бүген, ихтимал, кире әйләнеп килә алмавын әйтеп, чыгып китте.

Берничә сәүдә точкасында булып, андагы кешеләр белән сөйләшеп, тиешле киңәшләрен, боерыкларын биреп чыккач, ул ахырдан гына азык кибетенә кереп, аның мөдире аша үзенә бер шешә портвейн һәм бераз конфет, печенье кебек нәрсәләр төрдереп алды да, сәгать икеләр тирәсендә ОРС машинасына утырып, шәһәр үзәгенә китеп барды... Ни өчендер аны менә хәзер Рәшидә белән булачак очрашу беркадәр дулкынландыра иде. Сагынуы бик җиткәнгә күрәме, әллә бүгенге очрашуга аеруча бер әһәмият биргәнлектәнме, ул юл буенча шул хакта гына уйланып барды. Рәшидә бүген аның күзенә ничегрәк күренер, үзен ул ничегрәк тотар, аңа, Зөфәргә, ничегрәк карар? Күрешмәгәнгә шактый вакыт үтеп китте бит, ачуланмасмы, үпкәләмәсме икән?.. Тик менә очрашкач, Рәшидәне кая илтергә? Зөфәр моны уйлап-уйлап та хәл итә алмаган иде әле. Хәмит дустын кичә таба алмады, бүген дә эшкә барышлый иртән иртүк аңа керсә дә, туры китерә алмады — ялгызак егет өендә бөтенләй кунмаган булып чыкты. Ачкычын да калдырып китмәгән. Димәк, Рәшидәне бүген иләшкән урынга алып барып булмаячак. Ә каядыр алып барырга кирәк.

Кольцога килеп җиткәч, Зөфәр машинадан төште дә, шоферга кире кайтырга кушып, үзе җәяүләп кенә Ленин бакчасына таба менеп китте. Көннең нәкъ үзәге — бик эссе вакыты иде, таш стеналардан, тротуардан бөтенләй ут бөркелеп тора. Зөфәр күләгә яклап кына атласа да, бакчага җиткәнче тәмам әлсерәп, тирләп чыкты. Юк, мондый җәһәннәм эссесендә шәһәр таптап булмас, дип уйлады ул, пошынып... Чынлап та, кая алып барырга соң?.. Әлбәттә, ул, өйләнмәгән ялгыз егет, яратып йөргән кешесен үзенең иркен, бай йортына алып кайтса да әллә ни гаеп эш булмас иде. Ләкин аны өйгә алып кайту, бигрәк тә әнисе карчыкка күрсәтү — бу мәсьәләгә җитди төс бирү, ә яшь ханымны ни беләндер өметләндерү булып чыгачак. Юк, болар берсе дә ярамый иде, билгеле... Аннары ул, Зөфәр, гомумән Рәшидәгә кайда, ничек торуын да ачып бетерергә теләми иде. Гамбәр туташка күрсәтү мөмкин булыр иде, ә Рәшидәгә юк, ярамый әле... Бик четерекле,

идеалист хатын, әллә ни уйлавы мөмкин. Иң яхшысы — читтә, аулакта, күзгә-күз генә очрашу инде, әлбәттә.

Бакчага килеп кергәч ул, ерак китмичә генә, агач күләгәсендәге бер эскәмиягә барып утырды. Сәгатенә карады. Өч тулырга унбиш минут вакыт бар әле. Әгәр Рәшидә филармониядән туры гына килсә, әнә шул Куйбышев урамына караган капкадан килеп керергә тиеш. Тик соңга гына калмасын иде. Шәһәрдә Зөфәрне белүчеләр күп, йә берәрсе очрап, янында туктала башлар. Үткән-сүткәннәргә йөзен бик үк күрсәтмәс өчен ул, тезләренә таянып, иелебрәк утырды. Шул ук вакытта аның теге капкадан да күзен бер дә аласы килми иде. Кинәт борчылып уйлап алды: әгәр шуннан Рәшидә, берәр сәбәп аркасында, килмичә калса, нишләр ул? Андый хәл була гына күрмәсен, югыйсә яңадан шалтыратырга, эзләргә, икенче бер вакыт билгеләргә туры киләчәк.

Юк, әнә ул үзе түгелме соң?.. Әйе, шул ич, шул, Рәшидә!.. Өстендә кыска җиңле, ачык изүле юка гына күлмәк, башында чуар ефәк косынка, аягында кызыл чүәк — үсмер кыздай кулындагы сумкасын селкә-селкә, вак-вак атлап, җиңел генә килә ул!

Зөфәр аны урыныннан торып каршы алды. Кызның сузган кулын кысып күреште дә, җибәрмичә сак кына тотып, янына утыртты һәм бер сүз әйтмәстән бик текәлеп, аның күзләренә, йөзенә, ачык муенына карый башлады. Рәшидәнең йөзе дә, муены да, ялангач беләкләре дә тигез генә булып шактый нык каралган иде — авыллар арасында озак йөреп кайтканга күрәдер инде бу... Хәтта ул ничектер ябыга да төшкән кебек иде. Тик шуңарданмы, әллә тар, юка күлмәк кигәнлектәнме, түшләре генә тагы да тулыланыбрак киткән төсле иде.

Зөфәрнең болай бер сүз дәшмичә, юри тикшереп чыккандай, бик сынап-текәлеп каравыннан Рәшидә уңайсызланып бер кызарды, бер елмайды, ахырда түзмәде — учы белән аның күзен каплагандай итте:

— Карамагыз инде ул хәтле... Миңа уңайсыз ич!

— Карыйм... Карамыйча булдыра алмыйм!

— Нишләп алай?

— Сагындым! — диде Зөфәр, тирән-татлы сулап.

Рәшидә кискен генә башын чайкады:

— Юк, ышанмыйм мин моңа!

— Ни өчен?

— Ни өчен дип... үзегез дә беләсездер инде... Сагынган кеше айлар буенча югалып тормый бит.

— Их, Рәшидә бәгырем! — диде Зөфәр, авыр көрсенеп.— Гаепләргә ашыкма син, менә сөйләрмен, үзең дә

аңларсың!.. Ә хәзер безгә, вакытны әрәм итмичә генә, берәр җиргә бару турында уйлашырга кирәк.

— Нигә, шушында гына сөйләшеп утырсак ярамыймыни? — диде Рәшидә, ни өчендер Зөфәрдән күзләрен яшереп.

— Куйсана, Рәшидә, әллә нидә бер очрашып, моның кебек кеше йөреп торган җирдә ничек утырмак кирәк!.. Синең вакытың бардыр бит?

Рәшидә, туры җавап бирергә кыенсынган төсле, иңбашын җыерып куйды:

— Мәсьәлә вакытта түгел.

— Ә нидә соң?

Рәшидә башын тагы да ия төште, ә Зөфәр аның каралган ябык кулын зур учы белән йомшак кына сыйпап торды:

— Йә? — диде ул, әкрен-сак кына.

Рәшидәнең нечкә кашлары тартышып куйды, йөзе сытылыбрак киткәндәй булды:

— Беләсеңме, нигәдер күңелем тартмый, Зөфәр! — диде ул, ниһаять, ниндидер бер пошыну белән.— Шушында гына сөйләшеп утырыйк инде...

— Юк, булмый, акыллым! — диде Зөфәр, шунда ук аның газаплы икеләнүен сизеп.— Без монда сөйләшеп тә утыра алмыйбыз... Ярамый миңа монда... Аңла!.. Китик, сөеклем!

— Ә... кая соң?

Яшен тизлеге белән Зөфәрнең күңеленә гаҗәеп шәп бер уй килде:

— Беләсеңме кая? Идел аръягына. Киттекме? Минем бүген синең белән рәхәтләнеп бер йөрисем, су буенда, яланда буласым килә. Бәйрәм итәсем килә. Кич булганчы, төн узганчы, күпме теләсәң, шулкадәр! Мин бит сине сагынып үлә яздым, ышанасыңмы?.. Киттек!..

Һәм ул Рәшидәнең ризалыгын да көтмичә, көчләп дигәндәй, аны кулыннан тартып торгызды. Рәшидә карыша алмады, юк, карыша алмый иде инде ул Зөфәргә... Бигрәк тә Зөфәрнең бүгенгедәй чын ихластан якын итүен, бу хәтле кадерләргә, назларга, сөяргә ашкынып торуын ул бик сирәк күрә иде. Һәм менә төрле шикләрдән, кимсенүдән моңарчы газапланып йөргән, инде бүгенге очрашуда үзен салкынрак, тыйнаграк тотарга уйлап килгән Рәшидәбез, эченнән генә сыкранып булса да, аңа буйсынды, аңа иярде.

Бакчадан чыгып, аз гына киткәч тә Зөфәр узып баручы бер кара машинаны туктатты. Шофер белән бер-ике авыз сүз сөйләшү җитте — алар, шуңа утырып, Устьега

таба китеп тә бардылар. Икесе дә бераз дулкынланганнар иде, һәркайсы эченнән генә үзенекен уйлый иде, шуңадыр инде, юл буенча сөйләшмичә бардылар, аннары шофер татар булып чыкмасын дип тә шикләнделәр, ахрысы.

Устьега барып төшкәч, Зөфәр әйтте:

— Карале, Рәшидә, безгә капкаларга да тегесен-монысын алырга кирәк булыр бит. Югыйсә ачыгып бетәрбез. Минем менә бу төргәктә вак-төяк нәрсә бар барын да, ул гына җитмәс. Әйдә, караштырыйк әле, берәр нәрсә тапмабызмы икән?

Алар азык-төлек сата торган лапаска таба киттеләр. Анда кыяр, помидор, йомырка алдылар. Зөфәр водниклар кибетенә кереп, аннан ярты кирпеч икмәк белән бер ит консервысы да алып чыкты. (Зөфәргә үз эшеннән канәгать булмыйча һич мөмкин түгел, чөнки кая гына кермәсен, аны беләләр, ни генә сорамасын, шуны биреп чыгаралар иде...) Рәшидәнең сумкасында сеткасы бар икән, шуңа барысын әйбәтләп салдылар да яр буена юнәлделәр.

Халыкны Маркиз атавына кечкенә буксир сөйрәп йөрткән бердәнбер паром ташый иде. Паром яңарак кына аргы якка кузгалып киткән булып чыкты. Аны көтеп, вакыт әрәм итмәс өчен, Зөфәр берәүнең моторлы көймәсен яллады. Бу иске генә, озын гына, буялмаган бер көймә иде, нәкъ уртасында Нух заманыннан калган, майга-мазутка катып беткән чуен моторы тора иде. Шуның койрыгына Зөфәр белән Рәшидә сакланып кына кереп утырдылар. Көймәнең хуҗасы — ялангач өстенә брезент чалбар гына кигән яшь егет моторын терелтеп җибәрергә азаплана башлады: ниндидер бер тәгәрмәченә каеш бау урап, шуны бөтен көченә кинәт кенә бер тартты, ике тартты, өч тартты, шуннан соң гына мотор төтен атып төчкерергә, калтырарга, зырылдарга тотынды... Ниһаять, кузгалып киттеләр. Һәм көймә тип-тигез су өстеннән, чуртан шикелле, борынын сузып бара башлагач, Зөфәр белән Рәшидәнең дә кәефләре ничектер бердән күтәрелеп, җиңеләеп, яктырып киткәндәй булды. Аларга рәхәт, хозур иде. Рәшидә, нәкъ менә яңарак кына кимсенеп елаган балага сөенеч-шатлык кайткан төсле, бөтен күңеле белән аз гына моңсу, әмма рәхәт-куанычлы чын юану татый иде — Ходаем, янәшәңдә генә сине яраткан кешең, аның җылы игътибары, бу якты, тыныч Идел, ниһаять, шушы әкәмәт иләмсез көймә — барысы, барысы да аңа бик тансык, кадерле түгелмени соң!.. Ә Зөфәрнең кәефен әйтеп торасы да юк; аеруча ул, юлга чыкканнан

башлап, гел уңышка гына очрап торуларына эченнән бик сөенеп бара иде. Юк, бу сәфәр, аныңча, бик әйбәт, күңелле булып бетәргә тиеш.

Маркизның эссе, ак комында кызынып ятучы яшь-җилкенчәкләр шактый күп иде. Шуңар күрә бу тирәдә тукталып тормыйча, алар атауның түренә үк уздылар. Шактый ерак китеп, куе таллыклар аша узып, ниһаять, бер ялгыз тирәк төбендә тукталдылар. Бик тыныч, аулак урын иде бу; кечкенә ачыклыкның тирә-ягы таллык, утырыр җире сирәк кенә үлән үскән такыр комлык — менә шунда, тирәк күләгәсенә газеталар җәеп, урнаштылар. Тик монда шактый бөркү иде, Зөфәр утыргач та кепкасын салып ташлады, бил каешын чиште, ак күлмәгенең кыек якасын чишеп җибәрде. Ул Рәшидәгә дә бераз «бушанырга» кушты. Рәшидә бары күлмәк путасын гына ычкындырды. Шуннан соң Зөфәр, Рәшидәнең тарсынып маташуын берьюлы бетерергә теләп булса кирәк, сүзсез генә аны иңбашыннан кочаклап алды да, башын артка каера биреп, иреннәреннән үбәргә тотынды. Рәшидә башта каршылык күрсәтмәде, тик бераздан гына Зөфәрне үзеннән этәреп, тураеп утырды. Ул нигәдер бик кызарды, күзләре дә дымланып киткәндәй булды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Аннары, шулай ук сүзсез генә, алып килгән төргәкләрен чишеп, азык-төлекләрен уртага таратып салдылар. Бары Зөфәр портвейн шешәсен чыгаргач кына Рәшидә көлемсерәп әйтеп куйды:

— Син эчми торган кеше бит, ничек әле бу алай булды?

— Их, гүзәлем, сахрага чыгып та эчмәсәң, җир йотар!..— диде Зөфәр, егетләнеп; аның бүген ваемсыз-шат буласы һәм Рәшидәне дә шул ипкә көйлисе килә иде.— Синең хакка — бик рәхәтләнеп! Тик менә нәрсәгә салып эчәбез, вот проблема!

Алар, бер-берсенә карап, көлешеп алдылар.

— Безнең әле консервыны ачарга пычагыбыз да юк,— диде Рәшидә.

— Ә анысы бездә бар,— диде Зөфәр һәм чалбарының арткы кесәсеннән сөяк саплы, әллә ничә җәпле, өр-яңа пәке чыгарып сузды.

— Һу, болай булгач, барысын да эшли алабыз,— диде Рәшидә, ихтыярсыздан балаларча куанып.— Ачып бир әле миңа... Хәзер мин «бокал» ясыйм.

Ул арадан зуррак кыярны сайлап алды да, шуның бер башын кисеп, эчен чокып чыгарды.

— Менә бу сиңа булыр!

— Ә үзеңә?

— Хәзер үземә дә ясыйм! — Һәм җитез генә икенче кечерәк кыярның да эчен чокып ташлады.— Тик утыртып кына булмый,— диде ул, көлеп.

— Ничево, без «бокалларны» кулдан төшермәбез!

Рәшидә калган кыярларны, помидорларны, икмәкне турады, бер-ике йомырканы әрчеп, Зөфәр алдына куйды. Зөфәр исә, аның ипле-өлгер эшләвенә соклангандай, бераз карап торды да пичәтле шешәдән «бокалларга» портвейн салды.

— Йә, нәрсә өчен эчәбез, уңганым? — диде ул, «бокалын» күтәреп.

Рәшидә, нечкә кашларын җыера төшеп, аз гына уйланып торды.

— Нәрсә өченме?.. Әйдә, күңелләрнең шушы аяз күк төсле саф, керсез булуы өчен эчик!

— Һо, син бик биеккә сикердең, җанкисәгем! — диде Зөфәр, көлеп.— Ну что ж, күккә дә менәргә була. Ә шулай да мин, практичный кеше буларак, башта синең саулыкка эчәргә телим. Ярыймы?

— Ихтыярың. Рәхмәт!

Кыярларны чәкештерделәр дә эчеп җибәрделәр. Аннары бик тәмләп ашарга тотындылар. Ачыкканнар да икән, бер дә бер-берсеннән тарсынып тормадылар. Бераздан Зөфәр тагын «бокалларны» тутырды. Эчтеләр. Тагын бертын ашадылар. Эчми эчкән Зөфәргә җитә калды — тамырлары буйлап рәхәт җылы таралды, йөзе аз гына алсуланып кызарды, күзләре чак кына томанлана төште, ә башында, әйтерсең төрле төстәге күбәләкләр очкаларга тотынды — әллә нинди гаҗәп матур, акыллы уйлар килә башлады. Аңа бик рәхәт, бик күңелле иде. Каршысындагы Рәшидәгә — аның каралган йөзенә, уңа төшкән кашларына, кайтарылыбрак торган керфекләренә, ялангач беләкләренә, сузып утырган төз аякларына, кыскасы, бөтен-бөтен җиренә — ул сөеп, кабынып һәм бәяләп карый иде. Йә, бу беткәнче бирелеп, онытылып сөймәслек хатын түгелмени? Нәфис, сылу, ягымлы, әрсез түгел, дорфа түгел, аз гына үпкәләүчән, аз гына киреләнүчән, әмма иркә, назлы, татлы, шайтан алгыры! Аннары ул бөтен барлыгы белән аныкы бит, хуҗа бит ул аңа! Бер сүзенә, бер теләгенә дә каршы килә алмый бит ул аның!.. Йә, рәхәт-бәхеттә йөзәр өчен тагын ни кирәк?

— Ә хәзер күккә дә ашарга була! — диде Зөфәр, өченче тапкыр «бокалын» сузып.

Рәшидә каш астыннан күз сирпеп кенә аңа карады, уйчан-сөйкемле генә елмайды, ләкин сүз әйтмичә башын

гына кагып куйды. Кыярына да ни өчендер иренен генә тидереп алды. Зөфәр аның янына шуышыбрак кырын ятты һәм беләгеннән сыйпап, пошынып сорады:

— Сөеклем, нигә син бүген тын утырасың, сөйләмисең бер дә?

— Синнән көтәм әле мин,— диде Рәшидә аңа.

Зөфәр белә аның нәрсә көткәнен. Акланувы читен, билгеле, ләкин бүгенге рәхәтлек хакына ялганны чын итеп, үзең дә шуңа ихластан ышанып сөйләргә мөмкин иде. Һәм ул кырын яткан җиреннән Рәшидәнең әле беләгеннән, әле аркасыннан йомшак кына сыйпап, әкренкиеренке тавыш белән үзенең аны, Рәшидәне, никадәр сагынуын, гел генә аны уйлап йөрүен, тик соңгы атналарда эшенең бик күп булуын, төрле мәшәкать-борчулар кичерүен, менә яңарак кына бераз шулардан бушануын һәм бушагач та тизрәк аны күрергә ашкынуын, бүгенге очрашудан әйтеп бетергесез шат, бәхетле булуын сөйләп бирде. Әлбәттә, ул нинди эш, нинди мәшәкатьләргә таруын җентекләп сөйләп тормады — бу кадәресе, аныңча, кирәксез, артык иде. Рәшидә исә бүтән хатыннар кебек төпченә белми иде, кешедән шикләнергә, кешенең ялганын тотарга яратмый иде. Бигрәк тә яраткан-якын кешесенә аның бик ышанасы килә иде. Менә хәзер дә ул Зөфәрнең һәр сүзенә ышанып утырды, аның өч ай буена югалып торуын бүтән бер сәбәптән булыр дип күңеленә дә китермәде. Ул нәкъ элеккечә, балаларча беркатлылык белән, Зөфәр мине ярата бит дип уйлады, шуңа эченнән генә куанды һәм йөрәгендә күптән төерләнеп торган сызлавыгы бераз кими төшкән кебек булды... Ә нинди сызлавык соң бу? Хикмәт шунда, Зөфәр мине ярата дип ышанса да, ул аның ни өчен яратуын, нинди максат белән, озаккамы, әллә вакытлы гынамы яратып йөрүен белми иде, һәм бу билгесезлек аны бик борчый, бик уйландыра иде. Айлар буенча күрешмичә тору нәтиҗәсендә бу уйлану-борчылулар аның йөрәгендә әнә шулай сызлавыклы бер төер булып укмаша иде.

Ләкин менә очрашкач, ул Зөфәрнең җылы, йомшак мөгамәләсенә, гүя ихластан сөйләгән сүзләренә эри дә китә һәм аның дәртләнеп назлавына, аның теләгенә бер дә каршы тора алмый иде. Дөрес, соңыннан ул еш кына бу йомшаклыгы өчен әрнеп үкенә, бик кимсенә, хәтта үз-үзеннән нәфрәтләнеп тә куя иде. Хатын йөрәге белән ул, мондый йомшаклыгым өчен ир кеше миннән бер бизәр, дип сизенә һәм шуңардан бик курка да иде. Ләкин нәкъ менә хатын булганга күрә дә ул яраткан кешесенең са-

гынуын аңларга, тоярга, аңа карышмаска, аңа буйсынырга мәҗбүр иде.

Рәшидә беләкләре өстенә башын салып, күзләрен йомып, бик озак хәрәкәтсез чалкан ятып торды. Йомык күзләрендә ерак нурлы күкнең яшькелт җылы яктысы кытыкландырып йөзә, акылы оеган, күңеле бушап калган, бөтен тәненә хәлсез-рәхәт талчыгу җәелгән иде. Зөфәр дә тынычланып калган иде, ләкин бераз хәл алып ятканнан соң ул, терсәгенә таянып, күтәрелеп Рәшидәгә карады — аның бу кадәр хәрәкәтсез-тын ятуы аңа әллә ничек бик сәер тоела башлады. Шулай дәшәргә дә, орынырга да кыймыйча ул карап торган чакта, Рәшидәнең йомык күзләреннән ике генә бөртек яшь сытылып чыкты.

— Ни булды сиңа, кошчыгым? — диде Зөфәр, пошынып, һәм бармак бите белән сак кына аның яшьләрен сөртеп алды.

Рәшидә озак көттереп, йөзен читкә борып, көчкә генә җавап бирде:

— Авыр миңа! — Һәм тавышы аның өзелә язып куйды.

— Гаҗәп! — диде Зөфәр, көләргә итеп.— Нидән әле ул алай кинәт авыр булып китте?

Рәшидә тагын озак кына дәшмичә ятып, ниһаять, күзләрен ачты. Һәм бу яшьле күзләр салкын бер ятсыну белән Зөфәргә төбәлделәр.

— Кинәт түгел бу... күптән миңа авыр инде, тик син генә күрмисең! — Аның иреннәре калтыранып куйды, ләкин тавышы сынмады.— Кем син, Зөфәр, кем? — диде ул, кинәт тирән әрнү белән өзгәләнеп.— Мин бит сине бөтенләй белмим... Менә өч елдан артык вакыт узды, ә мин берни дә белмим, син сөйләмисең, яшерәсең, качасың, син минем белән дә һич кызыксынмыйсың, сорашмыйсың... Нәфесеңне басар өчен генә мине әллә нидә бер эзләп табасыңмыни, яратуың бары шуның өчен генәмени?.. Ходаем, бары шуның өчен генәмени?..

Һәм кисәк кенә аркасы белән борылды да, йөзен куллары белән каплап, еш-еш калтыранып үкси дә башлады. Зөфәр бер мәлгә аптырап, югалып калды: Рәшидә үксеп елый! Шат, ваемсыз, иркә, кочагын-назын аңардан һич кызганмаган һәм моңарчы шуңа үкенүен һич сиздермәгән Рәшидә кинәт, мәсхәрәләнгән яшь кыздай, бөгелеп-калтыранып үкси, җитмәсә, нинди сүзләр әйтеп! Юк, һич тә көтмәгән иде ул мондый хәлне... Беренче минутта ни әйтергә, нишләргә белмичә аптырап торды, курка калды, аннары Рәшидәнең иңбашыннан кочып, чәченнән сыйпап ничек тә юатырга тырышты:

— Куй, Рәшидә, куй, акыллым! Ярамый болай, бетермә үзеңне, тукта! — Ул аның кулларын көчләп йөзеннән аерды, башын үзенә таба борды, күкрәгенә кысты.— Йә инде, йә, бала булма, тынычлан! Гаеп миндә икән, кичер! Только җылама, зинһар, җылама, яме!

Рәшидә аның күкрәгенә капланып тыела алмыйча тагын күпмедер үксегәннән соң, ниһаять, акрынлап тынычлана башлады, ә бераздан бөтенләй тынып калды. Шул хәлдә аз гына онытылып торганнан соң ул пышылдап кына сорады:

— Сумкамны алып бир.

Зөфәр читтә яткан сумканы алып бирде. Рәшидә шуннан кечкенә зәңгәр кулъяулыгын алып, битен, күзләрен сөртте. Аннары торып утырды, күлмәгенең алгы төймәләрен каптырды.

Бу минутта Зөфәр тәмам айнып, исен-акылын җыеп өлгергән иде инде. Башта ул Рәшидәне чынлап кызгангандай булды, ә хәзер менә аңа бераз шелтә белдерәсе килде: ярыймы соң болай урынсызга кешенең котын алып, истерикага төшеп еларга? Ни өчен бу? Алдаган яки көчләгән что ли ул аны?

Әйе, ул, Зөфәр, үзен Рәшидә алдында нәрсә өчен дә булса гаепле, күпме дә булса бурычлы итеп санамый иде. Аннары, гомумән, ул хатын-кызның зарын, үпкәсен тыңларга яратмый иде. Мондый «ирекле» бәйләнештә булган чакта андый претензияләрне урынсыз, артык нәрсә дип саный иде.

Ләкин шулай да ул шелтәсен белдерергә ашыкмады; чөнки, беренчедән, сүзне тирәнгә җибәрәсе килмәде, икенчедән, ничек кенә булмасын, Рәшидәнең күз яшьләрендә хаклык барын сизмичә калмады. Ихтыярсыз вөҗданы аның бераз кузгалып, борчылып куйды. Ихтыярсыз үзен беркадәр аклыйсы, ә Рәшидәне юатасы килеп китте.

— Тынычландыңмы инде? — диде ул, Рәшидәнең кулын ике учына алып.— Менә ярый, менә бик әйбәт, мин бик шат...— Ул аз гына тынып торды да, көрсенеп, сөйләнергә тотынды.— Әлеге бер сүз инде, сөеклем! Эш, мәшәкать, төрле борчылулар, шуның аркасында үзеңне дә, иң яраткан кешеңне дә онытып җибәрәсең... Просто баш-күз әйләнеп бетә. Эшем минем шундый инде. Ләкин мин моны сиңа акланыр өчен генә әйтмим, дустым, әгәр минем гаебем бар икән, син кичер мине, яме!

— Ярый, үтте инде,— диде Рәшидә, тирән-хәсрәтле сулап.

Зөфәрнең сүзне тизрәк икенчегә борасы килде:

— Әйт әле,— диде ул, соңга калган кайгыртучанлык

белән,— синең театрга күчүең ничегрәк тора, күчәсеңме инде, алалармы?

Рәшидәгә хәзер үзе хакында ни дә булса сөйләү авыр иде. Хәтта Зөфәр аның хәле белән кызыксынамы-юкмы, хәзер инде барыбер иде. Күз яшьләре белән барысы да — үпкәсе дә, хәсрәте дә, әрнүе дә — чыкты да бетте. Күңелендә бары көзге кыр өстедәй тын, моңсу бушлык кына торып калды. Уйлыйсы да, сөйлисе дә, хәтта кузгаласы да килми иде. Шулай да Зөфәрнең соравын җавапсыз калдыруны килештермәде һәм үзен көчләбрәк булса да акрын гына сөйләргә тотынды.

— Юк шул әле,— диде ул, башын иеп кенә.— Йөреп карадым. Министерствога да бардым, театр җитәкчеләренә дә кердем, ләкин берсеннән дә ачык кына җавап ишетмәдем. Директор: уйлап карарбыз, ди, баш режиссер: сезнең амплуа бездә җитәрлек, танылган артистkaларга да эш юк әле, ди. Шул ук вакытта, сезнең данныйларыгыз миңа ошый, ди, бәлки киләчәктә берәр җаен табарбыз, ди... Менә шулай йөртәләр. Мин ни, ялына белмим, протекция эзләмим, кирәк кешегә ярарга тырышмыйм. Бәлки берәрсе миннән шуны көтәдер... Ә мин... ә мин... бервакытта да...— һәм ул сүзен әйтеп бетерә алмады.

Зөфәр Рәшидәнең бөгелеп, катып калган аркасына карап, аның елап җибәрүдән никадәр зур көч белән тыелып утыруын ачык сизде. Шуңа күрә дәшмәде, кагылмады.

Инде кояш баеган иде, агачлар арасына кичке зәңгәрсу караңгылык акрын гына иңә башлаган иде. Алар, ниһаять, урыннарыннан тордылар. Өс-башларын рәтләделәр. Рәшидә, урыныбыз чүпләнеп калмасын дип, газеталарны җыеп алды, азык-төлек калдыкларын җыештырып, агач төбенә салды: «Төнлә берәр җәнлек килеп ашар әле»,—диде ул, шуңа алдан ук сөенгәндәй.

Алар яр буендагы басмага килеп җиткәндә, караңгы тәмам төшеп өлгерде. Соңгы паром киткән иде инде. Зөфәр ары барып, бире килеп шактый вакыт көймә эзләп йөрде. Ахырда бер балыкчы картны очратып, шуның белән бик үтенеп сөйләшкәч кенә, карт боларны шәһәр ягына чыгарып куярга риза булды. Ишкәкле тар көймәгә чайкала-чайкала кереп утырдылар һәм пристань утларына карап кузгалып киттеләр.

...Төн гаҗәеп бер төн иде. Әйтерсең бөтен җир өсте йомшак-калын кара бәрхеткә төренгән — шундый караңгы, шундый җылы һәм шундый тын иде ул! Һични күренми, һични селкенми, су салкыны да сизелми, бары

ишкәкләрнең тигез-салмак чапылдап алуы гына ишетелә иде. Көймә, күзгә күренмәс дегеттәй кара суны авыр ерып, акрын гына бара шикелле, ләкин каршы якка бер дә якынаймый төсле иде. Әллә ничек менә җир дә, кешеләр дә моннан бик-бик еракта кебек, һәм аларга барып җиткәнче бик күп вакыт үтәр кебек иде. Әмма алар кайдадыр бар, алар сизелә, шуңа күрә куркыныч түгел, шомлы түгел иде.

Бераз киткәч тә көймәнең түр очында утырган һәм кулын җылы суга тыгып барган Рәшидә, гүя үзе өчен генә, тавышын көчәйтмичә тыелыбрак, ләкин гаҗәп тирән бер моң белән җырлый башлады:

Ялан да гына җирләрдән болан килә, Зөлхиҗҗә,
Уйсу гына җирләрдән ай үтәм дип, Зөлхиҗҗә,
Төн уртасы җиткәч, бер кыз елый, Зөлхиҗҗә,
Яшь гомерем заяга, ай, үтә дип, Зөлхиҗҗә.

Юк, бу гади җырлау гына түгел иде, бу гүя йөрәгенең иң нечкә, иң сизгер-моңлы кылларына акрын гына чиртеп уйнау иде... Һәм каршысында утырган Зөфәр аны таңга калып тыңлады. Ул кузгалырга да, дәшәргә дә курыкты, бары аның менә шулай онытылып, өзелеп-өзелеп җырлавын гына көтте. Рәшидә җыры аны исертеп, сихерләп кенә калмады, ә ничектер менә йөрәген урыныннан кузгатты, сызландырды, җан тынычлыгын алды. Һәм исе китеп уйлады ул: нинди кодрәтле талант, нинди саф, нечкә күңел, нинди якты, кешелекле хатын бу Рәшидә!.. Йә, шуны ташла, шуны югалт, имеш!.. Мөмкинме соң бу?.. Шушындый алтын бәясенә торырлык хатынның сөелергә, бәхетле булырга, үзенең асыл теләкләренә ирешергә хакы юкмыни?

Ә бит ул, Зөфәр, теләсә аңа ярдәм итә ала, аны бәхетле итә ала. Иң элек аңа әнә шул театр җитәкчеләре белән бер сөйләшү җитә, һәм Рәшидә үзенең күптән ашкынган сәхнәсенә менәчәк. Чөнки Зөфәрнең үтенечен кире какмаячаклар, чөнки Зөфәр сугыш елларында театрга шактый күп ярдәм итте, һәм хәзер дә ул анысын-монысын табып бирүдә аларга бик кирәк кеше.

Менә хәзер үк аның Рәшидәне бер-ике генә сүз белән булса да юатасы, өметләндерәсе килде, ләкин... ләкин сак булырга өйрәнгән акылы аңа ашыгырга кушмады. Вөҗданын тынычландырыр өчен ул, нигә алдан ук әйтеп куярга, эшлим дигәндә моны бит Рәшидәнең үзенә әйтмичә генә дә эшләргә мөмкин ләбаса, дип уйлап азапланды.

Ә Рәшидә җылы-йомшак төн эченнән үзалдына һаман акрын гына җырлап барды. Гүя һичкемгә зарланмыйча,

үпкәлмичә генә ул үзенең ялгызлыгын җырлый иде. Шунлыктан ахры кызгандыру хисен ничектер уятмыйча гына тирәнтен сыкрата, уйландыра, борчый иде аның җыры... Зөфәр хәтта үз хәлен бераз җиңеләйтер өчен Гамбәр туташны исенә төшереп, аны күз алдына китерергә тырышып карады, әмма көн яктысында йолдыз кабына алмаган шикелле, Рәшидә белән янәшә билгесез туташ та һич туа, күренә алмады.

Ахырда алар пристань ярына килеп җиттеләр. Көймәдән төштеләр, ярга менделәр һәм шалдыр-шолдыр селкенеп йөргән трамвайга утырып, шәһәргә кайтып киттеләр.

Кольцога җиткәч, Зөфәр, гадәтенә каршы, Рәшидәне өенә чаклы озата барды. Һәм, гадәтенә каршы, якын көннәрдә тагын шалтыратырга вәгъдә биреп, ханымны үбеп, кулын кысып аерылышты. Рәшидә өч катлы иске таш йортның астындагы капкадан, башын иеп, сүзсез генә караңгы ишегалдына кереп китте.

## XIV

Бу соңгы атнада Зөфәргә вакыйгаларның төрлесен — кечкенәсен-зурысын, күңеллесен-ямьсезен кичерергә туры килде. Тормыш шулай бит ул, кайчак тыныч кына аккан җиреннән, бусагалар өстенә барып менгәндәй, бәргәләнеп-суккаланып каядыр ашыга башлый. Һәм күпмедер ара котырып чапканнан соң, яңадан иске юлына төшеп, элеккечә тыныч-салмак кына агарга тотына... Тормыш шуның белән кызыклы да ул!

...Беркөнне Зөфәр өенә кайтып керсә, коридорда сеңелесе Хөршид елап утыра. Бу ни хәл?.. Хөршиднең болай елавын аңа бик сирәк күрергә туры килә иде.

— Ни булды сиңа? — диде Зөфәр, аның янына тукталып.

Хөршид дәшмәде, тик арык иңбашларын калтыратып елавын гына белде.

— Ник дәшмисең? Берәр җирең авыртамы, әллә берәрсе тидеме, йә?

Кыз абыйсының соңгы сүзләрен ишеткәч, тагы да катырак еларга тотынды. Зөфәр аның өстенә бераз карап торды, иелеп башыннан сыйпамакчы булды, ләкин кыз «тимә!» дигәндәй, кисәк кенә иңбашын сикертеп куйды.

— Менә юләр! — диде Зөфәр, аптырагач, аннары өйгә кереп китте.

Өйдә Таибә абыстай да, кемгәдер нәрсә өчендер бик хәтере калгандай, турсаеп, сөремен коеп йөри иде.

— Хөршидкә ни булган, ник елый? — диде Зөфәр, керү белән.

— Ахмак булганга күрә! — диде Таибә абыстай, кырт кисеп кенә.

— Юк, шулай да?

Зөфәрнең басып соравына абыстайның ачуы килде булса кирәк, бераз дәшми йөрде, аннары гасабилануын яшерә алмыйча өзеп-өзеп кенә сөйләп бирде. Эш болай булган икән: Хөршид янына әлеге шул күршедәге инвалид кызы Люся кергән. Ахирәт, янәсе!.. Китапларына төртелеп кенә утырсалар, бер хәер иде, юк, утыралармы соң! Безнең Хөршид, тиле, йокы бүлмәсенә тегене алып кергән дә, зур шифоньерны ачып, кием-салымнарын күрсәтә башлаган. Бер дә киелмәгән өр-яңа туфлиләрен Люсяның тузанлы аякларына кидереп караган... Моны күреп алгач, Таибә абыстай түзмәгән инде, орышып, бүлмәдән куып чыгарган үзләрен... Шулай итмичә ярыймы соң!.. Ә теге пумала баш Люся, үзенә күрә түгел, чынлап үпкәләгән булып, бөтенләй үк чыгып киткән... Китсен, алдыннан арты чибәррәк!.. Ә безнең Хөршид шуңа җенләнеп, әнә баядан бирле коридорда елап утыра. Җитмәсә, әнисенә авыр, каты сүзләр әйтеп бетергән: имештер, бездән кешеләр кача, безгә берәү дә керми, имеш, аңа бу өйдә ямь дә юк, кызык та юк, имеш, без аңардан иптәшләрен качырып бетерәбез... Кара син аны, явызны, бөтенләй шайтан коткысына бирелеп бара бит!

— Их, әни, ялгыш эшләгәнсең, ялгыш! — диде Зөфәр, чын-чыннан ачынып.

Таибә абыстайның гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнеп китте:

— Ничек инде ул ялгыш? Нәрсәсе ялгыш? Өеңне актарсалар да дәшми торыргамыни?

— Юк, иплән кенә кирәк иде, каты бәрелмичә генә...

— Ярар, янарал кызы түгел әле,— диде Таибә абыстай, нәфрәт белән кулын селтәп.— Олы башым белән шул өтекнең хәтерен саклап торыйм ди тагын...

— Әх, аңламыйсың, әни!

— Аңламыйсың? Ачуыңнан үләрсең! Син бик аңласаң, әнә сеңелеңә нык кына әйтеп куй: җыен ач күзгә, юмартланып, эчке дөньясын ачарга тормасын. Өйнең серен саклый белсен. Боездә ни булмас. Болай да көнчеләрдән көн юк.

— Менә шуңа күрә дә кеше белән сак булырга кирәк, әни! — диде Зөфәр, ничек тә сабырлыгын җуймаска ты-

рышып.— Без бу урында яңа кешеләр, барысы да безгә сынап карыйлар, шулай булгач, күршеләргә ачыграк, йомшаграк тору безнең үзебез өчен кирәк ләбаса!

— Һай, син бик акыллысың инде, үтә акыллысың! Әниеңне генә өйрәтәсең калды... Әниең бит кеше дә күрмәгән, күршеләр белән дә яшәмәгән! Вәт син, ә!.. Кем өчен диген, бер исерекнең ыштансыз кызчыгы өчен бит, йа Рабби!

Таибә абыстай бу сүзләрен чын рәнҗү белән ярсып әйтеп ташлады. Зөфәргә моны ишетү бик авыр булды... Кайтарып, аның, үзе төсле, каты итеп җавап бирергә уйлаган иде дә, ничектер тыелып калды: әни бит! Һәм кисәк кенә борылды да үз бүлмәсенә кереп китте.

Озак тынычлана алмады ул, бүлмәсендә ишекле-түрле һаман йөреп торды. Кирәк бит, кайтып керүенә шундый мәгънәсез скандал!.. Әнисенә дә, сеңелесенә дә аның чынлап ачуы килде... Дөрес, әнисе үзенчә хаклы да иде — өйдә ул хуҗа, ул монда күз-колак булырга, үзе әйтмешли, өйнең серен сакларга тиеш. Инде олы кеше теге юньсез кызларга катырак әйткән икән, бик дөрес эшләгән дип акларга да мөмкин булыр иде. Ләкин бөтен бәла шунда, әнисе бер хакыйкатьне — күршеләрнең аларга никадәр кырын карауларын аңлап җиткерми. Ә сеңелесе менә яшь кенә булса да, ничектер шуны йөрәге белән сизгән. Һәм нинди сүзләр әйтеп ташлаган ул!.. Бу бик хәтәр, бик шомлы нәрсә бит. Бу — семьяның үз эчендә фаҗигале каршылык бөреләнеп килә дигән сүз бит! Ничек итеп моны күрмәскә яки моңа игътибар итмәскә мөмкин ди?

Зөфәргә бу хәлнең сәбәбе ачык. Ул үзе дә яңа күршеләрнең (искеләрен әйткән дә юк!) аларга ничегрәк карауларын, тиресе белән дигәндәй, сизеп йөри. Әнә шул үпкәләп чыгып киткән кызның әтисен генә искә төшерү дә җитә. Зөфәр белә аны, эшкә барышлый яки кайтышлый еш кына очрата үзен... Әйе, сугыштан кайткан инвалид ул, бот төбеннән бер аягы юк, култык таякларында йөри. Әйе, бик эчә булса кирәк, чөнки бите-күзе аның һәрвакытта кызарып шешенгән була... Менә шул кеше аңа, Зөфәргә, ничегрәк карый?.. Дөрес, Зөфәр очрашканда үзе башлап аның белән исәнләшә, һәм инвалид беркайчан да аның сәламен алмыйча калмый. Әмма шул чагында Зөфәр инвалидның юри кыса төшеп караган боздай салкын-тонык күзләрендә нәрсә күрә? Бары бер генә нәрсә: нәфрәт, ачу, усаллык — гүя никадәр дошман итеп каравын яшерергә дә теләми... Тагын шунысы гаҗәп, кайчагында ул, исерек баштан ялагайланасы килепме,

Зөфәрнең исәнләшүенә каршы түбәнчелек белән баш иеп, җәелеп елмайган да була, ләкин барыбер күзләрендәге усаллык сүнми, ә елмаю ничектер зәһәрле килеп чыга... Һәм Зөфәр мондый чакта аеруча бер чиркану, шомлану тоеп, аның яныннан тизрәк узып китәргә ашыга.

Әлбәттә, ул — Хөршид түгел, инвалидның ни өчен алай каравын бик яхшы аңлап тора. Бер хакыйкать бар: дөньяда кешеләрнең тормышлары да, язмышлары да бертигез түгел. Шулай булып килгән, һәм хәзергә шулай бара әле ул. Ләкин, гафу итегез, моңа ул, Зөфәр Сабитов, гаеплемени?

Шуңа күрә Зөфәр һәртөрле көнче, усал карашларга игътибар итмәскә, намусын тыныч тотарга тырыша. Әмма җиңел түгел бу... Кайчагында кешеләрнең кырын карашлары аны борчый, аны шомландыра. Менә ни өчен ул өйдәгеләрдән дә сак булуны таләп итә.

Бервакытны кемдер аңа, казларны котыртмаска кирәк, дип әйткән иде. Бик дөрес сүз! Әйе, «казларны» котыртырга ярамый.

Ул көнне Зөфәр әнисе белән дә, сеңелесе белән дә бүтән сөйләшмәде. Кичкырын, кәеф бераз төзәлмәсме дип, кинога барып кайтты. Иртә ятып йоклады, иртә генә торып эшенә китте.

Кабинетына барып утыргач та аңа сәүдә министрының урынбасары Әхмәтҗанов шалтыратты. Зур начальникның сүзе кыска булды: бүген үк үз янына килеп чыгарга кушты, сезнең белән бер җитди мәсьәлә турында сөйләшәсе бар, диде, ләкин нинди мәсьәлә икәнен әйтеп тормады.

Сәгать уникеләрдән соң Зөфәр министрлыкка китте. Юл буенча нәрсә хакында булыр икән бу җитди сүз дип уйланып барды. Азрак кына борчылып та куйды — гадәттә бит начальник кеше күбрәк йә наказ, йә шелтә бирер өчен чакыра. Алай дисәң, Әхмәтҗановның аңа, ОРС системасында эшләүчегә, нинди мөнәсәбәте бар.

Зөфәр министр урынбасарын танып, күреп белсә дә, моңарчы якыннан очрашырга да, сөйләшергә дә туры килгәне юк иде әле. Нindирәк кешедер инде. Хәер, аның кул астында эшләүчеләрнең әйтүенә караганда, ул болай «ярыйсы гына мужик», имеш! Фәлән Фәләновичның көенә тора белсәң, ничево, эшләргә була дип әйтәләр. Күбрәк ул акыл сатарга, вәгазьләргә ярата икән. Ләкин югарыдан үзен кыса башласалар, бик усалланып китә торган гадәте дә бар икән.

Фәлән Фәләнович. Тукта, Зөфәр бит аның исем-отчествосын да ишетеп белә иде. Ничек кенә соң әле, аты

коргыры?.. Әһә, тапты: Вилдан... Вилдан... Гыйльманович!.. Хуш, Вилдан абзый Гыйльманович, нимә турында гына гәп корырсың икән?

Әхмәтҗанов — тәбәнәк, юан гәүдәсенә кайтарма якалы күк гимнастерка киеп, салына төшкән корсагын киң каеш белән күтәреп буган, сакал-мыексыз, итләч битле, олы гына яшьтәге кеше — Зөфәрне ачык йөз белән каршы алды.

— Хуш киләсез, иптәш Сабитов! — диде ул, зур өстәл артыннан торып, һәм кул биреп күрешкәч, урын тәкъдим итте: — Утырыгыз!

Зөфәр шунда ук уйлап алды, болай булгач, сүз күңелсездән булмаска тиеш.

— Йә, саулык-тазалык, эшләр-уңышлар ничегрәк соң, иптәш Сабитов? — диде Әхмәтҗанов, елмая төшеп.

— Рәхмәт, Вилдан Гыйльманович! — диде Зөфәр, беренче сүзеннән үк үзен ничектер иркен, кыю хис итеп.— Хәзергә зарланырлык түгел.

— Сәүдәләр барамы?

— Бара, әйбәт бара!

— Шулайдыр шул. Завод ОРСына фондны күп бирәләр, товар булгач, сәүдә бара инде ул.

— Дөрес, Вилдан Гыйльманович, безне товар ягыннан алай кысмыйлар, ләкин без үзебез дә тик ятмыйбыз, эзлибез, табабыз, кыскасы, завод халкын ничек тә яхшырак тәэмин итәргә тырышабыз.

— Ә сез беләсезме,— диде Әхмәтҗанов, чак кына пауза ясап,— завод ОРСлары бетәчәк бит.

Зөфәр өчен бу өр-яңа бер хәбәр иде, ләкин ул сыңар кашын да селкетмичә гамьсез генә әйтте:

— Ишеттек, шундый сүз йөри, только тиз булмас әле ул. Без, мәсәлән, алдагы елда товар оборотын ике тапкыр арттырырга уйлап торабыз...

— Юк, тиз булачак. Мин моны сезгә бик белеп әйтәм, иптәш Сабитов... Бөтен сәүдә хәзер үзенең төп хуҗасына — сәүдә министерствосына күчәчәк. Шулай ул! ОРСлар сугыш шартларында кирәк иде, ә хәзер нигә алар?.. Сату итү заводлар эше түгел, безнең эш ул! Хөкүмәт бу мәсьәләне бик белеп, бик дөрес хәл итә.

— Бәхәсләшмим, Вилдан абзый! — диде Зөфәр.— Хөкүмәт, әлбәттә, дөрес хәл итәр.

Бу юлы инде Әхмәтҗанов бик канәгатьләнеп елмайды:

— Менә шул шул! Анда, брат, мудрый башлар утыра! — Һәм шунда ук җитди кыяфәткә кереп, кисәк кенә сорады: — Ә беләсезме, мин сезне ни өчен чакырдым?

— Юк, Вилдан Гыйльманович, белмим...

Әхмәтҗанов беравык Зөфәргә төбәлеп карап торды, аннары креслосының аркасына ята төште, учы белән өстәленә бер-ике тапкыр суккалап алды.

— Эш менә болай тора, иптәш Сабитов! — диде ул, ашыкмыйча гына сүзен башлап.— Без тиздән шәһәрдә зур универмаг ачабыз. Центрда, элекке люкс бинасында, хәзер аны оборудовать итеп яталар... елына өч йөз миллион сум оборот белән, сизәсеңме?.. Бу әле башта гына, тора-бара ул миллиардка да җитәр. Совет сәүдәсенә хәзер киң юл ачыла, ә товар булачак. Моңарчы корал эшләгән заводлар да мирный продукциягә күчәләр. Кыскасы, перспектива бик шәп!..

...Без менә хәзер шул ачылачак магазинга кадрлар җыябыз. Иң яхшыларын, честныйларын, культурныйларын... Кеше күп кирәк. Универмаг — үзе бер комбинат бит ул, ә киләчәктә төрле җирдә аның филиалларын ачу да күздә тотыла. Менә шундый зур сәүдәне культурный итеп, бай итеп оештыра белүче бер специалист, икенче төрле әйткәндә, коммерческий директор кирәк булачак безгә. Да. Без монда һәм тагын кайбер җирләрдә уйлашып киңәшкәннән соң, сезнең кандидатурага тукталдык. Деловой качестволарыгызны без беләбез. Сезнең специальный образованиегез дә бар бит, шулаймы?

— Әйе, бар.

— Бик яхшы. Безгә шундый кеше кирәк тә... Хуш, әгәр без сезне шул булачак универмагка коммерческий директор итеп чакырсак, ни диярсез? Условиесе начар түгел, төп оклад ике мең ике йөз сум. Шуның өстенә тагын премиальный... Йә, ничек карыйсыз бу тәкъдимгә?

Зөфәр бик тыныч утырды, дулкынлануын берничек тә сиздермәде һәм җавап бирергә дә ашыкмады. Бары кирәк кадәр уйланып торганнан соң гына, дәрәҗәсен саклап, әдәп белән:

— Рәхмәт тәкъдимегез өчен, Вилдан Гыйльманович! — диде.— Сез миңа зур честь ясадыгыз! Ләкин, беләсезме, мин урыннан урынга күчеп йөрергә яратмыйм. ОРСтагы эшемнән канәгатьмен, күптән эшлим...

— Мин сезгә әйттем ич: ОРСлар бетәчәк!

— Кайчан бетәр бит әле ул. Ә сезгә кеше хәзер үк кирәктер?.. Так что, китим дисәм дә мине ОРСтан җибәрмәүләре мөмкин.

— Эш бары сезнең теләктән тора. Әгәр риза булсагыз, без сезне аннан ала белербез, борчылмагыз! — диде Әхмәтҗанов, мәгънәле генә итеп.

— Анысына ышанам, ләкин...

— Сез беспартийный бит әле? — диде Әхмәтҗанов, кинәт кенә Зөфәрнең сүзен бүлеп.

— Әйе, беспартийный.

— М-да! — дип куйды Әхмәтҗанов үзалдына гына, аннары Зөфәргә туры карап, үпкә белдергәнрәк тавыш белән сорады: — Ни өчен моңа кадәр партиягә кермичә тордыгыз?.. Үзегез әйбәт работник, белемегез, развитиегез бар, политиканы аңлыйсыз, күптән керү кирәк иде, туган!

Бу сүзләр Зөфәрнең җан сөяленә барып тигәндәй булды, ләкин ул бер генә хәрәкәт белән дә үзенең читен, авыр хәлен сиздермәде, бары гаепсез генә елмайган булып әйтте:

— Ничектер туры килмәде шул моңарчы, Вилдан абзый! Бик җаваплы эш бит... Әзерлегем җитәрлек түгел дип курыктым инде, дөресен генә әйткәндә...

— Әлбәттә, партиягә керү мәсьәләсенә җиңел карарга ярамый... Достойный булып керергә кирәк... Ну, зарар юк, без сезгә болай да ышанабыз... Йә, ничек соң, мин әйткәнгә ризамы сез?

— Вилдан Гыйльманович,— диде Зөфәр, кулын күкрәгенә куеп,— рөхсәт итегез, сезгә яңадан зур рәхмәт белдерергә, ләкин мин менә хәзер үк бер сүз дә әйтә алмыйм, миңа уйларга кирәк.

— Ярый, уйлагыз... Ләкин, учтите, мин сезгә уйлар өчен вакытны күп бирә алмыйм.

— Шулай да күпме?

— Ну, күп булса, бер атна. Безгә ведущий кадрларны алдан комплектовать итеп куярга кирәк. Ә коммерческий директорның эше, үзегез беләсез, магазин ачылганчы ук башланырга тиеш.

— Аңлыйм... Ярый, Вилдан Гыйльманович, мин сезгә җавапны бер атна эчендә бирермен.

— Бик хуп!

— Тик... бер нәрсәне алдан белергә мөмкин түгелме?

— Именно нәрсәне?

— Универмагның директоры кем булачак? Билгеләндеме әле ул?

— Приказ юк әле, ну билгеләп, согласовать итеп куйган кешебез бар: Комаров Павел Петрович, министерстводан.

— Ә, Комаров... Беләм... Ну, что ж, бик әйбәт.

— Работник ул ярыйсы, энергичный, тырыш, дөрес, күбрәк аппаратта утырган кеше, үзе сату итеп караганы юк әле... Зато сез — специалист, сез сәүдәне яхшы беләсез... Берегездә — җитәкчелек, икенчегездә — коммер-

ция, начар булмас ул!.. Минемчә, сез аның белән килешеп эшли алырсыз.

— Мин, Вилдан Гыйльманович, теләсә кем белән дә эшли алам,— диде Зөфәр, тыйнак кына көлемсерәп.— Рөхсәтме?

— Әйе, пожалысты!

Алар, торып, кул кысыштылар.

— Мин уңай җавап бирерсез дип ышанам,— диде Әхмәтҗанов, Зөфәрнең кулын аз гына җибәрмичә торып.— Белегез, кеше юктан без сезне чакырмыйбыз, ә деловой качестволарыгыз өчен...

— Аңлыйм, Вилдан абзый, аңлыйм. Рәхмәт!

— Ну пока алайса!

— Хушыгыз!

Министрлыктан чыккач, Зөфәр ни өчендер бик кызу атлап бара башлады. Хәтта бераздан үзе дә аптырап: «Тукта, кая бу кадәр чабам соң әле мин?» — дип уйлады һәм... ихтыярсыздан елмаеп куйды. Баксаң, аны эченә сыеша алмаган эчке бер дәрт, рухи күтәренкелек ашыктырып куа икән. Әйе, канатланып очмаслык та түгел шул! Иптәш Әхмәтҗанов, министрның беренче урынбасары, үзе чакырып алып, каршысына утыртып, нинди тәкъдим ясады! Сез — специалист, сез безгә кирәк, рәхим итегез! Беләләр, таныйлар бит, шайтан алгыры!

Ләкин хикмәт анда гына да түгел әле. Тәкъдим ителгән эш үзе аңа, Зөфәргә, бик ошады. Зур универмагта коммерческий директорлык вазифасы — бу аның эше, бу эштә инде ул үзенең сәләтен тагын да шәбрәк күрсәтә алачак. Һәрхәлдә, ОРСның вак точкалары арасында чабып йөрү булмаячак.

Дөресен генә әйткәндә, ОРСта эшләү аны соңгы вакытларда туйдыра да башлаган иде инде. Сугыш елларында завод канаты астында эшләү әйбәт булса да, хәзер кызыгы бетеп бара иде. Әхмәтҗанов әйтмешли, чын сәүдә урынымыни ул? Аннары халкы да бик тынгысыз, бәйләнчек — һәртөрле сүз, шик, гайбәттән башың чыкмый... Әлеге шул дошманың Симаковтан котылыр өчен генә дә әллә кая качарсың... Гомумән, сәүдә работнигына бер урында бик озак утыру, врачлар теле белән әйткәндә, противопоказано ул!

Шуңа күрә Зөфәр, җае туры килсә, берәр сылтау табып, ОРСтан китү турында уйланып та йөри башлаган иде. Һәм менә уйлап таба алмаслык җай үзеннән-үзе килеп тә чыкты. Сылтауны эзләп торасы да юк. Министерство аны үзе ОРСтан бик әйбәт кенә сорап алачак... Әлбәттә, ул Әхмәтҗанов тәкъдименә ике куллап риза.

Тик дәрәҗәсен төшермәс өчен генә уйларга вакыт сораган булды. Ә инде Әхмәтҗанов аның җавабын көтәчәк, һичшиксез, көтәчәк!.. Сабитов кебекне тиз генә таба алачак та түгел ул!.. Тукта!..

«...Кем син, Зөфәр, кем?»

Бу ни хикмәт, иң якты хыялларга бирелеп киткән чакта да шушы сүзләр әллә каян гына аның исенә төшеп, кинәт йөрәген өтеп ала, кәефен боза, дөньясын караңгылатып җибәрә. Ачу китергеч хәл!.. Неужели, ул үзенең нинди әйбәт, шәп кеше булуын шул бала табигатьле, наивный хатынга гына аңлата алмас? Юк, булмый, ярамый болай! Ике ара бөтенләй өзелгән чакта да ул аны тәмам үзенә әсир итеп, үзенең кодрәтенә тәмам ышандырып, гомере буена үкенеп, сагынып яшәрлек хәлдә калдырып аерылырга тиеш!.. Аерылырга? Ә ни өчен аерылырга? Мөмкинме бу, кирәкме бу? Шайтан белсен, нигә ул бары шушы Рәшидә мәсьәләсендә генә катгый бер карарга килә алмыйча йөри torгандыр?!

Ә вакыйгалар, әйткәнебезчә, бер-берсен кысрыклый, ашыктыра башладылар. Озак та үтми, Зөфәр өчен тагын бер мөһим вакыйга булып алды. Эш шунда, Зариф абыйсы аны теге Гамбәр туташ белән таныштыру чарасына чынлап торып керешкән икән. Моның өчен ул тоткан да дүшәмбе көнгә кызның әти-әнисен һәм кызны үзенә кунакка чакырган. Менә шул мәҗлескә Зөфәр дә, билгеле, барырга тиеш. Абзыйның планы болай: башта өлкәннәр үзләре генә киләчәк, ә кыз соңгарак калачак, чөнки йоласы аның шулай икән. Димәк, Зөфәр дә «эштә тоткарланган» булып, соңгарак калырга тиеш. Менә шулай эшләгәч, ашап-эчеп туйган өлкәннәр алданрак кузгалачак, ә яшьләр, соңрак килү сәбәпле, беразга калып торачаклар.

Зөфәргә абыйсының планы һич тә ошамады. «Шитокрыто» булыр дигән иде ул, ә монда бөтенесе шәрран яра: булачак «кияүне» дә күрсәтү, булачак «киленне» дә карау нәкъ татарча ап-ачык, тупас итеп оештырылган. Башта Зөфәр бу рәвешчә танышуга кул-аягы белән каршы торды. Ләкин аңа: «Эш узган, кунаклар чакырылган, әгәр кыз килеп тә син килмәсәң, бөтен эш сүтеләчәк»,— диделәр. Шуннан соң гына Зөфәр кулын селтәп, ниһаять, риза булды. Бигрәк тә аны Гамбәр туташның менә болай мәҗлескә килеп, әти-әнисе алдында егет белән танышырга риза булуы гаҗәпләндерде. Ниндирәк туташ икән соң инде ул?!

Дүшәмбе көнне Зөфәр яхшырак киенеп эшенә китте һәм сәгать бишенчеләрдә ОРСтан туры гына абыйлары-

на барды. Өйалдында самовар яңартып йөргән, бәйрәмчә киенгән, ничектер шактый тазарып та, матурланып та киткән Сәкинә җиңгәсе аны өтәләнеп каршы алды:

— Һәй, Зөфәр җаным, килдеңме, әйдә, әйдә... Көтәләр! — диде ул, серле генә итеп.

Зөфәр, кепкасын салып, чөйгә элде, кечкенә тарак белән чәчен тараштырды һәм алгы бүлмәгә таба узды. Тәрәзә төпләре гөлләр белән тулы тәбәнәк-җыйнак кына залның ишегеннән керүгә, Зариф абыйсы аңа каршы урыныннан сикереп торды.

— Ну, туган, саргайттың бит безне, ни булды, нишләп болай соңга калдың? — диде ул, чынлап та көтә-көтә йөдәгән кешедәй.

— Эш бит, абый... Гафу итегез инде! — дигән булды Зөфәр, йомшак кына елмаеп.

— Шулайдыр дип уйлаган идем үзем дә... Синең кебек нәчәлникнең эше бетәме соң!.. Әйдә уз, әнә түрдән!

Зөфәр күрсәткән урынга керергә кыймыйчарак торгач, абыйсы эшне сизеп алды:

— Ә, әйе, ни, Зөфәр, таныш бул: бу, немец әйтмешли, минем белән бер сүстимдә эшләүче Җиһанша абзый була, ә бу аның җәмәгате Мәфтүхә ханым инде...

Камыр ашлары, конфет, печенье, чикләвек, вареньелар белән тулы өстәлнең түр башында икәү янәшә утырган кызыл чырайлы, чал мыеклы, аска таба бөгелеп килгән зур борынлы, чандыр-эре сөякле Җиһанша абзый һәм ап-ак түгәрәк йөзле, май баскан кечкенә күзле, кара бәрхеттән киенгән симез-юан Мәфтүхә ханым белән Зөфәр сузылып кына күреште һәм шуннан соң гына күрсәткән урынга кереп утырды.

Зариф абзый Зөфәрнең аркасыннан кагып:

— Менә шушы була инде, Җиһанша абзый, минем брат! — диде.— Зөфәр Мөбарәкович Сабитов! Ийе, э-э!

Кунаклар башларын кактылар:

— Яхшы, бик әйбәт!

Абыйсының, мал базарында чегәннәргә тай күрсәткәндәй, тәкәллефсез рәвештә аркасыннан кагып, кунакларга тәкъдим итүе Зөфәргә бер дә ошамады, уңайсызланды, һәм ул ирексездән кызарып куйды... Аз гына пауза булып алды.

— Исән-сау, сәламәт кенә йөрисезме? — диде Җиһанша абзый, ниһаять, Зөфәргә дәшеп.

— Рәхмәт! Хәзергә зарланырлык түгел. Ә үзегез?

— Без дә, шөкер, бер көе исән-имин генә йөрибез әле.

Тагын сүз өзелеп калды. Кунакларның дүрт күзе

Зөфәрдә иде, шунлыктан ул үзен ничегрәк тотарга да, нәрсәдән сүз башларга да белми иде әле.

Сәкинә җиңгәсе яңадан кайнатып чыгарган самоварын өстәлгә җиңел генә китереп куйды.

— Син,— диде ул иренә,— кунакларны кыста әле, кыста әле, кыста. Үз эшеңне онытып утырма. Ягез әле, кунаклар, рәхим итегез әле яңа чәйдән.

— Булган иде инде безгә,— диде Мәфтүхә ханым, гүя кыстатыр өчен генә.

— Эчәрсез әле, эчәрсез, менә яңа килгән кунак белән бергәләп.

— Яңа килгән кунакка син аш-суыңны тизрәк китер,—диде Зариф абзый.— Коры чәй белән генә туйдырып булмас аны, хе-хе-хе!

— Ашыкма, һәр нәрсәнең үз җае бар. Берәр чәшке эчә торсын... Нишләптер менә Гамбәр туташ бик соңлады.

— Әйттем мин Мәфтүхә ханымга, үзегездән калдырмагыз, дидем.

Мәфтүхә ханым, бер дә сер сынатмыйча һәм Зөфәрдән күзен алмыйча, төче генә елмаеп:

— Гамбәргә ахирәте килеп калды шул,— диде.— Ташлап китәргә яхшысынмады инде... Ахирәте белән бит алар парлап, дүрт кулдан пианинода уйныйлар. Музыка булса, ипи дә кирәкми инде безнең Гамбәргә... Бәлки, килеп тә җитәр әле.

Зариф абзый кунакларның чынаякларына куе итеп чәй ясады, рәхим итегез, диде, өстәлдәге сыйларның әле берсенә, әле икенчесенә кулы белән ишарәләп күрсәтте. Кунаклар рәхмәт әйтеп, чынаякларын алдылар, балкашык белән генә чәйләрен капкаладылар. Күрәсең, алар чынлап та туйганнар иде инде... Аннары Зөфәрдән сүз көтәләр иде шикелле. Ләкин Зөфәр, авызына йозак салынгандай, һаман телгә килә алмыйча, бары тыштан ничек тә бәйсез тынычлык саклап, кашыгы белән чәен болгаткалап, тик кенә утыра бирде.

Ахырда Зариф абзый, ниндидер өзелгән сүзне ялгап җибәргәндәй, кинәт кенә:

— Ну бу Американы, мин әйтәм, баеп калды да соң, каһәр! — диде.— Башта сугыш буена безгә сатып ятты, хәзер Германга сата башлар, йөртә белә эшне үзе дә! Бездән күп көчледер инде ул хәзер, ә Зөфәр?

Зөфәр, таптың сорар нәрсә дигәндәй, кашын җыерды һәм иренеп кенә җавап бирде:

— Бәлки, хәзерге вакытта шулайдыр да... Сугыштан имгәнеп калмады бит ул. Ләкин байлык бездә дә бар, хәтта артыгы белән.

— Ә син җир-суның күплеген әйтәсең инде, беләм! Ул бит әле мертвый капитал, ә тегенең бөтенесе худта. Аннары аның кулында атом бит, атом!.. Шутишь син!

— Дәүләтнең көче байлыкта, Зариф, — диде Җиһанша абзый, сабыр гына.— Байлык булса, акрынлап атомы да, барысы да булыр.

— Белмим шул, Җиһанша абзый... байлыгын байлык та бит, әмма ләкин атомның сикрите тегенең кулында ич! Әллә ул сикритен безгә сатар дип уйлыйсыңмы? Җитмәсә, үлгән аюның тиресен үзара бүлешә алмыйча ызгышырга торган бер чакта!

Зөфәр абзыйларның политика турындагы сүзләренә бүтән катнашмады, колак салып кына утырды. Җиһанша абзый аз сүзле, төпле кешегә охшый иде. Акылы сүздән алда йөри булса кирәк. Ничектер үзен тотышында ук чын ирләргә хас тыныч сабырлык аңарда сизелә иде. Кыскасы, булачак «бабай» Зөфәргә ошады. Ә менә булачак «әби» ни өчендер аны бераз гына борчый, тынычсызландыра иде. Ихтимал, бу Мәфтүхә ханымның ачыктан-ачык бары аңа күзләрен елтыратып карап утыруыннан килә торгандыр. Әйтерсең ул аның тышкы кыяфәтен генә түгел, эчен дә күрергә, капшарга тырыша иде... Мондый «әбидән» бер адымыңны да яшерә алмассың, дип уйларга мәҗбүр булды Зөфәр.

Ирләрнең бер дә кирәксездән чит мәсьәләгә кереп китүләре Мәфтүхә ханымны да туйдырды булса кирәк, ахырда түзмәде, үзе башлап Зөфәргә дәште:

— Сез каядыр Арча кырында торасыз шикелле?

— Әйе, Зинин урамында торабыз.

— Үз йортыгызда, шулаймы?

— Әйе.

— Кайчан алган идегез?

— Былтыр гына әле.

— Зариф абый сөйләгән иде шул. Бик зур, бик матур йорт икән. Рәхәтен күреп торырга насыйп булсын инде.

— Рәхмәт!

— Без үзебез жакт йортында торабыз,— диде Мәфтүхә ханым, сүзне өзмәс өчен генәме, әллә бүтәнрәк бер максат беләнме.— Аркылы Тукай урамында. Квартирабыз болай бик әйбәт, икенче катта, өч бүлмә, дүртенчегә — аерым кухня... Без бит үзебез дә өчәү генә. Җитә, бик җитә.

— Жакт йортында тору бер яктан уңайрак та ул, мәшәкате азрак.

— Белмим инде. Халык хәзер йорт ала да йорт ала. Мин дә Җиһаншага әйтеп караган идем, шәһәрнең шул югары, чиста ягыннан үзебезгә берәр йорт әзлик дип... Ирем әйтә, нигә кирәк ул, ди, без олаеп барабыз, кемгә калыр ул, ди. Аныкы да дөрес инде.

Зариф абзый тагын кунакларның чынаякларына үрелде. Ләкин Җиһанша абзый чынаягын учы белән каплады:

— Булды, Зариф, рәхмәт! Безгә рөхсәт итегез инде.

— Туктагыз ла, бу нинди сүз, күңелле генә сөйләшеп утырганда... Өлгерерсез әле.

Мәфтүхә ханым бала ботыдай ак беләгендәге кечкенә алтын сәгатенә карап алды:

— Юк, чыннан да безгә вакыт икән... Рәхмәт, бик зур рәхмәт сезгә... Инде үзегез безгә рәхим итегез, менә Зөфәр... әфәнде белән бергәләп.

Әфәнде!.. Зөфәр хәтта куырыла төшеп, маңгаен ышкырга тотынды.

Шул арада өйалдыннан кеше сөйләшкәнгә охшаганрак нindидер тавыш ишетелеп калды. Ул да булмый, гадәттән тыш бернәрсә бар шикелле, бик ашыгып, залга Сәкинә килеп керде.

— Кызыгыз килде... Гамбәр туташ килде!

Зариф абзый урыныннан сикереп торды, икәүләп алгы бүлмәгә чыктылар, икесенең берьюлы килгән кунакны шатланып каршы алулары, кыстап чакырулары ишетелде:

— Һа, хуш килдегез, Гамбәр туташ! Менә рәхмәт, менә яхшы иткәнсез!

— Әйдә узыгыз, уз, Гамбәр җаным, рәхим итегез!

— Ягез инде, йә, тарсынып тормагыз! Бездә ят кеше юк, үзебез дә эти-әниегез генә...

Ә шул чакта залдагылар тып-тын калып тордылар. Җиһанша абзый белән Мәфтүхә ханымның йөзенә азрак кына уңайсызлану билгесе дә чыккандай булды, ләкин алар моны сиздермәскә тырышып, горур гына, киеренке-тыныч кына утыра бирделәр.

Ниһаять, зал ишегендә Гамбәр туташ күренде.

Иң элек Зөфәрнең күзенә ташланган нәрсә шул булды — кыз буйга кечкенә, гәүдәгә бик җыйнак — миниатюрный иде. Аңа әле «туташ» дип дәшергә дә иртәрәк кебек иде. Әмма ул яшь ханымнардай бик бай, бик зәвыклы итеп киенгән иде. Өстендә аның, фигурасына ыспай ятып, туры гына төшкән, шунлыктан буен озынрак та,

нәфисрәк тә итеп күрсәткән бик затлы яшел йон күлмәк. Аякларында биек үкчәле, көзгедәй кара «лодочкалар». Колакларында җем-җем уйнаган кечкенә бриллиант алкалар, ә ап-ак муенында вак кына энҗеләрдән өч рәтләп тезгән кыйммәтле муенса. Һәм болар барысы да аңа бик килешеп, ничектер бөтен кыяфәтен яктыртып тора иде.

Хуҗалар Гамбәр туташны нәкъ Зөфәр каршысына утырттылар. Аз гына киеренке тынлыктан соң, Мәфтүхә ханым кызына йомшак кына дәште:

— Нигә болай бик кичектең, кызым? Без китәргә тора идек инде.

Кыз, түбән карап, кызарып кына җавап бирде:

— Дустым озак утырды... Ул гына киткән иде, Алма апа килде.

— Алма апаң килде?

— Әйе.

— Ай Аллам! — дигән булды Мәфтүхә ханым, борчылып.— Онытып та җибәргәнмен, килермен дигән иде шул! Киткәндер дә инде?

— Юк, бездә калды әле...

Мәфтүхә ханым урыныннан ук тора башлады.

— Әйдә, картым, кузгалыйк! Безне кеше дә көтә икән.

— Утырырга иде дә бит әле, кешене көттерү уңайсызрак шул! — диде Сәкинә, аптырабрак калгандай.

Кунаклар тагын бер кат рәхмәт әйтеп, урыннарыннан тордылар. Шул чакта Гамбәр туташ кыюсыз гына әйтеп куйды:

— Мин дә алайса... калмыйм.

— Ә юк, сеңелем! — диде Зариф абзый, гаҗәп бер өлгерлек белән.— Кузгалмыйсың, рөхсәт итмибез! Синең кебек соңга калган кунагыбыз бар әле, менә бергә-бергә ашап-эчәрсез, Алла бирсә!

Мәфтүхә ханым да гүя икеләнебрәк кенә әйтеп куйган булды:

— Килеп кергәч тә кузгалу килешмәс инде, кызым, азрак утыр, булмаса!

Хуҗалар кунакларны озата чыктылар. Зөфәр башын игән чәчәк төсле каршысында утырган туташка карап, эченнән генә: «Кыз белән очраштыру менә ничек була икән ул! — дип уйлады.— Ә шулай да таныштырырга оныттылар...»

— Гамбәр... Сезнең исемегез Гамбәр икән!

Кыз сискәнгәндәй керфекләрен тибрәтеп, Зөфәргә бер карап алды.

— Әйе! — диде ул, пышылдап кына.

— Бик оригинальный исем, матур исем.

Кыз елмайды, кызарды, ләкин сүз кайтарып әйтә алмады.

Зөфәр һич тартынусыз кызны җентекләп карарга тотынды. Абыйсы бераз арттырып җибәрсә дә, гомумән, дөрес сурәтләгән икән: кыз сөйкемле-чибәр генә иде. Кашы-күзе кара, керфекләре озын, йөзе бик чиста-ак, тик аңа гаҗәп тиз кызыллык йөгерә һәм тиз үк кире дә кайта; борыны төз генә, кечкенә генә, авызы да уймактай кечкенә, ә ияге... Зөфәр хәзер генә шәйләп алды: ияге очлы һәм озын икән. Менә ни өчен ул, бичара, башын гел түбән иеп утыра, имеш! Шулай утырганда сизелми диярлек, ә йөзен күтәр дисә, очлы озын ияк алга таба сөзә дә чыга. Һәм бу нәрсә аның матур-нәфис йөзен нык кына боза иде. Кызганыч!

Зөфәр кызның буй-сынына да игътибар итте; әйткәнебезчә, кыз буйга кечкенә булса да какча-ябык түгел иде. Һәр җире бик чамалы, бик килешле, тулы-йомры гына иде... Абыйсының: «Нәгызь», — дигәне менә аңлашылды хәзер...

Кыскасы, Гамбәр туташ Зөфәргә ошады. Ничево, зарарсыз, кабул итәрлек, әгәр ияге генә эшне бозмаса, бер караудан гашыйк та булырга мөмкин булыр иде дип уйлады ул.

Ашыгып кергән Сәкинә җиңгәсе:

— Көттердем сезне, кунакларым, хәзер була, бөтен нәрсәм дә әзер,— диде һәм кунаклар алдына тәлинкә,-кашыклар куя башлады.

Зариф абзый бик кәефләнеп, кулларын уа-уа килеп керде.

— Менә сезгә, яшьләргә, мин әйтәм, олыларның китүе әйбәт тә булды бит әле. Аулакта, ичмасам, бер иркенләп утырырсыз.

Буфет алдыннан кызыл вино салган графин белән ике рюмка алып, өстәлгә куйды, аннары тәкәллефләнеп торуны хәзер артык нәрсәгә санап булса кирәк, Зөфәргә туп-туры әйтте:

— Син, Зөфәр, үзең кунак та, хуҗа да бул инде. Туташны бик әйбәтләп сыйла!

— Ә син?

— Ә мин китәм,— диде Зариф абзый, ваемсыз-тыныч кына.— Барасы җирем, күрәсе кешеләрем бар.

Зөфәр, абыйсының хәйләсен ачык сизеп, авыз кырые белән генә елмаеп куйды: әйдә, көйлә инде, көйлә!

Сәкинә җиңгәсе кунакларның тәлинкәләренә пилмән сосып чыкты. Зөфәр рюмкаларга вино салды.

— Ягез, Гамбәр, болай булгач, икәү генә сыйланыйк әле... Күтәрегез!

Гамбәр туташ каш астыннан гына аңа карап елмайды, ләкин рюмкасына үрелмәде.

— Ягез инде, көтәм!

— Ягез, йә, туташ! — диде Сәкинә дә.— Аз гына эчкәннән берни дә булмас.

Кыз сузылырга куркып, һаман тик кенә утыра бирде.

— Алайса мин дә эчмим,— диде Зөфәр, рюмкасын кире куеп.

Шуннан соң гына Гамбәр туташ, ияк очына кадәр кызарып, рюмкасын кулына алды. Зөфәр чәкәштерер өчен үзенекен аңа сузды:

— Сезнең саулыкка!

Кызның кулы калтырады, виносы чайкалды һәм рюмкасын ирененә тидереп кенә алды. Пилмәнгә дә ул юньләп кагылмады — бик кыстагач кына бер-ике кашык капкан булды. Сәкинә пилмәннән соң кара җимеш салып пешергән пылау китерде — кыз аны да әз-мәз генә капкалады. Аннары өрек суы килде...

...Зөфәр туташка карап тыелып тормады инде, алдына килгән берсен ашап бетерә барды, чөнки ул бик ачыккан иде. Шул ук вакытта ул кунагын игътибарсыз калдырмаска тырышты, кыстап, ашларны мактап, һаман сүзката торды. Әмма шуннан артыгына көче-сәләте җитмәде, чөнки үзен махсус күрсәтергә килгән туташыбыз артык тыйнак, артык йомык, артык киеренке хәлдә иде. Ул, бичара, егет алдында үзен гүя менә витринадагы манекен шикелле хис итә иде. Хәрәкәт тә юк, сүз дә юк, тик шунда эчтән калтырап, тыштан янып һәм бөтен зиннәтләре белән ялтырап утыра иде.

Чәйдән соң алар кузгалдылар. Зөфәр Гамбәр туташны озата барды. Суконныйдан Кабан буена чыктылар, аннары Болак күпере аша узып, күлнең икенче ягына борылдылар. Кыз егеткә бераз ияләшеп өлгерде, ахрысы, юл буенча алар ашыкмыйча гына анысы-монысы турында сөйләшеп бардылар. Билгеле, күбрәк Зөфәр инициатива күрсәтергә тырышты, сорашты-нитте, шулай итеп кызның да беркадәр телен ачты.

Аркылы Тукай урамының очына җиткәч, кыз тукталды. Зөфәр аңлады — туташ үз өйләренә чаклы ук барып җитәргә теләми, уңайсызлана иде. Саубуллашкан чакта Зөфәр аның кулын каты итеп кысты, күзләренә карады, ничек тә җылырак итеп:

— Ышанам, бу безнең соңгы очрашуыбыз булмас, шулаймы, Гамбәр? — диде.

Туташ гадәтенчә кинәт кенә кызарды, мескен генә елмайды, озын керфекләрен тибрәтеп, башын кагып куйды.

Аерылып киткәч, Зөфәр кыз турында уйланып кайтты. Менә өйләнергә дип мактый-мактый димләгән туташны аңа күрсәттеләр. Ни дисең, ярамаслык кыз түгел, билгеле. Начар хатын булмас, бәлкем. Гомумән, кечкенә хатыннарны бик тәүфыйклы, бик ир җанлы була дип сөйлиләр. Аннары моңа өйләнүе дә бик ансат булыр шикелле... Тик шунысы гына аяныч: кыз Зөфәр күңелендә хәзергә бер генә төрле дә хис уята алмады. Сәбәбе нәрсәдер инде моның?

## XV

Зөфәр шәһәрдә яңа ачылачак универмагка коммерческий директор булып барырга ризалыгын бирде. Хәзер аны күчерү турында Сәүдә министрлыгы белән ОРС арасында сөйләшү бара. Тоткарлык булмас кебек, чөнки Зөфәр ОРС җитәкчеләренә үзенең китәргә теләвен ачык белдерде. Һәрхәлдә, берәр атнадан ул яңа урында эшли башларга тиеш.

Яңа эш — киләчәккә яңа юл. Зөфәр мәсьәләгә әнә шулайрак карый. Иң элек ул үзенең хезмәт эшчәнлегендә югарырак баскычка күтәрелә, дәрәҗәлерәк кешегә әверелә, шулай итеп аның алдында яңа мәйдан, яңа киңлекләр ачыла. Шуңа карап инде ул эшен-гамәлен дә, көнкүрешен дә ничектер бүтәнчәрәк, яңа шартларга яраштырып, көйли белергә тиеш. Кем белә, бу сәүдә эшендә ул бәлки тагы да югарырак үсәр. Моның өчен аның бөтен мөмкинчелекләре бар. Әгәр эш партияле булу-булмауга килеп терәлә башласа, анысын да уйлап карарга ярый. Иптәш Әхмәтҗанов үзе үк өндәп тора бит... Дөрес, Зөфәр моңарчы нисбәтән кечкенә кеше иде, партиясез көенә дә бик әйбәт эшләп килде, кыскасы, урын өчен генә куркашикләнә партиягә керүнең кирәге булмады. Инде киләчәктә кирәк була икән... хәер, бу хакта алдан ук

баш ватмыйча да торырга мөмкин. Башны ваттыра торган икенче, ашыгычрак мәсьәләләр бар әле монда...

...Бу — Рәшидә — Гамбәр мәсьәләсе. Зөфәр өчен менә шул төенне, ниһаять, чишәр вакыт җитте. Һәм ничек тә озакка сузмыйча.

Дөресен генә әйткәндә, Гамбәр мәсьәләсе аны артык борчымый да, уйландырмый да иде. Аңа җиткерделәр инде — ул кызның үзенә дә, әти-әнисенә дә бик ошаган. Әгәр Зөфәр тарафыннан әйбәтләп, чынлап сорау булса, шик юк, ике куллап бирәчәкләр. Ә кыз ярамаслык түгел. Шуңа күрә Гамбәрне ул кесәсенә кергән мал кебегрәк итеп саный иде инде.

Әмма Рәшидә... Рәшидә икенче мәсьәлә. Рәшидә турында ансат кына уйлавы да, тәгаен бер карарга килүе дә бик-бик читен. Тик бер генә нәрсә ачык: аның йөрәгендә Гамбәр туташ Рәшидә урынын ала алмады, хисләре аның Рәшидәдә, һичшиксез, ул Рәшидәне ярата... Ияләшкән, күнеккән дә инде ул аңа — кинәт кенә аерылуы, югалтуы бик авыр булачак.

Соңгы көннәрдә Зөфәрне, бөтен корып йөргән исәпләренә каршы килеп дигәндәй, бер уй бик нык били, борчый башлады: әгәр ул Рәшидәгә өйләнеп куйса, ә?.. Тузга язмаган тиле, кысыр бер хыял түгелме бу?.. Мөмкин эшме, кирәкме, хәерлегә булачакмы? Ул бит күпме генә яратып йөрмәсен, Рәшидәгә өйләнү дигән фикерне моңарчы башына да китермәде. Киресенчә, иртәме-соңмы ике ара өзелергә тиеш дигән уй белән йөрде, шуңа исәп тотты, хәтта артык якынаеп китмәс өчен мөмкин кадәр сирәгрәк очрашырга тырышты. Башта ук бит ул аны кемнәндер калган хатын дип, артистка дип, үзе өчен һич лаек булмаган кешегә санады.

Ә хәзер аның уйлары — гаҗәп хәл! — бөтенләй икенче юнәлеш ала башлады: хуш, Рәшидә хатын кеше, ди, ләкин аңардан ни зарар? Өйләнер өчен кыз гына булсын дигәнмени?.. Гамбәр әнә өлгереп кенә җиткән кыз да бит, әмма ләкин булачак хатынының бөтен яме-тәме бары шуңарда гынамыни?.. Ә соңыннан ул Рәшидәдәге төсле нәфислекне, нечкәлекне, хисләр дәртен аңарда табармы, Рәшидәне яраткан кадәр үк аны яратып китә алырмы —бу кадәресе бик шикле!

Ләкин хикмәт анда гына да түгел әле. Иң мөһиме, шуларның кайсысына — Рәшидәгәме, Гамбәргәме өйләнү аның өчен отышлырак булачак? Дөрес, Гамбәргә өйләнү хәвефсезрәк, ә Рәшидәгә өйләнү куркынычрак, чөнки

Рәшидә эше-тормышы белән аңардан шактый ерак кеше. Ләкин бу хәзергә генә шулай тоелмыймы икән, бергә кушылгач, бәлки пар күгәрчендәй яраклашып торып та китәрләр. Кешеләрне уртак тормыш бик нык бәйли бит ул.

Аннары мәсьәләнең бу ягы да бар: ни өчен ул үзен бөтен яктан да бары сәүдә кешеләре белән чорнап алырга тиеш? Ул бит хәзер дәрәҗәле кеше, үсеп бара торган кеше, бәс, шулай булгач, сәүдәгәр абзыйлар, сәүдәгәр бабайлар киләчәктә аның аягына тагылган авыр герләргә әйләнмәсләрме? Коммерческий директор тирәсендә кемнәр чуала, кемнәр белән ул аралаша-йөри, туган-тумачасы, агай-энесе кем — моны бит исәпкә алып торучылар булачак. Онытырга ярыймы соң!.. Ә хатының башка эш кешесе, әйтик, артистка булса, халык күзенә дә, начальниклар каршында да аның өчен бик уңай, бик отышлы булып чыгуы мөмкин. Чынлап та, Зөфәр Сабитовның хатыны яшь кенә артистка — бу, русчалап әйтеп җибәргәндә, что-то стоит, шайтан алгыры! Үзе төскә чибәр, сылу, кыланышлары сөйкемле, акыл да, сизгерлек тә юк түгел, чөчеп караучылар аз булмас иде аңа... Искусство әһеле почетта хәзер, тик бер ялтырап, күтәрелеп кенә китсен!.. Әлбәттә, ул үзенең Рәшидәсен иң модный, иң затлы киемнәргә генә төреп, кадерләп кенә йөртер иде... Һәм алар алдында нинди генә түрәләрнең ишекләре ачылмас иде!

Менә шундый хыяллар Зөфәрне соңгы вакытта котырта һәм мавыктыра башлады. Ә Рәшидәгә килгәндә инде, Зөфәр артык шикләнми иде, тәкъдим ясый калсам, риза булыр, чыгар, дип ышана иде. Юк, чыннан да, нишләп риза булмасын ди ул?.. Бердән, Рәшидә аны ярата, икенчедән, менә өч ел инде болай да аңа хатын булып йөри, өченчедән, Рәшидәнең дә бай, рәхәт тормышта яшисе килмимени? Артистка ич ул!

Кыскасы, Зөфәр Рәшидә белән яңадан бер очрашып, ачыграк һәм чынлабрак сөйләшеп карарга булды. Әлбәттә, ул аңа туп-туры: «Мин сиңа өйләнәм!» — дип әйтергә ашыкмас, чөнки бу җиде кат үлчәп, бер кат кисүне сорый торган мәсьәлә. Башта кылын тартып карар, бераз өметләндереп куяр, аннары инде... күз күрер!.. Шулай уйлап, бераз баш ваткач, ул Рәшидәне туры үзенең өенә чакырырга булды. Әйдә, килсен, күрсен, белсен Зөфәрнең ничек яшәвен!.. Шушы үзе үк яшь хатынның йөрәген һәм хыялын әсир итмәсме?

...Инде бу карарга килгәч, тагын бер бик четерекле мәсьәләне хәл итәсе калды: Рәшидәнең килүен әнисе Таибә абыстай күрү түгел, сизми дә калырга тиеш. Шулай итмәгәндә бер хикмәт тә чыкмаячак. Бүтәнен әйткән дә юк, хәтта юньләп сөйләшү дә мөмкин булмаячак... Соң, билгеле инде, Гамбәр туташны димләп кенә йөргән чакта улы янына яшь бер ханымның килеп керүен карчык, керпе шикелле, бөтен энәләрен торгызып каршы алачак. Мондый вакытта үтә сизгер, үтә уяу булалар бит ул әни карчыклар!.. Димәк, аңардан котылырга кирәк. Ләкин ничек итеп, нинди генә хәйлә белән үзен берәр яры чыгарып җибәрергә!

Төрлечә уйлап, озак кына баш ватканнан соң, Зөфәр, ниһаять, исенә төшерде: әнисе күптән зиратка барып кайту турында сөйләнә иде. «Бу йортка күчкәч, барып әтиегезнең рухын шатландыра алганым юк, көтәдер, бичара, бетмәде бу дөнья мәшәкате дә!» — дип, еш кына зарлана иде. Менә шәп тә булыр иде әгәр карчыкны шул Яңа бистә тарафларына озатып булса! Ләкин моны бик оста, шома эшли белергә кирәк.

Җомга көн кичке чәй янында Зөфәр газета караштырып утырган җиреннән әнисенә гүя болай гына әйтеп куйды:

— Әни, күптән зиратка әти янына барып кайту турында сөйләнә идең... Бара алмадың ахрысы инде...

— Кирәк иде, бик кирәк иде дә бит,— диде Таибә абыстай, авыр гына көрсенеп,— дөньясы, һич кенә менә бушый алмыйм.

— Әйе, эшең күп шул... Әллә шулай да, мин әйтәм, бу якшәмбедә Хөршид белән икәүләп барып кайтасызмы? Җәй дә үтеп бара...

— Бик әйбәт булыр иде дә бит, йортны ничек ялгыз калдырасың?

— Ә мин ул көнне көн буена өйдә утырачакмын, эшләрем бар... Чын, уйлагыз әле, бүтән минем өй саклап утырырлык көнем әллә булыр, әллә юк. Аннары үзеңнең дә җаның бер тынычланып калыр иде.

— Әйе шул, әйе шул! — диде Таибә абыстай, тәмам килешкән шикелле.

Ә шимбә көнне Зөфәр, Рәшидәгә шалтыратып, аны әйбәтләп кенә үзенә чакырды, адресын бирде, сәгать уникеләрдән калмыйча килеп җитәргә кушты. Рәшидә бу чакыруга бик гаҗәпләнде шикелле, башта ни әйтергә дә белмичәрәк торды, ләкин Зөфәрнең чын ихластан үтенеп чакыруын ишеткәч, килергә риза булды.

Августның соңгы якшәмбесе бик матур килде, элекке кичтән шактый җилләп, төнлә яңгыр ява башласа да, иртән тагын аязып җибәрде. Көн бик җылы һәм тымызык иде... Таибә абыстайның да мондый көнне әрәм итәсе килмәде: иртәнге чәйдән соң тәһарәт алып, озак кына җыенып, ниһаять, Хөршидне ияртеп, зиратка китеп барды. Кичәдән бирле әни кире уйлый күрмәсә ярар иде дип, эченнән бик борчылып торган Зөфәр аларны тыныч кына озатып калды. Хәерле сәгатьтә!

Рәшидә килеп җитәргә дә вакыт күп калмаган иде инде. Зөфәр тагын бер кат үзенең йокы бүлмәсен тиз генә күздән кичерде, тәрәзә пәрдәләрен төшереп куйды, аннары өстен алыштырды. Шартына махсус яхшы да, килешле дә булсын дип, ул өстенә кыек якалы бик иркен ефәк күлмәк һәм чесуча ак чалбар киде. Сары ботинкаларын өйдә генә кия торган кызыл чүәкләр белән алыштырды.

Залдагы биек көзге каршына барды: юк, бик әйбәт, бик килешә икән!.. Йә, кызларның һушын алмаслык егетмени ул? Буе-сыны директорларныкыдай мәһабәт, йөзе сөттә югандай чиста да шоп-шома, ә аксыл чәчләре... Рәшидә сөеп сыйпарга ярата торган чәчләре... кылган чугыдай йоп-йомшак... Хәер, үз-үзенә болай сокланырга яратмый ул. Ирләр эше түгел.

Унике туларга ярты сәгать калды. Зөфәр, бер урында гына тора алмыйча, бүлмәдән бүлмәгә йөри башлады. Ишек-капкалары бикле ялан кадәр йортта япаялгыз кеше көтеп утыру, гомумән, җиңел түгел инде ул, ә монда... таш та урыныннан кузгалыр. Беренче тапкыр килә бит, беренче тапкыр аның бусагасыннан атлап керә. Һәм бу минут һаман якынлаша, һаман якынлаша...

Зөфәр атлаган саен сәгатенә күз төшерде, ләкин еш кына ничәне күрсәтүенә игътибар итә алмады, һаман йөренә торды, ахырда, зал тәрәзәсенә килеп, урамга карап тора башлады. Унике тулып, биш минут үтте, ун минут үтте, ә Рәшидә юк та юк. Чынлап борчылу Зөфәрне, ниһаять, биләп алды: бу ни эш бу, шулай ук килмәве булдымыни инде бу?

Беренче звонокны ул ничектер ишетми дә калды шикелле, ләкин икенче тапкыр шалтырагач, ихтыярсыз сискәнеп куйды һәм ашыгып ишеккә китте. Кем дип сорамыйча гына парадный ишеген ачып җибәрде. Аның каршында күк жакет, ак берет кигән Рәшидә үзе басып тора иде. Зөфәр бер

сүз әйтмәстән аны, кулыннан тотып, эчкәре тартып кертте. Ишекне япкач кына дулкынланудан пышылдап:

— Карап торып күрми дә калдым бит, карап торып! — диде.

— Кемне?

— Сине инде, сине! Күзем урамда, ә хыялым әллә кая киткән. Менә нинди хәлгә төшердең син мине...

— Аңламыйм,— диде Рәшидә, коридор уртасында туктала биреп.— Ни өчен аңа мин гаепле?

— Килмисең дип торам, аңлыйсыңмы, шуңа борчылып!.. Унбиш минут узды бит!

Рәшидә җиңелчә генә иңбашын җыергандай итте.

— Минем вәгъдәмдә торуымны беләсең ич! Ә соңга калуга... мин гаепле микән? Беренче тапкыр эзләп киләм бит.

— Әйе шул! — диде Зөфәр, ашыгып һәм Рәшидәне беләгеннән тотып, өйгә алып керде.

Зур залның ишегеннән керүгә Рәшидә тукталды, сәерсенеп тирә-ягына каранды һәм шундук бер урындыкның кырыена гына утырды. Зөфәр дә утырырга мәҗбүр булды.

— Менә килеп бик яхшы иттең бит әле, Рәшидә! — диде ул, нидән сүз башларга белмәгәндәй.

Рәшидә эченнән сиздермичә генә сулап куйды.

— Килдем шул... Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, диләр бит...

— Нигә алай дисең, Рәшидә? Мин сине куар өчен чакырмадым.

Рәшидә дәшмәде, түшәмгә карады, стеналарга карады, аннары башын кырынайтып, нәрсәгәдер колак салыбрак торды.

— Әллә өйдә берәү дә юк?

— Юк шул.

— Нишләп?

— Шулай... китеп беттеләр,— диде Зөфәр, тотлыгыбрак.

Рәшидә, гүя эченнән генә нидер уйлап, башын кагып куйды. Зөфәр аның кулыннан тотмакчы булды.

— Мин үзем синең белән ялгыз гына калырга теләдем,— диде ул, сер әйткәндәй, пышылдап кына.

Рәшидә кулын акрын гына читкә алды. Елмаймады, кызармады, сын шикелле текә-туры гына утыра бирде. Зөфәр шундук сизде: Рәшидә бүген йомык, Рәшидә бүген салкын. Менә ни өчен алар арасында элеккечә гади-җылы

якынлык туа алмыйча тора. Лəкин нидəн бу? Ятсынамы, уңайсызланамы, əллə исе китеп калдымы? Хəмит бүлмəсе түгел шул монда!.. Əмма, ничек кенə булмасын, бу салкынлыкны, бу ятсынып маташуларны тизрəк бетерергə кирəк иде. Ул үзе дə əллə ничек каушабрак калды шул, хəерсез!

— Рəшидə, син өстеңне салыр идең,— диде ул, яңадан аңа кыю гына үрелə башлап.

Рəшидə, кулын суза төшеп, аны туктатты:

— Кирəкми.

— Ни өчен?

— Миңа болай да яхшы.

— Куй əле, Рəшидə, үз өеңдəге шикелле генə бул əле... Бу нинди ятсынып тору, килешмəгəнне!

— Мин ятсынмыйм, тик...

— Нəрсə «тик»?

— Сəер, əллə ничек... Менə килдем, ə ни өчен килдем — үзем дə белмим.

— Үкенəсең?

— Үкенмим дə...— Рəшидə сүзен əйтеп бетермəде.

Зөфəр пошынып һəм үпкəлəгəн сыман аңа беравык карап торды, аннары җитди генə итеп, лəкин ничек тə йомшак булырга тырышып əйтте:

— Рəшидə, мин сине бүген танып җиткермим! Валлаһи!.. Нигə син болай... күңелсез... салкын? Əллə кəефең юкмы?.. Мин бит сине бик телəп чакырдым. Менə үз өемдə сине күрəсем килде... Йə, начармыни бу?

— Юк, мин алай димим, Зөфəр... Син чакырдың — мин килдем... Тик... бу чакыруның, ничек дим, максатын аңлап бетермим əле мин... күпме вакыттан соң беренче мəртəбə бит... Əллə ничек...

Зөфəр бик аз гына иреннəрен кысып торды.

— Мин сиңа, Рəшидə, шуны əйтергə тиешмен: бу йортны мин былтыр гына сатып алдым... Аңарчы без ике семья бер кечкенə квартирада тордык... Алгач та əле моның эше күп булды. Ремонт, тегесе-бусы... Ну вот хəзер аны кешегə күрсəтергə дə ярый. Ə минем сиңа кайда, ничек торуымны күптəн күрсəтəсем килə иде... Чын əгəр!

— Рəхмəт!.. Ə шулай да син, Зөфəр, яшерен кеше икəнсең... Бер генə тапкыр да əйтмəдең бит...

— Ə нигə алдан шауларга? — диде Зөфəр, көлгəн булып, һəм урыныннан торды.— Ə хəзер, дустым, мин сиңа... апартаментларымны күрсəтим əле. Иң элек бакчага чыгыйк.

Рәшидә сүзсез генә аңа иярде. Аш бүлмәсе аша террасага чыктылар. Зөфәр, туктала биреп, Рәшидәне алгарак уздырды. Бакча!.. Карт, зур бакча!.. Түрдә кып-кызыл алмаларын көчкә күтәреп торган терәүләр салган карт алмагачлар... Ә монда, терраса алдында гына, балкып янган куе кызыл, ак, сары геогрин, астра (йолдыз) чәчәкләре... Һәм шуларның барысыннан Рәшидәгә бөтенләй билгесез, ләкин укыпмы-ишетепме хыялында сакланган нindидер борынгы дворяннар тормышы кинәт аңкыгандай булды... Ул бик азга гына тукталып калды һәм ихтыярсыз бер тыннан әйтеп ташлады:

— Мату-ур!

Шунда ук аның күзләрендә балаларча самими, якты сөенү кабынды. Җиңел генә түбән төште, түтәл тирәсен әйләнә-әйләнә чәчәкләрнең әле берсен, әле икенчесен иелеп исни башлады. Зөфәр, аңа карап, куана калды — ул белә инде, Рәшидә болай сөенеп, рухланып киткән чагында аңа бик ышанучан, назлы һәм күндәм була торган иде.

— Рәшидә, чәчәкләрнең матурларын гына өзеп биримме? — диде ул.

— Юк, юк, кирәкми,— диде Рәшидә, ашыгып.— Җәлләмичә өзәргә ярыймы соң!

Зөфәр кыстамады, ул үзе дә чәчәкләрне өзәргә яки өздерергә яратмый иде... Бакчаның түренәрәк уздылар. Рәшидә әле бер, әле икенче агач янында тукталды, күтәрелеп карады, тирә-ягына каранды һәм гаҗәпләнеп сорады:

— Бу бакчаны кем карый соң?

— Күбрәк әни, сеңелкәш карыйлар, үзем дә буш вакытта казынам,— диде Зөфәр.— Дөрес, башта бер карт килеп, тәртипкә китереп, безне өйрәтеп китте. Безнең өчен яңа эш бит әле бу... Йә, ничек соң, ошыймы сиңа бакча?

— Ошый, бик матур!

— Аңа әле карау җитми. Әнигә авыр, сеңелкәш рәтен белми, үзем бушый алмыйм. Караучы кирәк.

— Кеше ялла.

— Юк, ни өчен ялларга?.. Ялларга ярамый... Монда тагын... бер хуҗа кирәк.

— Нинди хуҗа?

— Менә минем үзем кебек.

Рәшидә, аңлап җитмәгәндәй, Зөфәргә күтәрелеп карады һәм шунда ук күзен түбән төшерде. Гүя үзен көчләп кенә әйтте:

— Анысын да табарсың.

— Ә кемне? — диде Зөфәр, сак кына.

Рәшидә алгарак узып, исе киткән булып, карт алмагачка карап тора башлады. Зөфәр моның җаваптан качу икәнен сизде. Алмагачның кып-кызыл алмалар сырган өстәге бер ботагын Рәшидә алдына бөгеп төшерде.

— Йә, иң әйбәтләрен генә үз кулың белән өзеп ал әле!

Рәшидә үзе дә ни өчендер алмадай кызарды, аз гына кыюсызланып торды, аннары сайламыйча гына берсенә үрелде.

— Анысын түгел, менә боларын.

— Барыбер инде.

— Барыбер түгел шул. Зуррагын, пешкәнрәген.

Рәшидә Зөфәр күрсәткән алмалардан берсен генә өзеп алды.

— Нигә берне генә,— диде Зөфәр.— Өз әле, өз!

— Юк, җитте, мин алманы берьюлы күп ашый алмыйм, тешем камаша.

— Кесәңә салырсың.

— Кесәм юк,— диде Рәшидә, ничектер бик уңайсызланып.

Зөфәр алмагач ботагын кире җибәрде. Рәшидәнең уңайсызлануына юри игътибар итмәскә тырышып:

— Ярый алайса,— диде,— киткән чагында мин сиңа пакетка салып бирермен.

...Алар өйгә таба борылдылар. Зөфәр Рәшидәнең култыгыннан алды. Ничек тә яшь ханымны юатасы, юмалыйсы килә иде.

— Сиңа ничектер, сөеклем, ә миңа бик рәхәт бит әле,— диде ул, Рәшидәнең беләген үзенә ныграк кысып.

— Нидән ул? — диде Рәшидә, акрын гына.

— Нидәнме?.. Синең белән аулак бакчада менә шулай икәүдән-икәү генә йөргәнгә күрәдер инде... Беләсеңме, көн дә мин сине бу бакчада култыклап кына йөртер идем.

Рәшидә уйчан-боек кына елмайды, ләкин кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Бу бакчага чыгу белән аңарда кабынган балаларча сөенү нишләптер акрын гына сүнә башлаган иде инде.

Өйгә керделәр. Зөфәр, бүлмәдән бүлмәгә күчеп, Рәшидәгә өен күрсәтте. Рәшидә аңа ияреп, якты, зур, ләкин җиһаз җитмәгәнлектән күбесе шактый шәрә күренгән бүлмәләрне сүзсез генә карап йөрде. Инде Зөфәр аны үзенең өр-яңа никель карават куелган, стенасына

һәм идәненә кыйммәтле келәмнәр түшәлгән йокы бүлмәсенә алып кергәч, Рәшидә ишектән ерак узмыйча тукталып калды. Әйтерсең аны нидер куркытты. Ә Зөфәр, аны-моны абайламыйча:

— Бу инде минем спальный була,— дип сөйләнде.— Ялгыз ир бүлмәсе, сиңа бераз шыксыз күренәдер инде... Уютный итәр өчен хатын-кыз кулы кирәк шул, дөресме?

Рәшидә, нидер уйланып, башын гына кагып торды. Зөфәр исәбенчә, бу бүлмәдән күз йөртеп кенә кире борылырга ярамый иде. Бу бүлмәдә алар арасындагы менә хәзерге һич аңлашылмаган әллә нинди киеренке салкынлык бетәргә, яңадан элекке җылы якынлык туарга тиеш иде. Моның өчен күп тә кирәкми, сынаганы бар, әгәр шушы урында ул Рәшидәне кочагына алып, юмалап-сөеп кенә бер назласа, ханым балавыз кебек йомшарып калачак. Әйе, бары шулай гына... Һәм ул Рәшидәнең алдына басты да кинәт кенә биленнән кочып, иелеп, кайнар пышылдап: «Син генә җитмисең монда, син генә!» — дия-дия аның битеннән, иреннәреннән кызу-кызу үбәргә тотынды. Рәшидә бер мәлгә онытылып, сеңеп калды, ләкин Зөфәрнең, аны кочаклаган килеш, караватка таба чигенә башлавын күргәч, кинәт башын артка ташлап, ике кулы белән дә егет күкрәгенә терәлде.

— Җибәр! — диде ул, куркуыннан хәтта тавышсыз калып.

— Йә инде, Рәшидә, бәгырем, йә инде!

— Юк, юк, җибәр! — диде Рәшидә, бөтен көченә карышып.

Зөфәр аны таза кулларыннан ычкындырмыйча аз гына тукталып, тәмам исе китеп, кайнарланып сорады:

— Ни өчен соң, йә, ни өчен?

— Юк, юк, булмый, мөмкин түгел! — Һәм Рәшидә, кисәк кенә чүгеп, егетнең кочагыннан шуып чыкты да бер адым артка чигенде.

Зөфәрнең йөзе берьюлы бүртенеп китте, күзләре кысылып калды, яңак сөякләре уйнаклап куйды. Көчкә тынын алып, усалланып әйтте ул:

— Ә тегендә... Островскийда ярый иде?

— Әйе, анда ярый иде, анда без бертигез идек,— диде Рәшидә, кабаланып һәм ярсып.— Ә монда юк, монда теләмим, монда мин хурланам, хурланам, аңлыйсыңмы?.. Ходаем, кемгә генә саныйсың соң син мине?! — Һәм кычкырып елап җибәрмәс өчен ул бүлмәдән атылып чыгып китте.

Зөфәр беравык, үгездәй башын иеп, уң чигәсен ыш-

кып торды. Берни уйлый алмаса да: «Тынычланырга кирәк, тынычланырга!» — диде ул үз-үзенә, аннары авыр гына кузгалып, Рәшидә артыннан залга чыкты.

Рәшидә урамга караган тәрәзә янында басып тора иде. Иңбашлары салынган, ләкин кызларныкыдай нечкә фигурасы, оеп калгандай, ничектер бик тын-хәрәкәтсез күренә. Юк, еламый булса кирәк... Зөфәр аның артынарак барып басты. Гаҗәп авыр тынлык һәм бушлык. Шактый сүзсез торганнан соң, Зөфәр акрын гына әйтеп куйды:

— Аңламыйм, һичнәрсә аңламыйм! Әллә ни булды...

Рәшидә дәшмәде, селкенмәде. Зөфәр аның аз гына бөгелә төшкән тигез аркасына, чәч бөртекләре арасыннан күренгән нечкә муенына, яңадан орынасы килеп, карап торды.

— Бик ачуландыңмы?

— Юк,— диде Рәшидә, көттереп, сүлпән генә.

— Чынмы?

Рәшидә тирән итеп бер сулады:

— Үзем гаепле, белеп килдем бит...

— Нәрсәне?

— Ни өчен генә чакыруыңны... Ярый, мин китим инде.

Рәшидә тәрәзәдән борылды — йөзе бик боек, күзләре тәмам сүнгән иде аның.

— Тукта, Рәшидә, ашыкма! — диде Зөфәр, аңа юл бирергә теләмичә.— Безгә сөйләшергә кирәк.

— Тагын нәрсә турында инде?..

— Бар әле, бар... Сөйләшмичә булмый...— Ул Рәшидәгә урындык алып куйды.— Утыр әле шунда, утыр!

Рәшидә, аз гына икеләнеп торганнан соң, урындыкның читенә генә утырды. Зөфәр, икенче урындыкны тартып, аның каршысына утырды да... тезләренә таянып, уйга калды. Нәрсәдән, ничек кенә итеп сүз башларга да авыр иде аңа. Рәшидәнең һич көтмәгәндә бу кадәр кинәт һәм кискен рәвештә каршылык күрсәтүе аны тәмам аптырауга төшерде, киртәсеннән чыгарды, бөтен исәп-планнарын аударып ташлады. Искиткеч мәгънәсез, ямьсез, читен бер хәлгә куйды ул үзен! Һәм шушы хәлдән ничектер чыгарга кирәк. Алай гына да түгел, менә хәзер тагын да ныграк суына, ераклаша, читләшә төшкән Рәшидәгә үзенең асыл теләген ничек тә ышандырырлык итеп аңлата белергә тиеш ул. Читен мәсьәлә. Гомумән, ул бүген, роленә керә алмаган артист шикелле, ни үзен, ни сүзен таба алмыйча азаплана — гомердә булмаган хәл.

— Рәшидә,— диде ул, ниһаять, иелгән килеш кыенсынып кына,— иң элек син мине кичер, яме! Минем хәлемә дә кер. Мин бит сине... яратам, сиңа бик иярләштем, ну... ачык кына әйткәндә, сине теләмичә тора алмыйм мин... Моны үзең дә беләсең бит. Минем генә гаеп түгел ич!..— Ул куркынып Рәшидәгә күтәрелеп карады һәм аның, теше авырткандай, чыраен сыта башлавын күреп, тизрәк сүзен дәвам иттерде: — Ләкин, Рәшидә бәгырем, әгәр син бу мине бары шуның өчен генә чакырган дип уйласаң, бик нык ялгышасың. Әйе, ялгышасың!.. Аңла, бер дә аның өчен генә түгел. Бөтенләй икенче максат белән чакырдым мин сине... Бик зур сүз әйтү өчен... Әйе, бик җитди мәсьәлә турында, беләсең килсә! — Ул, Рәшидәдән берәр сүз ишетергә теләп булса кирәк, тагын бер генә мизгелгә тукталып калды. Ләкин Рәшидә, куркып очарга торган кош шикелле, ничектер бик текә-киеренке утыра иде. Зөфәр сак кына аның кулын алды: — Әйтим алайса... Мин... өйләнергә булдым, менә сиңа өйләнергә, аңлыйсыңмы, Рәшидә, сиңа!

Рәшидә ток бәргәндәй сискәнеп китте һәм тирән әрнү белән өзгәләнеп әйтеп ташлады:

— Уйнама, Зөфәр!

— Юк, нишләп уйныйм, ди. Алла сакласын! Мин сиңа чынлап әйтәм, Рәшидә!

— Юк, юк, ышанмыйм!

— Ни өчен?.. Тукта, син иң элек тынычлан әле, тынычлан! Хәзер барысын да аңлатып бирермен.

Рәшидә, ике кулы белән битен каплап, күпмедер тынып торды, аннары йөзен ачты, турайды һәм шик, өмет, газап тулы күзләре белән үтә җитди итеп Зөфәргә карап тора башлады.

— Син беләсең,— диде Зөфәр, бу караштан ихтыярсыз борчылып,— мин ялгыз кеше, миңа өйләнергә кирәк. Бу бик аңлашыла торган нәрсә бит инде... Тик мәсьәлә — кемгә?.. Иң читене шул бит? Бу турыда мин бик күп уйландым. Синнән яшерәсем килми, сайларга кызлар бар иде... Ләкин мин ашыкмадым, күңелемә ошаганны эзләдем. Һәм таптым. Ул — син, Рәшидә, син, ышанасыңмы?.. Өч ел бит инде мин синең белән йөрим, сине беләм, җитәрлек өйрәндем, чынлап яраттым...

Рәшидә иңерәнеп куйды:

— Ходаем, өч ел буе йөреп, ник бер сүз әйтсәң иде! Нинди кеше син?!

— Алай димәле, Рәшидә! Һәр эшнең үз җае, үз вакы-

ты бар. Иң элек мин ныклы бер карарга килмичә торып, алдан шауларга яратмыйм. Икенчедән, өйләнүгә мин җиңел генә карый алмыйм. Сүз бит семья кору турында бара. Моның өчен мин булачак семьяның башта, ничек дим, материаль нигезен салырга тиеш идем. Ә бу күп көч, күп вакыт сорый торган нәрсә. Былтыр менә шушы йортны сатып алдым, быел аны төзәттердем, яңарттым... Җиһазлар алдым... Хәзер ул яктан кайгы бетте диярлек. Инде менә...

— Димәк, барысы да план белән?

— Әйе... Нигә, начармыни ул?

— Юк, начар димим... Хәер, белмим, аңламыйм мин берни дә.

— Син бер генә нәрсәне аңларга тырыш, җанкисәгем! —диде Зөфәр, аның кулын йомшак кына сыйпап.— Мин сиңа өйләнергә телим, мин сине шушы йортка чакырам. Бергә торырга, яратышып, бәхетле булып торырга... аңлыйсыңмы?

Рәшидә әкрен һәм тирән итеп сулый иде. Аның хәтта куллары да суына төште, тезләре дә акрын гына калтырый башлады... Зөфәр, өч ел буена аның җанына һәм тәненә хуҗа булып килгән Зөфәр, менә аңа өйләнергә тели! Ярабби!.. Бәлки, бу аның өчен бердәнбер мөмкинлектер, әйе, ир хатыны, семья кешесе булыр өчен бердәнбер кабатланмас мөмкинлектер? Бәлки аның бәхете шушы йортта, шушы кеше кулындадыр? Аңа ялгызлыктан, нуҗадан йөдәгән билгесез артисткага тагын ни көтәргә кирәк?.. Әмма мөмкин эшме бу?

Зөфәр көлемсерәп әкрен генә сорады:

— Йә, ни дисең, сөеклем?

— Белмим, күзем җитми, ышана алмыйм мин бу эшкә!

— Гаҗәп!.. Ничек ышанмыйсың? Мин әйтәм ич сиңа моны, мин әйтәм, чынлап торып... Ишетәсеңме?

Рәшидә гүя хәлсез бер гаҗизлектән кинәт үксеп җибәрде:

— Газап... газаплама мине, Зөфәр!

Зөфәр җитез генә үрелеп, аны аркасыннан кочаклап алды:

— Чү, ярамый болай!.. Тынычлан, иркәм, тынычлан!.. Менә шулай!..— Ул якынрак шуышып, Рәшидәне күкрәгенә кысты.— Җүләрем, газаплаумыни бу?.. Бәхет турында сөйлим ич мин сиңа, бәхет турында! Мин... мин... сине көне-төне менә шулай назлап-сөеп кенә торырмын, рәхәттә йөздерермен мин сине... Бер кайгың,

бер нужаң булмас синең... Менә бу йорт, менә бу җиһазлар, әнә теге гөлбакча — барысы да синеке булыр... Хуҗа булып, хуҗа гына түгел, бикә булып торырсың!.. Йә, бу бәхет түгелмени, сөеклем?

— Куркам мин бу бәхеттән,— диде Рәшидә, Зөфәрнең күкрәгенә пышылдап кына.

— Тиле, тиле! Бәхеттән куркалармыни?! Бәхетне аны тилмереп эзлиләр, аулыйлар, кирәксә, сугышып, тартып алалар!

Һәм ул, яңадан кабынып, тагын да ныграк елышып, Рәшидәнең түшләренә кулын салды, Рәшидә айнып киткәндәй булды.

— Тукта, кирәкми, җибәр! — диде ул, тизрәк Зөфәрдән тайпылып.

Зөфәр кисәк кенә көлеп куйды:

— Никахтан соң дисеңмени инде?

Үткен пычактай телеп җибәрде бу сүзләр Рәшидәнең йөрәген, тирән сызланудан йөзе сытылып китте:

— Көләсең?

— Юк, юк, бетте! — диде Зөфәр, ашыгып.— Мин болай гына, шаяртып кына... Ачуланма!.. Соң бит инде син минем хатыным, фактически хатыным, шулай түгелмени? Нигә дөреслектән куркырга? Ә тиздән законный хатыным булырсың! Мин шуны телим, бик телим, син дә теләргә тиешсең!.. Үзең өчен бит? Йә, ник дәшмисең?

Рәшидә әллә аптыраудан, әллә килешә алмаудан сүзсез, акрын гына башын чайкап торды.

— Нигә башыңны чайкыйсың? Мин әйткәннәр дөрес түгелмени?

— Дөрес,— диде Рәшидә, авыр көрсенеп.— Кызганычка каршы, дөрес!.. Синең өчен мин бары хатын гына булдым шул, хатын гына... шуңардан башканы син миндә күрмәдең дә, белмәдең дә... Хәер, бүтәнчә булуы мөмкин идемени? Синең үз дөньяң, минем үз дөньям!..

— Башта ук ул шулай иде бит, Рәшидә!.. Ләкин шуңа карамастан без якынаеп киттек ләбаса!

— Зинһар, үткәнне искә төшермик инде...

— Юк, шулай да,— диде Зөфәр, Рәшидәнең гаебен тоткандай кыюланып,— әйт әле, ни өчен башта син безнең дөньялар башка булуы турында уйламадың?

Рәшидә үпкә-рәнҗү тулы күзләре белән Зөфәргә күтәрелеп карады:

— Нинди йөз белән син моны әйтәсең, Зөфәр? Нигә

минем ярама кагыласың?.. Беләсең ич... ничек булганын!.. Әйтерсең мин генә гаепле!

— Мин сине гаепләргә җыенмыйм, Рәшидә. Тик шуны гына исеңә төшерәсем килә: мин һаман шул ук кеше бит!

— Әйе, син шул ук кеше... шул ук кеше,— диде Рәшидә, ничектер уйга калып...— Хәер, белмим тагын... шул укмы син, түгелме?.. Тик бер нәрсәне тоям: без... ерак кешеләр.

— Ни өчен ерак?

— Шулай инде... Хәтерлисеңдер, соңгы вакытларда мин синнән: кем син, Зөфәр, кем? дип өзелеп сорый торган идем. Тикмәгә түгел бит ул, төрле шикләрдән аптырап йөргәнгә күрә бит ул... Дөрес, моңарчы мин сине яхшы кешегә, саф кешегә санап килдем. Әгәр моннан бер ел элек кенә син миңа өйләнергә теләвеңне әйткән булсаң, минем түбәм күккә тигән булыр иде. Мәхәббәт дияр идем мин моны, без бергә булырга тиешле кешеләр дип, чын күңелемнән ышанган булыр идем. Ә хәзер... мин ни әйтергә дә белмим... Менә йорт кадәр йорт алгансың —аны миннән яшергәнсең; ни өчен, ни сәбәптән — моны мин, үтер, аңлый алмыйм. Йорт мине кызыксындыра икән дип уйлый күрмә, һич юк, мин аның кирәклеген дә белмим, тик әле шушындый зур эшне дә яраткан кешеңнән яшереп була микәнни дип шаккатам!.. Аннары, сүзең чын булса, миңа өйләнергә күптән уең булган, имеш —аны да яшереп килгәнсең... Ходаем, бу ни хәл соң бу, өч ел буена яратам дип йөр, өч ел буена минем мәхәббәтемнән файдалан, ә чын теләгеңне бер генә мәртәбә дә, ичмасам, ялгыш кына да әйтмә, белдермә, имеш! Нинди генә кеше болай эшли ала, Зөфәр, әйт, нинди генә кеше?!

— Тукта, Рәшидә, нигә син боларның барысын да шулхәтле куертасың әле! — диде Зөфәр, чын-чыннан тынычсызлана башлап.— Ярый, мин сиңа моңарчы отчет биреп бармаганмын, ди, бу минем зур хатам, ди, ләкин менә хәзер мин сиңа барысын да әйттем бит, ачып салдым, руслар әйтмешли, товар лицом! Тагын ни кирәк?

— Миңа сине аңлау кирәк, Зөфәр, беткәнче аңлау кирәк! — диде Рәшидә, газаплы бер җитдилек белән.— Югыйсә мин ышана алмыйм, миндә шик кала, авыр шик!.. Синең бүген миңа өйләнергә телим, дип әйтүең чын ихластанмы ул, әллә берәр коры исәптән генәме? Өйләнгәннән соң да синең миннән яшерен гамәлең, яшерен тормышың

булмасмы?.. Алла сакласын, әгәр шулай була калса, син вәгъдә иткән бәхетле тормыш ул минем өчен далада уйнаклап югалган кайнар рәшәгә әйләнер иде!.. Син беләсеңме рәшәнең нәрсә икәнен? Мин күп йөргәч, беләм аны, күргәнем бар... Тип-тигез дала түрендә менә бервакытны ялтырап яткан күл ачыла. Чын күл бу, хәтта җем-җем уйнаклаган вак дулкыннарына кадәр күренә. Менә шуңа карап барасың, барасың, ләкин күпме генә барсаң да теге күлгә барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-котыртып уйнаклаган эссе шәүлә генә. Менә шулай ул, дустым, кайчагында кешенең нигезсез, булмас өмете дә рәшә төсле юкка чыга...

Зөфәр, иреннәрен кысып, алга иелде. Аңа хәтта эссе булып китте. Кылт итеп, теге вакытта, Җиңү көне таңында күргән төше хәтеренә килде. Рәшә! Аның сусаудан шашынган күзләре алдында кинәт ачылып киткән күл — чын күл түгел идемени, ул да рәшә генә идемени? Булмас, булмас! Алай юрамаган иде ул газаплы, әмма куанычлы төшен!.. Бәхеткә юраган иде, бәхеткә!.. Рәшә, юк, бу мөмкин түгел! Аның күңелендә хәтта, Рәшидәне өенә чакырып, менә хәзер аны өйләнергә кыстап утыруы өчен үкенү кебек бер нәрсә дә кыймылдап куйды. Ләкин ул чигенергә теләмәде, чигенү ярамый иде... Эченнән сиздермичә генә сулап:

— Үткән эшкә салават! — Ә киләчәк турында алдан ук начарга юрамыйк әле, Рәшидә. Тормышны матур итеп кору безнең кулда. Кыскасы, Рәшидә җаным, мин сиңа үземнең чын теләгемне әйттем. Хәзер синең җавабыңны көтәм, йә, ни дисең?

Рәшидә уйланып, кечкенә йодрыгын башына терәп торды:

— Белмим. Хәзергә берни дә әйтә алмыйм. Миңа уйларга кирәк, уйларга, уйларга!

Зөфәр, борчылып, аның бик йончып киткән йөзенә карады.

— Алай... җитди мәсьәлә. Азрак уйларга кирәктер шул... Ләкин син, Рәшидә, мине озак зарыктырмассың бит?

— Киткәнче әйтермен.

— Киткәнче? Кая киткәнче?

— Минзәләгә.

— Минзәләгә? Ни өчен Минзәләгә?

— Минзәлә театры чакыра мине...

— Туктале, Рәшидә! Әллә ни сөйлисең! Кеше, Казанны ташлап, Минзәләгә китәме соң?!

— Миңа сәхнә кирәк,— диде Рәшидә.— Сәхнә өчен мин җир читенә китәргә дә риза!

— Ә монда?

— Монда алмыйлар, урын юк, диләр.

— Сабыр ит, Рәшидә! — диде Зөфәр, җанланып.— Мин үзем сөйләшәм. Театр җитәкчеләренең миңа һәрвакыт йомышлары төшә, мин сорасам — берсүзсез сине алачаклар.

Рәшидә башта гаҗәпләнгән, хәтта куанган төсле булды, аннары нидер чамалагандай кинәт җитдиләнеп, кашларын җыерып беравык Зөфәргә текәлеп торды.

— Аңламыйм мин сине, Зөфәр, аңламыйм,— диде ул, ниһаять, акрын гына.— Ни өчен син менә хәзер генә бу турыда әйтәсең? Ни өчен элегрәк, сүзең үтәрдәй булгач, сөйләшергә уйламадың?.. Кайчаннан бирле минем театрга керергә теләп, хыялланып, азапланып йөрүемне белдең бит, белдең!

Зөфәр бер генә секундка бик уңайсызланып китте, ләкин бу читен хәлдән тизрәк чыгар өчен елмайган булып, башын селкеп әйтте:

— Һе, син, ни, дустым, миннән гаеп табарга гына торасың. Бигрәк!.. Ярамый бит болай... Элегрәк ни, хәзер ни — эш узмаган ич әле!

— Юк, эш узган! — диде Рәшидә һәм капыл гына урыныннан торды.— Бел, үзеңә кирәк булгач кына күрсәтергә теләгән ярдәмеңне мин кабул итә алмыйм!

— Рәшидә, акыллым, ул хәтле кырт кисмәле!.. Ну, ярый, үзем өчен дә ди, ләкин минем протекция барыбер синең файдага ич ул!

— Юк, юк, үзең дә, протекцияң дә кирәкми миңа... Булмый, теләмим, әллә нинди кеше син!.. Ышанмыйм мин сиңа!

Зөфәр берьюлы үзгәреп, кисәк кенә аңа таба омтылды.

— Тукта, тукта...

— Орынма миңа! — диде Рәшидә, агарынып, һәм кинәт борылып, ишеккә атлады.

— Рәшидә!!

Ләкин Рәшидә, җилдәй, залдан, аннары өйдән үк чыгып китте... Бер мәлгә аптырап, катып калган Зөфәр, кинәт урыныннан кубып, аның артыннан ташланды. Парадный ишеге янында артыннан җитеп, беләгеннән тотып алды.

— Рәшидә, тукта, качма! — диде ул, көчкә тынын алып.

Рәшидә тирләгән, ярсыган, тешләшергә торган кеч-кенә җәнлектәй аңа шундый бер ялвару, куркыну, нәфрәт белән карады ки, Зөфәр ихтыярсыз аның беләген ычкындырды... Шап итеп парадный ишеге ябылды, һәм Рәшидә яшьләрен йота-йота, шак-шок атлап, тын урам буйлап китеп тә барды.

...Зөфәр, ябык ишеккә маңгае белән терәлә язып, күпмедер вакыт өнсез, хәрәкәтсез басып торганнан соң акрын гына кузгалып, өйгә керде. Ләкин монда калу мөмкин түгел иде, әйтерсең тып-тын, буш өйнең эчендә шак-шок, шак-шок ераклашкан аяк тавышы яңгырый иде... Зөфәр ава-түнә террасага чыкты һәм, хәлсезләнеп, башын учлап, аның баскычына утырды... Китте... өзел-де... бетте...

Рәшиданең качуы Зөфәрне чынлап та тамырыннан кискәндәй итте. Атна-ун көн ул, яңгыратылган балык шикелле, әйле-шәйлерәк бер хәлдә йөрде. Кая барса да, нишләсә дә аны Рәшиданең соңгы минутта шундый бер җан өшеткеч ачу-нәфрәт белән аңа каравы һич күз ал-дыннан китмичә азаплады. Нинди тирән упкын алар ара-сында яткан икән!.. Ул шуны, артисткага ышанып бет-мичә йөрүенә карамастан, ничектер алдан күрә белмәгән. Коточкыч сукырлык!.. Хәзер инде аңа көн кебек ачык: Рәшидәгә өйләнергә теләве бөтенләй нигезсез, кысыр бер хыял гына булган икән. Менә шул хыял җимерелде дә төште... Китте, югалды Рәшидә аның өчен — бөтенләйгә, мәңгегә!..

Хәер, Рәшиданең югалуы белән килешергә дә, акрын-лап аны онытырга да мөмкин булыр иде, тик шунысы яман — сизгер күңелле яшь артистка ничектер аның иманын да какшатып китте. Гомерендә беренче мәртәбә ул үзенең киләчәгенә шикләнеп, шомланып карарга мәҗбүр булды. Рәшидә бит аның үзеннән генә түгел, ул вәгъдә иткән тормыштан да гүя куркып качты. Рәшә булып чыкмасын, диде. Рәшә — менә нәрсә куркыныч икән. Һәм Зөфәр күбрәк шуны уйлап борчылды, шуңар-дан шомланып йөрде, кайчандыр күргән төшен түгел, ә реаль киләчәген юрап азапланды, кыскасы, рәшә дигән шул алдакчы томанны ничек тә күз алдыннан куарга тырышты.

Әйе, юкка гына аны Зөфәр Сабитов димиләр. Күпме-дер вакыт үтүгә ул үзенең «реаль» уйлый торган салкын акылына кайтты. Моңарчы гел бер юнәлештә эшләп килгән логикасы яңадан сәгать механизмы кебек эшли

башлады. Ни өчен әле мин бу кадәр каушап калдым, диде ул, үз-үзенә ачуы килеп. Шул хыялый бер хатынның киртә җимерүеннәнме? Ни белә ул, нәрсә күргән ул?.. Гади бер хакыйкатьне аңламый ич ул: һәркем үз бәхете өчен көрәшә, һәркем тормышын үзе теләгәнчә корырга омтыла. Баерак, иркенрәк, рәхәтрәк яшәргә теләүче әллә бер мин генәме? Юк, алар күп, бик күп, бөтен дөнья, бөтен галәм! Бәс, шулай булгач, ни өчен мин үземнең теләкләремнән баш тартырга тиешмен? Ни өчен мин дә бу дөньяда үзем теләгәнчә яшәп калмаска тиешмен?! Әллә минем кулымнан килмәсме ул?.. Юк, килер, Алла бирсә, килер, рәтен-җаен табарбыз без аның... Өркетмәсеннәр!

Шулай диде ул үз-үзенә тискәре бер үҗәтлек белән һәм шушы иманында ничек тә ныгып калырга тырышты. Аның юлы сызылган, кая гына алып барып чыкмасын, ул инде аңардан чигенмәячәк, юк, чигенмәячәк... Әмма күпме генә ул шулай батырланмасын, теге электән үк күңеле төбендә яткан, шуның өстенә Рәшидә дә көчәйтеп киткән курку-шомлану барыбер бетмәде. Бу курку-шомлану аның тырыш, уңган, хәйләкәр, ялагай табигатенең астарлыгы булып кала бирде.

Ә ике айдан соң Зөфәр Гамбәр туташка өйләнеп ташлады. Кыз, ичмасам, диде ул үзен юаткан булып... Гамбәр туташ та бәхетле иде. Очлы иякле мөлаем йөзен кечкенә көнбагыштай күтәреп, Зөфәренә, «хуҗам!» дигәндәй, карап кына тора иде ул. Ләкин Зөфәр аңа беренче көннәрдән үк шаярткан булып әйтеп куйды: «Сиңа, орчыгым, башыңны түбән иеп кенә тору килешә!» — диде.

Шау-шулы зур мәҗлесләрне Зөфәр артык яратмаса да, туйны бик шәп үткәрде. Ниндидер ярсыну һәм үчләнү белән дөньясын бер селкетеп алырга теләде. Әүвәл-ахыры шул булсын диде бугай... Кыз квартирасында яшерен никах укытып, бер мәҗлес үткәргәч, ул үз өендә өч көн рәттән шаулатып туй ясады. Кичләрен зур йортның барлык тәрәзәләре ялт итеп торды. Соңгы мәҗлескә үзе белән элек эшләгән һәм яңа урында танышкан иң мөхтәрәм кешеләрне генә чакырды. Ләкин бу мәҗлесләрнең берсенә дә ул — ни гаҗәптер — Хәмит дустын чакырмады. Моның сәбәбе, билгеле, бик тирән һәм катлаулы булырга тиеш иде. Шушы биләмче, ялгызак егетнең көннәр буе буш яткан бүлмәсендә ул Рәшидә белән хәзер инде айга карап уласаң да кире кайтмас, иң бәхетле минутларын кичерде; ихтимал, шул минутларны исенә

төшерүдән куркып, якын дустын Гамбәр туенда күрәсе килмәгәндер; ихтимал, яңа тормыш башлар алдыннан Хәмит шикелле аның бөтен үткәнен белеп торучы кешедән котыласы килгәндер... Бик мөмкин, әмма болар өстенә тагын бер җитди сәбәп бар иде: ул да булса — Әйттем-бетте Хәмитнең рәхимсез усал теле!.. Шушы теле белән ул Зөфәр дустын, бритва тидереп алгандай, һаман кисә генә торды. Бигрәк тә соңгы вакытларда аеруча бер канығу белән Зөфәрнең һәр хәрәкәтенә, һәр эшенә тамга салгандай үзенең кара мөһерен баса барды. Хәтта, Зөфәргә авыр булсын дип, Гамбәр туташны да аяп тормады: — Гамбәр килен — алтын чебен! — диде ул, юри көйләгән булып кына, әмма ниндидер бер ямьсез нәрсәгә ишарә ясап.

Һәм Зөфәр түзмәде, күтәрә алмады, үзенең кара күләгәсеннән качкан шикелле, иң якын сердәшче дустыннан качарга мәҗбүр булды.

...Озак кына уйлаганнан соң, Зөфәр туй мәҗлесенә шулай ук иптәш Әхмәтҗановны да чакырмаска булды. Әлбәттә, бу инде Әйттем-бетте Хәмит түгел, иң югары начальник, гаять кирәкле кеше, ләкин шулай да аны чакырырга иртәрәк иде әле. Кем белә, бәлки киләчәктә аңардан рекомендация сорарга да туры килер... Тормыш бу... Исәп белә торырга кирәк!.. Әйе, бары тик исәп белән, исәп белән, исәп белән, кадалып киткере!

*1962*

# ЭЧТӘЛЕК

**Уяну (Рәхмәт, иптәшләр!)**

5

**Саз чәчәге**

117

**«Йөрәк сере»**

173

**Рәшә**

269

Литературно-художественное издание

*Амирхан Еники*
*(Еникеев Амирхан Нигметзянович)*

**СОЧИНЕНИЯ В ПЯТИ ТОМАХ**

**том 2**

*Повести*

(на татарском языке)

Нәшрият мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *В.В.Фомин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *З.А.Даутова, Г.Х.Сундукова, Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән

Оригинал макеттан басарга кул куелды 16.10.2001.
Форматы 84×108$^{1}/_{32}$. ВХИ кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 23,52+ф.0,21.
Шартлы буяу-оттиск 23,94. Нәшер-хисап табагы 25,42+ф.0,36.
Тиражы 5000. Заказ А-442.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур.,19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул.Баумана,19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Татарстан газета-журнал нәшрияты» Дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.